ISSN 0206-418

# КАЗАН УТЛАРЫ

11. 1998



# JAZUCЬLARЬBЬZ CIT ILLƏRDƏ



Ədip — akademik *Mirqasьjm Ƣosmanof* Vengriədə. Anьꞑ jənəşəsendə ƣalimnər *Edvard Lazzerini (AQŞ), Iştvan Zimoni (Vengriə). 1997 jьl.*



Jazucь *Rabit Batulla* həm ƣalim *Çəmil Zəjnullin* Orevisi universitetь rektorь *Salli* əfənde belən *(Finləndiə).*

# Казан утлары
# Qazan utlarь

1998

11

(913)

ОЕШТЫРУЧЫЛАРЫ:

**Татарстан хөкүмәте,**
**Татарстан Язучылар берлеге,**
**редакциянең хезмәт коллективы**

Баш мөхәррире
**Равил Фәйзуллин**

**Идарә:**
Гариф Ахунов, Харрас Әюпов, Нәҗип Бакиров, Хәлим Гайнуллин, Тәлгат Галиуллин, Миркасыйм Госманов, Аяз Гыйләҗев, Флүс Латыйфи (*баш мөхәррир урынбасары*), Салих Маннапов, Туфан Миңнуллин, Хатип Миңнегулов, Ринат Мөхәммәдиев, Нажар Нәҗми, Рашат Низамиев, Булат Солтанбәков, Ренат Харис, Розалина Шаһиева.

**Мөхәррирләр:**
Мансур Вәли, Наис Гамбәр, Рәдиф Гаташ, Алмаз Гыймадиев, Шамил Маннапов, Шаһинур Мостафин, Марс Шабаев.

**Гамәли хезмәткәрләр:**
Тәслимә Сибгатуллина, Гөлзадә Фәйзуллина, Лилия Гатауллина, Альбина Әхмәтова, Флера Сабирова, Тәгъзимә Шиһабиева.

**Исәп-хисап бүлеге:**
Асия Рәхимова.

✉✉:
420066, Казан, Декабристлар урамы, 2.
☎☎:
Баш мөхәррир — 49-36-60.
Баш мөхәррир урынбасары — 49-36-09.
Җаваплы сәркәтип һәм компьютер үзәге — 43-56-12.
Бүлекләр: шигърият, фән, сәнгать — 49-36-61, чәчмә әсәрләр, хатлар, тәнкыйть — 49-36-63, корректорлар — 49-36-65.
Исәп-хисап бүлеге — 43-56-12.

# КАЗАН УТЛАРЫ

ӘДӘБИ-НӘФИС ҺӘМ ИҖТИМАГЫЙ-СӘЯСИ ЖУРНАЛ

1922 ЕЛНЫҢ МАЙ АЕННАН БАШЛАП ЧЫГА

## *Бу санда*

ШИГЪРИЯТ ҺӘМ ЧӘЧМӘ ӘСӘРЛӘР

Ркаил ЗӘЙДУЛЛА. Шигъри тәфсирләр ..... 5
Мансур ШАҺИМӘРДӘН. Татлы агу. *Роман* ..... 11
Рашат НИЗАМИЕВ. Жилләр сыман, су агышы сыман... *Шигырьләр* ..... 55
Фәйзи ГАЛИЕВ. Әтнә - күнелем бишеге. *Истәлекләр* ..... 61
Рәдиф ГАТАШ. Салисәбез турында ..... 85
Салисә ГӘРӘЕВА. Симфония. *Шигырьләр* ..... 86
Шамил МАННАПОВ. Гали батыр оныгы ..... 91
Әсрар ГАЛИ. Лаеш шулпасы. *Хикәя* ..... 94
Әсгать САЛАХ. Балыкчы малайлар. *Хикәя* ..... 106
Флера ТАРХАНОВА. Нәүмиз күнелем кабат канатлана. *Шигырьләр* ..... 115

ДРАМАТУРГИЯ

Фоат САДРИЕВ. Яшьләй сөйгән ярлар. *Пьеса* ..... 118

ПУБЛИЦИСТИКА

Нургаян ӘКБӘРОВ. Шәфкатьсезлек ..... 140

ЯКОВ ЕМЕЛЬЯНОВНЫҢ ТУУЫНА 150 ЕЛ

Равил ФӘЙЗУЛЛИН. Шагыйрь, поп һәм якташ ..... 151
Яков ЕМЕЛЬЯНОВ. Әләк. *Шигырьләр* ..... 153

ӘДӘБИ ТӘНКЫЙТЬ

Гариф АХУНОВ. Шагыйрь ачкан дөнья. *(Шәүкәт Галиевкә 70 яшь)* ..... 157

ТАРИХ

Рәис САФАРОВ. Төрки халыклар ..... 162

ӘДӘБИЯТ ТАРИХЫНА

Рәмил ИСЛАМОВ. Алтын Урда әдәбияты ..... 175

"МӘГАРИФ" ЖУРНАЛЫНА - 80 ЕЛ

Фәрит ШӘРИФУЛЛИН. Мөгаллимнәр мөгаллиме ..... 179

КИТАП КҮЗӘТҮ

Миркасыйм ГОСМАНОВ. Яңа юнәлеш ..... 182
Азат ӘХМӘДУЛЛИН. Әдәби вакыйга бу ..... 184

УКУЧЫ СҮЗЕ

Илшат ВӘЛИУЛЛА. Тәгәллек кирәк ..... 188

КОТЛЫЙБЫЗ!

Булат Солтанбәковка - 70 яшь ..... 190
Иҗтимагый-мәдәни тормышыбыздан ..... 191

*Журнал выходит один раз в месяц*

## В НАШЕМ НОМЕРЕ:

"Проза и поэзия": роман М. ШАГИМАРДАНА "Сладкий яд"; окончание документальной повести Ф. ГАЛИЕВА "Атня - колыбель души моей"; рассказы А. ГАЛИ, А. САЛАХА; стихи Р. ЗАЙДУЛЛЫ, Р. НИЗАМИЕВА, С. ГАРАЕВОЙ; Ф. ТАРХАНОВОЙ.
"Драматургия": пьеса Ф. САДРИЕВА "Как молоды мы были..."
"Публицистика": статья Н. АКБЕРОВА "Безжалостность".
"К - 150 летию Я. Емельянова ": статья Р. ФАЙЗУЛЛИНА "Поэт, поп, земляк"; стихи юбиляра.
"Литературная критика" : статья Г. АХУНОВА "Мир поэта" посвящена к 70 - летию Ш. Галиева.
"История": статья Р. САФАРОВА "Тюркские народы".
"К истории литературы": статья Р. ИСЛАМОВА "Литература Золотой Орды".
"К 80 - летию журнала "Магариф": статья Ф. ШАРИФУЛЛИНА "Учитель учителей".
Книжное обозрение.
Слово читателя.
В номере отмечается 70 - летие видного ученого и общественного деятеля Б. Султанбекова.
Дневник общественно-культурной жизни.
На наших обложках: Государственный ансамбль песни и танца Республики Татарстан; писатель М. Шигапов.

## IN OUR ISSUE:

*The magazin edits monthly*

" Prose and poetry ": the novel of M. SHAGIMARDAN "The sweet poison"; the termination of dokumentary story of F. GALIEV "Atna — the cradle of my heard", the stories of A. GALY, A. SALAKH; the verses of R. ZAIDULLA, R. NIZAMIEV, S. GARAEVA, F. TARKHANOVA.
"Dramatics": F. SADRIEV'S play "How young we was..."
"Publicism": The article of N. AKBEROV 'S article "The pitiless".
"Commemorating the 150th Anniversary Y. Emelianov": R. FAIZULLIN'S article "The poet, the priest, the countryman; Y. Emelianov's verses.
" Literary criticism ": G. AKHUNOV'S article "The poet's world ".
"History": R. SAFAROV'S article "Turkic people".
"To the history of culture": R. ISLAMOV'S article "The literature of Gold Orda".
"Commemorating the 80th Anniversary "Magarif" magazin": F. SHARIFULLIN'S article "The teacher of teachers".
"Book's review"
"Reader's word"
The jubilee of B. Sultanbekov.
The diary of social and cultural life.
In our covers: the state ensemble of song and dance of Tatarstan; the writer M. Shigapov.

★Авторлар фикере редакция фикере белән туры килмәскә мөмкин.
★Редакциягә килгән кулъязмалар рецензияләнми һәм кире кайтарылмый.
★Басмаханә гаебе белән киткән җитешсезлекләр өчен редакция җавап бирми, брак журналларны алыштыру мөмкинлеге юк. Алар хакында 49-36-62 телефоны белән басмаханәнең техник контроль бүлегенә хәбәр итергә кирәк.

Журнал редакциянең компьютер үзәгендә җыелды һәм битләргә салынды.
Басарга кул куелды 22.10.98 ел. Офсет ысулы белән басыла. Кәгазь форматы 70X108 $^1/_{16}$.
Учетн.-изд. табак 14,2. Басма табак 12 (16,8). Тиражы 11238 Заказ Я-516
Журнал Татарстан Республикасының Мәгълүмат һәм матбугат министрлыгында теркәлгән.
Теркәлү таныклыгы № 7.

Татарстан газета һәм журналлар нәшрияты басмаханәсе.
Казан, Декабристлар урамы, 2

© «Казан утлары», 1998 ел.

# ШИГЪРИЯТ



## Ркаил Зәйдулла

### ШИГЪРИ ТӘФСИРЛӘР

* * *

*(2 сүрәдән)*

Күз яшедәй бәллүр дулкын килеп
Ялан аягымнан үбә тагын.
Кагылам да аккош иңнәреңә,
Мин сәҗдәгә сине уятамын.

Тып-тын күлдән балык сирпелгәндәй
Нурлар сикерешә безнең күздә.
Үзгә кебек бу өр-яңа иртә!
Күңелләр дә бераз үзгә, үзгә.

Аллага да мәдхиябез бүтән —
Дәртлерәк һәм кыска...
Дөнья башка!
Мин текәләм сиңа, гүя мамык
Өзгәләнеп карый чакматашка.

Алла бүләк иткән бу ләззәттән
Өзгәләнсен җаннар, өзгәләнсен...
Күпергән дә котеп ята үзән
Сәҗдәгә дип таулар тезләнгәнен.

Шарлавыклар аска томырыла,
Офык күтәрелә пәрдә сыман.
Елгаларның тагын сөте арта,
Бал саркыла туфрак арасыннан.

Син әйдисең мине куакларга,
Һәм башлана барысы да кабат —
Ымсындыра сине сусыл алма.
Мин сузылам аңа меңенче кат.

* * *

*(77 сурәдән)*

Атчабарлар чыккан юлга,
Җилдерәләр бер-бер артлы.
Игелек һәм яманлыкның
Арасы бит шундый шартлы,

Әмма алар төгәл белә:
Кем син? Ни син? Эчең-тышың...
Алып килә сиңа хөкем
Шул җайдакларның ярышы.

Килә вәгъдә ителгән көн,
Тотасыңмы аны истә:
Таулар очар тузан булып,
Һәм күкләр ишелер өскә.

Бу көнне ялган диюче!
Ярлыкау юк, бар да үткән, —
Синең мескен ялваруны
Беркем дә ишетмәс бүтән.

Без хуҗа! — дип күкрәк суга
Халык сәхнәгә менүгә,
Мәңгегә килгәндәй уйный,
Аннан...
Давыл себереп түгә.

Килер вәгъдә ителгән көн,
Сурдан чыгар шул чак өн ди...
Әлегә туй дәвам итә,
Монафикълар дингә өнди.

Атчабарлар чыккан юлга,
Инде соңармаслар бүтән.
Ямансу кичләргә күчеп
Мин дә менә кичерү көтәм.

* * *

*(80 сурәдән)*

Су йөгерә яшел үләннәр эчендә,
Нидер безләп төклетуралар күчендә.

Йөзем тәлгәшләре үрелеп кояш эчә,
Кошлар сайрый бакчаларда элеккечә.

Мин бер сукыр — тузанлы юл буйлап киләм, —
Яланаяк, ә өстемдә иске җилән.

Күрмәсәм дә: будыр кешелекнең язы! —
Ишетелә анда пәйгамбәр авазы.

Ава-тора, йөзем куаклары аша,
Тәнем-җаным шул авазга якынлаша.

Бакыйлыкта хозурына керерменме,
Һәм Тәңренең нурлы йөзен күрерменме?

Тынны кысып бер читтәрәк көтеп тордым.
И пәйгамбәр! Ник йөзеңне читкә бордың?

Шул мәнидән яраткан бит юкса Алла,
Һәммәбездән бер калкулык туфрак кала.

Сур тавышын син, пәйгамбәр, искә төшер, —
Туган туганны күрмичә йөгерешер.

Берәүләрнең йөзе балкыр шул сәгатьтә,
Сукырларның күзләре дә ачылыр хәтта.

Мәңгелекнең шулчак мин күреп узармын
Тәкәбберләр чыраендагы тузанын...

* * *

*(90 сурәдән)*

Ничә ел мин бу шәһәрдә инде?
Таныш бугай хәзер һәр ташы.
Кем ук итәр кара диварларга
Бәрелеп сынган минем карашны?

Офыклар юк. Сүрән йолдызлар да
Шәһәр утларында эрегән.
Диңгез төсле шаулый төнге кала —
Дулкыннары куба эредән.

Кара кучкылланган урам ташы, —
Әллә тузан инде, әллә кан.
Шунда яшибез без! Юкса Алла
Җирдә казганырга яраткан.

Янәшәдә ятимнәрнең зары,
Коллар ыңгыраша күптәннән,
Коргаксыган кулын суза кортка —
Хәер өсти үткән-сүткәннән.

Беркем күрми. Аллы-гөлле балкыш
Тимер рәшәткәләр эчендә.
Анда мәңгелек туй! Утлар балкый
Ярлы-ябагалар өчен дә.

Ә тантана бүтән! Мыштым гына
Якынлаша утлы гарасат,
Без күрербез аның күләгәсен
Бер-беребезнең күзенә карасак.

Коргаксыган кортка кулларыннан
Наз эзләрләр... Кирәк булыр наз!

Ут ияртеп килгән уңганнарга
Уңга таба юллар табылмас...

* * *

*(94 сурәдән)*

Сәҗдәгә әгәр егылсаң,
Тәңре күкрәгеңне ачар
Өстән иңгән хакыйкатькә,
Һәм яңгырар җанда — ашшар!

Канга баткан иңнәреңнән
Ул авыр йөк төшәр шул чак,
Кочак-кочак өмет өстәп
Офыкларда янар учак.

Җанга җиңел булган чакта
Иңдәге йөк — мамык сыман.
Җиләс җил йөзне иркәли
Исеп таулар арасыннан.

Йөрәкне ачып Аллага,
Чалмаларны сыга-сыга,
Алга омтылу ул безнең
Үзе дә төкәнмәс дога...

* * *

*(99 сурәдән)*

Мең яшәрлек дәү имәннәр бер көн
Шырпы кебек сынар, урман гүләр!
Калкып чыгып җирнең карыныннан
Авыр, авыр иман китерүләр.

Тимер ага эреп ярмәкләрдән,
Күк гөмбәзе күптән чәрдәкләнгән,
Бер сүнә дә офык, бер яктыра,
Адәми зат!
Ярлыкауны сора...

Тәкъва кебек кыланса да дәһри,
Ул беркайчан алдый алмас Аны.
Юк дияргә барны мөмкин түгел,
Бар дип ышандырып югалганны.

Җирнең карыныннан кузгалырбыз.
Туфрак коелыр бездән, тамар сулар...
Дошманнарын күреп сөенер кемдер,
Дусларына карап ямансулар.

Күз алдыннан үтәр узган гомер.
Ни эшләдек, кылдык нинди дога?
Кем онытты изге Бисмилласын,
Кеше булып юлга кузгалуга?

Берәү карар — күләр тиле кебек.
Берәү карар — тып-тын гына елар.
Хәтерләтеп безнең яшәешне,
Бер мизгелдә күздән узар еллар.

Куанырбыз аз булуын күреп
Бездән калган явызлыкның,
Әгәр
Сискәнмәсәк әрнеп шул чагында —
Кылган игелек тә — тузан кадәр...

• • •

*(100 сурәдән)*

Ыргылалар алга сугыш атлары,
Тимер ташкын сыта таш пулатларны.

Калканга калкан бәрелә. Калкына —
Даладан тауларга күчә ялкын да...

Качасы килә ышыкка, онтасы, —
Бу соң нинди чор барымтасы?

Тояклардан чәчри очкын — ут каба,
Шашып һәркем кызыл офыкка чаба.

Һәрберсе алдан җитмәкче ялгызы —
Ахактай балкый учакның һәр кузы.

Төяргә иде тулганчы бар кесә...
Алга барган саен нәфес тә үсә...

Майга батып кергән пычактай, диләр,
Офыкка үтте алар, эределәр...

Сурдан ургылыр да аваз, югалмас —
Итәктән тартыр мал, кузгалып булмас.

Анда — Алла. Анда фәрештәләр сак, —
Ахыргы хөкемен көтәр һәр җайдак.

• • •

*(104 сурәдән)*

Диңгездән килә бу җил, җиләс җил!
И син, кайнар чүл, бул инде бәхил.

Чәч арасында, тырнак эчендә,
Комнар кымшана, комнар күченә.

Нинди юлчы бу? — Ачулы, зәһәр.
Җилләр сискәнә, якын килсәләр...

Ул капчык аскан, капчыкта — алтын! —
Дустыннан качкан, ташлаган халкын.

Мәңгелек диеп уйлый ул мескен,
Алтын хакына шушы җир өстен.

Ул көтә кәүсәр, көтә ул хөрмә...
Бөтереп ала утлы өермә,

Диңгез суыдай чайпала ялкын,
Бугаздан ага эрегән алтын!

Кыяматкәчә әле янасы —
Калка йөрәктә ут баганасы.

Юатма аны, и син, җиләс җил...
Гыйбрәт алсыннар, булсыннар бәхил.

## Һәм... бер багышлау

* * *

Назлы сүзләрне тыңларга
Күңелең уянган булыр,
Буш өметләр кебек ләкин
Иренем янган булыр.

Серле төшләреңне өзеп
Кинәт кысылса учың,
Язмыш аңа көтмәгәндә
Йөзеген салган булыр.

Йөгерәсең килер синең
Офыкта яланаяк,
Үзәннәрдә яшел үлән
Ләмгә буялган булыр.

Итәкләреңне күтәреп
Суларга төшсәң әгәр,
Яр өстендә ак яулыгың
Онытылып калган булыр.

Күзеңдәге ишарәне
Йөземә бөрке әле, —
Мин барыбер торалмамын,
Тезләрем талган булыр.

Күз карашларымны эзләп
Хөҗрәмә килсәң дә син,
Табалмассың, инде аны
Көн сөртеп алган булыр.

Тик иреннәрем селкенер
Хушлашу сурәсеннән...
Соңра ни генә әйтсәм дә
Сүзләрем ялган булыр.



## Мансур Шаһимәрдән

# ТАТЛЫ АГУ

РОМАН

I

### Беренче башлам

Мөбарәк армия хезмәтеннән авылга кайтып төшкәч, иң элек сөенеч алырга кош булып очучы җилкенчәк — күрше кызы Кадрия булды.

Моннан ике ел элек кенә малай-шалайдан аерып булмаган кызны хәзер әнә танырлык та түгел: өстендә яңа гына энә-җептән чыккан ак алъяпкыч, коңгырт күлмәк, нәфис аякларында ак босоножкалар, түгәрәк алсу йөзендә мәхәббәт чокыры, томыраеп багучы тирән-зәңгәр күзләр, безнең халыкка бигүк ятышып бетмәгән куе сары чәч. Дөресен генә әйткәндә, җиләк өлгергән, өзәсе генә калган!..

Чәйләп алырга кыстаганнар иде, Кадрия ерак авылга мәктәпкә — сынау тапшырырга барачагын, соңга калырга һич ярамавын, ләкин... мөмкин булса, өйдәгеләр каршы килмәсәләр, кичен кереп чыгарга теләге юк түгел икәнен искәртеп, һәм... каушап-кызарып әйтелгән сүзләре хуҗа абзый тарафыннан хуплап кабул ителгәч, сөенеченнән очынып чыгып китте.

Инде көтүләр кайтып, мал-туарның һәммәсен барлап-урнаштырып бетергәч, Кадрия иңнәренә тормыш авырлыгы баскан сабыр әнисенә җайлап кына иптәш кызы белән киногa барачагын һәм фильм тәмамлангач озак тормаячагын әйтеп, әмма үзе ялгызы гына һәм нилектәндер уйланып кына, солдат кайткан йортка таба атлады.

Ап-аяз, җылы кич. Очсыз-кырыйсыз, төпсез күк йөзендә меңләгән йолдыз җемелди!.. Баярак, кояш баер алдыннан гына Кадриянең күрше егете белән очрашырга ашкынып торган саф, нечкә күңеленә: "Мин Мөбарәк белән бәхетле була алырмынмы соң?" — дигән шомлы уй килгән иде. Чөнки егет чагында Кадриянең әтисе Мөбарәкнең әнисе белән сөешеп йөргән ди бит. Әгәр дә араларына Кадриянең әнисе Кәбирә кермәгән булса?! Яшьләрнең ул чактагы мәхәббәтләре, һичшиксез, туй белән очланыр иде. Һәрхәлдә, Кадриянең бүгенге көндә читтә яшәп ятучы әтисе шул фикердә, имеш.

Мәгәр усал телләр дөньяга әллә ниткән гайбәт таратсалар да, олыларның "бәхетсезлегендә" Кадриянең тамчы да гаебе юк! Ул да бит

җир йөзендәге меңләгән-миллионлаган кыз-кыркын кебек үк бу якты дөньяга сөяргә һәм сөелергә туган! Ул да көннәрнең берендә ошаткан, яраткан егетенә кияүгә чыгарга хокуклы бит! Хәтта әле егетнең әнисе белән Кадриянең әтисе, кайчандыр ки, бер-берсен шашып яратып, кавыша алмый калган булсалар да! Чөнки инде замана бүтән, мәхәббәткә, өйләнешүгә таләп-үлчәү бүтән! Хәзер, әнә, яшьләр әти-әниләренең кинәш-табышыннан, рөхсәт бирү-бирмәвеннән башка да тәвәккәлләп, бергә кушылып яшәргә остарып життеләр! Әлбәттә, бу яшьләргә мактау яңгыры китерми, аларны чибәрләми, бизәми. Мәгәр, шулай да соң чиктә аларның дәгъваларын киребеткән олылар аңлап житкермәсә, яшьләргә, Мөбарәк белән Кадриягә тик бер генә юл кала — шәһәргә китү! Әйе-әйе, Кадрия моның шулай очланачагын инде күптән үк сизеп-тоеп йөри. Чөнки ул кечкенәдән үк күрше малае белән еш аралашып, аның холкын өйрәнеп һәм чынлап та аның кем икәнлеген, нәрсәгә сәләтле булуын үтәли күрергә остарып үсте. Аннары, кыздагы бу — кешеләрне бәяли белү ише тапкыр сыйфатлар Мөбарәккә дә ошамый түгел иде, һәм... Менә бүген солдат егет инде житкән, тулып өлгергән кызны күреп-танып алгач...

Яшь кызның йөрәге лепелди, чигәләре сулкылдап-сулкылдап тибә, аяклары җиңелчә генә калтырана, күңеле исә, кем әйткәндәй, тарихи очрашуга ашкына иде.

Чү! Килеп тә житкән ахры. Әйе шул — менә капка! Аһ, баш әйләнә, гүя җирнең асты-өскә килә... Бу — капка?! Ай, чоңгылга төшеп бара бит инде! Тотыгыз аны тизрәк, өскә, яктыга күтәреп чыгарыгыз... Шул мизгел Кадрия алдында уптым-илаһым капка ачылып китте. Кыз кинәт каушап-югалып калды. Аннары тиз генә үзен кулга алып, караңгыга текәлде... Кем бу?.. Һәй, Мөбарәк икән ич!

Талчыбыктай биленнән кочаклап, җиләктәй иреннәреннән суырып үпкәч кенә Кадрия өнгә килде. Гүя шул чакны бердәнбер кызының колагына әнисе: "Егет-җиләнне тәнеңә орындырма, сак бул!" — диде.

"Ие шул, дөрес!" — дип уйлап куйды ул. Әмма армиядән бөтенләйгә кайткан шәп егеткә исә ачуланмый гына:

— Кит инде абый, шаярма! — дигән булды.

Мөбарәк бик бәхетле иде бу минутта. Көтмәгәндә генә бәхеткә тиенеп куйган егет андый вак-төяккә генә хисап биреп торамы инде! Төз, таза, мөлаем йөзле солдат егет тә күптән таныш, яшь боландай житез, чибәр кызның бәләкәй генә рәнҗүенә җавап рәвешендә, кала укымышлысыдай гафу сорап, акланып, кимсенеп маташмады, иң элек үрелеп капканы япты, аннары кызны алдан атлатып, үзе чак кына артка калып, хуш исле тәмәке кабызды.

Аһ, чынлап та яшәүләре нинди күңелле! Дөньялары нинди гүзәл! Ә кичләре... кичләре гаҗәп тә матур бит!

Кадрия капылт кына туктап, як-ягына каранды да, солдатны көтеп алды. Ашыкмый гына янәшә киттеләр. Мөбарәк гасабиланып тәмәкесен сүндереп атты һәм уң кулын кызның сыгылмалы биленә куеп, башын чак кына сөйгәненә таба авыштырып, сүзләр-серләр тулы капчыгын чишеп җибәрде:

— Мин әйтәм, сынавынны?... Ә-ә, бишкәмени! Әйбәт, әйбәт! Инде аттестат аласың гына кала болай булгач! Аннары, исәнме-саумы калакаем, менә мин килдем әле сиңа белем алырга!... Нишләп?! Да-да, әниеңне ялгызын өйдә калдырып китә алмыйсың шул инде! Ну ничего, менә мин дә авылда төпләнеп калырга уйлыйм әле... тамырларыбыз монда бит безнең!..

Соңгы сүзләрен китапчарак әйтте Мөбарәк, матур әдәбият белән җенләнеп үсүнең җимеше иде инде бу! Чынлап та, Мөбарәктәге тел байлыгы хәйран мул иде һәм моның шулай икәнлеге иләс-миләс башында җил уйнап тормаган кешегә аңлашылмыйча кала аламы?.. Әнә бит... аны тыңлап таныш тыкрыклардан, урамнардан урап узулары ничек күңелле, рәхәт һәм бер дә туйдырмый, ялыктырмый. Югыйсә бу... таш астыннан

чыккандай, тәвәккәл, үткен күрше егетенең оста теле тик бүген генә тилчәләнмәгәндер инде!... Ул тегендә, армиядә дә, кем әйткәндәй, теле белән борчак яргандыр, тегермән тарттыргандыр!.. Аның погонындагы өч сызык та шулай дип кычкырып-әйтеп торадыр сыман!..

Кадриянең яшьлегенә хас үҗәт, төпченүчән, елгыр уйларын дәлилләгәндәй, Мөбарәк бу кичне сөйләде дә сөйләде армиядә күргән, очраткан гыйбрәтле вә кызыклы хәлләрне сырлап-бизәкләп! Кыз исә рәхәтләнеп көлде, шаркылдады һәм шул ук вакытта егетнең кайнар тәнендәге үтә дә тансык җылыны йөрәге аша үткәреп бара-бара: “Мин дә бигүк төшеп калганнардан түгел әле, моннан соң Мөбарәкне беркайчан да читләр кулына бирмәм һәм ятларга алыштырмам, боерса!” — дип, күңеленнән генә антлар эчте.

Шулай бер-берсен ошатып, чынлап йөреп китүләренә ел тулып узганда, ниһаять, алар бергә кушылып яши башларга карар кылдылар. Чөнки бу вакытта кыз егеттән йөккә дә калып куйган иде инде. Мәгәр монысы әлегә юләр җил хөкемендә генә, ягъни әле киләчәктә кубарылып алга килеп басачак хәтәр, шомлы вакыйгаларның яралгысы егет белән кызга гына билгеле иде. Тик, ни әйтсән дә “капчыкта безне озак саклап булмый” — иртәме-соңмы сер йомгагы сүтелә-сүтелә чишеләчәк тә, теге кыңгыр эшләре халыкка фаш булачак, менә шунда инде аларга никахсыз чәчкән орлыкларының гөнаһлы уңышы белән бүтән беркайчан да мактанырга, масаерга туры килмәячәк! Чөнки авыл халкының чуар теленә керденме бетте — маңгаеңа гына түгел, нәсел-нәсәбеңнең тамырына ук төшеп, кап-кара мөһер чәпеп куячакларын көт тә тор!

Һәм... Көннәрнең берендә, күктә яңа ай калыккан һәм тирә-юньдәге ямь-яшел бакчалардан алмагач, шомырт чәчәкләренең хуш исләре сизелер-сизелмәс кенә искән җил белән әллә кайларга китеп тарала торган җылы май кичендә Мөбарәк өенә Кадрияне килен итеп алып та кайтты.

Ачык тәрәзәдән каядыр текәлеп, уйланып утырган күркәм холыклы Аит абзый шушындый ямьле, матур кичтә улының су сөлегедәй елгыр, шәптин-шәп күрше кызына, җитмәсә, эшкә бетеп унган Кәбирә кызына өйләнеп ташлавын, кулын күкрәгенә куеп, кырган башын килешле генә итеп түбән иеп алу белән риза булуын белгертте. Ә менә һәр сүзен җелегенә үткәрерлек итеп әйтергә өйрәнгән һәм уйларын да уйдырып салырга остарып беткән Мәкшыя түти генә яшьләргә хәер-фатиха бирергә ашыкмады, гадәттәгечә салкын канлылык саклады, кат-кат үлчәде... Чү, туктале, амакачкаем: җанкай-җанашым дия-дия, Мөбарәк ялгышмыймы Кадриягә өйләнеп?! Ул елан кыз тышкы сөйкемлелеге-мөлаемлыгы белән генә түгел, башка юл белән дә улымны сихерләп, тәмам башын әйләндереп-саташтырып, күзен буып-иләсләндереп һәм тагын әлләниләр, әллә ниләр эшләтеп бетермәгәнме?! Ник дигәндә, әле Мөбарәк тегендә — армиядә чакта ук, Кадрия иптәш кызы аша бер студент егет белән танышып алган иде... Бу турыда миңа бик тәмләп, мактана-мактана, якягына ялт-йолт карана-карана, Кәбирә сөйләгән иде ич... “И күршекәем, и ходаның хикмәте, ахири... быел кызыма әллә ни булды менә, гел генә дә күзге каршыннан китеп тормый инде! Ул бөтерелүләре, мин сиңа әйтим, ул бөтерелүләре...”

Шуннан соң да Кәбирә очраган саен, кызының каладагы академик булачак егете белән кызыша-кызыша хатлар язышуын һәм Ленин сурәте төшерелгән ак конверт эчләренә кипкән күбәләкләр вә кипкән чәчәкләр дә салып-салып җибәрүен гаҗәп тә кызыклы бер ачыш итеп, шатлык-куанычка, бәхет-сәгадәткә юрап сөйли дә сөйли иде. Түземе җитеп тыңлап торган Мәкшыягә аның сүзләреннән менә ни аңлашыла иде: димәк, болай булгач, Кадриянең студент егет белән яскана-яскана хатлар язышуы гади бер мавыгу гына булып калмаган, тирәнгә үк төшкән һәм тамырланып та киткәнгә охшый бит; димәк, замана Ләйләсе сөекле Мәҗнүненә — хат эченә тыгып кипкән күбәләкләр вә кипкән чәчәкләр генә түгел, үзенең йөрәген үк җибәрмәгәнме икән әле?

"Һай, үзенең кулыннан эш килми түгел анысы!" — дип, уйлап куйды Мәкшыя, Кадриянең бит урталарын чия-кызыл төскә кертеп, бик тырышып кер үтүкли башлавын күреп, бераз гына йомшара төшеп.

— Улым, кил әле монда! — диде Мәкшыя түти.

— Минме! — диде Аит абзый газетасын кыштырдата-кыштырдата.

— Әй, сиңа эндәшкән кеше юк әле, тик тор! — дип, зәһәр генә итеп, кулын селтәп куйды хатыны.

Аит абзый ни өчендер аңа сынап карап куйды, ләкин каршы сүз әйтергә кыймады, газетасына күмелеп, тынып калды.

Әйе, хуҗа дигәнең гаять сабыр, түземле кеше, гомере буе хатынының сүзеннән чыкмыйча, дөресрәге, хатыныннан узып ни дә булса майтарырга җөрьәт итмичә, шым гына яши дә яши менә! Ә Мөбарәккә килгәндә, ул да шул инде шөкер, әнисенең кушкан йомышларын, әйткән сүзләрен җиренә җиткереп үтәмичә калганы юк әлегә.

— Улым?! — дип, йомшак кына итеп, елмаеп эндәште Мәкшыя.

— Тыңлыйм, әни, нәрсә кушасың?

— Әйдә әле... — Мәкшыя улы артыннан кухня ишеген япты, кара күзләрен әле тегендә, әле монда текәп, француз яулыгын чишеп һәм яңадан сирәк кара чәчле башына татарча ябып бәйли-бәйли:

— Бу заманда чәчү өстендә кем өйләнә инде, улым җә?! Кешедән оят бит! Халык ни әйтер? — диде. — Аннары малаеның хәтере калмас өчен генә өстәп куясы итте. — Көзгә өйләнерсең улым, яме... Туйның асылы көздә ләбаса!.. Менә, Алла кушып, игеннәр уңып куйса, заманалар имин булса, шәттә өйләнерсең, улым, өйләнмичә калмассың!... — Ә үзе исә, эченнән генә: "Көзгә чаклы әле вакыт күп! Бәлки, аңарчы миңа ошый торган берәр кыз да табар әле!" дип уйлый иде.

— Анысы шулай шулаен да... — дип авызы эчендә шулпа куертты Мөбарәк, һәм кинәт Кадриянең көмәнле булуы исенә төшеп: "Бәлки, әнием дөрес әйтәдер, әлегә никах укытып, авыл Советында паспортларга мөһир суктырып та бергә яши башларга була ич!" дип, кыяр-кыймас кына уйлап куйды. Әнисенә ул:

— Алайса без болай итик... — дип, ниятен ачып салмакчы иде, мәгәр улының тел төбен аңлап өлгергән Мәкшыя шундук очкындай чәчрәп:

— Шайтан табыны ясап маташырга минем җилдән туган малаем юк, никахны да, туйны да көзгә үткәрәбез, йола кушканча! -диде.

"Йола" сүзе Мөбарәкне тәмам җебетеп ташлады. Аның каушаптынып калуының сәбәбе, аларның сөйләшүләрен ишек аша тыңлап торган Кадриягә кояшлы көн кебек ачык һәм аңлаешлы иде. Димәк, монда Кадриягә урын юк! Ул монда артык кеше!..

Кыз, күз яшьләренә төелеп, әлеге каһәрле йорттан тиз генә йөгереп чыгып китте...

* * *

Сикәлтәле урам буйлап җирне дер селкетеп, акчылбырлар арасыннан як-якка балчык сибеп килгән кызыл трактор Мөбарәкнең каршысына ук килеп туктады. Тәрәзәдән шабашник Кәримуллин керле башын чыгарды һәм тузанлы тупас йөзен күрсәтеп, күзләрен сәер елтыратып, мыскыллы елмайды:

— Син, сабакташ, көчеңне-вакытыңны әрәм итеп рәискә каршы көрәшеп маташма инде, барыбер җиңеләчәксең бит! Син аның янәшәсендә кем? Сине кем яклый, ә?.. Шул-шул менә, дәшмисең... Ә рәисне бөтен район яклый! Шул, син инде хуҗасына турылыклы эт кебек, менә безнең кебек, рәиснең күзенә генә карап тор, — дип күкрәгенә сукты ул. — Балда-майда гына йөзәрсең. Рәис әйтте, әгәр дә Мөбарәк элекке хаталарын танып, бүген үк Киндер һәм Аккош күлләрен сөреп ташласа безнең кеше булыр! — диде. — Соңгы сүзләрен әйткәндә Кәримулланың черек теш уртларына чаклы күренеп китте.

Мөбарәк үзе дә сизмәстән таш эзләп жиргә иелгән иде, шул мизгел якында гына бер-бер артлы ачыргаланып елап җибәргән сабыйлар тавышы ишетелде. Капка төбендә кояшта изрәп утырган Кәбирә дә, башын борып тавыш килгән йортның тәрәзәләренә таба карады...

Тәрәзәләр... Әйе, бүгенгедәй хәтердә... Ул елны җәй, дөресрәге, җиденче август көнне авыл буйлап яшендәй таралган хәбәр Мөбарәккә дә килеп ирешә. Әлеге яман хәбәрне китерүче бәндә, кайчандыр ки, аеруча яраткан, үз иткән кызының да "алданган" дигән даны чыгып, шул хурлыктан эчүгә сабышкан торна Бәдретдин иде.

Торна Бәдретдин озын буена ятышмаган нечкә, нәзек тавыш белән:

— Ананны сатыйм!.. Әнә синең Кадрияң анда... ыстудент егет белән урманга кереп киткән, җиләк җыярга! — диде.

— Ә? Кем күргән?..

Сүз иясе белән йөрми диюләре хак икән. Баксаң, әтисе урынында яшь таналар күтәргә калып торган Кәримуллин Кәримулла күреп калган икән аларның урманга кереп киткәнен.

Мөбарәк сабакташын эзләп җәйләүгә барып чыкты, аны су буенда көтүче Ленар белән кәрт сугып утырган хәлдә очратты һәм колына ташланган бүре сыман бугазыннан эләктереп тә алды.

— Син... фәлән-фәсхет! Күрдеңме? Дөресме шул хәл?

— Кәнишне, гадук, дөрес! — диде кабартма бит, хәтта күзен дә йоммады. Алай гына да калмады әле, ипи тотып ант та итте.

Шуннан шул, Кадрия бу кичне клубта шәйләнмәде...

Мөбарәк, ашыга-кабалана сөйгән кызының түр бакчасына кереп, өе янына килеп, караңгы тәрәзә аша, еламсырагандай Кәбирәгә эндәште:

— Апа, җаным, Кадрияне бер генә минутка чыгар әле, зинһар!

— И-и, Мөбарәк, ул җиләктән бик арып кайткан иде шул, йоклый хәзер, — диде Кәбирә, тыныч кына.

— Алайса, апа җаным, уятып тәрәзә янына гына чакыр, бер генә сүз әйтәсем бар ие!

— Ярар...

Менә Кадрия төнге ак челтәрле күлмәктән тәрәзә каршында басып тора. Куе сары чәчләре иңнәренә таралып төшкән. Үзеннән бөркелеп урман, кура җиләге исе килә.

— И-и, мине шулай тиз сагынып та өлгердеңмени, җанашым?! Бүген клубка чыга алмадым инде, көндез җәяү күп йөрелде, арылган, — диде ул, көмештәй тавыш белән.

— Ә син икенче юлы урманга таза беләкле студент белән кер, ул сине көчле кулларында күтәреп кенә йөрер һәм болай арымассың да, ялыкмассың да! — диде Мөбарәк, һич тә шаяртырга исәп итмичә.

Кадрия кып-кызыл булып кызарды, әмма үзен кулга алып өлгерде:

— Ә син, син... теләсә кем сүзенә ышанып йөрүче сабый икәнсең әле! Бар, өеңә кайт, бишеккә кереп ят, әниең тирбәтә-тирбәтә йоклатсын үзеңне! — дип, тәрәзә капкачларын шапылдатып ябып куйды...

... Ниһаять, ачыргаланып-ачыргаланып елаган сабыйларны кемдер кулга алып тынычландырды, ахры. Мөбарәк учындагы кырлы ак ташны кычыткан эченә ташлады. Кәлимулла җинел сулап, очынып трактордан төште һәм кара, керле кулы белән сабакташының җилкәсенә йомшак кына суккалап:

— Ярый, ахир... Мин сиңа персидәтельнең сүзен генә җиткердем... Син бу корыч айгырга атланып ничек тә эшне җиренә җиткереп башкарырга тырыш инде! — дип, эре-салмак адымнар белән, үз-үзенә нык ышанып китеп барды.

Егет нәфрәтләнеп җиргә төкерде дә, эченнән генә: "Төлкеләр өерендә төлке була алмасам да, бирешергә исәп юк әле", — диде һәм ясканып тракторга кереп утырды.

Кызыл трактор урыныннан дәррәү кузгалып, басу-кырлар ягына таба юл алды.

... "Шөкер, булды бу!" Өч тармаклы иләмсез юан карт карама турысында Мөбарәк эче галәмәт бөркүләнгән, уттай кызган тракторын туктатты һәм майлы бармак эзләре беленеп торган ишекне ачып, дымлы, кара җир өстенә сикерде. Шундук күн итекле аяклары тубыктан мамыктай йомшак туфракка батып керде... Егетнең кара-кучкыл йөзендә елмаю балкый иде... Мөбарәк күңелле җыр көенә сызгырырга кереште. Бит басу-кырлар сөрелеп бетте. Әнә, Аккош күле, арырак Киндер күле, аннары башка күлләр!.. Их... Егет җиңе белән маңгаеннан аккан тирне сөртеп алды: шул күлләрдә балачактагы шикелле рәхәтләнеп ял итәсе, чиста саф суында колач җәеп йөзәсе, чумып-чумып ләззәтләнәсе иде хәзер!... Ләкин... Мөбарәк хыялында гына булса да максатына ирешә алмый калды, кемнендер шәрран ярып "Әй!" дип кычкырган тавышына сәерсенеп, борылып карады — сөрелгән җир өстеннән хәтәр-хәтәр генә җилләнеп аңа таба сабакташы килә иде.

Кызыл йөз тиз килеп җитте:

— Рәис тракторыңны бөтенләйгә миңа тапшырырга кушты, — диде. Аннары: "Бу күлләрне иртәгедән башлап төштә генә күрерсең инде", — дип, тракторга утырмакчы булды.

Әмма Мөбарәк сабакташының юлын кисеп өлгерде һәм кечкенәдән үк җене сөймәгән бәндәнең чак кына күз тирәсен "бизәп" ташламады, мәгәр вакытында үзен кулга алып, тыелып калды:

— "Беренче" килеп боерса да утыртмыйм сине тракторга, белдеңме?! — диде. — Күлләргә кагылмый тор әле!

Кәлимулла киң җилкәсен күрсәтеп, басу кырында калган матаена таба китте, утырды, аннары авыл тарафына очты. "Әләкләргә китте", — дип уйлады Мөбарәк. Ул ямь-яшел үлән өстенә тәгәрәде һәм "Әһ-һә-й", дип, изүен чишеп, таза ак күкрәген кояшка ачып салды: өстә, биектә ничаклы иркенлек, киңлек... Мөбарәк хозурланып ята торгач, күзләрен йомды. Бераздан тагын ачты, шул төбәктә түбәндә генә асылынып торган катлы-катлы ак болытларны күрде, аннары теге карама ягына башын борып караган иде, сикереп торганын тоймый да калды. Ул!!!

Яшь ат шикелле җиңелчә генә җилдереп килгән "Газик" Мөбарәккә орынып үк диярлек туктады. Кабинадан туптай атылып карсак, рәис чыкты:

— У-у, контр! Хәзер үк күз алдымнан югалган бул! Барыбер авылда яшәтмим мин сине! — диде. Аннары, майлы күзләре белән Мөбарәкне бораулап маташкан табак биткә: "Давай, ныклап эшкә кереш!" — диде.

Бакыр чәч, Берлинны алырга җыенган танкка менгәндәй, тракторга ялт итеп кереп утырды. Менә шулай, коммунистлар үтә тәвәккәл кешеләр алар, дигән шикелле, Мөбарәккә тәкәббер караш ташлады да, җикәнле вә камышлы күлләр ягына таба кузгалып китте.

... Мөбарәкнең ачуы күәстәге камырдай, чымырдап кабара иде. "Их, мин... — дип үз-үзен битәрләде егет. — Килмешәкләр алдында суга салган шикәр сыман җебедем дә төштем... Тыңлыйм, әфәнде, имеш! Ә син, сабакташ дус, мә, утыр тракторыма, тар-мар ит күлләрне: сандугачлар оя кормасын, һавада тургайлар сайрамасын, аккошлар беркайчан әйләнеп кайтмасын... Кыр, ут ач... Чәчәкләргә — сугыш! Җиләкләргә — сугыш! Балыкларга — сугыш!

Урманнар?! Нигә кирәк алар: кис, тура! Колач җитмәс агачларны сөйрәтеп, авыл урамнарындагы юклы-барлы чирәмнәрне актартып, утынга алып кайт!..."

Күмелгән кое урынында ташка абынгач кына исенә килде Мөбарәк. Их, күкрәк эчендәге ялкын басылырлык итеп эчәсе иде тәмле, салкын суны! Ләкин кайдан аласың аны? Юшкынлы торба суы эчеп юан инде син — туган җиреңдә үз-үзеңә ят булып калган, тамырларыннан өзелеп бетәргә якынлашкан мескен адәм!

Узган ел киселгән өянке төбенә утырып бераз хәл алгач, Мөбарәкнең күз алдына, оялчан гына булып, Кадрия килеп басты.

... Теге унышсыз, кызганыч хәлләрдән соң Кадрия, ниһаять, тәвәккәлләп, шифаханәгә юл тоткан. Мәгәр гинеколог ханым, чарасыз калып: "И-и, сонаргансың шул инде, сенелем, алданрак килергә кирәк иде", — дип, кызны тудыруханәгә озаткан, имеш.

Ә студент, сукин сын, хәзер авылда — инженер! Зурдан кубып рәис кызына өйләнеп җибәрде дә...

Мөбарәк йодрыкларын төйнәде, тешләрен шыкырдатты һәм ачык бер карарга килеп урыныннан сикереп торды да тиз-тиз тауга күтәрелә башлады.

Бераздан инде ул, дулкынланып, Кадрияләр өе буенда басып тора иде.

... — Нихәл әби?

— Әйбәт кенә әле, кияү!

— Кадрия өйдәме?

— Өйдә-өйдә... Күптән түгел генә детдомга барып кайтканыек әле, игезәкләр янына дим... — Кәбирә түти яшьләнгән күзен яулык чите белән сөртеп алды. Икесенә тиң тач син инде, Мөбарәккәем!

— Көлүләре коеп куйган инженермы?! — дип тәрттерде "егет" ачуланмый гына.

— Авызыңнан җил алсын, кияү, көлүләре дә синеке!

... — Исәнме Кадрия!..

— Үләргә җыенганым юк әле, ни йомыш?!

— Чү! Әчемсерәдеңме әллә тагын?..

— Әй, саруымны кайнатмасана, зинһар! Элек тә кешелеген ташка үлчим генә иде, хәзер бигрәк тә... "Трактор" дия-дия тәмам тимергә әйләнеп беткәнсең инде!

— Трактор түгел, Кадрия, система әверелдерә безне тимергә, бел, система-а!.. Ә малайлар ничек, әкренләп үсәләрдер ич калада ак калач кимереп?!

— Үсмичә... Син туйдырмыйсың ич аларны! Күке! Әле, җитмәсә, система, имеш...

— Ярар, бетте!... Ә икенче яктан караганда ул икмәкне кем үстерә — мин!!

— Харап инде, бик! Майга батып йөрүдән башың чыкмый: театрың да — трактор, хатының да — трактор...

Мөбарәк — театр итеп Аккош-Киндер күлләрен һәм аларның дару үләннәренә бай ямь-яшел тугайларын әйтмәкче иде, бүгенге мажаралар исенә төште дә... Ә гаилә мәсьәләсенә килгәндә...

— Кадрия, мина бу көннәрдә күпне күрергә, күпне кичерергә туры килде! Мин... аңладым инде, мина синнән башка тормыш юк икән! Әйдә, кавышыйк та калага китик яшәргә. Малайларны да детдомнан үз яныбызга алып кайтырбыз, ни дисәң дә аларның әтисе мин ич!

Яшь хатын Мөбарәкнең авыл һәм район житәкчеләре белән борчагы пешмәгәнен белә иде.

"Әйе, моның белән яшәүләре җинел булмаячак" — дип уйлады Кадрия. Ул яшь ирнең каладагы алдавыч тормыш кануннарына да җайлашып, яраклашып бетә алуына шикләнеп, әмма чынлыкта исә:

— Ярый, мин риза, — диде, — тик бер шарт белән: әниемә кыш чыгарлык утын хәзерләп бир башта. Күп итеп!

... Мөбарәк бензин пычкысын "Иж-Юпитер" бишегенә чыгарып салды. Тагын кәрәк һәм балта да алырга кирәк дип ишегалдына кергән иде, әнисенә тап булды.

— Чү! Кая барасың? Болар нәрсәгә? — диде Мәкшыя түти малаена. — Син бит кырга, эшкә киткән идең. Тракторың кайда?..

— ...

— Әниең сорый бит, улым, җавап бир! — диде Аит абзый. Ул каерысы куптарылган имән бүрәнә өстендә сызлаулы билен кояшка күрсәтеп, буыннарын да йомшартырга исәп итеп, сыйпап-сыпырып һәм уып-уыштыргалап утыра иде.

— Булмый бу болай... Калага китәргә уйладым мин, — диде Мөбарәк сүзләрен теш арасыннан гына сыгып чыгара-чыгара. — Әнә, эти гомеренең иң матур өлешен колхозга "бүләк" итте, бил бөкте. Ә хәзер, сәламәтлеген югалткач, белмиләр дә үзен! Мин дә тора-бара эти шикелле ярык тагарак алдында утырып калачакмын бит, аңлыйсызмы шуны?! Чөнки монда, колхозда намуслы кешегә рәт юк, сан юк! Ә тегендә, калада ичмасам... — Мөбарәк кулын селтәп куйды. — Әй, сезгә әйттең ни, әйтмәдең ни... Сез шул гомер буе җитәкчеләр сүзеннән чыкмыйча: "җитәкчеләр укыган кешеләр, акны карадан гына аера беләләр, алар һичкайчан файдасызга көч сарыф итмәсләр, алар сүзе безгә закон", дия-дия, җитәкчеләр кушканны карусыз үтәргә, бушка бил бөгәргә өйрәнгән коллар инде! Әмма мин, гафу итегез, алай... намуссыз җитәкчеләргә кирәк-кирәкмәскә тәлинкә тотарга, калҗаның симезрәге миңа булсын, дип, алар алдында иртә-кич "Әпипә"гә биеп торырга һәм намуслы кешеләрне чага-чага, әләкли-әләкли, батыра-батыра югарыга үрләргә, зур-зур дәрәҗәләргә ирешергә теләмим! Рәнҗетелгәннәрнең сытык чырайларын, җимеренке кашларын, канлы-яшьле күзләрен, һәм шуларның миңа карата: "Менә бу бәндә кабахәтнең дә кабахәте инде", дип, каргана-каргана сөйләнүләрен теләмим! Юк, теләмим! — диде Мөбарәк һәм берни аңламаган Акбайның койрык чәнчеп ялагайлануына игътибар да итеп тормастан, матаена юнәлде.

Мәкшыя түти, ниһаять, исенә килеп:

— Карале, кара... Бу бала чынлап та акылдан шашкан ахры! — дип, иренә төбәлде.

— Улым, акылыңа кил! — диде Аит абзый, хәлсез-йомшак тавыш белән. — Бездәй кешеләргә ашар өчен, көн итәр өчен кайда да эшләргә, бил бөгәргә кирәк! Шунысын да бел: әгәр дә атаң-анаңның хәер-фатихасын алмыйча юлга кузгалсаң, кайсы гына илләрнең җәннәтенә барып керсәң дә, язмышның кара сакалы барыбер артыңнан калмыйча ияреп йөриячәк һәм сиңа рәхәт күрергә насыйп булмаячак. Ә ул хәер-фатиханы без сиңа бирмәячәкбез: кал авылда, яшә Кадриянә өйләнеп, балаларыңны каладан алып кайтып, матур итеп... — Аит абзый сүзеннән бүленде, ютәлләргә кереште.

— Әйе, улым, әйе, атаң бик белеп әйтә! — диде Мәкшыя түти һич көтмәгәндә ире ягына авышып. Чөнки түти сизә: уллары читкә китеп барса, кулларыннан трактор ычкыначак лабаса! Ә авыл җирендә трактордан башка яшәүне күз алдына да китереп булмый хәзер!

— Акылыңа кил, улым! — дип өтәләнде Аит абзый. — Агыйделнең аръягында бер энәгә бер сыер, ди. Барып карагач берсе дә юк, ди. Әле соң түгел, юләр уйларыңны башыңнан чыгарып ташла! Үтенеп сорыйм, ә?!

— Юк, юк! Кыстамагыз да, соң инде! — диде Мөбарәк дорфа бер тискәрелек белән.

Ул көрәк белән балтаны матай бишегенә куйды да, биленә таянды:

— Калада әле яртылаш кешечә яшәргә мөмкин, чөнки анда кемнең-кемлеген белмиләр, маңгайга да язылмаган... Мәгәр килер бер көн, калада да минем кемлекне белерләр, чөнки мин коллык тәртипләре белән килешә алмыйм, андый түбән, җирәнгеч яшәү рәвешенә җайлашасым килми, — диде һәм әнисе белән әтисе аңышып өлгергәнче матаена утырып китеп тә барды.

Чумар тавын төшкәч, Мөбарәк, елмаеп, җырлап җибәрде:

Ай югары, ай югары,
Айга менәсем килә.
Айга менеп, түбән карап
Кукиш күрсәтәсем килә!..

— Әйе, бередәге сөлекләр — түрә-монтагайларга кукишнең кукселен күрсәтәчәкмен әле мин, берзаман... — диде Мөбарәк, җил уңаена очып-килеп күз-кашларына сарган чебен-черкиләрне як-якка сыпырып ташлый-

ташлый... Аннары ул ындыр юлыннан бара-бара, тирә-юньгә карангалады.

Бу жирләрдә әле кайчан гына бихисап өянкеләр тезелешеп торалар иде, аларны кешеләр аерым хужалык заманында үз ындырларына утырткан булганнар. Мөбарәк тә барлык югары оч малайлары кебек үк, шул өянкеталларга үрмәләп, шулардан егылып, кул-аякларын сыдырып, борынын канатып, шулай чыныгып үсте. Хәзер бу төшләрдә һичнинди агач юк инде. Чөнки, утынга турап бетергәннәр.

"Мин дә картәтиемнең бабасы утырткан караманы кисеп, Кабирә әбигә алып кайтып бирәчәкмен, аннан һичшиксез кышлык утын чыгачак!" — дип куйды Мөбарәк, кыр уртасында үсеп торган ялгыз, сәер караманы күз алдына китереп. Ул карама гади агач кына түгел, анын турында авылда телдән-телгә күчеп, яшь буыннарның колагына да килеп ирешә торган гыйбрәтле риваять бар. Мөбарәк әнә шул риваятьне кабат хәтереннән кичерде.

... Урыс патшасы Искәндәр III заманында Көмеш Елгада бер фәкыйрь кешенең кызы бай малаеннан алданып буйга узгач, үз-үзенә кул салган. Шәригать кануны буенча хөкем каты булган — "тәмут кисәвен" зиратка жирләтмәгәннәр! Шуннан Аккош күле буенда яна кабер калкып чыккан... Шәһри Мәккәдән, изге хаж сәфәреннән кайтып килүче бер суфый карт әлеге исемсез-билгесез кабергә юлыгып, авыл өстенә озак кына текәлеп карап торган да, тәгам капчыгыннан карама орлыгы алып кабер туфрагына күмеп куйган. Орлык жирдән дым алган, тамырланган, кызыл, каты балчыкны аралап, иркен, якты дөньяга чыккан һәм өчкә тармакланып үсә башлаган. Бу тамаша кешеләрне шаккатырган, ни әйтергә дә белмәгәннәр. Серне күрәзә сәләтенә ия суфый карт чишеп биргән, ди. Баксаң, мескен кыз үзенекен генә түгел, карынында яралган өч сабыйның да гомерен өзгән икән!..

* * *

Читкә китәм, фәлән итәм, дип, сөйләнү бер хәл, аны тормышка ашыру икенче нәрсә икән ул. Ягъни "сөйләнү" белән "чиләнү"нең арасы, кем әйткәндәй, жир белән күк арасы кебек.

Әнә, Кәбирә бала вакытыннан ук тормышның арбасына жигелеп, сугыш чорында окоплар казып, аннары Пермь урманнарында агачлар кисеп, саллар агызып һәм әллә нинди кырыкмаса-кырык эшләргә катнашып, ватылып беткән кеше буларак белә — гади эш кешеләренә авылда да, калада да яшәүләре жиңел түгел. Бигрәк тә Мөбарәк кебек туры сүзле, намуслы эш атларына кыен бу дөньяда! Менә шул "дөрес" кешегә бердәнбер кызыңны — киләчәктә юаныч вә таяныч булыр дип үстергән бердәнбер баланны ияртеп чыгарып жибәр инде!

Әллә соң башта Кадрия өйдә генә калып торсынмы? Болай, берберенең аягына тышау булганчы, ин элек Мөбарәк үзе генә китеп калага урнашсын, ягъни яшәрләренә урын әзерләсен, эш тапсын, аннары инде, кайтып Кадрияне үзе белән торырга алып китәр!

Менә шуларны күңеленнән кичереп чыккач, Кәбирә түти, жанындагы борчуларын, йөрәгендәге бимазаларын, шик-шөбһәләрен кияве белән кызына житкерде. Әлбәттә, Мөбарәк бу катмарлы дөньяда күпне күргән, күпне кичергән әби кешенең акыллы, төпле вә саллы кинәшләренә каршы дәлилләр таба алмады. Кадрия дә әнисенең үткен, гыйбрәтле үгет-нәсихәтләрен санга сугарга мәжбүр булды. Соңгы чиктә — йөрәк һәм хис түгел, ә бәлки акыл һәм тәжрибә тантана итте!

— Ярый, әби, алайса синеңчә булсын, Кадрия әлегә авылда калып торыр, сиңа утын белән печән әзерләшсен, ә мин шәһәргә китеп яшәргә урын эзлим, эш юнәлтим, аннары инде, кайтып, Кадрияне дә алып китәрмен! — диде ул.

Шулай килештеләр.

Мөбарәк кеше-фәләнгә юлыкмаска теләп, бакча артлатып кына өйләренә керде. Әнисе өйдә генә түгел, ишегалдында һәм абзар-кура эчендә дә юк иде. Күрәсең, кичтән җәйләүгә илтеп арканлаган сыерны алып кайтырга киткән. Әти кеше йоклый иде әле.

Ул чемоданга кирәкле өс киемнәрен җыеп салды, документларын да калдырмады, үзенә кирәк кадәр акча да тапты. Аннары, читкә чыгып китүенең максатын кыскача гына шәрехләп һәм әтисе белән әнисенә корычтай ныклык, озын гомер вә ак бәхетләр теләп язган кәгазьне игътибарны җәлеп итеп тора торган урынга куеп, ишеккә юнәлде.

Күп тә үтмәде, яшь хатын белән яшь ир авыл читендә иделәр инде. Күктә яп-якты булып, анда-санда, берән-сәрән генә таң йолдызлары яна.

Аһ, беләсе иде, бу ике яшь йөрәкне алда ниләр көткәнен... Ниләр...

Юк, җавап юк!.. Өстә чит-чите болытлар белән каймаланган күк тә күк! Аяк астында хәтфә үләнле җир! Унда-сулда бөдрә урманнар белән, күптән түгел генә сөрелгән, чәчелгән кырлар да кырлар! Алда исә — бушлык, билгесезлек...

Шулай да күңелне иң сөендергәне — күктә, гүя бер-берсенә күз кысыша-кысыша, таң йолдызлары балкый... Дөрес, таң йолдызлары инде бу вакытта ялгызлар, мәгәр бик яктылар...

Шулай, тойгылар, хисләр аша гына аңлаша-аңлаша, күпер янына килеп җиттеләр. Һәм кинәт... машина авазы ишетеп каударлана-каударлана дамбага менсәләр — зур тизлектә үзләренә таба якынлашып килгән кара "Волга"ны шәйләп, аңарга таба карап баскан көе, уң кулларын селкә-селкә туктарга куштылар. Дүрт көпчәкле айгыр хуҗасы ялындырып тормады... Ул — Кавказ ягы кешесе — Мөбарәкне әйбәт киемнәренә карап, елмаеп каршы алды. "Ялгызыма гына ямансу иде, бергә-бергә барулары күңелле булыр инде", — дип, сигарет кабызып җибәрде, пассажирына да тәкъдим итте. Мөбарәк тә: "Кунак хуҗаның ишәге ич, әйдә, сезнеңчә булсын!" — диде дә, рәхәтләнеп, җәелеп утырып, затлы тәмәке төтәтергә кереште.

Кадрия исә, чем кара "Волга" күздән югалганчы кул изәп, хәерле юл, уңышлы сәфәр теләп басып торды. Аннары авыл ягына таба борылды.

Ләкин яшь хатынның өйгә кайтып керәсе килмәде, иртә булса да: "Барыйм әле, бәлки, эш белән онытылып булыр", -дип, башка сукмактан эшенә — медпунктка китте.

## Икенче башлам

Бүген... кеше дигәнең дөньяга килүенә, яшәвенә, тормышка сөенеч тулы күзләрен төбәп:

— Ярый әле мин туганмын! Ярый әле мин яшим! Менә бу ичмасам минем тормыш! Мондый гүзәл тормыш бары тик миндә генә булырга мөмкин! — дип, кулын күкрәгенә куеп әйтергә, җөрьәт итәрме?!

Шикле... Чөнки, бүгенге адәм баласы кичәге кеше түгел инде ул. Мәхлук! Әнә... аның бер күзе алдындагы ризыкта, икенчесе — күршеләренекендә!

Кадрия шундый котсыз, шыксыз уйларга бирелеп атлый да атлый. Аның күңеле алгысыган һәм йөрәге кага, җаныннан да, кем әйткәндәй, тынычлык качкан: бит Мөбарәк калага бер үзе китте. Әйтәләр ич, "ир ул капкадан чыкканчы гына ир, ә капкадан чыккач — егет", дип. Мөбарәк тә, тиләләнеп, тегендә, калада егетләнеп йөрмәсә ярар иде инде, кана! Элекке заманда, дин куәтле чакта ир-атлар ят җирләрдә алай бик егетләнеп йөрмәгәннәр бугай. Дин бетерелеп, ил-көн өстенә ирекле мәхәббәт канат җәйгәч кенә...

Хәер, минем игезәк ике улым дөньяга, вакытлы-вакытсыз туута да шул ук ирекле мәхәббәт сәбәпче булды ич! Мин мондый ирекле мәхәббәттә

нәрсә оттым да, нәрсә оттырдым? Әйе, кайберәүләр, бәлки, ирекле мәхәббәтне йөгәнсез атка тинлиләрдер! Ягъни, динлелек — йөгәнлелек — ирексез мәхәббәт, ә динсезлек — йөгәнсезлек — ирекле мәхәббәт диләрдер. Минем үземә исә мондый беркатлы, пешеп житмәгән чагыштырулар ошамый. Чөнки мәхәббәт ул ирекле яки ирексез була алмый. Биредә диннен һичнинди катнашы юк! Мәхәббәт ул йә бар, йә — юк! Бары тик шулай гына!

И-и, нигә мин юк-бар белән баш катырам әле. Кияүгә чыгу яки бала табу бит мәхәббәттән башка да була ала! Әйе-әйе, була ала! Әйтик, көннәрнең берендә, һич көтмәгәндә юлында очрап куйган чибәр, таза, мөлаем ир кавеме белән рәхәтләнеп, бар дөньяңны онытып, гыйш-гыйшрәт уйныйсың да, аннары туп-туры тудыруханәгә юл тотасың. Биредә инде мәхәббәтнең пычак очы хәтлесе генә дә юк, дусларым-дускайларым! Биредә бары тик каршы як женес кавеме белән узгынчы мавыгу гына бар! Әйе, әйе...

Ләкин шунысы бар, мондый ирекле мавыгулар — кемнеңдер гомерендә бер генә, ә икенчеләрнең исә — ике, өч, дүрт, биш, хәтта күбрәк тә булырга мөмкин! Монда инде татлы хыяллар, кыюдан-кыю теләк-омтылышлар гына уңышның асылын тәэмин итми һәм очраклы жиңүләр генә әллә ни күп нәрсә бирми. Монда, минемчә, бөтен хикмәт — язмышта! Әйе, әйе, жәмәгать — язмышта! Чөнки бу гөнаһлы, гыйбрәтле, вәхши, кыргый дөньяга адәм балалары бер-бер артлы туа тора һәм олуг табигать аларга ашыга-ашыга төрледән-төрле язмыш өләшеп тора. Соңыннан инде бер генә кеше дә "миңа тигән язмыш биргәнсең", дип, табигать анакаебызга үпкәсен белдерә алмый. Чөнки бу — һәркемнең "өлешенә чыккан көмеше"! Минем "көмешем" кем икән? Мөбарәкме? Юктыр! Минем аннан теге чакта ук күңелем суынган иде инде. Чөнки, әнисе сүзеннән чыга алмаган егет кеше хатынына юньле ир була алмый ул! Мин моны яхшы сизәм.

Кадрия йөрәгендә, жанында һичтуктаусыз туып торган каршылыклы фикерләр эчендә бакчалар буйлап атлый торгач, искәрмәстән генә тыкрыктан килеп чыккан ак "Жигули"ны шәйләп алып, дерт итеп китте. Тиз генә читкә чыгып юл бирмәкче иде, ләкин машина кырт борылып, аның каршына ук туктады. Руль артында үз-үзенә нык ышанган гажәп тук кыяфәт белән инженер Гранит утыра иде.

Гранит янәшәдәге ишекне ачып, Кадриягә эндәште:

— Йөрәк маем, әйдә!.. — Ләкин ул сүзен әйтеп бетермәде:

— Ка-йа-а?.. — диде Кадрия, шикләнеп.

Гранит тыенкы рәвештә көлеп куйды:

— Утыр әле яннарыма, ял булсын жаннарыма, диләрме әле? Утыр инде, жимешем, карышма, машина көтә бит!

Кадрия куркулы төстә як-ягына каранды:

— Бар, бар, узып кит әле, кит!

Гранит машинасыннан чыкты һәм Кадриянең терсәгенә орынды:

— У-у, бүген иртән бигрәкләр дә чибәрләнгән, шәпләнгән син, татлы балым, нәкъ минем белән очрашырга әзерләнгән шикелле!

Кадрия капылт кына инженерны әйләнеп узып китмәкче иде, теге шундук аны, нәзек биленнән эләктереп, машинага таба күтәреп илтмәкче булды.

Кадрия искәреп алды: бакча артына чыккан бер түти аларны күреп һәм сөйләшүләрен тыңларга исәп итеп ахры, бәрәңге сабаклары арасыннан колорада кондызлары чүпләштергәләгән булып, якыная да якыная иде. Бу — Мөбарәкнең туганнан-туган апасы иде. Шуңлыктан, Кадрия сак кына, әкрен генә, иплəп кенә әйтте:

— Ярар, булды, аңлашылды мәсьәлә. Мин хәзер туп-туры медпунктка барам... Бераздан жаен-чарасын табып, кулыннымы-нәрсәннеме бәйләтергә дип минем янга килеп чыгарсың, калганын шунда сөйләшеп-аңлашып бетерербез, ямме Гранит, акыллым!

Ләкин инженер бүген кешеләргә, аларның әйткән сүзләренә, биргән вәгъдәләренә, хәтта антларына да ышанып бетәргә ярамаганлыкны үз җилкәсендә татып белә, аңлый һәм аның бу четерекле өлкәдә мул гына тәҗрибәсе дә бар иде инде. Шуңа күрә дә ул:

— Һавадагы торнаның җиргә төшкәнен көткәнче, кулга килеп кергән чыпчыкны ычкындыраммы инде мин, зөбәрҗәтем-мәрҗәнем! — дия-дия, Кадрияне сыйпап-сыпырып машинасына, янәшәсенә утыртты да: — Ну, сандугачым! Хәзер иркенләп сайра инде, сайра, — дип педальләргә орынды, рульгә кагылды. Шуны гына көткәндәй, ак "Жигули" үкереп, урыныннан кузгалып та китте.

Кадрия ялт кына борылып карады: теге түти бакча коймасы аша үрелеп һәм гаҗәпләнү катыш елмаеп, кызыгып, көнләп, алар китеп барган тарафка карап тора иде.

Буага житәрәк юл ике якка тармакланып китә. Берсе түбән оч һәм Шомыртлык урманы ягына — Камага, икенчесе авылның уртасына — медпунктка борыла.

Гранит юлның икенчесенә — медпунктка илтә торганына кереп киткәч, Кадриянең эченә җылы кергән иде, әмма инженер машинасын медпункт тирәсендә туктату түгел, киресенчә, ул төштә тизлекне арттырып, җилдереп кенә үтеп китте. Ә арт урамдагы сазламыкка әверелгән Әнәк күле буеннан тузан туздырып китеп барганда исә чак-чак кына ике казны таптатмыйча калды. Казлар машина астына туры килсәләр дә, көпчәкләргә тапталмауларына сөенә-сөенә дөнья бетереп каңгылдашалар иде.

— Өлкән агрономның казлары! — диде Гранит, җиңел сулап.

Аның әнисе — убыр, аждаһа! Әче теленә керергә ходай насыйп итмәгән булса кирәк. Кадриянең дә ирен читләрендәге хәйләкәр, мул елмаюы шуны сиздерә иде.

Юл күперне узып, бормаланып-сырмаланып зират янәшәсеннән үтеп менгәч, кырга китереп чыгарды.

Кадрия инде бу вакытта Гранитның ниятенә тәмам төшенгән иде. Аңа кинәт, мөмкинлекләрдән тулысынча файдаланып калырга — калага киткәнче әниемне кышлык печән белән утынлы итәргә кирәк, дигән уй килде.

Гранитның исә үз алдына куйган иң беренче мөһим бурычы — Мөбарәкне соң чиккәчә яманлап, каралтып, пычракка буяп бетерү. Шул сыналган алымы барып чыкса, Кадрия, һичшиксез, Мөбарәктән баш тартачак, һәм... Хәер, ул турыда уйларга иртәрәк әле. Хәзер исә яшь, чибәр, сөйкемле вә татлыдан-татлы затны сөйләндерергә, мавыктырырга, аннары...

Гранитның күзләренә шушы көннәрдә генә ерткычларча туздырып, сөреп ташланган Киндер, Аккош һәм башка күлләрнең урыннары чалынды, һәм Мөбарәкнең түрә-монтагайлар белән чәкәләшеп, җинелеп, хурлыклы төстә авылдан качып китүе кинокадрлардагы сыман, бер-бер артлы җепкә тезелгән шикелле хәтереннән кичте. Аның шатлыгыннан тыелгысыз рәвештә көләсе килеп китте. Менә ул машинасын урманга борды.

— Чү! Без кая барабыз соң? — диде яшь хатын, кыбырсып.

Кадриянең кыбырсуын үзенчә, ирләрчә аңлады яшь ир:

— Коммунизмга!

— Э-э-э, барырсың ач килеш... Өйдә әнинең кышлык утыны юк, печәне дә... — дип мыгырданды Кадрия.

— Хи, утын-печән проблемамыни безнең өчен! Ләкин аңарчы әле ни... — Гранит, әсәренеп, уң кулы белән Кадриянең калку, йомры күкрәген сыйпап-сыпырып алды. Моның белән ул: "бүген син — миңа, ә иртәгә мин — сиңа!" ди кебек иде.

Мәгәр, эшләр тирәнгә киткәнче әле үзара кайбер мөһим мәсьәләләрне ачыклап алырга кирәклеге зарур иде. Әйтик, Гранитның фельшер-акушер хатыны... Буйга зур булмаса да, төскә-биткә ярыйсы гына үзе,

акыллы да, усал да һәм шул ук вакытта нечкә күнелле дә сыман. Әмма ни хикмәттер — кимчелегеме, житешсезлегеме — таза, көчле ир-ат кавеме медпунктка килсә, Сабина һич сәбәпсезгә чиядәй кызара, каушый. Теге адәм тәганәсе чибәр дә булып куйса, рәис кызы үзенен кияүдә икәнлеген дә онытып жибәрә... Ә инде бер мизгелдән сон дәррәү анына килә дә, Дон Жуаннын ымсындыргыч кочагыннан оста гына шуып чыга, төзәтенә, аннары берни булмагандай, тынычланып, үз дәрәжәсен белеп кенә, эшкә керешә. Менә шул сәер ханымнын холык-фигылен, табигатен бүгенгәчә өйрәнә алмыйча изалана Кадрия. Чыннан да, әллә нинди ул Сабина, медицинага ялгыш килеп эләккән бугай. Анда зур артист сәләте бар шикелле һәм ана медицина училищесын түгел, ә театр училищесын тәмамларга кирәк булгандыр ахыры!.. Кызык, Сабина өендә Гранит белән ничек аралаша, анлаша? Алар бер-берсен яраталармы, хөрмәт итәләрме икән? Шулай да... шулай да кияүдәге ак халатлы хатыннын эшендәге хикмәтләрен һичничек анлап һәм анлатып булмый. Ә бәлки Сабинанын шундый тамашалар майтарып ташлавына Гранит гаепледер?

Гранит бит әле өйләнгәнче үк Кадрия белән урманнарда йөреп кеше телләренә керде. Инде менә шул ук Дон Жуан кавеме тиз йөрешле машинасына Сабинанын кулы астында эшләүче хатынны утыртып тагын урманга ашкына! Бу хәлнен дә Сабинага беленмичә, сизелмичә калмаячагына, хәтта арттырылып, күпертелеп, калага, Мөбарәккә барып ирешмәячәгенә кем гарантия бирә ала?!

Ә Мөбарәк үзе сон, үзе... Сабинаны матаена утыртып йөргән бит әле, үпкән дә әле аны... хыянәтче!

Кадрия үзе дә сизмәстән Гранитка елышты. Яшь хатыннын утлы тәне инженерны өтеп алгандай, тәмам иләсләндереп, әллә нишләтеп ташлады. Шуннан сон машина юл читенә кереп арткы көпчәкләре ниндидер чокырга төшеп, авышып туктап калды.

Гранит инде Кадрияне ашыга-ашыга үбә, ә сул кулы анын калку күкрәкләре турысындагы кофта сәдәфләрен каударлана-каударлана йолыккалый, чишә иде. Яшь хатын да аюдай таза, көчле ирнен ташып торган дәртеннән гипнозланып, әсәрләнеп, йомшак, озын бармаклары белән анын тынламаучан конгырт чәчләрен тырышып-тырышып аралый һәм янакларын, муенын сыйпый, иркәли иде.

Гранитнын кулы үз эшен эшли-эшли, ниһаять, сылу тәннен билдән түбән өлешенә житеп, дөньянын ин талантлы рәссамнары күнеләндә бик тиз ижат орлыкларын шыттырырдай, искиткеч гүзәл аякларны рәхәтләнеп, кинәнеп сыпырырга кереште.

— Ә юк... монда булмый икән, кысан, — диде Кадрия, сулышына кабынып.

— Алайса әйдә, арттагы урындыкка күчик... Гранит кысыла-кысыла шунда күчте, аннары Кадрияне дә янәшәсенә тартып алды.

— Туктап тор, әйбәтләп урнашыйм әле, — диде Кадрия, серле генә итеп.

Гранит исә әле һаман да булса яшь хатыннын билен һәм аякларын шашып-шашып сыпыруын дәвам итә иде.

— Ашыкма... хәзер, жайлашып кына бетим...

— Ух-х! Артык түзәрлегем калмады... Ач мин, бәгырем, ашап бетерәм үзенне, сөякләренне дә калдырмаячакмын, — дип Гранит бар куәтенә яшь хатынны йонлач күкрәгенә кысты. Мәгәр Кадрия билен борып өлгерде:

— Тагын бераз гына түз инде...

Гранит тәмам чыгырыннан чыга язды:

— Син нәрсә... белмисенме әллә... андый вакытта карышмаска, озакка сузмаска кирәк бит, — дип Кадриянен иреннәренә йотылды.

Әмма Кадрия ашыкмады. Чөнки ул акыллы хатын-кыз буларак яхшы анлый, белә: жинел табылган, тиз ирешелгән бәхет — бәхет түгел, чын бәхеткә бары тик үтә тырышлык белән, көч түгеп, тир агызып кына

ия булырга мөмкин! Билгеле ки, андый бәхетнең соңгы минутлары бигрәк тә тәэсирле, ләззәтле һәм татлы була!

Ләкин Гранитның һаман үз туксаны туксан. Аны гомумән бәхет төшенчәсе кызыксындырмый кебек. Ул бу тормыштан нәрсә көтә, Кадриядән нәрсә тели — аңламассың!

Ниһаять, яшь хатын Гранитны үз иркенә куйды, бүтән карышмады. Бераздан машинаның як-якка чайкалып-чайкалып китүе һәм Кадриянең ләззәтле ыңгырашуы, ә яшь ирнең татлы пышылдавы гына ишетелеп, күренеп торды.

— Җаным! Сезгә печән күпме кирәк соң, утын күпме кирәк?

— Бәгырем, күпме булдыра аласың, шуның чаклы!..

Урман эчендә кошлар концерт бирә, яшел куаклар арасыннан дымлы, салкынча җил искәләп-искәләп куя...

— Рәхәт тә соң, ай-йай!

— Рәхәт шул, рәхәт булмаса...

Әйе, дөньяда рәхәт дигән нәрсә булмаса, Гранит өр-яңа "Жигули"енә Кадрияне утыртып, бушка көпчәк туздырып, вакыт уздырып монда хәтле килеп йөрер идеме? Юк! Йөрмәс иде. Кадриягә хәтта күтәрелеп тә карамас иде ул! Ләкин, бәхетләренә, әллә кирәсенчәме, рәхәт дигән нәрсә бар шул...

— ... Кайтыр якка кузгалабызмы инде, юкмы?!

— Бүген минем ял көне. Синең дә ял бугай. Давай, кадерлем, барыйк Алмалы тауга. Аннан безнең авыл уч төбендәге шикелле генә күренә.

— И-и, нәрсәм калган минем анда?

— Баргач күрерсең, чәчәгем. Киттекме?

— Мин синең чәчәгең түгел шул, кызганычка. Синең чәчәгең...

— Кырымда ял итеп ята, — диде Гранит. — Бәлки, ял итеп яталардыр, менә синең белән минем шикелле, — дип өстәде аннары, теше сызлагандай, йөзен чытып.

— Сабина андый түгел ич... Аның турында әллә ни уйламасаңа, Гранит, дигән булды Кадрия йөзенә артык җитди төс чыгарып. Үзе киресенчә, эченнән генә сөенә, тантана итә иде.

— Үзе юкның күзе юк, диләр Кадрия! Ә мин сизеп-тоеп торам: Кырым чаклы Кырым сәхрәләрендә ялгыз башы адашмыйча, хаталанмыйча һәм чит-ят кишәрлекләргә барып чыкмыйча түзеп йөрүчеме инде ул Сабина! Аның әтисе дә, әнә...

— Син үзең дә Кырымда ял иткән кеше ич, Гранит! Чит-ят кишәрлекләргә чыкмый түзеп калдыңмы соң?

— Юк, билгеле! Әмма мин...

— Акланырга дигәндә сәбәп табыла ул, Гранит. Менә мин дә теге вакытта синең белән урманда... Син әле ул чакта өйләнмәгән дә идең. Хәзер син янә минем белән урманда. Син инде бусында: "Хатыным Кырымда, Кара диңгез кырыенда кем беләндер бака кабырчыклары җыеп йөри, ә мин менә синең белән"... дип, күңелеңне юатмакчысың! Теге вакытта Мөбарәк тә бит алдап, бүтән кыз-кыркыннар артыннан чабарга керешә, ә мин... елыйм да елыйм! Елап туйгач уйлыйм: "Мөбарәккә чит-ятлар белән типтерергә яраганны, миңа да ярар әле", дип, менә синең белән...

Гранит нәүмизләнеп:

— Минем белән генәме әле! — диде.

— Кем белән булыйм инде мин тагын?!

— Мәсәлән, Кәримуллин, Әүхәт, тагын...

Кадрия чыркылдап көлеп җибәрде:

— Котыртканнар гына алар сине!

Гранит яшь хатынга сынап карап куйды һәм шуны искәрде. Кадриянең авызы колакларына таба ерылып китсә дә, күзләре көлми иде. Мондый да салкын, битараф күзләр Гранитка күптән таныш. Чөнки

аның үз күзләре дә шундый әкәмәт, котсыз, нурсыз, куркыныч!

Нилектән соң бу?..

Мәгәр монын нилектән икәнлеген Гранит бик әйбәт белә. Ул бит балачактан ук исерек әтисенә ияреп, эчкечеләр арасында кайнашып, аларның әшәке, оятсыз сүзләрен — һәммәсен дә тынлап, ишетеп үсте. И-и, ниләр генә сөйләмиләр иде калай күзле, жете кызыл борынлы ул сәрхүшләр! Кайчакта ир белән хатын арасында гына була торган интим хәлләрне шундый да шәрәләндереп, ялангачландырып һәм тәмләп-тәмләп хикәялиләр ки, Гранит хәтта эченнән генә үз-үзенә: "Мин үскәч нишләргә кирәклеген белəм инде, боларның уңышсызлыкларын кабатламам, уңышлы якларын гына кабул итеп алырмын, ул өлкәдә тагын да югарырак күтәрелермен, тырышып-тырышып хатын-кызларның күңелен күрермен, рәхәтләнермен-кинәнермен, алар миннән һәрчак канәгать калырлар!" — ди иде.

Язмыш Гранитны үзеннән егерме-егерме биш яшькә олы апалар белән очраштырды. Аннары — институт! Анда — үзе шикелле үк боз карашлы, туң табигатьле студенткалар белән очрашты, танышты һәм...

Аннары аны күрше районга, Көмеш Елга дигән авылга практикага жибәрделәр. Анда исә Гранитның гомер юлы кияүгә чыкмыйча гына дөньяга ике игезәк малай китергән Кадрия исемле яшь, чибәр, дәртле, кайнар хатын сукмагы белән кисеште! Озак та үтмәде, Гранит шул колхоз рәисенең Сабина исемле берданбер кызына шашкын рәвештә тартылды! Юк, егет Сабинага гашыйк булмады, ул бары тик әлеге гүзәл кызның тәнен генә тели иде. Көннәрнең берендә, рәис кызына өйләнеп жибәргәч, максатына ирешкән шикелле булды ул. Аңа хәзер хәләле белән тигез гомер итәргә, рәхәтләнеп, куанып-сөенеп яшәргә дә яшәргә генә иде... Әмма Гранитның аңына бик иртә бозыклык, азгынлык сеңдерелү, үзенең дә шул коточкыч пычрак юлга кереп китүе нәтижәсез калмаган иде инде — ул женси яктан һич туя белмәс, ач күз, комсыз бәндәгә әверелгән икән ич! Сабина белән зөфаф төнен үткәргәндә дә, әллә нинди хатыннар, кызлар турында хыялланып, уйланып ятты бит ул! Менә хәзер, авылның төньягындагы тау кашлагында, Кадрия белән сөешеп ятканда да, әллә кемнәрне уйлап, исенә төшереп азаплана Гранит! Йә, нәрсә инде бу?!

Бу минутта исә Кадрия дә үзенең сәер, кызганыч үткән гомере турында уйлый иде. Әйе, ап-ачык хәтерендә... Аңа өч йә дүрт яшь булгандыр. Аларга Ленинградтан матур гына бер абый кунакка кайтты. Кадрия әтисенең энесе икән. Шул көннәрдә Ташкенттан чибәр генә бер апа да кунакка кайткан булган. Баксаң, болар яшьлекләрендә бер-берсен яратышып йөреп тә, сугыш чыгып аерылышу аркасында кавыша алмый калган китек күңелле, сынган канатлы, кыерсытылган изге жаннар, имеш. Житмәсә, бүгенге көндә берсе "чаплашка"дан гайре юньле сүз әйтә алмаучы шовинист маржа белән, икенчесе — үзеннән кырык яшькә олы бабайдан "кәнтәй" дигән сүзләр генә ишетеп, бик интегеп дөнья көтәләр ди. Менә, ниһаять, алар очрашалар һәм...

Кадрия бер төнне уянып китсә... янәшәдә генә кыймыл-кыймыл килеп яталар. Тәрәзәдән төшкән ай яктысында теге матур апаның татлы елмайган йөзе, рәхәтлектән кысылып бетә язган күзләре шәйләнә, аның ләззәтле ыңгырашуы да аерым-ачык булып ишетелә иде. Ә тәти абый исә каударлана, мышкылдый, тагын әллә нишли, әллә нишли...

Кадрия иртә белән уянганда, өйдәгеләр барчасы иртәнге чәйне эчеп утыралар һәм нәни кыздан һеһелдәп-һеһелдәп көләләр иде.

— Уянган да... күзләрен тозландырып миңа карап тора, — ди Ташкент апа.

— Нишләп мин күрмәдем соң аны? — ди Ленинград абый.

— Син кеше-кара күрерлек идеңмени ул чакта!

Тагын көлешәләр.

Кадрия оялып, юрганы эченә башын яшерә.

— Әй, кызый! Кил әйдә, безнең янга, ашарга! — ди аңа Ташкент апа.

— Куркак ич ул! Тешлибез ич без аны! — ди Ленинград абый.

Кем куркак? Кадрия куркакмы? Куркытырсың аны!

Нәни кыз юрганын ачып ташлый да, торып, тегеләр янына бара: менә ул нинди батыр, янәсе. Тегеләр, билгеле, гөр килеп көлəләр, кызның башыннан сыйпыйлар, аркасыннан кагалар, аннары үз яннарына утыртып ашатырга, сыйларга тотыналар. И-и, нинди генә татлы ризык, нинди генә тәмле күчтәнәч юк иде ул чакта өстәлдә! Кадрия хәтта шул татлы ризыклар, тәмле күчтәнәчләр хисабына Ташкент апа белән Ленинград абыйның төнге гөнаһларын эченнән генә гафу да иткән иде әле. Әмма... төн уртасында янә теге хәлләр кабатлангач, кыз Ташкент апа белән Ленинград абыйны тәмам күрә алмас дәрәҗәгә житте. Мәгәр, "гаеплеләр" Кадриягә кибеттән курчак алып биргәч кенә эшләр җайланган кебек булды. Ләкин тора-бара Кадрия үзе дә уйлана һәм апа-абыйларның берберсенә нинди мөнәсәбәттә булуларын ныклап күзәтергә, өйрәнергә һәм аннары аларның төнге маҗаралары белән дә җентекләп кызыксынырга, соңыннан, җай чыкканда, оят нәрсәләр турында да читләтеп-читләтеп кенә сораштырырга кереште.

Андый чакларда олылар шаккатып, тел шартлатып, башларын чайкап куялар иде:

— Ну-у бу хәзерге яшьләрне! Туганда ук медицина институтына кереп туалар инде әллә?

— Булыр, булыр! Кәбирә апа үзе дә...

— Юк, Кадыйр абыйга күбрәк охшаган бу бала!..

Әнә шуның ише сөйләшүләрнең дә шаһиты була иде Кадрия. Андый чакларда ул:

— Ә минем Ташкент апага охшыйсым килә, — ди. Сәбәбе, әлбәттә, төн уртасында уянып күрә, күзәтә торган хәлләр инде!... Әмма, беркөнне, Ташкент апа белән Ленинград абый әрләшеп-талашып аерылыштылар. Араларыннан кара мәче үтеп китте ахрысы. Шуннан соң Ташкент апа бабакае тарафына, Ленинград абый марҗасы янына юл тотты. Шулай итеп, Кадриянең берсеннән-берсе шикле, кызыклы сорауларына теләп, рәхәтләнеп, көлә-көлә җавап кайтаручы кешеләр дә калмады.

Аңлашыла ки, бу вакыйгалар нәни кызның күңел төпкелендә тирән бер эз булып сызылып калды. Ул гел теге төнге хәлләр турында уйлый, аны бүтән хәлләр белән җентекләп чагыштыра, баш вата иде. Ләкин, кызганычка каршы, җанын борчыган, күңелен бимазалаган, йөрәген дулкынландырган катлаулы сорауларга ул һичничек җавап таба алмады. Әле ул гынамы! Көннәрнең берендә, кызны аптырашка калдырып, Кадриянең әтисе бүтән апага яшәргә китеп барды!

Әнисе нишләдеме? Ул отыры усаллана төште, тиз кызып, ярсып китүчәнгә әверелде. Ана белән кыз арасында беренче тапкыр, аңлашылмаучанлык барлыкка килде, упкын хасил булды. Бу — Кадриягә гаҗәп дәрәҗәдә авыр тәэсир итте. Кыз инде элеккечә серләрен иң якын, иң кадерле әнисенә сөйләмәс булды, хисләрен дә иптәш кызларына түгәргә, бушатырга жилкенмәде, ашкынмады. Гүя аның юлына кемдер биек киртә корды, җанын читлеккә яшерде, кулларына богау салды, аякларын тышаулады. Кадрия үзен дөньядан ваз кичкәндәй тойды, һәммә нәрсәдән читләште, ераклашты, бигрәк тә женестәшләреннән — хатын-кызлардан качарга тырышты!

Әмма Кадриянең тормышында мондый сүрән, болытлы, җилледавыллы көннәр озак дәвам итмәде. Бервакыт, аларга Пермьнән Кәбирәнең туганнан туган сеңлесенең малае кунакка кайтты. Боря исемле иде ул. Кадриядән ике яшькә олы. Татарча бик начар белә — өйрәтмәгәннәр бугай. Һаман урысча гына сөйләшә.

Менә шул малай Кадрияне ошатты бит! Кадрия дә Боряны үз итте.

Әлбәттә, Кәбирә сеңлесенең малае белән берднбер кызының дуслыгына каршы килмәде... Кадрия белән Боря аглый белән таглый сыман гел бергә булдылар. И-и, кайларга гына бармады алар, нинди генә

уеннар уйнамадылар. Иң яраткан уеннары — өйләнешү, аннары әти һәм әни булып уйнау иде.

Шулай бер көнне Кәбирә урманнан кура җиләге җыеп кайткач Кадрия белән Боряның күзгә-башка чалынмауларын шәйләп, тавышларының да ишетелмәвен искәреп, кеше-карага әйтмичә, шыпырт кына эзләргә керешә. Таллыкларны кат-кат тикшереп чыкты, су буйларыннан әйләнде, тирән-тирән чокырларны, әвен базларын очлы карашы белән актарып, төпченә-төпченә карады. Хисам күленә барып килде — юк та юк болар! Өйгә кергәч, ниндидер тавыш ишетеп караватастына күз салган иде — чалкан авып китә язды: яталар, мин сиңа әйтим, ярым шәрә килеш! Кадрия өскә караган, Боря — аска!...

Аһ-һ! Нишләтәсең инде боларны, йә?!.

Кәбирә тешләрен селкенгәнче кысса-кысты, иреннәрен канатканчы тешләсә-тешләде, әмма тузде — бу хәлне кешеләр арасында чыгармады. Шуннан соң Боря да җәйге каникулны тәгәлләп бетермичә китеп барырга мәҗбүр булды. Бу вакытта Боряга нибары тугыз, ә Кадриягә җиде генә яшь иде бит ..

Ләкин... үткән көннәр, аккан сулар үзенекен эшли, табигать һаман үсештә, үзгәрештә — карт агачлар череп ава, яңа, яшь үсентеләр шытып чыга, баш калкыта, кояшка таба үрелә!

Кешеләр дә шул агачлар кебек — берәүләр картая, сула, икенчеләре, киресенчә, көннән-көн сылулана...

Әнә, Кәбирә дә биш ел эчендә шактый ук олыгая, чүгә төште. Кадрия исә бөтенләй танымаслык булып үзгәрде, тулыланды, буйга да әнисен куып җитә язды!

Ана ашарга әзерләп, табын җыеп йөргән кызына күз салып, сөенеп:

— Телеграм баганасы, олы юлга маяк ул, — дип көйләп җибәрә иде.

Кадрия үпкәләми. Чөнки белә: быел аларга Пермьнән Боря кайтачак! Ә Боря буйга, җилкәләренең киңлегә буенча — Кадрия ише генә түгел инде сиңа!..

Чынлап та... Алмагачлар һәм шомыртлар күбектәй ак чәчкәләреннән арынып бетәргә генә өлгерделәр — авылда Боря пәйда булды. Үскән, тазарган. Бигрәк тә тавышы калынаеп киткән. Ә күзләре, кечкенәдән угрылыкка йөреп шомарган кешенекедәй, бер ноктага гына төбәлеп тора алмый, тынгысыз, хәрәкәтчән! Куллары да һич ару-талуны белми икән: әле теге әйбергә барып кагыла, әле бу нәрсәгә килеп орына — кызыксына!

Кадрияне күргәч, авызындагы сагызын чартлата-чартлата, шат тавыш белән:

— О! Боже... Катюша? Неужели это ты! — дип, туганнан туган сеңлесен иңнәреннән кочып күкрәгенә кысты. Аннары Кәбирә апасына таба китте, елмаеп-көлеп күреште. Шундук өй эчендәге пөхтәлекне, чисталыкны мактап алды. Аннары инде букчасыннан, чемоданыннан күчтәнәчләр чыгарып, өстәл өстен тутырып куйгач, берсеннән-берсе үзгә, берсеннән-берсе татлы-баллы, әче-төче нигъмәтне күреп, Кәбирәнең исе-ушы китте...

Боря исә, Кадриянең нәзек биленнән эләктереп, тигез, матур, яңгыравыклы калынча тавыш белән:

— Ярый, Кәбирә апа! Без Кадрия белән бераз йөреп керәбез! — диде.

Алар ишегалдына чыктылар. Дәү, симез, ак әтәч җитәкчелегендә — кара, чуар һәм ак тавыклар яшел чирәм арасында кортмы-нәрсәме чүпләп йөриләр иде. Әтәч, каршыларында пәйда булган үсмер егет белән кызга, башын кыегайта-кыегайта, әле бер, әле икенче күзен төбәп карап-карап торды да, ниһаять, куркыныч янамавын аңлап булса кирәк, шундук бер тавыкны "эләктереп-каптырып" алды, сөенеченнән канатларын җәеп биеп куйды да, янә, тирәсенә җыела башлаган тавыкларның берсенә "һөҗүм" итте.

— О-о, какой молодец! — диде Боря. — Эх, мне бы так!..

Кадрия шаркылдап көлеп җибәрде. Чөнки күптән түгел генә аларга килгән җор телле бер тол хатын әлегедәй хәлне күргәч:

— И-и, шушы тавыклар хәтле дә бәхетебез юк бит безнең, Кәбирә, җаным! — дип уфтанган иде.

— Ә мин сине үлеп сагындым, — диде Боря.

— Мин дә... — диде Кадрия, үзе дә сизмәстән.

Шуннан башланды инде хәлләр. Боря үзе белән алып кайткан һәм рамына "Пермь" дип язылган кара сәпидкә кызны утыртып авыл урамнарын кичте, тыкрыкларны үтте, су буйларында йөрделәр. Аннары, җаннары-тәннәре белән авылга гына сыя алмыйча, кырлар буйлап, күзләре күргән, күнелләре теләгән тарафка китеп бардылар. Менә шушы тау кашлагына җиткәч, борчак басуыннан чак кына эчтәрәк булган кечкенә күл читенә кереп, үлән өстенә ятып күкне, күктә йөзгән юка, калын, ак, кара болытларны күзәттеләр, кузгалак, көпшә, какы, юа ашадылар, төрледән-төрле чәчәкләр җыйдылар, такыя үрделәр. Такыяне Кадрия сары чәчле башына киеп куйды. Коңгырт бөдрә чәчле Боря сокланып:

— Син чын патша кызына охшагансың! — диде. Шундый мактаулы, тылсымлы сүзләр ишеткәч, Кадрия үзен бер карышка үсеп киткәндәй хис итте, аның Боряга нинди дә булса яхшылык эшлисе килде. Ул һич сәбәпсез көләргә, чытлыкланырга, шаярырга тотынды. Егет, гүя шуны гына көтеп торган: кызны күтәреп тиз-тиз әйләндерергә керешге. А-а... Тау әйләнә, авыл әйләнә, күк әйләнә, бөтен дөнья...

— Ай, үләм, башым әйләнә! — диде Кадрия, ниһаять, җиңелүен танып.

Боряга кызның кычкыруын ишетүе рәхәт иде. Дөрес, аның үзенең дә башы зырылдап әйләнә иде. Әмма ул моны сиздермәде, кызны күтәргән көе һаман әйләнде дә әйләнде. Аннары Боряның аяклары тыңламый башлады, кул буыннары йомшарып китте һәм ул кыз белән бергә гәрселдәп үлән өстенә егылды.

— Ай-вай-вай, — дип чәбәләнде Кадрия, артык нык башы әйләнүдән күңеле болганып китүен тоеп.

Әмма Боря — тәҗрибәле шайтан — иркәләп-сыйпап кызны тиз тынычландырды. Аннары Пермь егете Көмеш Елга кызының тулы, татлы иреннәренә йотылды.

Күп тә үтмәде, Кадрия күлмәк каптырмаларының бер-бер артлы чишелүен, аннары билдән түбән таба нәрсәнендер шуып төшүен искәрде. Кызның күз алдыннан кайчандыр булган хәлләр: Ташкент апа, Ленинград абый, әнисе, чит абый, үзенең — җиде, Боряның тугыз яшьлек чагы, кинокадрлардай, чагылып узды. Кадриянең кинәт шаркылдап-шаркылдап көләсе, аннары нигәдер сулыгып-сулыгып елыйсы килеп куйды:

— Боря! Кирәкми... Без бит туганнар! Боря...

— Ну да-а... Туган сиңа! Минем әтием рус. Ә синеке? Мин бит сине яратам, Кадриякәем, бик-бик яратам! — диде Боря каударлана-каударлана. Шундый канатлы, кайнар сүзләр дә әйткәч, Боряга ничек ышанмыйсың ди инде!

Кадрия карышудан туктады, йомшарды, аннары Ташкент апа исенә төшеп һәм шул апага охшарга тырышып, ыңгырашып җибәрде.

— Менә бусы әйбәт! — диде Боря, дәртләнә төшеп. Бик әйбәт!

Бераздан чатнап, су эчәселәре килеп, Хәмидулла коесына юл тоттылар. Барганда гел шаярдылар, көлделәр, сәпид белән егылып-егылып киткәләделәр. Боряның игътибары Кадриядә генә, ә Кадриянеке — Боряда гына. Кадриягә Боряның үзен кирәгеннән артык ирекле һәм күпне күргән акыл иясе сыман тотуы аеруча ошый иде. Чөнки Боряның дөньяда белмәгән, күрмәгән нәрсәсе юк та шикелле — әллә Кадриягә генә шулай тоеламы?!

Ни генә булмасын, Пермь егетендә артистлык сәләте дә гаҗәп көчле иде шул! Әгәр дә ул шушы юлдан китсә, үскәч вә укыгач аннан

менә дигән актер чыгар иде мөгаен! Әмма кызганыч, Боря бу минутта киләчәк турында уйламый гына түгел, аны башына да китереп карамый шул! Егетнең бөтен хис-тойгыларын, югарыда әйтелгәнчә, Көмеш Елга кызы гына биләп алган иде. Боряга Кадриянең искиткеч сылу аяклары һәм рамның аркылы тимеренә зарланмый-нитми, рәхәтләнеп, чикылдый-чикылдый, җәелеп утырып баруы, аннары, мул гына булып беленеп торган күкрәкләре ошый иде.

Килеп җиттеләр. Кайчандыр бура булган урында тирән чокыр гына торып калган һәм шул чокырдан, гүя Хәмидулла бабайны онытмаска кушып, су ага да ага.

Боря: "Что за родник?" дип сораган иде, Кадрия: "Не родник это, а ключ без замка!" дип көлеп куйды. Боря, сусыл үлән өстенә тезләнеп, чокырга таба сак кына сузылып, учларына салкын су тутырып алып, йотылып-йотылып эчүче кызга кызыгып карап торды да, үзе дә тезләнеп, чокырга үрелеп, кызгылт-итләч учларына уйнак су тутырып алып, комсызланып-комсызланып эчәргә кереште.

Кадрия, эчеп туйгач та чокыр яныннан китәргә ашыкмады, Боряга су чәчрәтергә тотынды. Пермь егете дә җавапсыз калмады, суны Көмеш Елга кызы өстенә учлап-учлап сипте. Бераздан, икесе дә манма су булып, өс-башларын киптерер өчен, агачлар арасына кереп киттеләр... Кояш баеганда гына чыктылар алар аннан. Кадриянең җилкәсе, Борянын тезләре үлән сүленә буялып ямь-яшел булган иде...

Икенче көнне дә Боря белән Кадрия соң гына, ал чәчәкләрнең сабакларындагы дегеткә ягылып кайткач, Кәбирә нидер сизенеп, тавыш чыгармакчы иде, әмма... тотылмаган — карак түгел — телен тешләргә мәҗбүр булды. Шулай да егет белән кызны шелтәләп алды.

Шулай көннәр арты көннәр, атналар арты атналар үтә торды. Боря авыл егетләре белән дә уртак телне тиз тапты, дуслашты. Кызлар да аны чит итмәделәр. Агайлар-апалар да Пермь егетен үз күрергә өлгерде, хәтта әби-бабайлар да сокландылар бу "урыс малае"ның бик тиз генә татарча сөйләшергә өйрәнүенә! Ә Кадрия, укучы аңлыйдыр инде, Боря-Боренькадан бик әйбәтләп урысча "грамотный" сөйләшергә өйрәнде. Кыскасы, Пермьнән бертуган сеңлесенең малае кайткач, авылда Кәбирәне көендерә торган түгел, сөендерә торган хәлләр күбрәк булып чыкты. Менә шулай матур гына яшисе, тормышны акыллы гына дәвам итәсе иде дә бит, ләкин... ләкин адәм балаларының хатасыз яшәргә сәләтләре юкмы, әллә гел матур тормыш корып, парлашып-сайрашып яшәргә лаек түгелме алар?!

Көннәрнең берендә гаҗәп бер вакыйга булды... Күршеләрнең үгез бозавы бакчага чыккан да, бәрәңге сабакларын аударып-таптап йөри! Кәбирә балчык ата-ата бозауны куып барганда, кинәт нәрсәгәдер сөрлегеп китте, караса... Буразнада Боря белән Кадрия!

Кәбирә шундук:"Юк, юк! Монын булуы мөмкин түгел! Күземә генә күренгәннәрдер", — дип уйлады һәм соныннан да, башка вакытта да үзен шуңарга ышандырырга тырышты.

Әгәр дә Кәбирә шулчакта түземсезлек күрсәтеп тавыш куптарса, ызгыш-талаш чыгарса һәм авыл халкы бу тамашаны сәгате-минуты белән белеп алган булса — бетте, и чәйнәрләр иде аннары ана белән кызны, и көләрләр иде алардан бот чабып. Чәйнәп-көлеп туйганнан соң:

— Кадриянең болай булачагы күптән билгеле иде! Әнисе Кәбирә дә, әнә, ниләр майтарып ташлады ич яшь чагында! — диярләр иде.

Мондый һәм моңа охшашлы чәнечкеле фикерләр күңеленә килгән мизгелләрдә Кәбирә эсселе-суыклы булып китә дә: "Ярый әле... түздем, сабырлык күрсәттем, юкса, кеше күзләренә ничек күренер идем?!" — дип куя.

Шуннан соң нәрсә булдымы? Боря Балык Бистәсе пристаненда су трамваена утырыр алдыннан кызның күзләренә туры карап, сары чәчләреннән сыйпый-сыйпый пышылдады:

— Рәхмәт, Катюша! Рәхмәт!.. Мин сиңа гомерем буе бурычлы!

Мин сине онытмам!... Мин... үскәч, кайтырмын әле!.. Мин... әлбәттә, сиңа өйләнәчәкмен!.. Ә хәзергә.. Хуш-ш!..

Ул чакта Кадрия тыела алмыйча елаган иде. Хәтта "Әллә үләргәме икән?" сыман юләр фикерләр дә күңелендә баш калкытып-калкытып куйгалады.

Әмма вакыт дигәнең иң әйбәт доктор икән. Озакламый Кадрия янә үзеннән ике яшькә олы Гранит исемле егеткә гашыйк булды. Гранит Кадрияләр мәктәбенә Әтиле авылыннан килеп укып йөри иде. Аннары ул бәләкәй авылда клуб та юк. Кино карарга, каладан ук килгән артистларның спектакльләрен, концертларын тамаша кылырга да Көмеш Елгага йөриләр Әтилеләр. Менә шул чакларда шәпләп уралып кала да инде Кадрия Гранит тирәсендә. Ләкин, гаҗәпкә каршы, Гранит Кадриягә битараф иде әле. Чөнки Әтиле егетенең соры күзләре гел колхоз рәисе йортының тәрәзәләрендә генә. Ә анда... Рәис кызы Сабина яши.

Дөрес, Сабина чибәрлек ягыннан Кадриядән бераз кайтышрак, ә менә атасының властьлылыгы, дәрәҗәлелеге ягыннан... Бит Кадрия әтисен белми дә. Әнисе дә гади эш кешесе генә... Димәк, аңлашыла ки, Гранитны бары тик властьлы, дәрәҗәле кешенең кызы гына өметләндерә, канатландыра... Димәк, төптәнрәк уйлап караганда, Гранит Сабинага түгел, ә властька, дәрәҗәгә гашыйк булып чыга!..

... Кадрия уйларыннан арынды, Гранитка карады. Яшь ир тирләгән һәм манма су булган иде...

Ике көннән Кәбирәнең капкасы каршында, һич көтмәгәндә утын тавы пәйда булды. Тагын берничә көннән шул ук Кәбирәнең хуҗалыгында бер-бер артлы калкып чыккан әллә ничаклы печән кибәне бар иде инде.

Болар һәммәсе дә авыл халкын таң калдырды.

Кәбирә исә, кызыксынучыларга, төпченүчеләргә гел бер үк сүзләрне кабатлады:

— Менә минем кызым медпунктка кереп егылган бер дәү урындагы түрәне дәвалап аякка бастырган да, Аллаһның рәхмәте төшкере, изгелек йөзеннән, шул түрә безгә хәзер... утын, печән кайтарттыра!

Түтиләр, әби карчыклар "И-и, и-и" дип, гаҗәпләнеп баш чайкыйлар, абзыйлар, карт бабайлар, йөзләренә газаплы уйчан төс чыгарып, тамак кырып куялар иде.

Шулай да авылның усал, вә төртмә телле һәм шаян, җор телле кешеләреннән котылып буламыни! Алар:

— Беләбез инде Кәбирәнең медпунктта җыештыручы булып эшләүче кызы ул түрәне ничекләр итеп дәвалаганын!.. — дип мыек астыннан гына елмаялар иде.

Гранит урманга барып утын кисеп, печән чабып азапланып йөрмәде әлбәттә. Ул турыдан-туры күрше районның урман хуҗалыгына, элеккеге һәм яңа дус-ишләренә шалтыратты. Аннан аңа:

— Агу сиптерә торган җайланмага бер көпчәк табып бир башта... Аннары сездә мамык җыя торган комбайн күгәреп ята икән. Шуны безгә җибәрә алсаң — урман-болын синеке! — диделәр.

— Нәрсә, әллә мамык үстерергә җыенасызмы?

— Юк ла, мамык комбайнын без СК-4 комбайнына алыштырып алырга килештек. Ә соңыннан ул комбайнны без колхоз яки совхоздан трактор ише техникага алмашачакбыз — дигән җавап ишетелде телефон трубкасында.

"Ярар, килештек!" — диде Гранит. Үзе трубканы куйгач уйга бирелде. Чөнки мамык комбайны әлеге колхозга әнә шундый мәгънәсез алмашулар аркасында килеп эләккән иде дә инде! Менә хәзер ул Урта Азия комбайныннан котылырга җай чыгып тора! Өстәвенә, колхоз рәисе санаторийда ял итә һәм төп креслода кияү кеше — Гранит утыра бит!

Гранит селектрлар аша парктан механикны чакырып китерде:

— Шундый-шундый заказ бар! Син, давай, агу сиптерү җайланмасына бер көпчәк тап! — диде.

Үзеннән югарырак пост биләүчене, кем булуына карамастан, тыңларга һәм хөрмәт итәргә күнеккән механик, шундук:

— Ярар, эшләрбез! — дип чыгып китте. — Шул ук көнне, көпчәге алынып, "Аммиячная" цистернасы янтаеп ятып калды һәм аннан гөрләп чөгендер кырына таба аммиак селитрасы акты.

Ә мамык комбайны, ни өчендер, ферма янәшәсендәге каралты эчендә түрдә үк кысылып калган булып чыкты! Җитмәсә, аның янына ит комбинатыннан, сугымга тапшырылган сыерлар өчен, акча урынына, сөяк оны кайтарып тутырганнар икән! Икенче катта исә, целлофан капчыклар эчендә — ашламалар...

Әмма иң кыены — парктан өч механизатор ияртеп килгән механикны һәм аларга ярдәмгә чакырылган дүрт-биш ферма эшчесен нык аптырашта калдырганы — менә ни иде: теге чакта, эченә сөяк оны салып китерелгән кәгазь капчыкларны кызмача ирләр машинадан күтәреп алып корылма эченә керткәч, теләсә ничек ыргытып ертып бетергәннәр икән! Аларны хәзер һичничек урыннарыннан кузгатып, күчереп куярга мөмкин түгел! Азия тарафларына китәргә тиешле комбайнны, ничек кенә булса да, җаен-чарасын табып, тоткынлыктан азат итәргә, тышка чыгарырга кирәк лабаса!..

Эшчеләр "Тегеләй итикме? Болай итеп карыйкмы әллә?" дип гөрләшеп торганда, яннарында Гранит пәйда булды.

— Хәзер үк стенаны кисегез! Тик, карагыз аны, комбайн сыярлык булсын! — дип боерды инженер-рәис.

Шундук бензопычкысы да табылды, стенаны да кыеп төшерделәр. Мәгәр комбайнны сөйрәтеп алып булмады әле, аңа ниндидер трослар беркетелгән һәм шул трослар сөяк оны астында күмелеп калган икән!

Гранит ачуыннан төкергән иде, төкереген җил эләктереп алып чалбарына сылады.

— Вы что? Кайчаннан бирле бер кочак калай-салайны сөйрәтеп-тарттырып чыгара алмыйсыз!.. — дип җикеренде яшь түрә.

Ике механизатор һәм дүрт ферма эшчесе, ниндидер яшерен көч ихтыярына каршы тора алмагандай, буйсынып, шундук дәррәү комбайнга ябыштылар. Кәримуллин дә чылбырлы кызыл тракторына менеп кунаклады. Механик Гранитка карап куйды: амбар белән тегермән арасындагы киң, такыр юлда әле генә Кырымнан, ялдан кайтып төшкән Сабина басып тора иде.

"Типтергәнемне ишеттермәгәннәрдер ич", — дип уйлады инженер-рәис, ләкин эчендәген тышка чыгармады, сиздермәде.

Менә тростның сузыласы төше сузылып бетте — комбайн "эх" тә итмичә трактор артыннан иярде. Әмма шул мизгел йөрәкләрне тетрәндерерлек, аек башларны да сызландырырлык тамашага юликты Сабина... Комбайнга бәйләнгән һәм сөяк оны астында күмелеп калган уртадагы төп тростның ыргагы корылма баганасына эләгеп торган булган икән! Комбайн тышка чыгып бетәргә генә өлгерде, уртадагы багана — ярсыган тракторның алыптай көченә каршы тора алмыйча — авып китеп, корылманың икенче каты, ашлама-фәләннәр белән бергә, сөяк оны өстенә җимерелеп тә төште!

И-и, купты шулчакта тавыш, китте кычкырыш! Һәммәсе Кәримуллинга ябырылды. Янәсе, корылманың җимерелүенә һәм ашлама белән сөяк онының катышып бетеп ярамаслык хәлгә килүенә бары тик Кәлимулла гына гаепле!

Ә кызыл йөз, дерелди-дерелди, үзенең монда тамчы да гөнаһысы булмавын, хуҗаның фәрманы буенча гына эшкә керешкәнлеген әйтеп, аңлатырга тотынды. Бүтән механизаторлар вә эшчеләр дә бу минутта, табигый инстинкт колына әверелеп китеп, исән калып яшәр өчен үзләрен ничек кенә булса да акларга теләделәр.

Янәшәдә олы тормыш юлы узган гаять җитди, бай тәҗрибәгә ия механик агайның булуы һәм аның үзен гаҗәп сабыр, тыныч тотуы ярап

куйды әле, теге калай әтәчләр шундук сүрелеп, басынкыланып калдылар. Чынлап та, нидән куркырга? Аларны беркем дә җавапка тарттырырга җыенмый ич! Ә инженер Гранитка килгәндә, аның кайнатасы район җитәкчеләренә якын, хөрмәтле шәхес ләбаса! Шулай булгач... әйтер сүзенне әйтмәс, күрер күзенне күрмәс, ишетер колагыңны ишетмәс ит тә бетер!..

Гранит та "карга карганың күзен чукымас"лыгын белә иде. Ул күккә күтәрелгән сөяк тузанының басылганын, таралып беткәнен дә көтмәстән, Кәримуллинга кызып-кызыпниләрдер әйтте, аңлатты. Шуннан соң... җыелган кешеләр сөяк оны белән ашлама "ботка"сының якындагы елгага эттерелеп-эттерелеп ташлануын аю биеткәндәге шикелле рәхәтләнеп тамаша кылдылар. Тик Сабинаның гына йөзе борчулы, күзләрендә яшь иде:

— Террорист син, белдеңме?! — дип пышылдады ул иренең колагына.

Гранит исә, күкрәген киереп:

— Шулай яшәдек, шулай яшибез, шулай яшәячәкбез — большевикларча, решительный булып! — дип җавап кайтарды.

— Әнә... кара!

Анда, су өстендә исәпсез-хисапсыз үле балыклар ага иде.

— Ну и что! — диде Гранит төкселәнеп. — Ул шельма балыкларга мин үләргә кушмадым, үлмәсеннәрие! — һәм Сабинаны гына түгел, барча кешене шаккатырып, әле генә урман хуҗалыгыннан килгән КамАЗга таба атлады. Шоферга ниләрдер әйтте дә, эшчеләр янына килде:

— Мамык комбайнын КамАЗга төяп җибәргәч, корылманы тәртипкә кертегез, элекке хәленә кайтсын! — диде инженер-рәис һәм хатынын машинасына утыртып, өенә кайтып китте.

Төнлә Сабина ире янына ятмады, елый-елый:

— Медпунктка кайтарыр өчен дарулар сатып алырга акча юк, табарга да теләмисез, иеме, ә халык байлыгын теләсә ничек әрәм-шәрәм итеп бетерергә, суга салып агызырга, балыкларны агулап үтереп бетерергә ярый, иеме? — диде. — Йә, нәрсәгә сөйрәп чыгарттырдың инде аннан ул күгәреп беткән чит җир комбайнын?.. Нәрсә оттың инде шул тимер-томырны урыныннан кузгаттырып?..

Сабина сулкылдый-сулкылдый тагын ниләрдер әйтмәкче иде, Гранит шыпырт кына килеп, хатынының башын күкрәгенә кысты:

— И, юләрем минем! Юкка дулыйсың, тәрәзә бик калын, аны ватып чыгарга синең белән минем генә түгел, әллә кемнәрнең дә көче җитәрлек түгел!.. Ә мамык комбайны... ул безнең төзелеп ята торган йортыбызның икенче катына өр-яңа нарат бүрәнәләре һәм такта-материаллар булып әйләнеп кайтачак!.. Гранит көлеп куйды. — Халык байлыгы дисең... Андый байлык юк!.. Ил байлыгы, колхоз байлыгы гына бар!.. Халык ул — сарык! Халык ничаклы надан, авыру, зәгыйфь, тешсез булса, безгә аның белән идарә итүе шалчаклы җиңелрәк! — Гранит хатынын күтәреп алып үз ятагына таба юнәлде. Сабина карышмады. Ул инде "... йортыбызга өр-яңа нарат бүрәнәләр"не ишеткәч үк, Кырымда, диңгез ярында Кавказ егете белән гыйш-гыйшрәт уеннары уйнап йөргәнен оныткан, эрегән һәм Гранит та, гүя, Кадрия белән типтермәгән...

Алар, ниһаять, сагынышкан атлы кыланып, аннары... бер-берсенә аркаларын терәп йокыга талдылар.

## Өченче башлам

Кеше гомеренең байтак өлеше юлда үтә, диләр... Бу чыннан шулай. Юл — өмет тә, яшәү чыганагы да ул. Юлда йөрүне өнәмәгән кешене мүкләнгән ташка тиңлиләр. Юлларда йөрергә һәвәс кеше күпне күрә, белә һәм шомарган ташка әверелә.

Менә әле Мөбарәк тә, Кавказ кешесе иярләгән дүрт көпчәкле кара айгырда бара. Кавказлы Давид исемле, фамилиясе Кикиладзе икән. Грузиянең коньяк өлешендә, авылда туып үскән. Ике чиркәүле бу авыл

тау елгасының уң ягында, ә елганың сул ягында — өч мәчетле зур гына төрек авылы ди. Дөрес, ике авыл арасына, тарихи сәбәпләр аркасында, күпер салынмаган һәм... төрле диндәге ике халык бүгенгәчә бер-берсе белән бик аралашмыйча, кунак-фәләнгә йөрешмичә, сәер рәвештә яшәп ята, имеш.

Шулай да мажара сөюче яшьләр теләсә кайсы вакытта елганы йөзеп яисә көймәдә кичеп чыгалар. Күнелләренә ошаган төрек егетләре дә бу якка юл салып, грузин чибәркәйләрен урлап өйләнәләр, ди. Хәлбуки, теге якның туйларында да, бу якта да кыз ягыннан беркем дә катнашмый, имеш. Бу — борын-борыннан шулай дәвам итә, ди.

Давид Кикиладзе да яшьлегендә кызыксынучан табигатьле, кискен холыклы, шактый ук тәвәккәл егет булган, төрек кызын урлап алып кайтып өйләнгән! Бүгенге көндә Давид Казанда яши, төзелеш трестына житәкчелек итә икән.

— Минем дә синең кебек яшь, таза улым бар, — диде Кикиладзе Мөбәрәккә. — Төзүче инженерлар институтын тәмамлады! Кырымда ял итә иде әле. Шушы көннәрдә кайтыр инде...

— Ә син миңа ошыйсың! — диде Давид һәм өстәп куйды. — Татарларны хөрмәткә лаеклы акыллы кешеләр дип белгәнгә күрәме икән әллә?!

Мөбәрәк елмаеп иңбашларын сикертеп куйды.

— Чынлап та ошыйсың син миңа! Иә, үзең турында сөйлә инде! — Кикиладзе каршыга йөгерүче машиналар ташкыныннан карашын алмыйча, тыңларга әзерләнде.

Бу эчкерсез, ягымлы грузин Мөбәрәккә дә ошый башлаган иде. Ул аңа үзенең тәржемәи хәлен сөйләп бирми булдыра алмады. Сөйләп бетергәч, сүзләрем ничегрәк тәэсир итте икән дип, Давидка текәлде.

— Алай... алай... — диде Кикиладзе уйланып кына һәм кесәсеннән сигарет алып, чакмасыннан ут элдерде дә, бөтнек исен хәтерләткән төтенне авыз-борыннан бөркелдереп чыгара-чыгара, юлдашына мөрәжәгать итте:

— Слүши, син давай безгә кил, безгә трактористлар житми. Калган мәсьәләләрне урында хәл итәрбез, ризамы?.. — Давид Мөбәрәккә сынаулы караш ташлады.

"Бирәм дигән колына, чыгарып куяр юлына" — шушы буладыр инде, Мөбәрәк риза булды.

Туганнан туган апасының фатирында төн кичергәч, ул Кикиладзе янына китте. Анда аңа фәләненче номерлы төзелеш-монтаж идарәсенә барырга куштылар. Анда да булды яшь ир. Ләкин, эшкә урнашканчы әле медкомиссия үтәргә, наркология һәм туберкулез диспансерларында хисапта тору-тормавын ачыкларга һәм шул арада бик тиз генә прописка мәсьәләсен дә чишеп атарга кирәк икән! Ягъни, Мөбәрәк фатирга вакытлыча яшәргә кертүче кемсәләр белән уртак тел табарга тиеш булып чыга инде.

Әмма... яшь ирне сулы, газлы, ванналы заманча төзелгән йортлардагы фатирларга кертергә атлыгып торучы табылмады. Дөрес, аның үзен генә керткән дә булырлар иде, мәгәр Кадрия дә бар бит әле, аннары тагын игезәк малайлар...

Ярый әле Казанның үзәк өлешенә якында гына бөтен уңайлыклардан мәхрүм булган бер һәм ике катлы агач өйләр бар. Шул тирәдә эзләнеп йөри торгач, Мөбәрәкне бөтен гаиләсе белән өйдәш итеп кертергә ризалык бирүче бердәнбер йөрәкле ханым табылды. Рәсимә исемле иде ул. Ире төрмәдә... Ике кызы кияүдә. Берсе Чиләбедә, икенчесе Павлодарда яшәп ята икән.

Рәсименең әле Яңа бистәдә үз өендә гомер кичереп ятучы әни карчыгы да бар. Һәр өч көннең икесен ул шунда үткәрә икән. Әгәр дә Мөбәрәк Рәсимә йортында гаиләсе белән матур гына яшәп китсә, хуҗабикә үзе әнисе янына торырга күчәсен, бирегә фатирчыларның хәл-әхвәлләрен белешергә генә, алардан фатир хакын түләтергә генә килгәләп йөриячәген

белдереп, авыл тракторчысын Бауман районының эчке эшләр бүлегенә пропискага кертергә алып китте.

Кирәкле урыннарда булып, тиешле кәгазьләрне җентекләп тутыру һәм пропискага теркәлү әлләни күп вакытны алмады. Рәсимәгә рәхмәт инде — ул тырышты. Эчке эшләр бүлегендәге "паспорт өстәл"еннән чыкканда Рәсимәнең баярак кына буаз сарыктай бүселгән букчасы тәмам шиңгән иде.

Шулай итеп, Рәсимәнең йорт кенәгәсенә, ә Мөбарәкнең паспортына прописка штампы суктырып, Жданов урамындагы бер катлы кирпеч өйгә кайтып керделәр.

Урамнардагы кызган таш һәм асфальт исеннән соң, мондагы боз тутырган чокырдагыдай салкынча һава Мөбарәкне йокысын китерерлек дәрәҗәдә изрәтеп җибәрде. Аның шундук кайда да булса ятып, мендәргә баш төртеп уйланасы, киләчәккә дөрес, төгәл бәя биреп карыйсы килде.

Мәгәр бройлер тавыгыдай эре, симез, тулы тәнле Рәсимәнең нияте башкада иде бу минутта.

— Менә инде Мөбарәк мина пропискага да кердең. Иртәгә эшкә дә барырсың. Аннары, хатыныңны да алып килерсең, балаларыңны да монда күчерерсең — яшәрсез рәхәтләнеп! Ләкин аларгача әле хәзерге олы вакыйганы билгеләп үтәргә кирәк! -дип, ул юкәдән ясалган калын түгәрәк өстәл өстенә төрледән-төрле закускалар китереп утыртты. Шкафтан алып, борыч настойкасы белән ак вино да куйды.

Мөбарәк хуҗабикәнең һәр ымын, һәр хәрәкәтен күптән агартылмаган мич янәшәсендә күзәтеп утыра иде. Гадәттә "май чүлмәге тышыннан билгеле" диләр. Әмма Рәсимә май чүлмәге генә түгел шул, аның кемлеген тышыннан гына чамалап белеп булмый. Шулай да теләгәндә, хатын-кызның кайбер уңай яки тискәре сыйфатларын — яшәү рәвешенә, хуҗалык итүенең торышына карап та сиземләргә була шикелле.

Әнә... өстәл өстендә затлы закускалар һәм исерткеч эчемлекләр. Кадриянең алтын тешләре, мәрҗән муенсалары, җиңсез, тар, үтә кыска, мәгәр күз явын алырдай матур ефәк күлмәге...

Мөбарәк маңгаен җыерды, авыр сулап куйды һәм күзләрен йомды. Аның мие арыган иде. Хәзер аның тәннәренә генә түгел, миенә дә ял кирәк! Әмма ни хикмәт, яшь ирнең күзләре үзләреннән-үзләре ачыла да шайтан-ханымның тылсымлы ак ботларына, гаҗәп килешле төз, калын балтырлы аякларына төшә!

Хатын-кыз кавемендәге серлелек, илаһилык һәм барыннан да өстенрәге — сихерчелек сыйфатлары Һаува анабыздан ук килә!

Адәм атабыз ялгызы гына мең елга якын оҗмахта яшәгәндә гөнаһ-фәләнне бар дип тә белмәгән ләбаса! Мәгәр Аллаһыбыз көннәрнең берендә Адәм саллаллаһу галәйһи вәссәламга хатынлыкка, аның сулъяк кабыргасыннан Һауваны бар иткәч:

— Бергә яшәгез, яратышыгыз, балалар табып үстерегез, ишәегез, әмма... гөнаһ агачының җимешенә орынмагыз, — ди.

Һәрһәлдә Аллаһның бу сүзләрен шайтаннарның иң баш начальнигы иблис-явыз тыңлап тора да, килеп Һауваны яман эшкә котырта башлый. Имеш, син гаҗәеп сылу, гаҗәеп чибәр! Шуңа карамастан Адәм сине яратмый, ул һаман ялгыз калырга итә, синнән читләшә... Әгәр дә менә бу тыелган агачның җимешен өшкереп иренә ашатсаң, ул синнән бер адым да калмаячак, тагылып диярлек йөриячәк, сине мәңге-мәңге сөячәк, ди. Сылулыгыннан, илаһилыгыннан бик һуш Һаувa ирен тәмам буйсындырырга, гүзәллеге каршында тез чүктерергә, хәтта, мөмкинлек чыкса, табанын үптерергә ниятләп, иблис мәлгуньнең котырыгына күнә һәм үзен дә, Адәмне дә муеннан гөнаһка батыра!

Шуннан соң, Аллаһыбыз Адәм саллалаһу галәйһис вәссәлам белән Һаува анабызны оҗмахый күктән тәмугый җиргә сөрә:

— Яшәгез, яратышыгыз, ишәегез! — ди — Әмма...

Ул соңгы сүзен әйтеп бетерми. Мәгәр җирдә ничек яшәргә

кирәклекне аңлаткан, төшендергән берничә сәхифә индерә. Билгеле ки, Адәм белән Һауваны сынап, Аллаһыбыз каршында "дан" казанган иблис тә йоклап калмый, Һаува кызларын котыртып, Адәм улларын юлдан яздырып бетерер өчен, җиргә үз балаларын, ягъни шайтаннарны җибәрә!

Сихерче! Сихер иясе! Сихерләүче! Иблис коткочысы! Шайтан вәсвәсәчесе!.. Менә ул... ахак кашлы алтын колак алкаларын җемелдәтә-җемелдәтә, ак вино салынган бәлләүр рүмкәне сак кына тотып, хәйләкәр генә елмаеп һәм ул-бу була калганда, фырт кына дөрләп кабынырга исәп итеп, Мөбарәккә каршы тарафта, өстәл буенда басып тора..

— Йә, әйдә, якынрак килеп утыр, рүмкәне кулыңа ал, киттек! — диде Рәсимә, катгый рәвештә. Ул, рүмкәсендәге винoны ялт кына эчеп җибәрде дә закускага үрелде, аннары янә шешәгә сузылды һәм мөлдерәмә тулы рүмкәне күтәреп, Мөбарәккә ымлады. — Бусы, Казан каласында пропискага керүең хөрмәтенә!

Мөбарәкнең күз алдына бер бите ай, бер бите кояш Кадриясе килеп басты. Бу хатын, әлбәттә, аның кисеп ташлаган тырнагына да тормый!.. Мөбарәк өстәл буена килеп утырды, рүмкәне читкә этте, ашарга кереште.

— Хатының бик чибәрмени соң синең?!

Мөбарәк эндәшмәде.

— Шундый-шундый әйбәттер инде ул, иеме?!

Мөбарәк "әйе" дигән сыман башын чайкады.

— Булсаңи! Ул монда түгел ич, сине күрми!..

Мөбарәк каршында елан кебек боргаланган-сыргаланган Рәсимәнең ниятенә төшенә башлады:

— Мин дә аны күрмим ич!.. Хикмәт андамыни!.. Хикмәт — минем бу минутта өйләнгән булуымда! Бары шул гына!

Рәсимә мыскыллы рәвештә чыраен сытты:

— Һай, синдә генә ди ул хатын, Бүтәннәрдә юк ди! — һәм авыштәвеш атлап, диван-караватка барып ауды. Аннары: — Йә, нәрсә... карап торасың? Кил әйдә... изгеләнеп маташма, барыбер мулла була алмыйсың! Ә мин абыстай түгел... — диде.

Мөбарәк Рәсимәнең исереклектән тона башлаган күзләренә карап: "ирсез хатын — кызганыч, ирсез исерек хатын — аяныч", — дип уйлады, һәм үз алдына төкереп куйды.

— Алдакчы! — дип кинәт кычкырып җибәрде Рәсимә. — Ике йөзле, ханҗа! Паспортында "Мөшәрәф" дип язылган бит, ә үзең "мин — Мөбарәк!" дип, кешеләрнең башын әйләндереп йөрисең! Юк, тиккә генә түгелдер бу! Моның берәр сере бардыр! Туктале-е...

Рәсимә ясканып урыныннан торды һәм итәге кайтарылып бетү сәбәпле, аякларының шәрәләнеп калуын да искәрмичә, әвеш-тәвеш атлап Мөбарәк янына килде, йөзенә таба иелеп, күзләренә карады:

— Әй, син ник миннән куләсең? Кем булдың соң әле син ул чаклы!

Мөбарәк көтелмәгән бу һөҗүмнән югалып калды, аннары исен җыеп, кыюлана төшеп:

— Минем синнән көләргә уйлаганым да юк, Рәсимә апа! Мин бит...

— А-а-а-а... — Рәсимә кулын селтәде. — Кирәкми, акланма энем!.. Мин монда хуҗа, ә син кунак! Кунак хуҗаның ишәге! — ул шундук Мөбарәкнең алдына җәелеп утырды.

Рәсимәнең әлеге килбәтсез кыланышы, назлыбикәләргә бөтенләй хас булмаган дорфалыгы һәм аннан куе булып аңкыган ят вино исе Мөбарәкнең күңелен кайтарса, икенче яктан исә, мут хатынның искиткеч җылы, йомшак тәне вә акыл белән генә һичничек аңлап бетереп булмый торган әчке кайнарлыгы яшь ирнең канын дәррәү кыздырып җибәрде. Мөбарәк үз-үзен белештермәс дәрәҗәдә әсәренеп, Рәсимәне күтәреп алды һәм... шул мизгел гүя арага фәрештә керде: "Мөбарәк, нишләвең

бу, акылына кил, Кадриянә алыштырма аны!" — диде. Яшь ир кыз анасын, чирканулы төстә, идәнгә бастырды.

Ләкин бу минутта Рәсимәнең колагына шайтан нидер пышылдарга өлгергән иде инде һәм иреннән аерылган салмыш хатын бар куәтенә Мөбарәкне этеп тә җибәрде. Яшь ир сөрлегеп китте, нәрсәгәдер тотынырга теләп кулларын җәеп җибәрде, әмма аягында басып кала алмады, диван-караватка барып ауды. Рәсимәгә шул гына кирәк булган, күрәсең: ул чиный-чиный Мөбарәккә ташланды һәм симез ак йодырыклары белән аның кай төшенә эләгә — ярсып-ярсып төяргә, йолыккаларга тотынды, азакта җаен-чарасын табып Мөбарәкнең иреннәренә йотылды, онытылып үбәргә керешге.

Мөбарәк тиз айныды, Кадрияне исенә төшерде һәм суга сусаган балыктай тырпылдап маташкан дәртле хатынны көчле куллары белән читкә тибәрмәкче иде, мәгәр Рәсимә бирешмәде, карышты һәм һөҗүмчәнлеген арттырганнан-арттыра гына барды.

Янә арага фәрештә канатын җәйде: Мөбарәкнең ачуы ярларына сыеша алмаган язгы ташудай чиктән ашты һәм ул ачкүз, әрсез хатынны ике куллап сул якка тәгәрәтеп җибәрде. Рәсимә шап итеп идәнгә тезләнде һәм бер мәл Мөбарәккә шаккатып карап торды да:

— Тинтәк! — дип кычкырып куйды. — Сиңа монда түгел, юләрләр йортына пропискага керергә кирәк булган!!!

Алайга китсә, Мөбарәктә дә тел бар ул. Телнең дә әле ниндие генә!

— Сиңа пропискага мине түгел, берәр юләр бәндәне кертергә кирәк булган! — диде яшь ир, нәфрәтләнеп.

Хуҗа хатын сикереп торды һәм һичкөтмәгәндә кеткелдәп көлә башлады, аңа кушылып Мөбарәк тә көләргә тотынды. Ләкин аларның көлүләре төрле мәгънәгә ия иде.

Рәсимә кинәт усалланды:

— Ярар, житте, спектакльне шушында туктатабыз! Мин аңладым инде эшнең нәрсәдә икәнлеген... Синең, бәгърем, ирлегең юк икән! — Хуҗабикә, нервлана-нервлана, өстәлдәге ризыкларны җыеп, шешәләрне бөкеләп букчасына тутырырга кереште.

Мөбарәк ни әйтергә белмичә, аптырап катып калды. Аннары исенә килеп, тирләгән маңгаен җиңенә сөртте дә: "Нишләп булмасын минем ирлегем, бар, бик бар!" — димәкче иде — аны бит әле дәлилләп күрсәтергә кирәк — телен аркылы тешләде һәм... болдырга чыгып тәмәке кабызудан гайре бүтән чара калмады. Ишегалдында бер түти алак-шалак карана-карана керләр элә иде, Мөбарәкне күргәч: "әһә, җаным, белдем эшеңне, коям тешеңне" дигәндәй, астыртын гына мыскыллы төстә елмайды. Мөбарәк исә, иртәгә тракторда эшкә керешәчәген һәм монда Кадриянең яшәргә киләчәген, аннары барып игезәк малайларын алып кайтачакларын һәм... матур, бай, житеш киләчәк турында хыяллана-хыяллана, төтен суырды, күккә карады, тирә-юньдәге хәлләрне күзәтте. Янәшәдәге ике катлы агач йортның тәрәзәләреннән исә егермеләп кызыксынучан күз аны күзәтте.

— Эчкәнме, исерекме?

— Юк, юк...

— Димәк, авыл гыйбаты! — диделәр.

— Шөкер, моның кесәсен саектырырга була икән!

Теге түти дә сөяк күргән эттәй, керләр арасыннан Мөбарәккә үрелеп-үрелеп карады.

Менә ишектән букча күтәргән Рәсимә кукыраеп килеп чыкты. Гүя ишегалдында аның пәйда булуын гына көтеп торганнар: ишекләр бер-бер артлы ачылып-ябылып тора башлады. Озак та үтмәде, капка буен озын, кыска, юан, нәзек, яшь, урта яшьләрдәге һәм олыгайган хатын-кыз халкы сырып алды. Болар — заманында әллә нинди авыр, кара эшләрдә ватылган, изелгән һәм исерек ирләреннән җык булып, балалар

үстереп интеккән — авыр, караңгы тормышка ачулы, үчле кешеләр иде. Шулай да әле алар кешеләр, хатын-кызлар һәм хатын-кыз холкында нинди уңай һәм тискәре сыйфатлар булса — боларда да алар житәрлек иде.

Рәсимә, үзен әйләндереп алган күрше хатыннарга, түтиләргә, әбиләргә нидер сөйли, тегеләр исә Мөбарәк тарафына күңелле генә елмаеп, авызларын колакларына таба ерып жибәреп, карап-карап куйгалыйлар.

Беләсе иде, ни сөйли икән ул аларга, Мөбарәкнең гайбәтен таратамы?!

Чынлап та шулай булып чыкты.

Икенче көнне Мөбарәк эштән кайтып кергәндә, ишегалдында күрше хатыннар жыелып тора иде. Мөбарәк аларга "исәнмесез" дип үтте. Тегеләр яшь ирнең "исәнмесез"ен әллә ишеттеләр, әллә юк — жавап бирмәделәр. Аның каравы, тупас кыяфәтле, чырайсыз йөзле, әмма чырайсыз ирләрне дә мизгел эчендә помидор итәрлек кодрәткә ия әче, зәһәр телле түтиләр, чүкердәшә-чүкердәшә:

— Моның... ирлеге юк ди, ә!..

— Рәсимә белә инде аны... Монарчы безгә ялган сөйләгәне югие ич! — дип калдылар.

Нахак сүзләр Мөбарәкнең жанын талады. Ул өзлексез тартты да тартты. Әмма тәмәке-тәмәке инде: төтене үпкәләргә тула, агуы канга тарала, йөрәкне сикертә, хәлне ала! Ә жан әрнүен басар өчен... Мөбарәк кибет турында уйлап куйды... юк — эш кирәк, эш!..

Мөбарәк, шөкер, авыл малае әле. Ул үскәндә "егет кешегә житмеш төрле һөнәр дә аз" гыйбарәсен еш ишетте. Шуңа күрәдер инде, барча эшкә карусыз булды, эшне акка, карага бүлмәде, чирканмады. Тырышлыгы, үжәтлеге өчен аны авылда күпчелек хөрмәт итә иде. Мәгәр шул ук вакытта, үз сүзен өскә чыгарырга яратканлыгы өчен, аны өнәмәүчеләр, күрә алмаучылар да юк түгел иде бит!..

Мөбарәк башта үзе һәм гаиләсе яшәргә тиешле йорт белән әйбәтләп танышып чыкты. Йорт борынгы кирпечтән калын һәм нык итеп төзелгән иде. Ләкин фундаменты да кирпеч булганга һәм сумала сыланмаганга күрәдер инде, эчтәге диварлар дымланып, урыны-урыны белән юешләнеп үк торалар һәм шул сәбәпле өйдә ниндидер авыр ислар — күгәрек, саз исе сизелә иде.

"Бу дымнан, юештән ничек котылырга? Башкала үзәгенә хас булмаган яман исләрне ничек бетерергә?.."

Мөбарәк биленә таянып уйланып торды да, тәрәзәләрне киереп ачып жибәрде, ишекләрне ачып куйды: өй эченә кайнар һава тула башлады. Булды бу! Иртәгедән, шулай итә башларга кирәк!

Һе... Рәсимә монарчы нигә бу алымны кулланып яшәмәгән икән? Әллә ни мәшәкате дә юк, көч тә түгәргә кирәкми ләбаса!.. Хәер, бу йорт ул сагыз хатынга әллә нигә бер килеп китәргә — ир-ат белән очрашып, күңел ачарга, дәрт тузанын басарга гына кирәк бугай. Йортның чисталыгы, эчке-тышкы күркәмлеге дә ул чибәркәйне кызыксындырмый, чөнки аның мона сәләте дә, ихтыяжы да юк, аның йөрәген, уйларын бөтенләй бүтән дөнья — хыялларда гына туа ала торган дөнья рәхәтлекләре биләп, бөтереп үз эченә алып кереп киткән иде.

Берничә көннән Рәсимә калын-калын букчалар күтәреп килеп керде. "Мине тикшерәләр, боларны сиңа калдырып торыйм әле", — дип, букчаларны диван-карават эченә тожырып чыгып китте. Ә икенче көнне кич ул кара тутлы үзбәк егете ияртеп кайтты:

— Менә, Ташкенттан никахсыз ирем килгән, моны әнигә күрсәтеп булмый инде... монда гына кунабыз, — диде һәм үзбәк егете белән Мөбарәкне таныштырды. — Минем фатирчым бу, Мөбарәк-Мөшәрәф! Ике исеме бар үзенең, куш башлы елан кебек, коточкыч!!!

Үзбәк егете Мөбарәккә кулын бирде:

— Мин — Сулейман, Ташкенттан тегел, Андижаннан килдем, кипкен урюк сатам, кавун сатам! — дип, букчасыннан өстәлгә куш йодрык шае кавун куйды, аннары Рәсимәгә төбәлде, хатынның "әйе" дигәнен шәйләп, янә букчасына тыгылды, аннан акбаш, тау кәҗәсенең сөтенә кызыл борыч кушып ясалган сыр чыгарды һәм Мөбарәккә усал итеп, кырын гына карап: — "Монда тартырга рөхсәтме?" — дип сорады. Әмма Мөбарәк җавап бирмәде. Рәсимә исә: — "Тарт инде, тарт, нигә сорап вакыт исраф итәсең", — диде дә, борынгы шкафтан рүмкәләр алып килде. Үзбәк егете элек сигарет кабызды, аннары тәтенен Мөбарәккә таба өрә-өрә, пычак очы белән акбашның уртасына тишек уеп, зәһәр сыеклыкны рүмкәләргә мөлдерәмә тутырды. Рәсимә чәчәкле фарфор тәлинкәгә кавун турап куйгач, алдында торган бәллүр рүмкәне күтәрде:

— Әйдәгез... киттек!

Үзбәк егете шуны гына көткәндәй рүмкәне кулына алып, чәкештереп тә тормыйча, ялт кына эчеп куйды. Әмма Мөбарәк рүмкәгә орынмады, бер кисәк кавын гына алды, аннары сырдан авыз итеп карады. Шундук күзеннән яшь атылып чыкты. Ай, әче дә икән соң бу үзбәкнең сыры!..

Ә үзбәк егете кинәнә генә аракы эчеп! Әйе, кырыс, котсыз, кешелексез Рәсәй тормышы Урта Азияләрне дә ярыйсы гына аракы чөмерергә өйрәткән икән инде!..

— Син нәрсә... — диде Сөләйман Мөбарәккә, — мулла булдыңмыни... башыңа чалма урыйсың гына калган инде!

Мөбарәк җавап бирмәде, ишегалдына чыкты. Бераздан Сөләйман да кысык күзләрен җемелдәтеп килеп чыкты.

Юынылмаган агач шикелле билсез, шешенке юп-юан аяклы бер түти керләр элә иде, Мөбарәкне күреп, тиз-тиз генә килеп житте:

— Бәдрәфне чистартыргае бит, бәдрәфне! — диде ул сулышын көчкә алып. — Иртәгә машина кирәчәк, егерме биш сум кирәгие! — Һәм икенче катның тәрәзәләренә ялт кына карап куйды. Ул тәрәзәләрнең пәрдәләре вә гөлләре арасыннан бирегә уналты күз төбәлгән иде.

Мөбарәк сабыр гына төстә:

— Әлегә акчам юк, апа, жаным! Бәдрәфне чистарттырыгыз! Соңыннан бирермен, яме! — диде.

Түти ала күзләрен тасрайтты:

— Маһимы әллә син, энем?!

— Маһи? Аңламадым... ни дигән сүз ул?

— Улмы, ул. — Түти Мөбарәкнең колагына үрелде һәм... әйтте.

Яшь ир кып-кызыл булды.

— Бу — сиңа авыл түгел! — диде түти. — Монда сүзне бик үлчәп сөйләшергә кирәк, югыйсә... Йә, бирәсеңме егерме биш тәнкә, юкмы?!

Мөбарәк гаҗиз калып кесәләрен актарырга керешге. Шул мизгел, һич көтмәгәндә түтигә таба Сөләйманның кулы сузылды:

— Мә, апа, мин бирәм сиңа акча, ал!

Түти акчаны алып китеп баргач, Сөләйман борылды да бар көченә Мөбарәкнең яңагына чабып җибәрде. Мөбарәк шундук яңагын учлады һәм тәрәзәдән явыз елмаеп карап торган Рәсимәне шәйләде. Аһ, тирән, бик тирән ялгышкан Мөбарәк, аңа Сөләйманның акчасын алмаска кирәк булган! Әмма соң шул инде, хәзер бер нишләп булмый... Сөләйман исә сугуының сәбәбен бөтәнчә аңлатты. Рәсимә белән бәйле рәвештә...

— Юк, мин аңа орынмадым! — диде Мөбарәк, ант итте.

— Ә нигә соң аның тәне кара янган, ботының менә бу төше зәңгәрләнеп тора!

— Мин анысын белмим! Әмма мин аңа орынмадым!

— Хәзер үк кереп үзеннән гафу үтен! — дип боерды үзбәк егете, авызыннан аракы исе аңкытып.

Мөбарәкнең күләсе килеп китте. "Спектакльгә әзерләнү тәмам, тамашачылар каршына чыгарга вакыт җитте", дип уйлады ул, яшь чагында клубта үткәргән репетицияләрне хәтеренә төшереп, һәм җиңел сулыш

алып, ясканып өйгә кереп китте. Сөләйман да ана иярде.

Өйгә кергәч, Мөбарәк ярым исерек хатын каршына килеп, ун кулын күкрәгенә куйды:

— Рәсимә, акыллым, рәнжеткән булсам, гафу ит!

Чибәр хатын, ниһаять, тынычланып, рәхәтләнеп көлә башлады. Көлеп туйгач:

— Спектаклегез барып чыкты. Рольләрне әйбәт уйнадыгыз, рәхмәт, — диде.

Сөләйман килеп мәгъшукасының кулын үпте. Ә Мөбарәк, монда хәзер минем кирәгем калмады дигәндәй, болдырга чыкты, инде нишләргә икән дип, уйланып тора башлады. Чөнки Сөләйман Рәсимә белән кунса, Мөбарәккә аш бүлмәсендә — кысынкылыкта, раскладушкада йокларга гына кала! Ярый ла хуҗабикә сөяркәсе белән бер генә төн кичерсә! Ә бу эш, бәхетсезлеккә каршы, ешая башласа? Аннары бит әле Кадрия дә, игезәк балалар да бар — аларны кайда йоклатырга? Менә бит хикмәт нәрсәдә.

Шул мәлне Мөбарәкнең миендә җитди фикерләр борынлый башлады: утын сарае белән йорт арасындагы бушлыкка — такта-фанерлардан аш бүлмәсе әтмәлләп куярга була ич, миче-фәләне белән бергә!... Ә таш бүлмәләргә җылыту радиаторы урнаштырырга мөмкин! Чынлап та...

Гүя, яшь ирнең уйларын сизеп, болдырга Рәсимә чыгып басты. Ул дәшмәде, Мөбарәккә астыртын рәвештә сынап, көлеп кенә карап торды. Мөбарәк тә эндәшмәде, ләкин ул тыштан тыныч күренергә омтылса да, эчтән исә, шикләнә, борчыла иде: “Аһ, тагын ниләр майтарырга маташа инде бу пешмәгән артист-режиссер?!”

Рәсимә, Мөбарәкнең уйларын укыгандай, текәлеп карады да кереп китте. Шуннан соң Мөбарәкнең колагына күрше хатыннарның кайбер сүзләре килеп иреште:

— Бу... үзбәктән көнләшмәсме икән соң?!

— Нишләп көнләшсен инде! Барыбер ирлеге юк ич аның!..

Ай, усал да соң бу хатын-кыз заты, валлаһи! Әйтерсең лә дөньяда шуннан башка сөйләшергә тема юк!..

Мөбарәк лычкылдатып төкерде дә кереп китте.

Яшь иргә чынлап та юньле йокы насыйп булмаган икән. Рәсимә һәм Сөләйман төнозын һеһелдәшеп, ыңгырашып һәм тирә-юньне дөбер-шатыр иткән тавышлар белән тутырып чыктылар. Әллә алар моны юри Мөбарәккә үч итеп, аны көнләштерергә, ирештерергә һәм аның ирлек горурлыгына тап төшерергә, таптарга, изәргә, бетерергә, юк итәргә теләп эшләделәрме?! Шулайдыр! Базар кортлары бит болар! Алардан әллә ниләр көтәргә була әле, әллә ниләр...

Мөбарәк таң белән торып, салкын су гына эчеп, кызарган күзләрен челт-челт йомгалап, эшкә китте. Ул эшли торган участок күптән түгел генә кала читендәге болынлыкка күчерелгән иде. Монда — Казанның Архитекторлар идарәсендә расланган план буенча — өр-яңа микрорайон үсеп чыгарга тиеш икән. Тик әлегә биредә кызу-кызу эшләр башланырга гына тора иде шул. Әнә... ничаклы вагоннар, тракторлар, экскаваторлар! Кайчандыр ки, бу бинилә[illegible] болын тирә-юнь авыллардагы кешеләрне мулдан мул печәндер, дару үләннәредер, чәчәк балларыдыр ише нәрсәләр белән тәэмин итеп торган. Авыл кешеләре үзләреннән артып калган печәннәрне, дару үләннәрен, чәчәк балларын калага да илтеп сата торган булганнардыр! Ул гына да түгел әле, биредә, авылларда яшәүче һәм эшләүче, аннары каладан ял итәргә килүче студент һәм төрле учреждениеләрдә, конторларда, кибетләрдә, базаларда һәм, завод-фабрикаларда эшләүче яшь-җилкенчәкләрнең кичке уеннары гаҗәп күңелле үтә торган булган! Әле хәзер дә Мөбарәк белән бер участокта эшләүче ташчы, кранчы татар кызлары һәм егетләре бирегә кичке уеннарга килеп йөриләр икән! Бер чая, җырга оста кыз, Мөбарәкнең хромкада уйный белүен ишетеп алгач, тотынды яшь ирне болынга,

кечкенә уенга чакырырга, кодаларга: кил дә кил, уйна да уйна, беттекитте...

Баксаң, соңгы вакытларда алар гармунчысыз калганнар икән. Мөбарәк, җырга оста, телгә чичән, ә кирпеч тезү эшендә ут уйната торган кара күзле кызның ялыну-ялваруларына, ниһаять, биреште. Шулай да:

— Мин бит инде өйләнгән кеше: хатыным, ике малаем бар! -диде.

Мәгәр, чая кыз бирешергә уйламады да:

— И абый, җанашым, йөрәгең яшь булсын, йөрәгең! Син килсәң, хатының да килер, малайларың да килерләр! Кил, яме!.. — дип, гел үзенекен тукыды.

Мөбарәк елмаеп куйды:

— Болай булгач килермен инде! — Сүзендә торды яшь ир. Әлбәттә... ялгызы гына килде әле ул.

— Кайда хатының? — дип кызыксынып сораучыларга Мөбарәк: — Гармунчының хатыны буламыни аның, — дип шаярып җавап кайтарды.

Теге чая, кара күзле кыз исә, җитди рәвештә:

— Дөрес-дөрес, иптәшләр! Әмма кызларның барчасын да кисәтеп куям, гармунчыга өметләнмәгез, гармунчы тик үземнеке генә булачак!.. — диде.

— Синең Тәлгатең бар ич инде, шул җитмәгәнме?

— Ул Армиядә. Кайчан кайта әле! Ә бу — бирედә... — һәм ташчы кыз мамыктай йомшак кулары белән Мөбарәкнең кулларын тотты. — Иеме, бәгырем?!!

Бу сүзләргә ни дип җавап бирергә инде?!

Мөбарәк, үсенеп китеп, кемдер алып килгән гармунны кулына алды, каешларын иңнәренә киде дә, сыздырып уйнап җибәрде. Уйнаганы урам көе булып чыкты. Яшьләр гармунга кушылып җырларга керештеләр.

Китәм дисәң, китәм дисең -
Китсәң мине дә алып кит!..
Җәлләмәсәң салкын дәрья
Суларына салып кит!..

Яшьләрнең йөрәкләре үтә сизгер!

Айлар да юк, төн караңгы,
Кырларда кунам инде.
Ялгыз башым сине уйлап
Дивана булам инде!..

Халкыбызның гаять үзенчәлекле җырлары күп шул! Бер үк сүзләрне төрледән-төрле көйләргә салып җырлый да җырлый халкым, күңелен ача, йөрәгендәге утны баса төшә, сагышларын тарата... Их!..

Мөбарәк "Ай ли гөлкәем"не — болын көйләренең берсен, уенкөен бигрәк тә дәртләнеп, бормаландырып-бормаландырып уйнарга керешт. Яшьләр кулга-кул тотынышып бастылар да — түгәрәк ясап, гармунчыны уртага алып — җырлый-җырлый, бии-бии әйләнергә тотындылар.

Китәм дисең, китәм дисең -
Китсәң мине дә алып кит!..
Җәлләмәсәң салкын дәрья
Суларына салып кит!
Ай ли гөлкәем, күбәләккенәем,
Кара карлыгачкаем да, сары сандугачкаем!..

Яшьләр янында Мөбарәк тә яшәреп китте сыман, дөньяга гүя өр-яңадан туды. Дөрес, ул гаиләле кеше, монда ул гармун гына уйнады һәм аның биредәге эше, вазифасы да гармун уйнаудан гына гыйбрәт иде шикелле! Ләкин... Мөбарәктә дә җан бар, нәфес бар бит! Ул йотылып —

йотылып яшьләргә карады, аеруча мавыгып-мавыгып кызларны күзәтте, тикшерде. Аларны җылы карашы белән сөйде, иркәләде, назлады, юатты. Шунда егетләр белән кызларның бер-берләренә карата булган яхшы мөнәсәбәтләре Мөбәрәккә шундый-шундый тәэсир итте ки, шундук күңеленең әллә кайсы, әллә кайсы почмакларында тып-тын гына, посып кына яткан шигърият чишмәсе тибә башлады һәм колакларына моңарчы таныш булмаган көйнең нечкә, бик нечкә авазлары да ишетелеп-ишетелеп куйгалады.

Хәлбуки, яшьләрнең уйлары, хыяллары ничаклы гына уйнак, якты, йөгерек, җитез булмасын, дәрт-дәрманнары чишмә суыдай саф, тирән вә бетмәс-төкәнмәс тоелмасын — барыбер тән һәм җан сусавын йөрәк вә күңел теләгәнчә соң чиккәчә басып булмаячак — болынны калдырып китәргә, таралырга, өйләренә кайтып ятырга туры киләчәк аларга. Вакыт галиҗәнабләре ашыктыра: озакламый таң атачак, ди.

Яшьләр таралыша башлады...

Мөбарәк гармунны, каешларын иңнәреннән салып, чая кызга тоттырды:

— Рәхмәт!..

Кирпеч төзү остасы, гүзәллек иясе исә, җыр сүзләре белән җавап кайтарды:

— Әйдә, җаным, озат мине, уйсу җиргә җиткәнче!

Мөбарәк, өйләнгән кешегә кызлар озатып йөрү килешмәс, аннары егетләр дә бу хәлне ошатмаслар, гафу итмәсләр, дип уйлап:

— Мин бит... ни бит... — дип борын эчендә ботка кайнатып маташа иде, чая кыз шундук элеп алып:

— Ә... ие... синең бит Кадрияң бар! Ярый инде, сау бул! — дип китеп барды. Мөбарәк болын уртасында ялгызы гына басып калды.

Аһ... Кадриянең бу минутта Лаеш урманы тирәсендә, ак "Волга" эчендә Георгий Кикиладзе исемле грузин белән үбешеп утырганын белсә икән лә Мөбарәк!..

Әйе, Кадрия көндез, ирем янына калага торырга китәм дип, җыенып юлга чыккан иде. Озак та үтмәде, офыкта бер ак "Волга"ның җилдереп килгәне күренде. Тегә чакта Мөбарәк нәкъ шундый машинаны туктаткан иде ич! Кадрия дә тәвәккәлләп кул күтәрде...

Мөбарәк вагонга кайтып ятты, нигәдер тиз генә йоклап китә алмады, тегә өр-яңа җырның көе, сүзләре хәтеренә төшеп тинтерәтте, борчылды:

Бер битең ай, бер битең кояш, Кадриям -
Тик син генә, сине генә сөям!

Юк! Болай түгел ич, түгел...

Әһә, менә бусы бугай! Әйе, шушысы, шушысы!.. Мөбарәк үзе дә сизмәстән әкрен генә җырларга кереште:

Үтеп барган чакта
Төп-төз генә атлап...
Кара күзләреңдә таң йолдызы нуры! -
Кадриям, җаным, әйдә китик әле
Акчишмәгә туры!
　　Кара чәчкәеңә кызыл чәчәк -
　　Юл буенда гына үскәнен
　　Өзеп бирдем дә кадаттым.
　　Кадрия! Белмим, сине нигә
　　Шулай өзелеп яраттым?!
Хәтта сиңа "Сылу!" дия кебек,
Чишмә буенда үскән тал-җикән.
Күрше кызы, җаным, Кадрия -
Сул битең ай, уңы кояш икән!

Җыр тәмамланыр-тәмамланмас, Мөбарәкнең керфекләреннән яшь

бөртекләре тамып төшә башлады. Әйе, ул елый иде! Тын гына, кешекарага сиздерми генә, үзәкләре өзелеп-өзелеп елый иде Мөбарәк...

Нигә ага бу күз яшьләре?.. Аны рәнҗеткән кеше дә юк ич! Бәлки, ир кешегә елау килешмидер дә! Ләкин Мөбарәк елыйм дип еламый бит!..

Шулчакны ишек янында сәер кыштырдау ишетелде. Каравылчы агай икән.

— Ай, монлы итеп җырладың, энем! — диде ул Мөбарәк янына ук килеп. — Көен кайда отып алган идең?.. Сүзләре Такташныкы бугай!..

— Дөрес әйтәсең абый, дөрес! — диде Мөбарәк һәм икенче ягына борылып ятты. Каравылчы агай тамак кыра-кыра ишектән чыгып юк булды.

Иртәнге якта, һич көтмәгәндә, Мөбарәк эшли торган участокта идарәнең баш инженеры Георгий Кикиладзе пәйда булды. Мөбарәк бульдозер белән үләнле җирне актарып, яңа салыначак йортка нигез урын әзерләп маташа иде. Кикиладзе аны кул ишарәсе белән генә вагонга керергә чакырды. Мөбарәк килеп кергәч исә:

— О, революционер, исәнме-саумы! — дип каршылады.

Мөбарәк ни уйларга да белмичә:

— Исәнмесез... — дип кенә җавап кайтарды.

— Ярар, конкретно эшкә керешик инде, — диде Георгий һәм сигаретына зажигалкасыннан ут кабызды. — Синең турыда мин күп нәрсәләрдән хәбәрдар инде. Давай, ирләрчә сөйләшик әле, ярыймы?

Мөбарәк сагайды, әмма бирешмәде, тыныч рәвештә:

— Тынлыйм сезне, сөйләгез! — диде.

Георгий тәрәзәдән каядыр билгесез тарафка карап, уйланып һәм сигарет көлен банка капкачына кагып төшерә-төшерә: — Синең өстән идарәгә жалулар яңгыр урынына ява башлады бит әле, Мөбарәк, — диде.

— Ничек?

— Шулай... син аны үзең белергә тиеш, башың булса!

— Мин... начарлык кылмадым! Тәртип бозмадым!

— Тагын бер мәртәбә уйлап карале!

— Юк!.. Мин эчеп-исереп тә йөрмим!

— Үземә әйтергә кала инде болай булгач! Синең хатаң менә нәрсәдә... — Кикиладзе рогатка аяклы өстәл тактасына чирткәләп куйды. — Син нигә монда, вагонда куныл яткалый башладың әле? Син бит, ялгышмасам, кала үзәгендә менә дигән фатирга пропискага кергән идең... Кергән идең бит?!

— Ә... ие... кергән идем шул... — диде Мөбарәк гаепле төстә.

— Шуннан?..

— Шуннан шул!

— Йә син башыңны юләргә салып азапланасың, яки безне ахмакка санаясың! Беләбез без синең монда кичләрен нинди ният белән йөргәнеңне!

Шулвакыт Мөбарәкнең тәне эсселе-суыклы булып китте. Әллә теге чая кыз белән берәр нәрсә булганмы? Ул бүген эштә дә күренми...

— Ярар, Мөбарәк... Яшь чакта ялгышлык теләсә кемдә була. Хатаңны таны. Танырга теләмәсән, милиция органнарына язып бирәбез! Эшең судка китсә, хана...

"Теге чая кыз аркасында талкый бу мине. Ярый әле кичә озатмадым үзен"... — Мөбарәк эчтән шулай дип уйласа да, тыштан исә тыныч күренергә тырышып:

— Мин бернинди гөнаһ эш кылмадым... Миндә гаеп юк! — диде.

Кикиладзе каты итеп кычкырды:

— Гаепле булмаган кая инде! Син бит болынга татар яшьләрен җыеп, аларны Совет властена каршы котыртып, Казанга национальный революция ясарга ниятләгәнсең! Шулай ич?

Мөбарәк Георгийга сәер генә карап куйды. Шаяртамы соң бу? Әллә... чыннан да, моңа миннән ни кирәк икән?! Әйе, ул бит "синең

өстән жалулар күп ява башлады" диде. Димәк, кичләрен минем монда, яшьләр арасында гармун уйнап йөрүләрем кемгәдер ошамаган. Һе... Алайса, кемгәдер ошар өчен генә яшәргә кирәк булып чыга инде бу дөньяда!

— Дәшмисең, димәк, гаебеңне тулысынча танйисың?!

— Кабатлап әйтәм иптәш баш инженер, минем монда тамчы да гаебем юк! Чөнки, татар яшьләренең дә эштән соң бергә җыелып күңел ачарга хаклары бар, алар шулай... бергә җыелдылар да... Гармунчылары авырып киткән икән, бер кыз минем гармунда уйнавымны үтенде, мин уйнадым, бары тик шул гына!

Кикиладзе кырт кисте:

— Юк, ярамый, ярамый Мөбарәк, Мәскәү рөхсәт итми. Безнең интернациональ яшәү рәвешебездә искелек калдыгы булган милли чәбәләнүләргә урын калмаска тиеш! Эштән соң бүтән монда эзең булмасын, ярыймы?! Әгәр дә инде гармун-фәләндә уйнап, халыкның күңелен ачасың бик килә икән, аның өчен Казанда культура йортлары бихисап. Һәрберсендә сәнгать түгәрәкләре эшли, шунда бар син!

Һай, акыллы грузин! Каршы сүз дә әйтеп булмый үзенә. Мөбарәк:

— Ярар! — диюдән уза алмады.

Георгий Кикиладзе үзе уйлаганча, тракторчыны әйбәтләп "эшкәрткәч", утыз сажин ераклыктагы "ЗИЛ-кран" күләгәсендә посып торган ак "Волга"га таба китте. Аны инде баядан бирле түземсезләнеп Кадрия көтеп утыра иде. Георгий Мөбарәк белән "анлашканда" салкын канлылык саклап арган иде, машинасына кереп урнашырга да өлгермәде, шундук Кадриянең җиләктәй тулы иреннәренә йотылды. Озаклап, тәмләп, салкын су эчкәндәй, онытылып-онытылып үбештеләр.

... Яшьләр бу кичтә дә Мөбарәкне гармунда уйнарга чакырдылар. Дөрес, гармунчы егет хастаханәдән чыккан иде, әмма аңа кемнәрдер болында гармунда уйнарга кушмаганнар, янаганнар да ди әле хәтта, шуңарга ул баш тарткан, имеш.

Мөбарәк тә Кикиладзе белән булган сөйләшүне хәтеренә төшереп, гармун уйнаудан тыелып калмакчы иде, ләкин теге яна көй мона юл куймады, гел-гел җанын бимазалап, йөрәген борчып, яшьләр алдында уйнарга кирәклекне искәртеп торды, яна көйне-җырны киң җәмәгатьчелеккә ирештерергә, халык арасында таратырга кушып, күңелен ашкындырды.

Ниһаять, Мөбарәк риза булды: яшьләр "ура!" кычкырдылар.

Һәм менә болын... Мөбарәк берара яшьләрне уйнатып, биетеп күңелләрен ачкач, теге көйне уйнап, җырлап җибәрде. Яшьләр башта эшнең төбенә төшенмичә, аңышмыйча тордылар, аннары хикмәтнең нәрсәдә икәнлеген сизеп алгач, Мөбарәккә ябырылдылар:

— Моңлы да, матур да җыр икән бу! Безгә дә өйрәт әле!

— Алай бик ошаткач, өйрәтермен инде, өйрәтмичә булмас! -диде Мөбарәк сөенеп.

Әйе, яшьләр яшьләр шул, кызыксынулары көчле, өйрәнергә теләкләре зур — җырны отып та алдылар, шундук җырларга да керештеләр. Теге чая кыз җырның Кадрия исемле кемсәгә атап иҗат ителгәнлегенә төшенгәч, Мөбарәк янынннан китеп үк барды һәм бүтән ул тирәдә күзгә-башка чалынмады да. Яшьләр исә, җырның исемен "Күрше кызы" дип, ә җырның үзен "Мөбарәк җыры" дип атадылар... Шуннан, канатланып, Мөбарәк үзенең җырын тагын гармунда уйнарга керешә, яшьләр тагын җырларга тотындылар:

Үтеп барган чакта<br>Төп-төз генә атлап...<br>Кара күзләреңдә таң йолдызы нуры!..

Кинәт көтелмәгән бер хәл булып алды! Әллә кайдан , сиздерми генә килеп чыккан берәү, Мөбарәкнең гармунын ватып ыргытты да, тамак төбе белән сүгенеп кычкырырга тотынды. Аның сүзләре ятышсыз, аңлаешсыз булып, авызыннан бөркелеп аракы исе чыга иде. Әлбәттә, бу

бәндә ялгыз түгел, аның янәшәсендә ике исерек ир һәм салмыш бер милиционер да бар иде.

Гармунны көл иткән ир Мөбарәкнең үнәченнән каптырып тоткан килеш ысылдады:

— Син... Джунглида туып үстеңме әллә? Кисәткәннәр иде бит инде сине, гармунда уйнамаска дип... Әнә, эшчеләргә дә, колхозчыларга да ял итәргә ирек бирмисез! Аннары, Мәскәүнең ачуы безгә төшә, сез сбулычлар өчен безгә җавап бирәсе була соңыннан!

Мөбарәк бу ирнең колхоз рәисе икәнлеген чамалады. Әйе, элекке заманда яшьләрне кичке уеннардан тыеп, гармуннарын ватып карагруһ муллалар йөрсә, хәзер бу вазифаны фанатик колхоз рәисләре башкара икән...

Көндез Мөбарәкне вагонга тагын чакырды Кикиладзе. Бу юлы аның йөзе тыныч, күңеле дә күтәренке иде шикелле. Ул, елмаеп, Мөбарәккә кулын сузды һәм күрешкәч, башы белән тәрәзәгә таба ымлады:

— Карышма бүтән, җитәкчеләрнең сүзен тот, барыбер без дигәнчә була бит, — диде. Аннары яссы учы белән яшь ирнең җилкәсенә сугып куйды. — Кайткалап йөрисеңме авылга? Бу атнада кайтсаң, председатель кызына, Сабинага миннән күп итеп сәлам тапшыр, яме! Мин аның белән коньякта, ял йортында бергә булган идем! — Георгий Мөбарәккә мәгънәле генә итеп күз кысты. Аннары коры, боеручан тавыш белән:

— Ярый, бар, эшлә инде! — дип, вагоннан чыгып, "Волга"сына таба атлады.

Мөбарәк, ачынып бульдозерына менеп утырды да ачуын җирдән алырга теләгәндәй, ярсына-ярсына актарырга кереште.

Кичен, эш сәгате чыкканда Мөбарәк үзе куныл ята торган вагонга ниндидер гаиләле кешеләрнең урнашуларын белде. Аңа Жданов урамындагы фатирына кайтып китми мөмкин түгел иде хәзер. Ләкин яшь ирнең һич анда кайтасы килми. Әмма бу хәлләрдән соң кайтмыйча да булмый иде. Чөнки, иртәме-соңмы, аңа барыбер анда кайтып керергә туры киләчәк ләбаса! Хәтта Рәсимә белән үзбәк егетен сөймәгән, күрә алмаган тәкъдирдә дә...

Аннары, Мөбарәк янына яшәргә Кадрия дә килергә тиеш инде. Ул бер бите ай, бер бите кояш хатынның күптән калада яшисе килә иде ич! Менә хәзер яшәп карар инде, күрер шәһәрдәге тормышның ниндилеген! Мин аңа кайда урнашуымны бәйнә-бәйнә аңлатып хат язган идем. Хатым барып житкәндер инде. Ул аны шатлана-шатлана укыгандыр, әчтәлеген әбигә дә сөйләгәндер. Инде минем янга килергә дә чыккандыр, бәлки... Ә кем белә, килгәндер дә... Өйдә минем кайтканны көтеп утыра торгандыр! Аһ, шулай булса...

Мөбарәк трамвайдан төшкәч, тәмәке алырга дип кибеткә сугылып чыгарга уйлады. Свердлов урамы каршындагы гастроном янында биш-алты егет-кара басып тора иде. Берсе, Кавказлы кавеменә охшаганы Мөбарәккә эндәште:

— Әй, туган! Хәлләребез мөшкел, коткара күр безне!

— Нәрсә булды?

Сүзгә озын буйлы, сары чәчле егет кушылды. Ул сүгенүнең кайберәүләргә авыр тәэсир итүе турында уйлап та тормыйча:

— Идриана бухумайт, нәрсә булсын, баш авырта. Анасын фәләнфәсхет, кибетчеләр бирми бит әнә! Гүр такталарын кузгатып бетерим, акчабыз да бар үзе, — диде һәм Мөбарәкнең учына йомарланып беткән кәгазьләр төртте. — Башларына менеп нитим, бар алып чыгып бир әле! Курыкма, алар аек кешегә бирәләр, кеше-кара күрмәгәндә!

— Мин эчмим бит, — дип мыгырданды Мөбарәк.

Күзләрендә иман әсәре сизелмәгән очлы борынлы егет:

— Шуңарга күрә сиңа өметләнәбез дә инде, шеф! — диде.

Яшь иргә егетләрнең гозерләрен тыңларга туры килде.

Вино бүлегендә тәмәке алгач, иреннәрен кып-кызыл иткән, тутырган

тавык шикелле симез сатучы хатынга акча төртте Мөбарәк һәм ялт кына бер бармагын күрсәтеп куйды.

Сатучы хатын мизгел эчендә бер шешәне төреп, Мөбарәккә тоттырды һәм акшарланган йөзе белән ишеккә ымлады. Ягъни, әнә теге алкашлар сизгәнче чыгып ычкын!

Теге егетләр яшь ирнең "баеп" чыгуын искәреп, елмайдылар.

— Әйдә безнең белән! — диде Кавказ кавеменә охшаган егет.

— Идриана бухумайт, сина да салып бирәбез, — диде сары чәч.

— Мин эчмим бит! — диде ул егетләр кулыннан исән-аман котылырга исәп итеп.

Әмма Сары чәч Мөбарәкнең җилкәсеннән ук этә башлады:

— Әйдә, әйдә!

Мондый чакта тиктомалдан гына изрәп, каушап калу ир кешене бизәми, әлбәттә. Аннары, мондый бәндәләр кызгану ише бик борынгы изге хистән дә мәхрүм бит алар: кирәк икән сине камыр итеп тә изәрләр, чыбыркы итеп тә ишәрләр, бернишли алмаячаксың! Мондый очракта иң әйбәте — түземлек күрсәтү, нык булу! Синең ныклыгың тегеләрнең ныклыгыннан өстенрәк чыкса, син җиңәчәксең — бусы шиксез!

Мөбарәкне үз эченә алган төркем ниндидер бакчага килеп керде. Теге котсыз карашлы, очлы борынлы егет, илереп:

— Натька! Тиз генә стакан тотып чык әле! — дип кычкырды.

Каршы йортның тәрәзәсеннән бер хатын шулай ук илереп:

— Наталья кайтмый ул монда бүтән... Аның артыннан сез дә китерсез әле, дөмеккереләре! — дип җавап кайтарды да шап итеп тәрәзәләрне ябып куйды.

Сары чәч Кавказ кавеменә кадалды:

— Пахан! Мин бу кетәклектә башка беркемне дә белмим...

Очлы борынлы егет:

— Ярар... гурладан гына эчәрбез инде, — диде һәм хәнҗәренең очы белән шешәнең чалмасын каерып ташлады да, аракыны Мөбарәккә тоттырды. — Әйдә, шеф, исәнлеккә-саулыкка!

Мөбарәк хәнҗәр ише куркыныч нәрсә дә күргәч, карышсам бетереп атырлар болар мине дип, шешәдәге сыеклыкны укшый-укшый эчәргә кереште. Биш йотым эчкәч, сары чәчкә караган иде, теге исә, "эч әле, эч" дигәндәй, авызын чалшайтып, кулын гына селтәде.

Инде йота торгач, шешәнең яртысы да кимеде, ә тегеләр әле һаман Мөбарәккә битараф, аның кулыннан шешәне алырга уйламыйлар да. Ниһаять, яшь ир нишләтергә белмичә, буш шешәне Кавказлы кавемгә күрсәтте.

— Отлично! — диде кара егет һәм шешәне алып бар көченә янәшәдәге алмагачның ак кәүсәсенә тондырды, тирә-юньгә пыяла кисәкләре чәчрәде.

— Миңа ошый башладың әле син, — диде Кавказлы кавеме Мөбарәккә һәм куеныннан тагын бер шешә чыгарды. — Әйдә, туган, бусын да эч инде!

— Бусы өчен мин җавап бирәм, — диде сары чәч һәм шешәне, чалмасын салдырып, Мөбарәккә тоттырды. — Төбенә чаклы... давай, пли!

Мөбарәк исерде, җырларга кереште. Әмма теле көрмәкләнә, көе аңлаешсыз, сүзләре буталчык иде. Аны бакчадан култыклап алып чыгып киттеләр.

Аннары ул, кемнәр беләндер, шпаллар буйлап баруын, борылыштан вагон таккан трамвайның килеп чыгуын һәм колагына:

"Трамвайга нитик мәллә?.." Ярамый, "Орел" кушмады!" — дигән сүзләрнең чалынып калуын гына хәтерли.

Берзаман "Мөбарәк!" дигән таныш, иркә авазга уянып китсә, үзләренең ишегалдында — бәдрәф артында бөгәрләнеп ята, имеш. Янәшәсендә ниндидер хатын-кыз чүккән дә, аны селкетергә, торгызырга маташа.

Чү? Бу... Кадрия ич!!!

Мөбарәк торып утырды, чыклы үлән тәнен калтыратып җибәрде, бәдрәф ягыннан укшыткыч әшәке ис килә иде.

— Син ничек әле болай?! — диде яшь ир хатынына.

— Минем хәлем ару әле, шөкер... Ә менә синең хәлең яман, кеше көлкесенә калып беткәнсең бит! — диде Кадрия, Мөбарәкне шелтәләп.

Мөбарәк яртылаш исерек иде әле, "чепуха" дип кулын гына селтәде дә, торып басты һәм Кадриянең нәзек биленә кулын салды:

— Мин бит сине көтә-көтә сагынып, саргаеп беттем!

— Шуңа күрә дуңгыз булганчы эчтеңме? Акчаларың кайда? Бир...

— Акча? Мин үзем акча! — дип мыгырданды Мөбарәк.

— Акча аяк астында аунап ятмый ул, чүп син болай булгач!

— Чүп булгач... ник кияүгә чыктың соң?..

— Мондый бестолковый сораулар бирерлек булгач, ник миңа өйләндең соң, Мөбарәк?!

— Яраттым мин син чукынчыкны, шуңа өйләндем!

— Әй, безнең өйләнешүебез дә кешенеке төсле булмады ла!

— А ну, сөрт яшьләреңне: мин сиңа атап җыр чыгардым, тыңла!

— Исерекләр җыруыдыр инде, тыңламыйм!

— Түгел. Мәхәббәт җыруы ул!

— Кемгә гашыйк булдың тагын?

— Сиңа, Кадрия, сиңа!

— Миңа-а! — яшь хатын күңелләнеп көлеп җибәрде. — Әйтәм аны бәдрәф артында ятасың! Шуңарга икән. Гыйшык-мыйшык утына түзәлмичә ятуың булып чыга икән инде бу синең, алайса!

— Ярар, җыруымны тыңларга теләмисең икән, керик, — диде Мөбарәк һәм ишеккә җиткәч, кесәсенә кулын тыкты, дерт итеп китте. — Ачкычларым юк! Ачкычларым...

— Ишекләр ачык, — диде яшь хатын, — тарт үзеңә!

Чыннан да шулай икән. Эчкә керделәр. Мөбарәк бередә үзен хуҗа сизеп, киерелеп, кәперәеп йөрмәкче иде, Рәсимәнең бүлмәсе ишегенә аша караса — үзбәк егете йоклап ята! Юк, йокламый, түшәмгә төбәлеп, уйланып ята ахыры!

— А-а, мулла кайтты, — диде ул, Мөбарәкне искәреп. -Бөтенләйгә кайттыңмы, вакытлыча гынамы?!

— Хәзер поп итәм мин сине! Әйдә, ычкын яхшы чакта! — дип карлыгып кычкырды аңа яшь ир. — Мин бит сезнең Ташкентыгызга барып хуҗа булып йөрмим! Әйдә, тай, шу, аттыр! Живо!

— Эх, мулла, зрә тырышасың! — диде Сөләйман һәм торып утырды, киенде дә, су савыты янына барып эчкә күз төшергән иде, тамчы да су юк икәнен шәйләп, чиләк тотып чыгып китте.

— Ник бәйләндең инде тыныч кына яткан кешегә? — диде Кадрия Мөбарәккә. — Ул бит сиңа начар сүз әйтмәгән иде!

— Их, Кадрия, нәрсә беләсең соң син кичә генә авылдан килеп...

Кинәт капка шыгырдап ачылды. Карасалар — Сөләйман чиләк күтәреп кереп килә. Ул тәрәзә янына килеп җиткәч, Мөбарәкне ирештерергә теләгәндәй, чиләктәге суны чирәм өстенә түгеп ташлады.

— Авыл җире түгел бу! Әнә, күрдеңме нишлиләр монда, -диде Кадрия, агарынып.

— Үзебез юаш булып муеннарыбызга атландырып бетергәч, эшлиләр инде этлекне... Үзләре эт булгач, бүтән нәрсә эшләсеннәр тагын?! — диде Мөбарәк һәм иләндә торган ак чиләкне эләктереп чыгып китте.

Иртәләрен Спартак урамы чатындагы колонка янында суга чират аз була торган иде. Мөбарәк шунда юл тотты. Менә ул яшелгә буялган биек агач койма буйлап бара. Койманың эчке ягында җиләк-җимеш, суган-фәлән, бәрәңге бакчалары, берәр, икешәр катлы борынгы агач йортлар... шул тарафлардан калын-калын тавышлы этләрнең ялкау гына өреп куйгалаганы ишетелә! Кояш кыздыра да башлады инде. Кичә асфальт

жәйгәннәр ахыры, әшәке сумала исе һәм... Спартак фабрикасы ягыннан тире, Вахитов комбинатыннан сабын-порошок исләре, Мебель фабрикасыннан keләй исе, СКА заводыннан полиэтилен, Кызыл шәрык заводыннан аңкыган әчкелтем исерткеч исләре — Казан вино заводыннан һәм Таң кондитер тәгамнары комбинатыннан аңкыган татлы прәннек вә конфет, торт исләре белән аралашып, күнелдә каршылыклы хисләр кузгаталар. Бер үк вакытта жырлыйсы да, сүгенәсе дә килеп куя сыман! Ләкин, кем әйткәндәй, чебен тәрәзәне буйый, чебенне үтерергә кирәк дип тәрәзәне ватып булмый инде! Димәк, Казанда яшәргә телисең икән, бу "хуш" исләргә генә түзәсең инде, янашым!..

Мөбарәк башта колонкага иелеп, күлмәгенең изүен юешләп һәм чалбарларына чәчрәтә-чәчрәтә, рәхәтләнеп су эчте, аннары чиләген мөлдерәмә тутырып алгач, эченнән генә "хәзер кайтам да үзбәкне өйдән пыранлатып куып чыгарам" дип, дәртләнеп, кайтыр якка юнәлгәндә генә, колонка каршындагы капкадан Мөбарәктән бер башка озын, таза ир-ат килеп чыкты:

— Әй, мужик! Туктале!

Гүя Мөбарәкне аркан белән тарттылар. Ул шып туктады һәм таныш булмаган кешенең якынлашуын көтеп тора башлады. Ир кавеме килеп житкәч, соры күзләре белән Мөбарәккә өстән аска сөзеп карады да, көрәктәй, авыр кулын сузды:

— Сәлам!

Мөбарәк шикләнеп кенә "Сәлам" дип тегенең кулын кысты.

— О-о-о, таза икән син! — диде чит ир һәм тырышып-тырышып Мөбарәкнең мускулын капшарга керешге. — Авырлыгың күпме?

— Туксан ике кило!

Чит ир кинәт кулын-кулга сугып куйды:

— Так шту сиңа үлгәнче бу дөньяда беркем дә башлап бәйләнмәячәк, әгәр дә үзеңне матур гына тота белсәң! Бусы булды бер. Икенчесе, мин бу Спартак урамында — авторитет! Әгәр дә тагын бу урамда йөргәнеңне күрсәм... — авторитет-ир әче итеп сызгырып жибәрде. Озак та үтмәде, алар каршында унбишләп егет пәйда булды.

— Эш бар! — диде авторитет егетләргә һәм Мөбарәккә эндәште. — Син минe аңлагансыңдыр дип беләм?

— Аңладым! — диде Мөбарәк күкле-кызыллы булып. Шуннан соң яшь ирнең зиһене чуалып киткәндәй булды һәм ул ялгышып күршеләрнең ишегалдына барып керде, чак-чак кына бульдог тешләмәде үзен! Өенә кайткач, Сөләйманны куып жибәрү түгел, аңа күтәрелеп тә карамады. Ләкин... утын сарае янәшәсендә хатынының жиргә таба иелеп, укшып һәм көчәнеп-көчәнеп косарга азапланып торуын күреп, сорамыйча булдыра алмады:

— Нишләдең Кадрия?..

Яшь хатын көчәнеп-көчәнеп укшу аралаш:

— Ба-ы-а-га уздыргансың ич! — диде.

Менә хикмәт нәрсәдә икән! Мөбарәк бу хәлгә көенергә дә, сөенергә дә белмичә, бер мәл уйланып торгач, ниһаять, бирeдә куркырга түгел, ә шатланырга кирәклеген аңлап, Кадрия янына килде дә, аның жилкәсенә каккалап:

— Рәхмәт, карчык, булдыргансың! — диде.

Яшь хатын ышанмыйча, иренә текәлде.

— Чынлап әйтәсеңме?!

— Чынлап әйтмичә... — диде Мөбарәк — Ә хәзер өйгә кереп, чәй кайнатып эчик тә, алга таба ничек яшәргә кирәклеге турында уйлашыйк икәү, яме Кадрия!!!

Яшь хатын, ризалыгын белгертеп, ым какты.

Әмма дөньяда жаның теләгәнчә генә яшәргә насыйп булса икән лә ул, ягъни адәм балалары бер-берләре белән юк-барга ызгышып, талашып, дошманлашып, нервалар туздырып түгел, киресенчә, дус һәм тату булып

кына, матур итеп кенә яшәсәләр икән!!! Ләкин дөньяның үз шартлары, тормышының үз мантыйгы, яшәүнең үз кануннары бар шул! Димәк, телисеңме-теләмисеңме, галәм идарәчеләре тарафыннан җиргә җибәрелгән устав буенча яшәргә туры килә! Ә ул устав дигәнең берәү генә дә түгел әле, күп алар! Аларда язылган кагыйдәләрнең мәгънәләре дә гаять катлаулы, катмарлы, буталчык! Шуннан соң, җаныкаем, каршылыкларга кермичә генә, әрләшмичә, талашмыйча, ызгышмыйча , дус һәм тату булып кына яшәп кара!...

Дөрес анысы, гомерләре буена чит-ятлар эшенә катышмый, кирәк-кирәкмәс урыннарга тыкшынмый, әрләшми, талашмый, дус һәм тату, матур гына яшәргә омтылучылар да бар безнең әйләнә-тирә ягыбызда! Мәгәр алар аз һәм үтә тыйнак булулары сәбәпле, күзгә-башка бик чалынып йөрмиләр. Ә бит төптән уйлап карасаң, кешеләр язмышындагы иң җитди, иң четерекле мәсьәләләрне дә әнә шул "тыйнак каһарманнар" гына чишә ала икән ләбаса!... Андыйларны халыкта: "Ак әби" һәм "Ак бабай" дип йөртәләр.

Менә бу ике катлы агач йортта да — җыен әтрәк-әләм арасында, бәләкәй генә бер бүлмәдә яшәп ята икән Ак әби дигәнең. Ак бабай инде ун ел элек үк гүр иясе булган — авыр туфрагы җиңел булсын мәрхүмнең! Ә Ак әби, гәрчә дүрт бала тәрбияләп үстерсә дә, бүген гомеренең калган көннәрен ялгызы гына саный. Дөрес, "саный" дип, әбигә катышы булмаганнар һәм аңа йомышлары төшмәгәннәр генә әйтергә мөмкин. Ә Ак әби әле хаксызга рәнҗетелгәннәргә һәм киңәшкә мохтаҗларга, гаҗизләргә — булдыра алганча, кулыннан килгәнчә ярдәм итеп яши! Кыскача гына әйткәндә, Ак әби бәләкәй генә фатирында җаннары авыру булганнарны кабул итә һәм аларны рәхәтләнеп дәвалый! Ак әбинең тамырлары беленеп торган ябык, кара тутлы, нык, дәү кулларыннан Коръән-кәрим һәм пәйгамбәребезнең хәдисләре теркәлгән изге китап вә тәсфирларның төшкәне дә юк!..

Тик менә балаларының гына аналарын, ягъни Ак әбине онытып җибәрүләре, аны кадерләмәүләре бер дә күңелле хәл түгел шул! Әмма нишлисең — Күк Ияләренә җирдәге шундый тормыш ошагач — бер нишләп булмый, билгеле. Мәгәр шулай да, төптәнрәк уйлап карасаң, кешеләр чын кешедән башка яши алмый, кешеләр чын кешенең ярдәменә һәрчак мохтаҗ әле: бу-хакыйкать!

Көннәрнең берендә... Мөбарәк тә Ак әбинең фатир ишеген килеп какты.

## Дүртенче башлам

"Гаҗәп! Аптыраш!..

Кешелек дөньясы фәнгә тирәнрәк чумып, биеккә — айга, йолдызларга үрелгән саен, кешенең кеше дигән аты түбәнрәк төшә, бәясе коточкыч кими, кадере бетә бара, Аның каравы, комсызлык, әшәкелек чәчәк ата, усаллык, мәкерлек, кабәхатлек тамыр җәя"...

Мөбарәк газетадан укыган бу сүзләр белән ризалашкандай башын чайкап куйды, Кадрия исә үз уйларына күмелеп, ашыкмыйча гына, тәлинкәсенә өрә-өрә чәй эчүен белде. Шул чакта ашыгып-кабаланып Рәсимә килеп керде. Сөләйман әле һаман диван-караватта "Ташкент хәбәрләре" дигән газетын караштырып ята иде әле.

Рәсимә беркемгә дә игътибар итмичә Кадрия янына килеп басты да барысы да ишетерлек итеп:

— Кызый! Булды, сөйләштем, үз дигәнемне иттем, алалар сине эшкә, ашханәгә! — диде.

Шул сүзләрне ишетүгә, яшь хатын капылт торып, хуҗабикәгә ташланды:

— Рәхмәт, зур рәхмәт сина, Рәсимә апа жанашым-бәгырем! — дип аны кочаклап алуын сизми дә калды.

Рәсимә дә Кадрияне күкрәгенә кысты һәм Мөбарәкне ирештерергә теләгән сыман иттереп, сүзләренә аерым басым ясап әйтте:

— Гаризаңа Георгий Кикиладзе үзе... үзе кул куйды!

Кинәт Кадрия яшь кыздай биеп китте. Аның каршына түр бүлмәдән Сөләйман атылып чыкты да, боргаланып-сыргаланып бии башлады. Кадрия түзмәде, Мөбарәк янына килеп:

— Балтасы суга төшеп киткән мужик шикелле утырма, әйдә безнең белән бие, күңел ач! — диде.

Мөбарәк кулын гына селтәде:

— Тукай бабай бит "Эш беткәч кенә уйнарга ярый" дигән.

Рәсимә кыткылдап көлә башлады:

— Әй, пешмәгән арыш чумары, безнең илдә эшләп кем баесын ди?! Булмаганны...

Сөләйман Кадриянең алдына ук төшеп, кулларын болгый-болгый оятсыз хәрәкәтләр ясарга кереште. Мөбарәк кызарып чыкты, башын түбән иде һәм күзләрен йомды.

— Әнә шулай, әнә шулай! — диде Рәсимә учларын-учка сугып.

Кадрия чыелдап кычкырып җибәрде:

— Их-х, килә минем, бик килә-ә...

Аңа шулай ук хәтәр, нәзек тавыш белән Сөләйман кушылды:

— И-х-х, килә минем, бик килә-ә-ә...

Рәсимә түзмәде:

— Шашып, шашып үбешәсем... — диде.

Аңа котырып бии-бии Сөләйман кушылды:

— Шашып-шашып үбешәсем-м...

Кадрия дә:

— Шашып, шашып үбешәсем-м, — дип акырды.

Мөбарәкнең кинәт башы әйләнеп, күзалды караңгыланып китте, зиһене томаланды. Ул әлеге тамашага нинди бәя бирергә дә белмәде, тәмам аптырады, йөдәде. Ниһаять, түзмәде, бераз җилләнеп керим әле, дип, чыгарга кузгалды, болдырга җиткәч тәмәке кабызды һәм шул мизгел, сискәндереп, җилкәсенә кемдер сарылды һәм муенына, колакларына җылы сулышын өрде:

— Әйдә, мине сөяркән ит инде!

Мөбарәкнең күңелендә Рәсимәгә тапкыр җавап пәйда булды, ләкин теленә чыкмады — кыюлыгы җитеп бетмәде ахырысы.

— Нәрсә, нәрсә? — диде Рәсимә шактый ук йомыры түше белән мескен ирне диварга таба кысрыклый-кысрыклый.

— Миңа эшкә барырга вакыт , — диде Мөбарәк.

— Нинди эшкә?!

— Төзелешкә инде, кала читенә.

— Әй, эшмени ул, ташла аны... Әйдә, безнең компаниягә кушыл, ак калачлар ашап, матур-матур кызлар кочып кына яшәрсең, җаным! — диде Рәсимә, елмаеп-көлеп.

— Миңа үз эшем дә бик ошый, апа җанашым, — дип Мөбарәк өйгә кереп китте.

— Эшең бик ошый икән, ярый алайса, көннәр буе тимер-томыр сыпырып тик йөр! — диде Рәсимә, ачуланып һәм җиргә төкерде. — У-у, авыл гыйбаты: тракторис — майлы крис!

Мөбарәк өйгә керде һәм хатынының юынгыч астындагы чиләккә укшып торуын күрде. Сөләйман исә, ике кулын да чалбар кесәләренә тыккан көе, ишекле-түрле киләп-сарып йөри иде.

Мөбарәк һич көтмәгәндә:

— Кадрия! Син монда пропискага кердеңмени? — диде.

Кадрия укшуыннан туктап, ире ягына башын борды:

— Кая пропискага керим әле мин?!

— Соң... бая эшкә урнашам диден ич. Пропискасыз ничек урнаштыра торганнардыр сине, белмим?!

— Ә, аны әйтәсең икән әле. Анысын Георгий белә инде.

— Кай арада танышып өлгердең әле анын белән?!

— Миңа хат язгансың ич. Хатындагы адрес буенча барып таптым инде.

— Һәм ул сине шундук эшкә кабул итәм диде ме?!

— Ие!

Мөбарәк бераз гына уйланып торгач:

— Бүген нишлисең, кая барасың? — дип сорады.

— Медкомиссия үтәм, — диде Кадрия.

Мөбарәк Сөләйманга төбәлде:

— Ә син нишлисең?!

Сөләйман исә, дорфа рәвештә җавап кайтарды:

— Сиңа нәрсә кирәк соң?

Мөбарәк йодрыкларын йомарлады, тешләрен шакырдатты, мәгәр эндәшмәде.

Сүзгә Рәсимә кушылды:

— Аңа берни дә кирәкми монда! Ул хәзер кала читенә китә, төзелешкә, тимер-томыр сыпырырга!

Чыннан да, Мөбарәк эшкә бик басынкы, күңелсез кыяфәт белән килде. Җитмәсә, маңгаеннан гел тир агып йөдәтә, һаман-һаман су эчәсе килеп тора иде үзенең.

Яшь эшчеләр:

— Мөбарәк абый тозлы кыярны күбрәк ашап ташлаган ахыры кичә, — диештеләр.

— Юк! Ул тозлы балык ашагандыр...

— Бәлки... эчкәндер дә, кем белә, — диде прораб.

— Мөбарәк андый әче-мөче белән дус түгел ул, ие бит, — диде бригадир күз кысып.

Мөбарәк эндәшмәде, тиз генә тракторына таба атлады, чөнки бирегә таба Георгий Кикиладзенең кояш нурларында елык — елык килеп торучы өр-яңа ак "Волга"сы җилдереп килә иде.

Баш инженер объектларда озак йөрмәде һәм, ниһаять, Мөбарәкне вагонга чакыртты.

Георгий үгезне мөгезеннән алырга исәпләп булса кирәк, яшь ир пәйда булуга:

— Син ит чаба беләсеңме? — дип сорады.

— Беләм! — диде Мөбарәк үзе дә сизмәстән.

Кикиладзе тәрәзәдән карады да, ишеккә колак салып бер мәл тын торгач:

— Иртәгедән алып, идарә ашханәсендә ит чабу эше сиңа йөкләтеләчәк, иптәш Мөбарәк Аитович! — диде.

Әмма, гаҗәпкә каршы, яшь ирне тәкъдим ителгән төшемле эш тамчы да кызыксындырмады:

— Юк! Юк!.. Мин тракторчы һөнәрен яратам, и шушы эшемдә генә эшләячәкмен!

— Сиңа монда тузан, эссе, кыш көннәрендә салкын! Ашханәдә, беләсеңдер инде, җылы, чиста, тәртип! Янәшәңдә — хатының! — дип тә карады Кикиладзе, әмма барыбер Мөбарәкнең "бөкресен" сәүдә ягына таба турайтып булмады. Георгий да аптырап калмады:

— Ну, кара аны, соңыннан безгә үпкәлисе түгел! — диде дә Мөбарәккә аркасы белән борылып басты. Яшь ир исә, өстеннән тау төшкәндәй җиңеләеп, тракторына таба китеп барды.

Беркөнне эштән кайткач, Мөбарәк су гына эчте дә, ак бүлмәгә керде һәм хәл алыйм бераз дип, диван-караватка яткан иде, йоклап та китте. Гырылдаган авазга уянды ул. Караса — янәшәсендә Кадрия йоклап ята! Авызыннан бөркелеп шәрап исе аңкый үзенең... Кайчан кайтып ятты икән бу?

Мөбарәкнең борчулы уйларына җавап биргәндәй, Кадрия ыңгырашып куйды. Янә ыңгырашты. Аннары аңлаешлы-аңлаешсыз төстә сөйләнә башлады:

— Кит инде, кит... Шулайммыни?.. Ярар, үзем салам...

Мөбарәкнең йөрәге чыгардай булып тибәргә кереште, сулышы тәмам кысылды. Шабыр тиргә батты. Түзмәде, хатынын йолыккалап, селкеткәләп уятырга тотынды.

— Нәрсә-ә?.. — диде Кадрия, ниһаять. Һәм каршында күзләре коточкыч булып акайган, тешләре ыржайган Мөбарәкне күреп, дертләп куйды. — Нишләвең бу? Шаштыңмы әллә!..

— Кайда йөрдең? Кем белән булдың?.. — диде Мөбарәк Кадриянең колагы төбендә ысылдап.

— Эштә булдым инде! Эшлим ич мин хәзер...

— Беләм мин синең нинди эштә булганыңны, сөйрәлчек!

— Сүзләреңне үлчәп сөйләш, Мөбарәк җаныкаем! Мин синең законлы хатының! Өстәвенә мин синнән көмәнле дә әле!

— Ник шулчаклы соңарып, ярты төн уртасында гына кайтып яттың соң алайса?!

Кадрия Мөбарәкне кочаклап алды:

— И, сабыем минем! Дөньядан артта калып яшисең шул әле син, томана булып! Сиңа бит Георгий минем янга эшкә күчәргә тәкъдим ясаган, ә син-н... баш тарткансың! Бүген безне — ашханәдә эшләүчеләрне Давид Кикиладзе Маркиз утравына чакырды, чит ил кунакларын шәпләп сыйларга кирәк, диде. Менә шул... Әгәр дә син баш инженерның сүзләрен тыңлап, ашханәгә күчкән булсаң, җаныкаем, Маркиз утравында рәхәтләнеп сыйланып күңел ачкан булыр идең!..

* * *

Һай, бер килсә килә бит ул! Иртәгесен эштә дә Мөбарәкнең ашына таракан төшерүче табылды. Дөрес, әлеге кранчы ир перекур вакытында Мөбарәк бригадасы егетләре янына килеп, башыннан кичкән хәлне сөйләп, Мөбарәкнең бәгыренә төбәп ук атам дип башына да китермәгәндер

Ул кранчы ирнең кыйссасы менә нидән гыйбарәт иде. Беркөнне Равилнең (кранчы ирнең) хатыны яшь баласы белән авылга ял итәргә кайтып киткән. Бер айга гына дип киткән икән, шуннан бирле Равил бахырны интектереп килмичә ята ди менә. Коммуналь йорттагы кысынкылыкны авылдагы иркенлеккә, рәхәтлеккә алыштырып булмаганны Мәнди анасы да белә ләбаса! Әмма яшь балалы хатынга авылда рәхәт булса да, Равилгә биредә бер дә рәхәт түгел икән. Чөнки яшь, таза, сәламәт тәнендә көче-куәте ургылып-ташып торган кеше өчен, гаилә җылысыннан башка, бигрәк тә хатыны назыннан колак кагып яшәү — тәмуг газабы белән бер ди.

Шуннан, бәлки берәрсе очрар да, аның белән чак кына әңгәмә корып алырмын, хәлем уңайланып, кәефем яхшырып китәр дип, коридорга аяк бастым да, тәтәтеп тора башладым. Шул мизгел каршымдагы бүлмәнең ишеге ачылып, аннан искиткеч матур, яшь хатын килеп чыкмасынмы! Ай, аның ул гүзәллеге: бер бите ай, икенче бите кояш инде менә, валлаһи! Ә аның буй-сынын, аякларын күрсәң тагын... Рафаэль булып Рафаэль да шаккатыр иде мона бу минутта! Әйе-әйе...

Дөресен генә әйткәндә, Казан каласындагы яшь, чибәр хатын-кызны бергә җыеп, чагыштырып баксаң — бу иң чибәре булыр иде, мөгаен!

Мәгәр мине икенче нәрсә кызыксындыра иде. Бу күркәм зат бирегә кайдан, ни сәбәпле килеп чыккан? Чөнки — миңа билгеле — каршыдагы бүлмәнең хуҗасы өйләнгән кеше һәм аның чит хатыннар белән чуалып маташканын күргәнем дә, ишеткәнем дә юк иде әле! Хәер, ул бер-ике

көнгә авыл тарафларына кунакка китәргә җыенса, булмәсен, алдан хәбәрләшү буенча, элекке сабакташларының яки курсташларының берәрсенә биреп калдыра иде. Ә теге эшем иясе, аңлашыла ки, әлеге иркен бүлмәгә кемнендер сөекле хатынын яки кайсыныңдыр газиз кызын алып килеп... Юк, көчләми, Алла сакласын! Кыскасы, бу романтик очрашудан һәр ике як та канәгать кала иде булса кирәк. Чөнки моңарчы коммуналь йортыбызда бер тапкыр да тавыш-гауга күтәрелгәне, ыгы-зыгы купканы юк иде, зәһәр, әшәке исләрнең чыгып тирә-юньне сасы сөремгә күмеп ташлаганы юк иде бит!

Аннары, күршемнең дуслары арасыннан әллә мәрмәр, әллә сапфир дигән таш исемен йөртүче берәү алдагы көннәрдә генә күзгә-башка чалынган иде. Димәк, сөяркәсен алып килеп кундыру өчен курсташыннан бүлмә даулаган чагы булган аның! Ә сөяркәсе, сөяркәсе, шабашникның, сөяркә ише генәме соң: хәзер үк тотып ал да, кашыкка бер тамчы су салып, икесен бергә кап та йот!

Башымдагы уйларны сизгәндәй, чибәркәй туп-туры миңа килә башлады.

— Бәдрәф кирәгие бит! — ди.

Бәдрәфнең адресын әйтеп бирдем үзенә. Вак-вак кына атлап китте бу. Ә мин тагын берне тиз-тиз генә төтәттем дә, инде кереп ятып карыйм, бәлки йокыга талып булыр дип, ишеккә тотынган идем, кинәт җир астыннан калыккандай, каршыга килеп басмасынмы — әлеге дә баягы күз явын алырлык чибәр пәри кәмәше! Һәм елмаеп, энҗедәй ак тешләрен елтыратып:

— Сезнең, күрәм, башыгыз бик авырта ахыры?! — ди.

Үзем дә сизмәстән:

— Авырта шул! — дип ташладым.

Ә ул һаман елмайган килеш:

— Минем калган бар анда, алып чыгам?! — ди.

— Алып чыгыгыз тизрәк, — мин әйтәм.

Һәм ул кәс-кәс атлап кереп китте дә, бераздан... сырлап-бизәкләп эшләнгән шешә күтәреп килеп тә чыкты. Шешәдә яртылаш коңгырт сыекча бар иде. Коньяк ахыры! Аһ, яратмыйм да инде шул нәрсәне! Кандала исе килә бит аннан! Әмма бу очракта, Казанның беренче гүзәле сыйлыйм дип маташканда, коньяк түгел агуны да "тәмле" дип эчәрсең, фаразан!..

Шул, икәү кердек минем бүлмәгә. Таныш түгел яшь ханым як-ягына сокланып карап торды да:

— Ах, как хорошо! Как уютно синең монда! — дип, шкафтан кырлы стакан алып килде һәм аңа тутырып коньяк салды. Әйдә, эч, башың төзәлер, — диде һәм караватка карап куйды да, шунда барып, ботын-ботка атландырып утырды.

Ә мин... мин... шул бер бите ай, икенче бите кояш ханым каршына тезләнеп, аның илаһи аякларын шашып-шашып үбәргә һәм... тәмам онытылырга, бетәргә теләп, теге кырлы стаканны төбенә тиклем эчеп куйдым да, ханымның күлмәк изүләреннән ташып чыккан байлыкларына тизрәк ия булу нияте белән хәйләгә керештем. Ике куллап муеныма ябыштым да:

— А-а-а, а-а-а, — дип угаланырга тотындым.

Ханым башта аптырап китте, зәңгәр күзләрендә курку шәйләнде. Аннары:

— Чү, ни булды?! Нишләдең?.. — дип миңа сарылды.

Ә миңа шул гына кирәк иде инде!..

Равил сөйләп бетергәч, Мөбарәк үзе дә сизмәстән:

— Ул ханымның исеме ничек ие, белмисеңме? — дип сорады.

— Кәшифә... Хәдичә... Юк, Диләрә бугай! — диде Равил.

"Шул бу, сука! Кадрия"... — дип уйлады Мөбарәк һәм... эштән кайтышлый Ак әби янына керде.

Ак әбинең намаз укырга әзерләнгән чагы булган икән. Ул кулына тәсбих тоткан көе ишекне ачкач, Мөбарәкнең нинди йомыш белән йөрүен сизгәндәй (аны алдан ук белеп тора диләр), сорау-фәләннәр биреп тормый гына, түргә узарга кушып, ым какты.

Керделәр. Әлләни зур булмаган бүлмә эчендә яна җиһазлар да, артык-портык иске нәрсәләр дә юк. Һәммә әйбер үз урынында. Һәммә төштә тәртип, пөхтәлек! Бигрәк тә диварларда Аллаһы Тәгаләнең изге сүзләре язылган шәмаилләр ошады Мөбарәккә. Шул шәмаилләрдән гүя һичтуктамыйча өй эченә — күңелне җылытып, йөрәкне тынычландырып — илаһи нур агылып тора!

— Әйдә, утырышыйк! — диде Ак әби.

Мөбарәк исенә килеп, урындыкка утырды һәм Ак әбигә ияреп, дога кылыр өчен, ике кулын да авызы турысына күтәрде. Аның ишеткәне бар иде, кулларны болай күтәргәч, изге ниятләрдән чыгып теләгән яхшы теләкләр бары тик фәрештәләргә генә мәгълүм була, шайтаннарга ирешми икән, шуңа күрә, шайтаннар кешеләр арасына ут ташлый алмыйлар икән!

— Ярый, бу да булды. Инде Сезне тыңлап карарга кирәк, — диде әби Мөбарәккә елмаеп.

Яшь ир Ак әбигә үзе турында һәм Кадрия хакында белгәннәрен кыскача гына сөйләп бирде.

— Алай, алай-й... — диде Ак әби һәм тәрәзәгә карады. Аннан моңсу гына булып Рәсимәнең йорты күренә иде. — Үзең бик тырыш кеше, кулыңнан килмәгән эш тә юк шикелле. Каршыдагы килбәтсез йортны курчак өе кебек иттерден дә куйдың! Әйе, беләбез, Мөбарәк, бу эшләр күпме вакытыңны алган да, күпме көч түккәнеңне дә, күпме чыгымнар таләп иткәнен дә. Шул ук вакытта йорт хуҗасы исәпләнгән Рәсимәнең сиңа берьяктан булышмавын да беләбез. Әйе, аш бүлмәсе түзеден, мич чыгардың, йортның черегән түбәсен алыштырдың. Сиңа бу изге хезмәтләреңә өчен барчасы да рәхмәт кенә әйтергә тиеш иде дә... — Ак әби сүзен әйтеп бетермәде, кулын селтәп куйды. Аннары яшь иргә төбәлеп: — Дөресен әйткәнгә ачуланма, Мөбарәк, хатының, Кадриян — Рәсимәләр сыңары булып чыккан — синең өстән йөри, — диде.

Мөбарәк, күзләрендәге яшьне күрсәтмәс өчен, башын түбән иде:

— Миңа нишләргә инде хәзер?!

— Авыр хәлеңне җиңеләйтергә тырышып, кайгыңны уртаклашам, әмма... тегеләй ит, болай эшлә дип, киңәш бирә алмыйм! Чөнки мондый очракта, алтын урталыкны саклап булмас. Һәркем үзен хаклы санарга мөмкин һәм аның моңа хокукы да бар сыман! Шулай да әлеге кыен хәлдән чыгуның бер юлы бар кебек...

Мөбарәк әбигә якын ук килде:

— Нинди юл ул? Әйтегез, өйрәтегез: мин әзер!

— Ул ю-у-л... ул юлны син беләсең, Мөбарәк, кит шул юлдан, үкенмәссең азакта! — диде Ак әби һәм сүзне беткәнгә санап булса кирәк, авызы эченнән генә "Аллаһу әкбәр"не әйтеп, тәсбих тарта башлады.

— Шулай микәнни... беләм микәнни мин ул юлны? — дип мыгырданды Мөбарәк һәм Ак әбигә өч тәңкә сәдака бирде дә, ишеккә юнәлде. — Әйе, чыннан да беләм мин ул юлны! Беләм!

Кичен Мөбарәк фатирында ялгызы гына уйланып яткан чакта ниндидер чегән кызы ияртеп, Сөләйман кайтып керде.

— О-о, исәнме, мулла! — диде ул Мөбарәктән көләргә исәп итеп, тәкәбберләнеп. — Әрмән коньягыннан авыз җылытып бакмыйсыңмы соң, милорд? — Һәм Сөләйман чегән кызына ымлап, күз кысты. — Ә бу ак май чүлмәге — Молдавиядән! Ничава гына, иеме?!

Мөбарәк эндәшмәде, уйчан карашын үзбәктән читкә юнәлтте, һаман шул юашлык галәмәте инде! Чегән кызы исә Мөбарәкнең күзенә керердәй итеп карады да, кулын сузды:

— Мальчик дай... погадаю!

— Ул малай түгел инде, зур кеше... — дигән булды Сөләйман.

Мөбарәк чакырылмаган кунакларга аркасын ук күрсәтеп ятты. Тегеләр түргә, Рәсимә бүлмәсенә кереп киттеләр.

Шуннан, ярты төн авышканчы Мөбарәккә тынычлык булмады. Чөнки чегән кызы Рәсимә ише генә түгел иде шул. Анең очсыз-кырыйсыз дала иркенә сусаган кыргый җаны мондагы кысанлыкка сыеша аламы инде, йә! Шуңа да ,,, идән-түшәмнәрнең дер селкенүләренә, тәрәзә пыялаларының зыңгырдап-зыңгырдап куюларына байтак минутлар түзеп ятты яшь ир. Җитмәсә, елтыр күзле чегән кызы тышка чыгышлый яисә аннан керешли гел Мөбарәк каршында туктап:

— Мальчик, ну уж дай погадаю! — ди.

Әмма Мөбарәк нидер сизгәндәй җавап кайтармый да җавап кайтармый! Шулай ята торгач, йоклап кителгән...

Берзаман яшь ир "ах" иткән тавышка күзләрен ачып җибәрсә — анадан тума шәрә Сөләйман аңа төбәлгән дә:

— Елан хатын, аферистка, мине талап качкан, трусигымны да калдырмаган хәтта! — дип зарланып тора.

Мөбарәк чак-чак кына "шул кирәк сиңа" дип әйтеп ташламады, тыелып калды һәм эндәшмәде дә.

— Син миңа булыш инде, ярыйммы... Изгелегеңне мәңге онытмас идем, — диде үзбәк, еламсырап.

Мөбарәк торып утырды:

— Сиңа миннән нәрсә кирәк сон?!

— Акча биреп тор кичкә хәтле генә, акча! Аннары... — Сөләйман Мөбарәкнең ут карашын тоеп, идән чүпрәге белән капланырга тырышып, тәмам мескенләнеп, — мин ул баханы арттырып сиңа кайтарыр идем! — диде.

Мөбарәк, ниһаять, дошманыннан үч алырга мөмкинлек чыгуын аңлап:

— Ярар, мин сиңа булышырмын! Тик иң элек тезлән! — дип кычкырды.

— Нәр-сә-ә?!

— Тезлән хәзер үк, тезлән! Юкса...

— Юк, юк! Китмә! — Сөләйман шап итеп, Мөбарәк алдына тезләнде.

Мөбарәк кабахәт көндәшенә тагын да катырак җәза бирергә ниятләп, уйланып торды да: — Арт шәрифеңнең бер ягын үп! — дип боерды.

Сөләйман бер мәлгә аптырап, югалып калды. Аннары, күкле-яшелле төскә кереп, ертлачланып, Мөбарәкнең ят тәненнән олы гына кисәкне тешләп, өзеп алмакчы иде, мәгәр кире уйлады. Чөнки аңа Мөбарәк кирәк, бик кирәк иде әле. Һәм Сөләйман тәвәккәлләде, чупылдатып үбеп алды.

— Ай, шәп, шундый шәп булды бу! — диде яшь ир елмаеп һәм Сөләйманга көтеп торырга кушып, чыгып китте.

Әмма Сөләйман тәрәзә кырыена елышып капкадан күзләрен алмыйча күпме генә зарыгып көтмәсен, Мөбарәк күренмәде дә күренмәде, суга төшкәндәй юкка чыкты.

Тик соңыннан гына беленде: Мөбарәк ул көнне эшендә исәп-хисап ясатып, каладан ук китеп барган икән.

*(Ахыры киләсе санда)*

# ШИГЪРИЯТ



## Рашат Низамиев

### ҖИЛЛӘР СЫМАН, СУ АГЫШЫ СЫМАН...

#### Булачак рәссам

Дөнья аңа карыйдырмы-юкмы,
Ул — дөньяга гаҗәпләнеп карый:
Бал кортлары әнә чәчәкләрнең
Һәрбер таҗын берәм-берәм саный.

Чикерткәнең әзерләнгән чагы
Скрипка уйнау хәстәренә.
"Музыкант"ның яшел канатларын
Төреп салды күңел дәфтәренә.

Күбәләкләр нәни җил чыгара
Нәни канатлары белән тирбәлешеп.
Җирдән алып күккә кадәр булган
Бөтен матурлыклар — зәңгәр бишек.

Табигатьнең күчеш-әйләнешен
Кемнәр аңлый икән, кем соң белә?
Үлән арасында үскән Чәчәк
Кояш булып күккә күтәрелә.

... Тормыш безне әле өскә чөя,
Кайчагында йолкып ала аска.
Куркып калдым: ничек тә бит кирәк
Бу малайга үзен югалтмаска!

## Язмыш

*... гә*

Без - Мәхәббәт өчен яратылган.
"Йөрмәсеннәр Сак-Сок шикелле", -
Дигән сыман, ул бит икебезне
Кочагына дәшеп китерде.

Алмагачтай керден күңелемә,
Алма тәме килгән иреннәр...
Алма күкрәк... Ходай тарафыннан
Күпме байлык сиңа бирелгән!

Мәхәббәттән бирнә булды безгә
Икәү генә белгән тугрылык.
Шуңа күрә дә бит йөрмәдек без
Читләр капкасына сугылып.

... Елларыбыз чатнап китте кинәт,
Гаеплисең булыр син мине.
Их, чынлап та, хаталарым белән
Мин рәнҗеттем бугай сөюне.

Тыңламадым әйтер сүзләреңне,
Шуңа күрә язмыш таш атты, -
Бәхет алмаларын тартып алып,
Кыргый алма миңа ашатты.

Яңабаштан барлыйм үткәннәрне -
Ни чәчкәнбез, ниләр урганбыз?
Өр-яңадан гашыйк булыйк, әйдә,
Без бит -
Сөю өчен яратылганбыз...

## Моңсу халәт

Җилләр сыман, су агышы сыман
Хәрәкәттә узды көннәрем.
Йолдызларга якын булыйм диеп,
Мин биеккә таба үрләдем.

Фани дөнья кайнап кына тора
Бәгыреңә синең төртелеп.
Бер уйласаң, гел тупаслык анда,
Бер уйласаң үзе - гөл кебек.

Уйландыра күкләр зәңгәрлеге,
Моңсулата шәфәкъ балкышы.
Имән әле, имән яшәп ята,
Кочагында - яфрак алкышы.

Яшен бит ул чәчәкләрне түгел,
Имәннәрне сугып аудара.
Яшен суккан кәүсә төпләрендә
Кырмыскалар гына сау кала.

Табигатьтә - шундый кырыслыклар,
Ә тормышта - ничек, ни-нәрсә?
Ил күзендә җавап тотасы бар,
Сынамакка сине җибәрсә.

Сынган чагы була күңелләрнең,
Сүнгән чагы була учакның.
Көл астыннан яшәү чаткылары
Бәреп чыга барыбер шулчакны!

Йолдызларның кинәт атылуы
Тынгы бирми миңа кич-иртән.
Беркем ишетмәгән авазларны
Нигә икән ешрак ишетәм?..

## Юксыну

*Олы Мишә авылына кайткач...*

Гади генә агач мәктәп иде,
Күпме шунда белем эстәдек.
Ил кагырса, без дә кайгырыштык,
Шатлык килсә — шатлык өстәдек.

Дәфтәр битләренә яза идек
Фәлән сыйныф, мәктәп, башлангыч...
Еллар үткәч, күрәм: һәр почмагы,
Төсе-кыяфәте — ташлангыч.

Кемнәрдер бит бүрәнәсен өйгән,
Кемдер япкан такта түбәсен.
Йөз ел яшәр диеп уйласак та,
Вакыт барыбер талкый, күрәсең.

Бу тормышта сагыш-моңсулыклар
Килә безгә бары соңыннан.
Күрче, мәктәп тәрәзәләренә
Аркылыга такта сугылган.

Бушап калган кәрәз эчләредәй,
Тәмам бушап калган бүлмәләр.
Безнең күңел тәрәзәләрендә
Якты утлар исән, сүнмәгән!

Таш мәктәпнең диварлары биек,
Кирпеченнән күзләр камаша.
Киндер букчалардан йөресәк тә,
Кеше була алдык лабаса.

Чү, кыңгырау таккан атлар узды,
Сискәндереп күңел урманын.
Бертуктаусыз чыңлый бүген җанда
Кыңгыраулы мәктәп елларым...

## Ярулла юкәсе

*Әй, алма бит, алма бит,*
*Алма битләр кала бит.*
*Алма битләр калмас иде,*
*Патша солдат ала бит.*

(Халык җырыннан)

Тутырып егерме биш елын
Кайткан да төшкән ул авылга.
Шул кичтә бер килен ялгызы
Такмаклап елаган: "Ярулла-а..."

Винтовка дускаен, үчегеп,
Ыргыткан тузанлы чардакка.

Аракы-шәйтанга кушып ул
"Сөймәскә" ант эчкән аулакта.

Ни кала кып-кыска гомердән?
Югыйсә яшь бара, яшь үтә...
Бәрәңге бакчасы янына
Утырткан Ярулла яшь юкә.

Бервакыт шау килгән тын авыл:
Тоташ ут эчендә утарлар!
Атларны коткарган Ярулла,
Тик менә гәүдәсен ут алган.

... Кәүсәдә - меңләгән җыерчык,
Карт инде Ярулла юкәсе.
Бөҗралап түшәлгән елларны
Эх, димен, кирегә сүтәсе!

Җилләрдә чайкала карт юкә,
Ачкан да йөрәген давылга.
Тамырдан күкләргә кадәрле
Моң ага: "Ярулла...
Ярулла-а..."

## Бәйрәм сүзе

*Тәлгать Галиуллинга*

Үзе өчен генә яшәми ул,
Табигате белән - милләт җанлы.
Шулай итеп үстергәндер аны
Туып-үскән авылы Кычытканлы.

Карап торсаң, шундый сабыр кеше,
Кирәк булса, шактый кызу канлы.
Шулай итеп үстергәндер аны
Туып-үскән авылы Кычытканлы.

Тәнкыйть кирәк булса - кемгә, ничек
Чагып-чагып селти кычытканны.
Моңа бер дә гаҗәпләнәсе юк,
Туган авылы аның - Кычытканлы.

Бу болганчык сәер заманалар
Шундый итеп сыный һәрбер җанны.
Азамат ир бирә алган өчен
Рәхмәт инде сиңа, Кычытканлы!

## Тамга турында баллада

*(1942 нче ел фаҗигасе)*

I

Фронт икмәк сорый!
Ил язмышын

Кайгыртырга кирәк иң элек.
Һәркем бүген сугыш йөген тарта
Колхоз тәртәсенә җигелеп.

Рәис итеп сайладылар аны,
Миннехуҗа - юньле хуҗа, дип.
Һәм, чыннан да, ул дилбегә тоткач,
Күтәрелеп китте хуҗалык.

Белеме юк. Әмма эшкә җикте
Игенчелек серен, кодрәтен.
Култамгасы итеп сайлады ул
Урак белән чүкеч сурәтен.

Кул куясы булса кәгазьләргә,
Рәхим итеп сала тамгасын.
Көне-төне кырдан-кырга чапты,
Берүк, диеп, бездән калмасын.

Вакытында төште яңгырлары,
Вакытында исте җилләре.
Кайтты ашлык ындыр табагына -
Өлгер генә бары җилгәреп!

Колхоз рәисе Миннехуҗа
Исәп-хисап корды төнката.
Фронт өчен план үтәлә, дип,
Үзен-үзе эчтән юата.

Киләсе ел өчен амбарларга
Фәлән центнер орлык-симәнә...
"Иген иккән авылдашларыңны
Оныта күрмә инде син әнә".

Ындырдагы ашлык көшелләре
Әнә шулай итеп бүленде.
Ул йокларга яткан гына иде,
Кандай кызыл таң да беленде...

II

Берәрсеме барып әләкләгән,
Көнләшепме хәбәр иткәннәр -
Колхоздагы хәләл "урожай"ны
Тикшерергә килеп җиткәннәр.

"Йә, җавап бир: илнең байлыгына
Син хуҗамы, дәүләт хуҗамы?"
Шулай дия-дия караңгыда
Апкиткәннәр Миннехуҗаны.

Иманыннан кире кайтмаган ул,
Кыйнаулардан гәрчә егылган.
Шул минуттан, "халык дошманы" дип,
Яңа тамга аңа сугылган.

Ак-караны оста бутаганнар!
Кая инде халык дошманы -

Җиңү өчен, авыл өчен иде
Бөтен җаны-күңеле кушканы.

Колхоз малын симәнәгә түгел,
Үзе өчен, имеш, яшергән...
Чәнечкеле ГУЛАГ өсләрендә
Ике яклап уйный яшеннәр.

Култамгасын безнең Миннехуҗа
Хәтәр сайлаган шул ул чакта:
Чүкеч аны чүкеп кенә тора,
Урый урак үткер кочакка.

Мәңгелек туң катламнары белән
Җелегенә үтә Колыма.
“Сезгә монда череп каласы...” - дип,
Тоз сибәләр көн дә канына.

Илнең җинаяте, өстерәлеп,
Еллар аша әле барачак.
Борылмалы тарих битләрендә
К А Р А  Т А М Г А булып калачак!

## Тупыл мамык очыра

Табигатьнең шундый вакытлары -
Әй, котыра тупыл мамыклары!

Ничек ычкынырга белми, каһәр, -
Ак җәтмәдә бәргәләнә шәһәр.

Сабагыннан өзелгән дә бары -
Оча гүя тузганаклар шары.

Нәни көчекне син күрче-бакчы -
Шушы шарлар белән уйнамакчы.

Тула мамык бакча эчләренә,
Ханымнарның бөдрә чәчләренә.

Ир уйланып, туктап калды бер тын -
Ак чабылдык итеп
Юксынадыр ул авылдагы йортын.

Күзли ГАИ юллар бәрәкәтен,
Тик тыялмый мамык хәрәкәтен.

Уйный алар җилдә әйлән-бәйлән,
Малайларга исә ап-ак бәйрәм!

Кырысланган урам себерүче -
Кая бакма, шунда мамык күче.

Исе китми генә мамыкларга,
Шаулый Идел, сугылып бетон ярга...

## ЧӘЧМӘ ӘСӘРЛӘР

**Фәйзи Галиев**

# ӘТНӘ — КҮҢЕЛЕМ БИШЕГЕ

ИСТӘЛЕКЛӘР

## Зур төзелешләр чоры

Сугыштан соңгы елларда республика күләмендә зур төзелешләр җәелеп китте. Шундый зур төзелешләрдән Зәй районында электр станцасы, Түбән Кама районында (элекке Ширәмәт районы биләмәләрендә) "Нефтехим" берләшмәсе, шунда ук шин заводы, Яр-Чаллы шәһәрендә автомобиль заводы, шунда ук Түбән Кама ГЭСы, Казан шәһәрендә оргсинтез барлыкка килде. Заводлар гына түгел, алар янында зур-зур шәһәрләр калкып чыкты. Егерме мең халкы булган Чаллы урынына яңа шәһәр пәйда булды. Аларны төзү өчен кешеләрне һаман да колхозлардан ала тордылар.

Шулай бервакыт республиканың колхоз рәисләре җыелышында өлкә комитетының беренче секретаре Фикрәт Табиев:

— Безнең республикада гигант автомобиль заводы төзергә ризалык бирдек,—дип сөйләде.—Беренчедән, безнең татар халкы чит җирләргә таралган, аларга туган җирләренә кайтырга мөмкинлек ачыла, икенчедән, татар халкының зыялы кешеләрен күбәйтергә кирәк, аның өчен нигез-чыганак кирәк, шунсыз зыялы кешеләр әзерләп булмый, алар үсә дә алмый. Мәскәү түрәләренә әйттек, бу заводны бездә төзү уңай булыр, дидек. Төзелеш эшләрен сез уйлаганнан да алдарак бетерербез, дип ышандырдык. Дөрес, әлеге төзелешләр кешеләрнең авыл хуҗалыгыннан күпләп китүенә юл ачар, көчле техникага ышанган хәлдә, иген үстерүне үз югарылыгында алып барырга, сезнең белән бергә нык тырышырга туры киләчәк...

Төзелешкә колхозлардан кеше җибәрү өчен задание өстенә задание житкереп тордылар. Баштарак халыкның бер дә барасы килмәде. Соңга таба, авылдашлары барып урнашып, фатирлы да булгач, күршеләрен, танышларын тарттыра башладылар. Төзелешкә аеруча яшьләр агылды. Түбән Кама төзелешенә кеше җибәрү бигрәк тә кыен иде. Анда төрмә кешеләре эшләгәнлектән, тәртипсезлекләр дә булып торды. Әлеге эшләр байтак елга сузылды. Республика колхозларының эшче куллары кимүгә иң зур йогынтыны шулар ясады. Колхозларда кеше житмәү елдан-ел үзен сиздерде. Авыл хуҗалыгына тракторлар, төрле машиналар гел кайтып торды. Алар гына колхозлардан киткән кул көчләрен алмаштырып бетерә алмадылар. Аннары төзелешләргә киткән кешеләр барысы да эшләп үз гаиләсен туйдырып барачагына ышанган кешеләр иде. Күпчелеге яшь механизаторлар хисабына булды. Кайвакыт колхоз житәкчеләре гел аптырашта калдылар—колхозларда кеше көче житәрлекме-юкмы, шуларны исәпкә алмыйча, районнан йөкләмә җибәреп торалар иде. Әле ул зур төзелешләргә генә түгел, Казанда ит

---

*Дәвамы. Башы 10 нчы санда.*

комбинатына кеше кирәк булса да, колхозга йөкләмә килә, жибәрмәсәң, хайваннарыгызны кабул итмибез, диләр. Казанда рапстан май алу заводына да фәләнчә кеше сорап йөкләмә килде. Шул чорда яңа калаларны яшелчә, бәрәңге белән тәэмин итү өчен махсус совхозлар, теплицалар корыла башлады. Аларны кору өчен дә колхозлардан кеше жибәрү таләп ителә иде. Зеленодол районындагы яшелчәлек совхозын төзергә безнең колхоз өч ел рәттән унар кеше жибәрергә мәжбүр ителде. Кайвакыт радио, телевидениедән шул совхозларның житәкчеләре чыгыш ясый: "Без фәләнне төзедек, төгәнне төзедек" дип горурланып сөйлиләр, ә фактта бу төзелешләр республика колхозларына шактый кыйбатка төшкәнен әйтмиләр. Бервакыт авыл хужалыгы министры Минушев телефоннан мине эзләтеп сөйләшергә чакырды:

— Фәйзи Әхмәтович, яшелчәлек совхозында эшләүчеләрең эшне ташлап, качып киткәннәр, иртәгә сәгать 8 гә килеп житсеннәр, мин сиңа Министрның ишеген шакымыйча керергә рөхсәт биреп яшәдем, әгәр бу йомышны үтәмәсәң, икенче минем янга килеп тә йөрмә,—диде дә телефон трубкасын шалт итеп куйды. Ул элек безнең районда эшләгәнлектән, без аның белән тату, килешеп яшәдек. Шуңа күрә минем белән якын, үз кеше итеп сөйләшә торган иде. Бу вакыйгадан соң мин елмаеп куйдым да, сөйләшү нәкъ Минушевча булды инде, дидем. Иртәгесен аның йомышын үтәргә туры килде. Безнең колхоз шикелле хужалыкка мондый йөкләмәләр күбрәк тә килә торган иде.

Илебезгә электр энергиясе житештерү сәясәте колхозлар тормышына зур йогынты ясады. Куйбышев өлкәсенең Жигули тавы янында су көченнән файдалана торган электр станцасы төзелә башлады. Татарстанның кайбер районнарында күп жирне су басты. Лаеш, Алексеевск, Балык Бистәсе, Куйбышев районы жирләре жәберләнде. Безнең районга турыдан-туры кагылмаса да, колхозчылар шул районнарның су баса торган жирләрендәге урманнарны кисү өчен мәжбүри рәвештә жибәрелделәр. Безнең район кешеләре Лаеш районы, Атабай авылында торып эшләде. Ул урманнарга кешеләрне колхозлардан жыеп алып китәләр иде. Билгеле бер вакыт үтеп, монда эшләүче кызлар авылларга кайтып, киемнәрен алмаштырып, мунча кереп, чистарынып килергә сорагач, жибәрмәделәр. Кайтсалар килми калырлар дип курыктылар. Әле дә хәтеремдә, безнең колхоздан шунда киткән кызлар Атабай авылыннан дүрт тәүлек жәяү кайтканнар иде. Артларыннан ук: "Сезнең кызлар качып киткән, кире жибәрегез!"—дигән хәбәр алынды. Кызларны яңадан чыгарып жибәрү бик читен булды. Бер кайту вакытында анда эшләгән кызларны идарәгә чакыргач: "Без бармыйбыз, башкаларны жибәрегез!"—дип кырт кистеләр. "Анда безнең хәлебезне дә белүче юк, фатирларның төрлесе бар, безгә салкын идәндә бишәр кеше бергә йокларга туры килә",—дип сөйләделәр. Машина сораганнар, машина бирмәгәннәр. Качып жәяү кайтырга мәжбүр булганнар. Кайберләре киеп кайткан чабаталарын да алып килеп күрсәтте. Ул чабаталарның асты бөтенләй ашалып беткән, аякка эләгеп кенә кайткан. Гомумән, аякларына капчыклардан, яулыклардан чолгау ясап, урап кайтканнар. Аларны алмаштырырлык кеше юк иде инде колхозда. Әйбәтләп сөйләшеп, күпме эшләргә икәнен билгеләп, яңадан чыгарып жибәрдек. Бу эш өч ел буе дәвам итте. Районыбыз газап чикте. Су астында каласы урманнарның барыбер киселеп бетмәгәнлеген иң соңгы кайтучылар әйтте.

Моның кебек читтә эшләүләр ул елларда яшь кызларга авырга туры килде. Сугышка кадәрге чорда мондый эшләргә ир-ат кына мәжбүр ителгән булса, сугыштан соң гел кыз балалар гына эшләде. Аларга урман кисү, Мәскәүне жылытыр өчен торф чыгару кебек эшләрдә катнашу мәжбүри иде, күпчелек очракта түләгән хезмәт хакы ашарларына да житмәде.

## Колхозларны электрлаштыру

Элекке Әтнә районы биләмәләрендә 1956-62 еллар арасында республиканы тоташ электрлаштыру буенча бик әһәмиятле эшләр башкарылды. Идел суындагы гидростанция, Зәйдә төзелгән электр станцалары авылларны электрлаштыруга мөмкинлек тудырды. Башта нефть чыга торган районнарны, алардан соң шәһәр тирәсе районнарын, ниһаять, Биектау районының Чыпчык

авылы яныннан Әтнәгә электр китерү планлаштырылды. Беренче елларда бу эш Комыргужа авылыннан ерак китә алмады. Районыбызда электр челтәреннән беренче булып шушы авыл һәм аның янындагылар файдаланды. Янадан электрлаштыру буенча өченче омтылыш бөтен тармакларны исәпкә алып эшләнде. План буенча безнең район өчен Күшәр авылы янында электр станцасы төзү каралган иде. Бу эшне Зеленодол районының Васильево бистәсендәге төзелеш оешмасы башкарырга тиеш булды. Аларның вәкилләре килде һәм төзелешне башлау өчен эшче көчләре юклыгын әйтеп, безне бик "сөендерделәр". Шулай да төзелеш кирәк-яраклары белән тулысынча тәэмин итәчәкләренә ышандырдылар.

Шуннан соң бу төзелешне үз өстебезгә алырга булдык. Кешеләрнең дә фикере электрны тизрәк керту ягында иде. Шулай итеп, безнең "Искра" колхозы кешеләре районыбыз авыллары өчен электростанца салучылар да булып китте. Иң элек, подстанция өчен урын билгеләдек, нинди корылмалар кирәклеген ачыкладык. Анда эшләүче белгечләр өчен ике фатир төзелде, монтерларның эш урыннары өчен контор бинасы салынды, ишегалдына кое казылды, мунча өлгертелде, техника өчен гараж, кирәк-яраклар кую өчен лапас, бирелә эшләүчеләр хайван асраса дип абзар һәм туалет төзелде. Ихата үзе рәшәткәле койма белән әйләндерелеп алынды. Эшне тиз тоттык. Бер ел дигәндә барлык төзелеш тәмамланды. Без төзелеш эшләре белән мавыккан арада шәһәр белгечләре трансформаторларны урнаштырдылар. Аның өчен алдан ук фундаментларын әзерләп куйган идек. Төзелеш бетү белән, авылларга китә торган чыбыклар да тартылып куелды. Беренче юнәлеш безнең колхозның Күшәр, Күнгәр, Ташчишмә якларына китте. Әтнә ягына да махсус чыбык тартылды. Күәм, Күлле Киме якларына Түбән Шашы авылы яныннан аерым чыбык сузылды. Күнгәр яныннан Сап ягына китте. Ташчишмәдән чыбыкларны Карл Маркс колхозы ягына таба җибәрдек. Бу вакытта Бәрәскә тирәләре Дөбъяз ягыннан килгән электрдан файдалана башлаганнар иде инде. Аларның электрдан файдаланулары зур өзеклек белән булды. Чөнки Дөбъяз башка район булганлыктан, бу якка китә торган электр чыбыкларына игътибар итмәде. Соңыннан, Күшәр подстанцасы эшли башлагач кына, Бәрәскә яклары да безнең подстанцага ялгандылар. Бәрәскәнең колхоз рәисе Гатауллин Абдуллага бу эш артыннан күп йөрергә туры килде. Шулай итеп, Әтнә районының элекке биләмәләрендәге авыллар 1962 елда электр челтәренә тоташтырылып беттеләр. Уйлап карасаң, ул еллар өчен бу иң әһәмиятле эшләреннән берсе булды. Хәзерге көндә яшәүчеләр электр көченнән файдалану булмаган елларның авырлыгын күз алдына да китерә алмыйлар. Үзебез дә фидакарь булганбыз, республика да кузгалган иде шул. Бу эшне партия өлкә комитетының төзелеш бүлеге кешеләре һәрвакыт күзәтеп торды. Атна-ун көн саен төрле дәрәҗәдәге түрәләр килеп торды. Авылларга электр чыбыкларын китереп житкерү белән генә эш бетмәде, мәктәп, мәдәният йортлары, китапханә, кибетләр, фермалар, хуҗалык йортлары, производство биналары, урамнарны яктырту кирәк иде. Фермаларда электр уты яна башлагач, терлек караучылар бик шатландылар, хәтта бер-берләрен кочаклап, сикергәләшеп тә алдылар. Сыер савучы кызлар матуррак киенеп йөри башладылар. Торакларны да, тәрәзәләрне дә, хайваннарны да чистарак тотарга керештеләр. Фермаларга бару-кайту юлларын электр яктырта башлагач, йөрү уңайлашты. Гомумән, авылларны электрлаштыру авыл халкы өчен үзе бер революциягә тиң эш булды. Рәхмәт колхозчыларыбызга. Алар эшне җинеләйттеләр. Трансформаторларның көчен арттыра бару белән электр энергиясен хуҗалык эшләрендә файдалану мөмкинлеге дә туды. Үтүк, суыткыч, самавыр, чәйнек, телевизор, кер юу, хәтта идән себерү эшләрендә дә электр көчен файдалана башладык. Колхоз хуҗалыгында тегермән тарту, силос тарау, станокларны хәрәкәткә китерү, төзелеш эшендә бүрәнә чистарту, такта яру, тагын шундый бик күп эшләр электр көченә көйләнде. Кайвакыт авылыбызның олырак кешеләре белән хәзерге һәм элеккеге көнкүрешне чагыштырып сөйләшәбез. Әллә нигә бер кибеткә кайткан керосинны алу өчен озын-озын чиратларда торганны искә алабыз. Аны да йорт башына ярты яки бер литр дип исәпләп кенә бирә торганнар иде. Өлкәннәр элекке авыр тормышны күреп яшәгәнгә, хәзерге тормышның кадерен беләләр.

Электрлаштыру авылларда радио, телевизор, телефон станцалары төзергә

мөмкинлек бирде. Элегрәк авылларга радио кергәнче гәзитләрдән генә файдаландылар. Гәзиткә язылу мөмкинлеге чикләнгән, аны авылда берничә кеше генә алдыра торган иде. Әйтик — укытучылар. Алар авылның иң мөхтәрәм кешеләре булып яшәделәр. Гәзиткә язылган кызыклы хәбәрләрне сөйли торганнар иде. Ә менә радио, телевизор кергәч, халыкның хәбәрдарлыгы артты.

## Җитәкчеләр күбәйгән заманнар

Хрущев түрә булып эшләгән чорда, авыл хуҗалыгында күп төрле тәҗрибәләр үткәрелде. Үзгәрешләр берсе артыннан берсе чыгып кына торды. Кайберләре авыл хуҗалыгына файдалы булса, кайберләре зур уңайсызлыклар китерде. Чирәм җирләрне күтәрү, министрлыкларны бетереп, совнархозлар төзү, бер үк өлкәдә партиянең ике төрле комитетын ясап, берсен авыл хуҗалыгы, икенчесен промышленность буенча эшләргә тиеш дип билгеләү кыенлык китереп чыгарды. Бу эшләр МТСларда түрәләрне күбәйтте. Элек МТСның директоры, баш инженеры, агрономы бар иде. Шулар өстенә яңадан баш зоотехник штаты кертелде. Партия юлы буенча эшләүчеләр саны да артты. Элекке эштән бушатылмыйча эшли торган партия оешмасы секретаре урынына, эштән бушатылган секретарь сайланды. МТС зонасы буенча райкомның зона секретаре дигән тагын бер штаты артты. Ул секретарьларның эш тәртибе беркемгә дә анлашылмады. Алар үзләре райком секретарьлары дип аталдылар, ә эш урыннары МТС конторында булды. Безнең районда Әтнә МТСында Мозаффаров, Күәм МТСында Мугинов дигән кешеләр эшләде. Алар үз эшләрен үзләре дә аңламады. Шулар хакында халык арасында мәзәк сүзләр дә таралып өлгерде. Шулай бер вакытны Хрущев өлкәләрдә йөргән вакытта Мәскәү янындагы коммунистлар санаториена кергән. Шунда ял итүче зона секретарьлары әлеге штатның бер дә кирәк түгеллеген әйткәннәр. “Халык безнең хакта җыр чыгара”,—дигәннәр. Хрущев: “Нинди җыр?” дип сораган. Шуннан берсе, тапкыррагы, җырлап та күрсәткән. Ул чорда Һиндстанның “Сукбай” дигән кинофильмы бара иде. Шул фильмдагы сукбай җырын үзгәртеп, сукбай урынына “зональный” сүзен кыстырып, Һинд көенә русча җырлап күрсәткән. Хрущев көлеп җибәргән.

Әлеге шартларда электән МТС директоры булып эшләп килгән Ишниязов Ибраһим абый белән яңа килгән секретарь Галәветдинов Ихсан, Нурмөхәммәтов Кашшафлар арасында дәрәҗә бүлешүдә ызгыш чыкты. Зона секретаре Галәветдинов: “Мин — райком секретаре, мин партия кушканны үтәргә, син, директор булсаң да, мине тыңларга тиеш”,—дигән таләп куя. Ә директор үзен хуҗа саный. Ике араларында купкан ызгыш Ибрай абыйның эштән китүе белән тәгәлләнде. Озак еллар бу эштә эшләгәч, кимчелексез генә булмагандыр. Шул кимчелекләрне җыйнап, аларны партия җыелышына куеп, эшеннән бушаттылар. Аның урынына Галәветдинов директор булды. Ибрай абый үзенә карата булган бу эшне гаделсезлек дип бәяләде, райком тирәсендә үзен яклаучы булмаганга бик нык үпкәләде. Шуннан соң аны Күәм колхозына рәис итеп сайладылар. Анда да чын күңелдән тырышты, колхоз өчен күп игелекле эшләр башкарды. 1958 елны МТСларны бетерү турында карар чыкты.

Районнарның буталчык бер чорына аерым тукталмыйча китсәм, язмаларым тулы булмас шикелле. Әтнә районы яшәгәндә, аның райкомы да, райбашкармасы да, башка түрәләре дә эшләп торганда шулар өстенә КПСС өлкә комитетының партия оештыручысы дип аталган бер штат та бар иде. Ул эштә Гыйматдинов Габбас Кыямович дигән кеше эшләде. Ул моңа кадәр Саба райкомының беренче секретаре булып торган. Саба районы алдынгы районнарның берсе иде. Партия эшенә күчкәнче колхоз рәисе булып эшләп, бик таркау бер колхозны алдынгылар рәтенә чыгарган иде ул. Холкы ягыннан кырысрак, әмма эшлекле, кешелекле, фикерен ышанычлы итеп, төгәл әйтә ала торган кеше. Аның белән беренче очрашуым истә калган. Арча авыл хуҗалыгы идарәсе буенча дәүләткә икмәк тапшыруны үтәр өчен соңгы

тырышлык бара иде. Ашлыкны кайсы колхоздан күпме чыгарырга кирәклеге билгеләнде. Әтнә райкомы бюросында да икмәк тапшыруның барышы тикшерелде. Бюро утырышына Арча авыл хуҗалыгы идарәсенең башлыгы һәм сельхозтехника управляющие килгән иде. Бюро утырышын райком секретаре Борһанов Тимерхан алып барды. Ул бюрога мин дә чакырылган идем. Әтнә районыннан күпме икмәк чыгарылырга тиешлеген секретарь саннар белән атап чыкты. Шунда мин җитәкләгән колхозның икмәк тапшыру планы арттырып үтәлүен әйтеп, мактап сөйләде. Ләкин колхоз өстәмә рәвештә икмәк тапшырырга тиеш икән. Миңа карап, ул өстәмә икмәкне тиз көндә чыгарып бетерергә кирәклеген әйтте. Мин: "Бездә дәүләткә тапшыра торган икмәк башка юк",—дип җавап бирдем. Шунда ук бу планның инде өченче тапкыр өстәлүе турында белдердем. Икмәк хәле ул елларда авыр иде. Безнең колхозның иген уңышы башкаларга караганда югарырак булып килде. Минем икмәкне башка тапшыра алмавым турында әйткәннән соң райком секретаре Борһанов авыл хуҗалыгы идарәсе начальнигы Шәрифуллинга карап: "Менә мондый тискәре кеше белән ничек эшлисең инде?"—диде. Райком бюросына буйсынмавым, районның патриоты булмавымны әйтте.

Җыелыштан күңелсез уйлар белән чыктым. Иген үстерә белүче колхозлар начар эшләүче колхозлар өчен икмәк түләргә тиешмени инде? Мондый гаделсезлекләр елдан-елга кабатланып тора. Икмәге начар булган колхоз җитәкчеләре әле генә булып үткән бюро газапларын күрмиләр...

Бюрода безнең секретарь белән сөйләшүебезне тыңлап утырган Шәрифуллин бер якка да кушылмады.

Җыелыштан соң ике көн узгач, безнең колхозга өлкә комитетының партия оештыручысы Гыйматдинов белән Әтнә райкомының икенче секретаре Җиһаншин килеп төштеләр. Гыйматдинов белән беренче очрашуым иде. Ул минем белән кырыс кына исәнләште. Хәлләрне сорашкан булды, әйдә, амбарлардагы ашлыкны карап чыгыйк, диде. Бер-бер артлы келәт ишекләрен ачып, ашлыкны карап бара торгач, бер амбарда юка гына итеп салып куйган дымлы борчакның ап-ак булып күгәргәнен күрдек. Үзе күп тә түгел, шулай да хәлем бик мөшкел иде. Башка келәтләрдәге ашлыкны да карап бетергәч, ындыр табагының урта бер җирендә туктап, минем күземә төбәп карап, усал кыяфәт белән әйтте бу: "Фәизи Әхмәтович, монда бер генә нәрсә җитми икән",—диде. "Әйе шул, борчакны киптерәсе бар, бүген үк эшләрбез аны",—дидем. Ә ул: "Юк, алай түгел, миңа телефон трубкасын алырга да, прокурорга, "Искра" колхозына бардым, дәүләткә ашлык чыгармыйча, чи көенчә амбарга бикләп, ашлык черетеп ятучы колхоз рәисе өстеннән эш кузгатыгыз, дип кенә әйтәсе калган",—диде. Бюродагы батырлыгым кинәт юкка чыкты. Машинага утырдык та колхоз идарәсенә кайттык. Анда килеп туктау белән ул: "Сезнең библиотекагыз бармы?"—дип сорады. "Бар",—дидем. Алар Җиһаншин белән икәүләп китапханәгә кереп киттеләр, миңа колхоз идарәсенә керергә куштылар... Озак көттермәделәр, чыктылар да, идарәгә кереп, минем белән сөйләшә башладылар. Янәсе, нинди планнарым бар, нәрсәләр төзергә телим. Планнарымны сөйләп бирдем. Район хәлләренә булган фикерләремне, район җитәкчелеген үзгәртүгә булган карашымны сорадылар. Дөнья хәлләре, газит материаллары, авыл хуҗалыгына кагылышлы мәсьәләләр хакында да сораштылар. Шактый озак сөйләшеп утырдык. Чәйгә чакырган идем, кермәделәр, киттеләр. Миңа килгәннән киткәнчегә кадәр Гыйматдинов икмәк тапшыру хакында бер сүз дә әйтмәде. Киткән вакытта күзләрендә килгәндәге кырыслыгы юк иде. Бераз елмаебрак: "Бик зур планнарыгыз бар икән, аларны тормышка ашыруда уңыш телим",—дип ягымлы гына саубуллашып китте. Алар китү белән мин тиз генә китапханәгә кереп, нәрсәгә керүләрен сорадым. Китапханә мөдире: "Ул сезнең китап укуыгызны теркәп бара торган карточканы карады, нинди китаплар укуыгыз белән кызыксынды",—диде.

Мин укыган китапларның күбесе төзелеш эшләренә бәйле иде. Ул китапларда кирпеч салу, измә ясау, цемент сортларын ачыклау, фундамент һәм стеналарны ничек салу язылган иде. Чөнки бу чорда колхозда агач корылмалардан кирпечкә, ташка күчү чоры иде. Шул эшләр буенча әзерлегем булмаганлыктан, төзелешкә бәйле китаплардан файдалана идем. Ул заманда төзелеш буенча колхозларда таш эшен белүче юк иде. Колхоз рәисләренә архитектор да, инженер да, прораб та булырга туры килде. Гыйматдинов,

миннән, нәрсәләр төзергә уйлыйсыз, дип юкка гына сорамаган икән. Гыйматдиновның нинди фикерләр белән киткәнен беләсем килеп йөрдем. Күгәргән борчак һаман күңелемнән китмәде. Аны шул ук көнне киптереп, фуражга салып куйдык. Иртәгесен телефоннан Җиһаншинга шалтыратып Гыйматдиновның нинди фикер белән китүен сораштырдым. "Ул сезне бик ошатып китте. "Башта, сөйләүләренә караганда, катып беткән бер надандыр дип уйлап килгән идем, бу кеше заманча фикер йөртүче, дөнья хәлләре белән танышып яшәүче икән", -дип әйтте" диде Җиһаншин. Шулай итеп, соңыннан икмәк сораучы да, бу вакыйганы кабатлаучы да булмады. Берсе дә миңа дошманлык күрсәтмәде. Райком секретаре Борһанов белән исә озак еллар бергә эшләргә туры килде. Бервакытта да теге хәлләрне искә төшермәде. Аның белән тату яшәдек. Кешелекле булуы аркасында аны хөрмәт иттеләр. Малга хирыс булмыйча, гади яшәве—аның уңай сыйфаты иде. Ә Гыйматдинов соңыннан республикабызның күренекле җитәкчеләренең берсе булды. Октябрь районында райкомның беренче секретаре булып озак еллар эшләде. Шунда эшләгәндә Социалистик Хезмәт Герое исемен алды.

## Республика җитәкчеләре белән очрашулар

Күп вакытта без аерым шәхесләрнең хезмәтен коллектив хезмәте белән капларга тырышабыз. Сүз дә юк, кешеләр эшләмәсә, ул эшләрнең берсе дә хәл ителми. Шулай да әлеге эшне башлаганчы, ничек итеп төзергә, нинди материалдан төзергә дигән сорауларга җавап кирәк. Аларга галимнәрнең, планлаштыручыларның, финанс белгечләренең эшен юнәлтергә кирәк. Ул эшне кешеләр ихтирам иткән акыллы җитәкчеләр генә хәл итә ала.

Семен Игънатьев өлкә комитеты секретаре булгач, республика районнарындагы беренче секретарьларны алмаштыра башлады. Министрлар Советы рәисе итеп Ульян өлкәсе Кулатка районында туып-үскән, Мәскәүдә ниндидер бер оешмада эшләгән, Абдразяков Габделхак дигән кешене китерде.

Абдразяков безнең районга игеннәрне карый-карый, Арча ягыннан килгәнлектән, мин аны Ташчишмәдән Күшәргә килә торган юл өстендә каршы алдым. Ул бик караңгы чырайлы иде, миңа каш астыннан сөзеп карап кына исәнләште. Аңа Күшәр һәм Күнгәр басуларындагы игеннәрне күрсәттем. Ниһаять ул ачылып сөйләшә башлады. Арча ягы басуларында игеннәр начаррак булганлыктан сөмсере коелган икән. Безнең игеннәрне күргәч, күңеле күтәрелеп китүен ахырдан гына белдем. Җыелышлар җыеп тормады, бездән туп-туры Казанга китте.

Игънатьев безнең республика өчен күп кенә төзелеш эшләре башкарды. Зур стадион, хәзерге Министрлар Советы урнашкан бина, Куйбышев су саклагычы төзелгәннән соң Казанны дамба белән әйләндереп алу, Идел порты төзү эшләрен оештырды. Ул элек Таҗикстанда җаваплы эшләрдә эшләгән, аннан Мәскәүгә Эчке эшләр министры итеп күчерелгән булган. Мәскәүдән Татарстанга китерү сәбәбен безгә әйтмәделәр. Шулай да ниндидер врачларны урынсызга җәберләгән, кулга алдыру кебек эшләрдә гаепләп аны министрлыктан бушатканнар, дип сөйләделәр.

Игънатьев Татарстаннан киткәндә Өлкә комитетының беренче секретаре итеп үзе янында элек бүлек мөдире, аннан мәдәният эше буенча секретарь булып эшләгән Табеев Фикрәт Әхмәтҗан улын тәкъдим итеп, сайлатып калдырды.

Фикрәт Әхмәтҗанов Казан университетын тәмамлагач, шунда эшкә кала. Аннан аны өлкә комитетына бүлек мөдире итеп күчерәләр. Шул вакытта аны безнең Әтнә районына язгы чәчү, урып-җыю барышын күзәтү, районга ярдәм итү өчен вәкил итеп җибәрәләр. Ул бу эшләрдә катнашып, кешеләр белән аралашты, авыл хуҗалыгы эшләре белән якыннан танышты. Табеев безнең районның колхоз рәисләрен дә якыннан белеп калды һәм шул исәптән без дә якын танышлар булып киттек. Бервакыт ул безнең колхозга да керде. Бик эссе вакыт иде. "Сусадым, су эчәсем килә", диде. Без аңа Күнгәр авылы чишмәсеннән бер графин су алып килдек. Ул аны бик яратып эчте.

Су бетте, аннары Кушәр авылы чишмәсеннән алып мендек. Суны авызына якын китерү белән ул: "Юк, бу теге су түгел, башка чишмәдән алгансыз икән",—диде. Без аптырап калдык. "Ничек алай белә алдыгыз?" Сунын тәменнән, исеннән белгәнен әйтте.

Шуннан сон унбер чишмәнең суын лабораториягә анализга җибәрдем. Анализдан Ашыт суының ун ягындагы чишмәләрдә сунын катылыгы 7-8 берәмлек булса, сул ягындагыларнын катылыгы 24-27 берәмлеккә житә икәнен белдек. Соңгылары эчәргә яраса да, дәүләт стандартына җавап бирми, диделәр. Әлгань ун ягындагы сулар стандартка җавап бирә булып чыкты. Шуннан соң җир катламыннан ГОСка туры килә торган сулы катламнарны табып, яна скважина суларын элекке су кудыру торбаларына ялгадык. Җир астыннан чыккан суларның эчәргә яраклы булуы кешеләр өчен зур бәхет икәнен аңладык. Мин үзем эшләгән чорда мона нык әһәмият бирдем. Шулай итеп, бу мәсьәләдә Табеев безнең күз ачылуга сәбәпче булды. Ул шундый сизгер кеше, синен белән күзенә карап, аз гына елмаеп сөйләшә, ни уйлавынны күзеннән күреп тора иде. Ул бик яхшы оратор да. Һичбер туктаусыз, ялыктырмыйча, конспектсыз өчәр сәгать сөйли ала иде.

Табеевны Әфганстанга илче итеп җибәргәннән сон беренче секретарь булып Мусин Рәшит Мусинович эшләде. Ул да безнең районга берничә мәртәбә килде. 1981 елгы корылыкта галимнәр көзге чәчүне—арыш чәчүне уздырмаска киңәш иткәннәр, корыда арыш тишелмәячәк, дигәннәр. Мусин аптырап калган. Шул вакыт аңа, иң озак, иң яхшы эшләүче колхоз рәисе Галиев Фәйзи белән киңәшеп кара, дигәннәр. Шуннан ул телефон аша миннән киңәш сорады. Галимнәр фикерен аңлатты. Мин үз чиратымда: "Көз беркайчан да яңгырсыз булмый, 15 сентябрьдән соң бер елны да яңгыр яумый калганы юк, без бернигә карамыйбыз, чәчәбез",—дидем. Мусин, галимнәр сүзенә карамыйча, барлык район житәкчеләренә арыш чәчүне үткәрергә күрсәтмә бирде. 1982 елны арыштан республика бик зур уңыш алды. Татарстан икмәк тапшыру буенча алдынгы урынга чыкты. Кайбер житәкчеләр белсә-белмәсә дә, әмер бирергә ярата, Мусин иң элек башкалар белән киңәш итүне кулайрак күрә иде. Ул минем белән элемтәдә булып, иген эше нечкәлекләрен сораша торган иде. Үз эшен яратып, тырышып эшли башлаган иде, гомере генә кыска булды. Аны соңгы юлга озатканда миңа да табуты янында почетлы караулда торырга, кумгәндә каберенә бер уч булса да туфрак салырга туры килде.

Аннан соң Өлкә комитетының беренче секретаре булып Усманов Гомәр Исмәгыйль улы эшләде. Без ул вакытта Арча районына берләшкән идек. Әтнәгә аерым да килде, Арчага килгәч тә Әтнәгә керми китмәде. Бер караганда усал, икенче караганда мөлаем, елмаеп кына сөйләшә, бик кешелекле кеше булып та күренә белә. Синең яхшы якларыңны тиз күрә, сөендерә белә, сиңа канат куярга да бик оста. Тәртипсезлекләрне бер дә яратмый. Колхоз рәисләре аның килүен шикләнеп кенә кабул итәләр иде. Безнең колхоздагы тәртипне, эш-гамәлне җыелышларда үрнәк итеп сөйләде. Бервакыт безнең колхозга килгәндә, печән өсте иде, икәүләп болында йөрдек. Болын чәчәккә күмелгән, чәчәкләрдән бал исе килгән вакыт. Гомәр, печән чабучылар янында туктагач, чыдап тора алмады, бер егеттән чалгы сорап алып, шактый гына печән чапты. Колхозчылар, бу житәкче ничек матур итеп чаба, иген эшен яхшы белә, ахыры, дип, аны яратып калдылар. Республиканың колхоз рәисләрен чакырып, очрашулар уздыру гадәтен саклады. Алар белән завод-фабрикаларга экскурсияләр оештыра, җыелышлардан соң спектакль, концертлар карата, күренекле артисларны чакырта иде. Шулай яхшы гына эшләгәндә аны Мәскәүгә алдылар. Ул ризалык биреп ялгышты булса кирәк, чөнки татар кешесен Мәскәүнең урыс житәкчеләре өнәп бетермиләр иде. Анда эштән бушатылгач, үзебезнең Казанга кайтып дөрес итте. Министрлар Советы рәисе булганда озак вакытлар Табеев белән килешеп эшләделәр. Усмановны Табеев үзе районнан чакырып алган иде. Алар арасындагы аңлашылмаучылыклар авыл, район житәкчеләренә ишетелмәде. Миңа бер вакыт Министрлар Советына үтенеч белән керергә туры килде. Минем йөри торган "Газ-69" жиңел машинасы тузган иде, яна машина сорадым. Усманов: "Мин инде ун ел эшлим, бер тапкыр да кермисең, бер әйбер дә кирәк түгел ахыры сиңа, ичмаса, телефоннан да сөйләшмисең",—дип үпкәләп тә алды.

Кем беләндер сөйләште. “Менә минем янда Фәйзи Галиев утыра, ун елдан бирле бер машина да бирә алмыйсыз, дип үпкәли, машина сорый”,—диде.

Мин авылга кайтып берничә көн үтүгә, машинаны килеп алырга дип хәбәр дә китерделәр. Аннары, ул өлкә комитетында эшләгәндә, бездә газлаштыру эше башланды. Газны Кырлайдан китертергә кирәк иде. Мин кирәкле торбалар, рөхсәтләр алу буенча аңа күп тапкыр мөрәҗәгать иттем. Минем соравымны ул һәрвакыт канәгатьләндерде. Гомумән, ул эш кешеләрен ярата иде. Безнең колхоз кешеләре аңа бик рәхмәтлеләр.

Усманов Мәскәүгә эшкә киткәч, беренче секретарь булып Минтимер Шәрипович Шәймиев калды. Аның эшләгән чоры Татарстан өчен тарихи чор дияргә була. Ул эшләгән чорда СССР таркалды. Аның җитәкчелегендә Татарстан мөстәкыйльлек ала алды, үз Конституциясен кабул итте.

Мин алтмыш яшем тулганнан соң колхоз хезмәтеннән азат итүне сорап Арча райкомы бюросына гариза бирдем. Ул хәбәрне партия өлкә комитетының беренче секретаре Гомәр Исмәгыйлович Усманов белгән. Мине үз янына чакырды. “Колхоз рәислегеннән китмә, дип үгетләргә чакырдым”,—диде. Колхозның шул елгы исәп-хисап җыелышына Минтимер Шәрипович килде. Бу вакытта ул Министрлар Советы председателе иде. Җыелышта башыннан ахырына кадәр утырды, соңыннан бик матур итеп чыгыш ясады. Шунда минем янадан рәис итеп сайлануымны хуплады, безнең эшкә зур бәя бирде. Шунда уйламаганда-көтмәгәндә Нурсөя исемле бер колхозчы: “Алай бик яхшы эшләвен дә белгәч, ник аңа Герой исеме бирмисез?”—диде.

Икенче мәртәбә Минтимер Шәймиев ике елдан соң безгә бәрәңге алганда килде. Көн кояшлы. Колхозчылар чишенеп, иркенләп эшләп йөриләр. Без Минтимер Шәрипович белән бәрәңге чүпләүчеләр яныннан үтеп бара идек. Минтимер Шәрипович теге җыелышта сөйләгән хатын янына барып чыкты. “Ә, син теге җыелышта Фәйзи Әхмәтовичка Герой исеме даулаган ханым бит әле”,—диде. Бәрәңге чүпләүчеләр көлештеләр. Гади итеп сөйләшкәнгә күрә кешеләр аны яратып калдылар.

Русиядә авыл хуҗалыгы таркала барганда, безнең республикабыз аны саклап калды. Минтимер Шәймиевнең кешеләрне яратуы, зирәк акылы белән сабыр эш итә белүе аркасында зур эшләр башкарылды. Халык аны аңлый, шуңа күрә аны олылый, хөрмәт итә, ярата. Өлкә комитеты безнең колхозда зур семинар уздырды. Семинар СССР күләмендә булып, анда 400 ләп кеше катнашты, җитәкчеләр, галимнәр бар иде. Аларга сукаламыйча яхшыртылган гади болынлыкны күрсәттек. Ул болын Әтнә ягыннан килгәндә Күшәр авылы янында—табигый үлән бик яхшы үскән иде. Шунда бер галим бер уч үлән йолкып алды да, дару үләннәрен аерып, аларның файдасы турында сөйләде. Хайваннар өчен дару үләнле болынның файдалы булуын, ә чәчкән үләннәрдә дару үләннәренең булмавын яки аз булуын аңлатты.

Семинарда катнашучылар терлекләр өчен төзелгән комплекслы торакларны карадылар, иген басуларын, авылларны йөреп чыктылар. Соңыннан семинар җитәкчесе Минтимер Шәрипович бик зур рәхмәт әйтте. “Төрле җирдән килгән кешеләр алдында Республикабызны акладыгыз”,—диде, киләчәккә дә уңышлар теләп китте.

Эчке эшләр министры Япиев Салих Бәрәзә авылына еш кайта иде. Туганлык аркасында кайтса да, ул шактый ярдәм дә иткәләде. Районда оештырылган бәйрәмнәргә дә, җыелышларга да катнаша иде. Республика прокуроры Хәмидуллин, мәгариф министры Мәхмүтов тә безгә еш килде. Мәхмүтов Мирза Әтнә мәктәбен үрнәк мәктәп итеп хәзерләүгә күп көч салды. Әтнә урта мәктәбе шактый еллар республикада үрнәк мәктәп булып, анда республика семинарлары үткәрелде.

## Истә калган көннәр

1968 елны авылдашларым минем кандидатурамны Татарстан Верховный Советына депутатлыкка тәкъдим иттеләр. Әтнә округы безнең авыл кешеләренең тәкъдимен кабул итеп, мине депутат итеп сайладылар. Шушы сайлау унаеннан, авылларда сайлаучылар белән очрашканда, сугышка кадәрге

сайлаулар уздырган көннәрдә авыл халкының һәм җитәкчеләрнең бу эшкә зур әһәмият бирүләрен күз алдыма китердем.

... 1937 елны СССР Верховный Советына депутатлар сайлау булган иде. Сайлау алды чорында депутатлар белән очрашуны бик тантаналы итеп үткәрделәр. 1938 елда РСФСР Верховный Советына да сайлаулар уздырылды. Бу елларны мин малай күзеннән карап кына фикерлим. Ә сугыштан соң, 1946 елны СССР Верховный Советына сайлаулар мин колхоз рәисе булып эшләгән чорда үткәрелде. Бу безнең Әтнә районында зур вакыйга булды. Сугыш вакытында мондый тантаналар бер дә булмаганлыктан, бу сайлауга әзерлекне һәм сайлауның үзен халык зур бәйрәм дип кабул итте. Әле дә хәтеремдә, депутатлыкка кандидатлар белән очрашуны безнең районда Күнгәр авылыннан башлау планлаштырылган иде. Шул көнне Күнгәр, Түбән Шашы, Югары Шашы авылы сайлаучылары Күнгәр авылы клубы янына җыйналып, Кызыл Юл районының Кышлау авылы ягыннан килергә тиеш булган депутатлыкка кандидатларны көтеп тордылар. Күнгәр авылының Кышлау урамы башында чаңгыда шуып йөрүче малайлар Кышлау ягыннан бик күп атлар килүен хәбәр итте. Клуб янына җыелып торучылар җанланып китте.



*Фәйзи Галиев әдип Гариф Ахунов һәм тәнкыйтьче Фәрваз Миңнуллин белән иген басуында.*

Без, җитәкчеләр, кешеләрне урам буена ике яклап тезеп, уртадан атлар белән узарлык юл калдырдык. Унлап кандидат, аларны озатучылар, каршы алучылар, гармунчылар, җырчылар без ясаган коридордан клуб янына шаулап килеп керделәр. Аларны каршы алырга баручылар—райком секретаре, КГБ начальнигының ярдәмчесе шулар белән бергә килде. Депутатлыкка кандидатларның берсе Юдино тимер юлы депосының паровоз йөртүчесе Яковлев, икенчесе Кызыл Юл районы Тукай-Кырлай колхозының рәисе Сафина Фәсәхәт иде. Депутатлыкка кандидатның өченчесе килмәгән булып чыкты. Кызыл Юл районы вәкилләре—озата килүчеләр—кайтып китте. Шуннан соң без, клубка кереп, тантаналы рәвештә очрашу үткәрдек. Очрашуга килүче сайлаучылар күп иде, клубка сыймыйча, тышкы якта калып, җыелыш барышын тыңлап тордылар. Җыелыш беткәч, кунакларны чәй белән сыйладык. Аннан соң Күнгәр авыл советына кергәч өч колхозның да рәисләре тәнкә-чуклы атлар, гармуннар белән кунакларны Әтнәгә кадәр озатып куйдык. Озатучы яшьләрне кайтарып җибәргәч, без, колхоз рәисләре, райком бинасына кердек, депутатлыкка кандидатлар беренче секретарь бүлмәсеннән чыкканны көтеп утырдык. Район җитәкчеләре белән депутатлыкка кандидатлар, алар белән

без дә Әтнә ашханәсенә кечкә ашка төштек. Очрашу күңелле шартларда узды. Үзешчән артистлар чыгыш ясады. Караңгы төшкәч кенә таралдык. Миңа, бүген җыеп килгән атым белән иртәгә кандидатларны Бәрәскәгә алып бару өчен, сәгать 8 гә Әтнә райкомына килергә куштылар.

Янадан шундый истәлекле вакыйгаларның берсе минем СССР Верховный Советына депутатлыкка сайлануым булды. "Искра" колхозы колхозчылары 1979 елда мине СССР Верховный Советына депутатлыкка кандидат итеп күрсәттеләр. Моңа кадәр мин берничә мәртәбә партия өлкә комитеты әгъзасы булып сайланган идем. Күп кенә очрашуларда да катнашырга туры килде. Республика күләмендәге җитәкчеләрне күрү, алар белән аралашу, сөйләшү насыйп булды. Инде кайберләренең гамәлләренә, үз-үзләрен тотышына, эшлеклелек сыйфатларына үземчә бәя бирергә дә мөмкинлек туды. Ә СССР Верховный Советына сайланып, анда йөри башлагач, дөньядагы хәлләр белән дә тирәнтен танышу мөмкинлеге ачылды. Шушы хәлләрдән соң, үткәннәргә кире кайтып, сайлаучыларның әйткән сүзләренә, үтенечләренә ныграк колак сала башладым, аларның көнкүрешләренә карата югары урында утыручы җитәкчеләрнең карашларын белеп, үземчә нәтиҗә чыгардым.

Депутат булганга кадәр кандидатның программасын сайлаучылар алдында игълан итү мәсьәләсе куела. Депутат булганнан соң сайлаучылар тарафыннан әйтелгән фикерләр наказлар итеп теркәлә. Ә менә шул депутатның сайлаучыларга вәгъдә иткән программасын үтәү шактый ук катлаулы, үтәп чыгуы авыр булган бер эшкә әйләнә. Нинди дә булса бер әйберне хәл итү өчен, депутатка күп кенә бусагаларны таптарга туры килә. Миңа үзебезнең колхоз сайлаучылары тарафыннан бирелгән наказ—авылларны газлаштыру булды. Подрядчик эзләү һәм торба табу өчен көне-төне чаптым. Республика оешмаларында йөреп арыганнан соң, үзебездә хәл итә алмагач, Мәскәүгә, госплан председателе Байбаковка барырга туры килде. Ул, хәл итәрбез, дип, минем хатымны алып калды. "Ул эшне хәл итү өчен РСФСР госпланына җибәрдек",—дип хат килде. Алар үз чиратында: "Фонд билгеләнде, Татарстан госпланы аркылы авыл хуҗалыгы министрлыгы аша хәл ителергә тиеш",—дип хат җибәрделәр. Татарстанга җибәрелгән торба фондында безгә кирәкле юанлыктагы торба республика авыл хуҗалыгы министрлыгына нибары 30 километрга бирелгән булып чыкты. Ә безнең колхоз өчен Тукай-Кырлайдан Күңгәргә кадәр 22 километр озынлыктагы торба кирәк. Шулай итеп, авыл хуҗалыгы министрлыгында утыручы Прохоров: "Сезгә бу торбаларны бирсәк, республикада башка хуҗалыкларга берни дә калмый. Ә андый торба кирәк хуҗалыклар 100 дән артык. Бу—тормышка аша торган эш түгел",—дип йомгак ясап куйды. Ә подрядчик табу буенча безнең хатны Татарстан АССР коммуналь хуҗалык министрлыгының төзү оешмасына җибәрделәр. Аларның еллык планы бу эш мәйданыннан аз гына артык булып чыкты. Кычкырып бер көлделәр дә, бу эш булырлык түгел, диделәр. Аннан соң Урта Идел газ төзү оешмасы җитәкчесе Газизовка мөрәҗәгать иттем. Ул да бу эшнең күләмен күргәч, моңа җитәрлек әйберебез юк, дип баш тартты. Шуннан соң "Татнефтепровод" трестына барырга туры килде. Аның җитәкчесе Дубле Иван Григорьевич "менә эшлибез, менә эшлибез", дип йөртте дә, бу эш сузыла башлагач, миңа өлкә комитетыннан ярдәм сорарга туры килде. Шунда төзелеш турында сөйләшеп утырганда, "Востокстройтрансгаз" тресты җитәкчесе Шиһабиев Тәлгать Нигъмәтҗанович белән очраштым. Ул карап-карап торды да: "Сезнең ул төзелешегез бик зур инде үзе, шулай да, әйдә, сезнең белән икәү эшләп карыйк әле", — диде. Ниһаять, эш башладык. Ул тумышы белән Арча районыннан икән, шуннан чыгып та ярдәм итәргә уйлагандыр инде. Аның белән килешеп эшләп җиде авылны да газлаштыруга ирештек.

Югарыда саналган бу хәлләрне ваклап аңлатып китүнең сәбәбе шул—еллар үткән саен беркүк эшне бер-берсенә кушып, кәгазь боткасы ясау турыдан-туры эш белән шөгыльләнүчеләргә тискәре йогынты ясый. Хуҗалык эшләрен хәл иткәндә, урындагы җитәкчеләр төрле оешмаларга йөреп арып бетәләр иде.

## Чын житәкче

Үз эшен белеп, ижади эшләүчеләрнең берсе—"Северный" совхозы директоры Сафин Нәкыйп булды. Мина аның белән бер районда эшләргә туры килде. Ул кешеләрне аңлый, аларны үзе уйлаган эшләрне башкаруга юнәлтә белә иде. Сугыштан Днепр суын кичкәндә күрсәткән батырлыклары өчен Советлар Союзы Герое исемен алып кайтты. Аңа Кенәр районының (Кызыл Юл) иң артта бара торган колхозларыннан совхоз төзү бурычы йөкләтелде. Бу совхоз 17 авылны берләштерде. Әлеге авыллар, Сафин кебек житәкче кулына эләккәч, республика күләмендә алдынгылар рәтенә чыкты. "Северный" ике ел эчендә рентабельле һәм зур табышлы совхозга әйләнде. Сафинның үзенә таләпчәнлеге һәм шуны үзенең буйсынуында булган урта буын житәкчеләргә күчерә белүе мактауга лаек иде. Төзелеш эшләренә хирыслыгы көчле иде. Һәммә жирдә агач кулланганда, ул совхозның үзәге булган Шушмабаш авылында кирпечтән биналар төзетә башлады. Районыбызда беренчеләрдән булып кирпечтән мәдәният йорты һәм хужалык биналары салдырды. Аның житәкчелек итү ысулында эшне тапшырганнан соң, үтәлешен тикшерү тәртибе булды. Алар ай саен жыелышлар, эшләрнең үтәлешен тикшереп, киләсе ай өчен план коралар иде. Ул жыйналуны авыллардан килүче житәкчеләр "почемуга барабыз" дип йөртәләр иде. Сафин жыелышта, теге яки бу эш үтәлмәсә, "почему?"—дип сорау бирә торган булган...

"Северный" үзәгендә авыллардан килә торган житәкчеләрнең атларын бәйләп кую өчен махсус мәйданчыклары бар иде. Ат ашату тагараклары калай белән тышланган. Атларны шунда тезеп бәйләп кую үзе бер тәртиплелекне күрсәтеп тора! Район үзәкләрендә дә мондый тәртип булмады. Әтнәдә дә атларны төрле жирләргә бәйләп куялар, райбашкарма бинасы алды төрле чүп-чар белән тула торган иде. Әтнәгә жыелышка Кенәр яклары Күшәр авылы аркылы килә. Сафин Нәкыйп атларының яхшылыгы, дирбияларының матурлыгы белән, кошовка чаналарының нәфислеге белән аерылып тора, гел атбашчы (кучер) белән йөри торган иде. Бик яхшы ике рысагы бар. Бер килгәндә берсен, икенче килгәндә икенчесен жигә. Төлке толыпка төренеп утырган хәлдә, безнең Күшәр авылы яныннан бик зур тизлек белән үтеп китүләре гел күз алдымда. Әтнәгә барып житкәч тә атына махсус япма ябып куя, атын атбашчы саклап тора. Боларны бөртекләп язуымның сәбәбе шул, бу кеше нинди генә эш башкармасын, аның зәвыклылыгын әйтеп тора иде. Аерым шәхесләргә бәя бирү бездә бер вакытта да житенкерәмәде. "Партиянең акыллы житәкчелегендә коллектив уңышларга иреште"—дип әйтеп, шул жөмлә астында аерым шәхесләрнең хезмәте күмелеп, югалып барды. Еллар үтү белән, безнең район Арча белән берләшкәч, озак тормыйча, Сафин Нәкыйп Зеленодол районының "Юдино" совхозына директор итеп күчерелде. Ул эшләгән вакытта Северный совхозының баш белгечләре районның иң яхшы кадрлары булып исәпләнделәр. Төрле дәрәжәдәге жыелышларның президиумнарында гел алар була иде. Сафин киткәч, совхозның директорлары булып шул данлыклы белгечләр эшли башлады. Белгечләр үз урыннарында калды, ләкин ике елдан совхоз үзенең ирешкәннәрен югалтып бетерде, рентабльлелек төште. Район житәкчеләре аның бу хәлгә төшүен совхозны бүлеп туктатып булыр дип уйладылар. Кенәр авылын Яңа Ашыт авылы белән бер совхоз итеп аерып чыгардылар. Бер ел яшәп карадылар, совхоз һаман ирешелгәнне югалта барды. Шуларны исәпкә алып Апаз авылын үзәк итеп "Ватан" совхозы ясадылар. Болай да бармый дип дүртенче итеп Акчишмәне аерып чыгардылар. Янадан Ватан совхозыннан яңа—Сафин исемендәге совхоз төзелде. Бу совхозга Сафинның туган авылы керде. Алтынчы совхоз итеп Носы совхозын ясадылар. Хәзерге көндә бер Сафин житәкләгән совхозны алты совхоз ясап, аларда алты директор эшли. Белгечләре дә шул күләмдә артты. Ниһаять, хәзер берникадәр тәртипкә төштеләр кебек. Эшләп торган вакытта мондый шәхесләргә югары оешмалар тарафыннан игътибар житмәде. Мин үзем, зурмы, кечкенәме, нинди эш булуга карамастан, заводмы, колхозмы, совхозмы, аның уңышлары житәкчесенең булдыклылыгына бәйле дип саныйм. Яхшы гына эшләп килгән хужалыкның житәкчесе китүгә, ике-

өч ел эчендә ирешелгәннәре юкка чыга, мин моңа шаһит. Район житәкчеләре шундый шәхесләрне эзлиләр, ләкин алар бик аз туа шул. Мин белгән чорда эшләгән колхоз рәисләренең 80 проценты ун елга кадәр дә эшли алмадылар. Колхоз рәислегенә яшьләр сайланганнан соң аларны эшкә өйрәтүче юк. Кайберләре сайлану белән үзләренчә өйрәтә башлый, бар кешедән дә өстен булмакчы булалар. Колхоз рәисләренең житәкчелек итү тәртибен мин ике төргә бүләр идем: беренчесе—ярдәмчеләренә ышанып, аларны үз тармакларының чын хуҗасы итеп тәрбияләү, анлашып эшләү, кычкырмыйча, тавыш күтәрмичә, сүгенмичә, башкарыла торган эшнең әһәмиятен төшендерү. Аның ае, көне, сәгатенең әһәмиятен аңлату. Моңысы—Сафин шикелле шәхеснең эш ысулы. Икенче юлы—якындагы ярдәмчеләренә ышанмыйча, бөтен байлыкны үз кулында тотып, үзең генә зур житәкче булып, үз фәрманың белән генә эшләтү. Бу ысул үзенә буйсынган тармак житәкчеләренең иҗади эшләүләренә комачаулый. Алар йомыш үтәүче кешеләргә генә әйләнәләр. Бу төр житәкчеләр районнан әйтелгән күрсәтмәләргә таянып, эштәге ялгышлыкларын акларга тырышалар. Колхоз житәкчеләренең еш алмашынып торучылары да шушы төр кешеләргә туры килә. Ә менә Сафин кебекләр үзләренең хаклыгына ышанып яшәделәр. Сафин "Северный"дан китеп, "Юдино" совхозына күчкәч, бурычка батып беткән совхозны ике елдан рентабельлегә әйләндерде. Бервакыт республика җыелышында: "Ничек болай югары күтәрелә алдың?" -дип сорагач, "Булды инде шунда, төрле юллар кулланырга туры килде,—дип көлә-көлә сөйләп китте.—Ин элек урлашу белән көрәшергә туры килде. Башта тавык фермасын койма белән әйләндереп алдык. Капкага көчле каравыл куйдык. Шулай да, азлап булса да тавыкларны урлау дәвам итте. Койма буеннан карап торырга каравылчылар куйдык. Ниһаять, урлау юлы ачылды. Койманың тышкы ягыннан кармакка борчак киертеп эчкә ыргыталар, тавык балык кебек шуңа капкач, теге яктан тартып алалар икән. Бу юлны да япкач, тавыклар кимеми башлады".

Акча табуның икенче бер көлкеле юлын да сөйләде. "Бер вакыт газитләрдә, радиода, бытбылдык асрау бик файдалы дип сөйли башладылар. Аның итеп ашасаң, яшәрәсең, имеш. Ярый, хуш, аны үрчетә башладык. Газитләрдән укыган кешеләр—сатып алучылар күбәйде. Ә кичләрен, Казаннан җиңел машиналарда төрле-төрле түрәләр җыела. Күбесенең яшәрәсе, көчле ир кеше буласы килә. Шулай итеп, акча табуның табигый булмаган юлларын да файдаландык... Соңыннан газитләрдә галимнәр бу эш дөрес түгел, ул ит андый гадәттән тыш көчкә ия түгел, дип язып чыккач, кызыксыну бетте, бытбылдык фермасын бетерергә туры килде".

Сафин кебек сәләтле шәхесләр кайда эшләсәләр дә, нинди шартларга туры килсәләр дә, каушап калмыйлар иде шул...

Сафин Нәкыйп эшләгән вакыттагы авыл малайлары, соңыннан югары уку йортларын тәмамлап, авыл хуҗалыгында зур житәкчеләр булып үстеләр. Соңгы елларда авыл хуҗалыгы Министры булып эшләгән Сибагатуллин Фатыйх, Балтач районының хакимият башлыгы Әхмәтов Марат, Арча районы хакимият башлыгы Минһаҗев Вәгыйзләр—сугыштан соң үскән житәкчеләр. Әгәр колхоз житәкчеләрен санап карасаң, Арча районында күп кенә алдынгы колхозларның житәкчеләре—Сафин эшләгән совхоз егетләре. Мин белгәннәре генә—"Носы", "Сафин исемендәге", "Ватан", "Северный", "Акчишмә", "Кенәр", "Власть Советов" совхозларының директорлары, "Авангард", "Заря" колхозларының рәисләре булып эшлиләр. Әле мин белмәгән башка җирләрдә дә бу совхоздан чыккан белгечләрне очратырга була. Республикабыздагы бер совхоздан шулкадәр күп авыл хуҗалыгы белгече чыкканын әле минем ишеткәнем юк. Сафин мәктәбенең шифалы җилләре бу кадрларның үсүенә һичшиксез йогынты ясагандыр.

Мина тагын "Игенче" колхозында рәис булып эшләгән Сәмигуллин Әдһәмнең эш ысулы ошый иде. Ул гел үз көченә ышанды. Яңалыкларга омтылучан, терлек үстерү, аларның нәселен яхшырту буенча күп эшләде, җир агротехникасының үз җирләренә яраклы системасын булдырды. Төзелеш буенча зәвыгы бик югары иде. Аның колхозындагы төзелешләр пөхтәлекләре белән аерылып тордылар. Шундый ук дәрәҗәле рәисләрнең берсе — Сабиров Наил. Ул "Чулпан" колхозында озак еллар рәис булып эшләде. Аңа кадәр бу колхозда рәисләр гел алмашып тордылар. Ә Сабиров Наил озак эшләде.

Аның зур хәзинәсе—ул кешеләр белән ышандырырлык, матур итеп, дәлилләп сөйләшә белә торган иде. Бу—колхоз рәисенә иң кирәкле сыйфат. Төзелеш эшләрен дә бик яратып башкарды. Соңгы елларда яшьләрдән колхоз рәисе булып "Шахтер" колхозында Хәкимов Габделәхәт эшли башлады. Бу колхоз районда иң авыр бара торган колхозларның берсе иде. Хәкимов "Шахтер" колхозын кыска гына вакытта алдынгылар рәтенә чыгарды. Ул эшли башлауга ук игенчелек эшен тәртипкә салуны максат итеп куйды. Һәм югары уңыш алуга иреште. Дәүләткә елдан-ел азлап кына икмәк тапшырып килгән колхоз бер елга 4 мең центнер икмәк тапшырып, җитәкчеләрне хәйран калдырды. Аның яшьлеген, тазалыгын, тырышлыгын исәпкә алып, Этнә совхоз техникумына директор итеп күчерделәр. Авыл хуҗалыгы продукцияләре җитештерү буенча совхоз югары нәтиҗәләргә ирешә башлады. Үзе эшләгән вакытта Хәкимов техникумда яна белгечлек—бухгалтерлар хәзерләү бүлеге ачуга ирешге.

## Район һәм республика мөнәсәбәтләре

Мин рәис булып эшли башлаганнан бирле безнең район, республикабыз белән бербөтен булып, ныклы элемтәдә яшәде. Республикабыз җитәкчеләре дә район җитәкчеләре белән яхшы мөгамәләдә булдылар. Соңгы вакытларга кадәр районнар белән республика оешмаларының җитәкчелек итүе өлкә комитетының конференцияләре, пленумнары, бюролары карарын үтәүгә нигезләнгән иде. Ул карарлар "яшерен" дигән тамга белән райкомга килә. Райкомнарда әһәмиятлелегенә карап район партия конференцияләренә, пленумнарга, райком бюроларына куеп тикшерелә. Аннары алар башлангыч парт оешмаларга җибәрелә һәм газитләрдә игълан ителә, колхозлар теге яки бу эшне кайсы айда, кайсы көндә үтәргә тиешлеге билгеләнә. Ә колхозларның ул эшләрне башкару мөмкинлекләре бармы-юкмы — анысы исәпкә алынмый иде. Өлкә комитеты һәм райкомнар халык тарафыннан сайланып куелган совет оешмаларына да шундый ук күрсәтмәләр бирен килделәр.

Соңгы вакытта өлкә комитеты бюросы Министрлар Советы белән бергә утырышлар үткәреп, бердәм каралар кабул итүне гадәткә кертте. Районнарда да райком бюросының район Советы башкарма комитеты утырышлары катнаш итеп үткәрелде. Шушындый юллар белән кабул ителгән карарларны урыннарда тормышка ашыру өчен районнарга республикадан, ә колхозларга районнардан вәкилләр җибәрелде. Бу вәкилләр язга хәзерлек, язгы чәчүне уздыру, урып-җыюга хәзерлек, тораклар төзү, ремонтлау кебек эшләрне тикшереп тордылар. Урыннардагы колхоз җитәкчеләренең иң теңкәсенә тигән нәрсә—дәүләткә икмәк тапшыруны оештыру булгандыр. Бу чорда вәкилләр берсе артыннан икенчесе килеп, колхозлардан икмәк тапшырту белән генә шөгыльләнделәр. Урылган басуларны махсус ясалган бер квадрат метрлы таяклар белән тикшереп йөрделәр. Район вәкиле балчык кисәген еракка ыргытып җибәрә дә, шул урынга квадратлы таякны салып, квадрат эчендә ничә башак калганын саный. Шул бөртекләрнең, авыл кибетенә кереп, ничә грамм булуын үлчәп чыга. Шуның белән бер гектарда күпме югалту булуын исәпләп чыгара. Алар бу эшне тантаналы рәвештә, кош тоткан кебек башкаралар иде. Һәм шулай итеп башак җыярга кушалар, эшнең үтәлешен тагын килеп тикшерәләр. Бу эшләр үтәлеп житмәгәндә, колхоз җитәкчеләрен җавапка тарталар. Безнең районда гына да кайбер елларны унар рәиснең төрмәгә ябылу очраклары булды. Аннан колхоз рәисләренең эшлеклелеген сыерлардан савылган сөт белән бәһаләү модага керде. Күп кенә рәисләр сөт җитештерүне киметкән өчен эшләреннән бушатылды. Бу хәл соңгы елларга кадәр дәвам итте.

Кыскасы, югары оешмаларның карарларын үтәү түбәнге оешмаларга мәҗбүри итеп куелды. Ә ул карарларның мәгънәсе ягъни мәгънәсезлеге хакында үз фикереңне әйтергә бик сирәк очракта гына рөхсәт ителә иде. Мин—шундый башбаштаклык аркасында кайбер райком секретарьларының җитмешәр рәисне алмаштыруларына шаһит булган кеше.

Кайбер очракта республика оешмаларына да югарыдан үти алмаслык бурычлар куела иде. Мин Үзәк комитеттан һәм СССР Министрлар Советыннан килгән шундый карарлар белән очраштым. Мәсәлән, безгә күпъеллык үләннәр чәчү юлы белән күп басулы әйләнешне бетереп, "пропашная система" дигәнгә күчәргә тәкъдим иттеләр. "Пропашная система" галим Пряпашников тәкъдименә нигезләнеп эш ителде. Шуннан соң Лысенко дигән "галимнең" нәселдәшлек гыйльме белән баш әйләндердек. Институтларда йөзәр ел нигезле өйрәнелгән нәселдәшлек теориясен юкка чыгарып, беркем тарафыннан кабул ителмәгән "фәнне" галимнәр безгә көчләп такты. Бераздан, алдан әзерлексез рәвештә СССРның барлык зоналарында яшел азык өчен кукуруз чәчүне тәкъдим иттеләр. Җитәкче кадрлар кукуруз игүнең үзенчәлекләрен белмичә тотынулары аркасында, зур гына мәйданнарда уңышсызлыкка очрадылар. Фәкать соңгы елларда гына эш бераз көйләнде. Шулай ук ил белән идарә итүче министрлыкларны бетереп, совнархозлар белән идарә итүгә күчү дә үзен акламады. Бу система озакка бара алмады, ил тагын министрлыклар белән идарә итүгә күчте.

1980 елда без коммунизмда яшәргә тиеш идек. Никита Сергеевич Хрущев шулай диде. Шуңа бәйләп матур итеп сөйләүләр күп булды. Шулай ук социализмның уңышлары һәм кимчелекләре хакындагы бәхәсләр дә куерды. Мин ул хәлләргә бәя бирергә җыенмыйм, әмма шуны гына әйтәм: коммунизм дигән нәрсә безнең өчен язуда гына калды, без ирешә алырлык булып чыкмады. Социализм дигән төшенчәнең исә бер ягын Ватан сугышы чорында белдем. Барлык байлык, аерата промышленность дәүләт кулында булып, ул гел сугыш кирәк-ярагларын, коралларны әзерләп торды. Димәк, корал җитештерү үзәкләшкән булуы белән уңай иде. Ә җитештерелгән байлыкка хуҗа булмау әрәм-шәрәм итүгә, урлау-талауга китерде. Капитализм тәртибе керсә, бөтен милек хуҗалы булыр, әрәм-шәрәмгә юл куелмас иде, дип исәплим. Социализм чорында хастаханәләрдә, ял йортларында дәвалану, балаларны мәктәптә, югары уку йортларында укыту, җәйге лагерьларда ял иттерү, картлыкта пенсияләр белән тәэмин итү, хөкемәт төзегән фатирларда яшәү, хезмәт белән тәэмин ителү халык өчен зур уңайлык булып саналды.

**Капитализм дип аталган система социализмның халык өчен тудырылган уңайлыклары белән баетылган очракта гына яхшы булырга мөмкин.**

Халыкка яшәү өчен унайлыклар тудырылса, хезмәте өчен үз вакытында түләнсә, дәүләт системасы нинди исемдә булса да ярый дип исәплим.

Хәзерге шартларда, СССР дип аталган ил таркалганнан соң, Россиядә халыклар ике төркемгә бүленде. Берәүләре социализмда яшәүне, икенчеләре капитализмга күчүне яхшырак күрә. Колхозлар төзелгәнче аерым хуҗалык булып яшәгән чор кешеләре беткәнлектән, колхоз чорында үскәннәр күмәкләшеп яшәүне кулай күрәләр. Безнең районыбыз авылларында яшәүчеләр дә колхозларны таратмауны яклый. Аерым хуҗалык булып яшәү өчен шартлар булмаганны алар яхшы аңлый. Югарыдагы оешмалар колхозларны таратып, җирне аерым кешеләргә бүлеп бирүне хуп күрә. Димәк, дәүләт авыл хуҗалыгы мәшәкатьләреннән котылырга уйлый. Бу юлны сайламаслар иде, әгәр җир астыннан чыгарыла торган күмер, нефть, руда, алмаз, алтын ише байлыклар, үзе үсеп утырган урман булмаса! Дәүләт шул байлыкларны сатып, икмәкне, җиләк-җимешне, яшелчәне чит илләрдән алмакчы була. Ләкин байлык бетмәс була алмый бит! Мәсәлән, белгечләр бездә нефть запасы 30-40 елдан бетәргә мөмкин, диләр. Нишләрбез аннан? Киләчәк буын ул вакытта безгә нәгъләт укыр бит! Җирдә иген үстерү, хәйван асрау белән шөгыльләнүчеләр, шартлар булмау сәбәпле, таралышып бетәрләр, аларны кабат иген эшенә җәлеп итеп тә булмас...

Болай да авыл хуҗалыгы ил, республика, район буенча төрле үзгәрешләр кичерде. Авыл хуҗалыгына көчләп үзгәрешләр кертү җир кешесенең гайрәтен чигерде, читкә китәргә мәҗбүр итте.

## Колхозларга мөстәкыйльлек бирелерме?

**30** елларда аерым хуҗалык булып яшәүне бетереп, колхозлашуга күчүне авыл халкы бик авыр кичерде. Уйлап карасаң, йөзләгән ел буена ияләнгән мөстәкыйль тормыштан аерылуны алар күз алдына да китерә алмады, аптырашта калдылар. Колхозның ничек булачагын дөрес итеп аңлатучы да булмады. Аннары, чәчүлек орлыкны, иген коралларын җыйдылар. Кешеләрнең амбарларын сүтеп алып, колхоз өчен берләштерелгән амбарлар төзеделәр. Җирләрне дә берләштереп куйдылар. Авыл халкының югарыдан бирелгән күрсәтмәне үтәми хәле юк. Ә күрсәтмәләр килеп кенә торды. Мин колхоз җитәкчесе булып эшләгәндә, бер елга 700 дән артык кәгазь язылып, аңа райком секретаре, райбашкарма рәисе кул куйган була иде. Боларның барысында да: таләп итәм, кушам, бер нәрсә белән дә исәпләшмичә үтәргә, үтәлмәсә, колхоз рәисләре эшләреннән алынып, җавапка тартылачак, чара күреләчәк, дип кисәтелгән була иде. Югарыдагылар безне һәрвакыт шулай куркытып тордылар. Элек аерым хуҗалыкта мөстәкыйль яшәргә өйрәнгән авыл халкы шушы юл белән эшли һәм яши башлады. Хәзер авыл халкы үз юлын үзе сайлап, мөстәкыйль яшәсен, диләр. Бу сүзләр—буш вәгъдәләр, буш сөйләшүләр. Мин авыл халкының бергәләп яшәү рәвешен 1930 еллардан бирле беләм. Шул вакыттан бирле колхозларга мөстәкыйльлек бирелмәде. Колхоз белән идарә итүдә бүгенгә кадәр үзгәреш юк. Элек тә һәм хәзер дә югарыдан: чәчә башларга, сөрә башларга, печән чабарга, силос, сенаж сала башларга, уракка төшәргә, яңгыр явып торса да ашлык егарга, борчакны чабарга, сыерларны җәйге лагерьга күчерергә, каплата башларга, башларга... Шулай итеп, авыл халкы һәм аның җитәкчеләре төрле күрсәтмәләр, җыелышлар белән буталып, хөкүмәтнең яхшырак карарлары булмасмы дигән өмет белән яшәп килә. Колхозчылар җитештергән продукциягә дә бәһа югарыдан куела. Сугыш вакытында авыл халкын эшләтү өчен сугыш чоры законнарын чыгардылар, хезмәткә түләнмәде диярлек. Сугыштан соңгы еллардагы хәлләр дә колхозларның үсешенә тоткарлык ясады. Сугыш чорында кая күпме кеше, корал, икмәк, ат һәм башкалар кирәк, шул законнарга таянып эш иттеләр.

Игенчеләрнең фикерләрен белмичә, сорамыйча, җирләрне эшкәртү буенча Үзәк комитет карары чыкты. Шул карар нигезендә, сөрү катлавы 15 сантиметр гына булган җирләрне дә тирән итеп сөрү аркасында басулар өстенә кызыл балчык чыкты, уңдырышлы катлау начарланды. Бу эшне районнардан килгән вәкилләр тикшерде, сукаланган җирләрнең тирәнлеген үлчәп, тикшереп, тирән сукаларга мәҗбүр иттеләр. Бер вакыт өлкәдән килгән вәкил, җир сөрүче тракторчы янына килеп, сукаланган җирнең 15 сантиметр гына булуын үлчәп белгән. Шуны ул райком секретарена җиткергән. Мине райком бюросына чакырдылар. "Ул тракторчыга мин үзем шулай сөрергә куштым, ул җирне шуннан да тирәнрәк сөреп булмый, кызыл балчык чыга",— дип аңлаттым. Алар МТС җитәкчеләрен дә, мине дә гаепләп, Үзәк Комитет карарын бозучылар, дип, бик зәһәр, гарьләндергеч сүзләр әйттеләр. "Сиңа Үзәк Комитет карары берни тормый, коммунист башың белән шул карарны үтәмәгән өчен син партиядән чыгарылырга тиеш. Син үз сүзле, колхозчылар алдында ялган дәрәҗә яуларга тырышасың. Барып чыкмас, без сиңа чара күрербез,—диделәр.—Белмәгән башың белән Үзәк Комитет карарына ревизия ясарга сиңа кем кушты?"—дип тә өстәделәр. Мин, хаклыгымны әйтеп: "Үзәк Комитетта безнең Кышлау авылы янындагы җирнең структурасын, сөрү тирәнлеген белсәләр, андагы акыллы кешеләр сөрү катлавын без сөргәнчә сөрергә кушарлар иде",—дип тә ычкындырдым. Бюродан чыккач МТС директоры Ишниязов Ибраһим абый: "Ну, энем, чын кеше икәнсең, МТС тракторы эшләгән эш булгач, миңа бирәр хәл булыр инде дип, бик куркып торган идем,—дип аркамнан какты.—Синең сүзең хак, үз фикереңне яклый беләсең, үзең белән эшләүчеләрне дә яклый, саклый беләсең",—диде.

Ул вакытта күп кенә ялгыш эшләрне колхоз рәисләренә, МТС директорларына сылтау гадәте бар иде. Ике елдан соң, инде сөрү җирләрен бозып бетергәч, Татарстанның төньяк, Кама алды районнарына тирән сөрүне туктатырга, диделәр. Шул ялгышны төзәтү, ягъни бер сантиметр калынлыкта

гумус булдыру өчен ун еллык эш кирәклеге хакында зур-зур мәкаләләр язылды. Безнең колхозлар да сөрү катлавын дүрт-биш сантиметрга тирәнәйткән иде. Тирәнәйтүне, тирес кертмичә, ашламасыз зур мәйданнарда башкару кыйммәткә төште.

Бервакыт илдә төрле-төрле машиналар күбәю сәбәпле көпчәкләр житми башлады. Шул кыенлыктан чыгу өчен колхозларга күк-сагыз чәчү планнары житкерелде. Аның жирен тигезләү өчен капка зурлыгында рамнар ясау кирәк иде. Ул да зур мәшәкать тудырды. Күп кенә техниканы үзгәртергә туры килде.

Бер, Мәжитов дигән галим кантар ваттыру жайланмасы тәкъдим итте. Республикада аңа зур бәһа биреп, заводлардан шуны күпләп ясаттылар, тагын бер-ике елдан ул яраксыз коралга әйләнде.

Ә бер елны Комбайн агрегатларына төрле чүпрәкләр астылар да, герметизация дигән исем куштылар. Алардан коелган орлыкны алып бушаткан комбайнчыны гына мин күрә алмадым. Уракка чыкканчы комбайнны яхшылап ремонтлап, орлык ага торган тишекләрен бетерсәң, комбайнга бер төрле чүпрәкләр дә, алъяпкычлар да кирәк түгел. Комиссия килә дә, чүпрәкләрне саный. Әгәр алар 32 гә житмәсә, нык кына тәнкыйтькә эләгәсең. Юкса, республиканың авыл хужалыгы министрлыгы аша ул кимчелекне заводка язып та бетертергә булыр иде.

Бервакыт, колхозларның финанс хәлен яхшыртабыз дип житен игүне тәкъдим иттеләр. Житен орлыгы кайтардылар, чәчтек, үстердек. Ә житеннән орлыкны ничек алырга—аптырадык! Шуннан, хатын-кызларны жыйнап, житенне тактага салып, тәпәчләр белән кыйнап-сугып алдык. Ул эш бик үрчемсез булды.

Аннан, мин эшләү дәверендә өч мәртәбә көнбагыш чәчү планы житкерелде. Чәчтек, уңышка ирешә алмадык. Чөнки аның орлыгы бездә өлгереп житә алмый. Бездә өлгерү вакыты кыска. Көнбагыш бездә силоска салу өчен яшел масса хәлендә генә файдаланыла ала. Аннан тары, турнепс, фасоль, кабак кебек культуралар да тәкъдим итеп карадылар. Алар да безнең шартларда яхшы уңыш бирә алмады.

Терлекчелектә исә мин эшләгән чордагы яңалыкларны, үзгәрешләрне санап бетерерлек түгел. Алар арасында файдасыз, югарыдан көчләп тагылганнары да күп булды. Колхозлашудан соң, хужалыклардан жыеп берләштерелгән бозау, тана, сыерлар холмогор нәселле үгезләр ярдәмендә шул нәселгә әйләндерелде. Шулай итеп районыбыз колхозларында да холмогор токымлы сыерлар асрауга күчтеләр. Кайбер районнарда швед һәм бистуж токымнары белән токым яхшыртылды. Шул тәртиптә яшәп ятканда, югарыдан кара-чуар урыс токымына күчәргә куштылар. Аннан голштино-фриз токымына, аннан чит илләрдән алтынга алмашкан тагын ниндидер токымнарга күчү башланды. Хәзер сыер терлекчелегендә бер төрле дә чиста токым юк дияргә була. Чит илләрдән таналар, үгезләр кайтарту буенча колхозларга план төшерү, сыерларны ясалма орлыкландыру башланды. Шуңа ышанып, яхшы гына үгезләрне иткә тапшыртып бетерделәр. Ясалма орлыкландыручыларның белемнәре, тәжрибәләре житмәү аркасында, орлыклана алмыйча кысыр калган сыерлар да күп булды. Нәсел эшен бутап бетердек. Сыерлар орлыклана алмагач, кысыр калмасын өчен, нәселе билгеле булмаган яшь буын үгезләр белән каплатылды.

Сарыклар, дуңгызлар белән дә шундый ук хәл булды. Омсктан кайтартылган тәкәләр тояк авырулы булып, бу авыру бөтен районга таралды. Сарык мескеннәр, аяклары авыртудан мүкәләп йөрделәр. Колхозларга кыйммәт бәягә авыру тәкәләр саткан өчен нәсел оешмаларына бу эшләре өчен бер төрле дә чара күрелмәде. Колхозларның сарык үрчетүе, игътибарсызлык аркасында, файдасыз тармак булып калды. Сарыкларны симерткәндә алар, авыру сәбәпле, ашый-симерә алмадылар, колхозга зур зарар китерделәр, ит йөкләмәсен үтәүгә комачаулык иттеләр.

Югарыдан кушу аркасында татар-мөселман халкын дуңгыз асрарга мәжбүр иттеләр. Безнең колхозга да Казаннан бер ата, ике ана дуңгыз кайтты. Аларны карарга-тәрбияләргә кешеләр таба алмый жәфаландык, кешеләр дуңгызны урамда йөртмәде, көтүгә дә жибәрмәделәр. Алар хәзер татар авылларында бетә бара.

Бер заман мәҗбүри рәвештә каз, үрдәк, тавык асрау планы житкерелеп, аларны да колхозларга өләшеп йөрделәр. Жылы торак һәм башка унайлы шартлар булмау сәбәпле, болар да үлеп бетте. Үрдәкләр өчен махсус сулыклар кирәк, алар бездәге салкын сулыкларда яши алмый. Хәзер Венгриядәгечә казлар асрый башлаган фермалар бар, ул казларның мамыгы бик йомшак һәм күп була икән. Менә алар үзләрен аклый алырмы?

Заман узу белән, куян бик файдалы дип, колхозларда куян фермалары оештырдылар, куян үстерү планнары житкерелде. Куян асрау мәктәп балаларына мәҗбүри куелды. Аны үрчетүнең файдасы турында республикада зур жыелыш үткәрелде. Казанда өлкә комитетының беренче секретаре Семен Игънатьев куянның хужалыкка файдалы булуы турында махсус сөйләде: күп балалый, ите диетик, аз ашый, калдык-постыклар белән дә туенып тора ала. Аннан, Арча районы "Северный" совхозының куян фермасында семинар үткәрелеп, анда бәрәнге боламыгы өстенә куян ите салып ашаттылар. Семинар эчтәлекле булды. Нәкыйп Сафин аны яхшы оештырган иде. Берничә ел үтү белән бу жәфалы эштән—балалар да, колхозчылар да котылды. Ул куяннарны асрау өчен күпме такта, тимер челтәр, савыт-саба, ризык, ветеринар, зоотехник, төзелеш остасы да кирәк бит!

Мин рәис булып эшләгән чорда сыерларны бәйдә тотып асрарга куштылар. Ул вакытта терлек аз, тораклар да юк иде. Сугыштан соң, фермалар үсә төшкәч, хайваннар иркен яшәргә тиешләр, дип, сыерларны бәйләми асрарга боердылар. Зур-зур торакларда шул ысул белән асрый башладык. Ризык житмәү аркасында бу ысул үзен акламады. Сыерларның усалраклары күп ашый, юашраклар ач кала булып чыкты. Торакларны янә дә бәйләп асрауга яраклаштырдык. Шулай итеп, мин эшләгән илле елга якын вакыт эчендә ике мәртәбә бәйсез, өч мәртәбә бәйле ысулга күчеп, һәммәсендә дә торакларны яраклаштырып, үзгәртеп жафаландык.

Колхоз житәкчеләренең эш ысулына гомер буе яңалык кертәбез дип сөйләделәр. Фактта, колхозлар төзелгән чорда кертелгән тәртиптән ерак китеп булмады. Фермерлар булдыру, бригадаларны комплекслау, бригадалар арасындагы икътисадны чеклар белән ныгыту, подряд тәртипләре кертү һәм башкалар һәм башкалар... Боларны берсе дә авыл хужалыгын үстерүгә үзгәреш кертә алмады.

## Районның яңадан төзелү тарихы

Әтнә совхоз-техникумы директоры булып эшләп, Хәкимов Габделәхәт совхозда авыл хужалыгы продукцияләре житештерү буенча күзгә күренерлек, телгә алып сөйләрлек үсешкә иреште, совхоз эшчеләренең көнкүрешен яхшыртуга нык игътибар итте. Совхоз-техникум эшчеләре, тырышлыгын искә алып, аны Татарстан Югары Советына депутатлыкка кандидат итеп күрсәттеләр. Көннәрдән бер көнне, 1990 елда, үзен депутатлыкка кандидат итеп күрсәткәннән соң, бу иптәш минем яныма килде. Бераз дулкынлануы да, сөенгәнлеге дә сизелеп тора. Чыннан да, синә буйсынып эшләүче кешеләр, эшчәнлегеңне танып, зурлап, сине депутатлыкка кандидат итеп күрсәткәч, житәкче өчен иң зур хөрмәт шул инде!

Исәнләштек, күрештек. Мин аны депутатлыкка тәкъдим ителүе белән котладым.

Габделәхәт әйтте: "Фәйзи абый, синең янга бер бик зур үтенеч белән килгән идем,—диде.—Күреп, торасың, тырышып эшләдем инде. Минем эшчәнлегемне синнән дә күбрәк белүче юк. Депутатлыкка кандидат итеп күрсәтелүем уңае белән, сайлаучылар алдында ышанычлым була алмассыз микән?"

Ризалыгымны бирдем. Ул яшь, үсә торган кеше, ярдәм сорый икән, нигә каршы килергә? Гомумән, мин кешеләрнең үтенеч белән килүләренә жаваплы карый идем. Үзем Татарстан АССР һәм СССР Югары Советы депутаты булып торган чорда бик күп сайлаучылар үтенеч белән килделәр. Ярдәм итә алганда канәгатьләнү кичерә идем.

Мин беләм, депутат булып сайланачак кешенең киләчәктәге эшчәнлеге

өчен ышанычлысы булып йөргән кеше җаваплы булачак.

Ярый, хуш, авылларга сайлаучылар белән очрашуга чыгып киттек. Әтнә округыннан депутатлыкка өч кандидат күрсәтелгән иде. Берсе—Хәкимов, икенчесе—Түбән Аты авыл советы рәисе, өченчесе—Бәрәскә фермасында сыер савучы. Өчесе дә хезмәтләре буенча депутатлыкка лаек кандидатлар. Бу ике иптәшнең ышанычлылары да үзләренең кандидатлары турында бик ышандырырлык итеп сөйләделәр. Мин үзем булган авылларда депутатлыкка кандидат хакында кыска һәм аңлаешлырак итеп сөйләргә тырыштым. Күп авылларда зур-зур наказлар бирделәр. Шуларның иң әһәмиятлесе хакында ачыклабрак язарга уйлыйм. Бу очрашулар Әтнә төбәгендә яшәгән авылларның киләчәк тормышларын үзгәртүгә юл тотылган беренче һәм чын адым булып калды. Әтнәдә булган, авыллардан килгән вәкилләр, депутатлыкка кандидат белән очрашканда, бик матур һәм актив чыгышлар ясады. Бу инде сайлауларга якынаю көннәрендә иде. Бер очрашу җыелышында Арчадан ерак булган, элекке Әтнә районына кергән авыллар һәм колхозларга карата хәзерге район җитәкчеләренең игътибары җитеп бетмәве тәнкыйтьләнде. Районга хөкүмәт тарафыннан җибәрелгән акча һәм төзелеш материаллары Арча район үзәген ныгытуга күбрәк тотыла дип кат-кат әйттеләр. Чыннан да, ул елларда Арча әйләнәсендә яңа поселоклар үсеп чыкты. Шул чорда Әтнә ягында, бигрәк тә Әтнә авылында төзелеш эшләре бөтенләй булмады. Утыз елга якын Арча белән берләшеп яшәгән чорда бер километр да юл төзелмәү турында сүз булды. Элек гөрләп торган Әтнә хастаханәсе биналары искерде, авыруларга шартларның Арча хастаханәсенә караганда түбән булуын да әйттеләр. Сәүдә эшенең дә канәгатьләнерлек булмавы искә алынды. Гомумән, нәтиҗә ясап, депутат булып кайсы кандидат сайланса да, бу тигезсезлекне бетерү өчен бердәнбер ышанычлы чара—Әтнә районын яңадан кайтару булып чыкты. Югары оешмалар алдында эш кузгатырга һәм шуңа ирешкәнчегә кадәр эш йөртергә, дигән наказ теркәлде. Ниһаять, сайлау көннәре килеп җитте. Сайлаулар авылларда оешкан төстә, тәртипле үтте. Депутат итеп Әтнә совхоз-техникумы директоры Хәкимов Габделәхәт Гыйлемхан улы сайланды. Шуннан соң, без, депутат белән икәүләп, озаклап сөйләшеп утырдык. Тәҗрибәләремнән чыгып, аңа киңәшләремне бирдем. Төп сүз районны Әтнәгә кайтару турында барды. 1990 елның июнь аенда, көннәрдән бер көнне, ул безнең колхоз идарәсенә килеп керде. "Фәйзи абый, сайлаучылар белән очрашканда, наказ итеп әйтелгән сүзләр, миңа бер дә тынгылык бирми. Әтнә районын кайтару буенча нишләп карыйбыз? Бу эшне башласак, ничек булыр, син ничек уйлыйсың?"—диде. Бу фикерне мин күптән көткән идем. Габделәхәт Гыйлемханович минем янга килгәнче үк совхоз-техникум, Әтнәдәге оешма җитәкчеләре белән сөйләшкән булган. Барлык фикерләрне берләштереп, эшне нәрсәдә башларга икәнне ачыкладык. Беренче эш итеп районны Әтнәгә кайтару буенча комиссия төзелде, Әтнә авылы кешеләренә һәм элекке Әтнә районына караган авылларда яшәүче кешеләргә мөрәҗәгать хаты язылды. Бу хат белән барлык авылларга вәкилләр таралды. Алар колхоз, совхоз, авыл советы җитәкчеләре белән сөйләшеп чыктылар. Һәр авылда кешеләрнең йортларына кереп йөрү өчен авыл активы оештырылды, имзалар җыелды. Авылдагы җитәкчеләр бик оешканлык күрсәттеләр. Идарә үзәге итеп совхоз-техникум конторасы билгеләнде. Моңа кадәр бу комиссиянең беренче утырышы Әтнә хастаханәсендә узган иде. Авыллардан уңай җаваплар, имзалар килгәннән соң, комиссия белән җитәкчелек итүне совхоз-техникум директоры Хәкимов Габделәхәткә тапшырдык. Авыллардан килгән ризалык кәгазьләреннән билгеле булганча, элекке Әтнә районына кергән Яңа Кишет, Иске Кишет, Кышкар, Симетбаш, Яңа Мәнгәр, Кушлавыч авылларыннан башка авыллар Әтнә районына керүләрен расладЫ.

Комиссия әгъзаларына үзләренең үтенече һәм республика чакыруы буенча берничә мәртәбә Казанга барырга туры килде. Истә калсын өчен, шуларның икесен язарга кирәк дип саныйм. Беренчесе, хәл иткәне, партия өлкә комитетының беренче секретарена хатыбызны алып барып, аның белән сөйләшү булды. Бу очрашуга кадәр хатның бер нөсхәсе өлкә комитеты секретарена тапшырылган иде инде.

Җәйнең матур бер көнендә җыйналып, өлкә комитетына барырга тиешле кешеләрне барладык. Алар түбәндәгеләр иде: Совхоз-техникум директоры

Хәкимов Габделәхәт, техникумның уку-укыту бүлеге мөдире Шакиров Зөфәр, "Игенче" колхозы рәисе Сәмигуллин Әдһәм, "Чулпан" колхозы рәисе Сабиров Наил, Әтнә сельхозтехника житәкчесе Хисмәтуллин Наил, Югары Бәрәскә авыл советы рәисе Әхмәтжанова Люция һәм мин—"Искра" колхозы житәкчесе Галиев Фәйзи. Кичтән очрашканда Габделәхәт Гыйлемханович: "Фәйзи абый, Казанда сөйләшү буенча бөтен ышаныч сездә инде,—диде.—Чөнки сез республика житәкчеләре белән күптәннән таныш, күп аралашкан кеше. Депутат булып йөргәндә дә, партия өлкә комитеты члены булганда да аларга йомышыгыз күп төшкәндер. Ә без, комиссия членнары, кирәк булганда булышырбыз, безгә карата сораулар булса, җавап бирербез",—диде.

Мин риза булдым. Шулай да бу төнне күңелем тыныч булмады. Йокы алмый алжыттты. Аз гына черем итеп алам да, уянып китәм, өлкә комитетына баргач әйтәсе сүзләремне барлыйм. Бу эш белән йөрүебезнең хаклыгына ышандыра торган фактлар, төгәл сүзләр эзләп маташам. Таң ату белән фикерләремне туплап, ишегалдында йөреп кердем. Кичтән килешү буенча иртәнге сәгать 7 гә Казанга барып житәргә тиеш идек. Әтнәгә чыгып китү өчен иртәнге 5 нче яртыга капка төбенә машина килеп житте. Мине йөртүче шофер Рафис төгәллеге белән ышандырган кеше. Шуңа күрә аны гел ихтирам иттем. Озак еллар минем белән эшләп, бер вакытта да әйткән вакыттан соңга да калмады, иртәрәк килеп, капка төбендә сигнал биреп тә тормады. Шулай итеп, кузгалып китү белән юлыбыздан бер ак эт аркылы чыкты. Ырымнарга ышана торган гадәтем бар. Эчтән генә уйлап куйдым: юлыбыз уңар, шөкер... Юллыкка эт очраса, юлым уңа торган иде. Ә мәнә мәче очраганны яратмадым.



*Фәйзи Галиев Әтнә районы хакимият башлыгы Габделәхәт Хакимов белән.*

Җәй иртәсе бик хозур: җылы, кояшлы, саф һава. Авылларны узганда, кешеләрнең көтү чыгарган вакытларына туры килдек. Күңелемнән нәтиҗә ясап бардым: Казанга якынайган саен көтүләр соңгарак калып чыга! Безнең авыл көтүе Биектау авыллары белән чагыштырганда ике сәгатькә алданрак чыга икән. Безнең булачак Әтнә районы кешеләре чын игенчеләр дип уйлап куйдым мин. Алар эшне иртәрәк башларга яраталар, район булгач та районыбызның йөзенә кызыллык китермәсләр...

Ниһаять, Казанга житеп, өлкә комитеты бинасы янына туктадык. Әле Казан урамнарында хәрәкәт сизелми. Без, өлкә комитет секретареның эше

күплегенә ышанган кешеләр, аның янына беренче кереп булмасмы дигән максат белән барган идек. Бераз көтәргә туры килде. Сәгать 8 нче яртыларда аппарат кешеләре килә башлады. Иң элек, өлкә комитетының оештыру бүлеге мөдире Низамов Халәф күренде. Ул шунда ук безнең ни өчен килүебезне аңлады. Чөнки хатыбызның бер нөсхәсе моннан берничә көн элек аларга житкерелгән иде. Бераздан, әкрен генә атлап, безгә таба өлкә комитетының беренче секретаре Шәймиев Минтимер Шәрип улы килгәне күренде. Мин читтәрәк тора идем, Габделәхәт Гыйлемханович әкрен генә этеп, алгарак чыгарга өндәде. Ул арада Минтимер Шәрипович безнең янга килеп тә житте. Минем белән кул биреп күреште, аннары башкаларыбыз белән дә күрешеп чыкты. Безнең килү сәбәбе аның өчен дә ачык иде. Барыбызны да өлкә комитеты секретаренең көтеп тору бүлмәсенә кертеп утыртты. Үзе эш бүлмәсенә кереп китте. "Сезне бераздан чакырырлар",—диде. Без утырып торганда алгы бүлмәгә өлкә комитетының җаваплы кешеләре: республика Министрлар Советы рәисе, төрле министрлар җыйнала башлады. Ярты сәгать тә үтмәгәндер, утырышлар бүлмәсенә чакырдылар. Зал тып-тын иде. Бу эшне тикшерүгә республика житәкчеләре зур әһәмият бирәләр, күрәсең. Аз гына вакыт эчендә барлык министрлар да җыйналды бит! Минтимер Шәрипович үзенә хас әкрен, иплe тавыш белән без язган хатны укып чыкты.

— Фикерегезне туплагыз, шушы мәсьәлә буенча сезне бирегә җыярга булдык,—диде.

Безнең коллективка карап кемнәр килгәнлеген сорап чыкты. Мин таныштырдым. Шуннан бу мәсьәләне күтәрүебезнең сәбәпләрен сорады. Мин депутатка наказ биргән сайлаучыларның теләген, гомумән, безнең төбәктә яшәүчеләрнең фикерләрен әйтеп чыктым: Район үзәгеннән ерак булу, район житәкчеләре белән колхозчыларның аралары салкыная бару, халыкның фикер уртаклашудан мәхрүм булуын сөйләдем. Мин сөйләгәннән соң, Шәймиев комиссия әгъзаларының кайберләреннән аерым мәсьәләләр турында сорашты, министрлар белән киңәште. Чакырылган кешеләрнең берсе, яңа район төзелгәч, күп кенә акча тотарга туры киләчәк, ә ул хәзерге вакытта авыр мәсьәлә, диде. Мин: "Безнең район өчен артык күп штат кирәкми, Арча район оешмаларын кыскарту хисабына хезмәт хакын түләргә була",—дидем. Комиссия әгъзаларының башкалары да үтенечебезне канәгатьләндерүне сорадылар.

Партия өлкә комитетының беренче секретаре монда чакырылган барлык житәкчеләргә Әтнәләр күтәргән эшне үз тармаклары буенча өйрәнеп, киләчәктә Министрлар Советына фикерләрен җиткерүне тапшырды.

Әтнәгә аерым район булып бүленеп чыгарга рөхсәт ителсә, яңадан берничә район бу мәсьәләне күтәрәчәк. Андый сүз дә булды. Бу безгә шик салды. Финанс ягына бәйле булу барлык эшнең нигезе булып тора икән, дигән фикергә дә ышанырга туры килде. Дөрестән дә, үз районыбызны булдыруда төп эш акчага кайтып кала иде. Беренче мәртәбә зур житәкчеләр дәрәҗәсендә бу эшне күтәрү шушы баруыбыздан башланды.

Өлкә комитетыннан чыккач шигебез кимеде. "Бу эш белән бүтән йөрмәгез",—дип әйтеп чыгаруларыннан курка идек, киләчәктә эшне җентекләп өйрәнергә кушылганнан соң, яңадан төрле дәрәҗәдәге житәкчеләр белән очрашырга кирәклеге аңлашылды. Шул фикер белән делегация шәһәр оешмаларында булган төрле йомышларын хәл итү өчен таралды.

Мин Мөндеш, Мокшы авылларын газлаштырып бетерү бурычы белән газ оешмаларына киттем. Кирәкле мәсьәләләрне уңай хәл иттек. Димәк, миңа очраган эт бу юлы да уңайга булып чыкты.

Авылга кайту белән тармак житәкчеләре комиссиянең Казандагы очрашуы ничек булганын белергә дип көтеп утыра иде. Алар да мәсьәләнең уңай хәл ителүен теләп гөрләшеп алдылар. Шул арада районны кабат кайтару буенча күңелсез хәбәр ишетелүен дә әйттеләр. Күршебез Муса Җәлил исемендәге колхоз әгъзалары: "Без кабат төзеләчәк Әтнә районын якламыйбыз, Арча районында калабыз!"—дигәннәр. Бу хәбәр минем өчен көтелмәгән яңалык булды. Идарәдәге иптәшләр белән шул мәсьәлә буенча шактый озак сөйләшеп утырдык. Бу авыл алай уйларга тиеш түгел иде. Сөйләшү өчен бер вәкил җибәрергә дип киңәш кордык. Вәкил аларга түбәндәгеләрне аңлатырга тиеш: беренчедән, кешеләрнең көнкүреше өчен кирәкле булган күп кенә эшләр Әтнә районына керәчәк Күнгәр авылына бәйле. Балалар Күнгәр

мәктәбендә укый, аларга шартлар тудырырга, интернатта тәрбияләргә кирәк булачак. Икенчедән, кешеләрнен сәламәтлеген саклау буенча Күнгәр хастаханәсенә мөрәҗәгать итми кая барасың? Өченчедән, сәүдә эше буенча кибетләре Күнгәр сельпосыннан файдалана бит... Дүртенчедән, кешеләрне пешкән яна икмәк белән тәэмин итү әлеге дә баягы "Искра" пекарние аркылы эшләнә. Бишенчедән, хуҗалыкларны газлаштыру "Искра" колхозының Тукай-Кырлайдан ук килгән газ торбалары аша планлаштырыла ич. Әгәр алар аерылып калсалар, рөхсәт итәбезме әле, юкмы! Вәкил итеп кемне җибәрү турында да килештек. РТС житәкчесе Хисмәтуллин Наил барып сөйләшкәннән сон, безгә анлатып бирүче булмады шул, дип унайсыз хәлдә калган болар. Шунда ук Әтнә районында калырга ризалыкларын биреп, хатка кул куеп җибәргәннәр. Чыннан да, Муса Җәлил исемендәге колхоз Әтнә ягында калырга риза булмаса, аның аргы ягындагы "Правда", "Тан" колхозлары да аерылып калырга мөмкин ләбаса! Бу эшнен унай хәл ителүе, киләчәктәге эшләребезнен янадан да ышанычлырак башкарылуына юл ачты.

Аяныч, элеккеге Әтнә районына кергән Кушлавыч һәм Иске Җөлби авыллары ("Тукай" колхозы) Әтнә районына керми калды. Сәбәбенен зурысы— бу колхозның рәисе Арча районында туып үскән, шуннан бирегә килеп эшли иде, ул Арча ягында калуны хуплады. Кызганыч, Әтнәдән 8 километр гына ераклыкта булып, Арчага 20 километр булса да, кешеләргә район белән аралашырга ераграк булу исәпкә алынмады. Ә Кышкар, Симетбаш, Иске Кишет, Яна Кишет авылларының Әтнә ягына күчү теләге булмауны Әтнә юлларының начар булуы сәбәпчедер дип уйларга кала. Арча ягыннан Тукай-Кырлай авылына кадәр асфальт юл килгәнлектән, бу авыллар өчен дүрт-биш километрга юл күтәреп, асфальт юлга чыгу, әлбәттә, унай иде. Шунын өстенә, районны бүлү хәбәре чыкканнан сон, югарыда искә алынган колхозларга Арчадан автобуслар йөртә башладылар. Шулай итеп, Әтнә ягының юлсызлыгы гомер-гомергә Әтнә ягындагы авылларның аерылып калуына сәбәп булды. Заманында мәдрәсәсе белән дан тоткан Кышкар авылы да калды. Ә бит Кышкар мәдрәсәсе тирә-як авылларга укымышлы муллалар әзерләп биргән. Бу авыл әйләнә-тирәдәге авыллар арасында, гомумән, Әтнә районына кергән авыллар арасында мәгърифәт үзәге булып саналган. Шул авылның читтә калуы күнелсезрәк булып чыкты. Ә Кушлавычны әйтеп тә торасы юк. Ул Әтнә районында булса, районыбызның иң мәртәбәле авылы булган булыр иде.

Районыбызның барлык авыллары республика оешмаларының Әтнә районын төзү хакындагы унай карашларын көтеп яшәде. Әтнәгә республика оешмаларыннан кешеләр килеп, булачак районны өйрәнә башладылар. Район оешмаларыннан райком, райбашкарма, аларның бүлекләре, суд, прокуратура, милиция органнары, гомумән, район өчен кирәк булган барлык оешмаларның урыннары кайда булырга мөмкинлеге өйрәнелде. Кайсы авыллар керәсе, аларның җир мәйданы, халык саны, милләте хакында мәгълүматлар тупланды. Хәзер соңгы хөкем — район буламы, юкмы, шул хәбәрне көтү генә калды.

Ниһаять, Министрлар Советыннан Әтнә делегациясен чакырып хәбәр килде. Янадан без, башта искә алган комиссия, Казанга киттек. Министрлар Советы бинасына килеп кергәч, үзебез белән очрашачак кешеләрне күреп сөйләшә башладык. Болар арасында республикабызның барлык оешмаларыннан да кешеләр бар иде. Министрлар, аларның кайбер ярдәмчеләре, бүлек мөдирләре катнашты. Министрлар Советының бу утырышын министрлар советы рәисенен беренче урынбасары Хәсәнов Мансур алып барды. Аның алдында шактый гына калын папка ята. Ул папканы ачып куйган. Бу папкада район оештырылганнан сон анда булачак оешмаларны төзү өчен нәрсәләр кирәк, бигрәк тә күпме акча кирәклеге язылган. Мансур Хәсәнович бик зур түгәллек һәм сабырлык белән бу кәгазьләрне язган министрлыкларның җаваплы кешеләрен тынлап чыкты. Вакыты-вакыты белән теге папка эчендәге кәгазьләрне укып, җавап тотучыларга сораулар биргәләп, мәсьәләгә ачыклык кертә барды. Сөйләүчеләр, район булган тәкъдирдә, үзләре тарафыннан нинди эшләр эшләргә кирәклеген аңлатып чыктылар.

Бу иптәшләр сөйләп бетергәч, утырышны алып баручы Мансур Хәсәнов: "Сезнең нинди фикерләрегез бар?"—дип, безгә мөрәҗәгать итте. Миңа сүз алып сөйли башларга туры килде. Кешеләрнен үтенечендә игътибар белән

карау бик әһәмиятле эш икәнлегенә тукталдым, республика җитәкчеләренең эшчәнлегенә уңай бәя биреп, рәхмәт әйттем. Шуннан соң бу эшнең иң авыр ягы булган акчага кагылышлы мәсьәләләр буенча өлкә комитеты секретаре бүлмәсендә әйткән сүзләремне кабатлап чыктым. "Зур Арча районы оешмаларының өчтән берен кыскарту бәрабәренә безнең районда штатлар булдыра алабыз. Аннан соң сельхозтехника, сельхозхимия оешмалары, банк, саклык кассасы, май заводы, халыкка көнкүреш хезмәте күрсәтү белән шөгыльләнүче оешмаларның Әтнәгә урнашкан филиаллары безгә җитә, шуңа без риза.Сәүдә оешмаларына килгәндә, бу районга кирәчәк авыллардагы сәүдә челтәре безне канәгатьләндерә,"—дидем.

Минем сүземне яклап иң элек Сәмигуллин Әдһәм чыкты. Район оешмалары тарафыннан бүленә торган хуҗалык кирәк-яраклары, техника, төзелеш әйберләре, дәүләт ярдәме аз булу—болар барысы да кешеләрне Әтнә төбәгендә мөстәкыйль район булуны сорарга мәҗбүр иттеләр диде ул. Хисмәтуллин Наил райондагы төзелеш эшләренең сүлпән баруын әйтеп, янә безнең фикерләрне яклады. Совхоз-техникум директоры Хәкимов Габделәхәт югарыда сөйләгән вәкилләрнең фикерен йомгаклап, бу киңәшмәдә катнашучы иптәшләрнең безне яклауларын үтенде.

Мансур Хәсәнов барлык фикерләрне тыңлап бетергәннән соң, йомгак ясап, бу эшне киләчәктә тагын да тирәнрәк өйрәнү өчен яңадан бер комиссия төзергә кирәклеген әйтте. Зал беразга тынды. Без, делегатлар, бер-беребезгә карашып, аптырап калдык. Җыелыш таралып китмәгәе дип, тиз генә сүз сорап, мин яңадан торып бастым. "Янә бер комиссия төзү эше белән шөгыльләнеп вакыт үткәрүне без урынсыз дип саныйбыз. Моннан да зуррак, дәрәҗәлерәк комиссия республикада була алмый торгандыр. Бу комиссиянең дәрәҗәсен төшерү кирәк түгел",—дидем. Шуннан Мансур Хәсәнов: "Сез, Фәйзи Әхмәтович, бу мәсьәләне бик тиз чишүне таләп итәсез, алай ашыгып кына эшли торган эш түгел ул",—диде.

Шушы сүзләрдән соң яңадан комиссия төзү фикере кабатланмады. Киләчәктә әлеге комиссиядә катнашкан кешеләр, урыннарга барып, барлык ваклыкларны өйрәнеп, Министрлар Советына өстәмәләр язып бирсеннәр, дигән фикер белән бу эш туктатылды.

Мансур Хәсәновның Югары Советка, Министрлар Советы исеменнән, Әтнә районын төзергә тәкъдим итәбез, дигән карар чыгармавында хаклык та булуын ахырдан аңладым. Бу хәтле җаваплы эшне хәл итүдә Татарстан Министрлар Советы рәисе Сабиров Мөхәммәт Галләмович катнашмавы сәбәп булгандыр. Әтнәдә район кирәк, дигән нәтиҗәне әйтү җыелышны алып баручыга зур җаваплылыкны өстенә алу булыр иде. Комиссиядә бит бу эшне яклап бетермәүчеләр дә бар иде. Кайберәүләре, тәкъдимнәрен әйтмичә, район төзелсә, нинди оешмалар булуын гына санап чыкты. Аларны да исәпкә алмыйча булмагандыр. Шулай да Мансур Хәсәнов Әтнәдә район оештыруны яклап, партия өлкә комитетына һәм Министрлар Советына уңай фикерен әйткән. Аның фатыйхасы Әтнәдә кабат район оештыруда зур ярдәм булды. Соңыннан, аның белән очрашкан вакытларда, бу вакыйгаларны искә алып сөйләшкәләдек. Минем бу иптәшкә карата фикерем бик уңай, аның эшлеклелегенә һәрвакыт сокланып яшәдем. Ул зур җыелышларда артык сүз кыстырмыйча кирәкле фикер генә әйтеп, төгәл сөйли торган иде.

Югарыда сөйләгән вакыйгалардан соң, Арча районында урып-җыю эшләренә керешелде. Игеннәр әйбәт үскән иде, ул эшләр уңышлы гына тәмамланды. Без һаман да Арча районы колхозлары булып яшәүне дәвам иттердек. Иген эшләре беткәч, мин, чираттагы ялга чыгып, Кисловодскига, санаторийга киттем. Көннәрдән бер көнне, октябрь азагында минем исемгә телеграмма килде. Ул телеграмманың эчтәлеге кыска булса да, көтелгән хәбәр иде. Указ чыкты, уңай нәтиҗә белән, диелгән. Минем өчен бу бик зур документ иде. Телеграмманы алгач, күнә буе дулкынланып йөрдем. Шулай итеп, 30 елдан соң, ниһаять, район үз исеменә кайтты. Бу телеграммадан соң минем исемгә яңадан икенче телеграмма килеп төште. Анысында яңа районның партия райкомын оештыру конференциясендә катнашу өчен кайтуым соралган иде. Самолетка билет алып, Казанга очтым.

Конференция үткәрергә өлкә комитетының беренче секретаре Шәймиев Минтимер Шәрипович килгән иде. Ул, залда мине күрү белән, үзе янына

президиумга чакырып алды, кочаклашып көрәште. "Үзең бу эшне башлап йөрдең-йөрдең дә, иң мәшәкатьлесен безгә калдырып, китеп тә баргансың",— дип шаяртты. Ничек ял итүләремне сорашты.

Пленум оештыру эшен тәмамлады. Райкомның беренче секретаре булып Хәкимов Габделәхәт Гыйлемхан улы, икенче секретарь итеп Күнгәр урта мәктәбе директоры Габдуллин Наил Гомәр улын сайладылар. Райком пленумы беткәч, Минтимер Шәрипович безнең киләчәк эшләребездә уңышлар теләп китеп тә барды. Әтнә районын төзүдә безнең фикерләребезне аңлаучы, ярдәм итүче кеше Минтимер Шәрипович Шәймиев булды.

Районның партия оешмасы төзелгәч, шул оешма ярдәме белән район советын оештыру бурычы алга килеп басты. Шул максаттан чыгып, район Советына депутатлар сайлау көне игълан ителде. Сайлаулар оешкан төстә узды. Беренче мәртәбәдән үк барлык округлар буенча депутатлар сайланды. Оештыру сессиясендә район Советының башкарма комитеты рәисе булып Хәкимов Габделәхәт Гыйлемхан улы сайланды. Шул уңай белән райком пленумында Хәкимов Габделәхәт райкомның беренче секретарьлыгыннан азат ителде. Райкомның беренче секретаре булып Габидуллин Наил Гомәр улы сайланды. Районның башка оешмаларын тулыландыру эше шушы ике оешмага йөкләнде. Әкренләп башка оешмалар да торгызылды, җитәкчеләре дә билгеләнде. Район Советының беренче ярдәмчесе итеп Әтнә сельхозтехникасының җитәкчесе булып эшләгән Хисмәтуллин Наил Хәйрулла улы сайланды. Район Советы рәисенең ярдәмчесе булып Әхмәтҗанова Люция Мәгъсум кызы, район план комиссиясе рәисе һәм райбашкарма рәисенең ярдәмчесе булып Габдуллин Фәрит Гәйфулла улы, район авыл хуҗалыгы идарәсе җитәкчесе итеп Моратов Фәрит Гыйният улы билгеләнде. Югарыда исемнәре аталган иптәшләр яңа төзелгән Әтнә районының беренче җитәкчеләре булып тарихка кереп калдылар. Район авыл хуҗалыгы бүлеген, милиция оешмасын, финанс, тәэминат бүлекләрен, прокуратураны, суд аппаратын, райпо оешмасын, почта, саклык кассасы, банк, мәгариф, культура бүлекләрен, медицина өлкәсендәге җитәкчеләре билгеләү һәм аларның алдындагы бурычларны ачыклау буенча күп эш башкарылды. Оешмаларга район кешеләренә хезмәт итү бурычы йөкләнде. Бу тарихы вакыйгаларны оештырып, яңадан районыбызны кайтару өчен төзелгән оештыру комиссиясе бик зур эшләр башкарды. Ул комиссия әгъзаларенең тулы исемлеге түбәндәгечә: 1. Шәрәфиев Зөфәр Шакир улы—техникум завучы 2. Сабирова Флера Абдулла кызы—банк управляющие 3. Гарипов Азат Харис улы—хастаханәнең баш табибы 4. Әхмәтҗанова Люция Мәгъсүм кызы—Бәрәскә авыл Советы рәисе 5. Габдуллин Фәрит Гайфулла улы—техникум хезмәткәре 6. Шакиров Фердинант Шакир улы—Әтнә авыл советы рәисе 7. Хәкимов Габделәхәт Гыйлемхан улы—совхоз-техникум директоры 8. Сәмигуллин Әдһәм Зиннәт улы—"Игенче" колхозы рәисе 9. Сабиров Наил Закир улы—"Чулпан" колхозы рәисе 10. Хисмәтуллин Наил Хәйрулла улы—Әтнә сельхозтехникасы җитәкчесе 11. Галиев Фәйзи Әхмәт улы—"Искра" колхозы рәисе 12. Шәрипов Әхмәт — пенсиядәге укытучы.

## Йомгаклау сүзе

Әтнә районын мөстәкыйль район итеп үзгәртү халык өчен нинди уңайлыклар тудырды, ягъни, ул үзен аклый алдымы соң?—дигән сорау туарга мөмкин. Бу сорауга минем җавап бер генә: ул үзен тулысынча аклады, дип йөрәксенеп әйтә алам.

Җитәкчеләребез халыкка якын килде, бигрәк тә өлкән яшьтәгеләргә. Соңгы елларда пенсионерлар өчен законнар гел үзгәреп тора. Вакыт үтү, законнар үзгәрү белән пенсионерлардан төрле документлар таләп ителә. Аларны аңлатырга кирәк була. Ә пенсионерлар, гариплэр андый йомышлар белән еракка йөри алмыйлар, аларны кеше аша да хәл итеп бетереп булмый. Менә шул мәсьәләләрне хәл итүдә районның якын булуы искиткеч уңай.

Казан шәһәре белән авыллар арасында автобусларның яңа маршрутлары ачылды. Бу аерата шәһәрдә укучы студентлар, Казанда эшләүче яшьләр

өчен унайлы. Алар авылдан азык-төлек алып китә, ялга кайта алалар. Юллар яхшы булмаса, автобуслар күп йөри алмас иде. Шушы дүрт ел эчендә юл төзү буенча да гаҗәп күп эш башкарылды. Юл төзү эшләрендә җир казу, балчык, таш ташу, күперләр салу, су үткәргеч торбалар табу, аларны ташу, урнаштыру кебек исәпсез-хисапсыз эшләр күп. Әлеге эшләрне башкаруда колхоз рәисләре, гади колхозчылар ихлас катнашты. Район җитәкчеләре, төпле план нигезендә, һәр биш көн саен эшнең барышын тикшереп, колхозларга наряд биреп, зур һәм кирәкле эш башкардылар. Кайбер җыелышлар, план үтәлешен тикшерүләр юл өстендә, юл буйларында, таш карьерларында үткәрелде. Кайбер очрашуларда чыбыркылар да шартлады, чәйләр дә эчелде, ачуланышулар да, көлешүләр дә булды. Ни булса да булды, менә дигән юллар төзелде. Хәзер район хакимияте якындагы елларда барлык колхозларның да үзәк авылларын олы юл белән тоташтыру өчен оештыру эшләре алып бара. Юл яхшы булу ул—машиналарны саклау, ягулыкка экономия, шулай ук вакытка да экономия дигән сүз. Юлларның яхшы итеп төзелүе һәр төрле уңайлыклар китерә, колхозларның акчалары исраф ителүне чикли. Районыбыз җитәкчеләренең икенче зур эше авылларны газлаштыру булды.

Авылларда мәчетләр салына. Әтнәнең үзендә дә бик матур мәчет салынды. Инде Бәрәскә, Бәрәзә, Күәм, Әйшияз, Дусым, Күшәр, Ташчишмә, Олы Мәнгәр авылларында мәчетләр ачылып, эшли башлады. Тагын берничә авылда мәчетләр салуга әзерлек бара. Күлле Киме авылында, балаларны сөендереп, яңа урта мәктәп төзелде. Анда Татарстанның халык шагыйре Сибгат Хәким музее эшли. Әтнәдә балалар бакчасы төзелде. Күптән түгел яңа хастаханә ачылды. Шулар өстенә колхозларда терлек тораклары, башка биналар төзелә.

Колхозларда хезмәткә түләү кыен булуга карамастан, авылыбыз кешеләре тырышып эшли. Дөрестән дә, безнең район биләмәләрендә яшәгән татар халкы бик эшчән, тырыш. Мондый халык өчен уңайлыклар тудыру үзе бер рәхәт. Уңайлыклар авыл хуҗалыгы продуктларын җитештерү өлкәсенә әйбәт йогынты ясый. Районыбыз 1994 елда бөртеклеләрнең бер гектарыннан 32 центнер уңыш җыйнап алды. Ә ул 1990 елда 21 центнер гына иде. Үсеш 38 процент булды. Иген уңышы алу буенча республика районнары арасында без өченче урынга күтәрелдек. Бәрәңге, чөгендер, терлек азыклары җитештерү буенча да үсешләр күзгә күренерлек булды. Терлекчелектә сөт җитештерү 1994 елда уртача бер сыерга 4200 килограмм булды, ул сан 1990 елда 3000 килограмм гына иде. Үсеш 40 процент. Мондый чагыштыруны һәр төр продукция буенча да китереп булыр иде.

Районыбыз кабат төзелгәннән соң эшләнгән эшләр шактый мул булса да халыкның көнкүрешен яхшырту буенча эшлисе эшләр күп әле. Ул эшләр район җитәкчелеге тарафыннан өйрәнелә, планнар төзелә. Шул планнарны вакытында үтәп, изге эшебездә барыбызга да уңыш, тазалык-саулык, дөньяга иминлек телим.

*1995*
*Әтнә районы,*
*Түбән Шашы авылы*

## ШИГЪРИЯТ

# САЛИСӘБЕЗ ТУРЫНДА

*Галижәнаб Вакыт агышлары...*

*Каләмдәшем Салисә ханым Гәрәева белән дә инде кырык елга (!) якын аралашам, аның уңышларына шатланып, иҗат серләрен уртаклашып яшим икән ләбаса! Үзе бер гомер, билләһи! Ул очрашулар турында уйласам, Казан университетының татар теле һәм әдәбияты бүлегендә канатланып укып торган еллар күз алдына килә. Салисә бездән бер курс түбәнрәк - Равил Фәйзуллин, Шамил Маннаповлар белән бергә укыды. Хәер, аларның группасыннан бүгенге атаклы галимнәр, милләтнең кирәкле, чын халимнәре чыкканын да искә төшерү урынлы булыр. Әйе, әйе, Рүзәл Йосыпов, Шәриф Асылгәрәев, Флера Баязитова, Фарсель Зыятдинов, Әнвәр Шәрипов, Фирдәвес Гарипова һәм тагын күпләр! Ул еллардагы әдәби, фәнни түгәрәкләр, университетта һәм Тукай клубында узган кичәләр, шигырь турындагы ярсу бәхәсләр, хыяллар... Тагын да шундый чор-мохит әйләнеп кайтыр микән? - дип, юксынып уйлаган чаклар да була. Яшьлекне сагыну бу, һәм шигырьнең киләчәге турында уйлану, бәлки...*

*Менә шул еллар хатирәләре булган фотосурәтләр, шигырьләр, газеталар, төрле төбәкләрдән килгән хатлар, китаплар уйда җанлана. Һәм әлеге шагыйрәнең беренче күргәндәгечә киң елмаю, мөлаемлык, нәкъ җирнең табигый баласына хас наз, ягымлылык белән кушылган ныклык, булганлык кебек сыйфатлары белән һичкемне кабатламаган портретын күзаллыйм. Шигырьләренә бер үзенчәлек биргән Минзәлә ягына хас дымсу-матур тавышын, көлүен төсмерлим... Әмма Тулбай авылы кызының шигъри тавышы туган ягы, Ык, Сөрмәт таулары белән генә чикләнмичә, аны башка тарафларга алып китте! Чиләбе, Урал төбәге, Курган якларына... Нәкъ татарның үз язмышы, читләргә сыендырган борма юллары, моңы кебек димме? Әмма Рәсәйдәге ул тарафлар, җырларыбыздагы Себер кебек үк, төрки-татарның борынгыдан үз җирләре, үз ватаны бит! Әнә шуна күрә дә Салисә иҗатында Урал-Чиләбе яклары бик табигый яңгыраш алды - шагыйрә озак еллар татар шигыренең шул яктагы тулы хокуклы илчесе булды ахры. Географик атамалар, тарихи исемнәр шигырь-җырга әверелде, халыктан алган күңел байлыклары әдәби хәзинәбезгә кушылды, дия алабыз.*

*"Уралым" дип аталган китабы да шуна мисал булды бугай. Кырык елга якын аралашу, дидем. Мин бу елларда Салисәнең Тукай, Җәлилләрнең, замандашлары Илдар, Равилләрнең, барыннан да бигрәк "Казан утлары" журналының ялкынлы пропагандисты булуын да, М. Җәлил исемендәге әдәби берләшмәгә җитәкчелек итүен дә, татарча "Дуслык" газетасын, йөзләрчә кичәләр оештыруын да, радио һәм телевидение тапшырулары редакторы булып эшләвен дә беләм. Үземә дә, башка әдипләргә дә Чиләбедәге мондый кичәләрдә катнашырга туры килгәне бар - болар да инде үткәннән якты хатирәләр хәзер... - шуна да Салисәнең талантлы журналист, оештыручы, тугандаш халыклар дуслыгын олылаучы буларак та*

*эшчәнлегенә баш иясем килде бүген...*

*Әйе, бик озак еллардан соң (һаман шул гомер агышлары!) Салисәбез Казанда яши инде. "Мәдәни җомга" кебек абруйлы газетада мөхәррир ул. Шул ук якты елмаюлы, житез, уңган, аралашырга яратучы, күңеленә бөтен дөньяны алып, аны җылытырга әзер зат. Инде тагын да моңлырак, җитдирәк, димәк, ышандыра торган, тормышчан лирика иясе - армый-талмый эзләнүче, янып яшәүче, "үлән арасында... яшь бытбылдык кебек гүләүче" табигать баласы, чын шагыйрь. Әйе, Тулбай-Минзәлә кызы, әмма татар халкының үзе кебек ук киңлек, таулар, елгалар, серле шигъри тарафлар яраткан нечкә хисләр җырчысы Салисәбез бар безнең!*

*... Шагыйрәнең олуг юбилее уңаеннан туган хисләр бу — аңа сез дә кушылырсыз бәлки, шигырь сөючеләр!*

**Рәдиф ГАТАШ**



# Салисә Гәрәева

## Симфония

**Симфония яңрый урманнардан -**
**күңелләргә тула дәртләре.**
**Кушылып китә шул куәтле моңга**
**каен, чыршы, нарат рәтләре!..**

**Каеннардан җиңел моң тарала,**
**яшьлектәй саф, дәртле, ялкынлы;**
**Ә ерактан килә чыршыларның**
**вәкарь тулы саллы дулкыны...**

**Югарыдан, торна тавышыдай,**
**наратларның килә сагышы;**
**Самими һәм рәхәт, сокландыргыч**
**шул көйләрнең бергә агышы.**

**Тукран куша аңа барабанын,**
**киек кошлар куша сайравын;**
**җилсез көндә әле белеп булмый**
**күлнең нинди тембр сайлавын!**

Төсле музыкадай, тау өстеннән
Ай алкасы калка - сизәмсең?!
... Бергә тыңлыйк
бөек урманнарның,
тауның, күлнең симфониясен!..

## Балам

Газиз балам - җаннан өзелгәнем,
Буй җитсә дә, миңа ул сабый.
Мең кешелек халык арасыннан
Аны күзләр, күңел, җан таный!..

Сүзе тансык, күзләрендә кояш,
Адымында - үткән яшьлегем!
Килер елларыннан бәхет көткән
Кызым белән йөрәк яшь минем!..

Сабырлыгым сыза сагынганда,
Бар хәсрәтем - балам турында.
... Ана булсаң, хәлем аңлар өчен
Куй үзеңне минем урынга!..

## Миләш төймә

Миләш пешкән.
Кызыл тәлгәшләре,
сокландырып, ала күз явын.
Хәтеремдә
сабый бала чакта
миләш төймә тезеп уйнавым...

Мин хәзер дә миләш төймәләрне
һич иренмәс идем тезәргә:
кырау тигән моңсу миләш кебек
килеп кердем үзем көзләргә...

## Алтынкүл

Шушы матур исем яңрап куйса,
Күл турында уйлар кузгала.
Минем кебек син дә гаҗәплән бер:
Күл түгел бу - гүзәл кыз бала!..

- Алтынкүл! - дип дус кызлары дәшә.
- Алтынкүл! - дип, егет чакыра.
Дәшми кызый. Тулпар атын гына
Дала буйлап ары чаптыра...

Казакъ кызы - гүзәл дала кызы:
Дала төне - болыт чәчләре!

- Алтынкүл! - дип мин дә аваз салдым.
Ишетмәде бугай - дәшмәде.

- Алтынкүл! - дип карт әнкәсе дәшә:
- Тулпарыңны җибәр кылганга!
Сөенеп, үзе төпчегенә карый,
Шундый сылу кызы булганга...

... Тышауланган тулпар чирәм кырка,
Кылганнарга ялы тоташкан.
Казакъ кызларының йөзен күрәм
Шул Алтынкүл дигән туташтан.

Көзге дала йөгерек кылганнарга
Иярә дә китә - кышларга.
Алтынкүл дип гүзәл исем йөрткән
Сылу кызны сөйлим дусларга.

## Җиткән кыз ник көрсенә

Көзге төн. Үз ятагында
Буй җиткән кыз көрсенә.
Ник көрсенә? Егетләрнең
Уе бармы берсенә?
Җиткән кыз ник көрсенә?

Йорт түрендә йомшак урын
Уңайлыдыр, җылыдыр.
Нинди хәсрәт-борчулардан
Яшь йөрәге җылыйдыр?
Яшь йөрәк ник җылыйдыр?

Тышта җилләр каеннарның
Биленә сырышканда,
Кара төндә бөтен дөнья
Йокларга тырышканда,
Болытлар тулышканда,

Көзге төндә ятагында
Кыз бала ник көрсенә?
Елап, яңгыр тамчылары
Ни сөйли бер-берсенә?
Җиткән кыз ник көрсенә?..

## Ялгызлык тупсасында

Хатын тынды йокы бүлмәсендә.
Зур бүлмәдә - ире.
Челпәрәмә килде бер мәхәббәт,
Юк, ябышмый кире!..

Йокы бүлмәсендә яшьле күзләр,
Мендәр япмалары.

Ир ягында авыр тынлык йөзә,
Төтен алкалары...

Араларда упкын, Төн һәм Тынлык,
Җимерек күпер сыны.
Күктә янган салкын йолдызларның
Җиргә коела чыңы...

Салкын, моңсыз, буш бер авыр халәт
Ике арада тора.
... Йөрәкләргә Ялгызлыкның каты
Чукмарлары ора...

## Көз

Табигатьнең Көз - иң матур чагы:
Үтә күренмәле иманлек!
Басуларда - салам эскертләре...
Муллыгына җирнең кинәндек!..

Күкләр Җиргә якынайган заман -
Болытлары ага, ишелеп.
Кылган эшләреннән, көчләреннән
Көз... имтихан тота Кешелек!

Җир өстендә, безнең язмышлардан
Калган эзләр кебек чуалып,
Җитмеш якка сукмак-юллар китә, -
Офыкларда кала, югалып...

Аңлашулар, сүзләр, вәгъдә, өннәр
Аермачык була көзләрен;
Сибелеп яткан сары яфраклардан
Күптән көткән хатны эзләдем...

Моңнарым да ачык, үзәк өзгеч, -
Сызылып чыга җилләр көеннән.
... Сары Көзнең чын сурәте булып,
Сары каен суга иелгән...

## Ут һәм су

Шундый чаклар була: тормыш авыр,
Җан яралы, күңел ямансу...
Борынгыдан кеше йөрәгенә
Шифа булган ут һәм агымсу...

Үз-үзенә урын таба алмаса,
Көйсә җаны, кайгы утыннан,
Су буена ялгыз килгән дә ул
Агымсуга карап утырган.

Ялгыз калса хәтәр кайгыларда,
Чит җирләрдә йөрсә, каңгырап, -
Янган утка карап уйланган ул,
Кара төнгә учак яндырып.

... Мин үзем дә кичтем кайгыларны,
Хыянәтнең таттым пычагын.
Агымсуга салдым күз яшьләрен,
Шифа иттем шигырь учагын!..

Ялкыннарым - илгә! Инде беләм
Ялгызыма бик аз кирәген.
Агымсулар итим җырларымны,
Учак булсын җырлы йөрәгем!..

## Сакла җирне

Утыр әле яшел үләннәргә,
ак каенга терәп аркаңны:
тыңлыйк әле сөзәк яр астында
ак ташларга дулкын какканны!..

Тыңлыйк әле эшчән кырмысканың
үлән сабакларын июен;
Ишетәсеңме яшел яфракларның
бер-берсенә нәрсә диюен?!

Бу - Табигать! Тузаны да тере! -
Яшәү дымын илтә терегә.
Бер уйласаң, вөҗдан күтәрәлми
үләннәргә басып йөрергә!..

Җир астында яткан тамырларның
чәбәләнгән очы, дым тартып:
Алар саклый Җирне, язлар саен
яшел Табигатьне яңартып!..

Бала көткән матур, яшь килендәй
безнең бу Җир - сакла, кадерлә! -
Киләчәк тә анда, бүгенге дә,
без ятасы йомшак кабер дә!..

Утыр әле яшел үләннәргә,
ак каенга терәп аркаңны:
тыңлыйк әле җирдә мәңге тере
гомер елгалары акканны.

## Чәчмә әсәрләр

# ГАЛИ БАТЫР ОНЫГЫ

*Ярты халык Галиләрдән тора,*
*Ватанына тугры галиләр.*

Сибгат Хәким
*("Дуга" поэмасыннан)*

Аның турында мин озаклап сөйли дә, күп итеп яза да алыр идем. Шулай булмый ни, без бит аның белән балачактан ук таныш, Алпар урта мәктәбендә бергә укыдык, район гәзитәсенә беренче мәкаләләрне бергәләп язган чаклар да булды. Мәктәпнең җәмәгать эшләрендә актив катнаштык, үзешчәннәр буларак, сәхнәләрдә чыгыш ясый идек, мәктәпнең татар теле һәм әдәбияты, шулай ук тарих укытучысы Хасиб абый Рахманов җитәкләгән әдәбият түгәрәгенә бик яратып йөрдек...

Әмма ни хикмәт, Әсрар Гали дигән төптән таза бу дустыбыз ул елларда күбрәк спорт белән кызыксына, бигрәк тә татарча көрәшү һәм гер күтәрү белән мәш килә иде. Дөрес, ул татар әдәбиятыннан язма эшләрне дә һәркем сокланырлык итеп башкара, табигать кочагына, Чирмешән буйларына чыккан вакытларда кычкырып җырлап җибәрә, йә булмаса үзеннән чыгарып, әллә нинди мажаралы хикәятләр сөйләп, безне таң калдыра иде. Ул аларны күп вакыт рифмалы нәсер итеп, көйләбрәк тә сөйли торган иде.

— Нигә боларны кәгазьгә төшермисең, гәзитәгә язмыйсың?—дип сораучыларга Әсрар:

— Проза бит ул шигырь генә түгел, проза әсәрләре язу өчен бик күп белергә, башта дөнья күрергә кирәк. Мин соңрак, өлкәнәя төшкәч, яза башлаячакмын...—дип кенә куя иде.

Балачактан язмаса да, ул чыннан да әнә шул зур эшкә—әдәби иҗат эшенә җитди әзерләнгән, күп укыган, күпне күрергә тырышкан, туган ягыбыз кешеләрен, аның кер тимәгән саф-чиста табигатен яратудан туган хисләрен җанына сеңдергән икән. Болар өстенә, әле ана сабан туйлары мәйданыннан әдәби-иҗат мәйданына атлаганчы мәктәпне тәмамлаганнан соң, Хәрби диңгез флотында хезмәт итәргә, аннан Лениногорски каласына кайтып, нефтьче булып эшләргә, Прокопьевск якларына китеп,шахталарга төшәргә, күмер чабарга, читтән торып, Казан дәүләт университетының татар теле һәм әдәбияты бүлеген тәмамларга кирәк булган икән. Ягъни, әгәр шулай әйтергә яраса, рухи биографиясенең тормыш биографиясе белән баетылуы кирәк булган. Моның өчен Ходай биргән сәләттән тыш, бик күп тырышлык, көч, максатка омтылучан үҗәтлек кирәклеген минем классташым яшьтән үк аңлагандыр, күрәсең.

Ә тырышлык, үҗәтлек дигәнең анарда—яшьли ятим калган фронтовик улында җитәрлек иде ул. Туган авылы Биктимердән егерме чакрымлап араны кайта-китә дигәндәй Алпарда уку, җәйге каникул вакытларында авыл тимерчелегендә авыр чүкеч белән тимер кыйнау, ишле гаиләне карауда әнисенең беренче булышчысы булу, шулар өстенә туктаусыз спорт белән шөгыльләнү әнә шушы үҗәтлек дәрәҗәсендәге тырышлык галәмәте түгелмени?! Ул вакытларда авылдашлары аның турында ярым шаяртып: "Әсрар йоклаганда да икешәр потлы ике герне баш астына салып йоклый"...—диләр иде. Әмма бу шаяртуда хаклык зур иде.

Хәтердә әле, 1957 елның февраль аенда әдәбият-сәнгать, спорт һ.б. буенча яшьләрнең башта районнарда, аннары республика күләмендәге фестивальләре шаулап узды. Үзебезнең Әлки районы фестивалендә безнең мәктәптән дә дистәгә якын укучы катнашты. Кем шигырь сөйләү, кем җыр, кем бию белән. Хәтерлим, аны

шигырь белән ачып җибәрергә миңа сүз биргәннәр иде. Төп темамнан аз гына читкәрәк китеп булса да, ошбу фестивальгә дип махсус әзерләгән әлеге шигыремне тулысынча язып китүдән тыелып калалмыйм. Соңыннан район гәзитәсендә басылып чыккан әлеге шигырь минем кулдан төзегән "беренче китабымда" саклана.

### Безнең фестиваль

*Яшь йөрәкләр хисләр дулавыннан*
*Күкрәкләргә дөп-дөп бәргәнгә,*
*Санга сукмый кышның буранын да,*
*Җырлый-җырлый киилдек бәйрәмгә.*

*Баштук әйтим әле:*
*Дуслар, безне*
*Гаепләми генә карарсыз,*
*Чөнки биючеңең бии-бии*
*Ботинкасы калган табансыз.*

*Җәл түгел лә ансы бер ботинка*
*Өйрәнгәндә шундый һөнәргә.*
*Зур сәнгатькә югалтусыз гына*
*Чыгалмыйдыр инде бераү дә...*

*Бәлкем, киләчәктә радиодан шаулар*
*Бүген җырлаячак чибәр кыз.*
*Шулчак исегезгә алырсыз да:*
*"Шул кыз микән чынлап?"—диярсез.*

*Үземнең дә әле хыялым бар,*
*Шундый бәхет тиздән килерме:*
*Халкым, төшермичә кулларыннан,*
*Кайчан укыр минем шигырьне...*

*Матур хыял—тормыш шатлыгы ул,*
*Үтәлүе булса ихтимал.*
*Үтәләсен аның шаһит булып,*
*Билгеләсен безнең фестиваль.*

Әй, бу яшьлек, әй, бу яшьлекнең үз-үзенә ышанган канатлы романтикасы! Әсрар Гали дә әлеге фестивальдә герләр белән жонглерларча чыгыш ясап, беренчелекне алачакмын, дип бик ышанып барган иде. Ләкин, герләр юк, дип, аның номерларын төшереп калдырдылар. Ул анда җырлау белән генә чикләнергә мәҗбүр булды. Әбераздан, менә кәмит, район комсомол оешмасы секретареның герләр белән чыгыш ясаячагын белдерделәр.

Әсрар фестивальне оештыру комиссиясе рәисенә мөрәҗәгать итте: "Бу нинди гаделсезлек: комсомол житәкчесенә герләр бар,ә миңа—юк!.." "Ул үз герләре белән чыгыш ясый бит",—дигән җаваптан соң, Әсрар фестивальнең йомгаклау концертына котомкага салып, Биктимердән, өч-дүрт чакрымнан җәяүләп, үз герләрен алып килде. Шунда да аны сәхнәгә чыгармаска маташтылар. Ул хаклык даулап, партия райкомына кадәр барып житсә-житте, барыбер үз дигәнен итте. Көндәшен уздырып, беренчелекне яулады, шул номерлары белән республика фестивалендә катнашу хокукына ия булды.

Герләрне балалар тубыдай чөеп уйнаган егет, район сабан туйлары батыры Әсрар Гали Әдәбият дигән олуг Мәйданга да "Батырга—батыр" исемле әсәре белән аяк атлады. Сабан туе күренешләрен, бигрәк тә аның татар керәшен тасвирлаган, халкыбызның матур гореф-гадәтләрен, хезмәт сөючәнлеген, эчке горурлыгын сурәтләгән әлеге хикәя әдәбиятыбызга районыбыздан чыккан Фәхри Әсгать (ул да Әлки төбәгеннән—Алпардан) рухындагы лирик пландагы прозаик киләсен хәбәр итте сыман. Бу вакытта Әсрар Лениногорскида татарча чыга башлаган "Ильич васыятьләре" гәзитәсе каршындагы язучы Шамил абый Бикчурин житәкләгән әдәби-ижат берләшмәсенең

актив әгъзасы иде инде. "Чишмәләр" дип исемләнгән әлеге остаханә заманында бик күп яшь талантларга әдәбият вә сәнгать мәйданына чыгарга ярдәм итте. Гомумән, алтмышынчы-җитмешенче елларда районнардагы әдәби-иҗат берләшмәләре нәтиҗәле эшли, анда катнашучылар үз иҗатлары белән өлкә гәзитәләрендә, журналларында да еш кына күренәләр иде. Соңгы елларда бу күркәм эш сүлпәнләнеп калды шикелле. Ул елларда Казандагы югары уку йортлары да, "Татарстан яшьләре" редакциясе дә, Горький музее да, хәтта кайбер завод гәзитәсе редакцияләре дә үзләренең әдәби түгәрәкләре, әдәбият-сәнгать берләшмәләре белән горурлана ала иде. Бу күркәм традицияне хәзер дә югалтмаска, аларга яңа сулыш бирергә иде бит, әй! Хәлбуки, әдәбият вә сәнгатебезнең чишмә башлары чыганаклары әнә шушы "Чишмәләрдә" ләбаса инде. Заманында Гали Хуҗи, Гариф Ахунов, Әдип Маликов, Шамил Рәкыйпов, Равил Фәйзуллин, Илдар Юзеев, Разил Вәлиев, Рахмай Хисмәтуллин, Шамил Бикчурин кебек фидакарьләрнең әдәби алмаш үстерүдәге күркәм эшләрен дәвам иттерү зарур.

Әлеге "Чишмәләр" әдәби берләшмәсенә Шамил Бикчуриннан соң Әсрар Галинең шактый вакыт җитәкчелек иткәнен дә хәтерлим әле. Лениногорски төбәгендәге әдәбият-сәнгать әһелләре өчен Шамил Бикчурин исемендәге премия булдырылгач, бу бүләкнең беренчеләрдән булып Әсрар Галигә бирелүе дә тикмәгә түгелдер. Биредә, аның иҗаты белән бергә, Шамил абый юл салган "Чишмәләр"не корытмыйча карап-тәрбияләп торуын да исәпкә алганнардыр дип уйлыйм.

Иҗатына килгәндә, соңгы елларда сәламәтлеге нык какшауга, өстәвенә күзләре дә бик начар күрүгә карамастан, Әсрар Гали туктаусыз яза, яза, яза. Гүяки ул авылда мөгаллимлек итеп, нефть чыгарып, шахтада күмер кисеп уздырган елларының әҗерен кайтарырга ашыга. Аның повесть, хикәяләр, нәсерләр, парчаларын эченә алган "Төнге җыр" (1980) исемле беренче китабыннан соң, "Асыл кошым минем" һәм "Көн яктысы" исемле күләмле җыентыклары дөнья күрде. Гәзитә-журналларда очерк вә хикәяләре басыла тора. Хәзерге вакытта ул җиң сызганып, кайчандыр үзе көрәшеп алган чуклы сөлге белән башын ураган хәлдә, калын пыялалы күзлеге аша геройларын барлый-барлый, "Гали батыр" исемле күләмле автобиографик әсәр иҗат итү белән мәшгуль. "Минем әле өйрәнгән тормыш материалларым бу томнарга гына сыешмый, әле шул рухта дәвам итәргә исәп..."—ди ул үзе. Иҗатта ул авыру-сырхауларын да, көн яктысыннан мәхрүм булып яшәвен дә оныта. Ана ничек тә рухы, акылы аша кичергәннәрен әдәби образлар, халыкчан сәнгать чаралары ярдәмендә үз укучыларына тапшырырга, шуңа өлгерергә кирәк!

Кыска гына бу мәкаләмдә мин язучының сюжет кору, вакыйгаларны, образларны тасвирлауда тормыш һәм сәнгать дәреслегенә ни дәрәҗәдә ирешә алу кебек иҗат алымнарына тукталмадым. Бусы—тәнкыйтьчеләребез эшедер. Бу җәһәттән шунысын әйтми булмый: башка шактый каләмдәшләре шикелле үк, Әсрар Гали дә үз иҗатына карата әлегәчә җитди әдәби тәнкыйть сүзен ишеткәне юк. Ә бит зур дәрьяга чыккан дингезчегә юнәлешне дөрес билгеләү өчен компас ничек кирәк булса, иҗат әһелләре өчен дә гадел тәнкыйть сүзе шундый ук әһәмияткә ия.

Шулай да, Гали батыр оныгының җилкәнен күтәргән иҗат "көймәсе" әдәбият дингезендә мең төрле кыенлыклар, җил-давыллар белән көрәшә-көрәшә, алга барырга тырыша. Элеккеге сабан туйлары батырының әдәби-иҗат дигән олуг мәйданда да сынатмаячагына ышанычым зур.

## Соңгы сүз

Шушы язмамны әзерләп, журналга тапшырырга торганда Лениногорски шәһәреннән кайгылы хәбәр килде: язучы, Татарстан Язучылар берлеге әгъзасы, элеккеге Сабан туйлары батыры Әсрар Галинең тынгысыз йөрәге 13 август көнне тибүдән туктаган!..

Ни үкенеч, аңа үзенең 60 яшен, иҗат бәйрәмен күрергә насыйп булмаган икән. Әле аның киләчәккә иҗади хыяллары да зурдан иде. Аһ, нишлисең, Әҗәл мәрхәмәтсез, ул берни белән дә хисаплашып тормый шул...

Инде Татарстан Язучылар берлеге идарәсенең "Ватаным Татарстан" гәзитәсендә басылып чыккан матәм белдерүендәге сүзләрне кабатлап әйтүдән башка чара юк:

"Кешегә, туган илебезгә, аның чын батырларына дан җырлаган язучы Әсрар Әбрар улы Галиев дөнья кинлеген, кояшлы, айлы зәңгәр күкне, җирдә булган бар шатлык-хәсрәтләрне, мәшәкатьләрне калдырып китте... Рухы Галәм кинлекләренә кушылды...

Бәхил бул, кадерле каләмдәш!

Авыр туфрагың җиңел булсын.

Халкың, дусларың, каләмдәшләрең күңелендә син үзеңнең якты әсәрләрең аша мәнге яшәрсең..."

Әсрар Әбрар улы Галиев булган барлык уңай һәм кимчелекле-йомшак яклары белән үзенчәлекле вә кабатланмас шәхес иде. Ул дөньяны, кешеләрне үзенчә итеп күрергә теләде, иҗаты белән дә, кылган гамәлләре белән дә шуна омтылып яшәде. Ни генә булмасын, аның күңеле—изгелектә, нияте яхшылыкта иде... Шушы сыйфатлары аның "Лаеш шулпасы" дигән хикәясендә дә ачык чагыла. Әсрар Гали бу әсәрен "Казан утлары" журналына үзенең ноябрь аенда булачак юбилее уңаеннан җибәргән иде.

Хөрмәтле укучыбыз, без бу әсәрне сезгә тәкъдим итәбез.

**Шамил МАННАПОВ**



# Әсрар Гали

## ЛАЕШ ШУЛПАСЫ

хикәя

Әсләм шахтадан кайтканның икенче елы иде бу. Лаеш районының Таушырмә авылына укытучы булып эшкә билгеләнде. Үзе икенче курста университетта укый иде. Алдан ук кисәтеп куйды аны роно мөдире:

— Директор булачак кешең—Намат Хәйриев,—диде.—Колхоз малае. Армиядә булмаган. Урысчасы ипи-тозлык кына. Бер кулы гарип. Шушы районныкы үзе. Алабугада читтән торып институт бетергән. Менә шул... Калганын эшли-эшли танышырсыз...

Әсләм турыдан-туры Намат Каштановичның өенә килеп керде. Юан, зур корсаклы кеше икән Намат дигәннәре. Тәскә-биткә ямьсез үк түгел үзе. Бер кулын чалбар кесәсенә тыккан. Кесәсе бик тирән иде күрәсең, ул кулы терсәгенә хәтле чумган. Ағай да, кара ситса перчаткасының бөрмәсе терсәк читендә күренеп калган. Әһә, гарип кулын шулай яшерә икән бу. Күрештеләр.

— Әсләм.

Намат әхлакый кагыйдәнең иң элементар бу өлешен дә белми икән. Аның исем әйткәнен ишетмәгән дә кебек сорау бирде:

— Роно мөдире минем турыда әйткәндер инде...

— Берни әйтмәде,—диде Әсләм.—Ул миңа менә шул приказ кәгазен бирде. Сезгә күрсәтергә кушты. Теләсәң алырсың, теләмәсәң үзеңә кара.

Алар шактый озак сөйләштеләр. Бер көтү предметлар бирде директор. Химия, физика. Тагын кечкеләргә тарих, әдәбият, җәмгыять белеме. Көндезләргә әле физкультура, җыр, сызым дәресләре дә бирәсе бар икән. Бер көн эшкә бармасаң, ярты мәктәп укымаячак. Предметлар исеме күп булса да, сәгатьләр саны аз иде. Димәк, акчасы булмаячак. Айга сиксән сум тиясе икән. Шахтада алган аванстан да кырык сумга кимрәк иде бу.

Әсләм шулай эшләп китте. Фатиры тыныч булырга ошый. Бер анасы да бер кызы гына.

... Әсләмгә хатыныннан хәбәр килде. "Балалар белән бөтенләйгә синең янга кайтам",— дигән. Алар аерылышкан иде. Инде нишләргә?! Таушрмәдә татар мәктәбе. Әсләмнең кызы исә беренче сыйныфта урысча укый иде. Монда яшәп, кызны күрше урыс авылы Тамгачыга көз-яз, кышкы суыкта йөртәсе килми.

Әсләм Тамгачыдан ашыгыч рәвештә эзләп, бер буш өй сөйләште. Зур түгәрәк күл каршында гына. Иске йорт. Бакча, йорт тирәсе тотмаган. Эше күп әле монын. Кышлыкка әзерлисе. Утын китертәсе. Бу авыллар тирәсендә урман юк. Ялтыраган су гына. Кама елгасы агып уза.

Октябрь башында ук Әсләм гаиләсен Казан поездына барып каршылады. Тамгачыга кайттылар. Ул, кызын, улын шулкадәр сагынган, бер минутка да аерыласы килми. Шуны күрә торып та, хатыны малайны Әлкигә кайтарып куйды. Үз әниләренә. Янәсе, эшкә керә, малай ялгызы өйдә тора алмый, имеш. Әсләм дәшмәде. Хатыны белән бәхәсләшүнең файдасыз икәнен ул инде белә иде.

Малайны әниләренә илтеп куюын-куйды хатыны, ләкин үзенең кара эшкә бер дә керәсе килми. Сыер саварга фермада урын бар югыйсә. Анда бармый. Таушрмәнең яңа клубы ачылуын көтә. Анда мөдир булырга исәбе. Ул клуб исә язга гына ачылачак. Шуны көтеп утыр инде менә.

... Ул заманда Совет авыллары эченне пошырырлык итеп бер ноктага үзәкләшкән иде. Кама елгасынын уң ягындагы авыллар "Коминтерн" совхозына берләшкән. Тормыш әсәре үзәктә генә. Калган татар авыллары онытыла, аларда тормыш учагы акрынлап сүнә бара иде. Әсләм укыткан Таушрмә авылы да совхоз партоешмасына карый, ә ул исә Рождествинода иде.

Партия җыелышына бару үзе бер әҗәл. Җәяү барып житешле түгел. Мәктәп атын Намат Хәйриев үзе барганда гына җиктерә. Анда да, мәктәп завучы Мәгъсүм Фаруковичны утыртмаска чамалый. Завуч исә, гаять тәрбияле, итәгатьле, чын мөгаллим кеше. Рус телен укыта. Әсләм белән тиз арада уртак тел табып, дуслашып киттеләр. Ә директор белән завучның коймагы пешми икән. Бервакыт, җыелыштан кайтканда, юл өстендәге бер авылга кереп, аракы эчеп алгач, завучка бәйләнеп, сугышып китә яздылар. Атта, чанада килеш.

Әсләм түзеп тора алмады, директорга тавыш күтәрде:

— Чанадан бәрәм дә төшерәм!—диде ул тешләрен шыкырдатып.

Шул вакыйгадан соң, завуч Намат белән бергә утырып җыелышка йөрмәс булды. Тизәккә тимә, сасысы дөньяга таралыр, дигән әйтемне уйлап булса кирәк, Мәгъсүм Фарукович моны үзе эшләде.

Ни генә әйтмә, ул вакыйга да, укытучылар арасында таралып, телдә йөрде. Әсләмне баштагы ике айда ук яратып өлгергән укытучылар, бу хәлдән соң ачыктан-ачык, Намат Каштанович күз алдында, мәктәптәге һәр эшне Әсләм белән киңәшеп башкаралар. Укучы балалар, алардан күрмә ата-аналар да Наматка түгел, Әсләмгә мөрәҗәгать итәләр. Моңа Наматның эче кытыклана. Ләкин, сиздерми әле. Сәбәбе юк.

Ләкин сәбәбен таптылар. Итәк астыннан ут йөртүчеләр оятсыз була икән. Әсләм, батыр егет булгач, аның белән болай уен-муен уйнаучылар юк иде. Үз калебе саф булгач, ул бөтен кешегә дә сабыйларча ышана иде. Әйткән идем ич, Әсләм мәктәпкә иртә китә, төнлә генә кайта. Менә шуны бик оста файдаландылар Намат Хәйриев белән

башлангыч класс укытучысы Мурдия Камбалиева. Әсләмнең хатыны чиктән тыш көнче иде. Моны ишетеп бәләләр иде инде. Имештер, Әсләм мәктәптә соңламый, фәлән-фәлән кызлар белән типтереп йөри, янәсе. Шундый коткы тараттылар. Бу аның хатынына җитә калды. Өйдә җәнҗал купты.

Әсләм мәктәпнең профсоюз оешмасы рәисе иде. Яңа ел алдыннан Намат Каштанович белән икәү Казанга бардылар. Мәктәп балаларына кием-салым, бүләкләр алыр өчен. Шунда исе китте Әсләмнең. Кибеттән әйберләр сатып ала да Намат, кибетчегә өч-биш сум акча төртә, аннары счет бәясен арттырып язган печатьле язу ала. Әсләмнең сизүен белгәч: "Дугадан да туры булсаң, үзеңә кыеңга туры килер. Ашасы-эчәсе, юлда кайтасы бар. Акча кирәгер..."—диде директор, күз кысып. Күрәсең, болай да баеп була икән.

Наматның кибет саен балалар акчасын чәлдерүен Әсләм күреп торды. Бар акча аның кулында. Теләсә нишли. Шуңа да Әсләм боек, грузчик булып, тик аңа ияреп йөрде. Аракы алды Намат Хәйриев. Ашханәгә кереп ашадылар, эчтеләр. Анда да аш акчасын Әсләм үзе түләде.

Үзе буе ике капчыкны Әсләм күтәреп, алар машина юлына чыктылар. Тырышып-тырышып та Намат ни машина, ни автобус, ни такси туктата алмый иде. Моның шәлперәйгән кыяфәтеннән җирәнеп Әсләм:

— Капчыклар янына килеп бас, үзем туктатам,—диде.

Әсләм алга килүче таксига елмаеп кул күтәрүе булды, шофер машинасын аның тезенә үк тери язып шып туктады.

— Кая?

— Таушырмәгә хәтле...

— Рождествинога кадәр илтәм.

— Утырабыз...

Әсләм җәһәт кенә капчыкларны алып килде.

— Кырык сум!—диде шофер, алар утыргач.

— Була ул,—диде Намат,—барып җиткәч түләрбез.

Киттеләр. Рождествинода шофер машинасын туктатты.

— Килеп җиттек!—диде. Үзе Наматка карады. Акчаны ул вәгъдә итте ич. Акча аңарда.

Намат исә шофер янындагы утыргычтан ишекне ачып җиргә үк төште. Рәхмәт әйтү дә юк. Шофер әйтте аңа:

— Бушка түгел бит,—диде.—Бу бит такси...

— Мин туктатмадым!—диде Намат, күзен дә йоммыйча. Нишләсен Әсләм, тавыш чыгарып, аның белән сугышып булмый бит инде. Кесәсендәге сиксән сум акчасының яртысын шоферга сузды.

— Рәхмәт!—диде шофер Әсләмгә. Аннары, урысчалап, сүгенеп, Наматка йодрык селекте.—Син булмасаң, мин бу баеңа күрмәгәнен күрсәтә идем инде... Әшәке җан...

Әсләмдә Наматның кешелексезлегенә нәфрәт уты чиксез иде. Ике капчыкның авызын бергә бәйләп, җилкәсенә күтәргәч әйтте Наматка:

— Болай, акча корты булгач, һич югы мәктәп балалары өлешенә кергән яртыларыңның берсен шоферга бирер идең, хәйван...

Тегесе дәшмәде. Хәзер караңгы төн. Тамгачыга кадәр биш чакрым. Аннары Таушырмәгә өч километр кайтасы бар. Болар икәү генә. Башка һичкем юк. Дәшсә, Әсләм аның корсагына китереп тибәчәк иде. Тырыша-тырмаша Тамгачыга кайтып җиттеләр. Әсләмнәргә керделәр. Әсләм капчыктагы бер яртыны тартып чыгарды.

— Тагын өч яртың кала әле. Аларын иртәгә эчәрсең,—диде кырыс күз белән карап. Намат хәзер аңа ияреп йөрүче малай хәлендә иде. Директорлыкның эзе дә юк.

Стаканнарны тутырып Әсләм аракы салды. Һәм, голт иттереп бер стаканны эчеп тә куйды. Гомерендә бер, хәтта, шахтада да стаканлап аракы эчкәне юк иде. Бу ни әйтер икән, дип. Наматка ачу итеп.

— А-а, син алкаголикларча эчәсең,—диде Намат.

— Әлкәшләр стаканлап аракы эчми,—диде аңа дөнья күргән Әсләм,—синең кебек кенә, туктый алмыйча әз-әзләп кенә эчәләр...

Әсләм бер тәрилкә аш ашап бетергәндә генә Намат үз стаканын өчкә бүлеп эчеп төпләде. Шешәдә янә бер стакан чамасы аракы калган иде әле.

— Сал!—диде Намат батыраеп. Ул аракыны калдырып китәргә кызганды.

— Юк!—диде Әсләм.—Әлкәш булма. Спортчылар алай эчми. Кунып каласыңмы, әллә?..

— Таушырмәгә кайтыйк. —Намат куна калырга курка иде.

Әсләм капчыкларны күтәреп, аны Таушырмәгә озатып куйды.

Намат юып алгандай айныды. Башында зәһәр уй туды. Әсләм китүгә, йөгереп барып Мурдия Камбалиева тәрәзен шакыды. Эчтән тавыш ишетелде:

— Нәстә, Намат! Аракы кирәкме?

— Ю-у-к, Мурдия апа. Хәзер генә Әсләм кайтып китте. Аның өендә бер стакан аракы калды. Иртән ул аны эчеп баш төзәтәчәк. Мәктәпкә килүгә иснән, бел, аннары аңа бәйлән... Өйрәтәсе юк. Үзең беләсең бу эшне...

— Баш өсте!—дип калды Мурдия.—Әйт кенә...

Чыршы бәйрәме көне иде ул. Әсләм иртүк мәктәпкә килде. Нишләптер бер кырыйга чүмәштерелгән чыршыны зал уртасына куйдырды. Тирәсендә балалар әйләнеп уйнарлык булсын. Ягъни, кешечә...

Укытучылар бүлмәсендә барлык укытучылар иде. Озакламый Мурдия килеп керде. Авызы пешкән кебек, кара иреннәре челт-мелт итә. Жыерчыклы бите тартыша.

— Мәктәптә нибары ярты ел эшли,—диде Мурдия, Әсләмгә таба атлап.—Үзенә өстәл биләп алды. Инде кичә без куйган чыршыны алдырып, үзенчә куйдыртты. Авызыннан аракы исе аңкый...

Дөрес, Әсләм бер өстәл биләгән иде. Профсоюз өстәле. Ләкин аның иртән беркайчан аракы эчкәне юк. Бүген дә эчмәде. Шуның өстенә ул бүген, барлык мәктәп балалары, ата-аналар алдында герләр күтәреп чыгыш ясарга тиеш иде. Аракы эчеп, ничек гер күтәрәсең, ди.

— Мурдия апа!—диде Әсләм әйбәтләп.—Син башлангыч класс укытучысы. Башлангычлар һәр класс елканы аерым үткәрә. Үз классларында. Биш-сигезләр бергә. Монда кысылып йөрмә. Әллә ниләр сөйләнеп. Аракы эчкәнме мин, юкмы, бик кызыксынсаң, бар, фельдшерны алып кил...

— Мин... гомерем буе... өстәлсез,—дип ачыргаланып тотынган иде Мурдия, аны Әсләм шундук кычкырып бүлде. Аның тавышы корычтай нык, янгыравыклы иде.

— Бар, моннан шагом марш!—диде, физкультура дәресендәгечә.

Мурдия ишеккә бәрелә-сугыла, атылып чыгып китте.

— Әсләм абыегыз... типте!—дип укучыларга әләкләве аерым-ачык ишетелә иде.

— Менә, оятсыз, юри гайбәт чәчә!—дип пышылдашты укытучы хатын-кызлар.

Әсләм типсә, черәшкән Мурдия түгел, таза-таза ирләр дә аяк өсте кала алмый. Явыз Мурдия исә, урам буйлап елый-елый өенә кайтып бара иде.

— Әсләм кыйнады. Уф, үләм!..

Аны ишетеп, Сараланның Хасәп Яружин туктады. Ул—Әсләмнәрнең партия оешмасы секретаре. Авыл советы рәисе. Мурдиянең туганы.

— Ни булды, Мурдия апа!—диде Яружин, ишетмәмешкә салышып, янә кабатлатырга теләп.

— Мәктәптә... Әсләм исерек. Якамнан сөйрәп алып, артыма тибеп, ишеккә бәрде. Уф, үләм! Бөтен эчем яна...

Яружин, күзләре акайган килеш, мәктәпкә килеп керде. Әсләмнең

авызына җирәнгеч борынын тыга язып:

— Әчтеңме?—дип үкерде.

— Син үзең исерек!—диде Әсләм аңардан да катырак итеп.—Ник монда кереп, балалар арасында буталып йөрисең?..

— Мурдия апаны кыйнагансың...

— Үзеңнең маңгаеңа берне утыртыйммы, исерек башың айнырлык итеп. Аннары минем йодрыкның ни икәнен белерсең. Өч йөз илле килолы удар ул. Ат типкән кадәре...

Яружинның төсе качты. Тизрәк чыгып таю ягын карады.

— Партҗыелыш... куабыз...—дип мыгырданды ул.

Моны барлык мәктәп балалары ишетеп торды.

Яңа ел кичәсен бик матур үткәрде Әсләм. Балалардан гимнастик, акробатик уеннар уйнатты. Пирамидалар ясатты. Үзе икешәр потлы дүрт гер белән ике сәгатьлек төрле күнегүләр үткәрде. Цирк номерлары күрсәтте. Кырык җиде төрле иде алар. Мондый цирк уеннарын Тауширмә халкы гомердә дә күргәне юк иде. Бер кулда сигез пот гер күтәрде Әсләм. Иң соңында үз өстенә ике ишек куеп, унбер кеше бастырды. Ике кулда, ике аякта гына тора бу йөк. Аннары җыр-бию башланды.

Иртәнге ямьсез күренешләр беразга сүрелгәндәй тоелды. Алай да, йөрәктә сүнмәс яра булып, күңелгә кан сауган иде...

... Тамгачыдагы өй ишегендә йозак иде. Иртәгә Әсләмнең Лаешка утынга барасы. Берсекөнгә Казанга сессиягә китәсе көне. Бу ни хәл бу? Ишекне бикләп, хатынының кая китүе мөмкин?

Өй эче таланган йорт кебек тузылып ята. Хатыны үзенә кирәк әйберләрне төяп киткән иде. Өстәлдә язу калдырган.

"Мин синнән бөтенләйгә аерылам, әниләргә кайтып киттек",—дигән.

Әсләмнең бу беренче генә аерылуы түгел иде. Эче пошса да, күтәрелеп бәрелмәде. Сабыр төбе саф алтын. Икенче көнне мәктәп атын җигеп, көн буе Тауширмәдәге элекке фатирына өй әйберләре, бәрәңге, калган утынны ташыды. Эче поша, йөрәге яна иде.

... Унынчы гыйнварга хәтле ни зачет, ни имтихан бирә алмады Әсләм. Укый үзе. Башында берни калмый. Күңелдә улы, кызы, янә аерылышу зәхмәте. Әрнү. Газап. Үкенү кайгысы гына. Ни хикмәт диген. Унбере көнне бер зачет, бер имтихан бирде. Уникесе көнне янә шулай. Күңел күтәрелеп китте. Бирәм дигән колына, чыгарып куяр юлына, ди бит Ходай. Үзе җан биргәнгә җүн бирде, Аллага шөкер.

... Казаннан кайтканның өченче көнендә үк Әсләмгә хәбәр килде. Партия җыелышы, ди. Мурдия Әсләм өстеннән шикаять язган. Намат Хәйриев белән берләшеп. Шул җыелышта Әсләм эше каралачак икән.

Әсләм Сараланда һичкемне белми иде. Димәк, аны берсе дә якламаячак. Партоешма секретаре Яружин Сараланныкы. Ул ни әйтсә, Саралан коммунистлары шуны сөйләячәк. Ә Тауширмәдән коммунистлар дүртәү генә. Намат, Мәгъсүм Фарукович, Әсләм һәм бүлекчә управляющие Мөҗип Ибниев кенә. Мөҗип бик һәйбәт кеше. Илле яшьләрендә ул. Җыйнак. Буйчан. Төз гәүдә. Йөзендә иман нуры балкый. Авылның сабантуйлары батыры да ул. Бер кызы Әсләм классында укый. Әсләмгә карата бик җылы караштa иде Мөҗип. Боларның икесе Әсләмне яклап та чыгарлар, бәлки. Ләкин, иллегә якын коммунистны ике унай тавыш белән генә Әсләм ягына авыштырып булырмы? Шуңа күрә дә Әсләм җыелышка бармас булды. Җыелыш көнне Сараланнан атлы килде.

— Хәсәп абый Яружин җибәрде,—диде юлаучы.—Сине алып килергә...

Әсләм урынында берәү булса, алдап маташыр иде. Авырыйм, дияр иде. Бәлки, шулай кирәк тә булгандыр ул, Әсләм исә күңелдә ни барын гына ярып сала иде. Хәзер дә:

— Бармыйм!—диде.

— Коммунистлар көтә.

— Мин аларны белмим. Шулай әйт...

Юлаучы китте. Күнелдә юшкын калды.

Икенче көнне Намат Хәйриев мәктәпкә кермәде. Ул, шулай, атналап-атналап мәктәпкә кермичә өендә ята иде. Имеш-мимешләрне ишетте Әсләм. Үзе күрмәгәч ышанмады. Имештер, капланып эчә, аракыдан айный алмыйча шулай ята, ди ул. Мәгъсүм Фарукович әйтте Әсләмгә:

— Бармавын бик яхшы булды,—диде.—Яружин барын да котыртып куйган иде. Синең эшне совхоз парткомы утырышында тикшерергә карар чыгардылар. Наматтан характеристика ал...

— Ул бит әле юк...

— Өенә кер. Алар ул көнне Яружин бүлмәсендә эчәргә калдылар. Махмырдан гына мәктәпкә керми ята Намат.

Әсләм ике дә уйламыйча директорның өенә китте. Намат Каштанович өйдә ялгызы иде. Бу бик яхшы. Сүзне әйләнеп түгел, турыдан башларга була. Өй аракы исенә тынчыган. Наматның эчә-эчә иреннәре яшелләнеп күгәргән иде.

— Миңа характеристика язасыңмы?—диде Әсләм, тегенең иләмсез кыяфәтенә туп-туры карап.

— Юк!

— Ник?

— Мин сине белмим. Әле бездә дүрт ай ярым гына укытасың бит...

— Шулаймы?!—диде Әсләм ачуы килеп. Ләкин, кызмыйча. Үткәрерлек итеп.—Аның каравы мин сине бик яхшы беләм, Намат. Тыңлап тор. Санап күрсәтәм: Минем фатирның күршесен ялган шикаять белән төрмәгә утырттың; үз мәктәбең укытучысы Ләйфәнең ире Тамирны төрмәгә тыктың; балалар акчасын урлап кесәңне тутырдың. Үзем шаһит! Ярты-йорты эшләп, һәркемнән артык акча аласың. Ай саен атналап мәктәпкә аяк та басмыйсың. Аракыга йотыгып... Мәктәп завучы турында гайбәт таратучы син; минем хатынны котыртып аертучылар Мурдия белән син; минем өскә Мурдияне өстерүче син; минем өстән бүгенге пычрак эшләрне оештырып йөрүче дә син.

Башка тискәре эшләреңне санап тормыйм, Намат. Менә, хәзер, шул караватыңнан каерып алып, аякларың матчага тигәнче күтәреп, артың белән идәнгә бер сыласам да мин хаклыдыр, бәлкем. Юк, мин эшләмим моны. Ходай үзе каргасын сине. Чүп белән чүп буласым килми. Ярый, хуш! Кылган гамәлләрең турында үзең уйла!

Һәм Әсләм калын аслы ботинкасы белән идәнгә нык-нык басып, ишекне каты ябып чыгып китте.

... Намат Хәйриев һаман мәктәпкә йөрми иде әле. Беркөн Наматның хатыны үзе туктатты Әсләмне.

— Әсләм, сине Намат өйгә чакыра,—диде, уңайсызланыбрак.

Хатыны Сәринә әйбәт укытучы аның. Һәркем белән кешеләрчә сөйләшә. Зурланмый. Кәпрәйми. Төскә дә матур. Телгә дә йомшак. Аны авылда да, мәктәптә дә хөрмәт итәләр. Иренең нәкъ капма-каршысы бу.

Әсләм чаңгыларын карга кадап, Намат янына керде. Өй аракы сасысына тынчыган иде.

— Һаман исерекме әле син, баш педагог?!—диде Әсләм, юри исәнләшеп тә тормыйча.

Директор кеше үзенең никадәр түбәнгә тәгәрәвен аңлаган иде, ахры, ул елый иде.

— Әсләм абый!—диде мескенләнеп, күз яшьләрен яшермичә. Үзе Әсләмнән ике яшькә олы килеш, аңа: “Абый!” диде.—Мин гарипне кызган... Райкомга да, милициягә дә берни язма... Үз укыту сәгатьләремне дә сиңа бирермен... Уңай характеристика да язармын...

— Кирәкми!—диде Әсләм.—Характеристикаңны муеныңа так...

Намат балалар кебек, әллә исерек җүләрләрчәме, кычкырып-кычкырып, тәгәри-тәгәри елый иде.

— Үтерергә теләмәсәң, мине хастаханәгә озат... Йөрәгем шартлый...

— Кайда?—диде Әсләм.—Столбищегамы, Лаешкамы?

— Рождествинога...

— Хәзер атны җигеп керәм. Киенеп куй...

Әсләм атны җикте. Наматның хатынына әйтте:

— Наматны хастаханәгә илтәбез. Минем белән син дә барасың...

Әсләм толыпка төренгән исерек Наматны балалар кебек кенә күтәреп, чанага чыгарып салды. Сәринә белән Әсләм дә утырып, юлга кузгалдылар.

Толып якасы эченнән борын очы да күренмәгән Намат, әледән-әле башын күтәреп, хатынына:

— Әгәр үлсәм, атны әтигә бир!—дип кабатлый.

Авыл Советы алып биргән мәктәп аты турында шулай ди бу.

Аның исерек тавышы янә дә ишетелмәсен өчен акыллы хатыны дәшми иде.

Наматны хастаханәдә калдырдылар.

... Мәгъсүм Фарукович, мәктәп завучы буларак, Наматның укыту сәгатьләрен: татар теле һәм әдәбиятын, бишенче-сигезенче классларда Әсләмгә бирде.

Намат Каштанович китү белән мәктәпкә җан керде. Сулар һава иркенәйде. Укытучылар элеккечә чыш-пыш сөйләшү түгел, тулы бәйсезлек белән үзләрен мәктәпнең чын хуҗасы итеп тоя башладылар. Мәктәпкә йөреш йөз процентка күтәрелде. Авыру балалар да дәрес калдырмый иде. Балаларны куркыту, дәрестән куып чыгару бетте. Өлгереш күзгә күренеп үсә башлады. Балалар, ата-аналар белән укытучыларның туганлашып эшләве нәтиҗәсе иде бу.

Әсләмнең сәгатьләр саны белән бергә, акчасы артса да, ул файдага булмады. Җәйге укытмый торган айларны, Тамгачыда бергә яшәгән айларда алимент түләмәгән итеп, Әсләмне хатыны Әлки район судына биргән икән. Утыз өч процент урынына, түләнмәгән ул айларны да исәпләп, Әсләмгә бер ел буе илле процент алимент түләргә язу килде. Төп башына янә утырттылар. Әсләм моны исбатлый алса да, суд юлында йөрергә кимсенде.

... Рождествинога партком утырышына Әсләмне бер ай узгач чакырдылар. Урыслар гына. Бүлекчә управляющие Мөҗип тә, совхозның баш агрономы гына татарлар. Әсләмнең учет кенәгәсенә язып, каты шелтә бирделәр. Мурдия Камбалиеваны укытучылар бүлмәсеннән куып чыгарганы өчен, һәм Сараланга партҗыелышка бармаганы өчен бу. Акланунын һични мәгънәсе юк иде. Үз сүзләре сүз. Һәм, Әсләм акланып та тормады.

— Теләсәгез нишләгез,—диде горур гына.

— Партбилетыңны алсак...

— Алыгыз... Аның миңа кирәге булганы да юк.

— Егетне аптыратмагыз,—диде совхоз директоры Романов. Ябык йөзле. Мөлаем кеше.—Ул шахтада партиягә кергән. Егерме өч яшьтә...

Башка сорау бирүче дә, яклаучы да булмады. Мөҗип Ибниевтән кала. Ул яклап сөйләде. Аны исәпкә алмадылар. Тәки, шул, каты шелтәне чәпәп чыгардылар. Учет кенәгәсенә язарга, дип.

... Партком утырышы Әсләмгә каты шелтә ябыштырса да, бу эш әле моның белән генә бетмәгән иде. Лаеш райкомы бюросы расларга тиеш иде бу карарны. Анысы тагын кайчан булыр. Партия органнары, милиция тикшерүчесе кебек, әнә шулай, тымызыклап канын киптерәләр иде кешенең. Коммунистлар партиясе илдә иң зур көч. Тикмәгә генә "райком кушса, керпе өстенә ялангач артың белән утырырсың", дип әйтмәгәннәрдер.

... Лаешка бюро утырышына Әсләм чаңгы белән барды. Столбище аша әйләнеп үтсәң, йөз чакрымнан артык ара ул. Кама бозы өстендәге ак кардан барсаң, илле чакрымнан да артмый. Март башы иде. Кар себерә. Көчле җил. Әсләм чаңгычылар формасы кигән көе, башлыгын да

салмыйча бюро буласы бүлмәгә килеп керде. Бер таныш кеше юк. Ялгыш та. Зур корсаклы тук чырайлы ирләр. Нибары бер хатын-кыз. Шунда берсе әйтеп куйды:

— Бюрога килгәндә әйбәтрәк киенеп киләләр аны!

— Мин сез йокыдан торганчы чаңгыга басып, илле чакрым юл узып килдем, бюродан соң да шул араны үтәсем була. Анда, галстуктан да кара костюмнан йөреп булмый...

Шым булдылар. Аннары, төрле-төрле сораулар яуды. Әлеге дә баягы:

— Партиядән чыгарсак?—дигән сорауны бирде берсе.

— Мин партиягә ихлас ышанып кердем шахтада. Минем арттан иң батыр, иң кыю шахтер егетләр партия сафына бастылар. Инде күрәм: сезнең оешмада алдашу, ялган тамыр җәйгән икән. Шул ук Мурдия Камбалиева, партия оешмасы секретаре Хасәп Яружин, күрсәтмәсе чын ялганга корылган. Анын өчен генә чыгарабыз дисез икән, чыгарыгыз мине партиядән. Ике йөз миллионнан артык кеше билетсыз яши бит әле. Эшләрмен дә, мин дә яшәрмен. Партком карары да, сезнеке дә (әгәр шуны расласагыз), чеп-чи ялган булачак...

— Гаиләсен җайласын. Партком карары белән килешергә! -диде калын тавышлы бердәнбер хатын-кыз. Бюро әгъзалары кул күтәрделәр.

Әсләм кайтып китте. Таушırмәгә җитәрәк караңгы төште. Давыл күтәрелде. Күз ачкысыз буран. Әсләм адашты. Әмма каравыл кычкырмады, җыр сузып җибәрде. Анын җырлавын укучы балалар ерактан ук ишетеп алганнар икән. Әсләм абыйлары авылны читләтеп үтеп баруын чамалап, алар чаңгыга баскан көе этләр һаулатып, Әсләмне каршы алырга чыктылар.

... Иртәгә сигезенче март көне дигән төнне көтелмәгән хәл булды. Хуҗабикә хатын Әсләмгә сарылды. Бүген генә, коедан су алганда кулы ычкынып китеп, чыгыр тоткасына маңгаен бәргән иде. Сукыр күзенең пыяласы ватылган. Ул күз хәзер чеп-чи булып җәрәхәтләнеп тора. Маңгае шешкән. Әсләм аны чын күңелдән кызганып, үзенчә ярдәм иткән иде. Әллә шуны ошатып, янына килеп ятты бит Әсләмнең! Әсләм элек тә бу хатынның үзенә күзләрен майландырып каравын сизә иде. Шулай да бермәл аптырап калды.

— Нәрсә, әллә акылдан яздыңмы?—диде ул урыныннан кубып, аягына басты.

— Беләм-беләм,—ди Хуҗабикә,—син яшь, матур, шуңа күрә дә миңа карыйсың килми.

— Кит, апа! _ диде Әсләм, ачуы килеп.—Булмый. Өмет итмә.

— Ярар-ярар, кил, янында җылынып кына ятам. Кума инде... Әллә миңа матурны яратырга ярамыймы?

Әсләм ут кабызды. Иртәнгәчә ул инде йоклый алмады.

Бүген исә бәйрәм көн. Яңа клубны ачтылар. Анда Әсләм кичен укучы балалар белән чыгыш ясыйсы. Җырлыйсы. Бииcе. Герләр күтәрәсе.

Клубтан соң бер өйдә яшьләр җыены. Бүләкләр алды Әсләм. Яхшы киемнәрен киде...

Моны күреп торган Хуҗабикә котырды. Елый. Чәчен йолка.

— Ничә сарык ите ашатып бетердем,—ди,—миңа якын да килми, яшьләрне эзли!—ди.

Әсләм аны ничек тә тыярга тырышты. Юк, көнләшеп үкерә бу. Һич уйламаганда урам як тәрәзгә ялан кул көе сукты Хуҗабикә. Каршыда таш кибет. Урам тулы ирләр, егетләр. Тамагы ярылганчы кычкыра бу.

— Әсләм үтерә... Коткарыгыз!

Ирләр капкага чабып килә башлады. Әсләм эшнең мөшкел булуын аңлап өлгерде. Йорт ягындагы берәр тәрәз рамын алып куйды. Урамга чыгып сугышсаң, җәмәгать тәртибен бозуга керәчәк. Үз өеңдә килеш, анда күз күрер...

Исерек ирләр йортка тулдылар. Ике уйлар чама юк иде. Җыйнаулашып кулга асылынганчы, Әсләм берсен урам як тәрәзә аша, икенчесен йорт тәрәзәсе аркылы тышка атты. Ләкин, берсенә дә сукмады.

Ирләрнең калганнары кире урамга шылды. Тәрәзәдән очучылар да, торып кагындылар да кибет каршына барып бастылар. Шул арада Хужабикә дә өйдән чыгып качкан иде.

Әсләм тәрәзәләрне куйды. Хужабикә сугып ваткан зур күзгә мендәр тыкты. Аны одеал белән каплады. Ләкин, тынычлана алмады. Күпме вакыт узгандыр, участок милиционеры килеп керде. Әсләмне Лаешка, милиция бүлегенә алып китте.

... Ялгыз камерада дүрт тәүлек ятты Әсләм. Сәгать саен аны сорау алуга йөрттеләр... Бишенче көнне аны икенче катка чакырдылар. Ни күрсен, анда укытучы кызлар... Әсләм аңлады. Болар тикмәгә килмәгән.

Районнан беркая чыгып китмәскә кушып, Әсләмнән имза куйдырдылар да, ябылудан чыгардылар.

— Сезне бу эшкә кем өйрәтте?—диде Әсләм, гаҗәпләнүен яшермичә.

— Мәгъсүм Фарукович,—диделәр кызлар.—“Халыктан имза җыеп милициягә барсагыз, Әсләмне коткарачаклар”,—диде.—Сараланда укучылар, үзебездәге жиде-сигезләр ун йортлыкларга бүлендек тә, биш йөз имза җыйдык. Мурдия белән хужабикән халыкны сиңа каршы котыртып йөрделәр...

Әсләм бу кичне мәктәп күршесендәге Нургазиларга кереп кунды. Нургази—әнисенә бер бала булып үскән егет иде. Тыйнак. Тыныч. Ягымлы. Ул, башта, Әсләм фатиры каршындагы таш кибеттә кибетче иде. Аннары бу эшен ташлап, комбайн ремонтлауга күчте. Өйләнде. Өйләре иркен. Әсләм белән якын дуслар иде. Шул төнне үк әйтте Нургази:

— Бер дә аптырама, Әсләм, үзебездә торырсың,—диде.

— Рәхмәт, дустым! Якын итеп әйтүеңә рәхмәт. Ну, мин сездә торырга дигән өметтә түгел. Күршедәге буш өйгә кертсәң, мин биш куллап риза булыр идем...

— Ялгызыңмы?

— Әйе, ялгызым. Кер юа беләм. Ашарга пешерәм. Мин бит флотта хезмәт иткән кеше.

— Ул йортның ачкычы миндә. Безнең туганнар йорты ул. Үзләре Казанда яши.

— Ачкычын бирсәң, иртәгә мин шунда күченәм дә куям.

Нургази ачкычны Әсләм кулына китереп тоттырды.

— Рәхәтләнеп яшә. Сөт кертербез. Үзебездә ашарсың. Анда, өстәл, караватъ, мендәр, юрган да бар. Бер малае, җәйләрен кайткалап, кунып-кунып киткәли. Өй минем күзәтчелектә. Сиңа ышанып бирәм ачкычны...

Бу фатирга ташынгач та, Әсләм классындагы бер малайның әтисе олы башын кече итеп, үзе өйгә килде.

— Үзебезгә генә күчәргә идең, Әсләм энем!—диде.—Без бит өчәү генә... Ашарга-эчәргә, Аллага шөкер...

— Хәерле булсын инде, абзый,—диде Әсләм.—Инде күчендем.

— Алайса үзебезгә килеп ашап йөрө. Бер тиен акча алмабыз...

— Бик зур рәхмәт сезгә, яхшы сүзегез өчен.

Ул китүгә каршы күрше Тәскирә апа керде. Ул кырык яшьләр тирәсендә, чибәр, кызлар кебек бик сөйкемле зат иде. Авыл яшьләре “Терлекчеләр йорты”нда концерт куйдымы, Тәскирәне сәхнәгә менгерми калмыйлар. Кычкырып. Сорап. Кул чабып. Һәм Тәскирә “Нурия”, “Галиябану” көйләрен үзенчә бер моң белән, бик матур итеп җырлый. Бу мәрхәмәтле ягы бер булса, ул, авылның тилчә телле Мурдия, Әсләмнең хужабикәсе, аларның әшнәләре, Намат, Хасәп ишеләрне акылга утырта белә. Алар, кеше алдында, Тәскирә белән сөйләшүдән уттан курыккан кебек куркалар. Бәбәкләренә бәреп, чын дөресен әйтә ул. Икенче сөйләшмәслек итеп. Ялганчыга юлны шулай яба иде Тәскирә. Бүген ул Әсләмгә кергән менә.

— Безнең авыл ирләре чәй кайнатып та эчә белмиләр. Ялгызын ничек яшәрсең? Безгә генә күчәсең калган. Мин бит, әти-әни белән

яшим. Пешкән аш бер булыр иде. Уку елы бетәргә дә күп түгел. Акча сорамас идек әле...

— Рәхмәт, Тәскирә апа! Без хәзер күршеләр бит. Йомыш төшкәләсә, керми калмам.

— Көн дә кер...

... Беркем уйламаганда, көтмәгәндә, мәктәпкә комиссия килеп төште. Болар арасында берсе, бәйләгән сары кофта кигәне, сипкелле йөзлесе партия райкомы инструкторы, ди.

Иң элек шул сипкелле кыз шикаять хаты укыды. Ямьсез хат. Барлык укытучыларны яманлап язганнар. Тәртип юк, имеш. Балалар бәйдән ычкынды, имеш. Директор барында тәртип иде, янәсе. Хәзер мәктәп Әсләм кулында, имеш. Ул теләсә нишли, имеш, завуч аннан узмый. Мурдия Камбалиева исә иң тәҗрибәле укытучы, янәсе. Әсләм коткысына Мурдия генә бирешми, имеш.

Шикаятьнең астына икенче кеше имзасы куелган булса да, бу чипчиста Мурдия стиле иде. Әсләм моны белеп алды. Башкаларның да башын арындыру өчен иң беренче чыгыш ясау кирәк иде. Әйе, бу, үзенә күрә кыюлык сорый иде. Яшь укытучы кызлар, елый-елый чыгыш ясап та, Мурдия исемен әйтмәячәкләр иде. Анардан барысы да курка-шүрли.

— Рөхсәт итегез!—диде Әсләм, башкалар зиһен туплаганчы, кул күтәреп.

— Сөйләгез!—диде инструктор.

Әсләм үзе белгәннең барын да төкми-чәчми үткәзерлек итеп сөйләде. Мурдия—Намат коткысын да, Мурдия—хуҗабикә, Мурдия—Хасәп Яружин корган капкынны да, Мурдия һәм Наматның теге еллардан алып бүгенгәчә, үзләренә ошамаган укытучыларга үчегүен дә, аларны мәктәптән китәргә мәҗбүр итүләрен дә,—барысын да чыгарып салды Әсләм.

— Бу шикаятьне Мурдия Камбалиева язган!—диде Әсләм, һичкемдә шикләнер урын калдырмыйча.—Шуңа күрә дә, Таушырмә мәктәбенә кара япма япканы өчен, гомерлек гайбәтче Камбалиеваны, мин, бу мәктәптән куарга тәкъдим кертәм...

Әсләмнең бу чыгышыннан соң буа ерылды. Таушырмә укытучылары тирән сулыш алдылар. Иң элек Мәгъсүм Фарукович гайбәтче Мурдияны тетеп чыкты. Аннары барлык башка укытучыларның да телләре чишелде. Барысының да фикере бер: әйтеп төзәлмәс Мурдияны мәктәптән куарга!

Чәчен йолкый-йолкый, Мурдия бик таркау сөйләде. Аның чыгышын берәүнең дә тыңлыйсы килми иде. Косасыны китерә икән, мондый мәгънәсез, кире бәндәнең акланырга тырышуы. Соныннан райком инструкторы торып әйтте:

— Әллә бу уку елын бетергәч, Мурдия Камбалиеваны мәктәптән куарга карар чыгарыйкмы, иптәшләр?—диде.

Шундук әйтте Әсләм:

— Гайбәтчегә йомшаклык күрсәтү була бу. Әлкәш Намат кайтты исә, әшнәсе Мурдияне үз эшендә калдырачак...

Шулай да укытучылар, райком инструкторы фикере белән килештеләр. Теләми генә... Димәк, уку елы беткәч, мәктәптән куарга... Шуңа кул күтәрделәр. Бу инде җиңүнең башы иде. Әсләм эшләп күрсәткәннәр барысы да Таушырмә мәктәбе укытучылары арасында ихлас мөгамәләнең кузгалышы иде.

... Әсләмнең йөрәге бер киерелә, бер кысыла иде. Киерелә: алда—Сабантуйлары. Кысыла: Хуҗабикә эше буенча милициядә "дело" ябылмаган. Ике ут арасында яши ул.

...Язгы ташулар, гөрләвекләр агып узды. Авыл урамнары кипшенде. Анда-санда яшел бәбкә үләннәре борынлады. Шундый ямьле көннәрнең берендә, озын-озын атлап, йәтли-йәтли, Әсләм өенә Мәгъсүм Фарукович килеп керде. Әсләм аны тәрәзәдән күреп, көтеп торды. Нигәдер артык шатлыклы иде ул. Өйгә керүгә Әсләмне кочып алды.

— Сөенче!—диде, матур иреннәрен бар булмышына җәеп. Ак йөзе

алсуланган. Битендәге һәр күзәнәге алтын булып ялтырый иде. Аннары, түбә тактасына тия язган озын чәчле башын артка чөеп, ха-ха-хайлап бер көлде. Янә: "Әсләм, сөенче бит туган!" диде.

— Миңамы?—диде Әсләм һаман аңламыйча. Завуч кулында бер кәгазь шуыта иде. Әсләмгә дигән хатлар мәктәпкә килә иде.

— Сиңа, әлбәттә!

— Хатын килгән дисәң, мондый чакта, бер дә сөенечкә түгел инде ул. Көенеч кенә... Әллә хат бармы?

— Хат шул,—диде завуч.—Прокуратурадан. Хуҗабикәгә бәйле эшеңне иптәшләр судына калдырганнар...

— Ур-р-а!—дип кычкырды Әсләм, үз-үзен белештермичә, хатны да укымыйча. Мәгъсүм Фаруковичны күтәреп алды да, зыр-зыр һавада әйләндерде. Аннары икәүләп көлделәр. Бу хәбәр иң зур шатлык иде. Иптәшләр суды бит ул—котылу дигән сүз. Аның иң зур җәзасы егерме биш сум штраф кына ләбаса!

Икенче көнне иптәшләр суды клубта булды. Монда укытучылар, эшчеләр дә җыелган иде. Хуҗабикә белән Мурдия янәшә, иң алда утыралар. Суд озак бармады. Һәркем үзенекен сөйләде. Ахырдан иптәшләр суды рәисе Мөҗип Ибниев хөкем карарын укыды. Әсләмгә нәкъ биш сумлык штраф бирде. Әсләм шундук штраф акчасын өстәлгә илтеп куйды.

Шуның белән өстән тау төшкәндәй булды. Намат, Мурдия, Хуҗабикә, Яружин нахакка өскә өйгән чүп-чар коелды да бетте сыман. Күңелдә мәңге төзәлмәс әрнүле яра гына калды... Мәктәпкә таба чыгып барганда завучка әйтте Әсләм:

— Мин китәм!—диде.

— Ну-у...

— Шулай әйбәтрәк булыр. Куркып түгел. Җиңеп китәм...

— Уйлаган булгач, үзең беләсеңдер инде. Син акыллы кеше. Ну, китүең җәл...

Лаешка барганчы, Әсләм мәктәп атына атланып, Сараланга элдертте. Анда Әсләм укытырга килгән чакта партоешма секретаре, үзе үк авыл Советы рәисе дә булып эшләгән Исфан Рәпшин бар иде. Аны сентябрьдә эшеннән алдылар. Аның урынында үчле кеше Хасәп Яружин эшли. Исфан исә һаман эшсез, өйдә утыра иде. Ул да, Әсләм кебек, университетның тарих бүлегендә читтән торып укый иде. Өйдә иде Исфан.

— Мин китәм. Минем дәресләрне алып кал, Исфан дус...

Исфан аптырап калды.

— Әйе-әйе, иртәгә Лаешка барам. Эшне өзеп кайтам. Роно мөдиренә әйтермен. Минем урынга Исфан кала, дип...

Аннары гына сүзнең чынлыгына ышанды Исфан.

— Калам дияргә яхшы да түгел кебек. Дус кешенең эштән китүенә сөенгән кебек килеп чыкмасмы бу? Болай, гозерләнеп килгәч, районда риза булсалар, сәгатьләреңне алырмын, Әсләм.

— Миңа шул сүзең генә кирәк иде. Киттем.

— Тукта әле, чәй...

— Юк-юк, мин ашыгам.

Әсләм атын чаптырып, Тауширмәгә юнәлде. Икенче көнне Лаешта иде ул. Туп-туры мөдиренә керде Әсләм. Гаризасын сузды. Мәгъсүм Фарукович язган хатны бирде. Анда, Әсләм урынына Исфан Рәпшинның укытырга килүчәге язылган иде. Мөдир боларны укыгач:

— Быел ук директор итеп куям, Әсләм энем, кал!—диде.

— Минем намусым чиста,—диде Әсләм.—Калсам да курыкмыйм. Ну, андый әшәке кешеләр: Намат, Мурдия, Яружин, хуҗабикә кебек оятсызлар арасында йөз суларым түгеп яшисем килми...

— Мин аларны да, синең хәлләрне дә бик яхшы беләм. Яшәрбез...

— Юк, китәм!—диде Әсләм.

— Райком секретаре белән сөйләшмичә гаризаңа кул куймыйм әле. Әйдә, икенче катка бергә меник...

Алар райком секретаре бүлмәсенә керделәр.

— Таушырмә мәктәбеннән. Әсләм Гаделев! Китәм, ди. Үзен мәктәп директоры итеп калдырырга иде исәп...

— Ә-ә, теге, сайлау кампаниясе вакытында өч сәгатькә якын герләр күтәрә-күтәрә, Лаеш клубы сәхнәсен җимергән егетме әле бу?—диде беренче секретарь Ташбулатов. Чәче коела башлаган. Матур йөз. Аның шахтер икәнлеген Әсләм белә иде. Ул, теге чакта, бюрода юк иде. Булса, Әсләм кайбер сүзләрне ана житкергән дә булыр иде. Бәлки бу хәлләр ел буена сузылмас та иде.—Ник китәргә булдың әле?

— Бер гөнаһсызга кара таплар өскә яккач, ул урында яшисе килми икән, иптәш Ташбулатов. Китәм...

— Кая әле, прокурордан сорыйк әле, китәрсеңме икән?

Ташбулатов аның хәлләрен яхшы белә иде бугай. Әллә прокурор белән куркытмакчымы? Алар телефонда сөйләштеләр. Әллә ни йөзе үзгәрмәде секретарьның.

— Гаебең юк, ди прокурор. Шулай да китүең өчен партия җәзасы бирәсе иде үзеңә дә, ярар инде. Шахтер булмасаң, башкача сөйләшер идем. Мәктәп директоры итеп булса да Лаеш районында калдырыр идем. Ну, бигайбә, җаны теләгән—җылан ите ашаган...

Таушырмәдә туры мәктәпкә юнәлде Әсләм.

— Партучеттан төштем. Менә, хезмәт кенәгәм. Менә приказ,— диде документларның барын да Мәгъсүм Фарукович алдына тезеп.— Шуның белән минем монда эш бетте...

Мәгъсүм Фарукович ул документларны җентекләп карады.

— Инде кая китәм дисен?

— Туган төбәгем Әлкигә кайтам. Әнием янына. Аннары күз күрер.

— Безне онытма...

— Кичләтә безгә кил әле. Мин хәзер Мөҗип абый янына барам. Транспорт кирәктер.

Кыңгырау шалтырады. Укытучылар дәрестән чыкты. Монсу гына саубуллашу сүзләре әйтелде. Әсләм барлык классларга кереп, укучылар белән дә саубуллашып чыкты.

Дәресләр бетү белән укучы балалар Әсләмнәргә җыелды.

— Әсләм абый, китмә...

— Абый, кал!..

Күңелләре мөлдерәмә тулган. Әсләм абыйларын кочалар. Ул, үзе дә аларны башларыннан сыйпады. Юатты. Һәм һәрберсенә үз төсе итеп бирәр әдәби китап бүләк итте.

Укучылар Таушырмә урамы очында, куллар болгап, озатып калдылар. Алар күздән күмелгәнче, Әсләм абыйлары ике кулын да югары күтәреп, яшел эшләпәсен болгый-болгый барды.

Бик тә монсу, бик тә авыр минутлар иде бу...



# Әсгат Салах

## БАЛЫКЧЫ МАЛАЙЛАР

хикәя

Минсәгыйт гаҗәп бер төш күреп ятканда кемдер шык-шык тәрәзә шакыды. Малай күзен ачып җибәрде. Таң атмаган иде әле. "Кем инде анда төш бүлдереп йөри?"—дип уйлаган гына иде, кинәт исенә төште: дусты Малик килергә тиеш бит... Күзләрен уа-уа Минсәгыйт ишегалдына чыкты. Җәйге төн искиткеч җылы, йомшак, тын иде.

Капка төбендә, озын кармак таякларын тотып, Малик басып тора иде. Минсәгыйт тә кичтән хәзерләп куйган кармакларын, иске чиләккә җыеп салган суалчаннарын алды, малайлар караңгы авыл урамы буйлап елгага төшеп киттеләр.

— Иртә торгансың. Мин рәхәтләнеп төш күреп ята идем әле,—дип куйды Минсәгыйт елмаеп.

— Мине бүген рәтләп йокы да алмады,—дип җавап бирде Малик шыпырт кына.—Гел теге балык искә төшә дә тора...

Минсәгыйт әле кичә генә сөйләнгән вакыйганы исенә төшерде. Иртә таннан балыкка төшкән булган икән Малик. Кармагына коточкыч зур балык эләккән, тик аны тартып чыгара алмаган имеш, балык кармак җебен өзеп китеп барган.

— Валлаһи, кимендә ишкәк сабы буйлык, сырты кап-кара...—дигән иде Малик.

Балыкчыларның шапырта торган гадәтләре бар-барын. Ләкин Минсәгыйт белә—дусты андыйлардан түгел. Аз, ихлас сүзле кеше ул. Дуслар алар! Бер-берсенә ялган сөйләмиләр, алдашмыйлар, хәрәмләшмиләр. Шулай итмәсәләр дус та булмаслар иде...

— Нинди балык икәнен таный алмадыңмы?—дип төпченде Минсәгыйт.

— Караңгы иде бит әле. Әллә җәен, әллә зур сазан инде,—диде Малик җилкәләрен җыерып.

Шушма елгасының иң тирән һәм тын агымында бар дөньяларын онытып күп тапкырлар балык чирттереп утырырга туры килде аларга. Икесенең дә аталары сугышта һәлак булды, икесе дә гаиләдә, аталарыннан бик бәләкәй калсалар да, олы балалар, икесе дә ач-ялангач туганнарының өмете, терәге. Казанга кырып салырга бәрәңге дә булмаган көннәрдә ике малай кармак тотып елгага төшеп китәләр һәм һич югында өчәр-дүртәр

---

*Әсгат САЛАХ — Әлмәт якларында танылган журналист, "Әлмәт таңнары" газите мөхәррире, 1997 елда публицистик хезмәтләре өчен Рафаил Төхфәтуллин исемендәге премия белән бүләкләнгән. Шул ук елны "Мирас" нәшрияты аның "Аккан сулар" исемле җыентыгын бастырып чыгарды. Безнең журналда беренче тапкыр басыла. Әлмәттә яши.*

булса да балык тотып кайталар. Ишле гаиләгә ул чәп итәргә дә житми, тик шулай да тамак ялгарга ярап тора.

Инде ул Шушма елгасында бу ике малай белмәгән балык та юк бугай. Көмештәй ялтырап торган чабагын да, юантык кызылканатын да, сап-сары, чабатадай кин корбанын да, кап-кара, шома сыртлы шамбысын да, тыгыз һәм симез тәнле бәртәсен дә, буй-буй майкалы алабугасын да, ертлач оптысын да аз каптырмадылар алар. Инде чәнечкеле шыртлака, тиктормас арыш балыгы турында әйтәсе дә юк. Балыкмыни алар? Ә менә Малик ычкындырган зур балык...

Малайларның икесенең дә күнелендә әнә шул балыкны эләктереп булмасмы дигән өмет яши һәм алар ашкынып-җилкенеп Шушмага якынлашып баралар.

“Әллә җаен иде, әллә зур сазан...”—диде бит әле Малик. Дөресен әйткәндә, бу балыкларның берсен дә тотканнары юк иде әле малайларның. Ә тотасылары килә, бик килә иде аларның...

Ниһаять, малайлар дәртләнеп, хыялланып елга буена килеп җиттеләр. Инде көнчыгыштан, чикләвеклек белән капланган калкулыклар артыннан сызылып кына алсу таң атып килә. Күгелҗем таллык һәм әкрен генә искән җилдә сизелер-сизелмәс кенә тибрәшкән камышлары белән елга буе сихри бер тынлыкка чумган. Тик уерап аккан су өстендә анда-санда балык уйнавыннан кинәт могҗизалы түгәрәкләр генә хасил булалар да, ашкынулы агым аларны мизгел эчендә юып ала.

Малайлар гадәтләнгән хәрәкәт белән тавышсыз-тынсыз, бик сөйләшергә кирәк чакта да сүзләрен кыска һәм шыпырт кына әйтеп, кармакларын сүттеләр һәм жим кадап суга салдылар.

Һәр икесендә икешәр кармак иде аларның: берсенә капмаса, икенчесенә кабар. Маликнын бер кармагы исә олы балыкка исәпләнгән. Аның кармак жебе дә ике катлы ат кылыннан үргән, кармагы да зуррак. Базарда вак товар сатучы Какыли бабай бер йомыркага ике бәләкәй кармак бирсә, зур кармакны берне генә тоттыра. Йортында тавыгын булмаса, аны каян алырга?

Кәсепче Какыли бабайны исә гаделләрдән дә, юмартлардан да санап булмый анысы. Әнә Чирмешән базарында бер йомыркага өч-дүрт кармак бирәләр ди. Алдашмаса, базардан соң исереп арбасы янына ауганчы аракы чөмерерлек акчасы булмас иде. Шуңа да Малик аның өлешенә керүне гөнаһ санамаган. Арбага салам җәеп салган йомыркалары күп иде Какылиның. Малик арба артындагы рәшәткә аркылы тыгылып, салам астыннан бер-бер артлы дүрт йомырканы кесәсенә шудырган. Аннары, бераз әйләнгәч килеп, аларны Какылига сузган: “Кармаклар бир әле, бабай”... Какыли йомыркаларны алып кояшка куеп караган—иске түгелләрме, янәсе. Аннары Маликка өч кармак—бер зур, ике кечкенәне тоттырган.

Беренче балыкны, һәрвакыттагыча, Малик тотты. Оста шул ул! Су астыннан чупылдап чыккан балык, һавада дуга ясап, яр башына очты һәм үлән арасында тыпырчынып сикерә башлады. Ярыйсы гына зурлыктагы көмеш чабак иде ул. Малик яңа суалчан кадады да, кармагын тагын агымга ташлады. Бу вакытта Минсагыйтнең кармагына да балык эләккән иде—ул бәләкәй корбан балыгын тартып чыгарды. Аның артыннан ук Малик тагын берне, инде бөкреләнеп баручы алабуга балыгын каптырды. Шулай бер-бер артлы малайлар бишәр-алтышар балык тоттылар таң атканчы. Тик Маликның бәләкәйрәк тавык йомыркасы чаклы тирес корты кадап салган зур кармагына гына кагылмады балык.

Малайларның үлеп ашыйсылары килә башлады. Инде ярыйсы гына балык та тоттылар. Тик менә ашыйсы килүне ничек басарга?

— Әллә учак ягып җибәрәбезме?—диде Малик. Дусты каршы килмәде. Әрәмә тулы таллык. Корыган тал аз түгел. Бер якка ексаң, шартлап кына сына ул. Учак ягып җибәрер өчен утын җыю авырмыни? Тик менә ут табуы... Ләкин Малик кебек дустың булганда ут табуы да

кыен түгел. Аның инде күптән чакма ташы бар. Атасыз үскән сугыш еллары малайлары ир-егетлек вазифаларын үтәргә иртә алындылар: ат җигә, җир сөрә, хәтта ир-егетләрчә сүгенә, тәмәке көйрәтә башладылар. Малик та астан гына, беркем дә күрмәгәндә, тәмәке көйрәтә иде. Ә тарткан кешенең чакмасы да булмагач, тартучы буламыни?

Минсәгыйт бер кочак тутырып чыбык-чабык җыеп килде.

— Кабызып җибәрәбезме?—диде ул һаман кармаклары янында калкавычларына текәлеп утырган Маликка. Тегесе эндәшмичә генә, кармакларына борылып карый-карый яр өстенә менде һәм кесәсендәге янчыгын чыгарып, чакма ташын чага башлады. Бераздан башы көйгән каен куына чаткы төште һәм төтенли башлады. Минсәгыйт таллыклар арасында кипшенгән үләннәрне алдан ук җыеп килгән иде—ут көйрәп китте. Учакта көл белән күмер төшүгә алар яна торган чыбыкларны актарып, зур әрекмән яфракларына төреп, үзләренә икешәр балык салдылар һәм аларны көл-күмер белән күмеп куйдылар. Чыбык-чабык өстәлгән учак кабат төтенли башлады һәм озак көттерми күңелле гөрләп янып китте.

Ярты сәгать тә үтмәгәндер, ике дус тәңкәләрен чистарта-чистарта көлдә пешкән балык ашарга керештеләр. Ашыйсылары бик килгән иде аларның һәм, бәлки шуңадыр, сөйләшергә дә вакыт тимәде. Шулай да, Маликның күзе гел зур кармакта булды.

Чү, нәрсәдер кагып куйды түгелме соң зур кармакны да? Кармак җебенең оста балыкчылар гына белгән гадәте Маликка инде яхшы таныш. Тик ул әле ашыкмый—олы балык бик саклык белән, ул-бу булмагае дип кенә ала җимне. Ә бер авызына капкач, дөбердәтеп өстерәп китә...

Һәм бу юлы да нәкъ шулай булды. Икеме-өчме тапкыр кагып куйды да, тартып та китте. Хәзер инде... Малик әкрен-әкрен ике куллап кармак җебен үзенә тарта башлады. Әз генә арада кармак җебе кыл кебек тартылды. Бу инде, чын-чынлап, олы балык эләгү билгесе иде. Ул гына да түгел, су астындагы, малайлар күзенә күренмәгән җан иясе үзенең тозакка эләгүен сизенде бугай, аннан котылу өчен унга-сулга ыргыла башлады. Тартылган кармак җебе елганың әле бер ярына, әле икенчесенә таба ташланды. Малик та белә—ул балыкны чыгарырга ашыкмый, аны шулай йөретә-йөретә арытасы бар. Тәмам хәлдән тайгач кына тартып алырга мөмкин олы балыкны...

Бераздан кармак җебе бушап китте һәм Малик аны тиз-тиз янына сава башлады. Тик җеп кинәт тагын бик нык тартылды һәм... су өстенә йөзеп чыккан иләмсез зур башлы, мич авызыдай олы авызлы балыкны күреп шаккаттылар. Балык юаш кына селкенеп алды, әйтерсең лә ул кояш нурларында җылынып, назланып алыр өчен өскә калыккан. Назланамы соң ул! Күз ачып йомганчы балык дугаланып килеп су өстенә озын койрыгы белән шап итеп сукты һәм бар көче белән аска ыргылды. Малик кармак җебен бушатырга өлгерә алмый калды, җеп шартлап өзелде. Әле яңа гына өстә чапаланган балык уерап аккан су астына чумып, күздән югалды. Кулларына бушап калган кармак җебен тоткан Малик агарынып киткән иде. Малайлар кармакны өзеп чоңгылга ыргылган балыкка елардай булып карап калдылар.

— Җә-йен,—диде Малик, ниһаять, иҗекләп.

Малайлар бер-берсенә бер сүз дә эндәшмичә яр өстенә менеп утырдылар. Икесенең дә сөмсерләре коелган, кәефләре юк иде. Үкенечле булды ла алсу таң! Йөрәк ярсуын басыйм дипме, Малик кәгазь кисәгенә тәмәке чорнап, тартып җибәрде...

Алар алай-болай иткәнче кояш чыгып, шактый гына күтәрелгән, инде кыздыра да башлаган иде. Балык та чиртүеннән туктады. Малайлар, моңсу гына җыенып, өйләренә кайтып киттеләр...

Икенче көнне дә су буена караңгыдан төштеләр малайлар. Тик җәенгә салган зур кармакны селкетеп тә караучы булмады. Моннан соң

да берничә танны заяга уздырдылар алар, әйтерсең лә теге җәеннән җилләр искән иде...

Шулай көннәр үтә торды. Сиздермичә генә август ае килеп җитте.

— Августта җәен каба да каба инде,—диде Малик Минсәгыйткә көннәрдән бер көнне.—Әллә иртәгә иртән төшәбезме?

Юк, бер генә түгел, әле күп тапкырлар төшәрләр алар балыкка. "Тагын бер тапкыр" дигәне аның җәенгә генә кагыла. Олы максат— буйсынмас җәенне каптыру, ә вак балык тоту—ул алар өчен кабыклы бәрәңге ашау белән бер.

Малик җәенгә дигән кармакка бауның икенчесен, тагын да ныграгын ясап өлгергән иде инде. Яр башында нефть эзләүчеләр буровое эшли. Пешкәк тасмасын яңага алыштырганнар да, искесен чыгарып ташлаганнар. Ә ул тасма бик күп нык җепләрдән тора икән. Әнә шул җепләрдән өч кат итеп үргән Малик кармак бавын. Алачыкка барып тимерчедән өч япьле зур кармак та койдырган.

...Менә малайлар тагын елга буенда. Шулай ук сихри таң алды, шундый ук әкияттәгедәй гүзәл Шушма буе, шундый ук мөкатдәс тынлык һәм күңелдә өмет уты көйрәткән су агымы. Тик август иртәсе генә инде бераз салкынча. Үләндә чык, су өстендә ак томан.

Кармакларын суга салып куйгач та, Минсәгыйт әрәмәдәге таллыклар тирәсеннән бер кочак коры чыбык-чабык җыеп килде һәм яр буенда дөрләтеп учак ягып җибәрде. Бераздан учакка төшкән күмерле көлгә бакчадан алып килгән яңа бәрәңгеләрне күмеп куйды. Шөкер, бәрәңге инде өлгереп килә, авыл халкы калын сабаклы, мул яфраклы төпләрне капшап, йомырка зурлыгындагы ике-өч бәрәңгене өзеп ала да, кабат туфрак белән каплап куя, икенчесенә күчә... Шулай тамак туйдырырлык бәрәңге эзләп таба.

Алай-болай иткәнче малайларның кармакларына, артык кыстатмый, төрлесеннән дүртәр-бишәр балык эләкте. Ничек кенә булмасын, өйгә алар буш кул белән кайтмаячаклар, куырып ашарга бер табалык балык бар.

— Тегене какмыймы?

Минсәгыйтнең "тегене" дигәнен Малик әйбәт аңлый—җәенгә дип салган кармакка тиюче, кагылучы юкмы әле, дигән сүз ул.

— Юк әле. Чиртми калмас,—ди Малик үзен дә, дустын да өметләндереп.

Бу арада Минсәгыйт көлдә пешкән бәрәңгеләрне учак кырыена тезеп куйды һәм Маликка эндәште:

— Әйдә, мен, бәрәңге пеште...

Кабыгын чистартып, буы чыгып торган бәрәңгене тоз сибә-сибә ашап җибәрделәр малайлар. Ашыйсылары килгәнгәдер, аларга шуннан да тәмлерәк ризык юк сыман тоелды.

Нәкъ шул чакта Маликның зур кармак бавы ургылып тартылып китте һәм суны ярып аска омтылды. Тәмләп кайнар бәрәңге ашап утырган малайлар онытылып киттеләр бугай, балыкның чирткәнен абайламыйчарак калдылар. Балыкта анысы да була торган хәл. Икесе берьюлы атылып су буена төштеләр. Малик кармак җебен кулына алып әкрен-әкрен генә үзенә таба сава башлады. Бау бераз килде дә, әйтерсең лә кармак төпкә эләккән, тартылып туктап калды. Малик аны көчлерәк итеп тартып карады. Юк, килми. Маликның уенча, балык җимне алды һәм хәзер төпкә ятты. Олы балыкның андый гадәте бар икән. Моны картлар күптән сөйли инде.

Икәүләшеп бик саклык белән бауны тарта башлагач, балык кузгалырга мәҗбүр булды. Олы балык эләккәненә малайларның шиге калмады. Өзеп кенә китә күрмәсен! Һәм ничек кенә тартып чыгарырлар икән соң аны алар? Кабат бер-бер хәл булмасмы? Ике тапкыр ычкынды бит инде... Дөрес, Маликның бавы нык иде хәзер.

Аннан соң, нәкъ теге вакыттагыча, балык елганың әле бер ягына,

әле икенче ягына йөри башлады. Йә булмаса кузгатып булмаслык итеп төпкә ятты. Ләкин малайлар аңа тынгылык бирмәделәр. Йөретергә, арытырга кирәк иде аны. Ял итеп ятарга вакыт бирергә түгел, һич түгел. Шуңа күрә Малик бауны әледән әле тартып торды. Ниһаять, балык дүрт-биш метрда гына су өстенә калыкты. Нәкъ теге көндәгечә! Аның яшь кызларның сыгылмалы көянтәседәй дугаланган кара сыртын да күргәч, яшь балыкчыларның дулкынлануы да, шөбһәләнүе дә арта төште. "Ничек кенә моны ычкындырмыйча тотып алырга соң?". Шөбһәләнерсең дә бит! Әнә ул бу юлы да көчле койрыгын су өстенә шап иттереп сукты да фонтан күтәреп кабат аска ыргылды. Ярый әле ачы сабак алган Малик бауны бушатырга өлгереп калды. Җәеннең аны шартлатып өзеп тә китүе ихтимал иде бит...

Вакыт үткән саен бау кыскара, балык та ярга якыная бара. Ул инде арыды да бугай, ләкин малайларны егып кармактан ычкынып китәргә көче житәрлек әле аның. Мондый балык белән шаярырга ярамый!

Менә җәенне су кырына ук тартып китерделәр. Өч япьле кармак балыкның авыз эчендә бик нык утыра булса кирәк, ул талпынып-талпынып караса да, ычкына алмый. Аруы да житкән ахры. Тик ничек судан чыгарга соң? Балыкның буе Минсәгыйттән калку Маликтан да озынрак бугай, башы да ат башы чаклы. Җәйпәк олы авызын ачып-ачып сулыш ала. Әнә зур җәен нинди була икән ул!..

Балыкның артына төшеп, аны кулга алырга һәм мөмкин кадәр яр кырыена чыгарырга теләп, Минсәгыйт суга керде. Утын агачы юанлыгындагы зур җәен хәзер аның аяк астында гына ята. Кулга алып, күкрәгенә кыс та, күтәреп алып чык. Шундый җинел уй белән Минсәгыйть балыкка үрелде, кагылды һәм... Җәен яшен тизлеге белән күтәрелеп бәрелде, малайны койрыгы белән сугып та екты. Минсәгыйт бар киемнәре белән суга чумды. Бу әкәмәтне өстән карап торучылар булса, бер рәхәтләнеп көләрләр иде. Тик малайларның хәле көлкедән узган, Малик исә бөтенләй кырыс иде.

— Юк, болай булмый! Ычкындыртасың хәзер, лучшы кагылма,—диде ул хафаланып.—Ярый әле бауны өзмәде.—Әгәр, малай, моны тота алсак... Аллаһы теләсә... Әгәр тотсак... Урамдагы бөтен балалар белән бергә ашар идек...

— С—с—син нәр—сә, ш-шун-дый зур җәен-не әллә кем-нәргә.., — дип ризасызлыгын белдерде Минсәгыйт калтырана-калтырана. Юеш киемнәрдән ул өши иде бугай.

Малик тиз генә җавап бирмәде, тынып торды. Ул һаман кармак бавы белән мәшгуль иде.

— Раббанины да, Котыйны да, аның сеңлесе Нисаны да ашатырбыз,— дип кабатлады Малик шулчак. Аның "Раббанины да, Котыйны да" дигән сүзләреннән Минсәгыйт айнып киткәндәй булды. Ах, син!.. Малик аның күңел ярасына орынды ич. Һәм ул яра бер Минсәгыйтнеке генә дә түгел, Маликныкы да, Раббаниныкы да, Котыйныкы да, бәләкәй Нисаныкы да иде...

Нишләп онытып җибәрде соң әле Минсәгыйт болар турында? Әле күптән түгел генә, яз башында гына булган иде ич ул вакыйга.

...Язгы ташулардан соң Югары әрәмәгә су җәелгәч, сельпо житәкчесе, форсаттан файдаланып, балык тотып калырга уйлады. Каяндыр биниһая озын җылым—җәтмә алып кайттылар, ашыгыч рәвештә балыкчылар әртиле оештырдылар. Өендә бәрәңгедән башка ашар әйбере булмаган авыл ир-атлары "балык" дигәч тә ашкынып әрәмәгә төштеләр. Тик җылым белән салкын суга керергә кирәклеген белгәч, күбесенең дәрте сүнде. Шулай да, берничә яшь ир-ат, алдан ук авызларына берәр стакан урыс аракысын әйләндереп капладылар да, тәвәкәлләп, бар булган ярлы киемнәре белән салкын суга кереп киттеләр. Ерактан әйләнеп, су салкыныннан ашыга-кабалана килеп чыктылар да, җылым башын яр буендагылар кулына тапшырып, авылга, ягып куйган мунчага чаптылар. Калган халык җылымны

көч-хәл белән тартып чыгара торды, андагы ишелеп-ишелеп килгән балыкны ярга алып ташлый, чыпта капчыкларга төяп арба белән сельпога ташый торды. Тотылган балыкның исәбе-хисабы юк иде. Ундүрт-унбиш яшендәге малайлар озынлыгындагы чуртаннарны күреп балыкчылар үзләре дә хәйран калдылар. Ул андагы зур-зур сазаннар, бәртәсләр... Вак-төяк балыкка бала-чагадан башка игътибар иткән кеше дә булмады. Тәүлекнең кайсы гына вакытында булмасын—иртән дә, көндез дә, кичен дә даими ашыйсылары килеп торган авыл балалары, шулкадәр күп балык күргәч, бер-икене эләктереп калу, өйгә алып кайтып әниләрен, туганнарын шатландыру уе белән яна башладылар. Иске куфайкасы өстеннән билен мунчала бау белән кысып бәйләгән Малик та култык астына өч-дүрт балык яшереп куярга өлгерде. Минсәгыйт тә җылым тирәсендә бөтерелде, тик ана балык алып калу җае чыкмады, югыйсә балыкчылар әртилендә әтисенең олы абыйсы да бар, ул да балык җыеша, төяшә һәм, әгәр теләсә, сугышта югалып калган энесенең ятим, тәрәксез улына, бөтен гаиләгә житәрлек итеп, балык тоттырып җибәрә ала иде, чөнки ул әртил башлыгы итеп куелган базар мөдире Әтәч Шәфинең ярдәмчесе кебегрәк иде су буенда. Тик аңарда энесенең ятим балалары хәленә керү, аларга булышу кебек изге ниятләр, кин күңеллелек, шәфкатьлелек кебек күркәм сыйфатлар юк иде. Киресенчә, ул Минсәгыйтне күреп алгач:

— Малай, нишләп йөрисең монда? Бар, кайт өеңә, йөрмә ыштан туздырып!—дип һич урынсызга кычкырынырга тотынды. Минсәгыйт бөтенләй каушап китте һәм бер балык та алып кала алмады. Ул гына да түгел, абзыйсының кычкырынуын ишеткән әртил башлыгы Әтәч Шәфи балык тотып басып торган, аяклары чебиләнеп беткән Раббанины эләктерде.

— Син нәрсә балык урлыйсың, маңка малай?—диде Әтәч һәм, Раббанинның кулындагы бәләкәй балыкны тартып алды да, арткы ягына сугыш кырында фашист мәетеннән салдырып алган калын табанлы күн итеге белән типте. Раббани, әллә авыртудан, әллә балыксыз калу үкенеченнән, әллә гарьлегеннән инде кычкырып елап җибәрде. Шәфи аңа игътибар да итмәде. Ул бу вакытта инде Котыйны каптырган иде. Ачлыктан тәмам коры сөяге генә калган, сәләмә киемле Котыйның да бердәнбер балыгын тартып алды Әтәч Шәфи һәм өстәп сугып та җибәрде. Раббани да, Котый да, абыйсы Котый артыннан ияргән биш-алты яшьлек четер кебек бәләкәй, абыйсы кебек үк ябык һәм сәләмә киемле Ниса да акырып елап кайтып киттеләр. Минсәгыйт үзенең җан күршеләрен бик кызганды, тик аларны яклый алмады. Шул арада Әтәч Шәфи Минсәгыйтне дә тотып, бар җирен капшап карады—янәсе балык яшермәгәнме. Юк, Әтәч тапмады. Тапмагач, тияргә дә кыймады. Минсәгыйт шунда ятим балаларга кул сузган явыз базар мөдиренең кыланмышын күреп торган авыл ир-атларының ятимнәрне яклап сүз катмауларына аптырады. Тамак тәмугка кертә, диләр. Балык, дип болар тәмугка кергәнче үк, Әтәч Шәфи белән эләгешүдән шөлләп, намусларын саттылар. Ниндидер бер командирның адъютанты булып сугыш кичкән, үзенең сөйләвенә караганда күп төрле батырлыклар кылган абзасы боларның барысын да күрмәмешкә салышты. Әтәч Шәфи Минсәгыйтне тентегән вакытта әйтә ала иде бит: "Ул минем энекәш, кагылма!"—дип. Юк, әйтмәде. Батыр түгел, куркак бер бәндә икән аның абзасы. Абруе нык төште аның Минсәгыйт алдында.

Ә менә Маликныкы...

— Син нәрсә, Әтәч тәре, ятимнәргә тиясең? Котырдыңмы әллә?—диде ул Әтәчнең күзенә туп-туры карап. Әтәч мондый хөрмәтсезлекне көтмәгән иде, йодрыкларын төенләп Маликка таба бара башлады. Малай да югалып калмады, кулына җылымга ияреп чыккан йомры таш алды. Шунда гына кемдер, әллә инде бу үткен малайның кыюлыгыннан әсәрләнеп, әллә үзләренең куркаклыгыннан оялып, Әтәчне килеп туктатты: "Кызма, Шәфи абзый! Егет дөрес әйтә: нигә ике-өч балык өчен балаларга тияргә? Үзебез олаулап ташыйбыз, ә мескеннәргә бер-ике балык та жәл"...

Малик белән Минсәгыйт өйгә кайтканда алдан елап киткән күршеләрен куып життеләр. Балалар әле һаман сыктап кайталар иде. Малик куфайка эченнән Раббанига да, Котыйга да, Нисага да бирәр балык чыгарып тоттырды. Тегеләр елауларыннан туктадылар һәм кайта-кайта хәтта күңелле итеп сөйләшә дә башладылар. Кулларына көтмәгәндә генә килеп эләккән кыйммәтле табыш күтәргән иде бу мескен балаларның кәефен...

Әле кичә генә булып узган сыман бу вакыйганы Минсәгыйт кабат башыннан кичерде. Кара инде, бөтенләй онытa язган бит ул теге көнне булып үткән хәлләрне. Менә сиңа Малик! Рәхмәт, искә төшерде...

— Мин аңладым сине, Малик,—диде, ниһаять, Минсәгыйт олыларча.—Дөрес уйлыйсың, мин риза, мин хуплыйм синең ниятеңне...

Малик, кармак бавын һаман кулларына кысып тоткан килеш, Минсәгыйткә борылып карады. Аның йөзе елмаюлы иде. Шул елмайган килеш ул Минсәгыйткә күзен кысып алды:

— Безнең, Минсәгыйт, барысы да алда әле. Тоттык, тотабыз, тагын да тотарбыз балыкны... Аллаһы теләсә... Бер шатландырыйк әле, малай, ач күршеләребезне. Туйганчы бер ашыйк әле барыбыз да. Бакчада үскән бәрәңге түгел, елга балыгы гына. Ходай биргән байлык. Әтәч Шәфи кебекләргә житмәсә дә, безгә житә ул... Бар, киемнәреңне сал, учагыңны көйрәт! Мин арытам әле тагын...

Минсәгыйт кабат учакка чыбык-чабык өстәп, утны көйрәтеп жибәрде һәм юеш киемнәрен салып ялкында киптерергә кереште.

— Яхшы әле кармак бавы нык булып чыкты синең, жәен ничек кенә тыпырчынмасын, ычкына алмый,—диде ул һаман балык белән маташкан Маликка. Бу вакытта Малик балыкны кабат яр буена китереп житкергән иде.

Инде нишләргә дип аптырап торганда, яр буена, озын чыбыркысын сөйрәп, көтүче Мортаза абзый килеп басты. Су буенда яткан кимендә метр ярым озынлыктагы жәенне күреп хәйран калды:

— Ват, малай актыклары, ват иты да? Кара син аларны, ә? Кара нинди жәен каптырганнар бит, ә? Ничек тартып чыгардыгыз моны, ә? Ват, малай...

— Чыгып житмәгән шул әле, Мортаза абзый,—диде Малик һаман бауны нык тотып.—Кагылсак, өзеп китәр дип куркабыз...

— Син, Малик энем, аның авызын судан чыгарып торырга тырыш. Һава суласын ул, хәле китсен,—дип киңәш бирде көтүче. Малик балыкны ярга тагын да якынрак китерде һәм аның авызын күтәребрәк куйды. Шулай шактый вакыт тотканнан соң балык, тагын берничә мәртәбә талпынып алды да, язмышына тәмам буйсынып, хәлсезләнеп, әкренләп тынып калды һәм ак корсагы белән өскә әйләнде.

— Булды бу, хәзер инде өскә алып менсәк тә була,—диде көтүче. Шома гәүдәле озын жәенне, ничек булса шулай эләктереп көчкә-көчкә өскә менгереп салдылар өчәүләшеп.

— Мына сиңа трафый дык трафый,—дип һаман соклануын дәвам итте Мортаза абзый.—Ну, малайлар, авыз итәбезме соң жәеннән?

— Итәрсең, Мортаза абзый, итәрсең,—диде Малик инде жинел сулап.—Урамыбызның бөтен фәкыйренә багышладык без бу жәенне Минсәгыйт белән. Сине дә чакырабыз балык ашына...

— Мына бусына рәхмәт, энеләрем! Яхшы малайлар сез,—диде көтүче. Салпы якка салам кыстырудан гына әйттеме ул аны, әллә чын йөрәктәнме, тик малайларның күңеленә ошады аның бу сүзләре.

Мортаза абзый малайларга жәеннең башын калын таякка тартып бәйләргә дә булышты. Малайлар, таякны икесенең жилкәсенә салып, авылга кайтып киттеләр. Күл буена житкәч аларга анда су кереп яткан малай-шалай килеп кушылды һәм шау килеп өйләренә чаклы озата барды. Әлегә кадәр мондый зур балыкны күрмәгән урам халкы капка төбенә чыгып, балыкчы малайлар артыннан таң калып карап калды. Балыкның

башы Малик белән Минсәгыйт җилкәсендәге таяк өстендә булса, койрыгы исә җирдән сөйрәлеп кайта иде...

Җаенне күтәреп кайту җиңел булмаса да, әле таң алдында гына шундый чамасыз зур балыкны тоту фәкать хыялларында гына яшәгән Малик белән Минсәгыйтнең шатлыклары йөзләренә чыккан иде. Алар күңелле итеп елмаялар һәм күтәренке, ягымлы тавыш белән арттан шаулашып кайткан малайларга, капка төбенә чыккан апа-абыстайларга, урамда очраган башка авылдашларына:

— Бу балык барыбызныкы да...

— Озакламый килегез...

— Балыгын да, шулпасын да бергә-бергә авыз итәрбез...

— Онытмагыз, җыелыгыз, — дип, ачлы-туклы тормыш иткән урам халкын уртак ашка, сыйланырга чакыра-чакыра кайталар иде. Бу сүзләрне ишетеп калган һәм һәрвакыт ашыйсы килеп, бер генә мәртәбә булса да тамагы туйганчы ашау турында хыялланган бала-чаганың да, олыларның да бераз вакыттан искиткеч тәмле балык ашы ашау уеннан авыз сулары килә башлаган иде инде...

Ике дус малайның кеше ышанмаслык биниһая зур җаен тотып кайтулары, аны олы урамның барлык ятимнәренә багышлаулары турындагы һичберкем башына китермәгән хәбәр тиз таралды. Кизләү инешенен хәтфәдәй каз үләне үсеп утырган уйсу, иркен буенда колхозның ин дәү казанын астылар. Бала-чага, кайсы кайдан тапса, шуннан утын җыеп килде. Кайсыдыр соскы белән үз өе учагыннан утлы күмер китерде. Бераздан күңелле төтенләп учак дөрләп китте. Олы ашны пешерүне урамның иң пөхтә, гадел карчыклары Камилә белән Таифә әбигә тапшырдылар. Гомер буе дин-иман белән яшәгән мөхтәрәм әбиләр балык ашын бисмилла әйтеп, кулларын инештә юып башладылар. Балыкны вак кисәкләргә бүлгәләп, аларны су белән йөгертеп, инде суы кайнарланып килгән казанга салдылар. Әбиләр белән бергә казан тирәсендә күтәренке күңелле, якты йөзле балалар чуалды. Олы аш икән—олы аш булсын дип, кемнәрнең өендә нинди ризык табылса, шуны алар инеш буена алып чыктылар. Берәүләр икешәр-өчәр бәрәңге, икенчеләр бер-ике чеметем тоз, өченчеләр кәсә төбендә булса да он алып килделәр. Кайсыдыр әбиләрнең кулына ярты кабак, ә кемдер бер чөгендер китереп тоттырды. Инде читән төбеннән йолкып килгән кычыткан, әрәмәдән җыеп кайткан балтырган һәм сәрдәне уртак ашка беркем дә кызганып тормады. Аяклары чебиләнеп беткән бакыр чәчле Раббани да өйләрендә булган соңгы ризыкны — бармак башыннан аз гына зуррак бер суган китереп бирде. Уртак ашка аның да өлеш кертә алуыннан канәгать булыптыр, ятим малайның ябык йөзендә матур елмаю чагылды. Әбиләр бар китерелгән ризык өчен балаларны аркаларыннан сөя-сөя, аларга ягымлы сүзләр, рәхмәтләр әйтә-әйтә ризыкларын юып-чистартып казанга салып җибәрделәр. Гадәттән тыш зур казан балыкны да, килгән барлык ризыкны да сыйдырды һәм, озак көттереп булса да, андагы аш тәмле исләр чыгарып кайный, пешә башлады. Әбиләр казан тирәсендә кайнашкан арада балалар хуш исләре бөркеп торган каз үләненә ятып, зур сабырлык белән аш пешкәнне көтә-көтә, Малик белән Минсәгыйтнең ничек шундый зур балыкны тотып кайтулары белән әсәрләнеп, аларның үзләренә төрледән-төрле сораулар бирделәр. Малик та, Минсәгыйт тә аларның керсез күңелләрендә соклану хисе уятты. Һәм бу хис аларның зур балык тотуларыннан гына түгел, ә икесенең дә бик якын дус булуларыннан да иде. Малайлар арасында: "Әх, Малик яки Минсәгыйт кебек дустың булсын иде!"—дип уйлаучылар да аз булмагандыр.

Ниһаять, әбиләр ашның пешеп өлгерүе турында инеш буена хәбәр салдылар. Сугыш дип аталган тинсез афәт утында күбәләктәй көеп калган, иген игү кебек изге эштән башка шөгыль дә белмәгән гади авыл ир-атларының мәңге тәрәксез, ятим калган балалары өйләреннән алып килгән савыт һәм кашыкларын тотып казан тирәсенә җыелдылар. Учак, казан

янында янып-пешеп аш әзерләгән, шуннан жыерчыклы йөзе яктырып, кызарып киткән Камилә әби, өеннән алып чыккан агач чүмеч белән, балаларга бисмилласын әйтә-әйтә аш салырга әзерләнде. Кин күнелле, гадел карчык башта балык тотучы малайларга—Малик белән Минсәгыйткә күп һәм куе иттереп аш салып бирергә уйлаган иде.

— Юк, әби, безгә иң соңыннан салырсың, — диде Малик катгый иттереп һәм Камилә әби, Маликның бу гамәлен эчтән тирән хуплап, иң элек бик бәләкәйләргә сала башлады ашны. Аннары бераз гына олыракларга, аннары тагын да олыракларга өлеш чыгарды.

Шулай һәркем үз өлешен алып, челтерәп аккан Кизләү инеше буендагы уйсулыкның яшел хәтфәсенә утырып, ашыга-пешә, өф-өф итеп өрә-өрә тәмләп балык ашы ашый башлады. Әле кайчан гына шау килеп сөйләшеп яткан балаларның тавышлары тынып, бары тик аларның савытка бәрелгән кашык тавышлары да, аш ашаудан ләззәт табып жиңелчә ыңгырашу авазлары гына калды.

Беренче булып Раббани үз савытын бушатты. Берничә көн авызына рәтле ризык кермәгән малайның сабырлыгы беткән иде—чөмерде генә ул ашны.

— Дөньяда мондый тәмле ашны ашаганым юк иде әле,—диде ул гел олыларча.—Рәхмәт, әбиләр! Рәхмәт Малик, рәхмәт Минсәгыйт... Балыкны тагын да күбрәк, жәеннең тагын да зуррагын тотарга насыйп итсен сезгә...

Ниһаять, казан тирәсендә кеше калмады һәм чират Малик белән Минсәгыйткә дә житте. Камилә әби аларга казан төбендә калган соңгы ашны бүлеп салды. Төрледән-төрле тәмле ис килеп торган ашны ашау теләге белән ике дус малай савытларын тотып чирәмгә утырдылар. Шул чак инеш буенда кабат Раббани күренде.

— Малик, ә нишләп Котый белән Ниса күренмиләр?—диде ул хәвефләнеп. Маликның да, Минсәгыйтнең дә йөрәкләре жу-у итеп китте. Чыннан да, кайда соң Әтәч Шәфи тарафыннан рәнжетелгән ятимнәр? Нигә уртак ашка чыкмадылар? Әниләре бетмәс-төкәнмәс колхоз эшендәдер инде. Ә балалар?

Ачлыктан киселгән балаларның артык хәрәкәт ясарлык егәрлекләре дә юк, алар аналары кайтканны көтеп өйдә, сәкедә генә ятып калганнар иде. Раббани керең:

— Әйдәгез, ашарга,—дигәч, Котый белән Ниса, каяндыр көч табып, торып бастылар һәм, Раббанига ияреп урамга чыктылар. Жил капкадан берсеннән икенчесе бәләкәйрәк абыйлы-сеңелле Котый белән Ниса килеп чыккач, инеш буендагылар аһ итте. Ятимнәрнең ачлыктан битләре жилсенгән, эчләре күпшенгән иде. Аякларында көчкә басып торалар.

— И-и, ходаем, нишләп шулай булды соң әле? Бер кашык аш та калмады бит,—дип өзгәләнде Камилә әби.

— Аш бар, әби,—диде Малик кинәт тыныч һәм ышанычлы тавыш белән, терсәге белән дустына төртеп алды.

Малайлар хәлсезләнеп жиргә ауган Котый белән Нисаны күтәреп алдылар да аш салынган савытлар янына китереп утырттылар:

— Ашагыз, аша!

Ач сабыйлар дөньяларын онытып, алларындагы ашны берәрсе килеп тартып алмагае дигәндәй, як-якка карана-карана комсызланып ашый башладылар.

— Борчылма, Сәгыйт, без иртәгә дә төшеп тотарбыз әле балыкны, — диде Малик авызына жыелган суны йотып. — Шулпасын да, балыгын да ашарбыз әле. — Әмма нишләптер күзләрендә яшь бөртекләре елтырый иде.

# ШИГЪРИЯТ



## Флера Тарханова

### НӘҮМИЗ КҮҢЕЛЕМ КАБАТ КАНАТЛАНА

* * *

Тәннәреңә кысып кочкан чакта
Сеңде миңа синең хуш исең,
Шуны сулый-сулый яшим хәзер -
Яннарымда син юк: нишлим соң?

Кая барыйм, сине кайдан табыйм -
Еракларга киттең калдырып,
Ул җирләрдән инде кайтып булмый -
Йөрим менә синсез каңгырып.

Тыеп булмый сине сагынудан,
Юксынудан аккан яшемне,
Тәнең булмаса да яннарымда,
Җаның белән бергә яшим мин.

### Чакыру

Бергә узган еллар дуслаштырды,
Якынайтсын иде тагын да,
Сер яңартып бер утырыйк әле -
Килегезче минем табынга.

Уен-көлке белән үрелеп барыр
Дәртле шаян җырлар, сихри моң,
Сездән башка нидер җитмәс кебек,
Яме булмас кебек табынның.

Җаннар шаһы - гүзәл сандугач та
Очынып сайрый тик үз талында,
Нәүмиз күңелем кабат канатлана
Сез булсагыз гына табында,
Килегезче, дуслар, табынга!

* * *

Синнән башка үлеп китәрмен дә,
Дөрләп януымнан туктармын,
Сиңа дигән иң кадерле сүзне
Әйтми калырмын, дип куркам мин.

Мин "киткәндә" әгәр яннарымда
Син булмасаң, ничек чыдармын?
Күрә алмый калдым, дип, "тегеннән"
Сине эзләп сәфәр чыгармын.

Очып керермен дә тәрәзәңнән
Бер күбәләк булып кунырмын,
Таныдыңмы инде, дигән кебек,
Күзләреңә карап торырмын.

Нидер әйтмәк булып талпынырмын,
Тилмерерсең мине аңламый.
"... Мин бу, мин бу..." диеп, канат җилпеп,
Чәчләреңнән сөеп назлармын.

Аның мин икәнен төшенмичә,
Куа күрмә җылы өеңнән,
Башка күралмассың - сагынсаң да,
Өзелеп чакырсаң да, мин килмәм.

* * *

Нинди бәхет: шашып сөя белү,
Сөйгәнеңне җанда тоя белү,
Шатлыклардан бергә елау-көлү -
Нинди бәхет: бары сөя белү!

Нинди бәхет: өзелеп сөя белү,
Кадерлеңне күрми күрә белү,
Ул гына, дип, һәрчак янып-көю -
Нинди бәхет, бары сөя белү!

* * *

Бит очымда калды кайнар тының -
Күңелемне "тора котыртып",
Хисләремә дөрләп ялкын капты
Әйтерсең лә куйдым ут йотып.

Уйларымда калды һәрбер сүзең -
Җавап көттең сыман тоелды,
Әйтмәсәм дә берни, сүзең җөпләп,
Йөрәгемә нидер уелды.

Күзләремдә калды көләч йөзең -
Сөеп карауларың чындырмы?!
Ихлас булса, өзеп атыйк әйдә
Җанны бәйләп торган чылбырны.

## Сине күргәч

Сине күргәч, уйлар чолгап алды -
Яшьрәк чаклар килде күңелгә:
Бозлы йөрәкне дә җылытырлык
Елмаюың истә бүген дә.

Тавышларың һаман шул ук икән -
Шул ук аһәң синең сүзләрдә,
Чаткы чәчрәп торган күзләреңнең
Төсе генә бераз үзгәргән.

Төн карасы чәчең нык бирешкән -
Ак ефәккә калган, агарып,
Кыя сыман горур маңгаеңда
Төрле юллар ята таралып.

Ул юлларда бардыр Әфганы да,
Алман иле, Мисыр, Иран да -
Һичбер кайчан сине туктатмады
Җәйнең челләләре, буран да.

Халык әйтә: "Ниләр күрми, - диеп, -
Ир-егеткәй белән ат башы?"
Син дә шулай: һаман ил гизәсең,
Кулларыңнан төшми "атташе".*

Еллар, еллар... Гүя очкан кошлар -
Акрын узып булмый микәнни?
Дөнья куып, сизми дә калганбыз
Гомеркәйләр үтеп киткәнне...

Сине күргәч, бик шатландым әле,
Очраттым, дип, якын кешемне.
Рәхмәт сиңа: хатирәмә кереп,
Яшь чакларны искә төшердең.

*Атташе—кейс.

# ДРАМАТУРГИЯ



**Фоат Садриев**

## ЯШЬЛӘЙ СӨЙГӘН ЯРЛАР

Катнашалар:

Рафаэль
Дамир
Иван
Гүзәл
Римма
Ләйлә
Люция

### Беренче кисәк

**Ык буендагы әрәмәлек. Җәйге кич, сандугачлар сайрый. Алдан ике кулын кесәсенә тыккан Рафаэль һәм гитара уйнап Дамир керә. Аларга рюкзак аскан һәм башка кирәк-ярак тоткан Иван, Римма, Ләйлә, Люция ияргән. Барысы да җырлыйлар.**

—Әйдә, әйдә!
—Кайда, кайда?
—Әйдә барыйк урманга.
Урман буйлары абага,
Урман суы шәп ага.
Авылыбызда бер чибәр бар -
Әйдә, салыйк шобага.
Чакрым саен телеграмм,
Чакрым саен багана.
Безнең хәзерге яшьләргә
Килде рәхәт замана.
—Әйдә, әйдә!
—Кайда, кайда!
—Әйдә барыйк урманга.
Урман буйлары абага,
Урман суы шәп ага.
Авылыбызда бер чибәр бар -
Әйдә, салыйк шобага.

**Римма йөгереп алга чыга да үләнгә барып ята.**

Римма. Шушы чәчәкле үләннәр өстендә, шушы йолдызлар астында үләргә ирек бирегез миңа!

Дамир. Юләрләргә үләргә рөхсәт юк!

Римма. Юләр барыбер үләндә үләр!

Люция. Юандыр гәүдәң. Мичкәне хәтерләтәсең. Чиләк белән өстеңә су ташый башлаганчы тор!

Рафаэль. Ха-ха-ха!

Римма. Их, көнләшмәсен иде кешеләр! (*Торып кагына.*) Берәрегез тәгәри аламы тагын?

Иван. Мин тәгәри алам.

Рафаэль. Терсәге ямаулы костюм белән шуышып та йөреп була.

Иван. Ялгышасың. Ялгышасың. Ул минем өчен мең сумлык костюм-чалбардан да кадерлерәк.

Рафаэль. Ямавы ефәкмени?

Иван. Кадерле истәлек булганга.

Рафаэль. Керәшен халкы искегә мөкиббән китә инде ул.

Ләйлә. Әле генә керәшен җыры җырлап килүебезне онытма.

Рафаэль. Кит аннан!!

Люция. Таптыгыз сүз! Әйтер идем инде...

Римма. Әнә йолдыз атылды.

Дамир. Ыкка төшеп чумды.

Иван. Оча торган тәлинкә булмасын тагын.

Люция. Әгәр чит планетадан шушында төшеп, әйдә безнең белән дисәләр. Ике дә уйламыйча ияреп китәр идем.

Дамир. Ә Рафаэль?

Рафаэль. Люциядән каламмы соң!

Люция. Ә мин үзем генә китәр идем.

Римма. Чибәррәк егет эзләп түгелдер бит?

Дамир. Андагы егетләр бер күзле, биш авызлы ди, биш авызы да сакал-мыек эчендә ди.

Римма. Йөн арасыннан эзләп табып үбеп бетерешле түгел икән.

Дамир. Авызларының берсе ашаганда икенчесе сөйләшә, өченчесе сызгыра, дүртенчесе гырлый, бишенчесе җырлый ди.

Рафаэль. Кызык, алар да безнеңчә җырлый микән?

Дамир. Юк, алар менә болай җырлый. (*Гитарада уйнап җырлый.*)

Тир-там, тир-там,
Җырлагыз, кызлар.
Күзләремә балкып тулган
Кечке йолдызлар.
Кечке йолдызлар.

Римма. Туктагыз әле, мәмкәләр, без кайчан чәй куябыз?

Ләйлә. Үзем су алып киләм.

Люция. Римманың бөтен уе ашауда.

Римма. Ашаган малда өмет бар.

Иван. Кайнар чәй эчеп җибәрсәң, дөнья яктырып китә инде ул.

Рафаэль. Безнең лимонад житәрлек. Чәй куймыйбыз.

Дамир. Учак ягып җибәрергә кирәк, җәмәгать. (*Гитарасын агачка элә.*)

Римма. Су да кирәк.

Люция. Мин алып киләм. (*Чиләк ала.*)

Дамир.
Чиләгендә пар тотка,
Ыкка иелеп су алганда
Берәүне салдың утка.

Люция.
Чиләгемдә пар тотка,
Шул тоткадан бер халтурщик
Ясады шигъри ботка.

**Көлешәләр.**

Рафаэль. Тәгәлләнеп бетмәде.

Люция. Бер ай шапырынасың бит инде.

Дамир. Иҗат ул сиңа майлы ботка ашау түгел. Сүзләрне фикер шампурына тезеп, хис ялкынында пешерү өчен ничә тонна илһам күмере кирәклеген беләсезмени сез!

Римма. Бигрәк катлаулы икән шул.

Дамир. Чыгарылыш кичәсенә әзер булачак, дустым Рафаэль.

Рафаэль. Көтик, күрик. Гонорары шул көнне үк түләнер, әлбәттә.

Дамир. Рәхмәт, рәхмәт. Мин анысына шикләнмим.

Рафаэль. Шикләнмә. Язмый калсаң да, түләнер.

Иван. Алай гадел булмас бит.

Рафаэль. Анысын үзе белә ул...

Римма. Лыгырдаудан туктыйбызмы без, юкмы? "Мәмкәләр җәмгыяте" әгъзаларының тамагы ач.

Дамир. Пешекче куыра башлады.

Римма. Әләй, аркам өшеп китте. Рафаэль, куртканны гына сал әле.

Рафаэль. Баш өсте, мадемуазель. (*Курткасын аның иңбашына сала.*)

Римма. Кем чыбык-чабык алып килә?

Дамир. Мин.

Рафаэль. Юк, син учакны ягып җибәрерсең. Чыбык-чабыкны Иван дәдәй әзерләсен.

Люция. Кунак кешегә эш кушмыйлар.

Дамир. Нинди кунак булсын ди ул? Велосипеды белән көн саен безнең авылда.

Римма. Ләйләләрнең капка төбен саклый диген.

Люция. Ләйлә акча түли торгандыр сиңа. Шулаймы, Ваня?

Иван. Көнгә өч тәңкә.

Дамир. Плюс утыз үбешү.

Римма. Үләсең инде шул үбешү дип. Бер үбешкәндә кешенең авызына бер миллион микроб керә ди бит.

Дамир. Керсә соң! Мин бит үзем дә шул кадәр үк микробтан котылам ләбаса!

Рафаэль. Анекдотны туктатыгыз! Учакка чыбык-чабыкны керәшен җыя. Аның кәчтүне дә пычранасы юк. Шулаймы, ямаулыкаем?

Иван. Буйсынам әмерегезгә.

Рафаэль. Дамир, бир аңа балтаны. Аң бул, югалта күрмә. Югалтсаң, тагын бер атнадан бирелачәк аттестатын белән алтын медаленне түләп тә котыла алмассың.

Иван. Җаның тыныч булсын. Әйдә, Ләйлә, икәүләп тизрәк җыярбыз.

Р а ф а э л ь. Лэйлэ бирэдэ кала.

Л ю ц и я. Алайса, чыбык-чабыкны Ваня белэн без икэү эзерлибез. (*Иванны култыклап китэ башлый.*)

Р а ф а э л ь (*аны Иваннан аерып ала*). Ә юк инде, керэшен белэн җибэрсэң, эллэ нишлэтер!

Д а м и р. Ну, телең дэ телең, дустым! Ха-ха-ха!

Р а ф а э л ь. Мин сиңа рөхсэт итэм, Лэйлэ.

Л э й л э. Киттек, Ваня (*Алар чыга.*)

Л ю ц и я. Көнлэште, көнлэште, көнче күбэлэк.

Р а ф а э л ь. Кемнэн?

Л ю ц и я. Озын койрыклы җеннэн.

Р а ф а э л ь. Әйдэ йөреп килик эле.

Л ю ц и я. Мин суга барам. (*Аннардан ычкына да, Дамирны барып култыклый.*) Дамир, эйдэ су алып килэбез.

Д а м и р. Рафаэль ни эйтер бит?

Л ю ц и я. Әгэр бер генэ телэгем үтэлмэсэ дэ, кайтып китэргэ дэ күп сорамам. (*Ул Дамирны читкэ тарта, Дамир кузгалмыйча Рафаэльгэ карап тора.*) Дустыңнан куркасыңмы?

Д а м и р. Мин... ни...

Р а ф а э л ь. Барыгыз, бар.

**Дамир белэн Люция чыгалар.**

Р и м м а (*Рюкзактагы эйберлэрне чыгарып җырлый*).

—Әйдэ, эйдэ,
кайда, кайда?
—Әйдэ барыйк урманга.

(*Җырлавыннан туктап.*) Пычак кайда?

Р а ф а э л ь. Кибеттэ.

Р и м м а. Кибет кайда?

Р а ф а э л ь. Безнең тыкрык башында.

Р и м м а. Сезнең тыкрык башы кайда?

Р а ф а э л ь. Икэү очраша торган җирдэ. (*Аны кочаклап ала, Римма аның кулыннан шуып чыга.*)

Р и м м а. Нишлисең, юлэр? Күрсэлэр...

Р а ф а э л ь. Күрсэлэр соң, укаң коелмас эле.

Р и м м а. Коела шул.

Р а ф а э л ь. Моңа кадэр коелганы юк иде бит.

Р и м м а. Хэзер коела.

Р а ф а э л ь. Үзгэрдеңмени?

Р и м м а. Ярар инде, бэйлэнмэ, урыны бу түгел.

Р а ф а э л ь. Син ялындыра башладың эле, кызый. Беркөн дэ күпме вакытымны эрэм иттем.

**Куаклар арасында Дамирның башы күренэ. Ул аларны яшеренеп күзэтэ.**

Р и м м а. Балык консервыларын ач энэ.

Р а ф а э л ь. Миннэн башка да ачарлар.

Р и м м а. Алайса, миңа клеенка җэяргэ булыш. (*Клеенканы сүтэ башлый.*)

Р а ф а э л ь. Мине тыңламаган кешегэ булышмыйм мин. (*Аны арттан килеп кочаклап аудара, үбэ. Римма сикереп тора, өстен кагып читкэ китэ. Люция керэ.*)

Л ю ц и я. Һо-о, барысы да эзер икэн монда. Шулайдыр дип уйлаган идем аны.

Р и м м а. Дамир кайда?

Л ю ц и я. Дамирыңны су анасына сатып эчтем.

Р а ф а э л ь. Ха-ха-ха!

Р и м м а. Ярар, алайса, Рафаэль миңа булыр. Әбекэй эйтмешли, тояк урынына тояк.

Л ю ц и я. Мин берсүзсез риза, эле өстэп хэерен дэ бирэм.

Р и м м а. Үтердең! Рафаэль, ничек түзэсең?

Р а ф а э л ь. Бу сүзлэрең өчен мин сине "ам" итэм! (*Люцияне кочаклап ала да озак итеп үбэ. Римма күзен алмыйча карап тора. Дамир керэ.*)

Д а м и р. Шул кадэр текэлмэ, сабыйларга күз тигерерсең.

Р и м м а. Болар тиюдэн үткэн инде.

Л ю ц и я. Иркенлэп үбешергэ дэ ирек юк. Тулы дискриминация.

Р а ф а э л ь. Дамир, эшеңне онытма.

Д а м и р. Баш өсте, дустым. (*Учак ягарга кэгазь ише нэрсэлэр эзерли башлый. Чыбык-чабык күтэреп, Иван белэн Лэйлэ керэ.*)

Р а ф а э л ь. Менэ бит Иван дэдэй дэ кайтып житте. Костюмыңның ямавы сыпылмадымы?

И в а н. Киемнең ямавы нэрсэ ул? Намусың ямаулы булмасын.

Л ю ц и я. Молодец, Ваня!

Л э й л э. Ә без сандугачлар сайравын тыңладык. Искиткеч!

Р и м м а. Мин конфет-шикэр ише нэрсэ тапмыйм. Кем алып килергэ тиеш иде эле аларны?

Л ю ц и я. Мин.

Р и м м а. Кая, китер монда.

Л ю ц и я. Рафаэль!

Р а ф а э л ь. Син миңа кушкан идең дэ, онытканмын бит, Люциям.

Л ю ц и я. Кыргансың икэн. Рэхмэт.

Р а ф а э л ь. Белэсеңме...

Л ю ц и я. Белмим, белергэ дэ телэмим.

И в а н. Борчылмагыз, кызлар, минем сумкада шикэр булырга тиеш.

Р а ф а э л ь. Сезнең халыкта эллэ нилэр бардыр эле.

**Дамир учак кабызып җибэрэ.**

Р и м м а. Ура! Мэхэббэт учагы дөрли башлады.

Л э й л э (*ярым пышылдап*). Кызлар! Егетлэр! Бер сүз эйтимме?

**Тавышлар:** —Әйт, әйт!
—Ни әйтерсең икән?
—Әйтсең, әйтсең!

**Ләйлә.** Әйдәгез, бер җырлыйк, бик әле.

**Дамир.** Була ул. (*Гитарасын ала, барысы да җырлап бииләр.*)

Тир-там, тир-там,
Җырлагыз, кызлар.
Күзләремә балкып тулган
Кечке йолдызлар,
Кечке йолдызлар.
Синең мине, минем сине
Яндырыр чагым.
Йөрәкләрне җылытадыр
Сөю учагы, сөю учагы.

**Алгы планда Рафаэль белән Иван бии.**

**Рафаэль.** Хәлләр ничек, гений?

**Иван.** Үзең белгәнчә.

**Рафаэль.** Ничек үзең белгәнчә?

**Иван.** Генийларча.

**Рафаэль.** Велосипедыңның тының чыгармасыннар.

**Иван.** Ул беркемгә дә комачауламый.

**Рафаэль.** Комачауламый. Янадан безнең авылга килеп йөрмәссең.

**Иван.** Анысы инде минем эш.

**Рафаэль.** Кушканымны үтәмәсәләр, мин түзә алмыйм.

**Иван.** Ә мин түзәм.

**Рафаэль.** Синең кебек салам сыйракларның унысын бергә өеп куя алганымны белмисеңме әллә?

**Иван.** Беләм, Рафаэль.

**Аларның арасына Люция килеп керә.**

**Люция** (*Рафаэльгә.*) Бар, әнә сеңлең килгән.

**Рафаэль.** Кайда ул?

**Люция.** Куаклар арасында басып тора.

**Рафаэль.** Янагын икенче якка күчерәм мин аның! (*Кызулап чыгып китә.*)

**Иван.** Аның сеңлесе бармыни?

**Люция.** Бар инде шунда... Ияреп йөри торган... Игътибарга алма. (*Бер-берсенә туп-туры карап бииләр.*)

Их, мәхәббәт, серле чишмә,
Мәңге шаулар суларың.
Суларының агышлары
Алып китте елларым.

Кушымта: Тир-там, тир-там,
Җырлагыз, кызлар.
Күзләремә балкып тулган
Кечке йолдызлар,
Кечке йолдызлар.
Синең мине, минем сине
Яндырыр чагым.
Йөрәкләрне җылытадыр
Сөю учагы,
Сөю учагы.

**Люция.** Ваня, син шундый яхшы егет...

**Иван.** Белмим инде...

**Люция.** Син яхшы егет... Ә киемеңә бөтенләй игътибар итмисең...

**Иван.** Хикмәт киемдәмени, Люция?

**Люция.** Киемдә шул. Хәтерләмәдеңмени: мәктәптә беренче булып джинсы чалбар кигән малайлар артыннан кызлар өерләре белән йөрделәр.

**Иван.** Йөрсеннәр. Миңа кызлар өерләре белән кирәкми. Берсе дә әйләнеп чыккан.

**Люция.** Юләр син. Яисә юләр булып кыланасың.

**Иван.** Юләрлегем бардыр, кыла-нуым да.

**Люция.** Шулай да син бу ямаулы терсәкле костюмыңны кимә әле.

**Иван.** Сез Рафаэль белән сүз берләшкәнсез, ахры...

**Люция.** Синең урыныңда булсам, мин Рафаэльгә дә теләсә нәрсә әйттермәс идем.

**Иван.** Сиңа минем урында булырга язмасын.

**Люция.** Ник алай дисең?

**Иван.** Үзең уйлап кара. Син акыллы кыз бит.

**Люция.** Уйлап карармын. (*Паузадан соң.*) Ваня, әти-әниең кем булып эшли синең?

**Иван** (*көттереп*). Юк алар.

**Люция.** Ничек юк?

**Иван.** Әти үлгән, әни Үзбәкстанга кияүгә чыгып киткән. Әби белән бергә яшибез.

**Люция.** Гафу ит мине... белмәгән идем...

**Иван.** Гафу үтенерлек әйбер юк. Мин синең ниятеңнең изге икәнен аңладым.

**Люция.** Рәхмәт. Күңелең яхшы синең. Рәнҗи белмисең...

**Иван.** Әллә инде... Ә пинҗәк... әтинеке ул. Әти пинҗәге...

**Алар биеп арткы планга күчәләр. Гүзәлне кулыннан сөйрәп Рафаэль керә.**

**Рафаэль** (*ачулы*). Ник килдең?!

**Гүзәл** (*йотылып карап*). Сине генә, сине генә күрергә...

**Рафаэль.** Мин сиңа беркөнне аңлатып әйттем кебек.

**Гүзәл.** Мин бит берегезгә дә комачауламыйм. (*Ялварып.*) Рафаэль, җаным, шушында басып торырга гына рөхсәт ит. (*Рафаэль аның янагына чаба, Гүзәл янагын тота, ләкин еламый.*)

**Рафаэль.** Ычкын, тотып яргансы.

**Гүзәл.** Нинди каты синең кулың... Миңа берни дә кирәкми. Синең яныңда синә гына карап торам. Мин бит сине яратам!

**Рафаэль.** Нинди ярату сиңа?! Борын астың кипмәгән.

**Гүзәл.** Башта алай дими иден бит...

Рафаэль. Үпкән-кочкан — жилгә очкан.

Римма (*бии-бии килеп*). Гүзәл, ялынма шуңа. Әйдә безнең белән. (*Аны үзләре уртасына ала. Жыр көчәя.*)

Жирдә учак, күктә йолдыз,
Йөрәгемдә син генә.
Их, мәхәббәт, серле чишмә,
Мәңге, мәңге сүрелмә.
Кушымта: Тир-там, тир-там,
Жырлагыз, кызлар,
Күзләремә балкып тулган
Кичке йолдызлар,
Кичке йолдызлар.
Синең мине, минем сине
Яндырыр чагым.
Йөрәкләрне жылытадыр
Сөю учагы,
Сөю учагы.

**Алгы планда Иван белән Гүзәл.**

Иван. Гафу итегез, сез кем?

Гүзәл (*эре, горур*). Мин йолкышлар белән эш итмим.

Иван. Кем йолкышрактыр бит...

Гүзәл. Миңа алай итеп карама.

Иван. Сез артык чибәр.

Гүзәл. Анысын үзем дә беләм.

Иван. Нигә сез сөйләшергә теләмисез?

Гүзәл. Теләмәгәнгә. Якын килмә, синең кебекләрне мин көненә өчне борып жибәрәм. (*Югала.*)

Римма (*якынлашып*). Гүзәл янагыннан ут күрсәтмәсен.

Иван. Ник?

Римма. Ә ул күп сорап тормый.

Иван. Кем соң ул?

Римма. Колхоз председателе кызы.

**Биюдән барысы да туктыйлар. Ләйлә елап жибәрә.**

Иван. Ләйлә, ни булды?

**Аны барысы да уратып алалар.**

Ләйлә (*яшь аралаш көлеп*). Беләсезме нәрсә?

Римма. Нәрсә?

Ләйлә. Без нинди бәхетле!

Дамир. Шуның өчен елыйсыңмы?

Ләйлә. Шатлыктан еларга ярамыймыни?

Римма. Дөрес. Тормыш шундый матур!

Рафаэль. Әйт бер сүз, Дамир.

Дамир. Мин телдән калдым.

Римма. Карагыз әле, йолдызлар нинди матур. Әйдә һәркайсыбыз бүген шушында үз йолдызыбызны билгеләп куйыйк.

Дамир. Әнә минем йолдыз.

Рафаэль. Әгәр барыгыз да бер үк йолдызны билгеләсәгез?

Иван. Башта билгелик әле, аннары тикшерербез.

Рафаэль. Керәшеннәрнең йолдызы керәле дә чыгалы ди.

Ләйлә. Тормыш нинди матур! Яшәү ничек рәхәт! Юк, сез барыбер аңламыйсыз...

Иван. Аңлыйбыз, Ләйлә, аңлыйбыз.

Дамир. Минем йолдыз Рафаэльнеке белән янәшә булачак. Әгәр аеры булса, мин риза-бәхил түгел.

Рафаэль. Рәхмәт, дустым.

Люция. Ә минем йолдызым юк.

Ләйлә. Күк тулы йолдыз бит! Сайла берсен.

Люция. Әти-әниең укытучы булмасын икән. Алар минем өчен барысын да сайлаган инде. Мин быел Казан пединститутының физика-математика факультетына укырга керәчәкмен. Шамил Усманов урамында бер квартирада торачакмын. Укуны бетергәч, Чаллыга эшкә жибәрәчәкләр. Практиканы үзебезнең авылда үтәчәкмен.

Римма. Бәхетле кеше син.

Люция. Мин иң бәхетсез кеше...

Дамир. Бәхетле—бәхетсез. Ташлагыз әле шундый гомуми сүзләрне. Миңа хәзергесе моментта безнең барыбызга да рәхәт бит, шулаймы?

**"Әйе, әйе! Рәхәт!" дигән тавышлар ишетелә.**

Римма. Әйдәгез жырлыйк.

Дамир. Була ул. (*Дамир уйный, барысы да "Ай, былбылым"ны жырлыйлар.*)

Ләйлә. Уйланып карагыз әле, унбер ел элек без менә шушының буе юеш борыннар идек. Ә хәзер зур кешеләр. Ничек тиз үткән дә киткән гомер... Беренче мәртәбә курка-курка мәктәпкә килүем бүгенгедәй хәтеремдә.

Дамир. Синең акырып елаган тавышың һаман колакта шул.

Ләйлә. Рәхәтләнеп еладым. Анда сезнең кебек әйбәт кешеләр, ягымлы укытучылар барын кем белгән.

Рафаэль. Римма дәрестә гел лач-лоч ашап утыра иде.

Римма. Ә син күпме елаттың безне?

Рафаэль. Абыегызны тыңларга кирәк иде.

Ләйлә. Нинди абый ди син безгә?

Рафаэль. Мин январь аенда туганмын. Шуннан соң гына сез дөньяга килә башлагансыз.

Дамир. Аңладыгызмы инде?

Рафаэль (*Ләйләгә*). Кулдагы менә бу җөйне таныйсыңмы?

Ләйлә. Безнең этне кыйнамаска иден.

Рафаэль. Тешләк!

Люция. Миңа нишләптер күңелсез була башлады.

Рафаэль. Табын янына утырыйк

дигән сүз бу, җәмәгать.

Ләйлә. Әйдәгез тагын бер җырлыйк әле.

Рафаэль. Ләйлә, минем ике әйтмәгәнне беләсең бит. Табынга! (*Барысы да Римма әзерләгән ризыклар тирәсенә җыелалар, утырышалар, чүгәлиләр, тезләнәләр.*)

Рафаэль (*Иванга*). Әй, сыйфат билгеле терсәк, сиңа аерым чакыру кирәкмени?

Иван. Кызлар утырып бетсен әле...

Ләйлә. Син бигрәк инде, Рафаэль.

Рафаэль. Шаяртканны да гаеп итмәгез әле. Гадәтемне беләсез, йә ачуланырмын.

**Римма Гүзәлне җитәкләп алып килә.**

Рафаэль. Бусы нәрсә тагы?

Римма. Утырсын инде, Рафаэль.

Рафаэль. Кайтып китсен. Ул бит безнең "Мәмкәләр җәмгыяте" әгъзасы түгел.

Гүзәл (*читкә китеп*). Мин шушында гына торам... Кума гына...

Иван. Кешеләрчә түгел бу.

Дамир. Ә бездә Рафаэль әйткәнне тикшермиләр.

Ләйлә. Һәр нәрсәнең чиге бар...

Рафаэль. Җитте! (*Стаканнарга шәраб сала.*) Ни өчен эчәбез?

Дамир. Рафаэль белән Люциянең Таһир белән Зөһрәнеке кебек кайнар мәхәббәте өчен!

Тавышлар: —Әйдәгез!

—Әйдә!

—Мәңгелек мәхәббәт өчен!

Рафаэль. Юк, син ашыктың, Дамир. Һәр нәрсәнең чираты бар.

Дамир. Аңладым, шеф. Әйдәгез барлык хыялларыбыз тормышка ашсын өчен!

Рафаэль. Туктагыз! Минем башка шәп идея килде. Һәркем үзенең иң кадерле теләген әйтсен.

Римма. Кызык бу!

Рафаэль. Ягез? Дамир әйтте.

Ләйлә. Мин әйтәм. Кеше көләсе килсә елаган булып, еласы килсә көлгән булып кыланмасын иде.

Рафаэль. Римма?

Римма. Барыбыз да кимендә туксан яшькә җитсәк, гел очрашып яшәсәк иде.

Дамир. Әйбәт, молодец!

Рафаэль. Люция?

Люция. Кеше ни тели, шуны эшли алсын.

Рафаэль. Иван дәдәй ни әйтә?

Иван. Сезнең барыгызның да әйткән теләкләре искиткеч матур... Шулар чынга ашса, мин бәхетле булыр идем.

Дамир. Тагын бәхет сүзе калыкты.

Рафаэль. Әйдәгез. Барысы өчен дә.

Римма. Ә үзең?

Рафаэль. Алла өчен. Кешеләрнең Алласы булсын өчен!

Дамир. Менә ул иң яхшы тост! Эчик!

Рафаэль. Туктагыз әле. Әйткән сүзләребез артык җитди булды. Һәркем бер шаян тост әйтсен.

Люция. Раф!

Рафаэль. Әү, революциям!

Люция. Купкә китте.

Рафаэль. Ишеттегезме? Люция эчик ди. Димәк, эчәбез.

**Чәкештерәләр. Римма, Люция, Дамир, Рафаэль эчеп куя, Ләйлә бер йота, Иван стаканын читкә куя.**

Рафаэль (*Иванга*). Аңламадым.

Иван. Мин эчмим.

Дамир. Ялгышасың, Ваня.

Римма. Алай ярамый!

Люция. Егетләрнең дәрәҗәсен төшермә.

Иван. Үпкәләмәгез, эчкәнем юк.

Дамир. Эчкәнең булмагач, бигрәк тә шәп. Син аны бер эчеп карасаңмы!

Иван. Эчмим, кыстамагыз. Әйдәгез җырлыйк әле.

Ләйлә. Әйе, җырлыйбыз, җырлыйбыз!

Дамир (*гитарасын чиертеп*). Нинди җыр?

Рафаэль (*аның гитарасын тартып ала*). Юк инде, болай булмый. Эч, керәшенкәй.

Иван. Чынлап әйтәм, эчкәнем юк.

Рафаэль. Ә син эчеп кара.

Иван. Юк, эчеп карамыйм.

Рафаэль. Сине "Мәмкәләр җәмгыяте"нә алдык. Шулай булгач, эчәсең. (*Стаканны аның авызына китерә, Иван стаканны ала, ләкин эчми.*)

Иван. Эчмим.

Рафаэль. Алайса ник сүз әйттең? Ник чәкештердең?

Иван. Ул тыеламыни?

Рафаэль. Безнең җәмгыятьтә андый нәрсә булмый.

Римма. Эч инде, Ваня.

Люция. Рафаэль барыбер эчермичә калмый ул...

Иван. Эчмим.

Рафаэль. "Суфый суган сөймәс" кебек түгелләр бит?

Иван. Мин беркайчан да, бер генә мәртәбә дә спиртлы эчемлек капмаска сүз бирдем.

Рафаэль. Кемгә?

Иван. Үземә. Мәңге, үз гомеремә бер мәртәбә дә.

Рафаэль. Алайса бер мәртәбә йот.

Иван. Юк, йотмыйм.

Рафаэль. Минем ачу килә башлады.

Ләйлә (*Ваняны кочаклап*). Бер генә йот. Үтенәм.

Иван. Кыстама, Ләйлә. Тамчы да капмыйм. Әгәр үз сүземне үзем бозам икән, нинди кеше булам ди мин?

Рафаэль. Димәк, эчмисең?

Иван. Эчмим.

Рафаэль. Яхшы. Ул чакта болай була. (*Стаканын ала да Иванның башына акрын гына агызырга тотына.*)

Ләйлә. Рафаэль, кирәкми! (*Кулына үрелә, ләкин аны Дамир тотып кала.*)

Дамир. Дустыма комачаулама.

Ләйлә. Өстен пычратасың!..

Рафаэль. Иске пинжәкнең кай җире пычрансын аның?

Люция. Тукта, Раф!

Рафаэль (*агызып бетереп*). Менә булды.

**Башын иеп хәрәкәтсез утырган Иван әкрен генә урыныннан торып баса, читкә китеп битләрен, муеннарын кульяулык белән сөртә. Куак арасына кереп китә. Ләйлә аңа омтыла, тик Дамир җибәрми.**

Ләйлә. Ул кайтып китә.

Дамир. Китсен.

**Шулчак куак арасыннан кулына балта тоткан Иван Рафаэльнең арт ягына атылып чыга һәм аңа ике куллап балтасы белән кизәнә. Кинәт Гүзәл кыргый тавыш белән кычкырып җибәрә дә Рафаэльны үзенең гәүдәсе белән каплый. Иван шашынып туктап кала. Шуннан файдаланып, Дамир аны этеп ега, өстенә ята.**

Дамир. Син нәрсә?!

Иван. Җибәр! Рафаэль (*балтаны әләктерә*). Әйдә кил әле...

**Кызлар аларны урап алалар. Люция Рафаэльнең балтасын читкә алып ыргыта. Римма аны тынычландыра, үбә. Ләйлә Иванны тынычландыра.**

Рафаэль. Хәзер үк гафу үтен!

Иван. Кемнән? Синнәнме? Үлгәндә дә үтенмәячәкмен.

Рафаэль. Син хәзер елый-елый гафу үтенәчәксең.

Иван. Мин үземнән түбән кешедән гафу үтенмим.

Рафаэль. Шулаймы?! (*Ул Иванга ташланмакчы була, аны Дамир, Люция, Римма тотып калалар да, куак арасына алып кереп китәләр. Гүзәл дә аларга ияре. Авыр пауза.*)

Ләйлә. Ваня, син нишләдең?!

Иван. Белмим...

Ләйлә. Син бит аны куркытырга гына теләдең, шулаймы?

Иван. Куркытырга? Юк...

Ләйлә. Алай димә! Ул сине рәнҗетте. Син аның бөтенебез каршында калтырап төшүен теләдең. Шулай бит?

Иван. Юк, Ләйлә. Мин аңа балта белән чаба идем. Нәкъ башына, бүтән җиренә түгел.

Ләйлә. Ни сөйлисең?! Бу бит коточкыч!

Иван (*акрын*). Әйе, коточкыч...

Ләйлә. Менә хәзер шушында Рафаэль кан эчендә үлеп ятса?..

Иван. Мин шуны теләдем.

Ләйлә. Ә хәзер?

Иван. Хәзерме... әллә инде...

Ләйлә. Мин сине белмәгәнмен икән... Син кеше үтерергә сәләтле... Коточкыч! Коточкыч бит бу!

Иван. Әйе, коточкыч...

Ләйлә. Мин синнән куркам... Ваня, ишетәсеңме, мин синнән куркам! (*Елый.*) Хуш! Мәңгегә хуш! (*Чыгып йөгерә.*)

Иван. Ләйлә, тукта! (*Аның артыннан йөгерә.*)

**Дамир һәм Римма керә.**

Римма. Минем һаман тез буыннарым калтырый. Иван аны үтергән булса?

Дамир. Бәлки шулай кирәк булгандыр?

Римма. Яратмыйм урынсыз шаяртуыңны.

Дамир. Мин шаяртмыйм.

Римма (*аның күзләренә текәлеп*). Син... аны...

Дамир. Әнә учак сүнә, утын өстик әле. (*Учакка утын өсти.*)

Римма. Мин синең чын сөйләвеңне аңладым. Син дустыңа үлем телисең... Башка сыярлык түгел...

Дамир. Әгәр мин юри әйтсәм?

Римма. Ник?

Дамир. Синең аның өчен януыңны күрү өчен.

Римма. Безнең арада берни дә юк.

Дамир. Белми дип уйлама. Мин әллә кайчаннан сизеп йөрим...

Римма. Нәрсә сизәсең?

Дамир. Берни дә юкмыни?

Римма. Берни дә юк шул.

Дамир. Ә нишләп бая үбешеп тора идегез?

Римма. Үбешеп?! Ә-ә-ә! (*Көлеп җибәрә.*) Ул бераз шаяртты шунда.

Дамир. Шаярткан... Синме шаярттырып торасың. Бу сүзләрне әбиеңә сөйлә. Әйт, ни бар сезнең арада?

Римма. Хатының булгач, сорау алырсың. Әнә Иван белән Ләйлә килә.

**Алар ашыгып чыга, Иван белән Ләйлә керә.**

Иван. Әйе, хәзер миңа ни әйтсән дә була. Тик мин бандит та, кеше үтерүче дә түгел. Ә инде төптәнрәк уйлап караганда, бу хәлнең килеп чыгуына син сәбәпче.

Ләйлә. Шулайдыр, балтаны ку-

лына мин тоттырдым бит.

Иван. Мин сине уйладым. Күз алдымда син генә тордың. Үземне дә, хәтта әбине дә, ни булачагын да белештермәдем.

Ләйлә. Шушы йолдызлар астында... Сандугачлар сайраганда...

Иван. Алар берсе дә юк минем өчен. Аңлыйсыңмы, юк!

Ләйлә. Бар, аларны беркем дә юкка чыгара алмый.

Иван. Мине син үзең генә биләдең, дөньяны томаладың. Синнән башка берни дә, хәтта үзем дә калмадым.

Ләйлә. Алай була алмый.

Иван. Була, Ләйлә, була! Аның һәр сүзе сиңа барып тиде.

Ләйлә. Ул миңа берни дә әйтмәде.

Иван. Аңла: мин юк идем, минем урында син генә идең. Ул сине рәнҗетте, сине кимсетте... Мин түздем... Тешемне кысып түздем... Әгәр үземне кимсеткән булса, һәммәсен дә күтәрер идем. Тик мин юк идем, минем урында син идең...

Ләйлә (*уйчан*). Барыбер... Ничек кенә булса да... Үтерү... юк, мин синнән куркам. Без башка беркайчан да очраша алмыйбыз. Хуш...

Иван. Шуны бел: әгәр без... син шулай теләсәң... Үзең үтерүче булачаксың.

Ләйлә. Мин үтерүче?!

Иван. Әйе... мине. (*Озын пауза.*)

Ләйлә. Син минем күңел түрендәге иң изге нәрсәмне җимердең. Ул мине мәңге сискәндереп торачак. Юк, юк, без хәзер чит кешеләр.

Иван. Үтерәсең алайса?

Ләйлә. Әгәр мин сине яратмый башласам?

Иван. Менә мин күптән көткән иң куркыныч сүзләр. Син ул сүзләрне әйтергә кыенсынып йөрдең. Хәзер сәбәп табылгач...

Ләйлә. Мин бит әле сиңа сорау гына бирдем.

Иван. Юк, Ләйлә, син сорау гына бирмәдең. Аның җавабы да шушы сорауның эчендә. Бөтенесе җимерелде... алдашу үтте... Мин җирдә иң бәхетле кеше идем... Хәер, мин юк идем.

Ләйлә. Мин синең уеңны гына белергә теләдем.

Иван. Нинди әшәкелек... Кешене бәхетле һәм бәхетсез итү. Кешене үзең тудыру һәм үзең үк үтерү... Юк, юк, кичерә күр, бу минем уйларым, минем сүзләрем түгел.

Ләйлә. Мине гаепләмәкче буласың... Юкка, Ваня.

Иван. Мин сиңа рәхмәт әйтергә тиеш. Башкага хакым юк. (*Акрын гына чыга башлый.*)

Ләйлә. Тукта, син кая барасың?

Иван. Курыкма... мин хәзер берниндн юләрлек тә кылмаячакмын. Зиһене эшли башлаган кеше юләр адым ясамый. Йөрәк кенә үлде... Мәңгегә...

**Иван чыга, Ләйлә ни калырга, ни китәргә белми, ахырда аның артыннан иярә. Дамир белән Римма керә.**

Римма. Дамир, син үзеңнең кем икәнеңне беләсеңме?

Дамир. Кем?

Римма. Кабахәт кеше син.

Дамир. Әйдә, аңлатып бир.

Римма. Син Рафаэльгә багышлап шигырь язасың. Аның өчен утка керергә әзер икәнлегеңне һәркайда сиздереп торасың. Ә үзең анардан көнләшәсең... Хәтта, әйтергә дә куркыныч, үлемен телисең...

Дамир. Ялгышасың, мин анардан көнләшмим.

Римма. Көнләшмәгәч?

Дамир. Мин куркам аннан.

Римма. Дус кешедән курыкмыйлар.

Дамир. Син безне чыннан да дус дип уйлыйсыңмы?

Римма. Әллә нинди сүзләр сөйлисең.

Дамир. Син аның кулына эләксәң... Аннан да рәхимсез кеше юк...

Римма. Ул сине кыйныймыни?

Дамир. Хәзер юк инде. Ә элегрәк...

Римма. Нишләп?

Дамир. Баш бирмәгәнгә. Анардан өстен чыкканга. Мәктәптә узган бер кичәдә мин гитарада уйнадым, җырладым, биедем, шигырь сөйләдем. Шул кичәдән чыккач, ул мине "әйдә тау башыннан әйләнеп килик" дип алып китте. Таугa менгәч, фәлән кызга күз аттың, төгән кызга күз аттың дип бәйләнә башлады. Сугышып киттек. Хәер, нинди сугышу ди! Мине әйләндерә дә сала, әйләндерә дә сала. Яңадан минем рөхсәттән башка тының чыкмасын ди. Беркайда да, беркайчан да ди. "Син кем соң?" дидем. Ә ул җавап урынына, авызга тибеп, ике тешне сындырды.

Римма. Ник беркемгә дә әйтмәдең?

Дамир. Әйтеп кара... Ул кушсын гына... Аның һәр класста үз егетләре бар.

Римма. Курыккансың, димәк.

Дамир. Курыкмадым. Ул миннән көчле. Ә мин нишли алам? Миңа имгәнеп, эштән чыгып бетәргә идемени?

Римма. Мин сезнең барыгызны да гөнаһсыз, беркатлы дип йөри идем. Сиңа рәхәтме шушылай?

Дамир. Син үзең дә минем халдә бит.

Римма. Юк.

Дамир. Бая көчләп үпте диден. Ник каршымадың соң?

Римма. Каршысым килмәде. Анарда ниндидер кыргый көч бар. Шул көч үзенә тарта.

Дамир. Ә миндә?

Римма. Синдә, Дамир, барысы да бар.

Дамир. Аңлашылды... Рафаэльне яратасың, димәк...

Римма. Кайчан мин аны яратам дидем?

Дамир. Әле генә әйттең бит.

Римма. Мин аны яратам димәдем.

Дамир. Кемне яратасың соң син?

Римма. Бәлкем синедер...

Дамир. Алайса бер үп әле мине.

Римма (*иренен аның иренен тигереп ала*). Син канәгатьме?

Дамир. Иреннәреңә әллә ни булган. Боз кебек салкыннар...

Римма. Вакыты җиткәч, җылыныр әле...

**Рафаэль белән Люция керә, бер читтә Гүзәл күренә.**

Рафаэль. Без инде сезне кайтып киткәнсездер дип уйлаган идек.

Дамир. Сезне ташлапмы?

Рафаэль. Кайда теге псих?

Дамир. Күренмәделәр.

Рафаэль. Әйдә бер җырлыйк әле.

Дамир (*Ул гитара чиертеп җырлый башлый. Аңа Рафаэль кушыла.*)

Тир-там, тир-там,
Җырлагыз, кызлар.
Күзләремә балкып тулган
Кичке йолдызлар,
Кичке йолдызлар.
Синең мине, минем сине
Яндырыр чагым.
Йөрәкләрне җылытадыр
Сөю учагы,
Сөю учагы.

Рафаэль. Кызлар, ник җырламыйсыз?

**Кабат җыр башлыйлар. Римма кушыла. Кинәт Люция Дамирның гитарасын тотып туктата.**

Люция. Сау булыгыз. (*Чыга башлый.*)

Рафаэль (*аны туктатып*). Син кая?

Люция. Өйгә.

Рафаэль. Ничек инде берүзең?

Люция. Мин курыкмыйм. Бүген мин биш яшькә олыгайдым.

Рафаэль. Хәзер мотоциклны кабызам.

Люция. Минем ялгызым кайтасым килә. Ә мотоциклыңа аны утырт.

Рафаэль. Кемне?

Люция (*Гүзәлгә ымлап*). Аны. Сине беркайчан да, беркем дә аның кебек ярата алмаячак, Рафаэль.

Рафаэль. Ә син соң, син?!

Люция. Ачыктан-ачык әйтер идем дә, икебез генә түгел.

Дамир. Без читкә китәбез. (*Кузгалалар.*)

Рафаэль. Туктагыз, беркая да китмисез. Әйт, алар барында әйт.

Люция. Әйтәм, тик үпкәләштән булмасын. Мин болай гына... вакыт кына уздырдым. Кичерә алсаң, кичер...

Римма. Син бит алдашасың, Люция. Теге чакта Рафаэль күрше авыл кызын озата башлагач, елый-елый артыннан йөрдең.

Люция. Мин сиңа кызыга идем. Мәктәптә бер егет. Миңа бернинди ирек юк, көндез дә, кич тә, өйдә дә, урамда да, мәктәптә дә. Хәтта телевизор карау да әниләр рөхсәте белән генә. Син мине беренче мәртәбә озата кайттың. Качыппосып очраша башладык. Син минем барлык теләкләремне үтәдең. Гомеремдә беренче мәртәбә минем теләкләремне үтәүче бердәнбер кеше барлыкка килде. Ул — син идең. Бөтен мәктәп синең табан астыңда. Ә син минекендә... Бары шул гына. Нишлим соң — булмады... Яратырга тырышып карадым югыйсә...

Рафаэль. Юк, син болай кинәт кенә өзә алмыйсың.

Люция. Мин авылдан ук чыгып китәм. Еракка, еракка, әллә кая, теләсә кая...

**Иван, Ләйлә, Дамир, Римма керә.**

Иван. Гафу ит мине, Рафаэль.

Люция. Гафу үтенмә, Ваня! Сүзләреңне кире ал!

Иван. Алмыйм! Рафаэль, гафу ит...

Люция. Гафу үтенмә, юкса мин сине яратмый башлаячакмын...

Рафаэль. Нәрсә?!

Люция. Телдән ычкынды... Син, Ваня, моны барыбер белергә тиеш идең.

Иван. Кичерәсеңме, Рафаэль? (*Озын пауза.*)

Рафаэль. Юк...

Люция. Мәрхәмәтсез!

**Ләйлә китмәкче була.**

Иван. Ләйлә! (*Ләйлә туктый.*) Үкенмәссеңме?

Ләйлә. Үкенмәм, Ваня.

Иван. Мин сиңа... син үкенерсең әле... Мин барыбер күрсәтермен сиңа!..

*Пәрдә.*

# Икенче кисәк

**Беренче кисәк белән икенче кисәк арасында пәрдә ачылганчы "Зәңгәр күлмәк" жыры яңгырый.**

**Егерме ел вакыт узган.**

**Бай җиһазланган зур йортның кунак бүлмәсе. Алъяпкыч бәйләгән бер хатын ашыга-кабалана табын әзерли. Игътибар беләнрәк карасак, без аның Ләйлә икәнен танырбыз. Ишектә Римма күренә. Ул шактый юанайган.**

Римма. Әле һаман беркем дә юкмыни?

Ләйлә. Люция кайтты.

Римма. Кит?! Кайда ул, кочаклап кысып үтерәм!

Ләйлә. Ваннада, юл бик мәшәкатьле булды ди. Йә, ничек?

Римма. Сабын күбеге эчендә булса да күреп чыгыйм әле.

Ләйлә. Дамир Рафаэльләр белән бакчага гына чыкты. Алар кергәнче әйтеп кал. (*Пышылдап.*) Кайтуы хакмы?

Римма. Хак.

Ләйлә. Күрдеңме соң?

Римма. Күрдем. Сакал-мыек җибәргән, чәчләре ап-ак. Үзе ябык...

Ләйлә. Мескен...

Римма. Ваня дип дәшәргә дә белмим. Иван дисән дә мәзәк. Кочаклап алды. Мин "исәнме" дим, ә ул колагыма "рәхмәт" ди. Әллә пышылдый, әллә үкси шунда...

Ләйлә. Минe сорадымы?

Римма. Юк, Ләйлә, сорамады. Син җибәргәнне үзем әйттем.

Ләйлә. Соң?

Римма. Сүзсез генә тыңлады.

Ләйлә. Безнен очрашуга ни диде?

Римма. Чакыруны алган. Барысына да сәлам тапшыр ди, үзе көлә. Аннары кинәт житдиләнде. Юк, сәлам тапшырма, кайтканымны беркемгә дә әйтмә, диде...

Ләйлә. Килми инде алайса...

Римма. Ничек килсен, ничек килсен инде ул?! Баштук әйттем лә мин сиңа. (*Пауза.*)

Ләйлә. Хәер, килмәве әйбәтрәктер дә, бәлкем...

Римма. Тормышлар бик яхшы ди, һәммәсе дә әйбәт ди...

Ләйлә. Урта Азиядә тапкан икән бәхетен...

Римма. Их, Ләйлә, нинди бәхет ди ул! (*Елый.*)

Ләйлә. Әле генә әйттең ич...

Римма. Мин барганда әбисенең каберенә чардуган куярга киткән иде. Әбисенең сенлесе белән сөйләшеп утырдык. Чәйләр, конфетлар куйгач, тәмам теле ачылды. Беркемгә дә әйтмәскә кушты: Иван бит япа-ялгыз калган.

Ләйлә. Аерылышканнармыни?!

Римма. Ул командировкага киткәч, өйдә газ шартлаган. Хатыны, ике баласы янып үлгән.

Ләйлә. Бичара!..

Римма. Мина үзе берни сиздермәде. Мескен булып күренәсе килмидер инде.

Ләйлә. Кайчан булган соң бу?..

Римма. Әле ярты ел да юк... Мафия эше ди. Ул аларның эзенә төшкән булган. Үзен ана кадәр машина белән бәрдергәннәр. Башы ярылган, кабыргалары сынган, бер аягы аксый...

**Дамир, Рафаэль, кулына сары чәчәк яфраклары тоткан Гүзәл керә. Дамир төз гәүдәле, чәчләре чигә турлап шактый чаларган, костюм-чалбары үтә дә купшы. Галстуктан, күкрәгендә депутат значогы. Гүзәл корып кипкән, бик нык картайган. Без аны яшь чактагыча борын чөюеннән генә таныйбыз. Ул гел Рафаэль янында бөтерелә. Рафаэль корсак үстергән, башында шактый зур пеләше бар, күз төпләрендә капчыклар, чырае кызыл. Ул бераз кызмача. Күлмәк якасы ычкындырылган, галстугы әле бер, әле икенче якка күчә. Гүзәл аны гел төзәтеп тора. Төзәткәндә Рафаэльгә карап елмая, әмма тегесе күп очракта битараф кала. Рафаэль туктаусыз ашый, кикерә, чытырдатып сөяк кимерә. Гүзәл аның битеннән дә, пеләшеннән дә тирен сөртеп тора.**

Дамир. О-о-о, Төмән кунагы да кайтып житкән икән! Әйдәле, яшь чакларны искә төшерик... (*Аны кочаклый, үпмәкче була, ләкин Римма аның кочагыннан шуып чыга.*)

Римма. Үтте инде, үтте ул чаклар!..

Гүзәл. Молодец, Римма. (*Алар кочаклашалар.*)

Рафаэль (*кочагын җәеп*). Әйдәле, Риммакаем...

Римма. Болай гына күрешәбез, Рафаэль. Үзем юанайдым —юан кешене женем сөйми.

Рафаэль. Ярар, хәерле каза булсын. (*Күрешәләр.*)

Дамир. (*Ләйләгә*). Люция кайтты дигән иден... Әллә шаярттың гына инде...

Ләйлә. Хәзер. (*Ул ягындагы ишеккә кереп китә.*)

Гүзәл. Мәктәпне бетергәннән бирле күргәнем юк минем аны.

Дамир. Әти-әнисе күчеп киткәч, безнен якларны онытты шул.

**Горур атлап Люция, аның артыннан Ләйлә чыга. Люциянең жемелдәп торучы алтын алкаларыннан, муенсаларыннан, беләзекләреннән бүлмә яктырып киткәндәй була. Аның йөзендә бер генә жыерчык та юк, чәчләре дулкын-дулкын, тәненә сыланган затлы күлмәге елкылдап тора. Аны күргәч, барысы да авызларын ачып катып**

**калалар. Рафаэль галстугын төзәтә, ашыга-кабалана пеләшен тарый.**

Рафаэль. Япрысытклмны!
Дамир. Яшәргән, чибәрләнгән...
Люция. Исәнмесез...
Римма. Чәчәк аткансың бит син, малай! (*Аны кочаклап ала.*)
Люция (*Гүзәлгә*). Ә сезне... вроде таныш кебек...
Рафаэль. Гүзәл бит.
Люция (*гаҗәпләнеп*). Гүзәл?! Извини, танымадым... (*Күрешкәндә Гүзәлнең кулыннан берничә яфрагы төшә. Люция аларны житез генә алып Гүзәлгә суза.*)
Гүзәл. Алары сезгә булсын, Люция.
Люция. Рәхмәт. Гомерем буе сары төсне, кызларне яратмадым. Поэтому вынуждена вернуть.
Дамир. Ул яфракларны мин жыярга кушкан идем. (*Гүзәлдән һәм Люциядән яфракларны алып, пианино өстендәге вазага куя.*)
Люция (*Дамир белән күрешеп*). Ә син... әйбәт саклангансың.
Дамир. Суыткычтагы ит кебекме?
Люция. Как тушенка. Разный приправалар салып, довольно озак кайнатканга ошыйсын. (*Көлешәләр.*) За откровенность извини, Рафаэль. Башка урында очратсам, хоть убей, не узнала бы тебя. (*Күрешәләр.*)
Рафаэль. Егет үзе картаймаса, дөнья картайта икән шу-у-ул!
Римма. Егерме ел аз вакыт түгел.
Лэйлә. Әйе, әйтергә генә ансат.
Рафаэль. Авыл картайта кешене.
Дамир. Перифирия дип тә өстә. Мәскәү Мәскәү инде ул.
Люция. Нет, друзья, Мәскәүдә дә нелегко. Там тоже — кто кого.
Гүзәл. Шулай да син яп-яшь...
Люция. Әйтимме картаймау серен, не надо ограничивать себя ничем.
Дамир. Нишләп без аягүрә торабыз соң әле?
Рафаэль. Утырырга кушучы юк бит, Дамир Заманович.
Лэйлә. Әйдәгез, табынга рәхим итегез.
Гүзәл. Без монда, читкәрәк утырабыз.
Люция. Яратмыйм табында да урын билгеләүне. В жизни и так разделено по рангам. (*Табынның иң түренә кереп утыра.*) Кил, Гүзәл!
Гүзәл. Юк, кыен...
Дамир. Әнисе, мин Люция янына утырсам, сүзләмәссеңдер бит?
Лэйлә. Обкомолда эшләгәндә сүзләмәгәнне, хәзер сүзлимме соң инде...
Люция. Да! Какие были годы! Үкенечкә калмады. Менә коммунизм кайда иде ул!
Дамир.

Эчмә-тартма, беләсең килсә,
Коммунизмны күрәсең килсә.

Лэйлә. Коммунизм булгандыр шул, өчәр тәүлек кайтып керми идең бит.
Дамир. Эш бит, әнисе, эш! Комсомол — гүзәл яшьлек, комсомоллар — ялкын йөрәкләр!
Лэйлә (*кулына рюмка алып*). Хөрмәтле мәмкәләр! Сезне жыюыма мин бик шат.
Дамир. "Мин" түгел, "без, без!"
Лэйлә. Ярый, без булсын. Аттестат алып таралышканга егерме ел үтте, ә безнең "Мәмкәләр жәмгыяте" исән.
Римма. Кем оештырган иде әле аны?

**Рафаэль басып баш ия, кул чабалар.**

Люция. Жәмгыятьнең бер кешесе юк бит.
Римма. Ул... ул булмаячак.
Лэйлә. Әйе, адресы билгесез...
Люция. Как жаль!
Рафаэль. Дамир Заманович! Бер сүз әйт инде.
Дамир. Нигә сүз? Барыбыз да исән-сау. Мин үзем шул кадәр сагындым барыгызны да. Иң бәхетле еллар бергә узган... Бер ана балалары шикелле. Инде кабат мәктәп стеналарына кайту мәнге юк. Тормыш юллары безне ешрак очраштырсын иде. Әйдәгез, шуның өчен.
Рафаэль. Амин, шулай булсын!
Люция. Почему-то стало грустно...

**Эчәләр. Лэйлә белән Дамир кунакларга салат бүләләр.**

Дамир. Лэйләнең салатын авыз иткән кеше мәнге картаймый.
Люция. Менә ни өчен бодрый син!
Дамир. А как же!
Гүзәл. Ышана алмыйм... Күпме елдан соң шундый очрашу...
Римма. Мәмкәләр, салат чыннан да теленне йотарлык бит!
Люция. Әнә Рафаэль телен йотып та жибәрде.
Рафаэль (*тулы авызы белән*). Ым-ма...
Лэйлә. Сез килештерерсез инде.
Люция. Тартырга мөмкинме?
Дамир. Әлбәттә, әлбәттә.
Рафаэль. Ә мина, Дамир Заманович? Мөмкинме?
Гүзәл. Дамир Замановичның тәмәке исен яратмаганын беләсең бит...
Люция. Нәрсә сез "Заманович та Заманович?!" Подумаешь, хозяин района! (*Дамирга тәмәке тәтенс өрә.*) Әллә син махровый бюрократка әйләнеп беттеңме?
Дамир. Люция, син нәрсә?
Люция. Смотри, безнең мәмкәләрне обижать итсән!

Рафаэль. Обижать итми, итми... (*Тәмәкесен пианино өстенә куя.*)

Дамир. Әйтерсең, мине белмисең.

Люция. Яхшы белгәнгә әйтәм дә. И предупреждаю вполне серьезно: анда минем шундый кешеләр бар... Бер сүз әйтәм — иртәгә син булмыйсың.

Дамир. Ышанам, Люция...

Рафаэль. Әллә-лә-лә!

Гүзәл. Син кем булып эшлисең соң, Люция?

Люция. Какое это имеет значение? Әти белән әни мине шундый итеп тәрбияләргә теләде. По-коммунистически. Исемнәрен генә карагыз: ике братның берсе Рево, икенчесе Резо исемле. Минеке белән кушкач, Революция белән Резолюция килеп чыга. Әгәр алар интектермәсәләр, өйдән чыгып та качмас идем. Всю жизнь ходить в пионерах? Боже упаси! Ну, давайте, чтобы веселле было. (*Рюмкасын ала.*)

Рафаэль. Ике сыңар — бер пар. (*Икесе эчеп куялар*)

Люция. Безне поддержать итмисезмени?

Дамир. Әйдәгез, без генә надан булып калмыйк. (*Эчәләр.*)

Люция. Вот рәхмәт. Йәгез сөйләгез, кем кайда, кем булды и так далее.

Ләйлә. Тик минем бер шартым бар, дөресен генә сөйләргә.

Дамир. Шушы тәкъдимгә кушылучыларның тавыш бирүләрен сорыйм.

Люция. Ой, настоящий бюрократ!

**Барысы да кул күтәрәләр.**

Дамир. Бертавыштан. Сүзне кемгә бирәбез?

Римма. Иң элек Рафаэль белән Гүзәл өйләнешкте. Алардан башлыйк.

Люция. Верно.

Рафаэль (*эчеп куя*). Кыюлык өчен. (*Аягүрә баса.*) Без инде бер малай, ике кыз үстердек. Әгәр аз дисәгез... (*Мактанып тамак кыра.*)

Гүзәл. Һи, мактанчык!

Рафаэль. Малай өйләнде, инде оныгыбыз бар.

Римма. Кырыкка да житмәгән әби белән бабай!

Рафаэль. Кызларның берсе техникумда, икенчесе үзебезнең мәктәптә укый.

Люция. Үзен, кажется, колхозом руководишь?

Рафаэль. Бабай пенсиягә киткәндә мине куйдылар. Дамир Заманович ярдәме белән, билгеле.

Дамир. Син үзең турында гына сөйлә.

Люция. Какой скромный! Вообще-то син, Рафаэль, Дамирчикка многим обязан. Теге чакта комсомол путевкасы белән авылга ул озатмаса, неизвестно чем бы кончился тот инцидент в общежитии института.

Дамир. Без дә төшеп калганнардан түгел. Бер кыз, бер малай үстердек.

Ләйлә. Ерактан кайткан кешене тынлыйк әле.

Римма. Күбегез белә инде, институтка керә алмагач, Әлмәткә киттем. Заводта эшләгәндә кияүгә чыктым. Төмән өлкәсендә төпләндек. Ирем нефтьче. Биш бала үстерәбез.

Люция. Вот это да!

Дамир. Институтка керә алмыйча авылга кайткач, мина хат язган булсаң, биш бала белән интекмәгән дә булыр идең.

Ләйлә. Син үзең көйсез ун балага торасың, ләбаса.

Рафаэль. Чират сиңа, Люция.

Люция. Сез миңа мактанышлыгыз... К сожолению, минем балалар булмады. Туристический бюрода эшлим. Пока не жалуюсь. Әти-әни Казанда. Изредка их навещаю.

Римма. (*фоторәсем күрсәтеп*). Сез миңа моны карагыз әле.

Ләйлә. Бу бит безнең беренче класста төшкән фоторәсем!

Рафаэль. Кая, кая!

Дамир. Экскурсиягә баргач, төшергәннәр иде.

**Барысы да Римманы чолгап алалар. Дамир кулын Люциянең биленә сала, Люция аны читкә алып куя.**

Ләйлә. Бусы син, Римма. Авызыңны карга кебек ачкансың, күзеңне йомып бетерә язгансың.

Римма. Үзеңне бел: чәчең авызыңа кергән.

Дамир. Аның урынына хәзер аның чәче минем ашказанына тула.

Люция. Ә бусы—мин.

Рафаэль. Карале басып торуын. Патша кызымыни.

Люция. А как же!

Римма. Арада иң горуры.

Дамир. Һәм иң үпкәчесе.

Люция. О-о-о! Карагыз әле: Дамирчик, син бит бу.

Гүзәл. Телен дә чыгармаган булса...

Дамир. Бүген карасыгызны белеп чыгардым мин аны. Сезне үртәп торам.

Люция. Ә Ваня кайсысы, Ваня?

Римма. Менә бит. Минем артка посып кына утырган.

Ләйлә. Йөзенең дә бер ягы капланган.

Дамир. Җәмәгать, без фоторәсем карарга гына жыелдыкмы әллә?

Рафаэль. Әйе шул. Әйдәгез утырышыйк, тамак төбе дә чатнап тора.

Гүзәл. Шундый кызык бит...

Римма. Ашыктырмагыз әле— өлгерербез. Мин каян кая алып кайттым.

Люция. Мин әтиләрне Казанга күчергән чорда Ваня райкомол секретаре дип ишеткән идем. Хәзер кайда?

Римма. Үзбәкстан якларында диләр.

Люция. Нишләп китте соң ул?

Рафаэль. Син аны һаман яратасың, ахры.

Люция. Рафаэль, на всю жизнь запомни: мин беркемне дә яратмыйм. Только үземне. Так что ярату исключается. Просто ошаган иде ул миңа. (*Лэйләгә.*) Менә ул сине үлеп ярата иде. А-а, дошло, сез Дамир белән кайтып төшкәч, түзә алмагандыр ул. Шулаймы? (*Пауза.*)

Лэйлә. Юк...

Дамир. Мин аңа ярдәм кулын күп суздым. Ул чакта райкомның идеология секретаре идем. Күпме көйләп карадым—чүпкә дә санамады, киңәшләремне тотмады.

Люция. Вроде андый түгел иде.

Дамир. Райкомолда чакта әле түздек. Читтән торып университет бетергәч, прокуратурага эшкә күчте. Менә шунда безнең йөрәккә ныклап тоз сала башлады да инде. Алны-ялны онытып эшләүче житәкчеләрдән кер эзләргә керешге. Ничә мәртәбәләр мин аңа дусларча әйтеп карадым, рәсми төстә дә мөрәҗәгать иттем. Ә ул мүкләк сыер төсле һаман үзенекен эшләде. Ул гына гадел, ул гына хакыйкатьне яклый.

Лэйлә. Тукта инде, ичмасам, Дамир!

Дамир. Туктыйм, карчык, туктыйм. Люциянең соравын җавапсыз калдыра алмыйм ла инде мин. Монда сабырсызланыр урын юк.

Люция. Үзбәкстанга, бәлкем, ул әнисен эзләп киткәндер?

Рафаэль. Эзләгән эзләми ни. Башта күрше районга күчте, аннары яңадан өч урынга житте. Башкортстаннан кугач, Үзбәкстанга...

Лэйлә. Син каян беләсең: куганнармы, юкмы...

Дамир. Бәлки кумаганнардыр да. Тик барыбер ала карга инде ул. Игелек күрсәтмәде. Ә без аны прокурор итәрбез дип уйлый идек. Бу хакта Рафаэльга да әйткәнем булды.

Рафаэль. Әйе, әйе.

Дамир. Үзе утырган ботакны үзе кискәч, ни хәл итәсең. (*Сәгатенә карап.*) Гафу итегез, әгәр сез рөхсәт итсәгез, минем шалтыратып аласым бар иде.

Рафаэль. Рөхсәт, рөхсәт.

Люция. Пожалуйста.

**Дамир чыга.**

Римма (*фоторәсемне күрсәтеп*). Әле сез бер кешене тапмадыгыз.

Рафаэль. Миндер ул.

Римма. Дөрес.

Гүзәл. Кайсы соң ул?

Римма. Әнә бит иң озыны.

Люция. Боже мой! Такой серьезный, маңгайларын җыерган.

Лэйлә. Маңгай җыерырга оста иде инде ул. Укытучы сорый, ә бу берни белми.

Люция. Точно!

Лэйлә. И җыера маңгаен, и җыера, үзе өскә карый.

Рафаэль. Арттырма инде.

Люция. Точно!

Римма. Имеш, белә, укыган, менә хәзер генә, шушы минутта гына оныткан.

Люция. Точно! Ха-ха-ха! Надан идең инде. Рафаэль, кара әле, шул кадәр наданлыгың белән как ты руководишь колхозом?

Гүзәл. Мыскыл итмә, Люция!

Люция. Причем монда мыскыл итү? Рафаэль математиканы белмәде, башка фәннәрне белмәде. Аның бер гаебе дә юк. Менә мин үзем надан, беркемнән дә оялмыйм. Оялырлык булсаң, укырга иде.

Рафаэль. Ялгышасың. Мин читтән торып авыл хуҗалыгы институтын бетердем. Дипломым бар.

Люция. Ә-ә, алайса син хәзер белемле икәнсең. Извини. Авыл гөрләп алга китә икән.

Рафаэль. Мин тартып керим әле. (***Пианино өстеннән тәмәкесен алып авызына каба.***)

Люция (***аның тәмәкесен авызыннан алып исни дә ыргыта***). Фу, гадость! Ничек тартасың моны? Туалет исләре килә.

Рафаэль. Тартмый нишлисең? Этә торган әйбер түгел...

Люция. Мә бер пачка.

Рафаэль. О-о-о! Чит илнеке! Рәхмәт.

Гүзәл. Салкын тигерә күрмә. (*Рафаэльның тирен сөртә, күлмәк якасын эләктерә.*)

Люция. Нәрсә син аны полировка тузанын сөрткән сыман гел сөртеп кенә торасың?

Рафаэль. Ярата, значится.

Гүзәл. Люция, Рафаэльга карата тагын берәр кимсетүле сүз әйтсәң, мин үпкәлим.

Люция. Вот это любовь! Извени, дорогая. Син бераз көнләшәсең дә, ахры. Что ни говори, без бит Рафаэль белән когда-то были друзьями.

Гүзәл. Көнләшмәгән кая ул...

Рафаэль. Гүзәл, житте!

Гүзәл. Бетте, картым, бетте...

**Рафаэль тәмәкесен кабып чыгып китә.**

Люция. Әйдәгез, эчик әле.

Римма. Ни өчен эчәбез?

Лэйлә. Яшьлектәге тойгылар сүнмәсен өчен. Әгәр мөмкин булса, яшьлектәге хыялларның тормышка ашуы өчен.

Люция. Прекрасно!

Римма. Шәп әйттең, Ләйлә.

Гүзәл. Яшьлектәге хыяллар...

**Люция эчеп бетерә, башкалар авыз итеп куялар.**

Римма. Люция, ничек исермисең син? Һәрберсен бетереп куясың.

Люция. Мина исерергә ярамый, кызлар. Профессия такая.

Ләйлә. Исерү таләп ителгән профессия бармы икән соң ул?

Люция. А у меня особая.

Гүзәл. Туристларга особый хезмәт, димәк...

Люция. Да, особый. Ә сиңа, Гүзәл, мин сиңа көнләшмәскә кинәш бирер идем. Рафаэль каким был, таким и остался. Кому он нужен?

Ләйлә. Бар аның кирәк кешеләре...

Люция. Не знаю, не знаю. Верьте моему опыту: ир-атка ни кадәр тәлинкә тотсаң, ул шул кадәр синнән издеваться итә. У них психология такая.

Гүзәл. Бәлкем син хаклыдыр. Ләкин халык бит ана колхоз житәкчесе дип кенә түгел, укытучы ире дип тә карый. Мин ана һәр көн үтүкләнгән чиста күлмәк-чалбар кигерәм. Балаларга да, бианай белән биатайга да. Авылда күз өстендә каш кебек без. Моңа ирешү айһай авыр! Сыер, сарык, кош-корт, бакча... Читтән торып институт бетердем. Көн саен дәрескә әзерләнү, план төзе, класстан тыш эшләр. Председательнең аның өйгә кайтса—төнлә, чыгып китсә—ачы таңнан... Мин аны югары күтәрә алмасам да, халык күзе алдында түбән төшмәсен өчен һәммәсен дә эшлим. Ана әйтелгән кимсетүле сүзне шуңа күрә күтәрә алмыйм мин...

Ләйлә. Нилектән йөрәк чиренә олгашуыңны аңлап була синең.

Люция. Йөрәк авыртамыни?

Гүзәл. Яшибез әле... Гүзәл Гүзәл булып калачак, үз исеменә барыбер тап төшермәс. Сезнеке кебек жинел генә бармый безнең тормышлар, Люция.

Люция. Минеке дә жинел түгел. По-моему Римма белән Ләйлә всем довольны.

Римма. Әйе, шулай кебек. Ирем эчми, тартмый, характеры әйбәт. "Волга" машинабыз бар. Үзем складта эшлим. Белемсез булсак та, акчабыз житешле.

Люция. Акча үзе образование инде ул.

Римма. Татарча ясле дә мәктәп тә юк. Ирем дә рус. Балаларым татарча белмиләр диярлек, исемнәре дә урыс исеме.

Гүзәл. Ирең жингән алайса?

Римма. Кая жиңсен? Хәзер инде ул балалар ни татар, ни урыс түгел. Татар жыры ишетсәм, күземнән мөлдерәп яшь ага...

Люция. Алайса балам булмау белән мин бәхетледер дә, бәлкем.

Римма. Син гел кияүгә чыкмадыңмыни?

Люция. Минем кияүгә дә чыкканым юк, ирсез дә торганым юк.

Ләйлә. Үзең турында начар уйларлар дип тә шикләнмисең.

Люция. Без бит ачыктан-ачык сөйләшергә дип сүз куештык.

Гүзәл. Ул мактана торган әйбер түгел.

Люция. А что? Трехкомнатная квартира, эче тулы импортный мебель, ковер и так далее. Иң очсызлы күлмәгем дүрт йөз меңлек.

Ләйлә. Син тормыштан канәгать алайса?

Люция. Как сказать. Канәгать тә, түгел дә. Бәйдәге этнең теләге ни? Чылбырыннан ычкыну. Әти-әнидән качтым. Институттан качтым... Я абсолютно свободна. Но до этого... Не хочется даже вспоминать. Акча бетте, торыр урын юк, голодная как черт. Сколько я моталось по Казани. Ярый, Дамирны таптым. Ул сельхозның комсомол комитеты секретаре иде. Обком комсомолдан бер кеше белән таныштырды. Фамилиясен әйтмим. Ул хәзер дә крупный урында. Әтиләргә квартираны да ул алып бирде. Вот шул әйтте: ты мне нравишься, что хочешь, все будет, диде. И так пошло. Потом московские знакомства. Все у меня есть.

Гүзәл. Синең зарланырлыгың юк алайса...

Люция. Думаете, это легко? Ирләр белән уйнау... О-о-о, это целая наука! Син менә, Гүзәл, сөйләдең... мин дә синнән ким тырышмыйм. Син һәрвакыт пөхтә, тәмле исләр генә бөркергә, ягымлы сүзләр генә сөйләргә тиеш. Елыйсың килгәндә дә көләсең. Эчендә боз булса да, тыштан ут булып кыланасың. Это очень тонкая игра... Минем һәр сүзем, һәр хәрәкәтем, һәр күз карашым акыл контролендә. Нужно всегда быть на уровне. Шул чакта гына ирләр синең кулыңда, ай-йолдызны алып бирергә әзер торалар. Я говорю о крупных личностях. Мин вак-төяк белән эш итмим...

Гүзәл. Синең сөйләгәннәреңне миннән дә яхшырак аңлаучы юктыр, Люция.

Римма. Ә шулай да, кызлар, безнең арада Ләйләдән дә бәхетлесе юк. Үзе атказанган врач, озакламый Дамир Татарстан халык депутаты булып сайланачак.

Ләйлә (*сөйләгәндә кызганнан-кыза бара*). Әйе, без бәхетле. Ул мине, мин аны өзелеп яратабыз. Эшләр дә гөрләп бара, акча да күп, жаның ни тели шул бар.

Римма. Башы Дамирдан шул...

Ләйлә. Ычкындырмаска иден

Дамирны, син дә минем кебек булыр идең.

Римма. Миңа кайсы ягы беләндер ошамады ул. Куркаграк иде димме... Ул да мине ярата алмагандыр... Ә хәзер шундый солидный...

Ләйлә. Күрәсең, минем өлешкә туры килгән...

Римма. Ә шулай да мин нишләптер Дамир белән сине бергә итеп күз алдына китерә алмый идем.

Ләйлә. Ә мин китерә ала идемме? Казанда укый башлагач, Дамир безнең институтның тулай торагыннан китмәгәндер. Аңа бөтен Казан кызлары мөкиббән. Яшь шагыйрь! Яшь композитор! Комсомол активисты! Инструменталь ансамбль җитәкчесе! Әнә Люция белә.

Люция. Да, да! Это было потрясающе!

Ләйлә. Миңа багышлап җырлар яза, шуны сәхнәләрдән җырлыйлар. Аның белән мине дә күтәреп йөртәләр. Андый татлы давыл эчендә исергәнегез юк әле сезнең! Көн саен кая гына барма—җыр, бию, шатлык! Аны обкомолга эшкә алдылар. Казанның үзәгендәге бер дигән квартирага килен булып төшүдән кем баш тарта алыр? Аннары үзебезгә эшкә җибәрделәр. Монда тагын оҗмах кебек тормыш... (*Кинәт елый башлый.*)

Люция. Что с тобой?

Ләйлә. Юк, юк, берни дә юк...

Римма. Мине дә елатасың...

Ләйлә. Үтә, хәзер үтә...

Гүзәл. Берәр күңелсезлек бармы әллә?

Ләйлә. Үткәннәр искә төште. Шатлыктан гына бу...

Римма. Их, яшь чаклар! Сездән көнләшәм мин. Җыелышып утырасыздыр, үткәннәрне искә аласыздыр. Шулаймы, Гүзәл?

Гүзәл. Безнең җыелганыбыз юк...

Люция. Как так?! Бер районда яшәп...

Ләйлә. Дамирның принцибы—район эчендә беркем белән дә аралашмау. Ярамый. Казаннан, бүтән җирләрдән берничә кеше бар...

Люция. Это разве интересно? Мин үләм без общения.

**Рафаэль керә.**

Рафаэль (*корык-корык ютәлләп*). Люция, мә бу тәмәкеңне. (*Сигаретын бирә.*)

Люция. Ник?

Рафаэль. Икене тарткан идем, ютәлләп үлә яздым. Эт корсагына сары май килешә димени.

Ләйлә. Әйдәгез, утырышыйк әле. Дамир!

Дамир (*чыгып*). Бирелә ниндидер үзгәреш сизелә.

Люция. Рафаэльгә ютәл төшкән.

Гүзәл (*Рафаэльга дару биреп*). Эчеп җибәр әле шушы даруны... (*Бокал белән су суза.*)

Рафаэль (*даруны кабып, аракы эчә*). Спиртта тизрәк эри ул. Кем тост әйтә?

Римма. Мин.

Рафаэль. Юк, син әйтми тор әле. Мәскәү кунагы әйтсен.

Дамир. Бу йортта әлегә кадәр хуҗа мин идем кебек.

Рафаэль. Кайчандыр бу йортның хуҗасына мин хуҗа идем дә бит...

Гүзәл. Рафаэль...

**Дамир Рафаэльгә ачулы күз карашы ташлый, тегесе "биреләдем" дигән мәгънәдә кулларын югары күтәрә.**

Римма. Әйдә, әйт, Люция.

Люция. Ну что ж... Беләсезме ни өчен эчәбез? За искренность и любовь!

Ләйлә. Мин берсүзсез кушылам.

Люция. Хотя... бер анекдоттагыча килеп чыкмаса.

Рафаэль. Ире командировкага китмәкче?

Люция. Юк, Рафаэль, ире командировкага китмәгән.

Рафаэль. Ире командировкага китсә, кызык була торган иде...

Гүзәл. Карткаем...

Люция. Колхозда собрание бара икән, на повестке дня два вопроса: сарай салу и коммунизм төзү. Такта булмаганлыктан, беренче көн тәртибен тикшереп тормаганнар, сразу икенчесенә күчкәннәр ди.

Дамир. Бик усал булды бу, Люция.

Рафаэль. Бусы минем колхозга кагылмый.

Люция. Может, без дә икенчесе өчен генә эчәрбез?

Гүзәл. Ә мәхәббәт эчкерсезлектән башка була аламы соң?

Ләйлә. Һәркем үзенә карасын. Мин икесе өчен дә эчәм. (*Эчәләр.*)

Римма. Кызлар, егетләр! Әйдәгез бер җырлыйк әле. Шундый сагындым үзебезнең татар моңын...

Рафаэль. Мин кин күңелле Дамир Заманович хөрмәтенә, аның хәләл җефете Ләйлә хөрмәтенә бер тост әйтергә телим.

Дамир. Рафаэль, яратмыйм мин андый нәрсәләрне.

Рафаэль. Ник?

Ләйлә. Кирәкми. Әйдә җырлыйк әле.

Дамир. Минем бер җырым бар. Комсомолда эшләгәндә үк берәүнең юбилеена язган идем. Тыңлап карыйсызмы?

Люция. С удовольствием.

Рафаэль. Ә мин хуҗалар өчен барыбер эчәм. (*Эчә.*)

Дамир (*пианинога утыра, үзе уйнап үзе җырлый*).

Басып торам яфрак янгырында,
Сары сагыш баскан кырларны.
Безнең белән бергә бу тирәкләр
Озын җәйләр буе җырлады.
Җәйләр генә безгә аз тоелды,
Сагынып сөйли идек язларны.
Кай арада җәйләр үтеп киткән,
Әнә генә кебек яшь чаклар.
Күкләр биек, еллар ерак инде,
Ява бары сары яфраклар.
Бар дөньяны баскан яфрак сарысы,
Тынлап торам гомер агышын.
Очрашабызмы дип сорарга
Тирәкләргә килсәм янадан,
Ни аяныч! Сары яфракларга...
Сары яфракларга кар яуган.
Тып-тын гына ява ак карлар,
Аһ, еракта калды шул язлар!..
..........................................
Их! Сары яфракларга ява карлар,
Йөрәкләрдән китми сөйгән ярлар!..

**Кул чабалар.**

Люция. Молодец!

Гүзәл. Сагышлы җыр...

Римма. Әйдәгез әле үзебезнекен.

Дамир. Минем "Кичке йолдызлар"нымы?

Римма. Әйе. (*Ул башлый, бүтәннәр кушыла.*)

Тир-там, тир-там,
Җырлагыз, кызлар.
Күзләремә балкып тулган
Кичке йолдызлар,
Кичке йолдызлар.
Синең мине, минем сине
Яндырыр чагым.
Йөрәкләрне җылытадыр
Сөю учагы,
Сөю учагы.

**Танцы башлана. Алгы планда Дамир белән Люция.**

Дамир. Нигә син эчкерсезлек өчен тост тәкъдим иттең?

Люция. Ты разве не видишь? Без бит бөтенебез дә үз кабыгыбызга бикләнгәнбез. Стоило ли для этого встречаться?

Дамир. Миңа карата да әйтәсеңме инде син бу сүзләрне?

Люция. В первую очеред для тебя.

Дамир. Яшерməвең өчен рәхмәт. Тагын бер сорау мөмкинме?

Люция. Пожалуйста.

Дамир. Бая минем кулны биленнән ник алып куйдың?

Люция. Комсомол яшеннән чыкканыңны оныттма. К тому же хәзер бушка берни дә эшләнми, мой милый. Рыночная экономика, договорная цена. (*Кәлә.*)

**Алгы планда Ләйлә белән Римма.**

Римма. Бая синең сүзләрең бәгыремне телде.

Ләйлә. Нишләп?

Римма. Әйтергә куркам... Ялгышсам, хәтереӊ калыр.

Ләйлә. Әгәр әйтми китсәң, минем күңелгә мәңгегә юшкын утырыр.

Римма. Бәхетле кеше алай сөйләмәс иде.

Ләйлә. Ялгышмагансың, Римма.

Римма. Сәбәбен дә беләм кебек...

Ләйлә. Әйт.

Римма. Иртән күрешү белән, юньләп хәл-әхвәл дә сорашмастан, Иваннар авылына барып кайтуымны үтендең.

Ләйлә. Хикмәт Иванда гына түгел шул, Римма.

Римма. Ә нәрсә соң?

Ләйлә. Дамирда...

Римма. Сине кыерсытамы?

Ләйлә. Юк.

Римма. Хатын-кыз белән йөриме?

Ләйлә. Бераз соңрак әйтермен әле, ямме.

Римма. Ярар.

Ләйлә. Ә үзең? Яратасыңмы иреңне?

Римма. Салкын кеше булып чыкты ул. Ярата-иркәли белми, ә үзе көнләшә. Бер әйбер әйтимме.. (*Туктап кала.*)

Ләйлә. Нәрсә?

Римма. Туры килгәндә мин хыянәт итәм...

Ләйлә. Хыянәт итәсең?!

Римма. Әйе. Ышан—азгынлыктан түгел. Бер мәртәбә булган ирләр миңа кабат әйләнеп тә карамый... Әллә аңа үч итәм, әллә бәхетле хатын-кызларга, әллә үземә... шуннан соң үз-үземә кул саласым килә...

**Аларның уртасына Рафаэль керә.**

Рафаэль. Римма, бер генә минут синең белән танцевать итәргә рөхсәт ит... (*Ләйлә арткы планга күчә.*) Син мине искә аласыңмы?

Римма. Көн саен.

Рафаэль. Рәхмәт.

Римма. Нәфрәт белән рәнҗеп искә алам.

Рафаэль. Мин сиңа нинди начарлык эшләдем?

Римма. Син бик күп кызларны харап иттең. Мине дә... Алланың ачы каһәре төшсен сиңа!

Рафаэль. Харап итү, имеш... Тик торган баганага бәрәү дә килеп кагылмый.

Римма. Дәшмә, ичмаса! Аллау, янау, куркыту, кул күтәрү —синнән барысын да көтеп була иде. Үзебезнең дә, ирләребезнең дә йөрәкләренә син мәңгелек яра салдың. Безнең каргыш барыбер тотар сине... (*Рафаэль янына Гүзәл килә, Римма читкә китә.*)

Гүзәл. Бүгенгә генә түз, Рафаэль...

Рафаэль. Кайткач сиңа тагын тукмак әләгәчәк.

Гүзәл. Синең йодрыгың хәзер куркытмый инде мине... Үтенеп сорыйм, бүген генә исермә. Оят миңа...

Рафаэль (*кычкырып*). Оят?! Кемнән ояласың?! Шушыларданмы?

Люция (*килеп*). Ник кычкырасың?

Рафаэль. Ә син кем булдың әле миннән допрос алырга?

Дамир. Каяле, Люция... (*Рафаэльны читкә ук алып китә, башкалар танцевать итәләр.*) Син кем өендә икәнеңне онытттың, ахры...

Рафаэль. Синең өйдә. Йә, шуннан?

Дамир. Бередә тавыш күтәреп сөйләшмиләр.

Рафаэль. Эш урынында шундый тәртипләр кертсәң иде син.

Дамир. Үзе турында гына кайгыртучы житәкчеләр беткәч, шулай булыр.

Рафаэль. Андыйларны сиңа альтернатив итеп депутатлыкка күрсәтмиләрдер, билгеле.

Дамир. Уеннан уймак чыкмасын, Рафаэль.

Рафаэль. Ихтимал...

**Танцы дәвам итә.**

Их, мәхәббәт, серле чишмә,
Мәңге шаулар суларың.
Суларыннан агышлары
Алып китә елларым.
Кушымта: Тир-там, тир-там,
Жырлагыз, кызлар.
Күзләремә балкып тулган
Кичке йолдызлар...

**Шул чак ишектә Иван күренә. Барысы да жыр һәм биюдән туктап калалар. Ул сакал-мыектан, маңгаендә тирән яра эзе бар. Чәчләре ап-ак. Йөргәндә аксый.**

Иван. Мин комачауладым... ахрысы...

Рафаэль. Ашка таракан төште... (*Эчеп куя.*)

Люция (*Иванны кочаклап*). Ваня! Синме бу?!

Иван. Теге Ваня юк инде...

Дамир (*тәрәзәне ачып*). Нишләптер бөркү булып китте...

Римма. Киләсеңне ник әйтмәдең?

Иван. Барыбер ич.

Ләйлә. Миңа алай карама, Дамир.

Дамир. Син инде күз карашыннан да әллә нинди мәгънәләр эзлисең.

Ләйлә. Сукыр түгел, күрәм. Әйе, мин чакырдым аны. Син бит башкаларның да кайтуын теләмәгән идең.

Дамир. Теләмәдем түгел. Очрашу вакыты хакында сүз булды. Чөнки сайлау чоры, көне-төне халык арасында кайный торган чак.

Ләйлә. Теләмәдем диген. Син хәзер дә эчтән ут йотасың.

Дамир. Ләйлә, кирәкми...

Римма. Ташлагыз әле вак-төяк ызгышны!

Иван. Күрешергә мөмкинме соң? Исәнме, Ләйлә... (*Аның кулын кыса, шактый вакыт жибәрми тора, моны барысы да сизәләр.*) Гүзәлме?

Гүзәл. Таныдың... (*Күрешәләр.*)

Иван. Сәлам, Рафаэль.

Рафаэль. Сәлам... (*Кул биреләр.*)

Иван. Менә күрештек тә... Чакыруың өчен рәхмәт, Ләйлә. Мин болай да кайта идем инде.

Рафаэль. Әллә... Бөтенләйгәме?

Иван. Кабул итәрсезме—белмим...

Дамир. Ваня! Мине оныттың бит. Кыерсытасың, яшьти! Әйтерсең, мин сиңа чит-ят кеше. (*Кочагын жәеп килеп кочаклый.*) Исәнме, саумы, мосафир!

Иван. Көтмәгән идем... болай ук... Син һаман да үз амплуаңда.

Дамир. Башкача ярамый, урын шулай куша. (*Аны өстәл янына алып килеп.*) Әйдә, утыр әле менә монда.

Ләйлә. Ваня, кил үземнең янымa.

Люция. Юк, ул минем янга утыра.

Дамир. Гафу, гафу, әйдә әле. Ләйлә янына утыр. Ә син, Люция, аның икенче ягына. Менә шулай.

Иван. Рәхмәт... Мин килмәскә уйлаган идем дә... түзмәдем...

Дамир. Ничек инде?! Син нәрсә?! Честное партийное—үпкәли идем, үпкәли идек. Шулай бит, Ләйлә. (*Ләйлә дәшми.*)

Люция. Ну как ты приехал?

Иван. Нормально.

Дамир. Менә бит табын китек иде, түгәрәкләнеп китте. Әле сине искә алып кына утырган идек. Мин дөрес әйтәммe?

Римма. Әйе...

Рафаэль. Дамир Заманович, син үз марканны бераз... ни...

Дамир. Кайчан синең өйгә жыелабыз, шунда син командовать итәрсең. Шулай бит, Гүзәл?

Гүзәл. Әлбәттә...

Дамир. Йәгез әле, Ваня хөрмәтенә.

Люция. С благополучным возвращением!

**Барысы да эчә, Иван эчми.**

Дамир. Ваня, син нәрсә? Беренче мәртәбә безнең өйгә кереп... Жирәнәсеңмени?

Иван. Сүз биргәнемне беләсез. Капканым юк.

Люция. Ни гомер үтте бит инде.

Иван. Биргән сүз—гүргә кергәнче.

**Рафаэль килә дә, Иванның**

**рюмкасын алып, аның баш өстенә күтәрә.**

Гүзәл. Рафаэль! (*Ана үрелә.*)

Рафаэль. Кит! (*Иванга*) Агызам бит.

Иван. Әйдә берәр тамчы тамызып кара әле.

**Аларның күз карашлары очраша.**

Рафаэль. Шаярттым гына... (*Рюмкасын авызына китерә башлауга, Дамир аны алып Иван алдына куя.*) Йә, дөреслекне таптыңмы соң, Ваня? Бик озак эзләдең инде.

Иван. Дөреслекне эзләргә кирәкми. Ул бар һәм яшь. Аны күрсәтергә генә кирәк.

Рафаэль. Мин сине шул кадәр үчлекле дип белми идем.

Иван. Аңлатып сөйлә.

Рафаэль. Әрәмәдәгене онытмадың. Прокуратурага күчү белән мине чокый башладың.

Римма. Урыны шушымы инде?

Люция. Не говори.

Дамир. Стоп! Бу принципиаль мәсьәлә, кызлар. Рафаэль, син Ваняга рәхмәт укырга тиеш.

Рафаэль. Рәхмәт укырга?! Ник?!

Дамир. Колхоз кесәсенә мул кергән идең син... Әгәр Ваня шәфкатьлелек күрсәтмәсә...

Рафаэль. Дамир Заманович, син ни сөйлисең?! Мин бит калҗаның чепетие генә... син... ул бит...

Дамир. Тик тор! Синең принципиальлеккә, Ваня, мин шул чакта ук сокландым. Чигенмәү һәркемгә дә бирелми.

Иван. Ул чакта миңа өстәл төятөя кычкырганда...

Дамир. Әйе, кызып кителгән... Син дә кыздың.

Гүзәл. Зинһар, тирәнгә кермәгез.

Римма. Ник җыелдык соң без? Әйдәгез, күңел ачыйк әле.

Иван. Китәм мин.

Люция. Син китсәң, без дә китәбез.

Дамир (*Иванны утыртып*). Җибәрмибез без сине, юк, юк! Беркая да китмисең. Кадерле кеше син. Ныграк уйлаган саен фикер аныклана... Әле менә хәзер генә, син килеп кергәч, мин бер нәрсәне аңладым: син дә, б... дә хаклы булганбыз.

Иван. Кызык бит бу, кызык...

Дамир. Ит, сөт, икмәк! Халык табынына ничек тә күбрәк бирергә! Без әнә шул экономикага батканбыз, бүгенге көн проблемалары шаштырган. Ә син ераккарак, кеше күңеленә карагансың.

Иван. Кайчан да булса бу сүзләрне ишетермен дип кем уйлаган?

Дамир. Син закон, гаделлек, әхлак, намус-вөҗдан, дидең. Без дә шуны таләп иттек. Асылда бу—бер медальнең ике ягы.

Иван. Килешәм, килешәм!

Дамир. Ашыкма! Кадрлар житмәве абындырды безне вакыт-вакыт. Ләкин һәрчак түгел. Шулаймы, Ваня?

Иван. Дөрес, Дамир. Мин дә рәхмәт әйтергә тиештер. Соңгы вакытта күп уйландым. Шактый нәрсәләргә яңача карый башладым. Бигрәк тә менә хәзер, синең бу сүзләреңне ишеткәч. Безгә күптән аңлашасы булган...

Ләйлә. Ваня, ялгышасың...

Иван. Юк, Ләйлә, мин элек ялгышканмын. Законга сукырларча ябышып ятып кына булмый икән. Политик бәя дә бирергә кирәк булган үз эшләренә.

Дамир. Анысы хак. Ләкин синең принципиальлек үз ролен уйнады. Синең кебек чигенмәүче кирәк булган. Әйе, әйе, кирәк!

Ләйлә. Ай, дөнья!

Иван. Син кадрларны саклау турында кайгырткансың. Җинаять эшләрен ябарга кушуны мин кул кулны юа, ике кул битне юа дип кенә аңладым.

Дамир. Ә мин күпме әйттем, аңлаттым, үтендем.

Иван. Бер селтәнүдә сындырмакчы идем шул мин. Шамгуновны төзелеш махинацияләре өчен дип, Бариевны күз буяган, урлашкан өчен дип, Сибгатуллинны... Күп инде алар. Шуларны җәзага тарткан, утырткан булсак, күпме сәләтле кадр югаласы иде. Хәзер берсе синең уң кулың, икенчесе СМУ җитәкчесе, өченчесе поселок Советы председателе...

Дамир. Менә аңлаштык, булды.

Иван. Алар барысы да нәкъ синең кебек җитлеккән кадрлар. Рафаэльны депутат итмәкчеләр әнә. Синең хезмәт түгелмени болар?

Дамир. Бу хакта җитәр. Үземне мактаганны күтәрә алмыйм...

Ләйлә. Комсомолдан ук кешеләр турында бик нык кайгыртты Дамир.

Дамир (*сагаеп*). Минем турыда җитте дидек бит инде, карчык.

Ләйлә. Юк, синең Рафаэльны комсомол путевкасы белән авылга җибәрүеңне әйтмичә ярамас.

Дамир. Нигә инде әллә кайчангылар? Әйдәгез, берне тотыйк әле.

Римма. Ә минем җырлыйсым килә.

Ләйлә. Рафаэль исереп тулай горакта...

Дамир. Ләйлә, тукта зинһар...

Гүзәл. Рафаэль, әйдә кайтыйк...

Ләйлә. Рафаэль, әгәр үпкәләсәң, әйтмим...

Люция. Мы же договорились: все на чистоту.

Дамир. Ләйлә, мәҗлеснең көен җибәрмә.

Рафаэль (*ачу белән*). Әйтсен, тыйма...

Л э й л ә. Тулай торакта сугышкач... бернинди гаепсез егетне...

Д а м и р (*аны бүлеп*). Ләйлә, ни телисең син? Рафаэль, җебемә... Ләйлә...

Л э й л ә. Гаепсез егетне...

Д а м и р (*ярсып*). Син каян беләсең аның гаепсезме, түгелме икәнен?! Гаепсез дә гаепсез!

Л э й л ә. Беләм! Гаепле Рафаэль, ә теге егетне биш елга утырттылар. Синең начар характеристикаң белән.

Д а м и р. Үзең белмәгән әйберне сөйләмәскә иде...

Р а ф а э л ь (*Дамирга*). Җитте инде! Ник син, ичмасам...

Л э й л ә. Алай ярамый, Рафаэль. Син аңа классташлар каршында рәхмәт булса да әйтергә тиеш бүген. Институттан да кумадылар, читтән торып уку бүлегенә күчерделәр. Әйтер сүзең юкмыни?

Р а ф а э л ь. Әйтергәме? Бар ул, ник булмасын. Дамир Заманович, мактап мин дә бер генә сүз әйтсәм, каршы килмәссең бит?

Д а м и р. Кирәкми, кирәкми! Ишетәсем дә килми.

Р а ф а э л ь. Мактап бит...

Д а м и р. Синең мактауга мохтаҗ түгел...

Р а ф а э л ь. Мин барлык колхоз председательләре, совхоз директорлары, башка житәкчеләр исеменнән әйтәм. Син бит тимер тәртип урнаштырдың кадрлар арасында. Шыкырдап кара.

Л э й л ә. Дөрес! Безнең баш врач тәртәгә тибәргә маташкан иде дә. Хәзер бөтен больница чөгендер, бәрәңге басуыннан кайтып керми. Авылга шефлык ярдәме...

Д а м и р. Сез туктыйсызмы?

Р а ф а э л ь. Совхоз директоры Галимжанов бер генә каршы сүз әйтте. Бер ай эчендә—выжт!

Д а м и р (*теш арасыннан*). Рафаэль...

Р а ф а э л ь (*башын юләргә салып*). Нигә, Дамир Заманович? Сине хөрмәт иткәнгә генә әйтүем. Тәртип кертүең хак бит. Әгәр сиңа ике орден биргәннәр икән, хөкүмәт дурак түгелдер. Эшләгәнгә бирелгән.

Л ю ц и я. Я не пойму вас. мактыйсыз да мактыйсыз. Ну что тут изменилось? Дамирчик, отвечай.

Д а м и р. Аның бөтенесе дә күренми инде, Люция. Продукцияне элекке еллар белән чагыштырганда, беләсеңме, күпме артык сатабыз?

Л ю ц и я. Это мне до лампочки.

Д а м и р. Дуңгызлар өчен комплекс төзедек.

Л ю ц и я. Тфу, дунгыз еще!.. Асфальт нишләп юк? Автобуста эчем төшеп бетте. Бөркелеп тузан туза. Фу, не могу!

Д а м и р. Асфальт заводы төзибез.

Р а ф а э л ь. Әйе, җиденче ел инде.

Л э й л ә. Өч-дүрт елдан бетәчәк дип сөйлиләр.

Д а м и р. Газ кертә башладык.

Л э й л ә. Күршеләр кертеп бетергәндә...

Д а м и р. Җитте! Сез нәрсә, сүз берләштегезме?!

Л ю ц и я. Не понимаю, почему ты кричишь?

Д а м и р. Потому что вы договорились. Это не честно.

И в а н. Дамир, син бит башлап үзең мине мактарга керештең. Ник сине мактарга ярамый?

Л ю ц и я. Да, по-моему, тут все нормально.

Д а м и р. Мактау, имеш... Тел төбегездә ни ятканын мин яхшы беләм.

И в а н. Синең тел төбеңдә ни ятканны без сизмәде дип уйладыңмыни?

Д а м и р. Күпме сәләтем бар—мин барысын да намуслы эшкә түгәм.

Р и м м а. Их, сез! Бергә булуның, татарча сөйләшүнең кадерен белмисез.

И в а н. Дөрес әйттең, Римма...

Р и м м а. Мин бит сезнең бөтенегезне дә яратам. Ә сез бер-берегездән вак-төяк гаеп эзлисез. Шуның өчен кайттыкмыни без?

Л ю ц и я. Верно.

Г ү з ә л. Әйдәгез бер җырлыйк әле.

Р и м м а. Нинди җыр җырлыйбыз?

Р а ф а э л ь. Башта тост кирәк.

Л ю ц и я. Тут уже сказано. За Дамирчика!

Г ү з ә л. Әтисе...

Р а ф а э л ь. Аның өчен булгач, мин тамчысын да калдырмыйм. (*Эчә.*)

Л э й л ә (*җыр башлый*).

Зәңгәр күлмәгеңне киясең дә
Зәңгәр күлгә көн дә киләсең.
Йөрәгеңдә нинди утлар яна,
Уйларыңны килә беләсем.
Зәңгәр күлмәкләрнең чын зәңгәрен
Җилләр ала—җилгә элмәгез.
Яшьли сөйгән ярлар барыбер ятка кала,
Яр сөйсәгез, яшьли сөймәгез...

**Җыр тәмамлангач, кайсы утырган, кайсы баскан килеш уйга чумып хәрәкәтсез калалар.**

Р и м м а (*сискәнеп*). Нишләптер өшетеп җибәрде...

Г ү з ә л (*ачык тәрәзәдән карап*). Теге яктан салкын җил исә, кара болытлар килә. Сентябрь ахыры димәссең. Ябыйммы тәрәзәне?

Л э й л ә. Яп зинһар, Гүзәл.

И в а н. Алай көн дә бозылгач, мин кузгалыйм әле... Җәяүләп кайтасы бар.

Л э й л ә. Ваня...: үтенәм... ашыкма.

И в а н. Юк...

Л ю ц и я. Ну, Ваня...

Д а м и р. Әйе, ашыкма... Минем машина илтеп куяр.

И в а н. Юк, Дамир! Син бит моны яхшылык эшләргә теләүдән әйтмисең...

Дамир. Ни өчен син мине шундый игелексез дип уйлыйсың әле?

Иван. Алайса ник соң мине районнан кудырдың, ә? Шул тикле мактаулы кешене.

Дамир. Мин сине аңлагансыңдыр дисәм...

Иван. Әртистләнмә, килешми. Син дә, мин дә, башкалар да бөтенесен дә аңлыйбыз. (*Пауза.*)

Дамир. Соң кайт алайса, әйдә, эшлә...

Иван. Дамир, ник һаман уйныйсың? Син бит миннән уттай курыккандай куркасың. Сиңа мин кирәкмим. Сина Рафаэль кебекләр кирәк. Уртак калжа өчен "Бәрел!" диюгә йөгереп барып таш стенага башы белән бәрелүчеләр.

Рафаэль. Хәзер бәреләм мин сиңа... (*Иванга ташлана, аны Дамир, Гүзәл, Римма тоталар.*)

Рафаэль. Кешедән көлмәсен...

**Аны йокы бүлмәсенә алып кереп китәләр. Гүзәл шунда кала, Дамир белән Римма чыга.**

Иван. Миңа чыннан да киләсе булмаган. (*Кузгала.*)

Ләйлә. Тукта... Синең алда мин гаепле... Бу дөньяда синең кебек яраткан кеше юк иде мине...

Иван. Нигә "иде?" Мин бит әле үлмәдем.

Ләйлә. Ай, нык рәнжеттем... Булдыра алсаң, кичер...

Иван. Рәнҗи алмадым мин сиңа, Ләйлә. Юкка битәрләмә үзеңне. (*Пауза.*) Мин кешеләргә яхшылык эшләргә тырыштым... бөтен йөрәгем белән... Хакыйкатьне ачарга... Җиңелдем... Алар һәрвакыт бергә, ә без... Анда да җиңәчәкләр...

Ләйлә. Кайт үзебезнең якларга.

Иван. Хәзер соң инде. Әнине таптым. Ни әйтсәң дә янәшәдә. Ике балам, хатыным белән булыйм инде мин...

**Рафаэль белән Гүзәл кергән бүлмәдән ыңгырашкан тавыш ишетелә.**

Ләйлә. Нәрсәдер бар...

Люция. Әйдәгез әле.

**Люция, Римма, Ләйлә кереп китә.**

Дамир. Нигә син минем кайт дигәнгә ышанмыйсың?

Иван. Син башкалар муенына пычак салсаң да, аны үз муенына салырга сәләтле түгел.

Дамир. Борғаланмыйча гына әйт.

Иван. Мин бит синең дә бик күп караңгы эшләреңне беләм. Әйтимме?

Дамир (*озак дәшми торгач*). Кирәкми...

**Шаулашып Гүзәл, Рафаэль, Ләйлә, Люция, Римма чыга. Гүзәлнең чәче-башы тузган.**

Гүзәл. Әйтмәгез, зинһар әйтмәгез!

Дамир. Ни булды?

Гүзәл. Әйтмәгез, үтенеп сорыйм...

Люция. Әйтмәбез менә! Посмотрите-ка на этого бессовестного! Гүзәлне кыйнап ята. (*Рафаэльнең яңагына берничә мәртәбә чалтырата.*) Подонок!

Рафаэль. Киттек кайтып!..

Люция. Заткнись!

Рафаэль. Ник сез безнең арага тыкшынасыз? Ул мине ярата. Кыйнасам да, яратачак. Гүзәл, ничек ратканыңны әйт әле.

Гүзәл (*елап*). Ярар, әйтәм. Ичмасам, сез белегез. Бәлкем баштарак ратканмындыр.

Рафаэль. Баштарак?!

Гүзәл. Көн саен дуңгыз булып исергән кеше яратуны да үтерә икән. Күнелен булдымы инде? Киттек!

Рафаэль (*аны туктатып*). Тукта, тукта, әйтеп бетер, матурым. Син мине яратмыйсыңмыни?

Гүзәл. Аңлаешлы итеп әйттем кебек.

Рафаэль. Алайса ник монарчы яшердең?

Гүзәл. Керсез кайнар тойгыларым сине ничек тә бер уятыр дип өметләнгән идем мин...

Римма. Ә безнең каршыда? Ник кирәк шул кадәр өтәләнү?

Гүзәл. Гадәткә кергән. Мәктәпне бетергәнче үк аңарга чыккач, авылда миннән күпләр көлде, мыскыл иттеләр. Мин шуларга үч итеп институт бетердем, үрнәк гаиләнең нинди булырга тиешлеген күрсәттем.

Рафаэль. Димәк, син яраткан булып кыланасың гына...

Гүзәл. Ә нишләргә миңа? Әйт, нишләргә?! Синең эчеп кайтуыңны, сүгенүеңне, кул күтәрүеңне чыгып сөйләргә, авыл халкына таратыргамы? Укытучы укучылары каршында кояш кебек саф булырга тиеш. Шуннан соң мин аларның күзенә ничек карыйм? Алар миңа ышаналар, табыналар, димәк, тәрбия алалар. Минем бөтен тормышым—аларга...

**Озын пауза.**

Дамир. Нинди түбәнлек! Шушындый фәрештәгә кул күтәрү... Оят түгелме?

Рафаэль. Аңа түгел, сиңа сугасы калган шул.

Дамир. Рәхмәт. Күп мәртәбәләр судан коры чыгарган өчендер инде ул.

Рафаэль. Институттагы гөнаһларым өчен миңа утырасы булган. Син бит мине коткардың да кыңдәм колың иттең. Кайчандыр мин сине үч төбемдә биетә идем. Хәзер инде мин —мәңгелек тоткын...

Дамир. Тоткыннарны депутат-

лыкка кандидат итмиләр.

Рафаэль. Синең урында булсам, мин бу хакта дәшмәс идем. Альтернатив итеп күрсәтерләр, әмма үз кандидатураңны сайлау житкәндә алырсың дип син әйтмәдеңме?!

Дамир. Чыннан да исерүең житкән—ни сөйләгәнеңне белмисең.

Рафаэль. Үзеңнең кабинетыңа чакырып әйттең бит. Йә, күземә карап, әйтмәдем диген әле?!

Дамир. Башта айны, аннары сөйләшербез.

Рафаэль. Өркетмә, күп өркеттең инде...

Гүзәл. Әйдә, Рафаэль, кайтабыз.

Иван. Миңа да вакыт.

Люция. Мин дә китәм...

Ләйлә. Туктагыз, берегез дә кузгалмый! Әллә сез мине болай гына жыйды дип уйладыгызмы?

Римма. Очрашу өчен түгелмени?

Ләйлә. Люциядән башка берегез дә безнең туйда була алмады. Мин сезне шул туйның дәвамына жыйдым. Ләкин ул шатлык-бәхет туе түгел...

Дамир. Ләйлә, син ни сөйләгәнеңне аңлата аласыңмы?

Ләйлә. Мин сезне аерылышу туена жыйдым...

Римма. Аерылышу туе?!

**Барысы да гаҗәпкә кала.**

Дамир. Ләйлә, бу нинди комедия?

Ләйлә. Минем ни әйтәсемне син сизендең... Ул сүзләр сиңа күптән таныш. Тик барыбер туктамыйм, туктар бу дип өметләнмә.

Дамир. Акылыңа кил!

Ләйлә. Әйттем бит—бүлдермә мине.

Дамир. Аңа эчәргә ярамый, Римма, Люция, зинһар тынычландырыгыз аны!

Римма. Әйдә кереп ял итик, Ләйлә.

Люция. Римма, комачаулама.

Ләйлә. Рәхмәт, Люция... Менә сезнең каршыда яшьлек дустыгыз Дамир басып тора. Ул бик тә яхшы күңелле иде. Хәзер аңарда берниндн игелек тә калмады. Ул намус-вөжданын да, кешелеген дә сатты.

Дамир. Ләйлә, Син өскә пычрак аударсаң да чамалап аудар!

Ләйлә. Мин чамамны беләм. Ә менә син... Әйләнә-тирәндә кешеләрнең күз яше, җимерелгән язмышлар гына.

Рафаэль. Дөрес бит, дөрес!..

Ләйлә. Исерек кеше түтәл арасында йөргән кебек, син берсен өзеп ташлыйсың, икенчеләрен ашыйсың, өченчеләрен таптыйсың. Сөяркәләреңә төшемле эш урыннары, фатирлар, коттеджлар...

Дамир. Бәлкем житкәндер?

Ләйлә. Кешеләр каршына чыгып, ике сүзнең берендә син бурыч, ил, халык, намус, гаделлек дисең. Депутат булу өчен ялган вәгъдәләр биреп йөрисең. (*Үкси.*)

Дамир. Бер кешегә... шушы кадәр дә кабәхәтлек... Рәхмәт, Ләйлә. Класслашлар өйдәге әшәкелекләремне дә белеп китсеннәр, әйтеп бетер. Ничек мин сине, балаларны жәберлим, өч катлы коттедж, мохтажлыкта тилмертәм...

Ләйлә. Башкаларны жәберләвең житмәгәнмени? Халыктан йөз мәртәбә яхшырак яшәвебез житмәгәнмени? Бу бит—кешеләрдән урлап алынган бәхет. Кемнәрнеңдер каргышы, күз яше хисабына...

Люция. Точно! Коточкыч авыр тойгы бу. Как будто воруешь.. чувства других...

Ләйлә. Кешеләрнең күзенә туры итеп карарга хакың булмагач, ник яшәргә? Гомер буе урлашып яшәгән шикелле... (*Пауза.*)

Дамир (*уйчан, акрын*). Сез инде мине көн саен ниндидер мәкерле планнар корып, шуларны тормышка ашыру өчен теләсә нинди әшәкелекләр кылып йөрүче бер коточкыч зат итеп күрәсез! Ю-у-ук! Күпчелек бәндә изге ният тә. Садистлар гына кеше газаплаудан тәм таба. Менә минем урынга утырыгыз да гел әйбәт кенә булып карагыз әле сез! Бер кешегә дә авыр сүз дә әйтмәгез, жәза да бирмәгез, ялгышмагыз да, эштән дә кумагыз. Минем дә жаным сезнеке төсле: беркемне дә рәнжетәсем дә, яман булып күренәсем дә килми.

Рафаэль. Менә бит, сөттән ак, судан пакъ кешене син гаепләмәкче буласың, Ләйлә.

Дамир. Юк, аклану түгел бу, аптырау. Мине үзем дә сизмәстән нидер суырып алды. Ул ниндидер хәтәр нәрсә. Ул сине кыса, син—башкаларны... Ниндидер язылмаган законнар. Бүтәнчә булмый... (*Пауза.*)

Иван. Их, Дамир! Синнән шагыйрь дә, музыкант та, башкасы да чыга ала иде бит. Син игелекле идең...

**Озын пауза.**

Люция. Мин бу туйның дәвамына килмәсәм, жиңелрәк булган булыр иде. Авыр тойгы белән китәм.

Гүзәл. Иван, озатып куй Люцияне.

Люция. Не надо. (*Иванның каршына килеп.*) Бер үбәр идем дә... Ярый инде... чиста килеш кал... (*Чыгып китә.*)

Иван. Бүтән күрешмәсәк... Сезне күрдем — мин канәгать. Әгәр ул якларга барып чыксагыз, мине белешегез. Нинди иде дип...

Ләйлә. Иван! Мин барысын да беләм. Без... әгәр теләсәң... мин...

Иван. Юк... (*Пауза.*) Син әле яшә, Ләйлә...

Дамир. Хәзер шалтыратам, машина илтеп куяр.

Иван. Кирәкми, Дамир, Хушыгыз... (*Кинәт Римма аны кочаклап ала, елап җибәрә.*) Тынычлан, Римма, тынычлан. Алайса хушлашыйк инде... (*Гүзәл белән, Рафаэль белән кочаклаша, Ләйлә белән Дамир каршына килә.*) Менә хәзер, нишләптер, үземне түгел, сине кызгандым, Дамир...

Дамир. Кызганма, Ваня...

Иван. Кызганам, Дамир. Ни булса да мин бит үз юлымда... (*Чыгып китә.*)

Римма (*елап*). Без шушының өчен җыелдыкмыни соң? Таралышабыз дамыни?!

Ләйлә. Китмә, кун бездә генә.

Римма. Юк, булдыра алмыйм...

Гүзәл. Исән булыгыз.

**Гүзәл, Рафаэль, Римма чыгалар. Ләйлә белән Дамир озатып керә. Озын пауза.**

Дамир. Йә, нишлибез?

Ләйлә. Белмим.

Дамир. Кызларны бүген әбиләренә җибәргәнең өчен рәхмәт инде.

Ләйлә. Ник?

Дамир. Тәк. (*Пауза.*) Нишләптер бу көннең киләсен мин сизеп йөрдем... Ләйлә, әгәр дә мин бөтенесен ко всем чертям ташласам? Килешеп яшәр идекме? (*Ләйлә дәшми. Дамир кызу-кызу йөренә дә кинәт кычкырып җибәрә.*) Юк, юк, ташлый алмыйм! Ташлатмаячаклар!

**Пауза.**

Ләйлә (*акрын гына тәрәзәгә бара, карап тора да аны ачып җибәрә*). Җырың рас килде...

Дамир. Ничек?

Ләйлә. Кар ява... Йомшак кына, тын гына кар ява... Сары яфраклар кар астында кала...

**Дамир пианино янына утыра. "Сары яфраклар"ны уйнамакчы була, ләкин бармаклары аңа буйсынмыйлар. Ул ике кулы белән дә пианино телләренә берничә мәртәбә доң-доң баса да маңгаен пианино тактасына терәп хәрәкәтсез кала. Ләйлә аңа борылып карамый.**

*Пәрдә.*

*1990*

---

## Киләсе санда укыгыз

*«Шамил Усманов урыннарда чыгып килүче татар газеталарын да күзәтеп бара, ул газеталарга карата күрсәтелгән гаделсезлекне бетерергә тырыша. Менә шул уңайдан Усмановның характерлый торган бер мисал. 1920 елның январь башында Ш. Усмановка Малмыждан бер хат килә. Биредә өяз партия оешмасының татар-башкорт секциясе тарафыннан чыгарылып килә торган «Ярлылар тавышы» газетасының чыгудан туктатылуы һәм аның сәбәбе буларак татарча белмәүче хәрби цензорның бу газетаны басканчы русчага тәрҗемә итеп аңа китерүне таләп итүе турында языла. Бу кычкырып торган ахмак гаделсезлек турында Ш. Усманов туп-туры Ленин исеменә телеграмма җибәрә. Ул үз чиратында бу эшне хәл итүне Троцкийга тапшыра. Ә Троцкий исә ул цензорны , цензорлык хокукын алып, эшеннән куарга күрсәтмә бирә. Шулай итеп «Ярлылар тавышы» газетасын бастыру җайга салына».*

Бу өзек тарих фәннәре кандидаты **Илдус Гыйззәтуллинның** «Язучы—милли гаскәр төзегән каһарман» исемле язмасыннан алынды. Язма тулысы белән журналыбызның быелгы 11 санында басылып чыгачак. Журналның яна санында укучыларга **Мансур Шаһимәрдәновның** «Татлы агу» дигән романының ахыры, **Госман Гомәровның** «Шаһмиран» дигән мажаралы повестенең икенче кисәге, «Татар хикәяләре хәзинәсеннән» рубрикасында **Мәхмүт Галәүнең** бүгенге заманга аеруча аваздаш «Яшәсен ипи белән суган» хикәясе тәкъдим ителәчәк. Шагыйрьләрдән **Әхсән Баян**, **Равил Фәйзуллин**, **Флера Гыйззәтуллинаның** яна шигъри бәйләмнәре, әдәби тәнкыйть мәкаләләре, халкыбызның тарихына һәм мәдәниятенә багышланган күләмле язмалар да укучылар игътибарын җәлеп итәр.

## ПУБЛИЦИСТИКА

**Нургаян Әкбәров**

# ШӘФКАТЬСЕЗЛЕК

### ТАТАРСТАН ЯШҮСМЕРЛӘРЕНЕҢ ҖИНАЯТЬЧЕЛ ТӨРКЕМНӘРЕ ТУРЫНДА СОЦИОЛОГИК КҮЗӘТҮ



*Нургаян Гаян улы Әкбәров — Казан шәһәренең Эчке эшләр идарәсе башлыгы, милиция полковнигы. Аның әлеге мәкаләсе тәрбиягә авыр бирелә торган яшүсмерләр белән озак еллар эшләү тәҗрибәсенә таянып язылган. Гади оператив хезмәткәрдән җаваплы җитәкче дәрәҗәсенә күтәрелгәнче Нургаян Әкбәровка җинаятьчел төркемнәрнең шәфкатьсез гамәлләрен күп күрергә-тикшерергә туры килгән.*

*Шәфкатьсезлек! Аның тамырлары кая китә, сәбәпләре нәрсәдә? Ни өчен хәзерге яшь буын үз корбаннарына шулай мәрхәмәтсез-миһербансыз, рәхим-шәфкатьсез? Автор әнә шул хакта уйлана-борчыла. Үзе тикшергән бик күп вакыйгаларны ул хәзерге чорның катлаулы социаль процессларына бәйләп карый, аларны теоретик фикерләүләре белән фәнни югарылыкка күтәрә. Н. Әкбәровның тарихи фактларны җентекләп өйрәнгәнлеге, шуларга таянып, бүгенге вәзгыять хакында тирәнтен уйлanулары, һаман үсә барган җинаятьчелектән котылу юлларын эзләве аеруча игътибарга лаек.*

*Журнал укучыларын бу хезмәт, һичшиксез, кызыксындырыр дип уйлыйбыз.*

*Профессор Н. С. ФӘТХУЛЛИН.*

* * *

Минем куен дәфтәрләремдә яшүсмерләрнең дистәләрчә җинаятьләре хакында бик күп язмалар теркәлгән. Алар арасыннан мин аеруча шәфкатьсезлек- миһербансызлык белән, әйтергә кирәк ки, кансызлык белән эшләнгәннәрен җентекләп тикшерәм-өйрәнәм, нәтиҗәләр ясыйм. Чөнки мондый җинаятьләр һәрвакыт авыр тойгылар уята, күңелдә тиз генә җавап таба алмаслык күп төрле сораулар кузгата. Ни өчен, ни сәбәптән, бу кадәр шәфкатьсезлекнең нигезләре кайда? Әллә соң кешелек дөньясы алга киткән, тәрәккый иткән саен деградациягә — үзенең бетүенә таба юл тотамы?

Менә берничә мисал.

Ундүрт яшьлек Н. В. Осколков үзенең корбаны М. Ю. Машинны әүвәле бугазыннан алып буа башлый, шул ук вакытта пычак белән аркасына һәм биленә кадый-кискәли, бугазына да дүрт мәртәбә кадап, тирән-тирән яралар ясый. Ул, шул рәвешле, корбанын газаплаудан, аның түзеп булмаслык авырту-әрнүләр кичерүеннән ләззәт ала, тәм таба. Шулай газаплап туйганнан соң гына ул Машинны идәнгә егып сала һәм, муенына янә ике мәртәбә кадап, аны үтерә.

Е. В. Турилин дигән икенче берсе исә тагын да коточкычрак шәфкатьсезлек күрсәтә: ул исерек хәлендә әле балигъ булмаган ундүрт яшьлек кыз бала С.ның башына күп мәртәбәләр чүкеч белән сугып, аны үтерә. Аннары, җинаятен яшерү нияте белән, корбанының гәүдәсен тураклап-кискәләп үзе яшәгән йортның подвалына яшерә.

Әлбәттә, бу җинаятьчеләр төрмәдә утырганда да үзләреннән көчсезрәк-юашрак үсмерләрне кыерсытырга, аларны төрлечә мәсхәрәләп-газаплап ләззәтләнергә юл эзлиләр. Моннан берничә ел элек Казандагы тәрбия-хезмәт колониясендә бер үсмерне учакка салып кыздырырга омтылыш ясадылар. Шуңа охшаш хәл күптән түгел генә — быелның июль аенда башкалабызның Киров районында да булды. Бензин иснәп исергән малайлар төркеме үзләренең ун яшьлек иптәшләрен, өстенә бензин сибеп, яндырмакчы булалар. Янган-пешкән бичара бала авыр хәлдә хастаханәгә озатыла.

Мондый мисалларның исәбе-хисабы юк. Без аларның кайберләренә яңадан әйләнеп кайтырбыз әле. Иң әүвәл бу мәкаләдә сүз алып барыла торган төшенчәләрне тәгаенлик, аларны ачыклап-аңлатып үтик.

## Нәрсә ул шәфкатьсезлек?

Шәфкатьсезлек, миһербансызлык, мәрхәмәтсезлек — болар татар теленә гарәп теленнән кергән алынма сүзләр. Аларның мәгънәләре, нигездә, бер үк шикелле: мәрхәмәтсез-аяусыз булу, рәхим-шәфкать күрсәтмәү, кызгана белмәү һ. б. Әмма шул ук вакытта һәркайсының үзенең төсмерләре дә бар, дини мәгънә белән дә өртелгәннәр. Болардан тыш төрки татарларда мәҗүсилек чорыннан бирле яшәп килә торган тагын бер сүз бар: ул — кансызлык, кансыз булу. Элек-электән безнең халыкта "аның каны каткан" дигән гыйбарә бар. Димәк, йөрәгендә кайнар каны, тәнендә җаны булган кеше кансыз булмаска, ягъни шәфкатьсезлек күрсәтмәскә тиеш.

Урыс теленә мөрәҗәгать итсәк тә, без "жестокий" сүзен шәрехләгән күп төрле мәгънәләргә юлыгырбыз. Мәсәлән, атаклы В. И. Даль болай санап күрсәтә: "Жестокий — немилосердный, безжалостный, бесчеловечный, немилостивый, не знающий жалости, сожаления, сочувствия; безмерно строгий, суровый, тяжкий или мучительный, невыносимый, неодолимо грозный, неумолимый" (Даль В. И. Толковый словарь живого великорусского языка. Русский язык. М., 1989 г.) Күрәсез, бер сүзгә никадәр күп мәгънә салынган! Бу сүз тезмәләре гади синонимнар гына түгел. Аларның һәркайсының үз төсмере-сыйфаты бар. Чөнки шәфкатьсезлек күренеше үзе күп төрле, ул төрле очракларда төрлечә явыз эш-гамәлләрне чагылдыра.

Инде килеп, шулай төгәл һәм анык җаваплар-төшенчәләр бар икән — "нәрсә соң ул шәфкатьсезлек?" дигән сорауга да урын калмый шикелле. Әмма шулай да сораулар туа тора. Алардан качып булмый. Мәсәлән, шундый сорау: шәфкатьсезлек — тумыштан, нәселдән киләме, әллә булмаса, шәхеснең гаиләсеннән, тирә-юнь мохиттән алган тәҗрибәсе аркасында барлыкка килгән начар бер сыйфатмы? Шәфкатьсезлек — кешелек тарихының гомерлек юлдашымы, әллә түгелме? Шәфкатьсезлек-усаллык җәһәтеннән бер милләт икенчесеннән аерылып торамы? Мисалга, "чеченнар — шәфкатьсез халык" дигән сүзләрнең объектив-гадел җирлеге бармы? Ә кыргый хайваннар шәфкатьсезме? Алар, чынлап та, ерткычмы?

Күрдегез, ни кадәр сорау!

Кешелек дөньясының үсеш тарихы шуны күрсәтә ки, бу мәсьәләдә бер генә ил-халыкка да, бер генә чорга да ташлама ясап булмый. Беренче ыруглык җәмгыяте дәвереннән башлап бүгенге көнгә кадәр шәфкатьсезлек күренешләре кешеләрне буеннан-буена озата килгән. Кыргыйлар һәм фиргавеннәр шәфкатьсез булмаганмы? Эллиннар, римлылар һәм вәхшиләр? Урта гасыр инквизициясе һәм иң соңгы җимергеч сугышларның шәфкатьсезлеген ни-нәрсә белән аңлатырга?

Американнар Япониянең Хиросима һәм Нагасаки шәһәрләренә, — инде сугыш җинүле тәмамланган көннәрдә! — атом бомбалары ташлап, бер селтәнүдә йөз меңләгән халыкны юк итмәделәрме? Һәм нинди максаттан чыгып? Киләчәктә бары тик бөтен дөнья ил-халыкларын куркытып тору максатыннан гына.

Шундый хисапсыз фаҗигалар атаклы поляк язучысы Ежи Ельцка күңелсез нәтиҗәләр ясарга сәбәп булгандыр да. Ул болай яза: "Бары бер генә нәрсәне әйтә алам: шәфкатьсезлек кешеләр табигатендәге үзгәрми торган, даими бер сыйфаттыр. Аның тик формалары гына үзгәрә: берниндн Цезарь да, берниндн фиргавен дә, атом бомбасы ташлап, берьюлы йөз меңләгән кешене һәлак итә алмаган булыр иде. Бүген исә бу мөмкин хәл. Бүген без остарак үтерәбез". (Литературная газета", 1996 ел, 2 ноябрь).

Безнең бурыч булган хәл-вакыйгаларны теркәп бару гына булмаска тиеш, теләсә нинди күренешне мистик аңлатулардан тайчанып, аңа фәнни аңлату табарга тиешбез. Нәкъ менә кешеләр арасындагы мөнәсәбәтләр тудырган шәфкатьсезлекне фәнни яктан тикшереп-өйрәнеп аңлаткан хезмәтләр күренми диярлек. Россиядә булсын, чит илләрдә булсын — бик аз алар. Психолог Е. С. Меньшикова бу мәсьәләгә багышланган тау-тау хезмәтләрне актарып-өйрәнеп бер нәтиҗәгә килә: Россиядәге психология фәне шәфкатьсезлек һәм көч куллану, ирексезләү күренешләренең механизмын, нигездә, өйрәнмәгән. Е. С. Меньшикова белән килешергә кирәктер, минемчә. Ә инде чит ил белгечләре үзләренең язмаларында гаиләдә балага карата булган кырыс-усал мөнәсәбәт белән җәмгыятьтәге, җинаятьчел төркемнәр арасындагы шәфкатьсезлек күренешләрен бергә бутап аңлатудан ары узмыйлар да шикелле.

Безнең карашка исә, шәфкатьсезлек — бары тик кешелек җәмгыятенә, кешеләрнең үзара мөнәсәбәтенә генә баглы бер сыйфат. Ә моны һич тә агрессивлык, һөҗүм итүчәнлек сыйфатлары белән тиңләргә ярамый. Агрессивлык — хайваннар дөньясына да хас, әмма анда, көч куллану булса да, шәфкатьсезлек юк. Хайваннар арасында көч куллану аларның яшәү-яшәмәүләренә һәм табигый сайланыш күренешләренә бәйле. Бер төр ерткыч хайваннарның икенче төргә карата көч куллануы ике төр арасындагы көрәшне чагылдыра. Һәр төр үз нәселен саклап калырга тырыша. Бу — табигатьнең табигый кануны. Инде бер төр эчендә шундый көрәш була икән — анысы да табигать кануны. Әйтик, көтүдә-өердә көтү башлыгы, өер айгыры берәү генә була һәм ул иң таза, иң көчлесе булырга тиеш. Бары тик аңардан гына көчле-таза токым туа, көтү-өер яңара, яшәрә, үсә. Юкса, башкача булганда, бу төр хайваннар көчсезләнеп, юкка чыгып бетәр, табигать кирегә китәр иде. Әмма шунысы да бар: көтү-өердә ике ата хайван "туй" вакытларында сугыша, көч алыша икән — алар бер вакытта да бер-берсенә үлем җәрәхәтләре ясамыйлар. Аларны гасырлардан-гасырларга каннарына салынган инстинкт коткарып кала. Ә менә кешеләр, — акылга-аңга ия булган затлар! — әнә шул табигать биргән инстинктларын югалтып, үзләренең акылларына (дөресрәге, акылсызлыкларына!) таянып, шәфкатьсез рәвештә бер-берсен юк итү, үтерүгә кадәр баралар. Әле ярый, үзеннән гомереңне саклап калу исәбенә булса иде, күбесенчә гел юк кына сәбәпләрдән килеп чыга бу шәфкатьсезлек.

Кешеләрдәге шәфкатьсезлек берничә төрле була, фән теле белән әйтсәк, берничә типка бүленә.

Беренче төр (тип) — кешедәге начар сыйфатларның берниндн контрольсез-чикләүләрсез тышка бәреп чыгуы. Бу очракта хәтта әйбәт кенә кеше дә шәфкатьсезлек кылырга мөмкин. Андый кеше үзенең начар гамәл кылганын да аңлыйдыр, әмма үзен вакытында тыеп кала алмый. Ул, бәлки, соңыннан бик каты үкенәдер дә, тик инде эш узган була. Мондый кешедә психик авыру башланган яки инде ул чын-чынлап авыру, дияргә була. Бәлки, бу усаллык-явызлык нәселдән — геннар белән салынадыр да, аннары үстерелә-ныгытыладыр. Монысы алдан уйланып эшләнгән шәфкатьсезлек түгел, башка берәүгә яки тирә-юньдәге кешеләргә уйсыз-ниятсез генә, үзең дә белештермәстән рәнҗү китерү. Мондый "шартлаулар" аның иясенә үзендәге стресслардан арыну, аңа төбендә яткан киеренкелектән бушану бирә. Үз гамәлләренең начарлыгын соңыннан, эш узгач аңлау әлеге шәхеснең үзенә дә газап китерергә мөмкин.

Авыру халәткә дучар булган кешеләрнең кайберләре, киресенчә, кылган явызлыгыннан, кемнедер рәнҗетүдән ләззәт ала икән — ул инде шәфкатьсезлек күренешләренең икенче төре (тибы) буладыр. Моңа мисал итеп атаклы психолог Владимир Левиның бер китабында бәян ителгән вакыйганы китерергә мөмкин. Владимир Леви бервакыт бер хирург ханым янына килә. Сәбәбе: бер бармагына кечкенә генә операция ясарга кирәк икән. Табибә ханым операцияне шул кадәр

ләззәтләнеп һәм кирәкмәгәнгә бик тә авырттыра-авырттыра ясый. Психолог буларак, Вл. Леви мона игътибар итми кала алмый. Сөйләшә торгач, ул табибә ханымның психикасында авыруга тиң үзгәрешләр булуын ачыклый, ханым моны үзе дә раслый.

Шәфкатьсезлекнең өченче төре (тибы) — максатчанлык. Бу очракта усал-явыз кешенең корбанына ниндидер физик авырттыру, газаплар китерүе турында гына бармый сүз. Андый шәхес алдан уйлап, нинди булса да бер максатны күздә тотып җинаять кыла. Ул үз корбанына каршы көч куллана, аны ирексезли-көчли, үз теләгенә каршы ниндидер гамәлләр кылырга мәҗбүр итә. Шулай итеп, җинаятьче үз максатына ирешә. Күп кенә очракта корбанын юк итүгә дә бара.

Кешелек дөньясының үсеш тарихы шундый мисаллар белән тулып ята. Шәфкатьсезлек күренешләре бу очракта анык бер җәмгыятьнең анык бер чорга караган менталитеты (үзенчәлеге) сыйфатында гәүдәләнә. Бу җәһәттән караганда, бер ил башка илләрдән, дөресрәге, бер ил халкының бер өлеше (вәкилләре, диик) башкалардан аерылып тора. Мәсәлән, колгага утырту, шул рәвешле җәзалап үтерүне урысларга гына хас шәфкатьсезлек дип әйтергә була. Шуннан урысның "дыба", "поднять на дыбу" дигән тәгъбир-төшенчәләре килеп чыккан да инде.

Урыс тарихчысы Н. В. Костомаров Явыз Иван патшаның (Иван Грозныйның) шәфкатьсез-миһербансызлыгын сурәтләп болай яза: "казыкка утыртты, тимер белән бәреп үтерде дә, янадан казыкка утыртты".

Ә менә инквизиция кулланган җәза чаралары, нигездә, урта гасырда Франция, Испания, Португалия кебек илләр уйлап тапкан җәзалар. Җәза төрләрен камилләштерү, төрле дәһшәтле явызлыклар уйлап табу, иң шәфкатьсез җәзаларны соң чиккә җиткереп оста башкара белү, аның барлык атрибутларын-кагыйдәләрен нечкә бер төгәллек белән үтәү —болар барысы да җәза мәйданына "тамаша кылырга" куып китерелгән халыкның котын алу, куркыту, дер калтыратып тоту өчен эшләнелә торган гамәлләр булган. Җәзалауны җәллад аеруча бер салкын канлылык белән, тәмен белеп башкарган.

Төрмәләрдәге җинаятьчеләрнең "гаепле" тоткынны кансыз-миһербансыз каты җәзага тартулары да җәллад эше кебек салкын канлылык белән, барлык йолаларын җиренә җиткереп үтәлә. Гомумән, рәхим-шәфкатьсез җәзалар җинаятьчел дөньяның үзенә күрә бер кануны ул. Ленинград язучысы Лев Самойлов "караклар советы" уйлап тапкан алты җәзаның берсе дип "гаепләнене" төне буе җыйнаулашып кыйнау-газаплауны атый. Төне буе кыйнау-тукмау — авыр эш, җәзалаучылар үзләре дә артык ләззәт ала алмыйлар, хәлдән таялар, әмма бу мәҗбүри кирәкле гамәл, чөнки ул башкаларны куркытып тоту өчен "тәрбия" чарасы да, профессионал җинаятьчеләрнең үз кануннарын ныгытуы, үз "йолаларыннан" тайпылмаулары өчен дә кирәк. Әгәр җыйнаулашып җәзалаучылар үз вазифаларын җиренә җиткереп, "гаепленең" үзәгенә үтәрлек итеп башкармыйлар икән, караклар кодексы буенча, алар үзләре үк шундый җәзага тартылачаклар.

Күргәнебезчә, бу төр шәфкатьсезлекләрнең асылы социаль мәсьәләләргә барып тоташа. Аның формалары күп төрле һәм туктаусыз камилләшә бара, максатчан булуы да көн кебек ачык. Шул ук вакытта ул формалар кешелексез, шуның өчен дә аларны социаль тормышыбызның аерым тармакларында барган деградация — таркалу күренешләре дип бәяләргә кирәктер.

Көнчыгыш илләрендәге "юлбашчыларның" шәфкатьсез деспотлыгы турында сүз барамы, Европа илләрендәге "цивилизацияле" шәфкатьсезлекме, яки Сицилия мафиясенең үтә "оста" миһербансызлыгымы, әллә булмаса безнең гасырның утызынчы елларында Лубянка подвалларындагы ерткычлыкларmы —болар барысы да тормыш сөючән кешелек дөньясына утырган социаль куныклар-тутыклар. Ул — рухсызлык, кешелексезлек!

Шул нисбәттән чыгып караганда, фиргавеннәр, шаһлар, патшаларның җинаятьчеләрне (хәтта алар гаепле булган очракта да!) аеруча миһербансыз җәзаларга хөкем иттерүләре ул хакимнәрнең дә рухи яктан кешелексез шәхесләр икәнлегенә дәлил генә. Кызганыч ки, кешелекле, рәхим-шәфкатьле хакимнәр кешелек җәмгыяте тарихында һәр чорда да аз булган шул.

Әлбәттә, көн саен үз вазифаларын башкарып, үлем җәзасына хөкем ителгәннәрне электр урындыгына утыртучы җәллад берәр кыз-хатынга урамда куркыныч янаганда, аны яклап ташланырга да мөмкиндер. Әмма Хиросимага атом бомбасы ыргытырга фәрман биргән президент әхлаксыз, кешелексез, рәхим-шәфкатьсез зат. Сталин белән Гитлер да шәфкатьсезләр генә түгел,

әхлаксыз-бозык, психик авыру бәндәләр булганнар. "Бөек" Мао хакында да шуны ук сөйлиләр.

Җәмгыятьтәге шәфкатьсезлекнең котылгысыз социаль күренеш икәнлеге турында сүз йөрткәндә, аның һәрвакытта да аерым кеше, аерым шәхес тарафыннан башкарылганлыгын әйтеп китми мөмкин түгел. Бу очракта, билгеле инде, җинаять кылучының шәхси сыйфатлары искә алынырга тиеш: аның холкы-табигате, дөньяга карашлары, аң-белем дәрәҗәсе һ. б. Әмма боларның берсе дә кешенең кылган гамәлләре социаль шартларга бәйле икәнлеген инкяръ итми. Һич кенә дә теге яки бу илдә шәфкатьсезлек күренешләре күп, чөнки анда усал-явыз кешеләр дә күбрәк, дип аңлатырга мөмкин түгел. Япониядә, мәсәлән, балаларны бөтенләй кыйнамыйлар. Бу — анда меңнәрчә еллар дәвамында барлыкка килгән гореф-гадәтләр, йолалар, мәдәни аң үсеше, яшәү рәвеше нәтиҗәсе. Әмма аңа карап кына Япониядә шәфкатьсез җинаятьләр кылынмый дип әйтеп буламы? Һич юк.

Җәмгыятьне гуманлырак, кешелеклерәк итү максатыннан чыгып, хакимият төрле ысул-алымнар эзли. Шәфкатьсезлек, усаллык-явызлыкның асылын аңлатырга тырышкан байтак теорияләр, фикерләр, карашлар бар. Шундыйларның берсе —галим-голәмә арасында киң таралганы Зигмунд Фрейд тәгълиматы. Зигмунд Фрейд (1856-1939) — австрияле табиб, невропатолог һәм психиатр. Аның психоанализ теориясен һәм методын фрейдизм дип йөртәләр. Бу табиб, барлык кешеләрне бер калыпка сала да, явызлык шәхеснең табигатендә-канында, аңардагы "эго" — "мин-минлегендә", дип өйрәтә. "Эго" —латинча "мин" дигән сүз. "Эгоист" — үз-үзен генә сөюче кеше.

Бу җәһәттән күренекле татар шагыйре Сәгыйть Рәмиевнең "Мин" исемле мәшһүр шигыре искә төшә:

"Мин!" димен мин, "мин" дидисәм
Мина бер зур көч кирә;
Аллалар, шаһлар, кануннар
Булалар бер чүп кенә...

... "Мин!" димен мин, яшәсен "Мин!"
"Мин" минемчөн Алла ул;
Рухым үлгәндә күренсә,
Рухыма җан салган ул.

Күрәсең, шагыйрь кайчандыр Зигмунд Фрейд тәгълиматлары белән шактый мавыккан булгандыр, ул аның "эго" асылын искиткеч тулы ачып салган. Безгә калса исә, З. Фрейдның табиб-психиатр буларак гамәли эшчәнлеге аның теоретик өйрәтүләреннән күпкә файдалырак һәм нәтиҗәлерәк булган.

Шундый ук теоретик фикерләр рәтенә И. Лалаянцның шәфкатьсезлекнең асылын табигый-биологик яктан килеп аңлатырга тырышуын да кертергә кирәктер. Аның фикеренчә, кешеләрнең яки хайваннарның бертигез шартларда үзләрен төрлечә тотулары аларның геннарына салынган. Табигать кануны шундый. "Явызлык-усаллык гены", имеш, хатын-кызларның җенси "Х" хромосомаларында туплана. Ул геннарны мирас итеп алуның үзенчәлеге шунда, имеш, "яраксыз" генны балага ана бирә, ә нәселдән килгән бу явызлыктан ананың уллары җәфа чигә. (Бу авторның "Семья и школа" журналындагы "Энергия агрессии" дигән мәкаләсен карагыз. 1995 ел, N 5.)

Бөтенесен дә шулай җинел аңлатырга тырышучылар шактый еш очрый. Аерым алганда, Галина Леонова ("Огонек" журналы, 1996 ел, N 2) бер мәкаләсендә "усаллык, гомумән, ир-атларга хас сыйфат һәм аны тестостерон дигән җенси гормон эшләп чыгара, шуннан башка чын ир-ат булмый" дип расларга тырыша. Күпмедер усаллык сыйфатларыннан башка "сугышчан шәхес" була алмый, президент, министр, директор, теләсә нинди атаман-лидер шундый сыйфатларга ия, имеш. Автор хәтта шуна барып җитә ки, Совет хакимияте, халыктагы усаллык-явызлыкны киметү ниятеннән, армия төзегән, спортка игътибар иткән, яшьләрдән чирәм күтәрткән, комсомол төзелешләре оештырган икән. Көнбатыш демократиясе исә, армия һәм спорттан кала, хиппилар, рок-музыкалар, мәдәнияттә авангардизм алымнары кебек күренешләргә дә юл куя килгән, имеш...

Сүз дә юк, болай фикер йөртүләр дә яшәргә хаклыдыр. Әмма бөтенесен дә тестостеронга гына кайтарып калдыру бик беркатлылык булыр иде. Әйтик, ни өчен хәзерге яшьләр армиягә барудан куркалар, аннан качалар? Армиягә

яманаты чыккан "дедовщина" — "бабайчылык"каян килеп керде? Элек ул юк иде бит. Әле быел җәй көне генә Россия телевидениесе журналисты Артем Боровик үзенең "Совершенно секретно" ("Үтә яшерен") программасында җан өшеткеч кадрлар күрсәтте. Ул аны каян алгандыр — анысы билгесез. Әмма ул документаль кадрлар, яшерен камера белән төшерелеп, Америкада күрсәтелгән, Америка халкы шок хәленә төшкән — татарча әйтсәк, шаккаткан. Әлеге телевизион лентада Россия армиясенең иң абруйлы частьларенең берсендәге хәлләр күрсәтелә: яшь солдатларны таш дивар буена тезеп бастырганнар да, "бабайлар" чиратлашып аларны тукмапмы тукмый — кайсы җиренә эләгә, шунда суга, тибә, бугазыннан ала... Яшь солдатлар — мескеннәрдән ник берәрсе каршылык күрсәтсен! Шушымы икәнни армиядә кешеләрдәге усаллык-явызлыкны киметү ысуллары?

Бу "яман чир" ниндидер җинаятьләр кылып, кайчандыр төрмәләрдә утырып чыккан яшьләр тарафыннан, армиягә алынгач, үзләре үзләштергән "төрмә кануннарына" охшатып таратылганы беркемгә дә сер түгел.

Аннары тагын бер мәсьәлә. Әгәр дә усаллык-явызлык ир-атлардагы тестостеронга гына тәрәлеп кала икән, хатын-кызлар, бигрәк тә яшүсмер кызлар арасындагы шәфкатьсезлек-миһербансызлык каян килеп чыга соң?

Хәер, монысы хакында алдарак тәфсилләбрәк сөйләшербез әле.

## Яшүсмерләрдәге шәфкатьсезлек

Казанның "Кварталлар" дип йөртелгән микрорайонында балигъ булмаган балалар эшләре инспекторы, милиция югары уку йортында читтән торып укучы Олег Трофимов үзенең һәм күршедәге участокларның дистәләгән яшүсмерләр төркемнәрен күз уңында тота. Ун-унҗиде яшьлек бу "батырларның" гадәтләрен, кылган гамәлләрен яхшы белә, төркемнәр арасындагы кырыс-каты, еш кына кешелексез "язылмаган кануннарны" аңлап эш итә. Һәр төркемнең үз тамгасы —символикасы бар, җир-мәйдан (территория) чикләре билгеләнгән, һәр төркем каттый бүленештә. Олег Трофимов аларның исем-фамилияләрен язып-теркәп бара: кем атаман-лидер, кем актив, кем төркемнең гади әгъзасы — аңа барысы да билгеле. Рәсми булмаган бу төркемнәр, үзләренең аралашу мөнәсәбәтләреннән, әйтергә кирәк, кешелексез мөнәсәбәтләреннән һәм һәркемгә бирелгән бәяләмәдән чыгып, үзләренчә гаҗәп рәсми дәрәҗә-баскычларга бүленгәннәр.

Вәзгыять шундый, теге яки бу яшүсмерне гаиләсе, ата-анасы яклап-саклап кала алмаса, аңа төркемнән читтә йөрү мөмкинлеге юк. Ләкин андый ышанычлы гаиләләр хәзерге шәһәр шартларында күпме генә соң?

Бу төркемнәрдәге усаллык-явызлык, шәфкатьсезлек аеруча үзенчәлекле, аеруча максатчан була. Сүз һәркөнне үзеңне таныту, төркемдәге дәрәҗәңне раслап тору турында бара. Әгәр аз гына куркаклыгыңны сиздерсәң — беттең: син көн саен, һәрвакыт кыйналып торачаксың. Олег Трофимов өлкәнрәк ике үсмернең төркемгә яңа кергән берәүне сынаганнары, ничек итеп "ныклыгын" тикшергәннәре турында сөйләгән иде. Бу "яңа бәрәнне" озаклап-тәмләп кыйныйлар. Малай сер бирми, нык тора. Икенче көнне төркемдә игълан итәләр: бу малай —"пацан", димәк, куркак та, хыянәтче дә түгел, дигән сүз. Икенче бер мисал. Унөч яшьлек малай сөйли, мин үземә-үзем хуҗа түгел, мин бернәрсә дә эшли алмыйм, һәммәсен дә төркем хәл итә. Үзара дуслык-иптәшлек мөнәсәбәтләре, кемнең кем булуына карамастан, катгый тыела. Төркемнең бердәмлеге, ныклыгы, оешканлыгы һәрберсенең "һәркем кебек булырга" дигән гомуми кагыйдәгә буйсынуда, көтү-өер булып яшәүдә.

Катгый кагыйдә — һәрвакыт җыйнаулашып эш-гамәл кылу. Үзара мөнәсәбәтләрдә берниндн кызгану булмаска тиеш — монысы да катгый таләп. Димәк, син үзеңнең төркемдә булу хокукыңны даими рәвештә усаллык-явызлык һәм шәфкатьсезлек аша раслап торырга тиешсең.

1996 елны "Раки" ("Кыслалар") кафесенда берәүне винтовкадан куркусыз-нисез атып үтерәләр. Үтерүченең төп максаты үз төркемендә абруй-дәрәҗәсен күтәрү була. Тотыла-нитә калса, үзен каты режимлы ун ел төрмә көткәнен белсә дә, бу егет шундый куркыныч эшкә бара. Үзенең абруен күтәрү өчен аңа башка юл юк.

Яшүсмерләр арасындагы җинаятьчелекне өйрәнүче күренекле галим, профессор В. Пирожков та шулай билгеләп үтә: "Абруй-дәрәҗәңне күтәреп,

өскә үрләр өчен нинди дә булса үтә кыю җинаять ясарга кирәк", — ди ул.

Җинаятьчел төркемнәрнең өер башлыгы — лидеры әле житлегеп житмәгән яшүсмер дә, акыл кергән егет тә булырга мөмкин. Лидерлар, үзенә житенкерәмәгән оештыру сәләтен, баш булып тору максатыннан, башка шәхси сыйфатлары — шәфкатьсезлек, оятсыз кабахәтлек, садистлыкка омтылышлары белән тулыландыра.

Садистлык дигәннән, бу төшенчәнең ничек килеп чыкканлыгын да аңлатып үтик әле.

Маркиз Донасьен Альфонс Франсуа де Сад (1740-1814) —француз язучысы. Дипломат улы. Сексуаль җинаятьләр кылып, күп тапкырлар кешеләр үтергәне өчен төрмәләрдә утыз ел утырган. Шунда утырганда сексуаль бозыклыклар, һәртөрле әшәкелекләр, мәхшәрләр, коточкыч саташулар белән тулы романнар язган.

Сад исеменнән садизм, садистлык төшенчәләре барлыкка килгән. Икенче бөтендөнья сугышыннан соң "садизм — ул хәзерге дөньяны танып белүдә әһәмиятле бер сыйфат" дигәнрәк фикерләр дә ишетелә. Гади халык телендә исә садизм, садистлык — шул ук шәфкатьсезлеккә тәнгәл төшенчә.

Күп кенә мәкаләләрдә җинаятьчел төркемнәрнең тормышыннан һәртөрле вакыйгалар сурәтләнә. Әйтик, Галина Мусалиева ("Огонек" журналы, 1996 ел, N 25): "Алар кыргыйланган сукбай этләр өеренә охшаган. Һәрвакыт көтмәгәндә генә почмактан килеп чыгып ябырылалар", — дип яза. Аның очерк герое Сережаны шундый каты кыйнап ташлыйлар, ул мескеннең урыныннан торып, ишек кыңгыравына басарлык та хәле калмый. Сергейны кыйнауда катнашкан төркемдәге Гад кушаматлы яшүсмер болай фикер йөртә: "Сезнең Сергеегыз шәхес түгел, ул бер төркемгә дә керми. Шәхес нәрсә соң ул, дисезме? Төркем башлыкларының сиңа хөрмәте булганда гына шәхес син. Төркем өч өлешкә бүленә: иң зур башлыклар, алардан соңгы башлыклар һәм башлык булмаганнар. Мин, мәсәлән, башлык булмаганнар арасында, ләкин мине иң зур башлыклар да белә һәм, кирәге чыкса, алар мине яклаячак. Димәк, мин — шәхес! Ә Сергей, бу тирәдә бер ел яшәп, хәтта кушамат та ала алмады". Бу үсмергә: "Шәхесләр өер булып йөрми бит", — дип әйтеп карыйлар. Ләкин Гадның үз туксаны туксан: "Әгәр артында төркем тормаса, син беркем дә түгел. Менә без ни өчен барыбыз да Сергейга ябырылдык", — ди ул. Шушы ишек алдында яшәүче Саша исемле малай әйтә: безнең кысан ишек алды төрмәгә әйләнде, мин үзем үлмәсәм, мине үтерәчәкләр.

Яшүсмерләрнең мондый төркемнәре аерым бер төбәктә, кварталда, ишек алдында җинаятьчел мөнәсәбәтләрнең бербөтен системасындагы иң түбән бер буыны — чылбыры ул. Теге яки бу төркемнең үзлегеннән оешуы-укмашуы нинди дә булса өлкән бер җинаятьченең, төрмәләрдә күп тапкырлар булган рецидивистның җентекле күзәтүе белән генә эшләнә. Кагыйдә буларак, яшүсмерләр төркеме анык бер максатка яки бер генә тапкыр башкарыла торган берәр эш-гамәлгә юнәлтелә. Күбесенчә бу төркемнәргә пычрак һәм тупас эшләр кушыла: рэкет, ягъни куркытып акча алу, бурычлыларның әҗәтен түләтү, гаепплеләрне, "хыянәтчеләрне" җәзага тарту һ. б. Эчтәлеге белән бу гамәлләр һәрвакыт көч куллану, кыйнау-янау белән бәйле. Теге яки бу шундый "эш-йомыш" төркемнең шәфкатьсез-миһербансыз булуын таләп итә. Хәтта хатын-кызларга яки балаларга карата туган кызгану хисе дә "эшнең" уңышсыз тәмамлануына китерергә мөмкин бит. Әлбәттә, тагын да катлаулы, җаваплы "эшләргә" өлгергәнрәк (16-19 яшьлек) егетләр тартыла.

Болар — җинаятьчел дөньяның ялчылары, коллары. Нәкъ менә шулар ешрак суд хөкеменә тартылалар, чөнки аларның гаепләре-җинаятьләре тиз исбатлана, ә инде төрмәләрдә исә алар "мәктәп" үтәләр, җинаятьче булып камилләшә —"үсә" баралар. Төркем — җинаятьчел дөньяның иң төбе дип әйтергә мөмкин. Чөнки нәкъ төркемдә үзара мөнәсәбәтләр бигрәк тә кешелексез, бигрәк тә кабахәт була. Гад кушаматлы үсмер әйткән "башлыклар" үзләре пычрак эштән — үтерү, җәзалау кебекләрдән баш тартырга да булдыралар. Ул "башлыкларның" төп бурычы — җинаятьләрне оештыру һәм башкарып чыгу, хакимият яки хокук саклау оешмаларындагы төрле түрәләрне сатып алу, аларга ришвәт бирү һәм шулай ук җинаятьчел дөньяның идеологиясен — кануннарын саклап тору. Әмма болар да иң аста торучы "сугышчылардан" шәфкатьсезлек-миһербансызлыкта һич калышмыйлар. Аларның явызлыгы, оятсызлыгы һәм кансызлыгы ярылып ята: алар үзләренең җинаятьләрен кылырга чия төсендәге "тугызлы" "Жигули"ларда яки чит ил машиналарында гына йөриләр. Җинаятьчел дөньяның иң төбе булган бу төркемнәр үзләренә

йөкләнгән "эшләре" буенча ук мәрхәмәтсез була. Аларга башкача ярамый.

Профессор В. Пирожков мондый нәтиҗә ясый: "Өстәгеләр" белән "астагылар" арасындагы үзара мөнәсәбәтләрдәге катгый субординация, ягъни түбән дәрәҗәдәгеләрнең югарыдагыларга сүзсез буйсынуы, "түбәннәрне" "өстәгеләрнең" аяусыз изүе-жигүе — төркемнәрне иләүнең котылгысыз шартыдыр. "Түбәннәр" белән үзеңнең хезмәтчеләрен-колларың шикелле итеп эш йөртү — үзеңне иң югары баскычтагыларга тиң икәненне исбатлау ул. "Түбәннәрне" рәнҗетүнең тулы бер системага салынган ысул-алымнары бар. Һәм ул, вакыты житкәч, "бумеранг законына" әверелә, кайтарып бәрә. Ягъни "түбәннәр" арасыннан "өстәгеләр" арасына күтәрелгәнә үзенең үткәндәге җәберләнүләрен оныта алмый һәм үзе дә башкаларны җәберли-кыерсыта, аларны талый башлый. Армиядәге бабайчылык та шушы ук кануннарга таяна.

Ниһаять, хатын-кызларның рәхим-шәфкатьсезлеге турында да бераз сөйләп китү кирәктер.

Соңгы елларда кызлар арасында җинаять кылу аеруча артып китте. Аларның да үз төркемнәре оеша башлады. Шундыйларны Казанда "моталкалар", ягъни "уралып-буталып йөрүчеләр" дип, ә кайдадыр, әйтик, Чабаксарда "метелкалар" — "себеркеләр" дип атап йөртәләр. Кыскалык һәм төгәллек өчен без "себеркеләр" сүзен кулланыйк. В. Ереминнын әйтүенчә, бу "себеркеләр" яшүсмер малайларны бозылмаган, гыйффәтле кызларны көчләргә әзерлиләр, ул көчләүләрне үзләре оештыралар һәм көчләгәндә "егетләрдән" иң кабахәт сексуаль әшәкелекләр эшләүләрен таләп итәләр. Мондый "себеркеләрнең" кайберләре шундый гамәлләрдән соң нииндидер канәгатьлек ала: әнә, бу саф кызны да аның шикелле "себерке" ясадылар бит...

Идрис Гыйльманов Чаллыда һәм Алабугадагы кызларның җинаятьчел эшләрен өйрәнеп, аларның артык шәфкатьсезлек һәм садистлык белән аерылып торуларын күрсәтә. Бу шәһәрләрдәге "себеркеләр" үзләре теләп авыр җинаятьләрдә — балигъ булмаган кызларны көчләүдә катнашалар икән. Аерым алганда, И. Гыйльманов шундый бер вакыйганы китерә: Алабугада уналты яшьлек бер гаепсез кызны көчләүне сыйныфташ кызлары оештыра. Янәмәсе, ул кызый болар турында "алар кыз түгел" дигән гайбәт таратып йөргән.

Тагын бер җирәнгеч, сөйләргә дә уңайсыз мисал. Бу хакта моннан берничә ел элек матбугатта язып та чыккан иделәр. Шулай булгач, безгә дә аны искә төшереп үтү зыян итмәс. Бер "себерке" кызый, дус-иптәш кызының үзенә ияреп йөрмәгәненә үртәлеп, тегене яшүсмер малайларга тоттыра һәм, ботын-чатын аерып, мескеннең җенси әгъзасына электр лампочкасы тыга, аны шунда вата, аннары яраларыннан кан аккан "дустына" карап, мәсхәрәле төстә: "Менә, хәзер син дә миңа иш булдың инде!" —дип көлә.

Кама-Чулман аръягы кызлары — "себеркеләрнең" төп "һөнәре", җөмһүриятебезнең башка сәнәгать (промышленность) төбәкләрендәге кебек үк — фахишәлек. Алар бу гамәлләрен "эшмәкәр", "бизнесмен" исемнәре астына яшеренеп эш итүче җинаятьчеләр белән берлектә алып баралар.

## Үсмерләр шәфкатьсезлеге — шәфкатьсез дөнья җимеше

Кешеләр арасындагы үзара мөнәсәбәтләрдә, бигрәк тә үсмер яшьтәгеләрдә шәфкатьсезлек-миһербансызлык күбесенчә (туксан процентка) социаль шартлар белән бәйләнгән була. Безнең моңа иманыбыз камил. Әгәр дә бүгенге яшь буын бозык-начар икән, моның сәбәпләрен җәмгыятьнең үз бозыклыкларыннан эзләргә кирәктер. Яшүсмернең үз корбаннарына карата кылган явызлыклары, шәфкатьсезлеге — шулай ук социаль сәбәпләрдән килеп чыккан сыйфат. Мондый гамәлләрнең бары тик ун проценты гына медицина карамагына бирелергә тиешле авырулар тарафыннан башкарыла. Калганнарының сәбәпләре социаль сәбәпләр һәм сәяси булырга тиеш.

Бу мәкалә инде матбугатка әзерләнеп беткән көннәрдә "Криминальная хроника" газеты (1998 ел, № 7) "В России растет поколение обсолютной жестокости" дигән гомуми баш астында зур мәкалә бастырды һәм бик борчылырлык, куркыныч фактларны китерде. Аерым алганда, анда мондый мәгълүматлар бар: 1997 елда Россиядәге балалар йортларында 62,6 мең бала тәрбияләнгән, шуларның 57,2 меңе әти-әниле, аларның әти-әниләрен ата-ана хокукларыннан мәхрүм иткәннәр. Димәк, бу "әти-әниләр" йә эчкече, йә наркоман, йә җинаятьче. Хәзер Россиядә үсмерләр җинаятьчелеге Көнбатыш Европа

илләрендәгегә караганда ике мәртәбә артыграк икән. Янә бер борчылырлык мәгълүмат: бүгенге яшүсмерләр үзләренең 1991 елдагы яшьтәшләренә караганда өч мәртәбә ешрак авырыйлар. Һәм, ниһаять, җан өшеткеч хәбәр: 1996 елда илдә өч мең яшүсмер үз-үзенә кул салган, үзен үтергән.

Социаль шартларны, нигездә, төп өч төргә бүлеп карарга кирәктер. Беренчесе — шәхесне тәрбияләүдә төп бурычны үтәргә тиешле гаилә, икенчесе — гомуми мәгълүмат чараларының (радио-телевидение, газет-журналлар, төрле чүп-чар китаплар һ. б.) турыдан-туры тәэсире һәм өченчесе — кешелек җәмгыятенең деградациягә бирелүе, бетүгә-таркалуга таба йөз тотуы.

Гаиләләрнең таркалуы, алардагы рухсызлык, тәрбия итү бурычларын оныту — болар хәзер беркемдә дә шик калдырмый торган күңелсез чынбарлык.

Күңелемдә уелып калган бер вакыйга. Бик соң гына, инде төн уртасы авышкач, милиция бүлегенең кизү бүлмәсенә унөч яшьлек татар кызын китерделәр. Әйе, әйе, халык җырларында җырланган, егетләр сокланырга тиешле әдәпле вә саф, садә күңелле, киләчәктә балаларына сөекле әни булырга, милләтебезгә лаеклы балалар тәрбияләп үстерергә тиешле татар кызын! Аны хулиганлык кылганы, үзен әдәпсез-тупас тотканы, әшәке сүзләр әйтеп сүгенгәне өчен тоткарлаганнар икән. Кизү бүлмәсендә дә кызый әдәпсезләнде, чәбәләнде-кычкырынды, хәтта кемнәргәдер кизәнеп тә маташты. Аның кулына богау салырга туры килде. Башка тоткарланучылар белән без мәш килгән арада, кызый юкка чыккан иде инде. Ул баланың кулары шулкадәр нечкә-зәгыйфь икән, богауларны шудырып кына төшергән дә чыгып качкан. Бераз вакыттан аны яңадан тотып китерделәр һәм камерага бикләп куйдылар. Ә ул мескенкәй шундый ябык, тәрәзә рәшәткәләре арасыннан да иркен генә үтеп, тагын чыгып шылган. Соңрак ул кызыйның бик авыр гаиләдә, эчеш-исереш, ызгыш-талаш шартларында даими кыйналып үскәнлеге мәгълүм булды. Андый шартларда ул, әлбәттә, үзе дә мәрхәмәтсез бер бәхетсез җан булып үскән...

Икенче мисал. Бу хакта "Комсомольская правда" газеты язып чыккан иде. Уфада булган хәл. Унбишәр яшьлек ике кыз үзара мөнәсәбәтләрен ачыклау өчен билгеле бер урында очрашырга сүз куешалар. Очрашалар. Ызгыша-талаша башлыйлар. Бик ачуы чыккан берсе икенчесенең битенә көйрәп торган сигарет белән баса, тегесе күп уйлап тормый, җавап итеп көндәшенә пычак белән кадый. Ике кыз да төркемнекеләр, икесе дә авыр гаиләдән. Берсенең әнисе — татар хатыны — бу вакытта төрмәдә утыра икән.

Җәмгыять гаиләдә бала тәрбияләү мәсьәләсендә бернәрсә дә эшли алмый. Усал-явыз балалар үзләрен даими кыерсытып торган гаиләләрдә үсәләр. Күзәтүсез-караучысыз калган балалар әти-әниләренең бер-берсенә карата булган рәхимсезлеген, бер-берләрен рәнҗетүләрен күреп үсә. Һәм, үсә төшкәч, алардан үрнәк алып, шундый ук гамәл кыла башлый.

Балалар һәм яшүсмерләр психологиясенә һәм психотерапиясенә багышланган хезмәтләре белән танылган галим Эрик Эриксон болай яза: "Баланың күңелендә нинди үзгәрешләр буладыр — билгесез, әмма күзәтүләр шуны күрсәтә: бала күңелендә бик иртә туган ышанмаучылык алга таба тоташ "үч-ачуга" сәбәпче була, балада рәхәт-тук тормышта яшәүчеләргә хуҗа булу хисе кабына, бу хис-хыял алга таба "рәхәт-тук яшәүчеләрне" юк итәргә өнди башлый, бу хыяллар, бу ачу килүләр һич тә юкка чыкмыйлар, еллар үткәч, аерым бер экстремаль шартларда янадан анда кабыналар". Э. Эриксон искәртә: "Иң җаваплы чор — баланың биш яшьләр чамасы чоры, бу вакытта анарда максатчан һәм бик көчле мөстәкыйльлек, "мин үзем эшлимлек" үсеш ала башлый, акылы-аңы да оешканрак төскә керә. Бу чорда ата-ананың түземлеге һәм ныклыгы-катгыйлыгы гына баланың үсешенә дөрес юнәлеш бирергә мөмкин. Башкача булганда, баланың җитлекмәгән аңында "үзгәрмәскә тиешле" төшенчә барлыкка килә, алар баштарак баланың үзенә зыян китерсәләр, үсә төшкәч, теге яки бу рәвешле башкаларга каршы юнәлтеләчәк".

Хәзер гаилә тирәнтен өйрәнүне, дәүләт оешмалары тарафыннан социаль күзәтүне, икенче төрле әйткәндә, гаилә коруны һәм аның белән идарә итүне җайга салуны сорый. Яңа өйләнешкән яшь парларның илле процентка якыны таркала. Ни сәбәптән? Чөнки бала тәрбияләү мәсьәләсендә ни педагогик, ни хокукый әзерлеге булмаган яшьләр никахлашалар. Аларны гаилә тормышына өйрәтү максатында бернинди дә эш алып барылмый. Беркем дә: "Менә бу яшь гаиләнең балалары тәрбияле, әдәпле булып үсәчәк", — дип ышандыра алмый. Заманында киң таралган Ушинский, Макаренко тәгълиматлары онытылды. Шулай итеп, җәмгыятьнең яшәвен тәэмин итәргә тиешле мөһим

гамәл —кешеләрнең туып-янарып торуы, буыннар алмашынуы идарә итеп булмаслык вәзгыятькә кереп батты. Ни аяныч хәл!

Инде мәгълүмат чараларына килик. Радио-телевидение, газет-журналлар һ. б. яшьләрне әхлаксызлыкка, усаллыкка-явызлыкка өйрәнүдә тыеп булмаслык көч булып торалар. Карагыз сез телевидениенең тапшырулар программасын: көн саен жиде-сигез канал аша ничәмә-ничә оятсыз порнографик, ничәмә-ничә үтереш-суеш һ. б. фильмнар күрсәтелә. Урам чатлары саен оятсыз-ялангач хатын-кыз һәм ир-атларның әдәпсез кыяфәтләрдәге төсле сурәтләре газет-журнал битләрен бизи, китап тышларыннан "чакырып" тора. Шул рәвешле, яшүсмерләрне максатчан бер эзлеклелек белән шәфкатьсезлек рухында тәрбиялиләр. К. А. Тарасов үзенең "От насилия в кино к насилию, как в кино" ("Кинолардагы көч кулланудан кинолардагыча көч куллануга") дигән мәкаләсендә (Социс, 1996 ел, № 2) бик дөрес билгеләп үтә: кинотеатрларның, видео һәм кабель телевидениесенең репертуарлары бик тә хафаланырлык һәм борчылырлык. Экраннардагы көчләү-ирексезләү, җәберләү-кыерсыту һәм эротика дулкыны шул кадәр көчле ки, ирексездән, рухи "интоксикация" — агулану эпидемиясе бу, аның корбаннары бихисап күп тамашачылар, дигән фикергә киләсең.

Бигрәк тә балалар, яшүсмерләр үзләре караган фильмнардагы геройларга охшарга тырышалар, тормышта да алар кылган гамәлләрне кылып карарга омтылалар. Югарыда без телгә алган И. Лалаянц шундый мисал китерә. Ун яшьлек һәм унбер яшьлек ике малай сәүдә үзәгендә йөргәндә, ике яшьлек бер сабыйны алдап ияртеп алып китәләр дә, тимер юл буенда газаплап үтерәләр. Шуннан алдагы көнне генә теге малайларның ун яшьлеге күршеләрендәге видеотекадан "Балалар уены" (АКШ) дигән видеофильм алып караган булган икән. Фильмда Чаки исемле куркыныч курчакның кем очраса, шуларны рәттән үтереп йөрүе күрсәтелгән. Бер вакыйгада Чаки үзенең корбаны булачак баланы тимер юл буенда куып йөри икән.

К. А. Тарасов исә мондый вакыйганы бәян итә. 1977 елда, мөгаен беренче мәртәбәдер, телевидениены суд җаваплылыгына тарталар. Эш болай була. Майамида (АКШ) яшәүче унбиш яшьлек бер үсмер сиксән өч яшьлек күрше карчыгын үтерә. Баксаң, ул карчык әлеге үсмернең ишек ватып урлашканын күреп торган һәм полициягә хәбәр итәм дип янаган икән. Суд яшүсмерне гомерлеккә төрмәгә ябарга дигән хөкем чыгарган. Әмма адвокат, үсмернең әти-әниләренең шаһитлегенә таянып, өч гомуммилли телекомпанияне балаларны җәберләү күренешләре белән "агулап" торуда гаепләп чыга. Яшүсмернең әти-әниләре ул телекомпанияләргә егерме биш миллион долларлык дәгъва белдерә.

Хәзерге вакытта кемгә карата булса да көч куллану, рәнжетү-җәберләү — үзенә күрә бер төрле яшәү рәвеше, үз-үзенне тотышта аерым бер кыйммәткә ия нәрсә шикелле ул.

Тәртипле-әдәпле, закон бозмыйча яшәүчеләр белән законга сыймас гамәл кылырга әзер торучылар арасындагы аерма көннән-көн җуела, кими бара. Кеше закон да бозмый шикелле, әмма башкалар хисабына, сорыкортларча яши. Шулай итеп, җәмгыятьтә язылмаган "уен кагыйдәләре" барлыкка килә. Яшүсмерләр арасындагы үзара кырыслык, шәфкатьсезлек — ул үзенә күрә бүгенге җәмгыятебездәге мөнәсәбәтләрнең бер кыйпылчыгы, ватык көзгесе.

Публицист Лев Самойловка язмыш ике мәртәбә колонияләрдә булуны "бүләк" иткән. Һәм ул "зонадагы" тәртипләрне, гадәт-кануннарны җентекләп өйрәнгән. Ул тоткыннар "йөзтүбән капландырылган, кирегә әйләндерелгән дөньяда яшиләр" дигән фикергә килгән. Ягъни иректә кешеләр арасындагы гадәти мөнәсәбәтләр анда гел кире мәгънәне аңлата. "Әмма ирекле тормышыбызда да күп нәрсәләр чынында баштүбән әйләндерелгән бит", — ди ул. Чөнки безнең тормышның, Россиядәге җәмгыятьнең төп сыйфаты — рухи-мәдәни эчтәлек булмау. Бүгенге рухи ярлылык, наданлык-мәнсезлек, ваемсызлык-игътибарсызлык — дистәләрчә еллар буе кешене изеп килгән социализм җимеше. Совет дәүләтенең оеткысы наданлык-аңсызлыкта булгач, ул берничек тә алдынгы җәмгыять булып оешып житә алмаган. Аң-белем, зыялылык, рухи байлыклар үстерелә барганда гына нәрсәгә булса да ирешергә мөмкин.

Танылган Мәскәү галиме, философ Л. П. Буева исенә төшереп, болай яза: бер ун еллар элек кенә яңа гына институт тәмамлаган яшь белгеч — балалар табибы әйтә икән: "Хәзер берничә дистә баланы карап итсәм, минә дигән

оста белгеч булып җитешәчәкмен". Һәм ул бит шулай эшләячәк тә. Үзен законнарга буйсынучан гади кеше дип тә исәпләячәк.

Үзебезнең Казан тормышыннан көндәлек бер мисал. Балалар бакчасындагы бер тәрбияче ханым балаларның берсе дә авырмыйча, көн саен барысының да бакчага йөрүләрен өнәми. Балалар артык күп, чыр-чу, шау-шу — эшләргә кыен. Шуннан бу ханым нишли, дисез? Тәрәзә форточкасын көне буена ачык тота. Нәтиҗәдә берничә балага салкын тия, алар бакчага йөрми башлыйлар. Менә хәзер тәрбиячегә эшләргә җинелрәк, рәхәтрәк!

## Рухсызлык — шәфкатьсезлек нигезе

Шәфкатьсезлек-миһербансызлыкның закончалыгын, зарури бәйләнешен аларны тудырган сәбәпләр-шартлар бәйләнешенә карап өйрәнергә кирәк, дигән социологик концепция безнең ил-халыкның рухсызлыгына, иманы юклыгына алып барып чыгадыр. Бу фикеребезне раслау өчен тарихи дәлил китерәбез. Германиядә булсын, башка илләрдә булсын, фашизмның барлыкка килүе, аның штурм-һөҗүм отрядлары оешуы асылда халыкның вак буржуаз катламы арасыннан үсеп чыкты. Немец бюргерлары (безнеңчә — мещаннар) патриотизм —ил сөючәнлек дигән төшенчәне ялгыш аңлап, ниндидер кыргый хискә бирелеп, сугыш кырында да, әсирләр белән дә, хәтта үз ватандашлары — антифашистлар белән дә артык шәфкатьсез-миһербансыз, кансыз кыландылар. Әйтергә кирәк, бүген дә, — һәр илдә үзенчә, — халыкның аерым катламнары-төркемнәре мещанлык, тар фикерлелек "йоктырган" хәлдә яшиләр, алар туктбитараф, ваемсыз гомер сөрәләр. Моны да рухи ярлылыктан килә дип уйларга кирәктер. Бу хакта А. А. Галкин үзенең "Германский Фашизм" (Мәскәү. 1996) дигән китабында бик тәфсилле итеп яза.

Рухи бай кеше икенче берәүгә начарлык эшли алмый, аны рәнҗетә алмый. Ә инде ваемсыз, мәрхәмәтсез кеше башкаларның кадерен белми, аның өчен икенче берәү әллә бар, әллә юк, шунлыктан ул аның рәнҗешләрен-әрнешләрен дә аңламый, шатлык-кайгыларын да уртаклаша белми. Башка кеше аның өчен бары тик ниндидер гамәл кылу өчен бер объект, бер мөмкинлек кенә. Кирәк булса, ул аның белән, әйтик, хатын-кыз белән, рәхәт кәеф-сафа кора, гыйшык уены уйный. Әгәр дә инде бу берәүнең кирәге юк икән, аны туп урынына тибеп җибәрергә дә була, инде эш шуңа барып терәлсә, аны юк итәргә дә була. Әлбәттә, кызганусыз-нисез, аяусыз бер шәфкатьсезлек белән!

Җинаятьчелекне бетерү, аны булдырмауның иң нәтиҗәле һәм иң мәрхәмәтле чарасы — халыкның рухи-әхлакый аның үстерү, аны рухи баету. Ә бездә исә аның әле булган кадәрен дә тоташ җимерү генә бара.

Россиянең бүгенге вәзгыяте шундый ки, гади хезмәт халкы, эшләгәне өчен акчасын ала алмыйча, гаиләсен ничек туендырырга, ничек яшәргә икәнен белми интеккән бер вакытта, аны рухи һәм әхлакый тәрбияләү турында сүз йөртү буш хыял гына шикелле. Бүгенге тормышның акылга сыймаслык, гаҗәпләндерерлек ягы шул: икътисади, сәяси һәм социаль мәсьәләләрне хәзерге шартларда тормышка ашыру бөек идеаллар, яңа зур максатлар, омтылышларсыз мөмкин дә түгел.

Димәк, рухи байлыклар, әхлакый тәрбия турында уйлануларыбыз да әллә кайда, җиде кат күкләрдә йөрү түгел, ә бүген иң кирәкле, иң мөһим гамәли эштер. Әгәр дә ил-халык рухи-әхлакый тәрбия ягына борылмаса, аның киләчәге юк, дигән сүз. Ахырда мондый ил үлемгә, бетүгә йөз тотачак.

Әмма әле соң түгел, авыру җәмгыятебез терелер, без иркен-мул тормышта, рухи сау-таза кешеләр булып яши башларбыз. Моның шулай булачагына ышанып һәм шул максатлар өчен көрәшеп яшәргә кирәк безгә.

*Яков Емельяновның тууына 150 ел*

# ШАГЫЙРЬ, ПОП ҺӘМ ЯКТАШ

Ул — күптән яшәп дөнья кичкән зат. Тууы — моннан 150 ел элек, вафатына да 100 елдан артык. "Кайсы дәвер соң ул һәм кемнәр заманы?" диярләр. XIX гасырның икенче яртысы. Россиядә Александр II патша вакыты. Реформалар (крепостное право бетерелү) чоры. Рус булмаган халыкларны көчләп чукындыруның, миссионерлык басымының котырган дәвере. Мөселман-татар дөньясында вәисевчеләр хәрәкәте, мәрҗаниләр мәгърифәтчелеге, басма китап тәэсире көчәйгән чорлар... Менә шул заманда яшәгән жырчы Җәкәү ( Җәкәү-жырау) — Яков Емельянов дигәннәре. Шул заман тирәлеген күзалласаң, ул — Кандалый, Гали Чокрый, Акмулла, Мәрҗани, К. Насыйрилар замандашы. Җирдә шаккатырлык байлык-мөлкәт, том-том әсәрләр калдырмыйча, 1893 елны 45 яшендә дөнья куйган якташны әдәби җәмәгатьчелек һаман онытмый. Элек заманда да, совет чорында да, хәзер дә аның исемен даими телгә алалар. Тормыш юлы һәм иҗатына багышланган язма мәкаләләр дә җитәрлек: А. Григорьев, Х. Госман, М. Гайнуллин, М. Глухов, Р. Әхмәт һәм башкаларның хезмәтләрен күздә тотып әйтәм.

Ни, нәрсә өчен бу олылау? Н. Ильминский, В. Тимофеевлар шәкерте, миссионерлык тарафдары бит юкса! Замандашлары да әхлакый яктан үрнәк шәхес дип сокланмаганнар бугай. Язганнары да бик аз: нибары ике дистәләп шигырь. Ә шулай да, антологияләргә кергән, дәреслекләрдә урын алган! Хикмәт, билгеле, күләмдә түгел. Хикмәт, хәтта шигырьләрнең ювелир (хәтта киресенчә!) эшләнешендә дә түгел. Хикмәт — ул әсәрләрнең — зурмы, кечкенәме — үз заманын объектив чагылдыра алуында, чор рухын бирүендә, яңа буыннарга тәэсир итә алырлык көчендә, һәм... иҗатчының ихласлыгында, үзенә хыянәт итмәвендә.

*Яков Емельянович Емельянов 1848 елда Лаеш өязенең (хәзерге Балык Бистәсе районы) Алан (Алан-Полян) авылында крестьян Емельян Петров гаиләсендә туа. Тугыз яшендә аны Мамадыш өязенең Җүкәче авылындагы волость писарьләре әзерли торган удельное училищега укырга бирәләр. 1864 елны Казандагы Үзәк керәшен-татар мәктәбенә (В. Тимофеев — Бәчли әти — ачкан Учительская школа) керә. 1869 елны укытучы сыйфатында туган авылының күршесе генә булган Үригә (Урей Чаллысы) кайтып балалар укыта. Ильминский инициативасы белән 1874 елны яңадан Казанга килә һәм Духовная академиягә (дөресрәге — академия каршындагы миссионерлык институтына) алына. Аны тәмамлагач дьякон дәрәҗәсе бирелә, ә 1880 елны ул инде протопоп була (шактый ук югары рухани чин бу!). Шул елдан башлап үлгәненә кадәр диярлек төрле (Чура Сала — Кукмара районы, Тәңкә — Саба районы, Шәмәрбаш —Балык Бистәсе районы) төбәкләрдә поп вазифаларын башкара. 1893 елда Үридә вафат була һәм шул авылда җирләнә дә. Бүгенгә килеп җиткән әдәби мирасы юка гына 2 китапчыкта тупланган: "Дьякон Я. Емельянов стихларе", — Казан, Св. Гурий җәмгыяте типографиясе, 1879; Стихи на крещено-татарском языке, Казань, Чиркова типографиясе, 1888. (Шунысын да искәртик —татар шигъриятенең кириллицадагы беренче үрнәкләре бу. Бүгенге имлябызның башлангычы "Братство св. Гурия" җәмгыятьләреннән килә икән ләбаса! Тикмәгә генә кайчак кириллицаны "керәшен хәрефләре" дип әйтмәгәннәр шул).*

Яков Емельянов иҗаты — үз шәхесе кебек үк — каршылыклы, һәм әйтер идем, идеологияләштерелгән иҗат. Бер яктан, аңы белән остазы Ильминский идеяләренә хезмәт итәргә тырышса, икенче яктан, күңеле белән үзен тудырган гади, ярлы халык интересларын якларга, аларга үзләренең нинди хәлдә икәнлекләрен аңлатырга, төшендерергә тырыша, үгет-киңәш белән генә булса да

аларга ярдәм итәргә омтыла. Христиан динен пропагандалау дип аның "Ходай сине илдән алган", "Саташканны уяту" кебек шигырьләрен санасак, ә "Кайгы", "Ярлы тормыш", "Олысыманлык", "Әләк", "Улым", "Әби үгете" кебекләре халык тормышының җанлы чагылышын күрсәткән ачык мисаллар.

Миңа калса, шагыйрьнең эчке мәгънәгә, поэтик яңгырашка, эстетик кыйммәткә ия шигырьләре берничәү: алар — "Әләк", "Кайгы", "Улым", "Кояш"... Алда ул шигырьләр тулы вариантта бирелгәч, бирерә фикеремә иллюстратив өзекләр китереп тормыйм. Укучы үз хөкемен үзе чыгарыр. Үз хөкемен чыгарыр дигәннән, Я. Емельянов иҗаты турында фикерем үзгәрә-үзгәрә байтак еллардан бирле тәгаенләнеп килә инде. Беренче тапкыр бу исемгә мин үсмер чакта (1957 ел бугай) "Татар поэзиясе антологиясе" китабын укыганда тап булдым. Безнең төбәк кешесе булгач, үзгә бер кызыксынып, дулкынланып укыдым ул шигырьләрне. Дөресен әйтим: артык тәэсир итмәде алар миңа. Аңлашыла да: үсмер җанга романтика кирәк, оптимистик дәрт, хисләндергеч лирика кирәк, китапча югары стиль, матур чагыштырулар, томанга өретелгән образлар, хыялый серләр кирәк... Укылган шигырьләр минем өчен гыйбат авылча, артык гади, хәтта тупасрак та булып тоелды. Безгә артыгы белән таныш натур фәкыйрь күренешләр... Бер ишләре әбиләр көндә диярлек безгә тукып килгән үгет-нәсихәт, акыл өйрәтү сүзләре булып кабул ителде. Беренче тойгылар, беренче кичерешләр күпчак дөрес була. Ул тәэсораттан ваз кичәргә җыенмыйм. Соңрак, студент елларында бу шагыйрьне бүтәнчәрәк аңлауда профессор Х. Госманның йогынтысы зур булды. Ул очынып-очынып укып күрсәтә иде "Җырчы Җәкәү" шигырьләрен! Халыкчанлыгына басым ясар иде, ритм-рифмаларының үзгәлеген әйтер, юл ахырыннан юл башына күчеп йөреп кабатлана торган сүзтезмәләр куллануны ачышларга тиңләр иде... Ул да мәрхүм үзенчә хаклы иде. Әмма эчке каршылыклы хис хәзер дә бетмәде... Хәер, объектив булыйк: кайчан, кем тарафыннан, ни максаттан язылган әсәрләр алар? Җавап: моннан 120-125 ел элек, христиан рухани тарафыннан, шагыйрьлек миссиясенә дәгъва итмичә күңелен бушатып, ачынып язылган "җырулар". Үзешчән иҗатның бер бөек (отышлы) ягы бар: ул — халыкчан. Я. Емельяновның 1879 елда чыккан җыентыгының халык телендә "Дарҗа әби кенәгәсе" дип йөртелүе дә үзгә бер мәгънәгә ия. Бүгенге "Мерседес" машинасыннан арбалы атка карап үз "бөеклегенә" соклану егетлекме? Хәлне, вакыйганы, фактны шул заман күзлегеннән, шул заман хәятеннән чыгып бәялә син! Шул чорда иҗат иткән шагыйрьләрнең кайсысында гади халык тормышының реаль чалымнары күбрәк чагылган икән әле? Һәм дә кайсысының әсәрләрен бүгенге укучы йөгертеп аңлап укый алыр икән? Бу җәһәттән, Я. Емельянов иҗаты бик тә отышлы хәлдә. Алда әйтелгән "Аны ни, нәрсә өчен олылыйлар?" дигән сорауга бер җавап-дәлил бу. Гомумән, бүгенге поэзиядә киң колач алган иркле, сөйләм интонациясенә корылган шигырьләрнең беренче яралгылары бит аларда.

Я. Емельянов турында әдәбият дәреслекләрендә беркадәр мәгълүмат булса да, алар шагыйрь шәхесен тулы күз алдына китертә алмыйлар. Асылда, ул мәгълүматлар язмадан язмага кабатланалар гына. Поп буларак, Я. Емельяновның бер авылдан бер авылга, бер приходтан икенчесенә күчеп йөрүе дә хәтер кардиограммасын тоныкландырган, әлбәттә. Халыкның хәерчелеге, руханиларның икейөзлелеге, өстеннән туктаусыз язылып торган шикаятьләр, әләкләр, һәм ниһаять, реаль тормышның үзе үк өндәгән максаттан бик-бик ераклыгы шигъри җанлы ирне нык уйландырган, йөдәткән булса кирәк.

"Җәшнә, Кояш, җалтыра!
Яктың җирдә уйнасын.
Иртәнге кырау, соңгы суык
Яна орлыкны коймасын"

дип оптимистик рухта язса да, кырыс тормыш, барыбер, аны бөгә, сындыра. Исеме "каһәрләнгән поплар" рәтенә керә. Тикшеренүчеләрнең язуынча, гомеренең соңгы елларында ул депрессиягә бирелә. Тикмәгә генә остазы Ильминский бер хатында аңарга болай дип язмагандыр: "Тормышыңны рәтләргә тырыш, югыйсә бетәрсең. Мин сине кызганам. Алла сиңа үзеңне кулга алырга ярдәм итсен. Син аптырап калма, бер кеше дә сиңа явызлык теләми. Бу икебезнең арада гына калырга тиеш. Синең дустың, кабак тотучы Афанасий синең өстеңнән архиерийга ... жалоба биргән."

Я. Емельяновның Борис исемле ( Стариков Борис Яковлевич, нигә Емельянов түгел?) улы булуы билгеле. А.Н. Григорьев язмаларына караганда, ул да шигырьләр язган, матбугатта катнашкан. Язмышы ничек булып беткән, безгә

билгесез. Алан-Полян авылында хәзер дә Стариков фамилияле гаиләләр бар. Аларның Емельяновлар нәселенә катнашы булырга тиеш. һәрхәлдә кызыксынучылар өчен жирлек бар.

Сүз уңаеннан, безнең як керәшен татарлары арасыннан соңгы дәвердә чыккан шәхесләр турында. Шактый алар. Чагыштырып карасаң, мөселман татарлары авылларыныкына караганда күбрәк. (Хәтердә: 1950-60 елларда Котлы-Бөкәш урта мәктәбенә — Кызыл йолдыз районына бер урта мәктәп! —Шәмәрбаш, Алан-Полян, Үри авылларыннан укырга килүчеләр дистәләгән иде, ә Күгәрчен, Күки, Балтач, Ямаш кебек зур татар авылларыннан килеп укучылар 1-2 генә була иде). Кечерәк кенә авыллар үзләре — Алан-Полян, Үри, Иванай, Керәшен Казысы, Шәмәрбаш (күпчак, ялгышып, Шомыртбаш диләр), Казак Чаллысы (Казаклар дип тә йөртәләр)... Ә күренекле кешеләре күп, шөһрәт-даннары зур. Я. Емельяновның авылдашы —атаклы математик, профессор Петров А.Н. (1900 —1969);Шәмәрбаштан — педагог, Үзәк керәшен мәктәбенең директоры Егоров Н. Н. (1870 — 1922); медицина фәннәре докторы, профессор Кибяков А.В. (1901 — 1989); профессор, үз вакытында Казан финанс-экономика институты ректоры Абрамов П.В. (1918 — 1985); Иванай ( Тупылат, Тук-Пулат) авылыннан — генерал-лейтенант Яковлев А.Е. (1903 — 1991); техник фәннәр докторы, профессор Никитин И.З. (1928); математик-профессор Ильин И. Ф. (1943); Казаклар Чаллысыннан — Советлар Союзы Герое Иванов В.П. (19?); филолог-профессор Марганова Р.А. (1954); Үридән — тарихчы әдип (керәшеннәр турында фундаменталь хезмәт — "Tatarica. Энциклопедия"нең авторы) Глухов М.С. (1937)... Исемлекне яңа заман балалары исәбенә дәвам да итәргә мөмкин. Ә бүтән төбәк, әйтик, Зәй, Бондюг, Чистай, Бакалы (Башкортстан) якларыннан чыккан атаклы кешеләрне барлый башласаң? Уртак цивилизациягә кушылучы көчле агым килеп чыга! Моны бәһаләргә, моңа сөенергә кирәк. Гомумән, соңгы ун ел эчендә керәшен татарлары рухи тормышында жанлылык һәм янарыш сизелә. Этномилли жәмгыятьләр барлыкка килә, жыр һәм бию ансамбльләре оеша яки торгызыла ("Бигәш", "Игәнәй", "Айбагар" һ.б.), "Керәшен сүзе" газеты нәшер ителә (1991), конкурс-фестивальләр уздырыла... Дөрес, халык тарихының чишмә башын эзләгәндә төрле каршылыклар, гипотеза белән аксиоманы буташтырулар, чиктән-чиккә ташланулар да була. Нишлисең, хакыйкать — күк капусы кебек —жиңел һәм тиз ачылмый. Шунсы куанычлы: теләсә кайсы ыру-төркемнең үз тарихын ачыклавы, үз рухи байлыгын барлавы, ахыр чиктә Уртак Хәзинәбезне баету бит! Без, XIX гасырның шанлы бер улы Я. Емельяновның 150 еллыгын билгеләп үтүне дә әнә шул юнәлештә күркәм һәм кирәк бер гамәл дип бәялибез.

**Равил ФӘЙЗУЛЛИН.**

*Сентябрь 1998*

# Яков Емельянов

## Әләк

**Тор гадел,**
**Йөр шиксез,**
**Бул изге,**
**Кыл яхшы,**
**Уйла туры,**
**Сөйләш чын,**
**Буяр әләк!**

**Кайгыр, көен,**
**Интек, инәл,**
**Ела, тилмер,**
**Уйла, шәйлә,**
**Уеңны җәймә,**
**Телеңне бәйлә,**
**Ябышыр әләк!**

Каладан илгә,
Җирдән суга,
Суыктан утка,
Төшлектән төнгә,
Таудан атауга
Күч, кач,
Табар әләк!

Чыкма, йөрмә,
Барма, кермә,
Берәүне белмә,
Шиклән, биклән,
Яклан, саклан,
Башыңнан каплан,
Сизәр әләк!

Шушы яман,
Тинтәк башлы,
Иң акылсыз
Чак каргадан
Бик тизеннән
Котылмасак,
Итәр харап!

Төнлектән - төнгә,
Таудан -атауга
Күч, кач,
Табар әләк,
Итәр харап!

## Улым(а)

Менә житте бәйрәм,
Безгә килер кунаклар.
Аларга ит хәзерлә,
Тиешенчә кадерлә:

Җумартны утырт янга,
Гаделне утырт алга,
Җакшыны утырт уңга,
Җаманны утырт сулга,
Усалны утырт ушага,

Оятсызга җарар бусага...
Сыйлаганда сак бул!
Җумартны җүнләп сыйла,
Саранны саклап сыйла,
Җуашны җуанып сыйла,
Гаделне куанып сыйла.
Җаманны җайлап сыйла,
Усалны уйлап сыйла,
Бусагага булса җарар,
Булмаса - алдына карар!

## Әби үгете

Син, улым,
Кай урынга барганыңны
Безгә әйтеп китмисең,
Ашар-эчәр вакытта
Өйгә кайтып җитмисең...

Кичәгеп дә чәй эчтең дә,
Өйдән чыгып киттең;
Кичке ашны ашарга
Көчкә кайтып җиттең.

Бүген тагы җылдай көнне
Урамда җөреп уздырдың.
Ары барып, бире килеп
Чабатаңны туздырдың.

Син, балам,
Болай булсаң,
Бабай йортын җабарсың.
Әзер малны тараткачтын
Үзең каян табарсың?!

Иптәшләрең кичәгеп дә
Иртүк эшкә киттеләр,
Ашар-эчәр вакытка
Өйгә кайтып җиттеләр!

Иртәгә дә җылдай көнне
Түшен киереп җатмаслар,
Кирәк җиргә тотарга
Чыгарып азык сатмаслар...

Тукта әле!
Бабаң исән чагында
Муеныңны сыгармын,
Чәчеңнән элеп, башыңны
Аяк арама тыгармын!

Шулай итеп "җомшатмасаң",
Сиңа үгет сеңмәс,
Әзрәк кенә сискәртмәсәң,
Башыңа акыл кермәс.

Син, җугыйса, соңыннан
Эш эрәтен белмәссең,
Бабаң белән без үлгәч,
Өйгә кайтып кермәссең.

Болай булгач, син, балам,
Җортны корып кабырсың;
Тапкан малны тараткач,
Үзең каян табырсың?

***

Кайгылы чакта көенмә,
Тыныч торам дип сөенмә;
Бу дөньяның хәсрәте
Һәрбер кешенең өендә...

Кайгылы чакта тынычлык
Ходайның үзеннән киләдер,
Килгән тынычлыктан тоючы
Төрле сынауны җиңәдер.

Кайгылар килә бәндәгә
Үткән тормышын аңларга.

Үткән тормышын аңлаган
Бирелә Алланы данларга.

Алланы данлаган бәндәнең
Кайгылы көннәре тиз үтә,
Үткән көннәрне тикшерсәң,
Алланың изгелегенә ис китә!

Алланың изгелеген тикшерергә
Кайгы күргәннәр куәтле,
Кайгылы көндә түзгәнне
Ходай итмәс оятлы.

## Ходай сине илдән алган...

Ходай сине илдән алган
Илгә иркен сөйләргә;
Ходай сиңа куәт биргән
Бирелеп чын дин сөйләргә!

Бирелеп чын дин сөйләвеңне
Соңгы көндә аңларлар,
Синең кылган эшләреңне
Вакытында данларлар.

Данларлар аны халыклар,
Үзеңә бер дә күренмәс.

Соңгы көндә эшләрең өчен
Бирелгән күңелең сүрелмәс!

Сүрелмәс синең чын күңелең,
Эшләрең данына туеныр,
Соңгы көндә зур эшләрең
Затка өлгегә куелыр.

Затлар аны өлге итеп
Һәрвакытта сакларлар.
Изге эшне гадел уйлылар
Һәрбер чакта җакларлар!

## Олысыманлык

Олысыманлыкны ватар өчен
Җыегыз җирдән кораллар,
Аның куәтен киметер өчен
Тагыгыз бакыр богаулар.

Бакыр богау аны басып
Җиргә чаклы төшерсен;
Шул яманга узган-барган
Тамагын кырып төкерсен.

Төкерсен аңар барысы да,
Ул хурлыкны тулы аңласын,
Аның куәте җир өстендә
Тамырын җәеп калмасын.

Калмасын монда яман шәүлә,
Ул төтен күк җирдән җыелсын,
Көферлек чыгы, шәйтан шыгы
Хурлыгын күреп тыелсын.

Гаделләргә сыенганны
Җилкеталмас сулышың,
Күпне күреп җан җарпайса,
Алырсың хурлык тулысын...

Тулы хурлык син, җавызны,
Һәрвакытта кыздырыр;
Аптыраганда аккан яшьләр
Син, зәхмәтне, сыздырыр!

## Кайгы

Китсен моннан зур кайгы,
Минем алда тормасын;
Йөдәгән җанны җил-давыл күк
Уңга-сулга бормасын.

Бормасын аны һичбер якка,
Ул теш кебек ныгып утырсын;
Кайгылы чакта җыйган уйдан
Савытын басып тутырсын.

Тутырсын савытын нык уй белән,
Ул соңыннан аңар куаныр,
Алҗыган чакта тилпенмәсә,
Талир күк бәла уалыр.

Уалсын бәла, ярылсын,
Каушатып җанны җиңмәсен;
Таудан чыгып диңгез белән
Сыналган җанга килмәсен.

Килмәсен җанга шаулап-улап,
Ул үлән күк аннан сыгылмас,
Аның куәте кагылганда,
Каушап, калтырап егылмас.

Егылмас инде сыналган җан,
Син һәрчакта аңа күрендең;
Куәтең, иркең аңлаткачтын,
Үзең дә каушап сүрелдең.

Сүрелдең инде, бөкре кайгы,
Ялкының һич тә кыздырмый,
Эчкә кереп кайнатсаң да,
Куәтең мине сыздырмый.

Сыздырмый инде синең куәтең,
Минем тирәмә сырышып,
Тоймастан тартып егармын дип,
Тозагың корып тырышма.

Тырышма юкка, кит янымнан,
Яманлыгыңны ярырмын.
Сине юкка чыгарыр өчен,
Төрле әмәлләр алырмын.

Төрле әмәлләр җыеп алгач,
Сине ялан хурлармын,
Син яманга түзгән җанны
Урамга чыгып зурлармын.

Урамдагылар түзгән җанны
Тагы да бигрәк зурларлар,
Син зәхмәтне бөтен җыен
Какырып, төкереп хурларлар.

Хурларлар сине йөрәклеләр,
Син алардан читкә качасың;
Куәтең, иркең белмәгәннәргә
Авызың киереп ачасың.

Ачма авызың син аларга,
Җибәрмә яман сулышың,
Алар бар да ныгып җиткәч,
Алырсың хурлык тулысын.

Тулы хурлык син явызны
Һәрвакытны кыздырыр,
Тилмергәнлектән аккан яшь
Син зәхмәтне сыздырыр.

Сыздырыр сине таза тамчы,
Ул җан кереп юып үтәдер,
Азыктан коелган нык койманы
Куәте белән сүтәдер.

Сүтелсен койма, ачылсын юл,
Җанга бигрәк кирәк шул,
Бервакытны актык көндә
Аннан куанып барыр ул.

Аннан куанып барган чакта
Кайгылар читкә качарлар,
Тилмергән чактагы теләкләр
Сөенеч ишеген ачарлар.

Сөенеч ишеге ачылганда,
Ул дәүләтне күреп куаныр,
Кайгылар күптән йөдәгән җан
Буласыны уйлап юаныр.

Юансын җан шуны уйлап,
Югыйсә монда калтырар,
Дөнья утына түзгән җан
Буласы көндә ялтырар.

*Шигырьләр тупламасын*
*Рафис ӘХМӘТ әзерләде.*

ӘДӘБИ ТӘНКЫЙТЬ

# ШАГЫЙРЬ АЧКАН ДӨНЬЯ

ШӘҮКӘТ ГАЛИЕВКӘ 70 ЯШЬ ТУЛУ УҢАЕННАН

Татар шигъриятенең сигез гасырлык тарихы бар. Анын Кол Галие, Утыз Имәние, Габделжаббар Кандалые, Габдулла Тукае, Такташы, Туфаны бар. Җәлиле, Кәриме, Фәйзие бар. Анын Исәнбәте, Маннуры, Хәкиме бар... Әнә шул поэзиядә үз урыныңны табып кара, үз шигъри дөньяңны ачып кара! Ай-һай, ансат эш микән бу?

Шигърият мәйданына әлерәк кенә аяк баскан яшь бер каләм иясе боларның барысы турында уйлана башласа, каләмгә тотынасы да түгел югыйсә, әмма яшь-жилкенчәкнең көч-энергиясе, югарыга-яктыга омтылуы шундый да тыелгысыз ки, ул, асфальтны тишеп чыккан яшь үлән кебек, дөньяда барлыгын сиздерә башлый.

Сугыштан соң поэзиягә килгән Илдар Юзеев, Хисам Камал, Рәшит Гәрәй, Гамил Афзал, Роберт Әхмәтҗановлар буыны турында шул сүзне курыкмыйча әйтергә мөмкин. Тыныч көннәргә сусаган, кояш яктысын, аяз зәңгәр күкне кайнар яшьле мөлдерәмә күзләр белән түгел, елмаюлы, нурлы күзләре белән күрергә теләгән, юлбарыстан көчле булып фашизм чирүенә каршы сугышкан, батыр улларының гомерләре бәрабәренә ил азатлыгын саклап калган халыкка — баһадир халыкка — яңа җыр кирәк иде. Сугыштан соң әдәбият мәйданына чыккан шагыйрьләрне әнә шундый ихтыяж алып килде.

Алар арасында Шәүкәт Галиев исеме дә бар.



*Шагыйрь Шәүкәт Галиев*

Апас ягы урманнарыннан, авыл жиреннән жиде сыйныф белем белән килеп, соңыннан кичке урта мәктәпне, аннары Әдәбият институтының ике еллык Югары курсларын тәмамлаган Шәүкәтнең беренче китабы мәктәп балалары яза торган дәфтәр калынлыгы гына булып чыкты. Ләкин автор аңа исемне, яшьләргә хас кыюлык белән, "Яңа көйләр" дип куйган иде. Ул чакларда, илленче елның башларында, яңа чыккан китаплар, хәзерге кебек, еллар буе үз бәясен көтеп саргаймыйлар иде. Рецензентларны без, әдәби журнал һәм газит хезмәткәрләре, үзебез эзләп таба идек. Мина, "Совет әдәбияты" журналының әдәби хезмәткәренә, Шәүкәт Галиев белән Рафаил Төхфәтуллин китапларына рецензентлар табу бурычы йөкләнде. Р. Төхфәтуллинның "Таныш гөрелте"сен Гомәр Бәшировка, Ш. Галиевнең "Яңа көйләр"ен Әхмәт Фәйзигә китереп тоттырдым. Гомәр ага Рафаилнең хикәяләренә мәкалә язарга әлләни ялындырмый гына килеште, ул аны күзәтеп бара, аның иҗатына шефлык итә иде. Ә менә Әхмәт ага яшь шагыйрьнең юка гына китабын алырга теләмәде. Гадәтенчә, күзен челт-челт йомгалап, җилкә аша "йөткергәләп" торгач: "Эшем бик күп, эшем бик күп энекәш, бүген үк мин Мәскәүгә кайтып китәм, "Тукай"ның икенче китабына тотынасым бар, ала алмыйм, бигайбә", — диде.

— Ярый алайса, — дидем мин, килешкәндәй итеп. — Сез аны, Әхмәт ага, поездда кайтканда, эч пошканнан актаргалап карагыз, ошамаса, вагон тәрәзәсеннән ыргытып калдырыгыз.

Өч көннән миңа хат килде. Әхмәт Фәйзи китапны укып чыккан, поездда ук рецензия язган һәм аны озакка сузмыйча бастырып чыгаруны таләп иткән иде.

Ил күләмендә танылган өлкән шагыйрьнең яшь шагыйрь иҗатына карата әйткән сүзе күп түгел, әмма авторны гомер буе җылытып торырга, үз иҗатына таләпчән карарга җитәрлек иде.

"Шәүкәт Галиевнең җыентыгы безнең поэзиядәге бик күп бер төрле иске көйләр арасында үзенә колак салырга мәҗбүр итә торган "яңа көйләр" булып яңгырый", — дигән иде ул.

Бу аванс белән әйткән сүз түгел, Әхмәт Фәйзи яшьләрне аванс белән сүз әйтеп юатырга яратмый иде. Әхмәт аганың әйткән сүзе хак булуына менә хәзер — кырык биш елдан артык вакыт узгач — аеруча ышанасың.

Ш. Галиевнең беренче чор иҗатына нәрсә хас соң? Бу сорауга тиз генә җавап бирү кыен. Мин моны аңлату өчен малай чагымнан ук истә калган бер хәлне әйтеп бирергә тиешмен.

Осталыгы белән дан алган Степан исемле тимерче бар иде Арча төбәгендә. Ул гомере буе Казанбаш авылында эшләде. Бервакыт әни миңа әйтте: бар, улым, тимерче Ычтапанга барып, балтаны таптатып кайт, диде. Бардым. Тимерче абый балтаны утлы күмергә салып, күрек баса-баса, озаклап кыздырды, аннары зур бер келәшчә белән тотып, сандалга куйды да чүкеч белән китереп сукты. Ут кебек кызган балтадан көлтәсе белән нур чәчелде.

Шул күренешне минем гомер буе онытасым юк.

Ш. Галиевнең беренче шигырьләреннән дә нур чәчелә кебек тоела миңа. Каян килгән нур соң ул? Авыл кешесенең төпле акылыннан, "каралтыга сөялеп, салкын кышны сагынган чаналардан", таңнар алсулыгыннан, аяк асты челтәр бозлар белән тулы чакта, "челтәрләрен ташлап чыккан кыз-кыркыннан", "күнелгә кага-кага аккан гомерләр"дән, авыл тугайларында аунап үскән малайның күңеленә сеңеп калган бик-бик газиз нәрсәләрдән садәлек, яшьлек, эчкерсезлек — барысы бергә җыелып, нур булып агыла. Әнә шул җылы нур Шәүкәт Галиевнең баштагы иҗатын балкытып тора.

Минем уемча, Ш. Галиевнең икенче чор иҗатына "Әткәйгә хат" поэмасын кертергә кирәк. Шагыйрь сугышта үлеп калган әтисенә хат яза, ә ул хат күз яше кою түгел, сугыш чорындагы кырыс хакыйкатьне реалистик буяулар белән, бик төгәл сүзләр белән әйтеп бирү.

Поэманы укыганда күнелдә моңсу уйлар кузгала. Байтак еллар узды инде ул көннәрдән соң, байтак сулар акты... "Илнең ярасына ак марля япкан кебек", ап-ак йортлар, асфальт юллар салынды. Ягъни сугыш калдырып киткән "материаль яралар" төзәлде, әмма күңел яраларының әле төзәлгәне юк. Әле бик күпләр, Шәүкәт белән бергә:

Чит кырларда, әткәй, егылып калдың,  
Чит туфрак ла булды бит юрган...  
Чит чәчәкләр үсә яннарында,  
Баш очында шаулый чит урман... —

дип сугыш кырында ятып калган әткәйләрен сагынырлар.

Автор әтисенең фронтка китүен иң кырыс картиналар итеп яза. Башка чакта кырларда тыныч кына эшләп йөргән ата, сугышка китәр алдыннан, сүзсез генә гел тәмәке тарта... ничәмә-ничә ел яралмый яткан түмәркәләрне ватып ташлый. Аннары... туган-үскән авылын, арба эзле юлларны, сукмакларны, үзе утырткан яшь каенны күздән кичерә. Болар бар да каласы... "Тал төбендә сары авызын ачып, азык көтә карга баласы..." Аның унике яшьлек улы да шул хәлдә кала түгелме соң? Сугыш давыллары аның да канатын сындырмасмы?

Шагыйрь әтисенең фронтта һәлак булу фаҗигасен дә мелодрамага әйләндерми, нык кул белән, кысылган йөрәк белән әйтеп бирә:

Бер көн шулай
Зарыгып хат көткәндә,
Почта авыр хәбәр китерде:
Кош теледәй кәгазь —
Әнкәйне тол,
Безне кинәт ятим иттерде...

Чын поэзия менә шундый саранлыкны, тыгызлыкны таләп итә. Әти кеше инде фронттан хат килгәнче үк үлгән. Ләкин әле бу фаҗигане аның гаиләсе белми, өмет белән яши. Ә "Кош теледәй кәгазь" өметләрне челпәрәмә китерә. Инде беренче каушаулар, мингерәүләнеп калулар узгач, фаҗиганең зурлыгы, тирәнлеге ачыла бара. Автор шәхси драманы ачып биргәннән соң гомумиләштерү ясый:

Озак үсә кеше...
Ел көтәсең
Киерелеп тәпи басканчы,
Тагын күпме куллан төшми әле,
Сүз әйтергә авыз ачканчы...
Авыр үсә кеше...
Егерме ел,
Чирек гасыр кирәк үтәргә,
Шунда гына әле өметеннең
Чынга ашуын була көтәргә.
Ата-ана, ил тырышып шулай,
Керфек какмый карап гөл итә.
Сугыш исә шуны бер секундта
Юкка чыгарала, көл итә...



*Шагыйрьләр (сулдан уңга) Р. Фәйзуллин, С. Шакир, Ш. Галиев, М. Шабаев, Н. Дәүли, З. Нури "Яшь ленинчы" (хәзерге "Сабантуй") газетасы редакциясендә. 1964 ел.*

"Əткәйгә хат" поэмасы татар поэзиясендә сугыш афәтләре, сугышның бетмәс-төкәнмәс яралары хакында дистәләрчә поэма язылган чорда иҗат ителде, әмма бер генә шагыйрьне дә кабатламады. "Бәхет турында җыр" кебек сугыштан соңгы беренче поэманың авторы М. Садрины да, "Курск дугасы", "Дала җыры", "Бакчачылар" поэмаларының авторы С. Хәкимне дә, "Олы юл буйлап" шигъри повестеның авторы С. Батталны да, сугыш батырлары турында унга якын поэма иҗат иткән Гали Хуҗины да, Муса Җәлил белән Фатих Кәримне дә — берсен дә, берсен дә кабатламады. Шагыйрьнең бу үз авазы, йөрәгеннән кан булып сулкылдап тамган үз җыры иде.

Безнең Арча якларында урманнан диләнкә алып, чаерлы нарат бүрәнәләрдән йорт салалар. Андый йорт гасырлар буена черемичә тора ала, өстәвенә — ул йортка керсәң, үзеңне җәйләрен хуш ис бөркеп утырган нарат урманына килеп кергәндәй хис итәсең. Бу поэмага карата да гомуми бәяне минем кыска итеп әйтәсем килә: әнә шул нарат бүрәнәдән салынган йорт кебек, озын гомерле булачак ул.

Моңарчы без Шәүкәтнең юморга бай шагыйрь икәнен дә, лирикага бай шагыйрь икәнен дә белә идек. Әлеге поэмасы белән ул киң колачлы итеп уйлый белә торган эпик шагыйрь икәнен раслады.



*Шәүкәт Галиев һәм Ирина Токмакова 1983 елда Мәскәүдә Г. Х. Андерсен исемендәге Мактаулы диплом алганнан соң.*

1978 елны шагыйрьнең бер томлыгы "Шигырь китапханәсе"ндә басылып чыкты. Нык эзлеклелек һәм җаваплылык белән төзелгән бу китапта даталары куелган шигырьләр әйтеп торалар: шагыйрь үсә, ныгый, иркенәя, авылда җыйган маясын — күңел тойгыларын — юмарт рәвештә ак кәгазь битенә түгеп ташлый.

Талант ул — барыннан да элек, күңел юмартлыгы. Апас урманнары ягыннан юмарт бер күңелнең әдәбият мәйданына чыгуын укучылар да, тәнкыйтьчеләр дә күз уңыннан ычкындырмады, еллар буе аның үсүен күзәтеп торды. "Əткәйгә хат" поэмасыннан соң кырык ел иҗат итә ул. Аның поэзиясе республикабызның иң зур бүләгенә — Тукай премиясенә лаек булды. 1978 елны аны хөкүмәтебез әдәбияттагы уңышлары өчен "Почет билгесе" ордены белән бүләкләде. 50 яшьлегендә аның иҗаты республика матбугатында да, үзәк матбугат битләрендә дә лаеклы бәясен алды.

Əмма шагыйрьнең үсүе, камилләшүе, осталыкка баруы минем үземне гел уйландырып килә. Каләмдәшебезнең иҗат бәйрәме көнендә бу хакта мин ачыграк итеп әйтүне дә кирәк табам, чөнки бу ярты юлда туктап калучылар өчен кирәк.

"Əткәйгә хат" поэмасыннан соң, минем уемча, Шәүкәт каләмдәшебезнең иҗатында берничә ел торгынлык булып алды. Моның җитди сәбәбе бар. Шәүкәт авылда җыйган маясын иҗатында файдаланып бетерә язган иде инде. Югары

сәнгать баскычына менеп житкәннән соң бары тик Пушкиннар, Тукайлар гына үзлексез шул югарылыкта кала алганнар. Такташ булып Такташ та, яңа бер сикереш ясар өчен, туктап тын алырга мәжбүр булган.

Менә безнең Шәүкәтебез белән дә шундыйрак хәл булып алды. Дөрес, ул язудан туктамады, тик ул язган шигырьләр "аерым деталь" шигырьләре булып, салкын акылга корыла иде. Бәлки мондый хәл гомер буе "суык тимерче" шигырьләре язган кайберәүләр иҗатында сизелмидер. Ә Шәүкәттә, гажәп жылы, нурлы шигырьләр биргән шагыйрьдә, ул сизелә башлады. Каләмдәшләре моңа борчылу белдерделәр. "Тамчылар тамар чаклар"ны, "Ник янара сагышлар"ны, "Тынгы бирми миңа шушы төннәр"не, "Әткәйгә хат"ны сагындылар.

Шәүкәт уйга калды. Эзләнә башлады.

Ниһаять, ул эзләгәнен тапты. "Чаян" журналында байтак эшләү аның башлангыч иҗатында чагылып-чагылып калган юморны, фикер сөрешендәге үткенлекне, хикмәтле, жылы шигырьләр юнәлешен көчәйтте. Нәкъ менә шушы юнәлеш Шәүкәт Галиевне зур бер серле утрау булган балалар поэзиясенә алып чыкты. Мин моны Шәүкәт каләмдәшебезнең бәхетле юлга юлыгуы дип исәплим. Балалар юморны ярата. Тукайлардан, Бари Рәхмәтләрдән, Әхмәт Фәйзиләрдән килгән матур традицияләрне безнең шартларда үстереп, шуларга тагын урыс әдәбиятында Михалковлар, Бартолар ирешкән югарылыкны да кушып, сурәт-бизәкләре, табышмак-серләре, Шәвәли, Камырша, Котбетдин кебек зирәк акыллы каһарманнары булган өр-яңа дөнья ачты.

Шагыйрьнең бер томлыгына акыллы кереш язган тирән белемле галимебез Нил Юзиев моны Ш. Галиевнең балалар психологиясен яхшылап өйрәнүе һәм балалар әдәбиятының үзенчәлекләрен тирән белүе белән аңлата. Мин мәсьәләне болай куюы белән килешәм. Ләкин, миңа калса, аның шигырьләренә "бала табигате кебек тере, хәрәкәтчән, йөгерек, тиктормас" дип бәя бирү генә житенкерәми төсле. Мәрхүм галимебез аңлатмасына мин менә тагын нәрсә өстәр идем: **Шәүкәт Галиев үзенең балалар поэзиясендә балалар психологиясен, балалар әдәбиятының үзенчәлекләрен тирәнтен белеп кенә калмады, бу зур һәм серле дөньяга Шәүкәт Галиев дигән кабатланмас шәхесен, үз дөньясын китереп куша алды.**

Нәкъ менә балалар әдәбиятында кабатланмас дөнья ачканы өчен бирелде аңа Татарстан АССРның Габдулла Тукай исемендәге Дәүләт бүләге. (1972) Ә ун елдан соң без тагын да шатлыклырак хәбәр алдык: аның Татарстан китап нәшрияты бастырган "Заяц на зарядке" китабы (тәржемәчеләре Татарстанда яшәгән урыс шагыйрьләре В. Баширов, Э. Блинова, С. Малышев, Б. Сулимов) Халыкара Андерсен дипломы алды (1982). Татар әдәбияты тарихында балалар поэзиясе өчен Тукай бүләген алу да, Андерсен дипломына лаек булу да беренче мәртәбә Шәүкәт Галиевкә эләкте. Шул ук бүләкләрне нәкъ менә балалар поэзиясе өчен егерме биш елдан соң Роберт Миңнуллин — Ш. Галиевнең шәкерте алуга ирешә. Болар, әлбәттә, татар әдәбиятының данын һәм дәрәжәсен күтәрделәр.

Шәүкәт Галиев илле елдан артыкка сузылган иҗат дәверендә күп кенә китаплар чыгарып өлгерде (прозадан да хикмәтле уймак хикәяләре бар аның), бәлки моңа озак еллар Татарстан китап нәшриятының матур әдәбият редакциясе мөдире булуы да ярдәм иткәндер. Тик мин шуны әйтергә тиешмен: кайда гына эшләмәсен, Шәүкәтне тәгаллек, үз эшенә жаваплы карау бизәп торды. Ул күп төрле җәмәгать эшләрен алып барды, шуларның бер өлкәсен генә күрсәтеп узу да житә дип уйлыйм. Мәсәлән, Шәүкәт Татартсан Язучылар берлегендә яшь язучылар белән эшләү комиссиясенең рәисе булды. Алар Илдар Юзеев белән бергәләп, ун ел эчендә 12 урында яшь язучыларның зона конференциясен үткәрделәр. Мин язучыларның житәкчесе булган чакта Чаллы язучылар оешмасын ачарга булыштылар (РСФСР Язучылар союзы секретариатында яшь язучылар белән эшләү турында хисап тоттылар). Хәзер Ш. Галиев балалар әдәбияты остаханәсен, И. Юзеев шагыйрьләр остаханәсен житәкли. Шәүкәт Галиев әле Татарстан язучыларының Кабул итү коллегиясе рәисе дә. Икесе дә Татарстан Республикасының халык шагыйрьләре. Шушыларның барысы өстенә — Шәүкәт өзлексез халык арасына чыга, мәктәп балалары белән туктаусыз элемтәдә тора, халыкның тел хәзинәсе дигән байлыгын армый-талмый өйрәнә. Ул СССР һәм РСФСР язучыларының съездларында делегат булып катнашты.

Табигый таланты, гаять зур тырышлыгы, ил язмышы белән яшәве аны республикабызның әйдәп баручы шагыйрьләре рәтенә китереп бастырды. Житмеш яшь тулган көнендә без аңа ышаныч белән карыйбыз, алга таба да шигъри хәзинәбезне яңа, зур, житди әсәрләр белән баетыр дип өметләнәбез.

**Гариф АХУНОВ,**
Татарстанның халык язучысы, шәрәфле академик.

*Тарих*

Рәис Сафаров

# ТӨРКИ ХАЛЫКЛАР

*1989 елгы халык санын исәпкә алу мәгълүматлары буенча элекке Советлар Союзы биләмәсендә 26 исемдәге төрки милләт яшәгән һәм аларның гомуми саны 49.530.529 кеше хисапланган. Танылган тюрколог, казакъ галиме Кенесбай Мусаев фикеренчә, соңгы сигез ел эчендә БДБ илләрендә төрки халыкларның саны тагын 10 миллионга арткан дип исәпләргә мөмкин. Төрки халыкларының 96 проценты үзләренең төрки телен туган тел дип таныйлар һәм шул телләрендә сөйләшәләр.*

*Саннарына карап алар түбәндәгечә урнаша:*

| | |
|---|---|
| 1. Үзбәкләр | 16697815 |
| 2. Казакълар | 8135813 |
| 3. Әзербайжаннар | 6770403 |
| 4. Татарлар | 6648760 |
| 5. Төрекмәннәр | 2728965 |
| 6. Кыргызлар | 2528945 |
| 7. Чувашлар | 1842346 |
| 8. Башкортлар | 1449157 |
| 9. Каракалпаклар | 423520 |
| 10. Якутлар | 381922 |
| 11. Кумыклар | 281933 |
| 12. Кырым татарлары | 271715 |
| 13. Уйгырлар | 262643 |
| 14. Төрекләр (месхет) | 207512 |
| 15. Тувалылар | 206629 |
| 16. Гагаузлар | 197768 |
| 17. Карачайлар | 156140 |
| 18. Балкарлар | 85126 |
| 19. Хакаслар | 80328 |
| 20. Нугайлар | 75181 |
| 21. Алтайлылар | 70777 |
| 22. Шорлар | 16652 |
| 23. Долганнар | 6945 |
| 24. Караимнар | 2602 |
| 25. Кырымчаклар | 1448 |
| 26. Тофаларлар | 731 |

## 1. Үзбәкләр

Үзбәкләр элекке Советлар Союзында яшәгән 26 төрки халык арасында иң күп санлы милләт. Әйткәнебезчә, 1989 елгы халык санын исәпкә алу мәгълүматлары буенча алар якынча 16698 мең хисаплана. Шулардан бүгенге Үзбәкстанның үзендә 15 миллион 220 мең, калганнары күрше республикаларда: Таҗикстанда (700 мең), Кыргызстанда (340 мең), Казакъстанда (230 мең), Төрекмәнстанда (200 мең) яши. Болардан тыш чит илләрдә (Кытайның Цянзин өлкәсендә, Әфганстанда, Иранда) 1,5 миллион үзбәк яши дип хисапланыла.

Үзбәк теле төрки телләрнең карлук төркемәнә керә. YI —XIII гасырларда Мәвараәннәһердә (Амударья белән Сырдәрья арасында) урнашкан төрки каганатында, Тюгеш, Карахани, Карлук патшалыклары дәверендә карлук теле уртак төрки тел булган. Төрки халыклар арасында үткән үзенчәлекле тарихи этногенетик процесс нәтиҗәсендә үзбәк теле өч төрки тел — кыпчак, угыз, карлук-уйгур телләре уртаклыгында формалаша һәм бу телләр хәзерге үзбәк телендәге өч төп диалектның нигезе дип хисаплана: кыпчак шивәсе, огуз шивәсе, карлук-чигил-уйгур шивәсе. Менә бу соңгысында Ташкент, Наманган, Әндижан, Фәргалә, Маргелан үзбәкләре сөйләшәләр һәм бу диалект үзбәк әдәби теленә нигез итеп алынган.

Бу өлкәләрдәге халыкларның теленә (фарсы) теле, гарәпләр экспансиясеннән соң гарәп хәлифәлеге дәверендә (XI гасырга кадәр) гарәп теле бик зур йогынты ясый, көчләп индерелә. Бу чорда алар, хәзергечә әйтсәк, дәүләт телләре булып хисаплана, ә төрки телгә сөйләм тел урыны гына калдырыла. Менә шуңа күрәдер инде, хәзерге үзбәк лексикасының төп өлеше (60%) әлеге телләрдән индерелгән алынмалардан тора. Шунысын да әйтергә кирәк, бүген төрле алынмалардан, бигрәк тә рус теле аркылы кергәннәрдән милли телләрне арындыру, чистарту чаралары үткәрелгәндә, үзбәкләр үз телләрен төрки тел нигезендә түгел, бәлки

инде кулланыштан чыккан, искергән шул ук фарсы, гарәп лөгатенә юнәлеш тоталар, яна сүзләр, терминнар ясаганда да әлеге телләргә нигезләнәләр.

Этногенез ягыннан караганда, үзбәкләрнең ата-бабалары согдиләр, хәрәзмнәр, бактриләр, фирганнәр һәм сакамәсәгутлар дип аталган борынгы төрки кабиләләргә барып тоташа. Төрек каганлыгы дәверендә алар яшәгән ике елга — Амударья белән Сырдарья арасындагы җирләргә төрки телдәге кабиләләрнең килеп урнашуы һәм бирелдәге феодаль мөнәсәбәтләр ике халык —үзбәкләр һәм таҗикларның формалашуын тизләтә, этәргеч көч бирә (VI — X гасырлар). Соңыннанрак, Караханилар дәүләте чорында (XI — XII гасырлар) үзбәкләрнең этногенез этабы тәгәлләнә, ләкин әле аларга карата "үзбәк" этнонимы гомум кулланышка соңрак, XV гасыр ахырында, бу халыклар арасында Шәйбани хан белән Дәште-кыпчак кавемнәре ассимиляцияләнгәч кенә керә.

Антропологик яктан үзбәкләр монголоидлар (сары) расасына керә һәм өч төп этнографик төркемне хасил итә: беренчесе электән "сартлар" дип аталган төп төркем, тышкы кыяфәтләре белән европеоидл (ак) расаны хәтерләтүче иранлыларга (таҗикларга) бик охшаш; алар дехканчылык (игенчелек) белән шөгыльләнүче утрак тормышлы кабиләләрдән гыйбарәт. Бу гавам үзбәкләрнең милләт буларак формалашуында төп укмаштыручы рольне уйный. Рус колонизаторлары үзләре басып алган Төркестан төбәгендәге башка халыклардан — таҗик, казакъ, каракалпак, уйгурлардан аерып, "сартлар" атамасын "үзбәк" этнонимы урынына кулланганнар һәм бу атама үзбәкләргә карата кимсетү, мәсхәрәләү ләкабе булып кереп калган.

"Төрекләр" этнонимы белән аталган икенче төркем — ике дәрья (Сырдәрья һәм Амудәрья) арасындагы борынгыдан ук ярымутрак хәлдә куйчылык белән шөгыльләнеп тормыш кичерүче төрек-монгол (карлук, барлас, угыз) кабиләләреннән укмашкан гаммә.

Өченче этнографик төркем (дәште-кыпчак) кыпчак, нәйман, канлы, хитой, кунгарт, мангыт, курама һ. б.) күчмә кабиләләрдән гыйбарәт.

Соңгы икесе XVI — XVII гасырларда утрак тормышлы сартлар тирәсендә укмашалар һәм бу берләшү XX йөз башында тәгәлләнә. Шулай да аларның һәркайсында кайбер этнокультура (тел, гореф-гадәт, матди көнкүреш һәм рухи-мәдәни мирас) үзенчәлекләре бүгенге көнгә кадәр сакланып килә. XIII —XIV гасырларда бу халыклар яшәгән Мәнвараэннәһер җирләре Чыңгызхан токымы (Жучи, Чагатай, Үгәдәй, Толуй, Хулагу хан) хакимлеге астында. XI — XVI гасырларда Тимурилар династиясе (Әмир Тимер үзе һәм аның токымнары Шәһрух, Олугбәк, Бабур) хакимлеге астында яшиләр. XVI йөз ахырында Аштарханилар династиясе хөкемдарлыгы башлана һәм алар кул астына Хива, Хәрәзм ханлыклары да керә. XVII гасыр уртасында исә үзбәк җирләрен Иран хакиме Надир шаһ гаскәрләре басып ала һәм бөек мангытлар династиясе хөкемлеге урнаша.

XIX йөзнең икенче яртысында, тәгәлрәге 1867 — 1968 елларда Урта һәм Үзәк Азияне һәм Казакъстанның көньяк өлкәләрен Россия гаскәрләре басып ала һәм Россия империясе "Төркестан крае" дип аталган генерал-губернаторлык колониясен төзи. Бу губернаторлыкка хәзерге Үзбәкстан, Көнбатыш Кытай (уйгур), Әфганстанның көньяк вилаятьләре дә кертелә.

1917 елда Төркестан төбәгендә совет власте урнаштырыла, 1918 елның мартында Төркестан АССР оештырыла, ә 1924 елның октябрендә Ташкент, Коканд, Бохара, Хива, Хәрәзм, Фәрганә, Каракалпак вилаятләрен берләштереп, Үзбәкстан ССР союздаш Республикасы төзелә.

Үзбәкләр Ислам диненең сөнниләр тармагына керәләр.

## 2. Казакълар

Үз атамалары — казакъ. 1925 елга кадәр русларда һәм тарихи әсәрләрдә, рәсми документларда аларны "кыргыз казаклары", күп очракларда күрше халык исеме белән бутап "кыргызлар" дип атап йөрткәннәр, хәзер аларны рус (Кубань, Урал, Себер, Дон) казакълары белән бутамас өчен рус телендә казахлар дип атап йөртәләр.

1989 елда халык санын исәпкә алу буенча элеккеге СССР территориясендә яшәгән казакъларның гомуми саны 8 миллион 135,8 мең хисаплана. Аларның төп өлеше бүгенге Казакъстанда (73%), калганнары янәшә республикаларда — Үзбәкстан, Төрекмәнстан, Кыргызстан, Таҗикстанда, Россия Федерациясендә яши. Болардан тыш 2 миллионнан артык казакъ читтәш илләрдә — Кытайның Синзян-Уйгур автономияле районында, Әфганстанда яшиләр.

Казакъ теле төрки телләренең көнбатыш тармагына караган кыпчак-нугай төркеменә керә. Башка төрки телләрдән аермалы буларак, казакъ телендә бер-

берсеннән ачык аерылучы диалектлар юк, фәкать башка төрки төркемнәр белән янәшә яшәүчеләрендә генә кайбер лексик һәм фонетик аерымлыклар күзәтелә. Шуның өчен казакъларда әдәби тел белән сөйләм теле арасында әллә ни аерма сизелми.

Казакъларның этник тарихы бик борынгыдан килә. Аларның кадимче ата-бабалары хәзерге Казакъстан җирләрендә һәм Урта Азиядә яшәгән "сакъ" дип аталган һәм соңыннан аларга кушылган "усун" кабиләләренең берләшү-аралашуыннан укмашкан канга токымыннан дип хисапланыла. Казакълар этносының формалашуына Арал диңгезе буйларында яшәгән аланнар да йогынты ясаган. XI — VII гасырларда бу җирләр төркиләр каганаты астында була, ә VIII — XI гасырларда бу якларга тюргеш, карлук, киман, кыпчак, угыз һәм башка төрки халыклар күчеп килгәч, алар ассимиляцияләшәләр һәм бу Дәште-кыпчак дип аталган зур территориядә төрки Караханилар дәүләте барлыкка килә. XII гасырда Караханилар дәүләтенә Киданилар-каракытайлар басып керәләр һәм үзләре дә бу җирләрдәге төрки халыклар арасында буталып бетәләр. Шуңа күрәдер дә, казакълар антропологик кыяфәтләре белән кытайларга тартым. XV — XVI йөзләрдә әлеге этник төркемнәрнең берләшүе төгәлләнә. Казакълар халык буларак формалашалар һәм Казакъ ханлыгын төзиләр. "Казакъ" дигән этноним этник термин сыйфатында бу ханлыкка кергән һәммә этник төркемнәргә карата кулланыла башлый.

Казакъ халкы тарихи-этногенез ягыннан хуҗалык, көнкүреш, гореф-гадәтләрен саклап килгән өч төп территориаль төркемгә бүленә:

**1.** Олы жуз (Җиде су төбәге). Моңа дулат, албан, суан, канглы, жалыйыр, сиргеле, шанышкылы, сары-уйсен этник төркемнәр керә.а **2.** Урта жуз. Монысы дала районнары, үзәк, Сырдәрья, Ишим, Тубыл төбәкләрендә көн күрүче аргын, найман, кыпчак, керәй, кунграт этник төркемнәрен эченә ала.

**3.** Кеше (кече) жуз көнбатыш казакъ җирләрен били. Бу төбәктә алим-улы, бай-улы кабиләләре, одай, алчын, жаппас оруглары урнашкан. XIX гасыр урталарында Россия экспансиясе нәтиҗәсендә бу жузлар таркатыла, Казакъ дәүләте җирләренең күп өлеше: хәзерге Семипалат, Акмолла (Акмолинск, Урал өлкәләре, Үзбәкстандагы Җите-Су, Сырдәрья өлкәсенең бер өлеше турыдан-туры Россия империясенә кертелә.

1917 — 1918 елларда бу өлкәләрдә бер-бер артлы Совет власте урнаштырыла. Төркестан краенда Төркестан Автономияле Совет Социалистик Республикасы — ТАССР төзелә. 1924 — 1925 елларда ТАССРда милли чикләрне билгеләү уздырыла һәм 1925 елның 19 апрелендә Казакъстан АССР оештырылып, РСФСР составына кертелә, 1936 елның 5 декабрендә Казакъстанга СССР составындагы союздаш Республика статусы бирелә. СССР таркалгач, Казакъстан бәйсез дәүләте барлыкка килә.

Шуны да өстәргә була, казакъ халкы икътисади һәм мәдәни өлкәләрдә Урта Азия һәм башка яклардагы төрки халыклар белән чагыштырганда Идел буе, бигрәк тә безнең татар халкы белән тыгызрак мөнәсәбәттә яши. Татар мәгърифәтчеләре, әдипләре, мөгаллимнәре казакъ җирләренә, далаларына изге миссия белән барып мәктәпләр ачалар, мөгаллимлек кылалар, агарту эшләре алып баралар. Мохтар Ауэзов, Габидин Мостафин, Габит Мусрепов кебек казакъ язучыларына татар әдәбияты, бигрәк тә Тукай, Г. Ибраһимов иҗатлары зур йогынты ясый.

Казакълар сөнниләр юнәлешендәге Ислам динен тоталар.

## 3. Әзербайҗаннар

Алар үзләрен әзербайҗан дип тә, әзәриләр дип тә атыйлар. Россия империясе кавказ халыкларын буйсындыру өчен алып барган сугыш вакытында (1817 - 1864) һәм аннан соң да (XX гасыр башына кадәр) Кавказдагы төрки мөселман халыкларын бергә җыеп, шулар җөмләсеннән әзербайҗаннарны да гомуми исем белән сөйләм телендә дә, рәсми тарихи документларда да татарлар дип атап йөртәләр. Л. Толстойның "Хаҗи Морат", "Казакълар" әсәрләрендә дә әзербайҗанлылар татарлар дип телгә алынган. СССРда 1989 елгы халык санын исәпкә алу мәгълүматларына караганда, әзербайҗаннарның саны 770 мең кеше тәшкил итә һәм алар төрки халыклар арасында сан ягыннан казакълардан кала өченче урынны билиләр.

Әзербайҗанның күпчелеге (70 проценты) хәзерге Әзербайҗанда, калган өлеше күрше өлкәләрдә: Грузия, Әрмәнстан, Дагъстан, Казакъстан, Үзбәкстан, Төрекмәнстанда яшиләр. Болардан тыш әзербайҗаннарның үз

республикаларындагыдан да күбрәге (5 миллионга якын) Иранда ("Иран әзербайжаны" дип аталган аерым вилаяттә), 1,7 миллион әзербайжанлы Гыйракта тора. Бәйсез Әзербайжан дәүләтендәге әзербайжанлыларның 85 проценты Ислам диненең шигыйләр тармагына, калганнары сөнниләргә карый. Әзербайжан теле төрки телләрнең угыз төркеменә керә. Халыкның 97 проценты әзербайжан телен туган теле дип саный һәм шул телдә сөйләшә. Бу тел грамматик, фонетик һәм лексик яктан төрекмән, төрек, гагауз телләренә бик якын тора, бер үк вакытта әлеге билгеләр, бигрәк тә фонетик яктан, элекке кыпчак, карлук төркемнәренә кергән үзбәк, нугай, кумык телләре белән дә аһәңдәш.

Әзербайжан телендә дә, башка төрки телләрдәге шикелле, берничә диалект бар һәм алар фәндә кабул ителгәнчә, дүрт төркемгә бүленә:

**1.** Көнчыгыш төркем. Бу төркемгә көбә, бакы, шәмәхә диалектлары һәм дә муган, ленкоран сөйләшләре керә.

**2.** Көнбатыш төркемне кезакъ, ганжә, карабах диалектлары һәм әйрум сөйләше тәшкил итә.

**3.** Төньяк төркемгә нухлар диалекты һәм зәкат-как сөйләше керә.

**4.** Көньяк төркем. Монысына нәхичиван, ардубәд, тәбриз диалектлары һәм дә әреван сөйләше керә. Болардан тыш, берсе белән икенчесе арасында торган тагын берничә: көкчәй, агдаш, жәбрәил шикелле шивәләр дә бар.

Этногенезы буенча әзербайжан халкының тамыры бик ерактан килә.

Безнең эраның I гасыр башларында, аннан соң да төрки-фарсы телле төрле кабиләләр (киммери, скиф, һун (гуннар), болгар, хазар, угыз, кыпчак һәм башкалар бу жирләргә басып керәләр яки башка баскынчылардан качып киләләр. Алар бу жирләрдә электән үк яшәп килгән төп халыклар — антропатен һәм албаннар, маннейләр белән кушылып, аралашып китәләр.

Әзербайжаннарның халык булып формалашуы XI гасырда бу жирләргә төрки телле сәлжуклар килеп кушылгач башлана һәм XII йөздә тәгәлләнә.

Әнә шундый аралашулар нәтижәсендә әзербайжаннар тарихында хужалык, көнкүреш, гореф-гадәт, мәдәният ягыннан үзенчәлекле берничә этнографик төркемнәр барлыкка килә. Көнбатыш, таулы төбәктә игенчелек һәм терлекчелек белән шөгыльләнүче карапапахалалар төркеме, алар сан ягыннан башкаларыннан өстенрәк. Әрмәнстан белән чиктәш районнарда, Грузиядә, ә күбрәк өлеше Төркиядә яши. Падәрләр көнчыгыш өлкәдә; шәхсеваннар төркеме көньякта, Муган далада, Иранда; карадаглылар — Карадаг калкулыгында, афшарлар Иран белән чиктәш районнарда яшиләр.

XIV гасыр ахырында бу жирләрне Аксак Тимер гаскәрләре басып ала һәм анда Ширвәншаһлар дәүләте урнаштырыла, ә XVI гасыр башларында алар иранлы сефебийләр династиясе кул астында калалар һәм бу чактагы Иран шаһы Габбаска (1587 —1629) каршы үз мөстәкыйльлекләре өчен көрәшкә күтәреләләр. Бу көрәшне тарихта һәм әдәбиятта исемен калдырган Кер оглы (сукыр улы) житәкләгән һәм аның турындагы поэма Әзербайжан халкының дастанына әйләнгән.

XVIII гасыр башында (1723) Әзербайжанга рус экспансиясе башлана. Моны күреп Төркия, Иран да үз гаскәрләрен жибәрәләр һәм бу илне бүлгәләү-телгәләү китә. Нәтижәдә, XVIII гасыр ахырында әзербайжан жирләрендә унбишләп вак һәм эре дәүләтләр (ханлыклар) барлыкка килә (иң зурларыннан Шекә, Карабах, Көбә), Иран, Төркия тарафыннан туктаусыз хәвефле чыгышлар булып тору аркасында, Карабах, Шекә, Гәнж ханнары Россиягә ярдәм сорап мөрәжәгать итәләр. Нәтижәдә, бу ханлыклар Россиягә кушыла (1803 — 1805).

1917 елның ноябрендә Бакуда совет власте урнаштырыла, әмма ул 1918 елның июлендә төшерелә, аның житәкчеләре — 26 комиссар, шулар җөмләсеннән әзербайжанлы М. Азизбәков, М. Везиров, Т. Әмиров эсер һәм инглиз интервентлары тарафыннан атып үтереләләр.

Ике ел буенча интервентларга, акгвардиячеләргә каршы канлы көрәштән соң, 1920 елның 26 апрелендә Әзербайжанда советлар хакимияте яңадан урнаштырыла. 1922 — 1936 елларда Әзербайжан аерым республика сыйфатында Кавказ халыкларын эченә алган РСФСРга кертелә. 1936 елда бу федерация таркатыла, Әзербайжан союздаш республика статусы белән СССР составына кертелә. 1992 елдан бәйсез дәүләт.

## 4. Төрекмәннәр

Элекке Советлар Союзы территориясендә яшәүче төрки халыклар арасында 1989 елгы халык санын исәпкә алу мәгълүматлары буенча төрекмәннәр 2,8 млн. чамасы кеше һәм төрки милләтләр арасында сан ягыннан алар бишенче урында. Төрекмәнстанның үзеннән тыш аларның күпсанлы булмаган төркемнәре Үзбәкстанда, Казакъстанда, Тажикстанда һәм Ставрополь краенда

яшиләр. Болардан тыш чит илләрдә (Әфганстан, Иран, Төркия, Сүрия, Кытайның Синцьзян өлкәсендә) барлыгы бер миллионнан артыграк төрекмән яши дип хисаплана.

Төрекмән теле төрки телләрнең көньяк-көнбатыш угыз төркеменә керә. Илебездәге башка төрки халыкларның теленнән аермалы буларак, төрекмән телендә чит телләрдән кергән алынмаларның микъдары әлләни күп түгел, лексик составының 85 проценты гомумтөрки, саф төрекмән сүзләреннән гыйбарәт һәм фонетик яңгырашы белән төрек, әзербайҗан, кырымтатар телләренә бик якын. Шуның белән бергә, фарсы, үзбәк, рус телләреннән кергән алынмалар барысы да диярлек үз телләренә яраклаштырып фонетикалаштырылган.

Төрекмәнстанда да туган телне чистарту, камилләштерү, баету процессы бара, әмма үзбәкләрдән (һәм татарлардан) аермалы буларак, ул искергән, онытылган гарәп, фарсы сүзләрен кире кайтару юлы белән түгел, ә милли тел мөмкинлекләреннән файдалану юлы белән башкарыла.

Төрекмән телендә тарихи сәбәпләр аркасында бик күп диалектлар, сөйләшләр барлыкка килгән. Лексик, фонетик, грамматик үзенчәлекләренә карап алар төп ике төркемгә бүленә. Беренчесе — төньяк төркем: ахал, текин салыр, гөкле, емуд диалектлары һәм карадаш, алили (язып), эрсари сөйләшләре. Икенчесе — көньяк төркемгә Копет-Даг, Амударья үзенчәлекләрендә яшәүче халыкларга хас нохур, анау, эске, сурхы, арабачы, кырыч, чандыр, мукра, хатап, баять, чегес шикелле көчле диалектлар һәм жирле сөйләмнәр керә һәм боларны төрекмән әдәби теленнән лексик яктан шактый аерылалар.

Ике төп диалект арасында лексик яктан да, фонетик яңгыраштa да сизелерлек аермалар бар. Мәсәлән: бозау — тане; өҗок — гөлө, ата (әти): — дәд е.

Төрекмәннәрнең этногенезына килгәндә, аларның килеп чыгышы Арал-Каспий тирәсендәге жирләргә сасанилар (IV —VII), Хорәсән, Парфән (VII — X) феодал дәүләтләрендә яшәгән масагыйтләр дип аталган төрки кабиләләргә барып тоташа. Масагыйтләрнең этногенезы тәгаен ачыкланмаган, әмма төрекмәннәрнең халык булып формалашуында аларның роле зур булуы инкарь ителми. Бу жирләр угыз кул астына төшкәч, монарчы ук башланып киткән төрекләшү процессы тизләзә.

Ниһаять, сәлҗуклар экспанциясе вакытында (X — XI) төрки телдәге кабиләләр консалидациясе барлыкка килә, алар уртак этноним белән “төрекмәннәр” дип атала башлыйлар. Һәм төрекмән теленә нигез салалар. Соңыннан, (XIV — XV гасыр) бу зур төбәктәге угызларның бер өлеше аланнар, кыпчаклар, хорезмлеләр, ә XV — XVI йөзләрдә Каспий диңгезенең көнчыгыш яр буйларында, Мангышлак ярымутравында, Сары Камыш күле тирәсендә сибелеп яшәгән төрки халыклар Төрекмәнстан дәүләтен коралар.

XVI гасырда Иран һәм Бохара хакимнәре арасында бу дәүләтне үзләренчә буйсындыру өчен сугыш башланып китә. Бу сугышта ике якның да хәлсезләнеп калуыннан файдаланып, үзбәкләрнең Хорезм ханы төрекмән жирләренең зур өлешен басып ала. XVII гасыр уртасына кадәр дәвам иткән үзара сугышлар нәтижәсендә төрекмән жирләренең күп өлеше Иран дәүләте, Бохара, Хива ханлыклары арасында бүленә.

Төрекмәннәрнең авыр хәлдә калуыннан файдаланып, Россия империясе дә үзенә өлеш чыгармакчы була, төрекмәннәргә Иран золымыннан котылу өчен ярдәм күрсәтү сылтавы белән Петр I бу жирләргә купсанлы хәрби “булышлык” экспедициясе жибәрә. 1869 елда Каспий диңгезенең көнбатыш ярына төшерелгән бу экспедициянең хәрби отрядлары Төрекмәнстанны әкренләп басып алу максаты белән бу урында форпост итеп Красноводск шәһәрен сала башлыйлар. Бу форпост салынгач, 1881 елда генерал Скобелев житәкчелегендәге рус гаскәрләре ачыктан-ачык оккупация башлап жибәрәләр, Гек-Типәне (Ашхабадтан 45 км.) алалар һәм Ахал төбәген Россиягә кушалар.

1867 — 1868 елларда Урта Азияне, Казакъстанны патша гаскәрләре Россиягә “кушып алалар” һәм бу жирләрдә “Төркестан крае” дип аталган генерал-губернаторлык урнаштырыла. 1899 елдан башлап Төрекмәнстан да шул крайга кертелә. 1918 елда бу край Төркестан АССР (ТАССР) дип игълан ителә һәм 1924 елда ТАССР да милли дәүләтчелек нигезендә чикләрне билгеләү уздырыла һәм Төрекмәнстан союздаш республика статусы ала. 1992 елдан бәйсез дәүләт. Диннәре — Ислам. Халыкның күп өлеше Исламның сөнни агымын тота, калганнары шигыйләр агымында.

## 5. Кыргызлар

Егерменче гасыр башларына кадәр аларны каракыргызлар дип атап йөрткәннәр, ә кытайлар кыргызларны бүген дә "бурут" диләр. 1989 елгы халык санын барлау буенча мәгълүматларда элекке СССРда яшәүче кыргызлар саны 2.529 мең чамасы дип хисаплана. Шуларның күпчелеге (1,6 миллион) Кыргызстанның үз территориясендә, калганнары күрше дәүләтләрдә: Үзбәкстанның Фирганә, Әндиҗан, Наманган өлкәләрендә, Таҗикстанның Таулы Бадахшан автономияле өлкәсендә, Әфганстанның көнчыгыш районнарында, Кытайның Уйгур автономияле районында торалар.

Кыргызларның чыгышына килгәндә, алар Кытай елъязмаларында безнең эрага кадәр II гасырда ук телгә алына һәм аларның тамыры Кытайның Тән-Гүн токымына бәйле дип күрсәтелә. Монголиянең төньяк-көнбатышында яшәгән бу кабиләләр гуннар тарафыннан кысрыклана башлагач, алар Минусин инкүлекләренә (хәзерге Хакас автономияле өлкәсе) күченәләр. Сонрак (V — VI йөзләрдә) кыргызлар төрки-угыз белән сугышлар алып баралар һәм Енисейдан Байкалга, Көньяк Төркестанга барып житәләр, шактый зур территорияне билиләр. VIII гасырда алар Тянь-Шань төбәгендә яшәүче төрки-карлукларга кушылып, уйгурларга каршы каты сугышлар алып баралар, аларны җиниләр. Кыргызларның биләмәләре тагын да киңәя, шулай да аларның хәрби һәм сәяси яктан берләшүе үзәге булып шул ук Минусин түбәнлеге һәм Тува җирләре кала. XIII йөздә Чыңгыз хан кыргызларны союздаш итеп үз гаскәрләренә алмакчы була, әмма алар моңа риза булмыйлар. Шуннан соң, Чыңгыз ханның өлкән улы Җучи үзенең гаскәрләре белән кыргыз җирләрен басып ала һәм энесе Төүне алар өстеннән хаким итеп куя. Кыргызларның XIV — XV гасырлардагы тарихы турында фәндә ачык мәгълүматлар юк.

XVI — XVII гасырларда аларның монгол ханнары, калмык, үзбәк феодалларына каршы көрәш алып барулары мәгълүм. Бу чорда Енисей буйларына сузылган дүрт кенәзлек — улуслар оеша: Түбә, Езәр, Алтыр, Алтысар.

XVII — XVIII гасырларда кыргызлар көньяк-көнчыгыш җирләрендә хакимлек урнаштырырга маташкан рус воеводаларына каршы көрәшкә күтәреләләр. XVIII гасыр башында Көньяк Себердә яшәгән 2500 кыргыз гаиләсен руслар һәм аларга кушылган калмыклар көчләп алып китәләр. Күпләре бу юлдан качып Памирга, Алай, Фирганә үзәннәренә күчә, бер өлеше хәзерге хакаслар һәм тувалыларга кушылып аралашып китәләр, калганнары Тянь-Шаяньга кайта.

XVIII гасыр ахырында Фирганә уйсулыкларындагы кыргызларны Коканд ханы үзенә буйсындыра һәм алар Россия колонизациясенә кадәр шушы ханлыкта яшиләр. 1862 — 1870 елларда Урта Азияне руслар үз империяләренә кушкач, кыргызлар Төркестандагы башка халыклар белән бергәттән, Россия империясенең Төркестан крае (Төркестан генерал-губернаторлыгы) составына кертелә һәм революциягәчә шул буйсынышта кала.

1918 елда РСФСР составында Төркестан АССР оештырылгач, кыргызлар да шуңа кушыла. 1924 елда Төркестан АССРда милли чикләрне билгеләү үткәрелә һәм РСФСР составында Төркестан АССРдан аерып, Каракыргыз автономияле өлкәсе төзелә. 1926 елда бу өлкә Кыргызстан АССР дип игълан ителә. 1936 елда исә аңа союздаш республика статусы бирелә. 1991 ел ахырында СССР дәүләте таркатылгач, 1992 елдан бирле Кыргызстан — бәйсез дәүләт.

Кыргыз теле төрки телләрнең көнчыгыш тармагына карашлы кыргыз (каракыргыз) кыпчак төркеменә керә һәм үзенең фонетик, лексик үзенчәлекләре белән тау-алтай теленә бик тартым һәм шул тел белән бер үк классификациядә хисаплана. Хәзерге кыргыз теле күрше кыпчакларның озак вакытлар дәвамындагы тәэсире аркасында нык үзгәрсә дә, үзенең төсмерен саклап калган. Кыргызларның 97,5 проценты үз милли телләрен туган тел дип саныйлар һәм шул телдә сөйләшәләр.

Кыргыз халык сөйләм теле һәркайсысында берничә сөйләш булган өч төп диалектка бүленә: төньяк, көньяк-көнчыгыш, көньяк-көнбатыш диалектлар. Бу диалектлар әлеге төбәкләргә фарсы, гарәп, үзбәк, уйгур, алтай телләре йогынтысы һәм шул телләрдән кергән алынмалар нәтиҗәсендә барлыкка килгән. Кыргыз әдәби теле исә 20 нче елларда гына формалаша. Аның формалашуында әлеге диалектларның һәм сөйләшләрнең барысы да диярлек катнашкан. Шулай да әдәби телнең нигезе итеп төньяк диалектының лексикасы һәм фонетикасы кабул ителгән. 1992 елда, Кыргызстан суверен дәүләт статусы алганнан соң, кыргыз теле бердәнбер дәүләт теле санала.

Кыргызларның дине Исламның сөнниләр юнәлешенә карый.

## 6. Чувашлар

Үз атамалары... — чаваш. СССРдагы халыкларның санын соңгы (1989) исәпкә алу нәтиҗәләре буенча чувашларның гомуми саны 1842346 кеше. Шулардан Чувашиянең үзендә 52 процент, ә калган 48 проценты күрше төбәкләрдә (Татарстан, Башкортстан республикаларында, Самара, Сарытау өлкәләрендә, бер өлеше Көнбатыш Себердә) яши.

Чувашларның этногенезына карата әлегечә тотрыклы, фәнни нигезле төгәл һәм ачык җавап һәм караш юк. Бу мәсьәләдә этнография һәм тел белеме фәннәрендә төрлечәрәк фикерләр яшәп килә. Шулардан берсе — "Болгар-чуваш теориясе".

Бу теориягә нигез салучы чуваш галиме Н. Ашмарин һәм аның шәкертләре (В. Егоров, Ф. Тимофеев, Т. Матвеев һәм башкалар) фикере буенча: "Чувашларның ата-бабалары — Идел болгарлары, бүгенге чувашлар шуларның турыдан-туры нәселе, ә татарлар исә алардан соңгы килмешәкләр. Татарлар килеп борынгы Болгарны жимергәннәр, аннары биредәге халыкларны ассимиляцияләштергәннәр, бер үк вакытта алар андагы халыкның (чувашларның югары мәдәниятен үзләренә кабул иткәннәр" (Н. Ашмарин. Болгары и чуваши, 1902).

Бүгенге чуваш галимнәре әле дә шушы "концепцияне" алга сөрәләр. Безнең татар тюркологлары (М. Зәкиев) фикеренчә, киресенчә, Идел-Кама болгарлары чувашларның түгел, ә татарларның формалашуында төп роль уйнаган.

Күпчелек галимнәр чувашлар төрки телле Идел-Кама болгарлары (суварлар-сувазлар) һәм җирле угро-фин халыклары (мордва, удмурт, марилар) белән аралашып китүе нәтиҗәсендә формалашкан, дигән фикердә.

Шуны да өстәргә була, антропологик төзелешләре — кыяфәтләре белән чувашларны тәгаен бер расага кертү дә читен. Тюрколог В. Алексеев әйтүенчә, баш сөяге формасы белән чувашлар үзләренең угро-фин телле күршеләренә охшыйлар, европеидларга тартымнар, болгарларга хас антропологик (монголоид) билгеләр комплексы чувашларда булса да, алар алай сизелерлек күренми. Бу бәя чувашларның этногенезы турындагы күпчелек галимнәрнең фикерен куәтли шикелле.

Диннәре ягыннан чувашлар электән мәҗүси булганнар. Фәкать XVIII гасыр урталарында гына руслар тарафыннан христианлаштырылганнар һәм православие динен кабул иткәннәр.

XV гасыр уртасында чуваш җирләре Казан ханлыгына кертелә һәм шул гасыр ахырында алар халык булып формалашалар. Яшәү җирләренә карап, алар ике төп этнографик төркемгә бүленә. Иделнең үрге агымында яшәүчеләр — үрге чавашлар (вирьялар), түбәнге агымында яшәүчеләре — түбәнге чавашлар (анатрилар), алар уртасында яшәүче уртадагы чувашлар ике төркемгә дә тартым: тел ягыннан вирьяларга, ә көнкүреш, гореф-гадәт ягыннан анатриларга якын. Чит өлкәдә яшәүчеләрнең күпчелеге анатрилар.

1551 елда чувашлар үз теләкләре белән Россиягә кушылалар һәм 1552 елда Явыз Иван Казанны басып алганда, аның гаскәрләренә зур булышлык күрсәтә, дигән фикер дә яши. 1920 елның июнендә РСФСР составында Чувашия автономияле өлкәсе оештырыла, 1925 елның апрелендә аңа Автономияле Республика статусы бирелә.

Чувашларның теле тюркология фәнендә кабул ителгән классификация буенча төрки телләрнең көнбатыш тармагының болгар төркеменә карый. Ул угро-фин һәм төрки телләр кушылудан барлыкка килгән. Әмма икесеннән дә ераклашкан, шулай да төрки нигезе сакланган тел дип карала (М. Зәкиев. Татар халкы теленең барлыкка килүе, 148 б.) Икенче бер галимебез: "Чуваш теле борынгы болгар теленең дәвамы һәм бу карашка ревизия ясауның һичбер кирәге юк", дип кырт кисеп әйтә (Р. Әхмәтҗанов. Сравнительное исследование татарского и чувашского языков. М. , "Наука", 1978).

Халыкның 75 проценты үз милли телен туган теле дип саный һәм шушы телдә сөйләшә. Халыкның югарыда әйтелгән ике этнографик төркеменә карап чуваш теле дә ике төп диалектка бүленгән (вирья һәм анатри). Алар лексик, бигрәк тә фонетик яктан бер-берсеннән сизелерлек аерылалар. Үрдәге чувашларга "о" лаштырып сөйләшү хас (бар — "пор") һәм аларның диалектында гарәп-фарсы, угро-фин (мари), рус телләреннән кергән алынмалар күп булса, түбәнге диалектка "у" лаштырып сөйләшү хас (бар — "пур") һәм татар, рус лексик катламы зур урын алган.

## 7. Башкортлар

Элеккеге Советлар Союзында яшәгән башкортларның гомуми саны 1449157 кеше (1989 елгы мәгълүматлар буенча) хисаплана. Ләкин шунысын да әйтергә кирәк, бу сан хакыйкатьне тулы чагылдыра дип булмый. Чөнки бу саннар исәбенә паспортларына "милләте башкорт" дип язылган Башкортстан территориясендә яшәүче бик күп татарлар да кертелгән. Башкортларның төп өлеше хәзерге Башкортстан Республикасында яши, калганнары —күрше-чиктәш Татарстан Республикасында, Чиләбе, Оренбург, Сарытау, Самара, Курган өлкәләрендә. Гарәпләрнең борынгы язма чыганакларында (Ибн Фадлан) алар "башгурд", "башгирд" исеме белән (X гасыр) Идел һәм Җаек арасында терлекчелек белән шөгыльләнүче халык дип телгә алына.

X — XIII йөзләрдә башкортлар Идел-Кама болгар дәүләте кул астында булалар. Алтын Урда берничә халыкка бүленеп таркалгач (XV гасыр), башкортлар да бүленеп китәләр: аларның көньяк һәм көньяк-көнчыгыш өлеше — Нугай, көнбатышы — Казан ханлыгына, төньяк-көнбатыш өлеше исә Себер ханлыгына кертелә. Иван IV Казан ханлыгын яулап алганнан соң, Рус патшалыгы бу ханлык территориясенә кергән башкортлардан рус подданствосын кабул итеп, ясак түләп торуны таләп итә. Көнбатыш башкортлар тәкъдимне шундук кабул итәләр (1552). Ә биш елдан соң (1557) башкортларның калган өлеше дә Россиягә үз теләкләре белән кушылырга риза булып, Мәскәүгә атчабарларын җибәрәләр. Аларның бу теләге, әлбәттә инде, кабул ителә.

1957 елда бу тарихи датаның 400 еллыгын Башкортстан зур тантана белән билгеләп үтте. Өфедә "мәңге какшамас дуслык"ка багышлап бронзадан мәһабәт "Дуслык монументы" салынды. Кушылуның 440 еллыгы да зурлап уздырылды. Ләкин русларга ясак түләү микъдары торган саен арта, патша хөкүмәтенең җәберләве көчәйгәннән-көчәя барды һәм мондый изүгә чыдый алмаган башкортлар берничә мәртәбә (XVII — XVIII йөзләрдә) коралллы күтәрелешләргә кузгалды: Пугачев явына кушылып Салават Юлаев, Кинҗә Арысланов житәкчелегендәге восстание, башкортларны һәм рус булмаган халыкларны көчләп чукындыруга каршы "газават" сугышы (1681 — 1683), башкорт җирләрендә русларның корал белән ныгытылган крепостьлар коруга каршы көрәш (1735 — 1740), патша хакимиятенең җәберенә һәм көчләп чукындыруларга каршы Батырша житәкчелегендәге коралллы восстание (1755) һәм башка җирле чыгышлар булды.

Революциянең икенче көнендә үк (8. 11. 1917) башкорт җирләрендә совет власте урнаштырыла, әмма ул озак яшәми, 1918 ел башыннан власть акгвардиячеләр, эсерлар кулына күчә. Янадан совет власте кайтарылгач, 1922 елның 23 мартында РСФСР составында беренче буларак бүгенге чикләрдән Башкортстан Автономияле Совет Социалистик Республикасы төзелә*.

Башкортларның этногенезы үтә катлаулы. Бу халык формалашып барган дәвердәге җирләр — Көньяк Урал һәм аңа тоташ далалар борын-борыннан төрле телдәге халыкларның үзара актив аралашу мәйданы була. Үткән эраның ахырында ук инде бу төбәкнең көньягында иран телле, терлекчелек белән көн күрүче ярымкүчмә сарматлар, төньягында игенчелек, аучылык белән шөгыльләнүче угро-фин кабиләләренең бабалары ( бүгенге удмуртлар, коми, хыряннар) яшәгән. Яңа эраның башыннан көньяк Уралга төрки халыклар үтеп керә башлый һәм алар беренче йөз ахырында башкортлар яшәгән барлык җирләрне биләп алалар. Бу урыннардагы аборигеннарның бер өлешен кысрыклап куалар, калганнары бу төрки халыклар арасында ассимиляцияләнә һәм әлеге төркиләр бу җирләрдә яшәгән башкортларның телен, мәдәниятен генә түгел, кыяфәтен формалаштыруда да хәлиткеч роль уйныйлар.

IX — XI йөзләрдә төрки угыз-печенеглар, ә соңрак кайбер монгол кабиләләре дә башкортларның этногенезында катнашалар. Башкортларның дине Исламның сөнниләр агымына карашлы.

Башкорт теле төрки телләрнең көнбатыш тармагына кергән кыпчак-болгар төркемена карый. Башкорт теле татар теленә синтаксик яктан бик якын булса, ул безнең телдән лексик, шулай ук фонетик яктан шактый аерыла. Башкорт сөйләм теле лексикасы һәм тартык авазларының аермасына карап ике төп диалектка бүленә: көнчыгыш (кувака) һәм көньяк (юрматы) диалектлары. Шунысын да әйтеп үтәргә кирәк, хәзер башкорт тюркологлары һәм язучылары Башкортстанның

---

*1919 елның июнендә берничә өяздән торган "Башкортстан мөхтарияте" оештырыла (башкаласы — Стәрлетамакта).

төньяк-көнбатыш төбәкләрендә, ягъни Татарстан белән чиктәш Яңавыл, Илеш, Нефтекама, Дүртөйле, Бөре, Калтасы, Бакалы, Туймазы, Борай районнарында яшәүче ярты миллионнан артык татарларны башкорт теленнән өченче — төньяк диалектында сөйләүчеләр дип игълан итәргә җыеналар.

Югарыда әйткән көнчыгыш диалектының төп билгесе — "с" фонемасының "һ"гә, (солы — һоло), л, м, н ның "т"гә күчүе, "д" белән алмашуы (ташлык — таштык, урманлык — урмандык һәм башкалар). Бу диалект әдәби телнең нигезе итеп алынган.

Көньяк диалекты күп кенә тарафтан татар теленә якын һәм аның безнең телдән аермасы "з" авазының "д"гә, "ми", "мый" юклык кушымчаларының "мәй"гә күчүендә дип исәпләргә була (бозау — бодау, кызыл — кыдыл, булмый — булмай, кирәкми —кирәкмәй). Башкорт теленең орфографиясе авазларның сөйләм телендә яңгыравына карап төзелгән (авыл —ауыл, болыт —болот, борылды — бородло). Башкортларның 70 проценты милли телләрен туган тел дип таныйлар.

## 8. Каракалпаклар

Рәсми аталышлары — каракалпак, үз атамалары — калпак. Бу халыкның гомуми саны 423 мең (1989 ел хисабы буенча). Аларның 81 проценты хәзерге Каракалпакстанның үз жирендә, калганнары Төрекмәнстан, Үзбәкстан, Әфганстанда яши. Чит өлкәләрдә яшәүчеләр шул җирләрдәге халыклар белән озак дәверләр аралашып, бөтенләй диярлек ассимилияцияләнгәннәр.

Каракалпак халкы этник яктан ике олы кавемгә — ике арыска бүленгән. Берсе "арыс унтурт" дип атала. Аңа Амурдәрьяның уң як ярларында, Кегәйле елгасы буйларында яшәүче ыруг-кабиләләр (кытай, кыпчак, кенгес, мангыт һәм башкалар) керә. Аларның төп кәсебе — игенчелек һәм терлекчелек. Икенчесе "Арыс конграт" дип атала, аңа Амурдәрья тамагында, Арал дингезе буйларында һәм аның утрауларында (хәзерге Муйнак, Тактакүпер, Кунграт районнарында) яшәүчеләр керә. Боларның төп кәсепләре — терлекчелек белән балыкчылык. Бу "Арыс конграт" шуллык һәм җавыгыр дигән тагын ике кабиләгә бүленгән, алары исә тагын берничә нәселләрдән тора. Мәсәлән, шуллык кабиләсе ошамайлы, колдалы, костамгалы, балгалы, кендекле, карамуен, кыят, мунтән дип аталган сигез нәселне берләштерә. Шулай итеп, каркалпаклар этник яктан бик чуар. Шуңа да карамастан, каркалпакларның һәр кавеме, нәсел-ыруы үзенең борынгыдан килгән гореф-гадәтләрен, яшәеш-көнкүреш шартларын, тәртипләрен әлегәчә бозмыйча саклап килә. Бу этник төрлелек һәм кавем-ыругларның исемнәре дә каракалпак этносының бик борынгы һәм катлаулы булуын күрсәтә.

Бу этносның нигезе Арал дингезе әйләнәсендә төрле чорларда яшәгән халыклардан башлана. Безнең эра башларында башта бу якларга апасиак, аугаси, массагетлар, һуннар килеп чыга, ә соңыннан (VI — IX г.г.) төркиләр килеп бу жирләрдә печенег һәм угыз халыклары формалашуда катнашалар, каракапакларның да этник яктан укмашуларында төп роль уйныйлар.

X гасырда угызлар һәм хазарлар үзара берләшеп, көнбатыш тарафларындагы печенегларны көньякка кысрыклыйлар, ә көнчыгыштагылары, Арал тирәсендә яшәгән печенглар, угызлар белән аралашып берләшәләр.

XI гасыр башында кыпчаклар бу берләшмә җирләрен яулап алалар һәм анда яшәгәннәрнең байтак өлешен чик сакчылары хезмәтенә куялар. Бу сакчыларның хәрби формалары кара төстәге каракүл куй тиресеннән тегелгән баш киеме кара калпак (кара бүрек) була һәм аларны халык телендә каракалпаклар (кара бүреклеләр) дип атый башлыйлар һәм бу атама халыкның этнонимы (исеме) булып китә.

XII йөздә каракалпакларны монголлар басып ала һәм аларның күп өлеше килмешәк монголлар белән аралашып яши. XV гасырда каракалпак җирләре Нугай ханлыгына буйсындырыла, ә XVI йөздә Бохара ханлыгына кертелә.

XVII — XVIII гасырларда каракалпаклар Хива ханнары хакимлеге астында яшиләр, 1873 елда, Хива ханлыгы Россиягә буйсындырылгач, каракалпаклар да Россия империясе кул астында калалар. Революциядән соң Урта Азия һәм Төньяк казакъстан җирләрен һәм халыкларын берләштереп Төркестан автономияле республикасы оештырыла, каркалпаклар да шушы автономиягә кертелә. 1924 — 1925 елларда Төркестан АССРда милли чикләрне билгеләү үткәрелә, яңа АССРлар төзелә (Үзбәкстан, Кыргызстан, Тажикстан, Казакъстан. Каракалпакстан исә автономияле өлкә статусы белән Казакъстанга кертелә (19. 02. 25). Моннан соң (20. 7. 1930) аны РСФСР үзенә ала, ә 1932 елда

(30.03) бу автономияле өлкә Каракалпак АССР статусы белән Үзбәкстан ССР составына кертелә. Сан ягыннан әллә ни күп булмаган халыкның тарихи юлы менә шулай бик катлаулы, сикәлтәле. Каракалпакларның дине Ислам диненең сөнниләр тармагына карый.

Каракалпак теле төрки телләрнең көнбатыш тармагындагы кыпчак-нугай төркеменә керә. Каракалпакларның 94 проценты үзләренең милли каркалпак телен туган тел дип саныйлар һәм шул телдә сөйләшәләр. Халыкның 21 проценты үзләрен рус телендә дә иркен сөйләшүче дип саный.

Лексик составы ягыннан каракалпак теленә угыз (төрекмән), карлук (үзбәк) телләре элементларының тәэсире нык сизелә. Әмма шулай да аның төп нигезендә, тамырында һәммә төрки халыкларга хас уртак лексик фонд ята.

Каракалпак телендә, инде әйтелгән географик һәм ыруг-кабилә аермаларына карап ике төп диалект яши: төньяк-көнчыгыш һәм көньяк-көнбатыш диалектлары. Беренчесендә казакъ теле тәэсире көчле булса, икенчесендә үзбәк теле йогынтысы зур. Шулай да, барлык төрки телләрдәге шикелле, каракалпак телендә дә гарәп, фарсы элементлары шактый урын били.

## 9. Якутлар

Үз атамалары —саха. Кайбер этимологларның фикеренчә (М. Фасмер), "якут" сүзе төрекчә "яка" (якутча "саха" сүзеннән, төрки телләрдә бу сүз чик, ахыргы урын мәгънәсендә кулланылган, хәзер дә кайбер очракларда кулланыла ("Хажи әҗәл якасында тора", Т. Гыйззәт). Соңгы "ут" ижеге монгол, бурят телендә күплек кушымтасы. Димәк, якут "яка" һәм "ут"тан ясалган һәм "якалылар", ягъни читтә, кырыйда яшәүчеләр булырга тиеш.

Элеккеге СССРда яшәүче якутларның гомуми саны (1989 елгы исәпкә алу буенча) 382 мең чамасы, шуларның төп өлеше (300 меңе) Якутия-Сахада, калганнары аерым диаспоралар булып Красноярск крента, Магадан, Сахалин, Амур өлкәләрендә яши.

Этногенез ягыннан якутлар Байкалның көньягында яшәгән төрки халыкларның бу якларга күчеп килеп, җирле эвен, эвенка, юкагар кабиләләренең төрекләр тарафыннан йотылуы (ассимиляцияләнүе) нәтиҗәсендә формалашкан дип санала. Якутлар Лена, Амга елгалары арасында, Вилюй, Олекма буйларында елына ике мәртәбә — җәйдә һәм кышта күченеп, терлекчелек (ат, болан асрау) белән шөгыльләнеп яши. Россия империясе Себерне һәм Ерак Көнчыгышны яулау вакытында якутлар җире Россиягә кушыла (1630). Җирле халык патша чиновниклары, купецлар, хәрби чиннар тарафыннан рәхимсез эксплуатацияләнә, аларга натуралата (тире, мех, болан мөгезе, киптерелгән балык) ясак салына.

Руслар килгәнче якутлар дин ягыннан шаманлыкта булалар (шаманлык — шөлдерле барабан, кыңгыраулар кагу, бию, сикерену, калтырану һәм башка ритуаллар аша изге рухлар белән элемтәгә кереп сөйләшү). Рус чиркәве миссионерлары аларны православие диненә "күчерәләр", әмма шаманлык якутларның бер өлешендә хәзергәчә сакланып килә.

1805 елда Иркутск губернаторына буйсындырылган Якут өлкәсе төзелә һәм шуннан башлап ул патшаның төп сөрген җире итеп билгеләнә. Бу җирләргә күбесенчә сәяси тоткыннар (декабристлар, народниклар, марксистлар, революционерлар һәм башкалар) сөрелә. Якутларны "уятуда" алар шактый зур эш башкаралар — агарту эшләрен башлап җибәрәләр, укытуны юлга салалар, мәктәпләр оештыралар. Соңгы вакытта анда сөргендә яткан Чернышевский, Худяков, Короленко, Бабушкин, Ярославский, Свердлов, Петровский кебек танылган шәхесләр якутлар арасында мәгърифәтчелек эшен башкаралар.

Революциядән соң Якутия акгвардиячеләр кул астында яши, алар куылгач, анда совет власте урнаштырыла (1919 ел, 24 апрель), 1922 елда бу өлкә Якутия АССР дип игълан ителә, 1992 елдан Саха (Якутия) дип атала. Якут теле төрки телләрнең уйгур төркеменә керә, әмма аның лексик нигезендә төрки тел ятса да (эр — ир кеше, кыыс — кыз, уол — ул, бала, басбаш һәм башкалар), ул төрки телләр гаиләсендә үзенчәрәк урында тора. Башка төрки телләр белән чагыштырганда ул (чуваш теле шикеллерәк) үзенең лексик, фонетик һәм грамматик төзелеше белән сизелерлек аерыла. Мәсәлән, без, татарлар, алар белән тәрҗемәчесез аңлаша алмыйбыз. Лексик яктан якут телендә эвенка, монгол, рус телләреннән кергән алынмалар зур урын били.

Якут теле ике диалектка бүленгән. Алар бер-берсеннән фонетик яктан гына аерыла: "о"лаштыру (хотун) һәм "а"лаштыру (хатын).

## 10. Кумыклар

Дагъстанда 30 дан артык милләт халыклары яши, шулардан сан ягыннан кумыклар икенче урында торалар. 1989 елгы халык санын хисапка алу буенча аларның гомуми саны 282 мең чамасы тәшкил итә. Дагъстан "Тау иле" дигән сүз, әмма аның көнбатыш тарафында тигезлекләр. Әнә шул бик киң тигезлектә —Хәсәуйорт, Бабайорт, Кызылйорт, Буйнак, Кайтак районнарында кумык халкы яши. Күрше Ичкерия, Ингушетия, Төньяк Осетиядә дә кумык авыллары бар.

Үз атамалары — къумукъ. Бу этнонимның этимологиясе турында берничә фараз бар, шуларның берсе — къом сүзенә бәйле: къомлы жирләрдә, къомлыкта яшәүче халык, къумыкъ —"къомлыкның" фонетик үзгәреше. Шуңа күрә Дагъстандагы башка күрше халыклар үз телләрендә "къомлыклы далада яшәүчеләр" мәгънәсен белдергән сүзләр белән атап йөртәләр, мәсәлән, дәрганнар аларны "дәркалантлар" дип, лаклар — "арниссалар", аварлар "теләругъиллар" дип атыйлар.

Кумыклар әлеге жирләрдә этник ыруг булып яңа эраның беренче гасыр урталарында ук укмаша башлыйлар. Шулай да аларның этнос булып формалашуында бу жирләргә килеп житкән төрки телле халыклар — угызлар, кыпчаклар, болгарлар зур роль уйный: алар аборигеннар белән аралашалар, жирле халык аларның телен кабул итә, әмма борынгыдан килгән гореф-гадәтләренә сизелерлек йогынты ясый алмыйлар.

XIX йөзнең икенче яртысына кадәр кумыклар жирле феодаллар — бәкләр, чанкалар хакимлеге астында крепостнойлыкта яшиләр: төп кәсепләре игенчелек була. Игенчелектә алар "къәшәр" дип аталган коллектив булып, күмәкләшеп эшли, чәчүдә, утауда, уракта, сугуда бер-берсенә булышалар. Къәшәрнең безнең өмәдән аермасы шул: анда кардәш гаиләләр һәм күршеләр жигү маллары һәм эш кораллары, үз ризыклары белән катнаша. Эш вакытында һәм эш тәмамланганнан соң ашату-эчертү, сыйлау булмый.

Кавказ сугышыннан соң (1865) Дагъстан белән бергә кумык жирләре дә Россиягә кушыла. Шуннан соң аларның этнос буларак тормышы-язмышы Дагъстан белән аерылгысыз була. Алар бүген дә (1921 елдан башлап) РСФСР, РФ составына кергән Дагъстан Автономияле Республикасында яшиләр. Шунысын да әйтергә кирәк, 1944 елда Сталин әмере белән Кавказдагы үз жирләреннән сөрелгән 19 "вак" милләтләрдән, шулардан төрки-мөселманнардан депортацияләнмәгән бердәнбер милләт —кумыклар. Ул чакта партиянең Дагъстан өлкә комитеты беренче секретаре Даниялов Сталинның һәм Бериянең якын танышы-дусты була һәм ул Дагъстан халыкларын инде боерык буенча тәгаенләнгән, әзерләнгән депортациядән коткарып кала.

Кумыкларның йортлары, кагыйдә буларак, киләчәктә балаларын да шунда калдыруны исәпкә алып салына. Бирәдә бер генә катлы өйләр юк диярлек. Ирләрнең милли киемнәре озын күлмәк һәм балагы аска тарая барган ыштан, аяк киемнәре чүәк, күн ката. Күн итек бәйрәмнәрдә һәм кунакка йөргәндә генә киелә. Милли ашлары ханкал — квадрат формасында юка итеп кабартылган камыр өстенә вак итеп туралган ит калжалары куела, ит пешерелгән шулпа касәләрдә аерым бирелә.

Кумыклар, безнең шикелле, Ислам диненең сөнниләр тармагын тоталар, аларның тормышында (гомумән, Кавказ халыкларындагыдай) жирле шәригать — адат-хәдисләрдә дә язылмаган кануннар зур роль уйнап килә (мәсәлән, кан үче алу).

Дагъстандагы халыклар-милләтләр 34 телдә сөйләшә. Алар барысы да дүрт төп төркемгә бүленгән иберий-кавказ гаиләсендәге телләр. Кумыклар — төрки телләрнең кыпчак төркеменә карашлы телдә сөйләшүчеләрдән бердәнбер халык. Аларның 97 проценты бүген дә үз ана телләрендә сөйләшә, калганнар авар телен якынрак күрәләр, 27 проценты рус телен яхшы белә. Кумык теле югарыда күрсәтелгән географик төбәкләргә карап, өч төп диалектка бүленгән: хәсәуйорт, буйнак, кайтак диалектлары. Буйнак, хәсәуйорт диалектлары кумык әдәби теленең нигезе хисаплана. Кайтак диалектына авар, лак телләренең тәэсире көчле һәм ул лексик яктан әдәби телдән шактый аерыла. Мәсәлән, әдәби телдә сыер — инек, явлук (яулык) — къана, чай — өзән (елга), жюжек (чебеш) —жикъ.

## 11. Кырым татарлары

Кырым ярымутравында һәм аннан төньяктарак борын заманнарда тавр, скиф кабиләләре яшәгән (шуннан "Таврия", "Таврида" атамалары сакланып кала). Алтын Урда дәүләте төзелгәнче үк, монгол-татарлар биләгән бу жирләрдән жиде ыруг аерылып чыга (1237 ел) һәм алар "Кырым йорты" дип аталган зур гына Олыс төзиләр.

Алтын Урда таркалып (XV йөз), төрле ханлыкларга бүленеп, ханлыкларына карап үзләрен Казан, Әстерхан, Касыйм, Себер татарлары дип атый башлагач, Кырым ханлыгындагы төрки халык та Кырым татарлары дип атала башлый һәм үз атамалары этноним булып китә. Урда ханы Туктамышның оныгы Хуҗа Дәүләтгәрәй "Кырым йорты"ның тулы мөстәкыйльлегенә ирешә, ләкин бу мөстәкыйльлек озакка бармый: 1425 елда Кырым ханлыгы солтан Төркиясе кул астына эләгә һәм бу вассаллык бик озакка — 300 елга сузыла. Өч гасыр дәвамындагы бу бәйлелек кырым татар халкының икътисадына, сәясәтенә, бигрәк тә теленә, мәдәниятенә, сәнгатенә, гореф-гадәтенә һәм, гомумән, бөтен яшәешенә сизелерлек йогынты ясый.

Географик һәм табигать шартларына карап, Кырым халкы өч субэтник төркемгә бүленгән була. **1.** Төньякта, далалы җирләрдә яшәүче "дала татарлары" (аларны башка этник төркемнәр "нугайлар" дип атыйлар); **2.** Тау ягы татарлары; **3.** Яр буе татарлары. Болары үзләре тагын "сульяк", "уньяк", "көньяк" яр буе татарлары дигән төркемнәргә бүленә. Менә шушы табигать, көнкүреш, яшәеш шартларына бәйле бу төркемнәрнең телләрендә, гореф-гадәтләрендә беркадәр аерма, үзенчәлекләр яши. Диңгез аркылы төрекләр белән тыгыз элемтәдә булган яр буе татарларында сәүдә, һөнәрчелек, кәсепчелек хөкем сөрсә, дала татарлары игенчелек белән шөгыльләнә, ә инде тау татарларының төп кәсебе куйчылык, башка мал асрау була.

Россия белән алты елга сузылган (1768 — 1874) сугыш нәтиҗәсендә Төрек солтанлыгы җиңелә, Кучук-Кайнарчэй солых шарты буенча Кырым төрек вассаллыгыннан чыга. Әмма бу "бәйсезлек" Кырым ханлыгына тынычлык китерми: ике бертуган —руслар яклы Шаһингәрәй белән төрекләр яклы Дәүләтгәрәй арасында ызгыш-талаш китә. Бу форсаттан файдаланып, Россия империясенең Суворов командалыгындагы гаскәре Кырымга басып керә, Дәүләтгәрәй хан тәхеттән төшерелә, тәхеткә руслар ярдәмендә Шаһингәрәй утыра. Ул Төркиядән Кырым утравына килеп төпләнгән госманлыларны кире куып җибәрә.

1782 елда Әби патша Кырым ханлыгын рус империясенә кушып ала һәм аны "Таврия вилаяте" (Таврическая область) дип атап, Новороссийск губернасына кертә. Екатерина II үзенең 1784 ел, 2 февраль фәрманы белән Таврия вилаятен Новороссийск губернасы составыннан чыгара һәм аны аерым губерна — Таврия губернасы (Таврическая губерна) дип игълан итә. Бу губерна шушы исем һәм шул ук административ территория хәлендә революциягә кадәр яши.

1918 елның гыйнварында Кырымда Совет власте урнаштырыла һәм шул елның 21 мартында РСФСР составына кертелгән Таврида Совет Социалистик Республикасы игълан ителә.

1918 елның май аеннан 1920 елның ноябренәчә Кырым тоташ ут эчендә. Кырым халкы башта немец, аннан соң Антанта оккупацияләрен, акгвардияче Деникин, Колчак, Врангель гаскәрләренең, гомумән, гражданнар сугышының барлык афәтләрен башыннан кичерә.

Кырым Врангельдән азат ителгәч, башта анда ревком идарә итә, 1921 елның 18 октябрендә РСФСР составында Кырым Автономияле Совет Социалистик Республикасы оештырыла.

1941 елның октябреннән 1944 елның 10 маена кадәр — ике ел ярым буенча, Кырым немец-фашистлар оккупациясендә калып, халкы үтә авыр көннәр кичерә, оккупантларга каршы көрәш өчен егермедән артык партизан отрядлары оештыра, күп корбаннар бирә, меңнәрчә яшьләр Германия коллыгына озатыла. Ниһаять, 1944 елның 10 маенда Кырым немец-фашистлардан азат ителә. Күпме җәбер-җәфалардан соң иркен сулап, яңадан тормыш башлап җибәрәбез дип торганда, һушка килеп нәкъ бер атна яшәгәч, 18 май таңында Сталин әмере белән берничә сәгать эчендә берсен дә калдырмый — күкрәк сабыйларыннан башлап карт-корысын, урында яткан хасталарын, сугыштан кайткан инвалидларын, геройларын — бөтен бер милләтне, янәсе, оккупантларга ярдәм иткәннәр дип, Үзбәкстан, Урал-Идел якларына мәңгелек сөргенгә озаталар.

Кырым АССР буларак яшәүдән туктый, ә Хрущевның "юмартлыгы" белән Кырым Украина ССРга бүләк ителеп, область статусы белән аның составына кертелә.

Аларга үз йортларына — Кырымга кайту хокукы, сөргендә 45 ел чамасы азап чиккәннән соң, фәкать 1989 елда гына рөхсәт ителә. Аларның җирләрендә, йортларында төпләнеп алган килмешәкләр, билгеле, аларны елмаеп, кочак җәеп каршы алмый. 1989 елдан башлап бу көнгәчә туган җирләренә 260 мең кырым татары кайтты, алар төпләнү, тормыш башлап җибәрү, үз телләрен, мәдәниятләрен торгызу өчен бик авыр шартларда эш алып баралар. Кырым татарлары башка "вак милләтләр" белән бергә фәкать 1991 елның 18 октябрендә генә тулысынча реаблитацияләнәләр.

Кырым татар теле төрки телләрнең кыпчак төркеменә керә һәм өч төп диалектка бүленә: төньяк (дала), урта һәм көньяк диалектлары. Төньяк диалектында

Евпатория, Феодосия, Керчь якларында яшәүче "нугайлар"дип йөртелүче татарлар сөйләшә, лексик һәм фонетик яктан аларның теле безнең татар теленә бик якын; Байдардан Феодосиягә кадәр диңгез буйларында яшәүче татарларның көньяк диалектында исә төрек теле йогынтысы зур, бигрәк тә фонетик яктан. Урта диалект әлеге ике диалект арасындагы территориядә яшәүчеләргә карый һәм шул ике диалект аралашмасыннан тора һәм кырым татар әдәби теленең нигезе санала.

## 12. Уйгурлар

Уйгурларның төп өлеше үзләренең борынгы жирендә, Көньяк Кытайның Синьцзян Уйгур Автономияле районында яши (7 млн.) Элекке СССРның Казакъстан, Кыргызстан, Үзбәкстан, Төрекмәнстан ССР территорияләрендә яшәүче уйгурларның саны 1989 елгы хисап буенча 262643 кеше.

"Уйгур" дигән этноним беренче мәртәбә Орхон кабер ташларындагы язуларда ук очрый (VIII гасыр). Ләкин бу исем төрле тарихи сәбәпләр аркасында югала бара һәм борынгы уйгурлар үзләре яшәгән аерым төбәкләргә карап төрлечә атала башлыйлар: Кашгар җирләрендәгеләр кашкалык, Аксу елгасы буендагылар — аксулук, Турфан уйсулыгында яшәүчеләр —турпанлык, Яркәнд үзәнендәгеләр — яркәнлек исемендә йөртеләләр. Күршеләре кытайлар аларны үзләренчә, хуәймин (мөселманнар), яки хуәйчаңтау (чалмалылар) дип атыйлар, руслар исә колонизацияләнгән Төркестан краенда яшәүче уйгурларны "Туркенстанские татары" дип атап йөрткәннәр. 1921 елда гына Алматыда уздырылган төрки халыклар съездында танылган тюрколог С. Е. Малов тәкъдиме белән аларга яңадан рәсми рәвештә "уйгур" исеме (этнонимы) кайтарыла.

Уйгурлар халык буларак Көньяк Кытайның хәзерге Синьцзян провинциясендә укмаша башлыйлар. Безнең эрага кадәр үк бу үзәнлектә иран (һинд-европа) телендә сөйләшүче тохар, сакс, согъди кабиләләре яшәп килгән. Яңа эраның VIII гасырыннан башлап бирегә күпчелеге карлуклардан торган төркиләр килеп керә, бераздан алар артыннан Монголиядә, Байкал (Байкүл), Селенга, Тола, Удә елгалары буйларында яшәгән уйгурлар күчеп киләләр һәм җирле халыкларны төркиләштерәләр, төрки тел гомумтелгә әверелә.

745 елда Муен-Чурәм хан хакимлегендә Уйгур каганаты барлыкка килә һәм бу җирләрдәге төрле кабилә-ыруглар уйгурлар эгидасы астында берләшәләр. Бу чак уйгурлар һәм башка кабиләләр будда динендә булалар, әмма алар караханилар дәүләте кул астына төшкәч (X — XI) Ислам диненә күчәләр. Караханилар дәүләте җимерелгәч (XII), уйгурларның этник яктан формалашуы өчен шартлар туа, бөтен территориядә бер генә дин — Ислам дине урнашуы белән бу процесс көчәя барса да, татар-монголларның басып керүе белән ул тукталып кала, этник төрки, иран төркемнәргә таркалу башланып китә. Шулай итеп, уйгурларның этногенезында төркиләр белән беррәттән иран, монгол элементлары да катнаша. Бу аралашу аларның тышкы кыяфәтләрендә дә сизелерлек чагыла: мәсәлән, көньяктагы уйгурлар антропологик яктан ак, сары расага тартым.

XIX гасырда Синьцзянда уйгурлар белән кытайлар арасында ызгыш, сугышбәрелешләр башланып китә. Кытайлар золымына каршы уйгурлар кораллы көрәшкә күтәрелә. Бу восстание 13 елга сузыла (1864 — 1877) һәм соңыннан Кытай гаскәрләре тарафыннан канга батырыла, уйгурларның байтак өлеше Урта Азиягә (Төньяк Төркестан краена) качалар.

1950 еллар ахырында, 1960 еллар башында совет-кытай (Хрущев-Мао) мөнәсәбәтләре кискенләшкәндә һәм "культура революциясе" котырынган чорда Кытайда уйгурларга карата апартеид чаралары көчәя һәм аларның шактый өлеше тагын Урта Азиягә — Үзбәкстан, Казакъстанга күченергә мәҗбүр була.

Уйгур (яңауйгур) теле төрки телләрнең көньяк-көнбатыш гаиләсенең карлук-чыгатай төркеменә керә.

Кайсы халык арасында яшәүләренә карап, уйгурларның теле дә шул халык теленнән алынмалар хисабына байый, үзгәрә, лексик яктан шуларга якыная бара. Мәсәлән, Синьцзян уйгурлары телендә кытайча сүзләр урын ала бара: жоза —өстәл, янио — бәрәңге, денза — язу, хат, ямул — бүлмә, ә Урта Азия, Казакъстанда яшәүчеләрнең телендә үзбәк, казакъ лексикасы шактый урын били.

Уйгур телендә, географик бүленешләргә карап, өч диалект бар: төньяк-көнбатыш (яки үзәк) диалект. Аңа турфан, аксу, кашгар, или, яркәнд һ. б. — барлыгы 10 сөйләм керә. Көнчыгыш (яки лобнор) һәм көньяк (яки хотан) диалектлары. Әдәби телнең орфоэпик нормасы итеп "или" сөйләше кабул ителгән.

*Дәвамы киләсе санда*

*Әдәбият тарихына*

# АЛТЫН УРДА ӘДӘБИЯТЫ

## Кисекбаш

"Кисекбаш" — элек-электән асылда татарлар арасында гына киң таралыш алган һәм яратып укылган әсәрләрнең берсе. Танылган мәгърифәтче Ш. Мәрҗани үзенең бер хезмәтендә аның төрки халыклар яшәгән башка төбәкләрдә очрамавын билгели.

Күләме йөз утыз дүрт бәеттән гыйбарәт булган әлеге әсәр беренче тапкыр 1846 елда Казанда университет типографиясендә нәшер ителә. Аннан соң ул төрле тиражлар белән күп тапкырлар башка матбагаларда бастырыла.

"Кисекбаш"ның кайчан һәм кайда язылганлыгы тәгаен генә билгеле түгел. Бу хакта текстның үзендә дә мәгълүмат китерелми. Ш. Мәрҗани аны Болгар чорыннан калган язма ядкярләрнең берсе итеп күрсәткән. Әмма соңгырак тикшеренүләрдә әсәрнең XIҮ йөздә барлыкка килүе раслана. Әдәбият галиме Г. Т. Таһирҗанов авторның үз әсәрен "Җөмҗөмә солтан"нан рухланып язганлыгын белдерә.

Шулай ук поэманың кем тарафыннан язылуы турындагы мәсьәлә дә ачык кала килә. Текстның әүвәлге бәетләрендәге "Башла Гали" дигән сүз тезмәсе кайбер тикшеренүчеләр тарафыннан шагыйрьнең үз-үзенә эндәшүе булып кабул ителгән. Хәтта әдәбиятчы Г. Рәхим әсәр "Кыйссаи Йосыф" авторының каләме белән язылмады микән дигән фараз белдерә.

Ш. Мәрҗани әлеге сүз тезмәсен "Башлыйк әле, башларга кирәк" мәгънәсендә укыган.

Төрек галиме В. М. Кожатөрек үзенең карамагында булган бердәнбер нөсхәнең текстында күрсәтелгән Кирдәрче Гали дигән исемгә нигезләнеп, поэманы шул кешегә нисбәтли. Мондый караш төрек әдәбиятына багышланган башка хезмәтләрдә дә чагылыш тапкан. Әмма профессор Г. Т. Таһирҗанов әлеге кешенең Төркиягә барып ирешкән "Кисекбаш" әсәрен төрек теленә тәрҗемә итүче генә булганлыгын раслый.

Ш. Ш. Абилов әлеге поэманы шул исемдәге фарсы чыганагыннан иҗади тәрҗемә булуы турында фикер белдерә. Әмма бу мәсьәлә киләчәктә ныклап өйрәнүне таләп итә, әлбәттә.

Төрле елларда үткәрелгән археографик экспедицияләрдә "Кисекбаш" поэмасының шактый гына күчермәләре табылган. Хәзерге вакытта алар нигездә Татарстан Фәннәр академиясе Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институты архивында, Казан дәүләт университеты Н. И. Лобачевский исемендәге фәнни китапханәнең сирәк һәм кульязма китаплар бүлегендә, Татарстан Милли китапханәсенең кульязмалар һәм сирәк китаплар бүлегендә, Россия Фәннәр академиясе Көнчыгышны өйрәнү институтының Санкт-Петербург бүлеге фондында, Мәскәүдәге борынгы актларның Үзәк архивында саклананалар. Шулай ук әсәрнең кайбер нөсхәләре Әзербәйҗан Фәннәр академиясенең кульязмалар фондында бар.

1963 елда дөнья күргән "Борынгы татар әдәбияты" дигән китапта әсәрне өйрәнүгә махсус урын бирелмәгән. Дөрес, аның турында бер-ике тапкыр әйтеп үтелә. Ә алты томлык татар әдәбияты тарихының урта гасырлар дәвере турындагы беренче китабында "Кисекбаш"ка күләмле аерым мәкалә багышланган. Әсәр кыскартылып "Татар поэзиясе антологиясе"ндә дә бастырылды.

"Кисекбаш" поэмасының теле, стиле һәм шигырь төзелеше мәсьәләләре Ә. Н. Нәҗип, Ә. Р. Тенишев, Х. Р. Курбатов кебек галимнәр тарафыннан өйрәнелде.

Я. С. Әхмәтгалиева әсәрне гомумфилологик планда тикшергән. Китап

булып дөнья күргән аның әлеге монографик хезмәтендә поэманың гарәп хәрефләрендә җыйнама тексты, транскрипциясе белән сүзгә-сүз тәрҗемәсе һәм сүзлеге урнаштырылган. Шулай ук тюрколог С. Н. Иванов башкаруында "Кисекбаш"ның урысча тәрҗемәсе дә бирелгән.

Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институтының өлкән гыйльми хезмәткәре Н. Ф. Исмәгыйлев "Кисекбаш"ны хәзерге татар теленә күчереп, кереш һәм аңлатмалар белән вакытлы матбугат битләрендә бастырды.

"Кисекбаш" әсәренең сюжеты татар әдәбияты һәм сәнгате өчен үз вакытында иҗатка рухландыру чыганагына әверелә. Башлап аңа Г. Тукай мөрәҗәгать итә. 1908 елда "Печән базары, яхуд Яңа Кисекбаш" исемле поэмасын барлыкка китерә. Әсәр шул ук елның 22 октябрендә Казанда И. Н. Харитонов матбагасында, басылу вакыты күрсәтелмичә, нәшер ителә. Әдәбият гыйлемендә еш кына аны пародия итеп карау гадәткә кергән. Әмма чынлыкта исә ул нәзыйрә. Бу турыда беренчеләрдән булып Ф. Әмирхан язып чыга. Аннан соңгы тикшеренүчеләр, аерым алганда галимә Р. К. Ганиева да шул ук фикерне куәтли. Ә әдәбиятчы Н. Г. Ханзафаров әсәрне нәзыйрә рәвешендә язылган пародия дип билгеләүне тәкъдим итә.



*"Кисекбаш" поэмасыннан өзек*

Г. Тукай 1908 елда янә "Кисекбаш"ка гыйлавә" дигән шигырь дә иҗат итә. Ул аны "Әл-Ислах" гәзитәсендә бастырып та чыгара. Гәрчә азакта "Ахыры бар" дип куелса да, аның дәвамы бүтән очрамый.

1918 елда Г. Камал "Өр-яңа "Кисекбаш" китабы" дигән зур булмаган шигырен яза һәм аны "Әүлия" һәм компаниясенең" тәхәллүсе белән "Эш" гәзитәсенең 19 сентябрь санында бастырып чыгара.

Г. Тукайның мәгълүм шигыре үз чиратында аңардан соңгы буын шагыйрьләргә чорның социаль-иҗтимагый тормышына карата сатирик әсәрләр иҗат итәргә этәргеч була. Мәсәлән, Н. Баянның "Караәхмәт", Ш. Мөдәрриснең "Янки базары яхут яңадан-яңа кисек баш", Ә. Исхакның татар теле мәсьәләсенә багышланган "Мещан базары яхут киселгән тел" пародик поэмалары шулар җөмләсеннән.

1958 елда әдип Ә. Фәйзи белән композитор Р. Гобәйдуллин "Кисекбаш" балетын иҗат итәләр.

Язучылар Ә. Камал тарафыннан балалар сәхнәсе өчен "Кисекбаш" дигән өч пәрдәлек сатирик комедия язылган. Әлеге әсәр илленче-алтмышынчы елларда Казан дәүләт курчак театрында да уйнала.

Әдәби ядкяр буларак, "Кисекбаш" поэмасы урта мәктәп уку-укыту программаларына да кертелде.

## Нәһҗел-фәрадис.

XIV йөзнең икенче яртысында, ягъни 1357-58 елда Идел буе әдибе Мәхмүд бине Гали әл-Болгари әс-Сараи тарафыннан "Нәһҗел-фәрадис" ("Оҗмахларның ачык юлы") дигән дини-дидактик характерда булган күләмле чәчмә әсәр язылган.

Әлеге әдәби ядкяр турында зур булган белешмә иң әүвәл татар мәгърифәтчесе К. Насыйриның "Ләһҗәи татари" исемле аңлатмалы сүзлегенең кереш өлешендә китерелә. Хосусан, ул аны борынгы уйгырчадан чыгътай теленә башкарылган тәрҗемә итеп кенә карый. Аңлашылганча, галимнең карамагында "Нәһҗел-

фәрадис"нең ниндидер бер күчермәсе булган, әмма ул сакланып калмаган.

Академик А. Н. Самойлович билгеләгәнчә, "Нәһҗел-фәрадис"ны өйрәнә башлау Ш. Мәржани исеме белән бәйле. Ул үзенең "Мостафадел-әхбар фи әхвали Казан вә Болгар" дип аталган мәгълүм хезмәтендә ядкярнең янә бер күчермәсе турында мәгълүмат урнаштырган. Анда текстның башы һәм азагыннан унсигез юл күләмендә китерелгән өзекләрдән күренгәнчә, Ш. Мәржани милкендә булган әлеге нөсхәдә әсәрнең 1357-58 елда Мәхмүд бине Гали бине әс-Сараи әл-Кәрдәри исемле зат язганлыгы бәян ителә.

Билгеле булганча, 1877 елның август аенда Казанда IY Бөтенроссия археология съезды үткәрелү уңае белән күргәзмә оештырыла. Анда куелган 11 Шәрекъ кульязмасы һәм 43 хан ярлыклары арасында 12 сан белән "Нәһҗел-фәрадис" та урнаштырыла. Археограф С. Г. Вахидиның тирән инануынча, ул язма истәлек нәкъ Ш. Мәржанинеке була.

Әлеге нөсхә соңыннан югала һәм аның язмышы хәзер дә билгеле түгел.

Әсәрнең бер күчермәсе Париж Милли китапханәсендә саклана.

Тарихчы Ә.-З. Вәлиди 1923 елда Истанбулдагы Яңа Җамигъ мәчете китапханәсеннән "Нәһҗел-фәрадис"нең бер күчермәсен табып ала. "Фәзаил әл-могҗизат" дип исемләнгән һәм анда 879 сан белән сакланган әлеге кульязманы тикшереп, ул үзенең нәтиҗәләрен 1926 елда "Төркият мәҗмугасе" журналында бастырып чыгара. Галим ядкярнең килеп чыгышын Хәрәзем төбәгенә нисбәт итә. Тюрколог Ә. Н. Нәҗип үзенең хезмәтләрендә авторның дөрестән дә Хәрәзем якларында булу ихтималын, әмма әсәрен Идел буенда язуы турында фикер үткәрә.

Кульязма китапның беренче битендәге язулардан күренгәнчә, ул үз вакытында Мисыр әмире Әбу Сәгыйд Чакмакның (1437-1445) улы Мөхәммәд бәкнең шәхси китапханәсендә булган. Аның мәмлүкләр җирлегенә барып ирешү сәбәбен XIII-XIY йөзләрдә Идел буе белән Нил арасындагы тыгыз дипломатик мөнәсәбәтләр белән аңлатырга мөмкин. Ә инде кульязманың Төркиядә ничек пәйда булуы мәсьәләсенә килгәндә исә, Госманлы империясе тарафыннан 1517 елда Мисыр дәүләте яулап алынганнан соң, аның ганимәт сыйфатында башка әйберләр белән бергә алып кителгән булуына шик юк.

1928 елда Ялта төбәкне өйрәнү музее тарафыннан оештырылган археографик экспедиция Бакчасарайда "Нәһҗел-фәрадис"нең XIY йөздә күчерелгән бер кульязмасын табып ала. Әлеге музейның гыйльми хезмәткәре Я. Кәмал аны өйрәнеп, хезмәтен 1930 елда бастырып чыгара. Аннан күренгәнчә, язма истәлекнең беренче бите юк, икенче һәм өченче битләре нык таушалган.

Академик А. Н. Самойловичның кереш сүзе белән нәшер ителгән бу китапта кульязманың тасвирламасы, аның табылу урыны, ядкярнең авторы һәм әлеге нөсхәне күчерүче турында белешмә бирелгән. Шулай ук текстның тел үзенчәлекләре тикшерелә һәм алар XIII-XIY йөздә барлыкка килгән башка төрки язма истәлекләр, аерым алганда "Котадгу белек", "Кыйссаи Йосыф", "Мәхәббәтнамә", "Хөсрәү вә Ширин" һәм башкалар белән чагыштырма планда анализлана. Азакта тексттан өзекләр, аларның урысча тәрҗемәләре, әсәрнең француз телендә кыскача эчтәлеге китерелгән һәм оригиналның биш факсимилесе урнаштырылган.

Кызганыч ки, әлеге кульязма соңыннан югала һәм аны эзләү уңышсыз тәмамлана.

С. Г. Вахиди археографик экспедиция вакытында Татарстан җирендә әсәрнең өч кульязмасын табып ала. Аларның беренчесе Мамадыш төбәгендәге Зур Теләче авылында Кәшшафетдин Габделҗәббар угълы Рәхмәтуллин исемле мөдәррискең шәхси китапханәсендә сакланган була. Ә икенчесе элеккеге Спас кантоны Ташбилге авылыннан (хәзерге Әлки районы) алып кайтыла.

Алар 1934 елда галимнең китапханәсеннән Россия Фәннәр академиясе Көнчыгышны өйрәнү институтының Санкт-Петербург бүлегенә күчерелә. Анда янә "Нәһҗел-фәрадис"нең ике бүлеген тәшкил иткән бер күчермәсе бар. Ул шул ук елда СССР Фәннәр академиясе тарафыннан оештырылган археографик экспедиция вакытында катнашкан С. Әлимов Әстерханнан алып кайткан бер җыентык арасында ($62^{а}$-$73^{б}$. бб.).

Өченче кульязма Спас кантонындагы Иске Сәлмән авылы мәчетендә табыла. Тулы булмаган әлеге күчермә хәзерге вакытта Казан дәүләт университеты Н. И.

Лобачевский исемендәге фәнни китапханәнең кульязмалар һәм сирәк китаплар бүлегендә саклана.

Танылган археограф тапкан кульязмалар аның тарафыннан өйрәнелеп, матбугат битләрендә бәян ителәчәге турында "Безнең юл" журналының 1929 елгы 5 санында хәбәр ителсә дә, тикшеренү нәтиҗәләре басылмыйча кала.

Күчерелү вакыты XYII йөзгә нисбәт ителгән бер нөсхә профессор И. Ф. Готвальд карамагында булган. Галимнең вафатыннан соң аның варислары кульязманы Казан дәүләт университетының мәгълүм китапханәсенә тапшыралар.

Әлеге китапханә фондында әсәрнең янә бер күчермәсе бар. Ул Татарстанның Баулы районында табылган һәм 1930 елда журналист И. Рәмиевнең шәхси тупланмасыннан кергән.

Тарихчы М. Г. Госманов җитәкчелегендәге археографик экспедиция 1968 елда Татарстанның Буа районындагы Әхмәт авылыннан "Нәһҗел-фәрадис"нең бер күчермәсен алып кайталар. Шул ук елда Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм тарих институтының гыйльми хезмәткәре М. Йосыпов Ульяновски өлкәсендә Иске Кулаткы районындагы Югары Тирәшкә авылында әсәрнең бер күчермәсенә юлыга. Мелла Рәхмәтулла исемле кеше тарафыннан 1723 елда күчерелгән җыентык арасында булган әлеге нөсхә хәзерге вакытта күрсәтелгән институтның архивында саклана.

Әлеге яңа табылган күчермәләр турында әдәбиятчы Ш. Ш. Абилов 1973 елның 5-7 июнендә Ленинградта үткәрелгән YI тюркология конференциясенең төрки халыклар тарихы һәм филологиясе буенча утырышта чыгыш ясый. Соңрак ул аларга махсус мәкаләләр дә багышлый.

Төрек телчесе Б. Кываметтин "Нәһҗел-фәрадис" лексикасын өйрәнүгә үз вакытында күләмле генә бер мәкалә язып чыга. Ул анда тексттагы борынгы сүзләргә бай аңлатмалар һәм шәрехләр бирә.

Мажар галиме Я. Экман 1956 елда кульязманың фотокүчермәсен, ә 1986 елда латин хәрефләрендә әсәрнең текстын нәшер итә. Ул шулай ук Париж Милли китапханәсендә саклана торган янә бер күчермәсе турында да матбугатта язып чыга.

Татар әдәбиятчысы Б. А. Яфаров әсәрне монографик планда тикшереп, хезмәтен кандидатлык диссертациясе итеп яклый. Дөрес, анда ядкяр Болгар чорына нисбәтән карала.

1963 елда нәшер ителгән "Борынгы татар әдәбияты"нда "Нәһҗел-фәрадис" турында шул вакытта билгеле булган белешмә бирелә һәм әсәрдән унсигез хикәя белән Казан дәүләт педагогия институтында саклана торган нөсхәдән бер фотокүчермә урнаштырылган. Ә күптомлы "Татар әдәбияты тарихы"ның беренче китабында исә ядкяр турында тагын да киңрәк, тәфсиллерәк мәгълүмат китерелә.

Язма истәлекнең тел үзенчәлекләрен өйрәнүгә төрек галиме Г. Ф. Караманлы углы сизелерлек өлеш кертте. Әлеге проблема буенча Казан дәүләт университеты укытучысы Ф. Ш. Нуриева тарафыннан да билгеле бер дәрәҗәдә эш башкарылды һәм, мәгълүм булганча, ул әсәрне өйрәнүне дәвам иттерә.

Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать белеме институтының өлкән гыйльми хезмәткәре, борынгы әдәбият белгече Н. Ф. Исмәгыйлев "Нәһҗел-фәрадис" текстының берникадәр өлешен хәзерге татар теленә якынайтып, аны бай кереш һәм аңлатмалар белән тулыландырып, матбугатта бастырып чыгарды. Аның шулай ук әсәрдәге "Йосыф вә Зөләйха" сюжетен анализлауга багышланган мәкаләсе дә кызыклы.

Соңгы елларда әсәрне өйрәнү урта мәктәпләрнең уку-укыту программасына да кертелде.

Кызганыч ки, татар әдәбияты һәм теле гыйлемендә "Нәһҗел-фәрадис"ны гамәлдәге алфавит нигезендә текстологик эшен башкарып, аны нәшер итү һаман да актуаль мәсьәләләрнең берсе булып кала.

**Рәмил ИСЛАМОВ**,
филология фәннәре кандидаты

Мәгариф 80




**Fərit Şərifullin,**

ƶurnalnьꞑ baş məxərrire,
Tatarstannьꞑ atqazanƣan uqьtucьsь,
Rossijənen atqazanƣan mədəniət xezmətkəre.


# MӨƢƏLLIMNƏR MӨƢƏLLIME

Məƣərif xezmətkərlərenen avgust kiꞑəşməsendə Qazanda Minzələ pedagogiə ucilişcьsь direktorь Miꞑnegəl Miftaxova belən səjləşergə turь kilgən ide. Çitdi genə məs'ələlər turьnda beraz fiker urtaqlaşqac, syzebez tabiƣьj rəweştə "Məƣərif" ƶurnalьna kilep totaştь.

"Uqьtu-tərbiə eşendə şaqtьj təçribə tuplarƣa əlgergən keşe bularaq, ƶurnal belən, bəlki daimi tanьşьp barmasam da buladьr inde, dip ujlaƣan idem. Juq şul. Hərkən kirək ikən ul ƶurnal. Cənki pedagogiə fənendəge, uqu—uqьtu metodikasьndaƣь hər jaꞑalьq iꞑ əywəl ƶurnal bitlərendə basьlьp cьƣa, — dide ul. — Xəjer, bu dənjaƣa kyzem acьlƣannan birle əjdə hərcaq şul ƶurnalnь kyrep ystem min. Əniem uqьtucь ide. Yzem pedinstitutta uqьƣanda da ƶurnaldan ajьrьlmadьm. Xəzer də "Məƣərif"tən ajьrьla almьjm. Taƣьn şunьsь bar: anь kyrygə əniem kyz aldьna kilə. Ul Cistaj rajonьnda jəşi, min Minzələdə eşlim. Jьş kyreşep bulmьj. Ƶurnalnь min əniem təse itep tə qabul itəm. Ənkəj kebek jaqьn ul".

Rəxmət Miꞑnegəl xanьmƣa şundьj cьlь syzləre əcen.

Əje, "Məƣərif" ƶurnalь — uqьtucьlar, tərbiəcelərnen jaqьn dustь ul. Xəjer, syzne uqьtucьlarnьꞑ yzlərenə birik.

"Kiꞑəşcem, tajanьcьm, — dip jaza anьꞑ turьnda Aqsubaj gimnaziəsenen tarix uqьtucьsь Tamara Leontjeva. — "Məƣərif" ƶurnalьnьꞑ jaꞑa sanь qulƣa kery belən başta ectəlegen qarap cьƣam. Annan soꞑ hər bylege belən tanьşam. Yzemə həm iremə (ul da uqьtucь, balalarƣa ximijə fənen əjrətə) kirəkle materiallarnь bilgelim.

Ƶurnal bujьnca ajьrьm kyrsətkec təzim. Cənki barь bu ƶurnalda ƣьna, salawat kyperendəge tərle təslərdəj, uqьtu-tərbiə eşenen tərle jaqlarь urьn alƣan. Ajьrma barь şunda ƣьna: salawat kypere, jaꞑƣьrdan soꞑ çirne bizəp, ber mizgel genə kyrenep tora, ə "Məƣərif" ƶurnalь gəmer bujь beznen belən, tormьştaƣь awьrlьqlarƣa da qaramastan, bezne alƣa taba əjdəp bara".

Şunьsь qьzьq: ul yz məktəbendəge tatarca belməgən başqa uqьtucьlarƣa ajьruca əhəmijətle məqələlərne tərçemə itep birə ikən.

Ƶurnal uqucьlar belən ocraşular waqьtьnda da bez ixlas kyꞑeldən əjtelgən mondьj syzlərne jьş işetəbez.

Redaksiənen pedagog-ƶurnalistlarь, çitəkcelərə məktəplərdə jьş bulalar. Qazanƣa kurslarƣa kilgən uqьtucьlar belən də ocraşalar. Şundьj ocraşularda məƣəllimnər kyp tərle fikerlər, təqdimnər əjtələr, ƶurnalnьꞑ hər sanьnnan jьllar dəwamьnda uꞑьşlь fajdalanularь, şuꞑa kyrə alarnь cьjьp barularь turьnda səjlilər.

"Bьjьl ƶurnalnьꞑ bizəleşe də jaxşьrdь",— dilər alar. Dimək, ƶurnal uqucьlarьbьz belən kybrək aralaşьp, alarnьꞑ fikerləren iskə alьp "Məƣərif"nen totqan qьjblasьn dəresrək bilgelərgə məmkin.

1997 jьlda ƶurnal ƶurraq kyləm belən cьƣa başladь. Bьltьr, məsələn, anda

biş jɵzləp məqələ urnaştьrьlƣan. Alar arasьnda şaqtьj zur kyləmlelәre də bar. Əjtik, 10 ncь sanda fizikadan olimpiada soraularь həm çawaplarь turьndaƣь məqələ 10 bit camasь. Maşinkada tutьrьp jazьlƣan 35 bitle material digən syz ul. Ike nəşer-xisap tabaƣьna jaqьn. Fizika uqьtucьlarь annan bik nətiçəle fajdalana alacaq.

Dɵres, ƶurnal yz uqucьlarьn çəlep itərgə tieş. Şulaj bulƣanda ƣьna anьꞑ tiraƶь da saqlana, ysə bara.

Вьjьl "Məƣərif"kə 80 jəş tula.

Il ɵcen iꞑ qьjьn jьllarda da tatar zьjalьlarь təƣlim-tərbiə eşenə baƣьşlanƣan ƶurnallar cьƣarьrƣa omtьlƣannar həm şuꞑa ireşkənnər. Moꞑa soqlanmьjca mɵmkin tygel.




1918 jьl. Sintəbrdə — Qazan şəhəre, ə oktəberdə isə guberna çire doşmannan azat itelə. Şuşь jьlnьꞑ 7 nojəbrendə "Məƣərif" ƶurnalьnьꞑ berence sanь dɵnja kyrə. Anьꞑ tьşlьƣьnьꞑ ɵcence bitendə: "7 nojəbrdən başlap Qazanda, Mərkəz mɵselman Komissariatь janьndaƣь Ƣьjlmi həjət organь bulƣan "Məƣərif" isemle ƶurnal cьƣa başladь. "Məƣərif" ƶurnalь rəsmi, tərbiəwi, ədəbi, fənni byleklərdən ƣьjbarət bulьp, ajƣa ike tapqьr cьƣacaq" dielgən həm anda nindi məs'ələlər jaqtьrtьlacaƣь kyrsətelgən. Bu xaqta "Sovet məktəbe" ƶurnalьnьꞑ 1958 jьlƣь 11 nce sanьndaƣь "Tatar telendə pedagogik ƶurnal cьƣa başlauƣa 40 jьl tuldь" digən məqələdən də uqьrƣa mɵmkin. Əmma ul məqələ iseme belən hic tə kileşəse kilmi. Əgər də xalqьbьznьꞑ pedagogik ƶurnal cьƣaru ƣədəte-traditsiəse, əzerlekle zьjalьlarь bulmasa, tuƣan çireꞑne doşmannan azat itygə yk "Məƣərif" dɵnja kyrə alьr idemeni? Juq, əlbəttə. Şunьsь məƣlym: tatar telendə cьƣa başlaƣan berence gazeta-ƶurnallarda uq təƣlim-tərbiə məs'ələrenə şaqtьj kiꞑ urьn birelgən. 1908 jьlnьꞑ fevralendə Qazanda "Tərbiə" ƶurnalь nəşer itelə başlьj. Əmma dyrt kenə sanь cьƣьp qala. 1913 jьlnьꞑ 21 fevralendə (jaꞑa stil" belən — 6 martta) Qazanda kyrenekle zьjalь Şihab Əxmərov çitəkcelegendə "Məktəp" digən redagogik həm təƣlim-tərbiə ƶurnalь dɵnja kyrə. Ul G. Tukajnьꞑ "Olug jubilej mɵnəsəbəte belən xalьq ɵmidlәre" digən şigere belən acьla. Şuşь uk sanda M. Bigiev, Z. Vəlidi, G. Battal, B. Mostafa, H. Maqsudi, M. Qorbangalief, G. Ibrahimov kebek mɵxtərəm zьjalьlar qatnaşa. Ƶurnalnьꞑ başka sannarьnda G. Isxaqi, G. Gaziz, Ə. Xəlil, G. Qarief, M. Aqcurina, H. Atlasof, N. Dumawi, G. Alparof kebek ədiplər həm ƣalimnərneꞑ məqələləren kyrergə mɵmkin. 1913 jьlda "Məktəp"neꞑ — 15, 1914 jьlda 10 sanь cьƣa. Soꞑƣьsь 1914 jьlnьꞑ 17 oktəbrendə basьla. Gɵmumən, əlege ƶurnalnьꞑ 25 sanь dɵnja kyrgən, berence bɵtendɵnja suƣьşь başlanu səbəple, ul cьƣudan tuqtaƣan.

Şuꞑa iƣtibar itik: "Məktəp"neꞑ berence sanьnda yz məqələse belən aktiv qatnaşqan Galimçan Ibrahimof 1918 jьlnьꞑ nojəbrendə dɵnja kyrgən "Məƣərif" ƶurnalьn ojьştьrucь, anьꞑ berence mɵxərrire bula. Başqa avtorlar da ƶurnalƣa bik teləp jazьşalar. 1936 jьlnьꞑ oktəbrennən "Məƣərif" — "Başlanƣьc məktəp", 1938 jьldan 1990 jьlnьꞑ avgustьna qədər "Sovet məktəbe" isemendə jərsə də, ul ƶurnallarnьꞑ ruxi, tematik jaqtan bertɵrle buluь xaqьnda səjli. Alarnьꞑ həmməse də diərlek tɵrle suƣьşlar arqasьnda berqədər waqьt cьƣudan tuqtalьp torƣan. "Məƣərif" ƶurnalь 1918 jьlda Yzək Mɵselman Komissariatьnьꞑ Məƣərif bylege qarşьndaƣь Ƣьjlmi həjət organь bularaq dɵnja kyrə. Graƶdannar suƣьşьnnan soꞑ ul 1921 jьlnьꞑ aprilennən Tatarstan Məƣərif Xalьq Komissariatьnьꞑ ajlьq ƣьjlmi-pedagogik ƶurnalь sьjfatьnda cьƣarьla başlьj. Menə şuşь soꞑƣь datanь iskə alьptьr inde, 1941 jьlnьꞑ aprilendə "Məƣərif"neꞑ (bu corda — "Sovet məktəbe"neꞑ) 20 jьllьƣь bilgeləp ytelə.

Bøjek Watan sugьşь başlangac, "Sovet məktəbe" cьgudan tuqtьj. 1945 jьlnьn maj ajьnnan anьn urьnьna Tatarstan Məgərif Xalьq Komissariatь organь bulgan "Xalьq məgərife bujьnca çitəkce həm pedagogik-metodik materiallar çьjьntьgь" nəşer itelə başlьj. Əlege çьjьntьq ike ajga ber tapqьr 4000 danə tiraz belən cьgarьlgan. Anьn 1 nce sanьndagь "Redaksiədən" digən beldery ectəlegennən kyrengəncə, çьjьntьq waqьtlьca zurnalnь alьştьrьp torgan, anda pedagogik-metodik məs'ələlər, aldьngь təçribə jaqtьrtьlgan.

1946 jьlnьn 4 majьnda respublika çitəkcelege, "Sovet məktəbe"n janadan cьgara başlarga rөxsət sorap, Məskəygə mөrəçəgət itərgə bula. Nihajət, rөxsət alьna. Tatarstan ASSR Ministrlar Sovetь 1949 jьlnьn 9 sintjəbrendə Tatarstan Məgərif ministrlьgьna "Sovet məktəbe" zurnalьn ike ajga ber tapqьr 6 men danə tiraz belən biş tabaqlь itep cьgarьrga rөxsət birə. 1956 jьlnьn 1 iylennən əlege zurnal aj sajьn cьgьp kilə. ("Məgərif" zurnalь tarixьna qaragan materiallar belən "Sovet məktəbe"nen 1941 jьlgь 4 nce, 1957, 1958, 1968, 1978, 1988 nce jьlgь 11 nce, şulaj uq 1975 jьlgь 5 nce həm 1993 jьlgь 4-11 nce, 1997 jьlgь 12 nce sannarьnnan tanьşьrga bula.)

"Məgərif" zurnalьnьn cьga başlawьna 80 jьl tulgan bu kennərdə anьn tөp dirizerlarьnьn — baş mөxərrirlərenen qajberləren iskə alьp uzu da urьnlь bulьr. Əjtkənebezcə, anь ojьştьrьp çibəryce, berence mөxərrir Galimçan Ibrahimof bula. Kyrenekle zurnalist, mөselman xalьq komissarь Şəhit Əxmədief ana zur jərdəm itə. Zurnalnьn 1 nce sanьnda uq anьn da məqələse basьla.

1921 jьlnьn aprilendə "Məgərif" janadan cьgarьla başlagac, anьn mөxərrire itep — Wəli Şəfigullin, çawaplь sərkətibe itep Mөxəmmətxan Fazlullin bilgelənə. Annarь Gajas Maqsudof (1923 — 1924 jьllarda), məgərif xalьq komissarь Mөxəmmət Tahirof (1925), N. Mөxetdinof (1927), I. Gabdrəşitof (1937), G. Bakirof (1937), Ş. Başkirof (1937), M. Vəlidova (1938 —1941), Xəsən Xəjri (1949 — 1950), F. Maxiənof (1951 — 1960), F. Ibrahimof (1960 — 1977), V. Zьjatdinof (1977 — 1989) kebek pedagoglar, zurnalistlar əlege qatlaulь həm bik tə çawaplь eşne əjbət kenə başqaralar.

Əjbət kenə didem də ujga qaldьm. Aj-haj, nindi genə qьjьnlьqlar kicermədelər ikən alar?! Ul jьllarnь kyz aldьna kitersən, ixtьjarsьz şul xaqta ujlьjsьn. Şəxes kul'tь jьllarьnda ezərlekləylərgə ducar itelgənnəre də bar... Şuşь redaksiədə utьz biş jьldan artьq eşləy dəwerendə zurnalnьn 5—6 mərtəbə urьnnan-urьnga nicek "kycerelyenə" də şahit buldьm. Jana gazetalar ojьşqan sajьn in berence ciratta şuşь "Məgərif" ("Sovet məktəbe") zurnalь redaksiəse bylmələre in "təmle qalça" buldь. Əmma jərdəmceləreebez də qul quşьrьp utьrmadь. Pedagogik çəmagətcelekkə, ajьruca xəzerge akademik Mansur əfənde Xəsənofqa zur rəxmət xislərebez əle də syrelmədə həm syrelməs.

Gomumən, "Məgərif" zurnalь da corьbьz belən bergə sikəltəle jullar ytte. Əmma ul uqьtucьlarga, tərbiəcelərgə, məgərif xezmətkərlərenə, jəş buьnga hərcaq tugrьlьqlь bulьp qaldь, yz qьjblasьn jugaltmadь. Alarga mөmkin qədər pedagogik-metodik jərdəm kyrsəttе, aldьngь təçribə mənbəre buldь, uqьtu-tərbiə eşendəge janalьqlarnь, yzgəreşlərne, şulaj uq fən qazanьşlarьn, ədəbiat-səngət janalьqlarьn yz waqьtьnda jaqtьrtьp barьrga omtьldь.

Daimi avtorlarьbьz arasьnda kyrenekle jazucьlarnь da, pedagog-galimnərne də, mөxtərəm məgəllimnər həm tərbiəcelərne də, tьngьsьz metodistlarnь da kyrergə mөmkin.

... 1990 jьlnьn 30 aprilendə zurnal tarixьnda matur ber waqьjga buldь: Tatarstan Respublikasь xөkymətе anь yz qanatь astьna aldь, jəgni zurnalnь ojьştьrucьlarnьn berse buluь turьnda qarar qabul itte. Şul uq jьlnьn sintəbrennən, redaksiənen xezmət kollektivь təqdime belən, zurnal yzenen in baştagь iseme — "Məgərif" dip cьga başladь.

Tugan tel həm ədəbiatnь, tөrle fənnərne uqьtu, klasstan tьş eşlər ojьştьru məs'ələləren kyz unьnda totu belən berrəttən, "Məgərif" balalar baqcalarьnda həm gailədə sabьjlarga təglim-tərbiə biryceləгgə jərdəm kyrsəty kirəklegen də onьtmьj. Alar өcen zurnalda "Məktəpkəcə tərbiə" digən maxsus bylek bar. "Sezgə, əti-ənilər, məgəllimnər" rubrikasьnda həm başqa byleklərdə urnaştьrьla torgan məqələlərdən də alar unьşlь fajdalanalar.

Qьsqasь, "Məgərif"tən hərkem yzen qьzьqsьndьrgan soraularga çawap taba ala, dip ujlьjbьz. Tugan telebezne, ədəbiat həm tarixьbьznь, mədəniətebezne өjrənygə qьzьqsьnu nьq kecəjə bargan xəzerge şartlarda "Məgərif"ne uqucьlar sanь tagьn da arta, bu isə redaksiə xezmətkərlərenə, zurnal belən jazьşьp torucь zьjalьlarьbьzga kөc-quət, jana dərman birə.

Китап күзәтү

# ЯҢА ЮНӘЛЕШ

Ниһаять, бу юнәлештә дә боз кузгалды бугай!

Сүз рухи мирасыбызның мөһим бер тармагын тәшкил иткән рухани әдәбият истәлекләрен өйрәнә башлау хакында. Мәгълүм булганча, халкыбызның зур өлеше мең елдан артык вакыт буенча китаби диннәрнең берсен — ислам динен тотып килде һәм шушы дингә караган күпсанлы, төрле характердагы әсәрләр тудырды. Басма һәм кулъязма китап мирасыбызга объектив күз салсак, әнә шул рухи байлыгыбызның иң кимендә өчтән икесен рухани әдәбият әсәрләре тәшкил итүен күрербез.

Ләкин, кызганычка каршы, язмышыбыздагы билгеле сәбәпләр аркасында рухи байлыгыбызның шул мөһим өлешенә тиешле игътибар ителмәде. Дөресрәге дини-рухани истәлекләрне өйрәнү, аларның тарихи урыннарын дөрес билгеләү, объектив әһәмиятләрен аңлау һәм аңлату урынына, андый күренешләр бөтенләй булмаган төсле, аларны күрмәмешкә салыну, яисә, җае килгән һәм килмәгән саен, "фәнни тәнкыйть" дигән булып, аларны тупас рәвештә тибеп узу гамәлгә кереп киткән иде. Дөньяви дип исәпләнгән әдәби истәлекләрне өйрәнгән чакта да алардагы дини мотивларны читләтеп узу (сызып-кыскартып ташлау) да, яки борынгы чор әдип-шагыйрьләреннән сузып-тартып атеист "ясау" да модага әверелеп беткән иде. Хәтта шул дәрәҗәгә барып җиттек ки, динилек битлеген кигән гадәти наданлыктан ихлас иманны аермау, хорафилык белән идеализмны бутау да аннарыбызда тирән тамыр җибәреп, гамәлләребездә өстенлек алган иде.

Шуңа да игътибар итәргә кирәк: мондый гамәл белән без гасырлар буена дистәләгән миллионнарның (үз элгәрләребезнең) иманнарын, ышанычларын тулаем инкяр итү, алар ихтыярына төкереп карау юлына баскан идек. Гавәмнең — халык массаларының — теге яки бу омтылышларына аңсыз ияру никадәрле сукырлык булса, тарихи нигезле ихтыярны тулаем инкяр итү, таптап узу да шул хәтле үк мәгънәсезлек, томаналык бит. Ә менә гавәмгә сукырларча иярмәү, әмма чын иман-ихтыярның тарихи әһәмиятен, урынын аңлап гамәл итү мисалын без Шиһабетдин Мәрҗани һәм аның шәкертләре эшчәнлегендә күрәбез.

Безнең бу өлкәдәге ялгышларыбыз тиешле "җимешләрен" бирде инде. Хәзер җәмгыятебездә хөкем сөргән бозыклык, ерткычлык, юлбасарлык, эпидемия кыяфәтен алган эчкечелек, иманга хаинлык шикелле тискәре күренешләр "букетының" гөрләп чәчәк атуы да әлеге ялгышларның бер нәтиҗәсе. Атеизм дигән булып, вульгар мәҗүсилеккә күңел капкаларын киң ачуның нәтиҗәсе бу!

Дөрес, соңгы елларда дингә һәм дини иманнарга, йолаларга карата булган әлеге беръяклылыкка чик куелды. Кешеләргә, халыкларга элек туздырылган, җимертелгән гыйбадәтханәләрен яңадан аякка бастыру, яңаларын салу, дини йолаларын ирекле рәвештә башкару мөмкинлекләре туды. Дини ихтыяҗлар өчен кирәкле, зарур кулланмалар, шул җөмләдән элекке голямалардан килгән рухани хезмәтләр һәм шәригать нигезләрен аңлата, өйрәнә торган популяр әсәрләр дөнья күрә башлады. Әйтергә кирәк, аларның хәзер ирекле рәвештә таратылуы да зур казанышлардан саналырга хаклы.

Шул ук вакытта кайбер тармакларда һаман бушлык саклану да үзен нык сиздерә иде. Мәсәлән, рухани әдәбият истәлекләрен фәнни планда өйрәнүгә караган гыйльми хезмәтләрнең бөтенләй диярлек булмавы. Мондый хәлнең объектив сәбәпләре дә бар, әлбәттә. Әйтик, тиешле дәрәҗәдә махсус белемгә ия белгечләрнең җитмәве. Биредә элеккеге кайбер атеистларның "иманга кайтулары" гына мәсьәләне хәл итми. Төп хезмәтләре һәм бурычлары классикларның әсәрләреннән цитата чүпләү булганга күрә, аларның дин нигезләреннән белемсез икәнлекләре күптән мәгълүм.

Ниһаять, сүз башында әйткәнемчә, бездә бу юнәлештә дә боз кузгала башлаган икән. Мин моны күп еллардан бирле Казан университетында шәрык телләрен укытып килүче ориенталист-галим Җәмил Зәйнуллинның яңа китабын күз алдында тотып әйтәм. Хезмәт "XYIII — XX йөз башында татар рухани әдәбияты" дип атала. (Казан, "Мәгариф"

нәшрияты, 1998, 207 бит.) Китап исеме астында бирелгән өстәмә белешмәдән күренгәнчә, анда Коръән тәфсирләре, хәдисләр һәм башка төр рухани әсәрләрнең тел үзенчәлекләре вә тәрҗемә принциплары тикшерелә.

Китапның баштагы өлешендә мәсьәләнең куелышына һәм рухани мирасның төрләренә кыскача күзәтү ясала. Ягъни өйрәнеләчәк истәлекләрнең төп төрләре, жанр чикләре билгеләнә. Аннары бер-бер артлы гарәпчә, фарсыча һәм төрки-татарча төзелгән, дөресрәге безнең халык арасында киң таралган, Коръән тәфсирләренә күзәтү тәкъдим ителә. Бу материаллардан китап авторының төрле телләрдәге күпсанлы истәлекләр, аларны өйрәнүгә багышланган гыйльми хезмәтләр белән якыннан танышуы күренеп тора. Басылып чыккан истәлекләр белән бергә кульязма тәфсирләрнең дә исәпкә алынуы, минемчә, аерата әһәмияткә ия. Чөнки татар җирлегендә барлыкка килгән, әмма бары язма килеш кенә сакланып калган тәфсирләрнең барлануы һәм беркадәре бәя алуы бу өлкәдә безнең халык керткән өлешнең күләмен, сыйфатын төгәлрәк күзалларга мөмкинлек бирә. Әмма, шул язма нөсхәләр хакында сөйләгән чакта, аларның кайчан, кайда язылулары белән бергә кайчан, кайда һәм кемнәр тарафыннан табылулары хакында да төгәлрәк белешмә китерелгән булса, мәгълүмат тагын да тулырак гәүдәләнер иде. Татар мохитының хәзерге Татарстан кысалары белән чикләнмәвен кульязма тәфсирләрнең таралу географиясе дә яхшы күрсәтә. Мисал өчен, безнең археографик экспедицияләр вакытында татар җирлегендә төзелгән, күчерелгән тәфсирләр Русиянең төрле өлкәләрендә табыла иде.

Хәдисләргә — Мөхәммәд пәйгамбәр әйткән яки аңа нисбәт ителә торган сүзләргә, фикерләргә багышланган бүлекчә дә, һичшиксез, игътибарга лаек. Анда автор кызыклы гына күзәтүләр ясый. Киләчәктә, минемчә, "Хәдисләр һәм халык авыз иҗаты" дигән тема буенча да махсус хезмәтләр язылырга тиеш. Чөнки бик күп хәдисләрнең канатлы гыйбарәләргә әверелүе, кайберләренең халыкчан әйтем рәвешендә яшәүләре, тәмам мәкальләшеп китүләре дә киң таралган күренеш. Аерым мөнәҗәтләрнең фикри нигезләрен мәгълүм хәдисләр тәшкил итүе дә шик тудырмый.

Китапның икенче бүлеге татарча рухани әдәбият үрнәкләренең тел-стилен һәм тәрҗемә принципларын яктыртуга багышланган. Монда халкыбыз арасында киң таралган аерым тәфсирләрнең филологик үзенчәлекләре эзлекле анализлана. Авторның, үз туган теле татарчадан һәм төп белгечлеге булган гарәпчәдән, тыш, фарсы теленнән хәбәрдар булуы, туганлаш төрек, үзбәк, уйгыр телләрендә дә үзен иркен сизүе игътибарга лаек. Бу телләрне белү аның мәсьәләгә карашын киңәйтә, чыгарган нәтиҗәләренең әтрафлы уйланылган булуын тәэмин итә. Гомумән, элекке чор әдәби телебезнең бай һәм бер үк вакытта артык чуар лексикасын белү ягыннан Ж. Зәйнуллин нык аерылып тора. Архаик лексикабызның мәгънәләрен ул белеп, дөрес куллана. Бездә соңгы елларда андый сүзләрне белер-белмәс куллану бер чиргә әйләнде бит. Ә бу автор гарәпчә, фарсыча махсус атамаларның дөрес янгырашын булдырырга да ирешә.

Китап авторының кайбер атамаларга төгәлрәк мәгънә төсмере бирергә омтылуын бер генә мисал белән күрсәтеп узыйк. Әйтик, ул бездә моңарчы киң кулланыла торган "дини әдәбият" дигән төшенчә белән чикләнмичә, "рухани әдәбият" дигән сүз тезмәсен актив хәрәкәткә кертеп җибәрә. Бу — акланган тәкъдим. Чөнки "рухани әдәбият" ул гомумән "рухани мирас" булган, димәк. Дөньявилыкны да эченә алган гаять киң, катлаулы күренешнең бер тармагы гына. "Рухани әдәбият" төшенчәсе русча "богословская литература" дигән атамага туры килә. Ә гомуми "рухи" дигән төшенчәгә исә саф дөньяви, хәтта атеистик рухлы әйберләрнең дә керүе ихтимал. Моның шулай икәнлеген аңлар өчен "рухи дөнья", "рухи халәт" ише сүз тезмәләрен искә төшерү дә җитә.

Дөрес, гамәлдәге язуыбызның кимчелекләре кайбер текстларны транскрипцияләүдә сизелмичә калмаган. Мәсәлән бер үк өрелмәле ирен-ирен W авазы белән башлана торган War, Wir сүзләренең төрлечә язылу очраклары бар (111 бит: уардыр һәм вирмәк...). Әгәр ныграк игътибар итсәң китаптан мондый вак кимчелекләрне тагын да табып булыр иде. Ләкин күрсәтелгән хәтлесе дә җитеп торыр. Чөнки язу-имлябызның җитешсезлегендә бер Ж. Зәйнуллин гына гаепле булмаган кебек, транскрипция өлкәсендәге кыенлыкларны билгеләп үтү дә минем бурычым түгел.

Икенче бүлек ахырында тәкъдим ителгән текст үрнәкләре дә рухани әдәбиятыбызның кайбер жанрлары, аларның стильләре хакында беркадәре төшенчә алырга ярдәм итәр дип ышанасы килә. Иске мирасыбызның кайбер төрләре белән киң җәмәгатьчелекне таныштыру юлында Ж. Зәйнуллинның моңарчы да күп эшләгәнлеген беләбез. Мәсәлән илдә "үзгәртеп кору" процессы башланугa ук аның радио һәм телевидение буенча мөнәҗәтләребез хакындагы тапшыруларын искә төшерик. Иске әлифбабыз — гарәп язуы — буенча уздырылган беренче дәресләрне дә Ж. Зәйнуллинның оештырган булуын онытмыйк.

Минем монда мөнәҗәтләрне искә төшерүем һич тә очраклы түгел. Мөнәҗәтләр ул — иң авыр, иң караңгы чорларда да халкыбызга тугрылыклы хезмәт иткән иң үтемле, иң демократик жанр. Һәм рухи, һәм рухани әдәбиятларның сыйфатларын үзендә туплаган шул бөек жанрның, хәзер нигездә сәхнәдә генә булса да, янадан яши башлавында Җ. Зәйнуллинның да өлеше кечкенә түгел. Кыскача, рухи байлыгыбызның мөһим өлеше булган рухани әдәбиятыбызны өйрәнү юлында Җ. Зәйнуллин — күптәннән эшләп килгән кеше.

Китапның гыйльми аппараты да тулаем уңай бәягә лаек. Ләкин текстларда очрый торган архаик сүзләргә төзелгән сүзлекчәнең алфавит тәртибендә бирелмәвен (158-164 битләр) мин ахыргача акланган дип әйтмәс идем. Автор китапның башыннан ахырынача укый торган кешене генә күз уңында тотып шулай эшләгән. Бу — хезмәткә карата дөрес мөнәсәбәт түгел. Чөнки китапның уртасыннан ачып карауч ылар да булачак. Мәсәлән, имтиханга әзерләнгән, теге яки бу конкрет мәсьәлә буенча белешмәләр эзләгән студентлар...

Әмма гыйльми аппаратта иң иң ошаганы: ул — Коръән сүрәләренең һәммәсенә бирелгән кыскача, ләкин шактый күләмле аңлатмалар (165-195 битләр). Шактый төгәл мәгълүматларга бай һәм бик ипле язылган бу кушымта белешмәлек сыйфатында мөстәкыйль әһәмияткә дә ия дип уйлыйм.

Ниһаять, рухани әдәбият үрнәкләреннән бирелгән иллюстратив материал да кызыклы гына. Ләкин һәр фотокүчермә астына кыскача белешмә бирелмәү аркасында әлеге фотосурәтләр "сукыр һәм чукрак" хәлендә калган.

Җыеп әйткәндә, Җәмил Зәйнуллин бик мөһим гаять кирәкле эш башкарган. "Беренче карлыгач" дип бәяләнергә лаеклы аның яңа китабы. Автор бу юнәлештәге эзләнүләрен киләчәктә дә дәвам итәр дип ышанасы килә. Ә эшлисе эшләрнең иге-чиге юк. Халкыбызның гасырлар буена тудырган, туплаган рухи һәм рухани байлыгын инләп чыгар һәм төрле яклап бәяләр өчен бер кешенең, бер буынның гына түгел, ә бәлки берничә буын вәкилләренең дә тырышлыгы таләп ителәчәк әле.

**Миркасыйм ГОСМАНОВ.**

---

# ӘДӘБИ ВАКЫЙГА БУ

Зөлфәт Хәкимнең өч томлык "Сайланма әсәрләр"е басылып чыгу соңгы еллардагы әдәби процесста күренекле вакыйгаларның берсе булды.

Өч томлыкка авторның 1997 елга кадәр иҗат иткән төп әсәрләре тупланган. Болар — һәм проза, һәм драма әсәрләре, һәм әдәби парчалар...

Беренче том асылда "Гөнаһ" исемле, 1995-1996 елларда язылган романнан тора. Романнан соң "Уйлар уйнавы..." дип аталган парчалар бирелгән, алар күләм ягыннан зур түгел. Әмма язучының фикер йөртүен, стилен күзаллау өчен дә, сәнгатьлелек үзенчәлекләрен төшенү өчен дә мөһим. Авторның фикри мәгънәгә, образлылыкка ничек ирешүен, ягъни сәнгатьле фикерләү үзенчәлеген боларда ук инде чамалап була. Билгеле, мәгънәви-фәлсәфи йөк салынган ике дистәдән артык бу парчаларның барысы да бердәй югарылыкта түгелдер. Мәсәлән, "Җир түгәрәк, дисең" дип башланган "уй уйнавын" оригиналь санап булмас. Ләкин аларның көчен мондыйлары түгел, ә "Килү, китү" кебек язмалар һәм "яшәүнең мәгънәсе — яшәү мәгънәсен эзләү" кебек афористик гыйбарәләр билгели.

Хәким Зөлфәт. Сайланма әсәрләр, 3 томда. — Казан: ТКН, 1997.

"Гөнаһ" исемле роман вә аның үзенчәлекләре хакында язучы Рафаил Сибат акыллы мәкалә бастырды (кара: "Шәһри Казан", 1998 ел, 13 февраль). Билгеле инде, ул әсәрнең барлык якларын да ачып бетерде дип әйтү дә, бер газит мәкаләсе кысаларында гына моны таләп итү дә урынлы булмас иде. Шулай да тәнкыйтьче һәр тарафтан оригиналь булган бу әсәрнең төп өстенлекләрен дә, кайбер җитди булмаган кимчелекләрен дә ачып, әйтеп биргән. Рафаил Сибат үз мәкаләсендә романны атаклы Европа (Ф. Кафка, И. Андрич) һәм бөек рус

язучылары (Л.Толстой, Ф.Достоевский) әсәрләре, аларның язу стиле белән чагыштырып карый, уртаклыклар күрә.

Татарстанның халык язучысы Гариф Ахунов 1997 нче әдәби ел йомгакларына багышланган җыелышта романны татар әдәбияты традицияләре яктылыгында да карарга кирәк, дигәнрәк фикер әйткән иде. Ул фикер миндә дә туган иде. Әйе, "Гөнаһ"ны, һәм гомумән Зөлфәт Хәкимнең язу стилен татар прозасы яссылыгында да карарга кирәк. Шул яктан аның яңалыгы нидә икән?

Бөтен буена алып караганда татар прозасына тәфсиллек, тигез агышлы сүрәтләү стиле хас. Бүгенге прозаиклар стилендә дә шул дәвам иттерелә. Классик үрнәкләр — Ф. Әмирхан, Г. Бәширов, Ә.Еники, Н. Фәттах, Г. Ахуновлар прозасы. Ләкин үзгә стиль агымы да юк түгел. Г. Исхакый, Г. Ибраһимов, А. Гыйләҗев, бигрәк тә Ә. Гаффарлар стиле бу яктан аерылыбрак тора. Беренче төр язучыларда психологик анализ бер яссылыкта, бер тигезлектә барса, "чоңгыллар" юк дәрәҗәсендә булса, икенче авторларда психоанализ тирән чоңгылларга ия булган елга агышын хәтерләтә. Бу җәһәттән Зөлфәт Хәким прозасы (мин аның тагын "Курку" повестен, хикәяләрен дә күздә тотам) яңа бер стиль үзенчәлеге алып килә. Монда эчке, рухи халәтнең төрле мизгелләре, төрле чагылышлары алгы планда, алар катлаулы фәлсәфи сораулар җебенә үрелгән, кеше психологиясенең нечкәлекләренә бай. Мин Рафаил Сибатның күпчелек фикер вә бәяләре белән килешкән хәлдә дә, аның бер раславын шик астына алам. Романда "хәрәкәт аз, динамика сизелми" ди ул. Миңа калса, болай дип әсәрнең кайбер урыннарына карата гына әйтергә мөмкин. Нәкъ менә динамика көчле романда. Ләкин бу тышкы хәрәкәт динамикасы түгел, ә психологик халәт, рухи кичерешләр динамикасы. Асылда үзәк каһарманның эчке кичерешләре, уй-газаплары киеренке хәрәкәтне барлыкка китерә, каядыр хәтта "тышкы" вакыйгалар үсешен дә билгели. Фәизнең гөнаһларын юу юлындагы иң әүвәл үз рухындагы киртәләрне җиңеп баруы, шәхес буларак үзен табуы һәм үсүе эчке киеренкелек шартларында бара, персонажның бу халәте укучыны бер дә битараф калдырмый, аңар да күчә.

Роман һәм повестьларында Зөлфәт Хәким бүгенге кешеләр, бүгенге ситуацияләр белән эш йөртә. Монда да аның үз өлкәсе бар. Безнең заманда кешене бигрәк тә вагайта, тарката, шәхесне җимерә-үтерә торган хәлләр вә вакыйгаларны күреп ала һәм оста кулы белән сурәтли белә. Рухи саэлыкның күп төрле гәүдәләнеше әсәрдә һәммә персонажлар язмышы белән тоташтырылып тасвирлана. Автор концепциясе ачык: кеше дигән табигать баласы Олы ЖАН булып кала, һәртөрле авырлыкларны, аларның да иң газаплысы булган рухи сынауларны уңышлы уза вә җиңә белә ул. Шулай да яшәешнең бу агышында барлык кеше дә бердәй, Фәиз кебек, авырлык белән йөзми. Марат кебек пакъ күңелләләр дә йөзә анда, һәм аларга йөзү күпкә җиңелрәк.

"Кеше" дигән җан иясенә югары көч тә табигать тарафыннан бирелгән хисләрнең (гөнаһтан чистарынуга омтылыш, куркуны җиңеп үтәргә тырышу һ.б.) шәхес язмышында уйнаган ролен, чиста яшәү дигән, мәрхәмәт дигән изге төшенчәләрнең җиңүенә алып килә алу мөмкинлеген, аларның тантанасына китерүен сәнгатьчә үтемле төстә күрсәтү — Зөлфәт Хәким иҗатының, иң беренче, аның прозасының көчле якларыннан.

"Сайланма әсәрләр"нең икенче томына автор иҗатының бу үзенчәлеген чагылдырган "Курку" әсәре белән бергә иманга тугрылыкның бөеклеген сурәтләгән "Әүлия кабере" исемле кыйсса да кертелгән. Көчләп чукындырылган Сөләйман үз авылдашлары тарафыннан читкә җибәрелә. Әмма күңелдә ныклы урын алган иман барыбер өстенлек ала: икенче диңгә күчерелүендә һичбер гаебе булмаган Сөләйман үлеменнән соң булса да авылдашлары тарафыннан таныла, олылана. Бер караганда, автор XVI гасыр кешеләренең надан-каралыгын фаш итә кебек. Ләкин монда диңгә-деңгә тугрылык һәм мөселманлыкның чисталыгы өчен көрәш мотивы көчлерәк яңгырый, шул ягы белән әсәр яңа вә файдалы, бүгенгә аваздаш.

Тарихыбыздагы әллә кайчангы чорны чагылдырган "Әүлия кабере" повестенда автор тарихи сүзләрдән һәм архаизмнардан иркен файдалана, диалекталь сүзләрне дә шактый кертә. Чагыштырмача яшь кеше булган авторның бу алымы һәм аны шактый ук белеп файдалануы сокландыра. Шулай да иске сүз вә гыйбарәләрнең урыны белән артыккарак китүен, һәр очракта да бүгенге укучыга аңлашылып бетмәвен дә әйтеп үтәргә кирәк.

Икенче томның күпчелек битләрен сатирик әсәрләр били. Монда да Зөлфәт Хәкимнең каләме үзенчәлекле һәм югары художестволы. Бездә юмор осталары күп түгел, сатириклар тагын да азрак. Зөлфәт Хәким беренче әсәрләре белән үк болар арасында ныклы урын алды. Томда "Хикәяләр һәм монологлар" исемле махсус бүлекчә бар. Мондагы сатирик һәм юмористик парчалар арасында кешедәге аерым кимчелекләрдән башлап ("Тын океанда көрәш") бүгенге җәмгыятьтәге тәртипләрдән көлүгә ("Гонорар", "Кызык заманда яшибез!") кадәр аралыкны күрергә мөмкин. Бусы — тематик яктан төркемләгәндә. Көлү тудыру алымнары ягыннан да Зөлфәт

Хәким каләме бай. Без монда яратып, вакыты белән сызланып көлүдән башлап ("Шифоньер", "Бөеклекнең зыяны", "Чын ярату", "Беренче мәхәббәт") ачы, мәсхәрәле сатира төрләренә кадәр булган көлү спектры белән очрашабыз. Соңгысының матур мисаллары — "Телевидение шаукымы", "Нурулланың эмигрант Сөнгатуллага язган хаты", "Ельцин трамвайга утырды", "Контра" һ.б. Боларны укыгач, "Зөлфәт Хәким — бүгенге иң көчле сатириклардан берсе" дип әйтәсе килә.

Авторның көлү осталыгы бу томга урнаштырылган "Агымсуда ни булмас..." исемле сатирик романында һәм "Кишер басуы" дип аталган сатирик повестенда да югары ноктага ирешә. Соңгы әсәрен автор сәхнәләштерде һәм ул Г. Камал исемендәге академия театрында куелып зур уңыш казанды.

Һәр ике әсәрне үзара якынайткан яклар бар: бүгенге көннәрнең билгеләре ачык чагылу, безнең заманга хас проблемалар, бүгенге кешеләр менәзендә (характерында) ныгый барган сыйфатлар — теләсә нинди юл белән байлыкка омтылу, миһербанлыкны вә кешелекне жуя бару, кешеләр арасындагы мөнәсәбәтләрдә матур гадәтләрнең кимүе... Мондый сыйфатлар шулкадәр көчәйгән ки, әнә, үзләре тәртип сагында торырга тиешле кешеләр үз вазифаларыннан явызларча файдаланалар һ.б.

Бу романдагы үзәк персонаж Мәрдәнша — сатирик образ булудан бигрәк трагикомик герой. Табигать вә кеше мөнәсәбәтендә дә авторның фажигалелеккә алга чыгаруы күренә — саф табигатьне пычратуыбыз, югалта баруыбыз аңарда сызлану тудыра. Трагизм һәм комизм монда бербөтен. Реаль чынбарлык, фантастика вә әкият ысул-алымнары мул булып аралашкан бу әсәр фикер йөгенең саллы булуы белән характерлана.

"Кишер басуы"нда исә инде аерым шәхесләр язмышыннан халык язмышы, милләт язмышы оеша. Моңарчы милләтебезнең генофондын саклауда төп чыганак булып килгән авылыбызның таркалуга, рухы сыекланута баруына сызланып көлү беренче урында тора. Кыскасы, повестьта көннән-көн көчәя барган кимчелекләр, гарип яклар үткен итеп, дөрес тәнкыйтьләнә. Мондый гарипләкләр Академия театрында куелган спектакльдә режиссер һәм актерлар уены белән тагын да калкурак итеп күрсәтелде, алар тагын да актуальрәк төс алды.

Сайланма әсәрләр"нең өченче томы пьесалардан тора. Барлыгы 7 әсәр, 7 төрле дөнья. Пьесалар шулай ук авторның бай иҗат фантазиясен, теләсә нинди тормыш материалында драматизм һәм комизм күрү сәләтен чагылдыра. Зөлфәт Хәкимнең алда карап үткән ике томлыгы аны оста прозаик итеп танытса, бу өченче том аның бик үзенчәлекле драматург булуын күрсәтә.

Автор каләменең палитрасы бай: пьесалар арасында "Үтермә" исемле саф драма, "Җүләрләр йорты" һәм "Җен бутады" кебек трагикомедияләр, "Карак" дип аталган комедия, "Хыянәтче" исемле мелодрама бар. "Зәхмәт" дип исем куйган бер әсәрен ул гади генә итеп "пьеса" дип билгели. Ләкин аерым кешеләрнең үз рухында-күңелендә яшеренеп яткан комсызлык, хыянәт кебек тискәре сыйфатлар белән көрәштә җиңеп чыгуын сурәтләгән вакыйгалар тезмәсе буенча килеп караганда аны шулай ук драма жанрына, аның да психологик драма төренә кертеп карарга була.

Драматик хәлләр төзүнең ике юлы бар. Берсе һәм бездә еш кулланыла торганы: әсәрнең башында ук капмакаршы торучы көчләр ачык төс ала, көрәшнең алга таба ничек барачагын чамалап була. Икенчесе исә — каршы торучы көчләр ачык ук булмый, алар әсәр ахырында гына тәмам формалашып-оешып бетә. Зөлфәт асылда соңгы юл белән бара, көлке вә драматик вакыйгаларны берьюлы гына ачып бетерми, аларга акрынлап килә, геройларның да характер буларак сыйфат-үзенчәлекләрен ашыкмыйча гәүдәләндерә. Тагын да бер, драма әсәре өчен бик тә кирәкле, бездә шактый сагындырып кына кулланыла торган алым — сюжет сызыгын көтелмәгәнчә борып кую, беренче карашка очраклы күренгән, асылда исә бик тә мантыйкый хәл тудыру. Монда Зөлфәт Хәким тапкыр. Шуларның һәммәсе ярдәмендә ул персонаж характеры дәрәҗәсендә фажигане һәм көлкене бергә берләштерә. Бу аның трагикомедияләренә генә түгел, мелодрама һәм комедияләренә дә хас.

Зөлфәт Хәким пьесаларын ике төргә: сәхнәгә кую, уку, кабул итү өчен ансатрак булганнарга һәм күңел-вөждан чоңгылларын бирүдә катлаулыракларга аерып карарга мөмкин. Беренчеләренә "Карак", "Зәхмәт", "Кишер басуы", "Күрәзәче" кебек әсәрләр керә. Боларда сюжет төзек, бер яки ике персонаж тирәсендә оешкан, тормышчан вә фабуласын тотып алуы ансатрак. Ә икенче төр пьесаларда сюжет шактый ук катлаулы, көтелмәгән хәлләр тагын да күбрәк, әсәр фабуласын истә калдыруы читенрәк. Аларда драматик хәрәкәтне тышкы вакыйгалар түгел, ә күбесенчә эчке халәт, рухи көчеш-чайкалулар билгели. Боларына "Җүләрләр йорты", "Хыянәтче", "Җен бутады", "Үтермә" кебек пьесалар керә. "Мәңгелеккә изге сәфәр" кыйсса-пьесасы да шуларга якын.

Ләкин бу һич кенә дә беренче төр әсәрләр артык гади икән дигән сүз түгел.

Мисалга "Карак" комедиясен алыйк. Гадәти булмаган ситуация:

профессиональ карак ансат кына эләгә дә куя. Тотучысы — йомшак һәм көчсез бер хатын-кыз. Чит-ят ирне үз фатирында күреп һуштан язарлык дәрәҗәдә курыккан Альбина ханымга Карак берьюлы гашыйк була да куя. Өй хуҗасы — милиция начальнигы — кайткач, "гөнаһ" өстендә тотылган Карак котылу өчен үзен Альбинаның сөяркәсе дип игълан итә. Шулай итеп бер — "сөяркә", бер — "карак мин" дип көнче ирнен, аның белән бергә күршедәге коммерсантның да (анын хатынынын да сөяркәсе, имеш) тәмам башларын катырып бетерә ул. Монда драматург һәртөрле детальләрне эшкә оста җигә. Ситуация үзәгендә Каракның фатир басуы, чибәр хуҗабикәгә гашыйк булуы, көнче ирләр белән аңлашу-бәрелешләр генә дә ятмый. Ул үзе дә — администрация башлыгы, прокурор, милиция начальнигы, эре мафиозник катнашкан житди интрига эчендә калган корбан. Бүгенге көнкүрештә чәчәк аткан караклык, жуликлык, кеше көчләү вә үтерү, хәрәм байлык туплауга омтылу кебек сыйфатлар комедиядә оста вә үткен чагылдырыла. Авторның яраткан алымы — сюжет сызыкларын башта чуалтып бетерү, аннары бер төенгә бәйләү, вакыйгаларның алга таба нинди төс алачагын әсәр геройлары өчен дә, тамашачы өчен дә ахыргача билгесез калдыру пьесаларны укырга кызыклы, карау өчен үзенчәлекле-оригиналь итә.

Йомгаклап әйткәндә, татар драматургиясен басып алган "үтә күренмәлелек" фонында Зөлфәт драматургиясендәге "катлаулылык" перспективалырак тоела.

Бу рецензия тулырак булсын өчен томнар төзелешендәге тагын кайбер якларга да тукталып үтәргә кирәк. Китаплар полиграфик яктан әйбәт эшләнгән, тышлыклары матур, җыйнак. Нәшрият редакторлары Н. Вәлитова, Ф. Зыятдинова, бизәлеш мөхәррире Р. Шәмсетдинов үз эшләрен яратып башкарганнар. Бүгенге китап һәм гәзит-журналларда мул очрый торган хәреф вә өтер хаталарыннан, компьютерлаштыру "бүләге" булган —кучермәләрендәге хаталардан да бу басма азат дип әйтерлек. Ә инде ни өчен "дип әйтерлек" дигәндә, кайбер чатаклыклар да очрый әле. Мәсәлән, шул ук "Карак" пьесасында коммерсант урынына "следователь" килеп керә (III том, 141 бит). Күрәсен, пьесаның беренче варпантында күрше Марат коммерсант түгел, ә суд тикшерүчесе булган...

Өч томлыкның Зөлфәт Хәким иҗаты турында күренекле әдәбият вә театр эшлеклеләре әйткән сүзләр, фикер-бәяләр белән ачылуы игътибарга лаек, янача. "Зөлфәт Хәким — татар халкының ходай биргән зур бер талант иясе, үзенә күрә бер могҗиза!" — дип яза Равил Фәйзуллин. Марсель Сәлимҗанов язучының "усал юморы", "төпле фикере" турында әйтә, аның "күз яше аралаш көлә белүе"н югары бәяли. Миркасыйм Госманов исә аның укучыны уйландыра алу сәләтен билгели. (Дөрес, беркадәр мәсьәләне тарайту да бар: "әдәбиятның бурычы нәкъ шул — уйландыру , — дип яза ул. Алай гына түгел, әлбәттә. Матур әдәбият үз чаралары ярдәмендә тормышны тулы чагылдырырга да, өйрәнергә дә, бәя бирергә дә, укучының рухын баетырга да бурычлы.) Миргазиян Юнысны авторның киң колачлы язу стиле сокландыра: "Аның әсәрләрендә Франсуа Рабле дә, Гарсиа Маркес та, Борхес та, Джером Клапка да, Марк Твен да, хәтта Сервантес та бар шикелле тоела, — дип яза ул. — Ә үзе, "сабакы", саф татар!" Фәиз Зөлкарнәй өч томлык авторының "Һәр өлкәдә дә хәзерге татар рухиятен заманча яңа итеп һәм югары дәрәҗәдә ача белүе"н алга куя.

Зөлфәт Хәкимнең "Сайланма әсәрләр"е бүгенге әдәби агышта, алда әйтелгәнчә, күренекле вакыйга төсендә тарихка кереп калыр, дип ышанабыз.

**Азат ӘХМӘДУЛЛИН.**

*Укучы сүзе*

# ТӨГӘЛЛЕК КИРӘК!

"Казан утлары" журналында (1998, 3 сан) Сәгыйть Хафизовның "Әдәбиятта базар заманы" дигән әдәби тәнкыйть мәкаләсе басылган иде. Язмада татар әдәбиятының бүгенге халәтенә гаять тирән һәм җентекле анализ ясала. Аларына тукталып тормыйм. Әмма мәкаләдәге кайбер төгәлсезлекләрне дә әйтми калырга мөмкин түгел. Биредә сүз моннан өч ел элек "Идел" журналында басылып чыккан "Татар декаденсы" дигән эссе турында бара. Әмма, еш кына, аның авторы дөрес аталмый: ул йә Илшат Хәлиуллин дип атала, йә Хәлиуллин дип кенә атала. Бу очракта кемнеңдер (мәкалә авторыныңмы, журнал хезмәткәренеңме) Илшат Вәлиулла дигән башлап язучыны танылып килүче тарихчы Илшат Хәлиуллин белән бутаганлыгы ачык күренә кебек...

Моннан өч ел элек басылган һәм күләме буенча зур булмаган эссега бүген зур игътибар күрсәткән Сәгыйть Хафизовка рәхмәт, билгеле. Ләкин, кызганычка каршы, аның тәнкыйть мәкаләсендә эссены аңлап җиткермәү дә сизелеп куя.

*Беренчедән.* Эссеның авторы Илшат Вәлиулла алман фәлсәфәчесе Фридрих Ницше тарафдары түгел. Теләсә нинди рухи авторитетка саклык белән килергә кирәк дип уйлыйм мин... Ә дөньяның зур фәлсәфәчеләренең берсе булган Ницше фикерләре ( Аллага ышанмау, яхшылыкның кыйммәтлелеген кире кагу) белән килешмәвем эсседа ачык әйтелгән бит.

*Икенчедән.* Фашизмны Ницшедан чыгаруның мәгънәсезлеге күптән инде исбат ителгән. Ницше кебек үз милләтен кимсетеп язган башка алман фәлсәфәчесен табуы авыр. (Мәсәлән: "Немцы — их называли некогда народом мыслителей: мыслят ли оны еще ныне вообще?", "Этот народ самовольно одурял себя почти в течении тысячи лет", "Происхождение немецкого духа — из расстроенного кишечника...") Шул ук вакытта ул яһүдләр һәм славяннар турында хөрмәт белән генә искә ала! Ә фашизм, билгеле булганча, "алманнар — иң югары раса" дигән идеологиягә һәм славянафобия белән антисемитизмга нигезләнә.

Шуны да әйтеп узарга була: Ницшены гына түгел, ә Лютер, Гете, Бетховен, Вагнер мирасларын да алман фашизмы үз идеологиясенә яраклаштырырга омтылган. Аңа карап без Гете шигъриятеннән яки Бетховен музыкасыннан баш тарта алыр идекме?

Искә төшерсәк, безнең үз тарихыбызда да мондый идеологик фальсификацияләр җитәрлек бит. Кайчандыр без Тукайдан Алласыз, атеист шагыйрь ясарга омтылдык. Бүген исә моның киресен танырга мәҗбүрбез...

*Өченчедән.* Ни өчен әле Хафизов Ницше, Шопенгауэр, Фрейд кебек "Алласызларны" кире кагып икенче бер "Алласызлар" (Маркс, Ленин) идеологиясенә ияреп язылган татар әдәби әсәрләрен яклап чыга? Сүз Һ. Такташ, Г. Ибраһимов, Г. Әпсәләмовлар һ.б.ш. турында бара. Югыйсә, атеизм, Алланың барлыгын кире кагу иң зур гөнаһлардан санала түгел... Нигә дәһри идеология белән сугарылган әсәрләр укырга безгә? Әллә чынбарлык бу гади фикри җавапларднан һәм арзан гомумиләштерүләрдән катлаулыракмы?!...

*Дүртенчедән.* С. Хафизов "Татар декаденсы" авторын чит цивилизацияләрдән калган концепцияләр, фәлсәфәләр чүплегендә казынуда гаепли. Әмма, шул ук вакытта, үзе үк Максим Горькийның Прометей һәм Христос турындагы фәлсәфәсен

---

*Редакциядән.* Бу очракта мәкалә авторы С.Хафизовның гаебе юк. Ул кульязмада дөрес итеп — Илшат Вәлиулла дип язган булган.

казып чыгарып, аннан Прометей һәм Мөхәммәт каршылыгы турындагы фәлсәфә тудырып, безгә тәкъдим итә. Бу үзе зур логикасызлык — фикри икейөзлелек. Нишлисең, чәй дә, бәрәңге дә, шахмат та, "Мерседес" автомобиле дә, Прометей да, Христос та, Мөхәммәт тә, Маркс та, Ленин да татарга читтән кергәннәр... Татар "бездә яхшы кино юк" дип кино карамыйча утырмый, ә урыс, америка, француз киноларын карый. Бездә "яхшы телевизорлар юк" дип күңелсезләнми, ә япон, алман телевизорларын сатып ала. Менә шундый симбиоз... "Саф" татарлык өчен җан аткач, бәлки, боларның барысыннан да баш тартыргадыр?..

Асылда исә гомумкешелек мәдәни мирасына булган мондый тискәре мөнәсәбәт белән килешергә мөмкин түгел. Әгәр без Көнбатыш мәдәниятенә (Бах, Гете, Кант, Бетховен, Шопенгауэр, Ницше, Шпенгиер) "чүплек" дип кенә карыйбыз икән, без милләт буларак ерак китә алырбызмы икән? Билгеле, Коръән — бердәнбер дөрес китап дип борынгы бөек китапханәләргә ут төртүчеләр булган. Әмма, Сәламәт Акыл шундамы?!.

Югыйсә, хәдисләрдә түбәндәге сүзләр дә бар: "Бер сәгать белем алу төннәрен гыйбадәттә торудан, бер көн белем алу өч ай руза тотудан хәерлерәк".

Әгәр без татар музыкасы фәлсәфәсен Аурупа музыкасы фәлсәфәсе белән чагыштырырга куркабыз икән, әгәр мондый чагыштырулар татар милләтен бетерергә мөмкин дип һәр фикерне тыябыз икән, бу милли кыргыйлыктан башка берни була алмый. Һәр фикер — бетү түгел! Ә менә изоляцияләнергә омтылу — бетүнең башы.

Гомумән, "Алласызлар" — коммунистлар белән бәйләнешле 70 еллык әдәбияттан соң һәр фикерне тыярга теләү көлкеле яңгырый...

*Бишенчедән.* "Татар декаденсы" дигән әсәрдә татар халкына инкыйраз юралмый. Монда кайчандыр Алтын Урда кебек бөек дәүләт төзи алган халыкның 80 нче еллар башына авыр хәлгә калуы турында ачыргалану аша әйтелә... Ул елларда, хәтерләсәгез, Казан урамында татарлар үзара пышылдашып кына сөйләшәләр иде. Сорау: сәламәт халык, милләт үз башкаласында үзен шулай тотар идеме? Юк, — бу халыкның үз тормыш көченә ( теленә, рухына, җинүчәнлегенә) ышаныч югалтудан туа... Шуның нәтиҗәсе буларак та (!) татар халкы тормышында моңлы җырлар, моңлы әдәби әсәрләр алга чыга...

Ә татар милләтенең юкка чыгу-чыкмавына кагылышлы рәвештә иң дөрес сүзләрне Туфан әйткән:

Тормыш үзе биргән гадәтенне
Кем таныймый аны, кем белми:
Йә җинелә татар, йә җинә ул,
Ә бирелми әмма, бирелми.

*("Ил" шигыреннән).*

*Алтынчыдан.* Хафизов "Татар декаденсы" авторын бүгенге татарларны Болгар, Алтын Урда тарихы белән бәйләп караудa гаепли. Хафизов буенча, татар халкы — яшь халык һәм аның тарихы 1,5 гасыр элек кенә башланган икән. Мондый фикерләргә комментарийләр була алмый дип уйлыйм...

*Җиденчедән.* Хафизов, бер яктан, Ислам яңарышын яклый, икенче яктан исә әдәбиятта сихерчеләрне, им-томчыларны сурәтләү зарурлыгы турында сүз алып бара. Ә бит "Коръән тәфсире"н укып чыккан һәркем Исламның сихерчеләргә, им-томчыларга каршы икәнен белә.

Ахыр чиктә шуны әйтергә була: бер генә татарның да "бу —татарлык", "ә бу түгел" дияргә хакы юк. Югыйсә, бу шул ук тоталитаризм булыр иде. Татарлыкны үзгәрешләр тулы Мәңгелек, Тормыштан аерып куярга кирәкми. Татарлык Чынлык-ка тугры калганда гына мәңгелек булачак.

**Илшат ВӘЛИУЛЛА.**

*Котлыйбыз!*

## Булат Солтанбәковка — 70 яшь



Булат Фәйзрахман улы Солтанбәков 1928 елны Казан шәһәрендә туа. Педагогия институтын тәмамлаганнан соң авыл мәктәбендә тарих укытучысы булып эшли. Совет Армиясе сафларында хезмәт иткәннән соң Татарстан өлкә комитетының мәктәпләр бүлегендә партия эшләрендә, 1961 елдан Казанның югары уку йортларында укытучылык хезмәтләрен башкара. Ул — Татарстан республикасының атказанган мәдәният хезмәткәре. Мәдәният, мәгърифәт өлкәсенә караган, милли мәсьәләләрне күтәргән, сталинизмның аяныч нәтиҗәләрен яктырткан йөзләгән мәкаләләр авторы. Шулай ук мәктәпләр өчен Татарстан тарихы буенча "Первая жертва генсека", "Тайны национальной политики", "Драматические страницы истории Татарстана", "Страницы секретных архивов" исемле китаплар авторы. Быел аның (Л.А.Харисова, А.Г.Галләмова белән берлектә) яңа хезмәте — "История Татарстана. XX век" китабы дөнья күрде. Бу хезмәт дәреслек сыйфатында гомум урта мәктәпләр өчен чыгарылган.

Ул, шулай ук, М. Солтангалиев һәм башка данлыклы шәхесләрнең исемнәрен халыкка кайтару буенча күп эш башкара, КГБ архивларын тирәнтен өйрәнеп вакытлы матбугатта байтак мәкаләләр бастыра.

Булат Солтанбәков, җәмәгать эшлеклесе һәм галим буларак, Татарстанда гына түгел, чит илләрдә дә танылу алган шәхес. Соңгы елларда, Мәскәү, Будапешт, Париж һ.б. башкалаларда уздырылган фәнни конференцияләрдә катнаша, чыгышлар ясый. Россия Дәүләт Думасы, Татарстан Дәүләт Советы комиссияләренең парламент тыңлауларында катнашып килә.

1993 елда Татарстан тарихчылары һәм архивлары оешмасының рәисе итеп сайлана. "Эхо века" журналының фәнни редакторы буларак халыкка аз билгеле булган тарихи материалларны туплап дөньяга чыгаруда үзеннән күп көч куя.

Бүгенге көндә Булат Солтанбәков укытучыларның белемен күтәрү институтында мәдәният теориясе һәм тарихы кафедрасы мөдире.

**Без күренекле галимне, даими авторыбызны, журналыбызның редколлегия әгъзасын юбилее белән котлыйбыз, саулык-сәламәтлек һәм иҗат уңышлары телибез.**

***"Казан утлары" редакциясе***

# *Иҗтимагый-мәдәни тормышыбыздан*

## ДУСЛЫК ВИЗИТЫ

Үзбәкстан Президенты чакыруы буенча, Татарстан Президенты М. Шәймиев җитәкчелегендәге рәсми делегация ике көнлек визит белән тугандаш Үзбәкстан Республикасында булды. Җөмһүриятебез Илбашын 12 октябрьдә Үзбәкстан Президенты И. Каримов кабул итте. Үзара дуслык-аңлашу шартларында үткән очрашу барышында президентлар ике республика арасында дуслык элементларын тагын да ныгыту мәсьәләләрен тикшерделәр.

Яклар мәдәният өлкәсендә тыгызрак хезмәттәшлек итү, аерым алганда, Үзбәкстанда Татарстан Мәдәният көннәрен һәм Татарстанда Үзбәкстан Мәдәният көннәрен үткәрү турында килештеләр.

## ТӨРКИЯ КОНСУЛЫН КАБУЛ ИТҮ

9 октябрьдә Татарстан Республикасы Президенты М. Шәймиев Төркия Республикасының Җөмһүриятебездәге яңа генераль консулы Әхмәт Риза Дәмирәрне кабул итте. Билгеле булганча, Әхмәт бәй монарчы Татарстанда консул булып эшләгән, хәзер исә Берлинда шундый ук җаваплы вазифа башкаручы Алпхан Шолен урынына килде.

## ЕВРОПАГА ТАГЫН БЕР ТӘРӘЗӘ

Татарстан Республикасының Урал төбәге буенча даими вәкиле Р. Бикбов Бөекбританиянең Екатеринбургтагы генераль консулы Стивен Харрисон әфәнде белән очрашты. Очрашуда Британия фирмалары белән Татарстан арасындагы элемтәләрне җайга салу мәсьәләсе кузгатылды.

## ТӨРКИ ЛИДЕРЛАР КИҢӘШӘ

10-14 сентябрьдә Карачай-Черкес республикасында "Төрки халыклар ассамблеясы"ның лидерлар советы утырышы булды. Киңәшмә эшендә Төркия, Украина, Молдова, Әзербайҗан, Татарстан, Якут-Саха, Дагстан, Балкар, Карачай-Черкес республикаларыннан төрки лидерлар катнашты. Анда Татарстаннан "Иттифак" партиясе рәисе—язучы Фәүзия Бәйрәмова, Милли Мәҗлес рәисе—язучы Айдар Хәлим (Чаллы), язучы Разим Вәлиуллин (Әлмәт) чыгыш ясадылар.

## ӘФГАНЧЫЛАР ИСТӘЛЕГЕНӘ

29 сентябрьдә башкалабызның Казансу елгасы буенда — Татарстан газета-журнаплар нәшрияты янәшәсендәге мәйданда — Әфганстанда һәлак булган якташларыбыз истәлегенә һәйкәл ачылды. Билгеле булганча, Әфганстанга Татарстан җиреннән генә дә 10 меңгә якын солдат һәм офицер киткән. Шулар арасыннан 279 ы һәлак булган, 546 сы яраланып кайткан.

Хәтер митингысында Казан шәһәре мэры К. Исхаков, Әфганстанда һәлак булганнарның аналар комитеты җитәкчесе Б. Корнилова, һәйкәл авторы — скульптор А. Миннуллина һ.б. чыгыш ясады.

## РЕДКОЛЛЕГИЯ УТЫРЫШЫ

29 сентябрьдә "Казан утлары" журналы редколлегиясенең чираттагы утырышы үткәрелде. Утырышны кыскача кереш сүз белән журналның баш мөхәррире Р. Фәйзуллин ачты. Аннан соң журналның быелгы 1-8 саннарында проза әсәрләренә баш мөхәррир урынбасары Ф. Латыйфи, поэзиягә Р. Зәйдулла, публицистикага М. Зарипов, әдәби тәнкыйть һәм фәнгә караган язмаларга Х. Миңнугулов анализ ясадылар. Редколлегия әгъзалары һәм чакырылган язучылардан Ә. Еники, Г. Ахунов, А. Гыйләҗев, Ш. Галиев, И. Юзеев, Ә. Баян, Т. Галиуллин, Р. Мөхәммәдиев, Х. Әюпов, С. Маннапов, М. Галиев, Р. Низамиев, Җ. Дәрзаман, галимнәрдән М. Госманов, Б. Солтанбәков, сәнгать белгече Р. Шаһиева һ.б. редакция эшчәнлеген, язмаларның эчтәлеген тагын да яхшырту, актуаль проблемаларны кыюрак яктырту турында үзләренең фикерләре белән уртаклаштылар.

Редколлегия утырышында журналның 1999 елга эш планы расланды, дөнья күрәсе язмалар, әсәрләр турында эшлекле һәм файдалы сөйләшү булды. Утырышта Татарстан Республикасы премьер-министрының мәдәният буенча киңәшчесе А. Сибгатуллин катнашты һәм чыгыш ясады.

## ЖУРНАЛИСТЛАР ТӘҖРИБӘ УРТАКЛАША

Казанга визит белән Германия журналистлары килеп китте. Алар, Татарстан Президенты киңәшчеләре, Дәүләт Советы депутатлары, кайбер предприятие-хуҗалык

житәкчеләре янында булганнан соң, республикабыз матбугатында, радио-телевидениедә эшләүче журналистлар белән очраштылар, үзара тәҗрибә уртаклаштылар.

Очрашуда Татарстан Республикасының Мәгълүмат һәм матбугат министры И. Әхмәтҗанов, Татарстан Журналистлар берлеге идарәсе рәисе, "Татар-Информ" агентлыгы житәкчесе Р. Ратникова катнашты.

## ТАТАРСТАН ЯЗУЧЫЛАРЫ ДӨНЬЯ ГИЗӘ

16-26 сентябрь көннәрендә Татарстан Язучылар берлеге идарәсе рәисе Р. Мөхәммәдиев Халыкара Язучылар берлеге делегациясе составында Кытай Халык Республикасында булып кайтты.

* * *

Татар ПЕН-үзәге президенты Т. Миңнуллин житәкчелегендәге бер төркем әдипләр сентябрь аенда 10 көн дәвамында Финляндиядә булып, язучыларның Һельсинкида уздырылган 65 нче Бөтендөнья конгрессы эшендә катнаштылар, әлеге илдә яшәүче милләттәшләребез белән якыннан аралаштылар. Делегация составында Казаннан Р. Вәлиев, Ә. Мушинский, М. Хәбибуллин, М. Галиев, С. Маннапов, Н. Гыйматдинова, Р. Зәйдулла һәм Мәскәүдән В. Юныс бар иде.

## МӘҢГЕ ЯШИ АЛИШ КҮҢЕЛЛӘРДӘ

Каһарман язучы, җәлилче А. Алишның тууына 90 ел тулуны Казанда да, аның туган авылы Көектә дә (Спас районы) билгеләп үттеләр. Очрашуларда Татарстан Президентының матбугат үзәге житәкчесе Ә. Хәсәнов, Татарстан Дәүләт Советының даими комиссияләре рәисләре Р. Миңнуллин, Д. Каюмов, Спас районы хакимияте башлыгы К. Нугаев, Казанда яшәүче җәлилче Ф. Солтанбәков, А. Алишның улы Алмаз, язучылар Л. Ихсанова, Ш. Галиев, И. Юзеев, Р. Мостафин, Ш. Мостафин, Казандагы 55 нче мәктәптәге Алиш музее житәкчесе И. Сөнкишева, Апас районы газетасы журналисты А. Сөнкишев, А. Алиш исемендәге совхоз директоры М. Гыймалетдинов һәм күпсанлы туганнары, дуслары катнашты.

## ЯЗУЧЫ-ГАЛИМНЕ ХӨРМӘТЛӘҮ

11-12 сентябрь көннәрендә Нурлат шәһәре мәдәният йортында һәм Кычыткanлы авылында күренекле язучы-галим — Казан дәүләт университетының татар филологиясе, тарих һәм көнчыгыш телләре факультеты деканы, филология фәннәре докторы, Россия Гуманитар фәннәр академиясе академигы, Татарстанның атказанган фән эшлеклесе, Кол Гали һәм Гаяз Исхакый исемендәге премияләр лауреаты Тәлгат Галиуллинга 60 яшь тулуга багышланган очрашулар булып үтте. Күлбай-Мораса, Кизләү, Югары Норлат мәктәпләрендә дә очрашулар булды. Язучылардан Г. Ахунов, Ш. Галиев, И. Юзеев, Р. Фәйзуллин, Р. Мөхәммәдиев, Г. Зәйнашева, Ә. Гадел, Ф. Галимуллин һ.б. юбилярның фәнни һәм әдәби эшчәнлеге турында сөйләделәр. Район хакимияте башлыгы Ф. Сибагатуллин Т. Галиуллинга истәлекле бүләк тапшырды.

* * *

Т. Галиуллин юбилеена багышланган шундый ук тантана 12 октябрьдә Казанда, Г. Камал театрында да зурлап уздырылды.

## ҮЗЕНӘ ТАРТА ТУГАН ЯК

5 октябрьдә Татар дәүләт академия театры бинасында Санкт-Петербургта яшәүче якташыбыз — Татарстанның һәм Россиянең атказанган артисты Альберт Әсәдуллинның иҗат кичәсе узды. Анда К. Хәйретдинова, М. Сөнгатуллин, А. Галимов кебек танылган артистлар белән бергә, Чаллыдан "Болгар кызлары" бию коллективы да катнашты. Җырчыны түгәрәк юбилее белән дуслары, әдәбият-сәнгать әһелләре котлады.

## КҮҢЕЛЕНДӘ — САЛАВАТ КҮПЕРЕ

"Казан" милли-мәдәни үзәгендә Башкортстанның Туймазы шәһәрендә яшәүче татар рәссамы һәм шагыйрь Хәмит Латыйповның шәхси күргәзмәсе ачылды. Ул әлеге күргәзмәгә үзенең рәсемнәре белән бизәлгән "Жир һәм күк" дигән яңа шигырьләр китабын да алып килгән иде.

## КОТЛЫЙБЫЗ!

Татарстан Республикасы Президенты М. Шәймиев Указы белән татар халкының мәдәни һәм фәнни традицияләрен пропагандалау өлкәсендәге хезмәтләре өчен, Әхмәтвәли Мәңгәр исемендәге мәдәни-хәйрия фонды президенты Сафия Имрегә (Төркия); Г. Тукай исемендәге мәдәни җәмгыять президенты, Һельсинки университеты профессоры Гомәр Таһирга (Финляндия) "Татарстан Республикасының атказанган мәдәният хезмәткәре" дигән мактаулы исем бирелде.


*Тышлыктагы сурәтләр*

**Тышлыкның беренче битендә:** Татар дәүләт җыр һәм бию ансамбле.

Д. Йосыпов фотосурәте.

# ЯҢА КИТАПЛАР

**Tatar literature today** (Бүгенге татар әдәбияты). — Казан: "Мәгариф" нәшр., 1998. — 160 б.




Татар ПЕН-үзәгенең "Мәгариф" нәшрияты белән берлектә әзерләнгән бу китап 65 нче Бөтендөнья язучылар конгрессы (сентябрь, 1998) алдыннан инглиз телендә нәшер ителде. Ул — бүген исән язучыларның, шагыйрьләрнең, драматург һәм публицистларның әсәрләреннән торган җыйнак кына антология булып чыккан. 32 авторның (Г. Бәширов, Ә. Еники, Г. Ахунов, М. Юныс, М. Хәбибуллин, А. Гыйләҗев, Ш. Галиев, Н. Фәттах, И. Юзиев, Т. Миннуллин, Ф. Яруллин, Р. Фәйзуллин, Р. Харис, Г. Рәхим, Х. Әюпов, Р. Мөхәммәдиев, Батулла, З. Хәким, Р. Зәйдулла һ. б.) иҗат үрнәкләре тупланган. Җыен-тык хәзерге татар милли әдәбияты һәм аның тарихи чыганаклары хакында Р. Мостафинның кереш мәкаләсе белән ачыла, ә соңгы битләре исә М. Госмановның Татарстан һәм гомумән татар иле турындагы әтрафлы язмасы белән тәмамлана. Бу китап, бер яктан ПЕН-үзәгенең эшчәнлеген чагылдырган бер факт булса, икенчедән, бүгенге татар әдәбиятын бөтендөнья җәмәгатьчелегенә белдертү акциясе булып тора.

Мансур ВӘЛИ. **Тукайлар рухы**. — Казан: Татар. кит. нәшр., 1998. — 286 б. Тиражы — 1000 данә.




Китап ике кисәктән тора: баш бирмәс шәхесләр белән әңгәмәләр, "Идел" өчен көрәш сәхифәләре. Беренче бүлекне авторның Ә. Еники, И. Нуруллин, Н. Фәттах, А. Гыйләҗев, Ф. Бәйрәмова, Р. Батулла, М. Әгъләмов, А. Хәлим, Ф. Батталлар белән бүгенге заманның һәм әдәбиятның актуаль мәсьәләләренә багышланган әңгәмәләре тәшкил итә. Алар үз вакытында (1991 — 1994) журналыбызда дөнья күргәннәр иде инде. Икенче бүлектә яшьләр журналы "Идел"не чыгару өчен барган көрәш (журналның 1 саны 1989 елның июлендә дөнья күрде) бәян ителә. Соңгы кисәк "Бунтарьлар оясында", "Үзебезнекеләрне ...җиңү", "Көрәшкә Табиев кушыла", "Суслов һәм башкалар", "Мин — Үзәк Комитетта" һ. б. бүлекләрдән тора.

Китапның редакторы — Н. Вәлитова, рәссамы — Э. Егоров.

Индекс 73210



Шагыйрь Мансур Шиһапов

КАЗАН УТЛАРЫ
QAZAN UTLARЬ
ОГНИ КАЗАНИ

Ежемесячный литературно-художественный
и общественно-политический журнал
(на татарском языке)